ISSN 0206-941

# КАЗАН УТЛАРЫ

12. 1991





# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
ТАТАРСТАН ССРның ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**1991**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ф. ЛАТЫЙФИ. Хыянәт. Роман ... 3
С. КУДАШ. Бер саплам җеп. Шигырьләр ... 79
К. ЛАТЫЙП. Шигъри газап. Шигырьләр ... 81
Б. РӘХИМОВА. Кояшка күтәрик. Шигырьләр ... 84
Р. КУТУЙ. Бер дә бер көзне. Повесть ... 87
Ә. ГАДЕЛ. Хат. Шигырьләр ... 113
Н. ХИСАМОВ. Дуртьюллыклар ... 116
И. ӘХСӘНОВ. Җирәбә. Шигырьләр ... 119
Ю. ӘМИНОВ. Кунактан кайтканда. Хикәя ... 121

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Р. СОЛНЦЕВ. Төнге сорау. Шигырьләр ... 133
Ю. СВИРКА. Яфракларны коеп йөри көзен... Шигырьләр ... 135
М. СЕНИЭЛЬ. Төнге теләкләр. Шигырьләр ... 136

ПУБЛИЦИСТИКА

В. ЮНЫСОВ. Ибраһим Гарәп чәйханәсе ... 137

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. ГУБАРЬ. «Без бер күкнең йолдызлары» ... 147
Ә. БАЯНОВ. Ихласлык (Г. Әпсәләмовның туына 80 ел тулуга карата) ... 152
Аның җылы карашы (Сибгат Хәкимнең туына 80 ел) ... 157
Р. ГАТАШ. Өлкән дус — яхшы кеше турында (Шагыйрь Зәки Нурига 70 яшь) ... 162

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН, Р. МӨХӘММӘТДИНОВА. Англия журналы татарлар турында ... 164
Р. МӨХӘММӘТДИНЕВ. Татар мәдәниятендә яңарыш ... 169
Ш. АБИЛОВ. Низаминың үлемсез иҗаты ... 173
Ә. СИНУГЫЛ. Бер мираска — ике караш ... 176

*Баш мөхәррир*

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН**

*Редколлегия*

**ГАРИФ АХУНОВ**
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ФЛУС ЛАТЫЙФИ**
*(җаваплы сәркәтип)*
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**МАРАТ МӨЛЕКОВ**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РАШАТ НИЗАМИЕВ**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**ГӘРӘЙ РӘХИМ**
**КОЯШ ТИМБИКОВА**
*(бүлек мөхәррире)*
**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ**
*(бүлек мөхәррире)*
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

Р. МӘРДАНОВ. «Әл-ислах» газетасында әдәби мәсьәләләр ........ 179

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. БӘШИР. Хушлашырга ашыкма ........ 183

«Казан утлары»нда 1991 елда чыккан әсәрләр исемлеге ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Ф. ЛАТЫЙФИ «Измена», повесть Р. КУТУЯ «Одна осень», рассказ Ю. АМИНОВА «Возвращаясь с гостей»; стихи С. КУДАША, К. ЛАТЫЙПА, Б. РАХИМОВОЙ, А. ГАДЕЛЯ, И. ХИСАМОВА, И. АХСАНОВА.
«Песня друзей»: стихи Р. СОЛНЦЕВА, Ю. СВИРКИ, М. СЕНИЭЛЯ.
«Публицистика»: В. ЮНУСОВ. «Чайхана Ибрагима Гарапа».
«Литературная критика»: А. ГУБАРЬ. «Мы звезды одного неба», А. БАЯНОВ. «Искренность», письма Сибгата Хакима (к 80-летию). Р. ГАТАШ «О старшем, добром друге».
«К истории культуры»: Я. АБДУЛЛИН, Р. МУХАММАТДИНОВА «Журнал Англии о татарах», статья Р. МУХАММАТДИНОВА «Новаторство в татарской культуре». Ш. АБИЛОВ. «Бессмертное творчество Низами». А. СИНУГЫЛ. «Два взгляда на одно наследие», статья Р. МАРДАНОВА «Проблемы литературы в газете «Әл-ислах».
«Книжное обозрение»: Ф. БАШИР рецензирует новую книгу Ф. Сафина.
Список произведений, опубликованных в 1991 году.
На наших обложках: старинные сафьяновые туфли — образец татарской кожаной мозаики; известный поэт М. Хусаин.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 15.10.1991 ел. Басарга кул куелды 27.11.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тираж 38544. Заказ И-479. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

Флүс Латыйфи

# ХЫЯНӘТ

РОМАН

## Билгесез көндәшләр

Казан каласы таш кала,
Күп калага баш кала...

Халык җыры



Балта осталары төшкә кадәр ялга туктамый эшләде. Казан ашыгырга кушкан. Каты куллы Сафагәрәй ханның үз авызыннан чыккан фәрман көне-сәгате белән Иделнең өске агымындагы ерак Саклаубашка да килеп җиткән иде.

Саклаубашы дигәнебез Казан мәмләкәтенең төньяк-көнбатыш чикләрендә гаскәриләр саклый торган соңгы кизләү иде. Моннан ары кеше аягы басмаган калын урманнар башлана. Аларның иясе юк диярлек. Анда-санда сибелгән чирмеш авылларында халык аз. Җир җитәрлек. Казан дәүләте казнасына хәлләреннән килгәнчә ясак түләп, тыныч кына яшәп яткан мари кабиләләре гомер бакый татарга тартылды, дус булды, Казанга сыенды. Алар үзләрен Казан иле кешеләре саный. Киң күңелле, тиз ышанучан һәм садә холыклы бу кабиләләргә яннарында коралллы, көчле гаскәр тупланган олуг кала, ныклы кирмән кирәк. Казан исә алар өчен һәнүз шул вазифаны үтәп килде: баскыннардан саклаучы калкан да булды, дошман явы узынса, сыеныр урын да биреп килде.

Сафагәрәйне урман кешеләре шикләндерми, алар артында күтәрелеп килүче тәртипсез, сугышчан, дуамал башка кабиләләр — Мәскәүгә тез чүктерелеп сындырылган урыс кенәзлекләре борчый. Саклаубашы аларның хәрәкәтен чамалау өчен куелган иде.

Кояш нәкъ баш очына күтәрелеп, күләгәләр аяк астына кереп югалгач кына Шәһит осталарга туктарга ишарәләде. Соңгы бүрәнәләрне каезлап, киртләп һәм ырмау салып килгән балтачылар теләр-теләмәс кенә эшләреннән аерылды. Ул аларга киекне куып җиткән ау этенә туктарга кушкан боерык шикелле тоелды. Шулай да яшь бинең ишарәсен санга сукмауны яхшысынмадылар. Гаскәр башы итеп җибәрелгән егетнең холкын белмиләр,

---

Ахыры. Башы 11 санда.

әмма тоткан җиреннән сындыручан кырыс Мәмәт би углы икәнлеген ишеткәннәр, аннан бераз гына шикләнәләр иде.

Ашчылар табак-савыт шалтыраткан арада акрын гына гәп куерды:

— Җилле чыкты бу. Элеккесеннән егерме терсәкләп биегрәк булыр, ахры,— диде арадан берсе.

— Үлчәнгән, чамаланган инде... Һәр карышы кәгазьгә төшерелгән. Аны фараз итеп утырасы юк,— дип белдекләлегән күрсәтте икенчесе.

— Дөрес чамалаганнар. Өстәге мәйданчыктан бөтен дөнья уч төбендәгедәй күренә...

— Монда озакка сузып, сырт кыздырып ятудан файда чыкмас. Тизрәк бетерик тә... Әле калада күпме эш көтә. Башланган да ташланган, дигәндәй...

— Борчылма... Башланган эш — беткән эш, дигән бабайлар. Алар белми сөйләмәс.

Бер читтәрәк утырган укчы-мәргәннәр осталар сүзенә катышмады. Күрәсең, һәркайсының үз уе бар иде.

Ашчылар табак тутырып ит китерде, казаннан агач җамаякларга шулпа чумырды. Учак янындагы бүрәнәләргә түгәрәк ясап утырдылар. Барысы да тынып калды. Гадәт буенча, дәрәҗә буенча аш янында беренче сүзне картлар әйтергә тиеш иде. Әмма өлкәннәрдән берәү дә тел кыймылдатмады, алар гаскәр башы, димәк, аларга да баш итеп тәгаенләнгән Мәмәт би оланының рөхсәтен, аның ишарәсен көттеләр. Кырыс морза нәселе монда да үзенекен итми калмас, аксөяк баласы үзеннән узып эндәшкәнне яратмас, дип кыенсыналар иде, күрәсең.

Шәһит шунда гына үзеннән нәрсә көткәнлекләрен аңлап алды, ирексездән кызарынып куйды. Уйларына бирелеп, йола гадәтен үтәми калган икән ләбаса.

— Алты көн ач булсаң да, ата гадәтен җуйма. Йәгез, аштан олы булып булмас, утырышыйк,— диде ул, ниһаять, һәм балтачылар арасында иң өлкән картка туп-туры карап әйтте:— И ага, арабызда хөрмәткә лаек аксакал сиңдер... Табын башы булып, тәгам җыюны ил-көнгә иминлек, бәхет теләүдән башласаң иде.

Шәһит тезләрен чәнчеп уртак табын янына чүгәләде. Аның ни кыласын, кемгә нинди мөнәсәбәт күрсәтәсен каш астыннан гына күзәтеп утырган, табыннан аерылып үзенә аерым тәгам китертер дип көткән осталар җиңел сулап куйды: Мәмәт би олан үзен зурга куймый, һаваланмый, гади балтачылар белән дә, укчы-мәргәннәр белән дә тиң күреп сөйләшә, аралаша белә иде. Яшь морзага эчтән генә бәхет-тәүфикъ теләделәр. Тышкы кабыгы гына түгел, егетнең әхлагы-тәртибе дә шактый ук чибәр икән.

Ниһаять, түбә такталарына соңгы кадак кагылды. Җирдән кеше буе чамасы биеклектә чыгып торган борынгы таш нигезгә бурап күтәрелгән манара, биегәйгән саен нечкәреп, ярымайлы очы белән күккә барып тоташты кебек. Һәрхәлдә, астан караганда шулай күренә, тотып тормасаң, баш киемең төшеп китәрлек иде.

Осталар ашыкмый гына җиргә төште, балта, чүкеч, кадак ише нәрсәләр тутырган әрҗәне куеп, өсләренә ябышкан йомычка, пычкы чүбен каккаладылар, сүзсез генә Шәһиттән мактау сүзе көттеләр. Аларның үз эшләреннән канәгатьлеге йөзләренә чыккан иде. Күзәтү манарасы, чыннан да, пыклы, тотрыклы, шуның өстенә матур һәм күренекле дә иде. Шомартылган, шыңгырдап торган сап-сары нарат ниргәләр берсе өстенә берсе шулкадәр төгәл һәм ипле ятты, алар тоташкан урынга кыеклап ябылган түбә такталары шул хәтле килешле иде, Шәһит ирексездән телен шартлатып куйды һәм корылманы бәбәй итәкле күлмәк кигән зифа кызга охшатып, үзалдына елмайды. Әллә нишләп күз алдына Гөлйөзем килде. Әйтерсең, тирә-якка сагыз исе, чиста агач исе таратып утырган яңа манара Гөлйөземне сынландыра иде. Елмаюын тыя алмыйча, алан читенә таба атлады һәм ерактан шактый озак сокланып карап торды, күңелен рәхәт бер тойгы биләп алды: Сафәгәрәй ханның боерыгы вакытында үтәлде.

Осталар аны котәләр иде. Шәһит биленә аскан күн букчадан бер янчык тәңкә тартып чыгарды һәм, авырлыгын чамалагандай учында биетеп алгач, карт остага эндәште:

— Ил агалары! Олуг йомышны авырсынмый, тиз, кирәгенчә эшли белдегез. Сафагәрәй хан галиҗәнабләренең шәхсән рәхмәтенә лаексыз дип беләм,— дип, янчыкны сузды.—Хәләл өлешегезгә карап, тиеренчә бүлешерсез...

Осталар бер-берсенә карап алды. Юк! Бу Мәмәт би угланы олыны олы, кечене кече итә белә торган затлардан икән. Аллаһы тәгалә гамәлләрен уң кылсын!—Аларның күзләреннән шундый фикерне укып булыр иде.

Шәһит озак юанмады, бил каешын рәтләп куйды да манарага ашыкты. Баштарак текә баскычтан йөгерә-чаба атласа да, биеклек үзенекен итте, соңгы араталарны үткәндә аяк буыннары шактый йомшаган иде инде.

Иң өстәге мәйданчыкка менде дә тирә-яктагы матурлыктан, тел белән әйтеп, каләм белән язып бетергесез гүзәллектән телсез калды. Әнә, еракеракта бормаланып аккан киң Идел, елга аръягындагы күе кара урманнар... Әле тау-тау булып калкып, әле төшеп югалган яшел киңлекләр!.. Шушы мизгелдә Шәһит үзен лачынга охшатып куйды. Алар, әнә ич, болытлар белән ярыша-ярыша зәңгәр күктә тавышсыз гына йөзәләр. Күккә караганда ул үзен дә шул болытларга каршы очкандай, талпынып йөзгәндәй хис итте.

Кулын маңгаена куеп кояш чыгыш ягына борылды һәм яңа матурлыктан тагын йөрәге ашкынды, бөтен барлыгын шатлык, сөенеч хисе биләп алды. Күз күреме ераклыкта нәкъ җеп сузып турылагандай бер сызыкта шундый ук биек манаралар тезелеп киткән иде. Аларның ерактагыларын күз белән күреп, аерып та булмый. Ләкин Шәһит белә, алар калкулыктан калкулыкка сикерә-сикерә шулай ил үзәгенә—пайтәхеткә кадәр җитәләр. Боларның ни-нәрсә икәнен кара халык белми. Белмәүләре әйбәт. Дәүләтнең бөтен кешегә таратырга ярамаган үз серләре була. Аларны никадәр азрак даирә белсә, шулкадәр яхшырак.

Шәһит юл букчасыннан ерактан күрсәтүче көпшә алды да күзләренә куеп, манараларны санарга кереште. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау... Хәтта коралланган күз белән дә инде җиденче манараны аеру мөмкин түгел иде. Анысы ерακта, бик еракта... Казан юлы өстендә. Озакламый аларын да корып бетерерләр, биектәге мәйданчыкларга күзәтчеләр менеп утырыр һәм... дәүләтнең ерак чикләрендә ни эшләнеп ятуы көне-сәгате белән хан сараендагы күзәтче бигә мәгълүм булыр. Дөрес, хәбәрләрнең ничек тапшырылуын якынча белсә дә, Шәһит күзәтчеләрнең сәер хәрәкәтләренең мәгънәсен аңламый иде. Аларны башкалардан аерып, яшереп әзерлиләр. Серне чишкән күзәтче—хаин! Аны дар агачы көтә. Мондый куркыныч серне белгәннән белмәгәнең хәерле.

Шәһит тагын үзалдына елмаеп куйды, аның бүген кәефе күтәренке иде. Эш тәмам! Иртәгә алмаш киләсе... Аннан Казанга. Анда барысы да аңлашылыр, хәл ителер. Гөлйөзем генә үз сүзен әйтсен!.. Шәһит аның уңай җавап бирәсенә өметләнә, ышана иде. Моңарчы Шәһит Мәмәт углы Мәмәт бигә каршы төшүче, кире җавап бирүче юк иде. Төнге мажара исә бер аңлашылмаучылык кына...

Шунда Шәһитнең язмышын багып карыйсы килеп китте. Кесәсеннән тәңкәнең зуррагын аралап алды да икеләнеп туктап калды. Бер ягына «Котлы булсын яңа пул[1]» дип язылган, икенче ягына киереп тарттырылган җәягә куелган ук сурәте төшерелгән, әле күптән түгел генә сугылган зур көмеш тәңкә иде ул. Аны әйләндергәләп торды, әгәр тәңкә кирәгенчә төшмәсә дигән уйдан арынырга теләгәндәй, башын чайкап һәм үзенең шикчел адәмгә әйләнә башлавына көлемсерәп, чөеп тә җибәрде. «Тамгалы ягы өскә чыкса—Гөлйөзем риза, язулы ягы белән төшсә—шикләрем рас килер!» Манара түбәсе астында зырылдап әйләнгән акчага карап шуларны уйлап өлгерде. Тәңкә зыңлап килеп төште дә түр почмакка тәгәрәде һәм... бөтенләй көтмәгәнчә, идән ярыгына кысылып, басып калды.

---

1 Пул — акча.

Тәңкә чөюнең уен гына икәнен белсә дә, Шәһит үзе өчен начар фал күрде. Йөзе җыерылды, ирен читләре белән елмаеп куйды. Каһәр суккан бу акча, аңа буйсынмыйча, ни әйтергә тели икән соң? Язмышның башкалар ихтыярында, алар хөкеменә буйсынырга мәҗбүрсең димәкчеме?! А-а... юк! Юк инде! Мәргән[1] буларак Бөек ханга, диванга баш орсам да, мәхәббәттә, көн күрешемдә мин ирекле! Ничек телим, шулай хәл итәрмен дә...

Тик, күңелендәге икеләнү, шик, барыбер, кимемәде. Ул тәңкәне ярыктан алып тагын чөеп җибәрде. Язмышны, гадәттә, өч тапкыр сыныйлар. Көмеш тәңкә чыңлап идәнгә төште, бер урында зырлап әйләнде һәм ничек ятарга белмәгәндәй алпан-тилпән килеп торгач, лапылдап ауды. Ашыгып идәнгә чүгәләгән Шәһит алдында аны үртәгәндәй «Котлы булсын яңа пул» дигән сүзләр ярылып ята иде.

Тәңкә аңа киләчәген әйтергә теләми. Һәрхәлдә, ул теләгәнне күрсәтми иде. Шәһит акчаны кесәсенә яшерде. Өченче тапкыр сынап карау теләге сүрелгән иде инде.

Шулчак балта осталары, укчыларның астан карап торулары исенә төште. Гаскәр башының бала-чага шикелле акча чөеп уйнавын алар нәрсәгә юрар?! Битенә куе кызыллык йөгерде һәм ул «Таптың вакытын, хөрмәтле Шәһит би»,— дип, үз-үзен мыскыллый-мыскыллый аска төбәлде. Бәхетенә, андагылар һәркайсы үз эше белән мәшгуль иде.

Осталар манара янәшәсендә күтәреләчәк йортның беренче ниргәләрен салып ята, гаскәриләр исә учак янында... Кайсы кылычын чарлый, кайсысы ат дирбияләрен җайлаштыра. Аланның аргы башында тышаулап җибәрелгән чаптарлар утлап йөри. Гадәти күренештән Шәһитнең күңеле тынычланды, әле яңа гына сабый балаларча шөбһәләнүен онытып, яңадан хыялга бирелде. Озакламый бөтен каралтылар төзелеп бетәр, осталарның кайсысы Казанга, кайсысы үз авылына, каласына юл тотар. Монда исә күзәтчеләр һәм укчылар гына калыр. Җәй буе аларны саклап, айга бер алышынып торырлар... Кыш көне бөтен тирә-як ап-ак карга күмелер. Адашкан аучылар, төн ягыннан кайтучы сәүдәгәрләр, киреәксә, йортка кереп кунак булыр, хәл җыяр... Табигать йокыга талган кебек, кыш көне дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр сүлпәнләнә, ызгыш-тарткалаш бетә. Казан йортка тамгысын сузучылар да кышын юлга чыкмый... Зәһәр кышның үз кануннары...

Шәһит җиргә төшәргә әзерләнде һәм очар кошлар биеклегеннән тагын бер кат әйләнә-тирәгә күз салды. Аның бу матурлыктан, хозурлыктан аерыласы килми иде. Әнә, Идел ягыннан, бер-берсе белән узышкандай, каурый болытлар агыла. Каралҗымланып торган калын урманнар өстендә җил уйный, агач башлары талпына...

— Шәһри Казан җиһан гөшә!— дип куйды Шәһит кинәт кенә хискә бирелеп. Аның шушы матурлык, шушы киңлек, хөрлек, соклану, ярату хакында җыр чыгарасы, күкрәк тутырып, дөньяны яңгыратып җырлыйсы килә башлады. Кайчан гына «Тапканнар кара урман уртасында саклаубаш куярга!? Кайсы зирәгенең башы җиткән»,— дип эчтән сукранганы исенә төште. Юк! Манара нәкъ кирәк җирдә икән. Әнә ич, Иделе дә, сәүдә кәрваннары салган олы юл да аерымачык күренеп тора. Манараны исә куе ябалдашлар томалый, аны чит-ятлар күзеннән яшереп тора. Әйе, барысы да уйланган, җиренә җиткереп әзерләнгән иде.

Кинәт аның игътибарын бер көтү саескан җәлеп итте. Кошлар, әйтерсең, кемнедер озатып килә, каен башлары өстендә чыркылдашып, агачтан агачка куналар. Әнә, астарак куак ботаклары да селкенде түгелме? Озак та үтми, Идел ягыннан бормаланып-бормаланып сузылган тар юлда аркасына биштәр аскан сыңар җәяүле күренде. Көпшәсен күзләренә куеп карады: үзе белән бер яшьләр чамасы егет. Юллардан, авыллардан читтәге урманда нишләп йөри бу? Нинди максат, нинди кайгы, ни йомыш куа бу мәхлукны?! Әллә бер-бер яшерен ниятле шымчы-фәләнме?

Шәһит баскычка ташланды.

---

[1] Мәргән — бу дәвердә гомерен гаскәрилеккә багышлаган кеше.

— Тукта! Кем килә?

Ике яктагы ике куак артыннан каршына чыгып баскан кораллы кешеләрне күреп, юлаучы егет бер генә мизгелгә каушап калды, әмма артка чигенмәде. Сакчылар, сөңгеләрен аның күкрәгенә төбәп, сорауны кабатлады:

— Син кем? Кайдан киләсең, кая юл тотасың?

Кораллыларның шаяртмавын төшендә булса кирәк, егетнең йөзеннән елмаю качты, кулын күкрәгенә куеп баш иде:

— Мин Казанга юл тотучы мөсафирмын... Сезгә балыкчы карттан сәлам алып килдем,— диде.

Таныш исемне ишеткән сакчылар сөңгеләрен төшерсәләр дә, ышанып җитмәделәр булса кирәк, тагын сорау бирделәр:

— Нишләп үзе килмәде? Аны каян беләсең?

Юлаучы җиңел сулап куйды һәм ашыгып тезәргә кереште:

— А-ай... сөйләргә озак аны... Ул мине үлемнән коткарды... Идел төбеннән тартып чыгарды...

Сакчылар бер-берсенә карашып алдылар һәм кул ишарәсе белән егетне туктатып алан уртасына, Шәһит би янына әйдәделәр.

Киң аланга, тирә-яктагы кешеләргә күз йөгертеп өлгергән Санька инде күптән мондагыларның башлыгын тәгаенләп алган иде. Өс-башы, затлы кораллары белән дә, кыяфәтендәге бәйсезлек, буй-сынындагы төзлек белән дә иптәшләреннән аерылып торган яшь егет аңа беренче күрүдә үк кай ягы беләндер ошады, аның үзенә зыян салмасына ышанды. Мондый ачык карашлы, бәйсез кешеләр, гадәттә, үчле булмый, кирәксез золымга бармый.

Аркасындагы биштәрне ычкындырды да егет каршына куйды, иелеп баш иде, кулын күкрәгенә куеп, тагын сакчыларга әйткәнне кабатлады:

— И мөхтәрәм гаскәрбашы... Сезләргә балыкчы карттан сәлам күндерәм, аның әманәтен тапшырам,— диде.— Мин сезнең хөкемегездәмен. Әмерегезне көтәм,— дип тә өстәде.

— Сәламеңне кабул кылдым, кем... мөсафир! Күчтәнәчең өчен рәхмәтен алла кабул кылсын. Үзең кемсең, кая барасың? Олы юллардан читтә, адәм аягы басмаган якларга нинди җилләр ташлады?— дип сорады яшь морза аны баштанаяк күздән кичереп.

Кием-салымына карап фикер йөрткәндә дөньяның бер фәкыйре тоелса да, Шәһит юлаучының йөзендә, сүз сөрешендә аксөякләргә хас чалымнар тоеп алды. Хәер, теткәләнеп беткән өс-башы да кайчандыр шактый затлы, кыйммәтле малдан тегелгәнлеген кычкырып тора иде. Ул соальләренә җавап көтеп егетнең күзләренә туп-туры карады: аларда яшерену-посу, икейөзлелек күренмиме? Әмма җете куе төстәге зәңгәр күзләрдә яшьләрчә турылык һәм гади кызыксынудан, дусларча елмаюдан башканы тапмады кебек. «Хәерле булсын! Бу да алла бәндәсе. Башына төшмәсә, ул да киндер капчык асып ялгызы юлга чыкмас иде»,— дип уйлап куйды.

Мөсафир ашыкмый гына сөйли башлады:

— Сөйләсәң бик озакка китәр, хөрмәтле гаскәрбашы... Үзем мин Казан ярминкәсенә килгән бер урыс сәүдәгәренең улы идем... Иделдә батып үлгән идем... Күрәсең, җыясы ризыкларым бетмәгәндер, караңгы чоңгылдан мине балыкчы карт тартып чыгарды, ул миңа яңадан җан өрде. Инде теләгем кире Казанга кайту. Бәлки, мәрхәмәт күрсәтеп, мине дә юл уңаеннан үзегез белән алмассызмы дип өмет итәм... Миңа Казанга кайтырга кирәк! Бик кирәк!..

Аның җавабыннан Шәһит тулаем разый калды, әмма сизенде: бу егет беренче карашка садә күренсә дә, артык беркатлы түгел, нәрсәнедер әйтеп бетерми, йөрәгендә нindидер сере, беренче очраган кешегә үк тотып селкергә ярамаган нindидер яшерен уе бар кебек иде. Шулай да шикләнгәнен йөзенә чыгармаска тырышты, тагын сорау бирде:

— Атыңны кем дип белик?

— Исемем Александр. Сәүдәгәрләр токымыннан...

— Анысын ишеттек,— дип бүлдерде Шәһит.— Казанда ни йомышың бар? Нинди кайгы сине янә пайтәхеткә куа? Югалткан малыңны эзлисеңме, аерылган юлдашларыңнымы?

Юлаучының керфекләре сизелер-сизелмәс дерелдәп куйды, битенә балаларча алсулык йөгерде.

— Юк, хөрмәтле гаскәрбашы, мине мал кайгысы йөртми, җан газабы куа,— диде ул, ниһаять, үзе өчен нәрсәнедер хәл иткәндәй кискенлек белән.— Казанда минем мәгъшукам, сөйгән ярым калды. Аның янына ашыгам, аны күрергә тилмерәм...

Шәһит эчтән генә көлемсерәп куйды. Ләйләсен эзләгән Мәҗнүн шикелле каршылыкларны, киртәләрне үтеп сөйгәне янына ашкынуын хуплап баш селкеде, ирексездән үзен аның белән чагыштырып карады. Хөрмәткә, ихтирамга лаек егет икән бу. Теле исә башканы әйтте:

— Сөйләгәнеңне хуп күрдек! Осталар янында чатырда урын табылыр. Кыенсынмасаң, башыңнан кичкәннәрне әле бәян итәрсең, мәрхәмәтле тыңлаучың булырбыз,— диде. Аның мәхәббәт кыйссасы ишетәсе, егетнең ничек шушы хәлләргә төшүен беләсе килеп китте.

Әмма сүзне дәвам итә алмадылар. Казан ягындагы сукмакта ат тояклары дөпелдәде, сакчылар бердән ук-җәягә тотынды, өч-дүрт мәргән тышаулаган атлар янына йөгерде. Шәһит морза да тәхеттәгечә җайлап утырган бүкәненнән сикереп торды һәм ашыгып сукмак ягына китеп барды. Аланда тынлык урнашты.

Күп тә үтмәде, агачлар арасыннан томырылып ялгыз җайдак килеп керде, тезгенен кинәт тартып атны арт аякларына чүктерде һәм Шәһит каршына атасының йомышчысы сикереп төште. Гелән-гелән асылзадәләр арасында буталып, бәкләр, морзалар итагатенең йола-гадәтләрен үзләштереп бетергән чая егет бөтен шартын китереп сәлам бирде:

— Олуг морзадан кечек морзага ашыгыч хат китердем, кабул кылып алсаңчы, Шәһит би,— дип аланны яңгыратты.

Аның кыланышында атасының гадәтләрен таныды Шәһит һәм, ирексездән, көлеп җибәрде. Бары тик аның атасы гына, әнә шулай, теләсә кая бәреп кереп үзенекен ярып салырга мөмкин. Баһадир гәүдәле әтисе — тыштан аюдай тупас күренсә дә, нечкә, саф күңелле кеше, ул сабый баладай куана, шатлана белә, читләр кайгысын үзенекедәй авыр кичерә, ярдәм кулын сузарга тырыша. Ә инде ачуы чыкса, аннан мәрхәмәт көтмә. Аяк атлаган саен җир тетрәп калгандай булыр, тынычланганчы үзенә урын таба алмый бәргәләнер. Шундый кеше ул!

Әтисен искә төшереп, Шәһит үзе дә шундый ук көр тавыш белән кычкырып җавап бирде:

— Булдыргансың, рәхмәт сиңа, углан! Хатыңны бир дә ял ит. Әй, ашчылар! Мәмәт би йомышчысына тәгам китерегез!..

Үзе исә бераз читкәрәк китеп көпшәләп төрелгән кәгазьнең башындагы мөһерне ватты да, таныш кулдан язылган йөгерек юлларга текәлде. Шулкадәр ашыгырлык нәрсә бар икән! Борчакны артык тиз куырырга яратучы әтисе тагын нинди шөгыль, нинди йомыш уйлап тапкан?!

«Алмаш килүгә, күзеңне дүрт итеп Казанга чабасыңны белем мин.— Беренче юллардан ук әтисен таныды Шәһит. Менә шулай кереш сүзсез-нисез бары тик ул гына яза ала.— Карт атаңны санга сукмаска чамалыйсың. Ашыкма! Әле минем йодрыгым нык, көчем җитәрлек, сине генә бөгәр чамам бар... Әмерем шундый: хатны алуга туры өйгә, Казандагысына түгел, төп утарга — Мәмәт би утарына чабасың. Җир ярылса да, күк ишелсә дә кайтасың. Сүзем шул. Шунсыз миннән мәрхәмәт көтмә».

Хатның ахырында, күрәсең, миһербаны уянган, ваграк хәрефләр белән өстәп куйган иде: «Күптин күп, чуктин чук сәламнәр күндереп, әтиең Мәмәт Сәүбан углы Мәмәт би».

Тизрәк кайтырга кирәклеген аңласа да, Шәһит хаттан моның сәбәбен сиздерүче бүтән бернәрсә дә таба алмады. Бу исә аның корган уй-фикерләрен, тизрәк Казанга эләгү өметен челпәрәмә китерә иде. Дуамал чагына юлыксаң, үзсүзле Мәмәт бидән тиз генә котылырмын димә... Укчылар арасында теленә салынган йомышчыны дәште.

— Дөресен әйт әле, утарда ни бар? Бер-бер хәл сизмәдеңме? Әти нигә шулай ут өерттереп чакыра икән?!

Йомышчының күзләре генә елтырады. Кирәкмәс чакта теленә шайтан төкергәндәй кыланучы үткен егет инсәләрен җыерды. Карт морзаның аны ни өчен шулкадәр якын итүен, үз күрүен хәзер генә аңлап алды Шәһит. Моннан кирәкмәс сүзне келәшчә белән каерып та ала алмассың.

Шулай да, яшь морзаның гозерен аяк астына салмады, аз гына җеп очын чыгарды йомышчы:

— Төгәл белмим,— диде.— Якыннары белән Дәүран би килеп төште. Сиңа йомышлары бардырмы...

Аның хәйләкәр кысылган күзләреннән аңлады Шәһит, белә, белә бу таш ярып чыккан углан. Әмма әйтми. Әйтмәячәк тә... Атасының холкын үзләштергән йомышчы кирәк чакта тимер йозакка әйләнә белә иде шул.

Кич буе баш ватты Шәһит, әмма борчылырлык сәбәп күрмәде. Мөгаен, атасы мәмләкәтнең көньяк вилаятеннән — Нугай дәругасыннан килгән дусты Дәүран би хөрмәтенә мәҗлес җыя. Кайтып күренмичә ярамас. Карт морза мондый мәсьәләләрдә бик чәүчәләк, нәзбереклек саклый һәм йола бозуны һич кенә дә күтәрә алмый.

• • •

Атларны тыймадылар. Алмаш соңлабрак килгәнлектән, төш алдыннан гына юлга чыккан гаскәр төркеме һич югы ясту алдыннан Мәмәт би утарына җитәргә чамалый иде. Шәһит шулай хәл итте. Үзе шикелле үк яшь мәргәннәрне аерып Казанга җибәрүне яхшысынмады, барысын да атасы утарына чакырды. Иш янына куш сыя дигәндәй, табын янында ун-унбиш егеткә генә урын табылыр... Аш-суны муллан әзерлиләр Мәмәт би утарында. Икенче ягын да күздә тотты Шәһит: чирү хәтле дус-ишләре белән кайтып төшсә, Казанга чыгып китү дә җиңелрәк булыр сыман иде. Һәрхәлдә, хан хезмәтендәге угылга ата кеше артык таләпчәнлек күрсәтмәс, йола кушканны үтәүгә үз иркендә калдырыр...

Чаптырып барган ат өстендә киңәеп сөйләшү, гәпләшү мөмкин түгел иде. Барысы да үз уйларына бирелде. Сәүдәгәр углы, мәгъшукасын юллап килүче Александрны берничә мәртәбә исенә төшерсә дә, Шәһит аның кыйссасын тыңларга вакыт таба алмады. Үз хәле хәл иде.

Санька исә мажарасын төпченмәүләренә, йөрәгендә сулкылдаган ачык ярага кагылмауларына, сорау биреп бимазаламауларына шат. Ышанып юлга алдылармы, алдылар; ашкынган, канатланып очардай Казанына якынаясыңмы — якынаясың! Тагын ни кирәк!? Дөрес, аның үзенең дә гаскәр башы, кай ягы беләндер мәхәббәтле Шәһит би белән сөйләшәсе, аның янәшәсендә барасы килеп куя. Ләкин бу аның ихтыярында түгел. Син — аның мәрхәмәтенә мохтаҗ юлдаш, ирексездән килеп эләккән бер сукбай. Башкасына өмет итмә! Хәер... аның кирәге дә юктыр... Казанда Санькины әле чишеп бетергесез яңа мажаралар, ерып чыккысыз башка мәшәкатьләр көтәдер... Кем белә? Барысы да алла кулында, бернәрсә дә анык кына билгеле түгел. Һәрхәлдә шуны ачык тоя: теләгәненә, алдына куйган олуг максатына ирешми торып, Санька Казаннан китмәячәк. Юл бер генә — йә җиңәсең, йә бетәсең... Ә бетәсе, олы юлда тузан булып каласы килми. Димәк, эзләргә, табарга, көрәшергә һәм җиңәргә кирәк!

Кинәт Шәһит бинең ак чаптары тирә-якны яңгыратып кешнәп җибәрде. Туып-үскән ихата якынлыгын тойган айгырның: «Уяныгыз, кайтып җитәбез»,— дип сөрән салуы иде бу. Бертуктаусыз чаптырудан арыган һәм адымнарны акрынайтуга изри башлаган укчыларның бердән йокысы качты. Алда уйнаклаган атның җанлануы башка чаптарларга да тәэсир итте, ияләренең тезген кагуын да көтмәстән, җай гына юыртырга керештеләр.

Урман авызыннан чыккан атлылар тау астындагы иңкүлектә җәйрәп яткан зур утарны, аннан арырак сибелгән эреле-ваклы йортларны күреп, бер мизгелгә туктап калдылар. Кайберләренең Мәмәт би утарын әле беренче күрүе иде һәм алар соклануларын яшерә алмадылар, баш чайкап, тел шартлатып куйдылар.

Мәмәт би утары, чыннан да, бик матур җирдә иде. Ике яклап тау кочагына сыенган иңкүлек дигәнебез тигез дала булып офыкка кадәр сузыла, анда исә күгелҗемләнеп торучы куе урманнарга тоташа. Күз күреме иңләгән һәр якта иген басулары, куе, сусыл үләнле болыннар. Алып батыр сибеп калдырган көзге кыйпылчыкларыдай ялтырап ятучы күлләр... Болар күңелдә иркенлек, киңлек тойгысы, шушы матурлыкны колачлау теләге уяталар иде.

Би утары иңкүлекнең кап уртасында, яшел дингез эчендәге утрау шикелле калкып тора. Калын бүрәнәләрдән биек коймa аңа кирмән төсе бирә; ихата эчендәге олуг таш йорт, аның тирәсендә, шулай ук бизәкләп салынган башка өйләр, биек манаралы мәчет, ныклы каралты-кура Мәмәт бинең дөнья көтү тәмен белеп яшәүчеләрдән икәнлеген күрсәтә иде. Шуның өстенә, бу кечкенә кирмәнчек һәрьяклап тирән, киң ур белән чолгап алынган, ур үзе күлгә тоташып, су белән тутырылган иде. Биек һәм калын капка алдында урны артык киң булмаган агач күпер сикереп үтә һәм ул, гадәттә, төннәрен икегә аерылып, капкага таба күтәртеп куела иде.

Шәһит тезгенен бушатты. Шуны гына көтеп торган айгыр сөзәк юлдан аска ыргылды, башка җайдаклар һай-һулап аңа иярде.

Капкадан керүгә Шәһитнең күзенә ташланганы — ихатадагы атлар, затлы арбаларның күплеге булды. Атасы, күрәсең, олыдан кубарылып нидер майтарып ята.

Тау башындагы атлыларны инде күптән шәйләп өлгергән хезмәтчеләр, кол-чуралар, кыз-кыркын ишегалдына сибелде. Кемдер атларның тезгененә ябышты, кемдер Шәһитнең кулыннан букчасын, кылыч-калканын алырга әзерләнде. Кыскасы, яшь морза кайткач була торган гадәти ыгы-зыгы башланды.

Шәһит аттан сикереп төште дә: «Төкле аягың белән Шәһит би! Аман гына йөреп кайттыңмы? Көтәбез, Мәмәт углан, күптән көтәбез», — дип сөйләнүче хезмәтчеләргә игътибар итмәстән, юл тузанын да кагып тормыйча, өйгә атлады. Бер-ике адым атларга өлгермәде, борылып әмер бирде:

— Дусларымны карагыз! Урнаштырыгыз! Аларны минем кебек үк кабул күрегез, — диде һәм арадан өлкәнрәген чакырып, колагына пышылдады: — Арабызда урыс углан Александр бардыр. Юньлерәк кием хәстәрләрсең... Атам каршында оятка калырлык булмасын!..

Кунак бүлмәсендә кеше күп түгел. Күрәсең, төшке аштан соң хатын-кыз таифәсе таянып алырга иткән. Тынгысыз атасы янында Дәүран бидән кала Шәһиткә таныш түгел, киемнәренә караганда аксөяк зат булырга тиешле тагын өчме-дүртме ир-ат утыра иде. Алар кызып-кызып нәрсә хакындадыр бәхәсләшәләр идеме, мәзәк сөйлиләр идеме, — һәрхәлдә, этисенең гөбедән чыккандай калын тавышы барысыныкын да күмеп, каплап китә иде. Ишек тавышына ярты сүздә бүленделәр. Кунакларның уңайсыз тынлыкка чумуыннан Шәһит сиземләде: сүз аның турында барган! Шулай булмаса, тып итеп килеп кергән Шәһиткә игътибар итүче дә, борылып караучы да булмас иде.

Мәмәт би табындашларына күз йөртеп алды да тавышын бөереннән чыгарып, улына ымлады:

— Бердәнбер варисым, дәвамчым Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би булыр, — диде.

Аның бу ымында горурлык та, аз гына масаю һәм мактанырга теләү дә бар иде шикелле. Янәсе, күрегез, нинди баһадир улым бар!

Шушыларны тоемлап өлгергән Шәһит үртәлде, атасының масаюыннан оялды, әмма моны кунаклар алдында сиздерергә ярамый иде, горурлыгын җиңеп, барысына берьюлы сәлам бирде:

— Исән-аман килеп җиттегезме, ил агалары! Юл авыр булмадымы? Йорт-җирегез, гаиләгез, бала-чагаларыгыз иминме? Ил-көн тынычмы?

— Шөкер, аллага шөкер, олан! Дөньяларыбыз имин, ил-көн тыныч, — диештеләр кунаклар беравыздан. Күзләре исә Шәһитне капшый иде әле.

Угланның үзләрен олылап, «ил агалары» дип эндәшүе, борынгы йолача тутырып исәнләшүе аларның күңеленә хуш килде, бер-берсенә карап елмаештылар, баш селкеделәр.

Бары тик шуннан соң гына Шәһит атасына эндәште:

— Хатынны алдым, и газиз атам. Кичер, юл киеменнән катыңа бәреп керергә ашыгыч чакыруың сәбәп булды. Әмеренне котәм...

Мәмәт би кул гына селтәде. Берни дә булмагандай тади генә әйтте:

— Бар! Әзерлән! Ярты сәгатьтән бөркетләреңне күрсәтерсең!— Табындашларыннан сорады:— Шәһит угланның мәргәннәрен карыйбызмы? Сыныйбызмы?

Аңа, күрәсең, Шәһитнең иптәшләре белән кайтуын хәбәр итеп өлгергәннәр иде инде.

Ярты гомерен иярдә үткәргән Дәүран би һәм башка кунаклар канәгать елмаешты:

— Мондый бөркетләрне дә карамасаң... Карыйк, багыйк, сыныйк. Казан-йорт язмышын шулар кулына бирәсе... Кылычлары үткенме, сыннары төзме, бәдәннәре ныкмы, гайрәтләре җитәрлекме?!

Ишегалдында мәргәннәр тезелде. Аларның байтагы Мәмәт би утарында Шәһит белән бергә аунап, тирә-яктагы урман-болыннарны бергә айкап үскән егетләр иде. Калганнары исә төркемгә Казанда гына кушылды һәм алар кыюлыгы, гайрәте белән бөтен дәүләткә танылган карт морза каршына басуларына горурлык хисләре кичерде. «Ясавыл булырга хыялланмаган мәргән — мәргән түгел». Карт морзаның канатлы сүзләре һәммәсенә дә мәгълүм иде.

Мәмәт би, аның артыннан Дәүран би, алардан бераз калышып башка кунаклар саф алдыннан үтте. Атасы риза калды, күрәсең, тамак кыргалап куйды, әмма сүз әйтмәде. Юлдан соң юынган, чистарынган, кием-салымнарын тәртипкә китереп баскан егетләр, чыннан да, матур иде, көч-гайрәтләре сизелеп тора иде. Аларның сөңге очларында кояш чагылды, калканнары берберсенә бәрелеп зыңгылдады.

Шулчак карт морза гаскәриләрдән бер адым читкәрәк баскан мөсафир егетне күреп алды. Кхы, кхы, дип ютәлләгән сыман итте, китә башлаган җиреннән кинәт әйләнеп килде, нәрсәнедер хәтерләргә теләгәндәй, ят егетне күзләре бораулады. Кунаклар белән гәпләшкән арада да Мәмәт би мөсафирга карап-карап ала иде әле.

Шәһит чит-ят егеткә аерым игътибарны сизде, әмма аның кем икәнлеген аңлатырга җае чыкмый калды. Өс-башын хезмәтче биргән киемнәргә алыштырып өлгергән мөсафирны мәргән дип уйлады, коралсызлыгына гаҗәпләнде, күрәсең, дип үзенчә нәтиҗә чыгарды Шәһит.

— Мәргән егетләр! Төз атуда көч сынашасы килгәннәр бире килсен! Җиңүчегә көмеш саплы булат хәнҗәр,— дип кычкырды морзалардан берсе.

Сафлардан таралган егетләр ук-җәяләрен тотып ашыга-ашыга аның янына җыелдылар. Мәмәт би Шәһитне үз янына чакырып алды.

— Минә инде синең белән сөйләшер чак та җитте,— диде ул улына сынап карагандай текәлеп.— Әйдә, йортка, бүлмәгә узыйк.— Олуг сүз бар сиңа, улым...

Атасы сүзне ерактан башлады.

Киң җиңле озын хөлләсенең изүен ычкындырып җибәрде дә аркалы урындыкка утырып, Шәһиткә янындагы тәбәнәк урынга күрсәтте.

— Утыр! Сүз күп булыр. Аяк өстендә сөйләшә торган түгел.

Шәһит шомлы хәбәр ишетергә әзерләнде, башыннан берьюлы әллә ничә гөман йөгереп узды: «Дәүран бигә дала баскыннары яу чапканмы? Аңа ярдәм кирәкме? Әллә юкса, атасы бер-бер яры чирү җибәрмәкчеме? Әллә соң ерак илләргә сәяхәткә юлламакчымы? Мәргәнлектән алып, ерак гарәп илләренә хаҗга чыгарырга җыенамы?» Каефе кырылган, җаны бәргәләнгән чакларда әтисе еш кына: «Хаҗ кылырга иде! Зәм-зәм сулары белән юынып, изге җирләрдә дөньялык гөнаһларыннан ваз кичәр вакыт җитте»,— дип сөйләнергә ярата. Аннан монысын да көтәргә мөмкин. Шәригать кануннары үзең өчен кем дә булса башканы җибәрү ихтималын кире какмый. Әмма Шәһитнең Казаннан беркая да китәсе килми иде һәм ул атасына да катгыян шуны белдерергә җыенды.

— Без жылкы ыруы, борынгы, бик борынгы нәсел,— дип тамак кырып, горурлангандай әйтеп куйды Мәмәт би.— Ерак бабаларың дошманга тез чүкмәде, авызы тулы кан булса да, дошманы каршында түкермәде. Якыннарына мәрхәмәтле, игелекле булды, ярлыларны, хәерче-саилчеләрне, гарипгорабаны рәнҗетмәде, авызыннан өзеп, мохтаҗларга өлеш чыгарып яшәде. Нәфесен сузган җаһил адәмнәрнең кулын кыскарта белде, кешенекен алмаган кебек, үзенекен чит-ятларга талатмады... Менә шул, улым! Боларын беләсең булыр...

Шәһит сүзсез генә башын иде. Кереш сүзнең тизрәк бетүен, атасының сузмый-тартмый төп мәсьәләгә күчүен көтә иде ул. Тик бу хакта кычкырып әйтергә теле бармады, түземен, сабырын җыеп тыңларга әзерләнде. Ишетәчәген ишетеп бетермичә, атасының ихтыярын белмичә, газиз әнкәсен күрмичә һәм фатихасын алмыйча ул барыбер утардан чыгып китә алмаячак. Һәр сәгатен, мизгелен бөртекләп санаган вакыт дигәнең аңа буйсынмый иде шул. Атасы исә сузачак, тартачак ул вакыт дигән нәрсәне!

Мәмәт би Шәһитнең кыбырсынганын әллә күрде, әллә күрмәмешкә салышты, башлагандагы вәкарен саклап, ашыкмыйча гына сөйли бирде:

— Болары белән син мактанырга хаклы.— Һәм кинәт, тавышын күтәрә төшеп, кычкырып сорады:— Ә син үзең шул нәсел мактанычын ишәйтү, көчәйтү өчен нәрсә эшләдең? Бармы бер-бер кылган гамәлең? Беләм!.. Әле син яшь, күрәчәгең дә, кылачагың да алда... Алла бөерса, изге Казан-йортта Мәмәтләр исеменә тап төшермичә, пычратмыйча көн күрерсең дип ышанам.

Бик азга гына бүлмәдә тынлык урнашты. Шәһит хәтта тышта очынып-очынып сайраучы тургай тавышларын да ишеткән кебек булды, колагына ук атуда көч сынашучы яшьтәшләренең күңелле шау-шуы килеп керде.

— Шулай, улым,— диде Мәмәт би уч төбе белән урындык тоткасына суккалап.— Без сине шул юлга кертергә карар кылдык. Шөкер! Инде балигъ егетсең. Киләчәгең, нәсел-нәсәбең хакында уйланыр вакыт җитте. Кыскасы, улым, без сине иҗабы кабул кылырга... ягъни, яраштырырга чакырдык.

Шәһитнең йөзе бер агарды, бер кызарды, күз алдын әллә нинди кара пәрдә томалап алды.

— Мин... мин... әле өйләнергә... теләмим,— диде ул, ниһаять, теленә беренче килгән сүзләрне әүшәләп.— Мин үзем... Мин... ни...

— Әйе, син... син үзең өйләнәчәксең,— дип бүлдерде карт морза.— Синең өчен мин өйләнә алмыйм лабаса!

Шушы мизгелдә язмышы хәл ителәчәгенең бөтен катгыйлыгын, билгесезлек дәһшәтен аңлап алган Шәһит кыюлыгын, батырлыгын җыеп әйтте дә салды:

— Минем сөйгәнем бар, үз дигәнем, үзем тапкан ярым бар,— диде.

Бу юлы инде Мәмәт бинең йөзе караңгыланды.

— Бардыр, ышанам! Әмма безнең чигенер юлыбыз юк,— диде ул авыр сулап. Әйтерсең, аның үзен көчләп өйләндерергә җыеналар иде.

Кызыксынуы җиңде булса кирәк, бераз тынлыктан соң, күзендә җылылык чаткысы кабынды, төз гәүдәсен алга ия төшеп, пышылдап эндәште:

— Анысы кем инде, сер булмаса? Кемне таптың икән?! Нинди нәселдән? Нинди ырудан ул синең башыңны әйләндергән гүзәл җан иясе?

— Ул... ул... алтынчылар... зәргәрләр нәселеннән. Мин... аның белән сүз куештым... Вәгъдәләштек инде... Казандагы иң маһир зәргәр Галиәкбар оста кызы,— диде Шәһит. Шушы сүзләре белән атасының күңелен йомшартырмын, морза вәгъдәсенең кадерен белгән аксөяк үз улының ант бозуына юл куймас дип өметләнә иде.

— Ыһы, ыһы,— дип куйды атасы.— Беләм, беләм ул нәселне. Безнең кадәр үк булмаса да... тирәннән, ерактан килүче ырудан. Казаяклар алар... Казаяк ыруыннан.

Шәһитнең эченә җылы йөгерде, һәр сүзен йотардай булып атасына текәлде. Карт морза башын чайкап куйды һәм кулындагы тамгалы йөзекне әйләндергәләп утыргач, кистереп әйтте:

— Юк, улым! Тамырларыңда аксөякләр каны ага. Син бары тик аксөякләргә генә өйләнә аласың!..

Шәһит үзен тыя алмады, үртәлеп кычкырып җибәрүен сизми дә калды.
— Алайса мин гомеремдә дә өйләнмим. Миңа кирәкми! Берни дә кирәкми. Өйләнмим.
Мәмәт би сүзеннән кире кайта торган кеше түгел иде. Ул улының тынычланганын үзенә хас булмаган сабырлык белән көтеп торды.
— Сабыр! Сабыр, улым! Без — җылкы, ягъни ат. Сөйгәнең исә — казаяк ыруыннан, ягъни, кош нәселеннән. Аларның тамгасы — каз. Әйе, ат казның матурлыгына, җиңеллегенә, зифалыгына сокланыр... Үзенең дә шулай җиңел талпынасы, зәңгәр күкләрдә болытлар белән ярыша-ярыша очасы килер... Әмма ат казга өйләнә аламы? Уйла, улым! Мин йодрык төеп тә тыя алган булыр идем... Иллә үзеңнең аңлавыңны, гади зәргәр — һөнәрче кызының аксөяк, асылзат, мәргән нәселенә тиң түгеллеген төшенүеңне телим. Бел, аксөяк югарырак булган саен бу мәсьәләдә тагын да югарырак очарга тиеш. Чөнки син үзең түгел, нәселең өчен уйларга, аның киләчәге хакында фикер йөртергә тиеш! Һәр адымың шулай! Һәр гамәлең күз алдында. Бүген каралар белән туганлашкан адәм иртәгә биләр арасында бер башка түбән төште дигән сүз. Хаким затлар сугыш башлый, меңнәрне яуга куа ала, кол-чураларның язмышы аның кулында... Аның бер авырлыгы бар — хаким зат үзе теләгәнгә өйләнә, үзе күзләгәнгә кияүгә чыга алмый. Әдәп, әхлак бар. Безнең үз кануннарыбыз. Тамырында Алмыш хан якыннарының каны аккан затның ул канны сыекларга хакы юк! Аңладыңмы?
Аның маңгае җыерылды, йөзе кырысланды, мыек чылгыен шактый озак бөтереп утырды. Ниһаять, авыр сулап куйды һәм улын ныграк ышандыру өчен, икеләнгәнен, күңелендә булса да, чыгарып түгәргә ашыкмаган фикерләрен әйтергә кирәк тапты:
— Шәригать кушканча ярәштерәбез. Дәүран би — җылкы ыруының иң затлы, бай адәмнәреннән... Кызын бер кашык су белән йотарлык диләр. Ике көчле тармак кушылганнан без дә, алар да отар...— Ул тамак кырып алды да улына каш астыннан карап әйтеп бетерде: — Каләме шәриф икене, өчне, хәтта дүртне алуны да фарыз саный. Аннан соң үзең карарсың... Күз күрер... Ләкин, кабатлап әйтәм, беренчесе Дәүран би кызы булыр. Асылзат булыр! Сүзем шул! Бүтән әйтмәм. Кабат сорама да, уйлама да!..
Нинди генә гаярь, үткен, чая булмасын, шәҗәрә намусын күз карасыдай саклап яшәгән гаиләдә тәрбия алган егет ул кануннарга буйсынырга кирәклеген, моның мәҗбүрилеген төшенә иде. Тик, барлы-юклы ике дистә елга да тулмаган гомерендә, аның теләгенә ирешми калганы булмады. Асыл егетнең, бердән, бүтән көндәше, тиңдәше юк; икенчедән, атасы хакына күпләр аның сүзен аяк астына салмауны хәерлерәк күрә; өченчедән, кызларныкыдай озын керфекле, янып торган кара күзле, мәнле егет ирләрчә чибәрлеге белән дә йомышы төшкәннәрне әсир итә, тәвәккәллеге белән буйсындыра иде.
Пайтәхеттә вә һәм дә мәмләкәтнең башка шәһәр-калаларында яшәүче, биләмәләреннән чыкмыйча көн күрүче биләр, морзалар тормышыннан да мәгълүматлы Шәһит моның шулай икәнлеген белә, күреп тора иде. Әмма егетлеген югалтмаган, дөньяда үз тиңең, бәхетең, мәхәббәтең бүленмәс һәм бердәнбер дип күз алдына китергән егет этисе белән килешә алмады, ачуына буылды:
— Мин... Мин нәсел айгыры түгел...
Мәмәт морза сынын тота алмыйча бөгелеп төште, кысынкы күз кабаклары арасыннан сытылып яшь бөртекләре чыкты. Ак сөлге белән битен, күзләрен сөртә-сөртә тагын нидер әйтергә теләгән иде дә, күңелен тыя алмыйча кул селтәде. Ниһаять, басыла төште, урындыкка кырын ятып, яңа гына күргәндәй, Шәһиткә тагын бер кат текәлеп карады да сер сорагандай пышылдап эндәште:
— Бәгъзе угыллар корсак асларына йон үсмәс борын кыз-кыркынның итәк астына борын төртә... Ә син... син... башлы-күзле итәм дигәндә... Хафага салма.— Кинәт ул җитдиләнеп китте.— Яшерми әйт, угылым, әллә хатын-кыз таифәсенең исен сизмисеңме? Борының ис сизмиме әллә диюем...

Шәһитнең бите бер агарды, бер кызарды. Әтисеннән мондый сүзне, ачыктан-ачык ирләрчә сөйләшүне көтмәгән иде. Гарьләнергә дә, үртәлергә дә белмәде, сүз таба алмый интекте. Ниһаять, әтисенең үртәлерлек нәрсә әйтмәвен аңлар дәрәҗәгә җитте, нигә хафалануын төшенде, тотлыга-тотлыга җавап бирде:

— Аны... анысы мин... мин үзем беләм, эти. Булачак җефетемне мин үзем табарга, үзем сайларга тели́м... Аңа гына хакым бардыр ич...

Әле генә көлүеннән буылган Мәмәт бинең йөзендәге хушлык кискен кырыслык белән алышынды.

— Мин әйттем! Нәселебез канунын боза алмыйсың! Әйе, әлегә синең хакың юк! Кемне димлибез, шуны аласың. Алачаксың!— Ул йодрыгын өстәлгә куйды һәм кинәт йомшап, килешкән сыман тагын дәвам итте:— Әнә, мин үлгәч карарсың... Анда барысы да синең кулда буласы.

Шәһит эндәшмәде. Гөлйөземнең арбада бәргәләнүе күз алдына килде, җылы сулышы колагына килеп бәрелгәндәй булды, бәдәненә тиеп киткән кайнар тәненнән әллә нинди аңлаешсыз бер рәхәтлек саркыганын янә тойгандай хис итте.

Мәмәт би исә сөйләде дә сөйләде:

— Шигемне алдың, анысына рәхмәт, Шәһит морза!

Әтисенең шулай рәсми итеп, читләтеп эндәшә торган гадәте бар. Андый чакта каршы төшү мәгънәсез. Үзенекен барыбер әйтәчәк, күңелендәгене чыгарып бетермичә туктамаячак. «Шәһит морза» дип эндәшү — аны җиткән егет, балигъ зат, олы кеше итеп тану билгесе. Әйтерсең, ике мәмләкәтнең илчесе сөйләшә. Мондый чакта эчтәгене тышка чыгармау хәерле. Илчеләр хисләрен яшерә белергә тиеш. Алар ил, дәүләт файдасы хакына шәхси мәнфәгатьләреннән баш тарта. Бу — асылзатларга, аксөякләргә генә хас шәкел. Әтисе, әнә шулай, сиздерми генә улын ачыктан-ачык, хисләргә бирелмичә сөйләшергә, аңлашырга чакыра иде. Шәһит моны аңлады, телен тешләргә мәҗбүр булды. Рәсми эндәшү аның күңеленә богау салды, ялыктыргыч булса да, кирәкле, кире каккысыз сүзләрне тыңларга әзерләде.

— Әйе! Син — нәсел айгыры,— диде Мәмәт би кистереп.— Син — минем бердәнбер углым, дәвамчым. Туталарың, сеңелләрең исәпкә керми. Минем нәселне син генә дәвам иттерә аласың. Орлыгы синдә. Белеп тор, мин нәселемнең теләсә нинди канга кушылып сыекланүын теләмим. Пычрануын теләмим. Моңа кадәр Мәмәтләр нәселе илгә-көнгә тап төшермәде. Кол-чуралар да җиде бабасын белә. Белергә тиеш! Син — Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би! Унҗиде буың бабаңны белсәң дә сиңа аз! Берсе дә йөзеңә кызыллык китермәс. Аларның җаннары сине күзәтә. Дөньялыкта кылганыңа ахирәттә җавап бирәсең, алар каршына басасың бар!

Картның тавышы карлыкты, әллә кайчангы, еракта, бик еракта калган үткәннәрне уйлап булса кирәк, карашын тәрәзәдән күренеп торучы урманнарга төбәп уйга калды.

Менә, ниһаять, Мәмәт би тәхетеннән торды да салмак адымнар белән түр башына — китап киштәләренә таба атлады. Идән сайгаклары шыгырдап куйды. Кайчандыр кызык өчен, көчен сынау өчен генә азау ярган гайрәтле аю җанварына яланкул каршы чыккан пәһлеван атасын танымады Шәһит. Аның туры, төз сыны, әйтерсең, сыгылган, аркасы бөкрәя төшкән, хәрәкәтләрендәге сыгылмалылык, җиңеллек юкка чыккан иде. Атасының инде шактый картайганлыгын беренче тапкыр тойды Шәһит. Кызгану хисе йөрәгенә сарылды, ихтыярын бәйләп куйды. «Еллар үзенекен итә... Көчкуәтенә тирә-якта тиңнәр юк кешене дә җир әнә ничек үзенә тарта, бөгә икән»,— дип уйлап куйды егет. Әтисенә ниндидер җылы сүзләр, юату хисләрен белдерәсе килеп китте. Ләкин бу мөмкин түгел иде. Хөр табигатьле, горур һәм азмы-күпме тәкәбберлектән дә мәхрүм булмаган атасы аларны күтәрә алмас, рәнҗер һәм картаюына, көчен югалтуына ишарәләү дип аңлар иде. Вакыт-вакыт теләсә нинди дуамаллыкка әзер Мәмәт би үзенә карата нинди дә булса кызгану хисен яисә төрттерүне кабул итә белми иде.

Аның уйларын сизгәндәй, Мәмәт би кинәт тураеп басты, киштәдәге төргәкләрнең берсен алып, аны бер сугуда үгез ега торган көчле кулы белән

сыйпаштырып торды һәм кискен хәрәкәт ясап борынгы кәгазьне сүтеп җибәрде. Күзләрендә яшьләрчә нур кабынды, гәүдәсенә элеккеге төзлек, җиңеллек кайтты кебек.

— Менә, кара, Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би! Синең тамырларың көчле, алар ерактан, бик ерактан килә,— диде ул тантаналы тавыш белән.— Кил, тагын бер кара, тагын бер кат алар каршында ант эч! Бүген без шушы гали затларның соңгы күзәнәкләре, соңгы буыннары...

Кинәт аның тавышы утырды, әйтерсең, тамак төбен нидер кыра иде. Карлыккан, үзгәргән тавыш Шәһит көткәнчә, элеккечә түгел иде, сүзләре дә башкача яңгырады:

— Йә, кил, улым,— диде ул баягы күтәренкелеген онытып.— Хәзер мин сиңа нәселебезнең тарихын сөйлим. Сиңа катылыгымның сәбәбен дә үзең төшенерсең... Төшенерсең, аңларсың дип беләм.

Шәһитнең күз алдында балачактан таныш сәер сурәт ачылды. Нечкә генә тамырдан чыккан күп тармаклы, куе ябалдашлы агачны хәтерләткән рәсем төрлесе-төрле якка сузылган нечкә сызыклардан һәм нәни яфракчыклардан тора иде. Һәр яфракчыкка яшел кара белән Шәһиткә таныш булмаган исемнәр язылган: Мәмәт, Кучем, Мәмәт, Латыйф, Сәүбан, тагын Мәмәт... тагын Сәүбан... Сызыклар бер-берсе белән кисешмичә, әмма асыл тамырда бергә тоташып оя-оя булып үреләләр, таралалар иде.

— Безнең нәсел агачы шушы булыр,— диде Мәмәт би шәҗәрә тамырына күрсәтеп.— Монысы олуг бабабыз Мәмәт. Борынгы Болгардан... Күренекле, көчле ырудан. Без барыбыз да аңа барып тоташабыз. Җылкы ыруының мин белгән башы шуннан килә. Шәҗәрәнең борынгырагы да булган, диләр. Анысы гарасатта юкка чыккан, янып көл булган...

Мәмәт би көрсенеп куйды.

— Ни аяныч, күпме тырышсак та, без аны инде кире таба да, яңарта да алмыйбыз. Хәтер кеше белән бергә үлә. Үлмәсен дисәң, кәгазьгә теркәп калдырырга кирәк. Инде ябалдашның очына кара... Күрәсең, агач корый бара. Җылкы ыруының асыл затлары бетүгә юл тота. Син шуны телисеңме?!

Чыннан да, куе ябалдаш өскә таба тарая-тарая килә дә, нәзек кенә чыбык очындагы яшел яфракчык белән тәмамлана иде. Аның эченә язылганны да Шәһит укып өлгерде: атасының кулы белән каты итеп «Шәһит би» дип язылган иде. Үзен шушы агачның бер яфракчыгы итеп тойган Шәһиткә әллә нәрсә булды, күңеле тулды, башы әйләнеп китте сыман. Әйтерсең, менә шушы мизгелдә тамырларында аккан каны — ерак гасырлардан килүче бабаларының авазы тавыш бирде. Алар чакыралар, өндиләр, үтенәләр, таләп итәләр: «Нәселебезне сакла! Нәселебезне сакла! Син бетсәң, без дә бетәбез!..» — диләр сыман иде.

Үзен борчый, газаплый башлаган сорауны бирергә иң уңайлы вакыт иде, Шәһит түзмәде, тынлыкны бозды. Хәер, «углым» дип эндәшеп, ата кеше аңа сөйләргә рөхсәт биргән иде инде.

— Әтием!.. Бер нәрсәне беләсем килә... Шәҗәрәбез куе, күп тармаклы... Нишләп соң минем... безнең... туганнарыбыз аз?

Мәмәт би гомердә булмаганны кыланды: улын иңнәреннән кочаклап үзенә таба тартты да тирән сулап куйды:

— Әй, углым... Күптән, бик күптән көтә идем мин бу сорауны,— диде.— Белеп тор: дошманнарыбыз күп булды, аяусыз булды.— Һәм ул шәҗәрә тармакларына төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләргә кереште:— Менә бусы Батый хан Болгарга яу чапкан елларда бетте, кырылды. Ил-йортны саклап башларын салдылар. Монысын Василий Темный башкисәрләре харап итте... Сөйләп кенә бетерерлекме... Ызгыш-талашларда күпмесенең гомере киселде. Аяныч... тормыш дигәнең без дигәнчә генә бармый. Җир йөзендә бердәнбер безнең тармак торып калды. Менә күрәсеңме?— Мәмәт би очлаеп сузылган нечкә ботакка күрсәтте.— Монысы бабаң Сәүбан, аннан соң инде мин калдым, миннән соң бер ялгызың син каласы... Ә мин синең ялгыз булуыңны теләми идем. Теләмәдем... Нишлим? Аллаһы тәгаләнең каһәренә дучар булдыкмы, башка сәбәпме... белмим. Әүвәл дөньялыкта мине япа-ял-

гызлыкка хөкем итте... Инде сиңа да шуны теләмим. Сүзем бер — нәселең ишле булсын, өеңдә бала-чага тупырдап торсын!..

Мәмәт би унлап кыз-кыркын арасында бердәнбер булып дөньяга килгән улын өзелеп ярата, аны күз карасыдай сакларга тырыша иде. Ул — аның өмете, киләчәге, нәсел-нәсәпнең, олуг Мәмәт токымының соңгы ышанычы иде. Киләчәк белән аны — Мәмәт Сәүбан углы Мәмәтне — бары шушы углан, борынгы бабаларының асыл сыйфатларын җыйган, терекөмештәй житез, пәһлевандай көчле һәм кызларча чибәр Шәһит углан гына тоташтыра ала. Бар мал-мөлкәт, Мәмәтләр нәселенең шанлы исеме аңа каласы. Ләкин никадәр генә яратмасын, кадерләмәсен, карт морза аларны, ул хисләрне угланга сиздерүне кирәк тапмады. Ир бала кырыслыкта, каты кулны тоеп, иркәләнми, назланмый, чын баһадир булып, мөстәкыйль булып үссен. Аның кагыйдәсе шундый иде. Бәлки, артык кырыслыгы белән улын үзеннән читкәрәк тә этәргәндер... Ләкин... Шәһиткә андый-мондый куркыныч янаса, дошманны ул теше-тырнагы белән ботарлап атарга әзер иде. Үзе тоеп йөрде, күреп, белеп торды: углы да аңа шундый ук кырыс мәхәббәт белән җавап бирә иде. Кечкенәдән атасыннан яклау эзләмәде, аңа салынмады, утардагы малай-шалай белән бәрелешеп, авыз-борынын канга батырып кайтса кайтты, әмма атасына зарланмады. Аның үзбаш яшәргә, һәр нәрсәне хәл итәргә үзе алынуын күрү ата күңеленә әйтеп бетергесез олы шифа бирә иде. Шуңа да ул балалык, үсмерлек һәм егет чакларында да Шәһиткә бар нәрсәдә ирек куйды, аның горурлыгына, көченә, үзен тота белүенә ышанды. Бәхетенә, барысы да ул көткәнчә барды: улы өметне аклады. Тик менә бүген, хәзер тәртәгә тибәргә азаплануы бердән сөендерсә, икенче яктан, ата ихтыярына буйсынмыйча үзбаш кыланырга маташуы көендерә иде. Барысы өчен үзе җавап бирергә күнеккән мәгърур җан буйсынмаса?! Хәер... Мәмәт би улын бөгә, әйткәненә күндерә алуына ышана иде. Ул бүген олы, гаять тә олы һәм тирән төшенчәләр белән эш итә!

Менә хәзер дә, шушы мизгелдә дә Мәмәтнең улын тагын бер кат кочып сөясе, аркасыннан кагып булса да иркәлисе килә иде. Әллә нинди тыелгысыз, тәкатьне бетерә торган сәер хис иде бу. Әмма карт морза кулларына ирек бирмәде, сөйләвен белде. Инде иң соңгы, үтемле сүзне әйтәсе калды.

— Мин дә ялгыз түгел идем,— диде көрсенеп Мәмәт би.— Атамның йорты киң, билек бакчалары чәчәктә, яшәвебез рәхәт иде. Газиз әнкәмнең кочагы җылы, атамның кулы кырыс булса да, йомшак иде. Барысы да бер көндә бетте, пыран-заран килде. Шушы утарда ялгызым утырдым да калдым.

— Әбием, бабам... Аларның гомере шулай аяныч киселдемени?— диде Шәһит атасының тын калуыннан файдаланып. Ул дәһшәтле көннәр хакында аның ишеткәне бар, әмма яшьлек иләслеге белән элегрәк артык әһәмият бирми иде. Хәзер исә, атасы кинәт ачылып киткәндә, бу сәер тарихны бөртекләбрәк, җентекләбрәк ишетәсе килү теләге уянды. Кырыс морзаның улы белән инде шактый күптән шулай ачылып сөйләшкәне юк иде.

Әтисе үкенечле, аянычлы көннәрне искә төшереп булса кирәк, тирән сулап куйды, башын учына терәп бераз утырды да акрын гына сөйли башлады. Маңгае җыерылды, күзләрендә яшерен ут кабынды.

— Мин ышанам... Әйе, кайдадыр бәлки... Минем сеңлем яшидер...— диде ул капылт кына.— Тик белмим, төгәл әйтә алмыйм. Бәлки синең дә ир туганнарың, ягъни туганнан туган абый-энекәшләрең бардыр... Юллап, эзләтеп карадым, очына чыга алмадым. Идел дулкыннары серен саклый белә. Ләкин сизенәм, тоям, күңел төбендә үлмәгән өметем бар... Исәндер шикелле ул. Аңлата гына алмыйм...

Шәһитнең күзләре зур булып ачылды. Әле генә: «Мин ялгыз, япа-ялгыз»,— дип утырган атасы моңарчы ишетмәгән сәер сүзләр сөйләп ята иде.

— Ничек? Кем ул? Кайда?— дип сорау бирүен сизми дә калды.

— Анысын мин үзем дә белмим. Бабаң, ягъни Сәүбан морза дәүләт йомышын үтәп ерактагы Бәлҗәмәнгә — Кырым-йорт белән Казан-йорт чикләрендәге ялгыз кирмәнгә киткән җиреннән әйләнеп кайтмады. Анысын беләсең... Кем кулыннан үтүе, кайсы дошманыннан һәлакәткә юлыгуы билгесез. Урыны җәннәттә булсын! Ул кайтмагач, әбиең Суфия бикә кечкенә

сеңлемне алып, укчылар белән көймәдә Бәлҗәмәнгә юлга чыга. Үгетлиләр, ушкуйниклар — урыс юлбасарлары азган чак, сабыр ит, диләр. Тыңламый. Әҗәле тартканмы... Бабаңны, минем әтиемне бик яраткан, диләр. Үлүенә, һәлагенә ышанмаган... Нишлисең?.. Курәчәгең гүргә кертер, ди бит.

Бер-ике атнадан укчыларның берсе кайтып егылды. Яраланып суга егылган да, ярга йөзеп чыгып, күзәтеп яткан. Ул сөйләде. Әбиеңне тураклап суга атканнар. Бик каты сугышкан ул. Ә нәни кызчыкны, сеңлемне, сиңа туган апа буласы кешене алып киткәннәр. Хак булса, аның өчен Сәүбан морзаның ярты байлыгын каерасылар, имеш. Шулай сөйләнгәннәр... Әмма юлбасар сүзенә ышанып буламы?! Барысы да шулай югалды, бетте. Ушкуйниклардан чапкын да, йомышчы да килмәде. Мин аны гомер буе көтеп яшәдем. Көт-тем... Калганын беләсең...

— Ул канәчкечләр шулай җәзасыз калдымыни? Казан-йорт хәтле Казан-йорт Сәүбан морзаның үчен алмадымы? — диде Шәһит ярсуына чыдый алмыйча. Канлы куллардагы нәни кызчыкны, кылыч тотып дошманына ташланган Суфия бикәне ул үз күзләре белән күргәндәй булды. Ирексездән бармаклары йодрыкка төйнәлде, күзләрендә уч чаткысы кабынды.

— Үчне алдылар анысы... Бише белән кайтардылар, — диде Мәмәт би. — Казан-йортның иң асыл ирләре яуга китте. Ушкуйникларның ояларын туздырып, мәңге онытмаслык иттереп кайттылар. Явызлыкларын кан белән юдырдылар... Тик ни файда?! Сәүбан морзаны да, Суфия бикәне дә кире кайтарып булмый иде инде. Сеңлем әле сабый гына, миңа нибары уноч яшь иде... Менә шул, улым.

Ә шулай да күңелем нидер сизенә... Бүген менә тагын искә төште. Ул бала исән калгандыр... Балалары бардыр, нәсел үрчетеп ятадыр... Бәлки урыс-улак арасындадыр. Бәлки... Тик инде алар Мәмәт би нәселе булмас, борынгы җылкы ыруының шәҗәрәсендә аларга урын табылмас. — Мәмәт би тагын бер көрсенеп куйды, күзен йомып уйланып утырды-утырды да кукрәгең тотып, акрын гына әйтеп бетерде: — Нигәдер күңелем урынында түгел. Йөрәгем уйный. Тиктомалдан әллә кайчангы вакыйгалар, югалган сеңлем искә төште. Хәерлегә булсын!..

Тузанлы юлдан бер төркем атлылар чаба. Алда буй-сынга бер чамадарак ике яшь егет килә. Ләкин бу тышкы охшашлык кына. Якынрак килеп караган кеше аларның берсенең күзләрендә чаткылы очкыннар күрер иде, икенчесенекендә кайгы, моң, хәсрәт күләгәсен абайламый калмас иде.

Ике егет дигәнебез — Шәһит белән Санька иде.

Шактый озак сүзсез генә бардылар. Ниһаять, Шәһит тынлыктан, телсезлектән, күңелен актарган хисләрдән котылырга теләде булса кирәк, атын тыя төште һәм куршесенә эндәште:

— Йә, Александр, Саклаубашта биргән вәгъдәнне үтә: сөйлә, ичмасам, башыңнан кичкәннәрне!..

Дәүран би кызы белән яраштерелгән яшь морзаның күз яшьле, мажаралы, газаплы һәм әрнеткеч мәхәббәт кыйссасы ишетәсе килә иде.

## Кол Шәриф

«Җәнаби үзенең тарихында болай дип яза: «Ул (Сафагәрәй) ханнарның олыларыннан, усалракларыннан иде. Аның заманында патшалык бакчалары рәхәт, ә мәмләкәте төзек иде».

Шиһабетдин Мәрҗани

Сафагәрәй тагын Казанга кайтты. Казанлылар чакырып кайтарды. Пайтәхеткә каты куллы, гадел һәм зиһенле хан кирәк иде.

Морзалар, биләр, карачылар, дәүләт хакимлегенә торган саен күбрәк йогынты ясый башлаган сәүдә әһелләре — малтабарларның ыгы-зыгысына,

сарайдагы талаш, кычкырышка чик куярга, хакимлекнең каты бер кулда тупланырга тиешлегенә басым ясаган ханның төшерелеп, хурлыклы рәвештә Кырымга кайтып китүенә өч ел вакыт узган. Өч мәртәбә язлар килгән, кышлар үткән. Нәуруз саен бөек аллаһы тәгалә кодрәтенә согынып, аннан Казан җиренә иминлек, бәхет һәм муллык, татулык сорап, ялварып чалынган корбаннарның нәтиҗәсе булмады, мәмләкәткә нә иминлек, нә муллык килмәде; карачыларның һәркайсы үз ягын каера башлады, биләр арасында астыртын көндәшлек тамырланды. Үз мәнфәгатьләрен генә уйлаган кайберәүләр алдап-йолдап та, ачыктан-ачык та Мәскәү ягына каеруны гөнаһка санамый, моның өчен кырыкмаса-кырык сылтау таба, аклану юлларын эзли иде.

Соңгы елларда урыс кенәзлекләренең бер-бер артлы мөстәкыйльлеген югалтуы, кайсының куршесенә хөсетлектән, кайсысының зәгыйфьлектән, күпләренең канга батырылып, корал тотардай ирләренең кылычтан үткәрелеп Мәскәүгә баш ияргә мәҗбүр ителүен, Казан җирләре чигендә генә уртак бөек кенәзгә буйсынган көчле мәмләкәт оешып килүен, аның нәфесе көннән-көн артуын аксөякләр аңлап бетерми. Күзләрен байлык артыннан куу томаны каплаган, зиһеннәрен комсызлык, нәфес чире баскан, колакларын алтын чыңы томалаган. Дөрес, Мәскәү белән сәүдә итү — табышлы, төшемле эш, әмма дә ләкин малтабарлык кына изге ханлыкның ныклыгын, бердәмлеген какшатырга тиеш түгел ләбаса.

Хуп, Сафагәрәйне тәхеттән төшердек. Ләкин ул китү генә казанлыларга бирәр отыш бирдеме соң?! Юк! Бирмәде генә түгел, дәүләтнең сәясәтенә зыян китерде, күп нәрсәдә мөмкинлекләрен чикләде. Борынгылар юкка гына: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»,— дип әйтмәгәндер. Казан һәм Кырым тәхетендә нәсел җепләре бер шәҗәрәгә тоташкан асыл затлар утырганда һәр ике ханлык бертуган булып яшәде, бер бөеклекнең, галилекнең ике канатына әверелде. Сафагәрәйнең Казан тәхетеннән төшерелүе аркасында кырымлылар белән мөнәсәбәткә салкынлык иңде, Кара диңгезгә юнәлгән сәүдә юлларына чирәм үсә башлады. Шуны гына көтеп торган, бөтен сәясәтләрен, хәйләкәр осталыкларын Казан белән Кырымны дошманлаштыруга юнәлткән мәскәүлеләр тагын отты, казанлыларга юл ябылган базарларда урыс малтабарларының кәрваннары шаулады.

Аллага шөкер, инде моны биләр, морзалар гына түгел, кара халык та аңлады. Диван[1] әһелләре ялгышларын төшенеп, кире Сафагәрәйгә бил бөгәргә, тәхеткә кайтуын гозерләргә мәҗбүр булдылар.

Кол Шәриф авыр сулап куйды: «Хәерлегә булсын! Сәясәттә барысы да ак-пакь булмый, күрәсең...»

«944 сәнәнең* язында күзен Мәскәү ягына аларткан, мәмләкәт ихтыярын урысларга саткан Җангали хан бәкләр кулыннан шәһит китте. Нәфесенә хуҗа була белмәгән, гали затлар тәхетенә утырса да галилектән, дәүләт мәнфәгатеннән бихәбәр Җангали кара гүргә керде. Урыны җәннәттә булсын дия алмыйм. Барысы да бөек тәңребез иркендә. Барыбыз да аның коллары. Казан тәхетенә яңадан Сафагәрәй хан утырды.

Аллаһы тәгалә куәт вә мәдәт бирсен!»

Кол Шәриф каурый каләмен көмеш кара савытына батырды да күзләрен бер ноктага текәп уйга калды, авыз эченнән генә дога укып битен сыпыргач, янәдән иртәдән бирле тынгы бирмәгән уйларын, чуалган зиһен җебен сүтәргә керешә. «Әйе, ни генә дисәң дә, Сафагәрәйнең тәхеткә кайтуы — олы җиңү, елъязмалар бизәге булырлык бөек вакыйга. Һичшиксез, ул Казан-йорт тарихына язылып калырга тиеш. Кырым-йорт белән бертуганлык мәмләкәтнең сулышын киңәйтеп җибәрер, көч-куәтебезне арттырыр. Казан, Кырым, Әстерхан хөкемдарларының туганлыгы даладан Каф тауларынача, Себергәчә мәгълүм, ул бәхәссез. Туганнарга каршы урыс та, башка бүтән бер кавем дә күтәрелергә кыймас».

---

[1] Диван — хан сараенда биләр, морзалар, карачыларның киңәшләшү мәҗлесе, идарәсе.

* Һиҗри белән 944 ел — милади буенча 1535 ел. Алга таба, укучыларга аңлаешлырак булсын өчен, еллар исәбе хәзерге календарь — милади буенча бирелә.

Кол Шәрифне куандырганы шул — тәхетне ныгытуда аның өлеше аз булмады. Алтын-көмеш чыңыннан колаклары томаланган малтабарларның күңеленә барып җитәрлек, зиһеннәрен уятырлык сүзләр табарга, күзләрен ачарлык дәлилләрне үтемле итеп күрсәтә дә белергә кирәк иде бит. Иншалла, ахыры хәерле булсын. Казан халкы аның сүзенә битараф түгел, әйткәне бер колактан кереп икенчесеннән чыкмый, биләр-морзаларның аңында да, гади халык күңелендә дә урын таба.

Әле ир уртасы яшенә җитмәсә дә, инде галимнәрдән дә галимрәк дип танылган галиҗәнаб мелла Шәрифкол сигез манаралы Җәмигъ мәчетнең беренче имам-хатибы, гыйлемле вә белекле затлардан да беренчесе иде. Аксөяк угланнарга вә дәхи гади халыктан чыгып, тырышлыгы, зирәклеге белән башкалардан аерылып торучы, гыйлемлек эстәүче яшь егетләргә сабак укыту белән бергә, ул мәмләкәтнең иң кадерле, иң асыл хәзинәсенә ия кеше. Чөй язуы белән чуарланган таш такталарны да, ерак Рум галимнәренең серләрен теркәгән, бозау тиресеннән тегелгән калын китапларны да, уйгыр, чин һәм гарәп хәрефләре белән сәйләндәй тезелгән йөзләрчә битле елъязмаларны, күтәрә алмаслык алып китапларны да табарга була аның хәзинәсендә. Алар арасында да иң кадерлесе — борынгы бабаларыбызның шәҗәрәсе — ерак-ерак гасырлар төпкеленнән килгән изге язмалар саклана.

Кол Шәрифнең инде күп еллар элек үзенә кагыйдә иткән бер гадәте бар: ил-көндә чуалышлар, хөкемдарлар арасында сәбәпсез ызгышлар кузгалса, яисә күңелендә шом-шөбһә уянса — китапханәнең аскы катындагы хөҗрәгә кереп бикләнә, калын китапларның дәверләр кичүдән тонykланган көмеш каптырмаларын ычкындыра да борчыган сорауларына, күңелен бимазалаган шикләргә җавап эзли.

Имам-хатиб, авыр уйларын куарга теләгәндәй, башын чайкап алды, имән бармаклары белән чигәләрен уыштыргач, тамак кырып тавыш бирде:

— Кайсыгыз бар анда, керсәгезче!..

Остазының үзен бүлдергәнне яратмаганлыгын белгән һәм шунлыктан бүлмә ишеге янында кизүдәй сакта торган китапханә хадиме тышкы яктан салмак кына тавыш бирде, шыгырдап калын ишек ачылды.

— Нәрсә кирәк иде, имам-хатиб әфәнде? Әмереңне көтәм...

Кол Шәриф шәкертенең ярату һәм ихтирам тулы күзләренә, боерык көтеп алга таба иелә төшкән яшь сынына карап, шактый озак сүзсез торды да, фикер җебенең очын яңа гына тапкандай, кистереп әйтте:

— Мин астагы хөҗрәдә булырмын. Кем килсә дә, кертмәгез. Мин — юк!

Килеш-килбәтендә олылык, зирәк ирләр олпатлыгы чагылган остазының һәр сүзенә тавышсыз баш иярга күнеккән хадим бу юлы тынлыкны бозды:

— Сарайдан килсәләр дәме? Галиҗәнаб Сафагәрәй хан хәзрәтләре...

Хадим әйтеп бетерә алмады, имам-хатибның куе кара кашлары астындагы зәңгәр күзләрендә ризасызлык чагылып үтте, киң ак маңгаенда бер генә мизгелгә җыерчыклар хасил булды, кул ишарәсе белән егетнең сүзләрен бүлдерде:

— Диваннан килсәләр дә,— диде ул сабыр гына.— Пәйгамбәрләр белән сөйләшкәндә комачаулаганны сөймим.

Кинәт аның карашындагы таркаулык әчке нур белән алышынды, салмак хәрәкәтләренә кисkенлек, нәрсәнедер хәл иткән һәм аны үтәргә ашыгуы кешеләрдәгечә омтылучан җитезлек иңде. Ул яшьләрчә җиңеллек белән урыныннан күтәрелде, бер төргәк ак кәгазь, кара савыты, каурый каләмен өстәлнең бер читенә шудырды, ашыгып-ашыгып өстенә яшел чапанын киде, кара кәләпүше өстеннән ак чалмасын чорнады.

— Аска ике көнлек шәм төшерерсең,— диде ул карлыгып киткән тавыш белән.— Өйдәгеләргә хәбәр ит: имам-хатиб хөҗрәгә бикләнде... Борчылмасыннар!..

Китаплар, кульязмалар, дистәләрчә таш такталарны кулыннан үткәрсә дә, яшь хадим әле аларның күбесен аңлап бетерми, мең-мең еллык белем, тәҗрибә тупланган, борынгыларның бүгенгеләргә җиткерәселәре язып калдырылган ул акыл хәзинәсенең кыйммәтен тулы дәрәҗәсендә күз алдына китерә алмый иде.

«Язу-сызу, китап — ул хәтер. Теге яки бу халыкны юк итим дигән илбасар, залим хөкемдар иң элек аның китабын, язуын бетерер, яндырыр, көлгә әйләндерер. Хәтерсез кеше — хайван мисалында,— дип өйрәтә аларны остазы.— Хайван ни эшләткәнгә дә риза. Муенына бау тагып сатарга алып барганда да, бәйләп суярга салганда да. Чәйнәренә ризыгы, күшәренә чүбеге булса — аңа шул җиткән. Сез — адәм затыннан. Хайван хәленә төшәсегез килмәсә, укыгыз, белем җыегыз. Белем алу — әнә белән кое казудыр. Аның башка юлы юк. Адәми зат дигән исемгә тырышып, күз нурыңны коеп кына ирешеп була. Анадан ике аяклы, ике куллы булып туу гына җитми. Әнә, маймыллар да ике куллы, ике аяклы, әмма кеше түгел. Адәм баласы үзенең кеше икәнен белгәндә, шул исемне аклар өчен яшәгәндә генә кеше».— ди остаз. Аны калада китап җене кагылган дип тә сөйлиләр. Бәлки шулайдыр да, кем белә? Бар байлыгын, тапкан-казанганын китапка түгәргә шул җен мәҗбүр итмиме икән әле?! Әнә ич, ярты Казан белә: моңарчы таныш булмаган ниндидер борынгы язмага тап булса, үзенекен дә, хан казнасы байлыгын да кызганмас, шул китапны кулына төшермичә тынычланмас. Ташаяк ярминкәсенә йөрүче карт сәүдәгәрләр Казандагы акыл иясенең бу гадәтен беләләр һәм ел саен нинди дә булса иске китап, язма, йә булмаса чөй язулы таш такта алып килмичә калмыйлар иде. Әнә шулай бөртекләп, кадерләп, энә күзеннән үткәреп тупланган акыл хәзинәсе саклана монда.

Яшь хадим үзенең кайчан да булса ул яшерен серләргә ия булачагын, борынгы акыл ияләре фикерләре, киңәш-тәгъбирләре белән танышачагын күз алдына китереп, канәгать елмаеп куйды. «Йа хода, моның өчен никадәр сабырлык, түземлек, дөнья ваклыкларыннан өстен була белү сәләте, тырышлык, үҗәтлек кирәк! Зиһенеңне чүпләмичә саф тота белү, аны олуг затлар туплаган тәҗрибә өчен ачу дигән сүздер»...

Уйларына бирелеп, ул Кол Шәрифнең ишарәсен дә сизми калган икән. Колагына сүзләре килеп керде.

— Йә, аллага тапшырып, тәвәккәллик, улым! Менә бу кулъязмаларны, әсбапларны алып төшәргә ярдәм итәрсең,— диде ул яраткан шәкертләреннән саналучы хадимгә борылып.— Кабатлап әйтәм, яу-фәлән килә калса гына, хәбәр итәрсез... Башкасына ризалыгым юк.

Шәкерт дивар куышлыгыннан махсус коелган озынча калын шәмнәр алды, ут элде һәм, остазы күрсәткән төргәкләрне култыгына кыстырып, ишеккә таба атлады. Тар аралыктан үтеп аска төшүче баскычларга борылдылар. Ишекне ачуга, борынга мәгарәләрдә була торган тынчу һава түгел, ә талгын җылылык бәрелде. Моның сәбәбен дә белә иде шәкерт. «Китап — нәзберек әйбер, ул саклаганны, кадерләгәнне ярата»,— дип өйрәтә Кол Шәриф. Шунлыктан, хәтта җәй көннәрендә дә китап саклау йортының мич ягулы, чүлмәк торбалар буйлап җылылык каттан катка йөри. Шома таштан тигезләп салынган диварларда дым әсәре сизелми, киштәләрдә калын-калын төргәкләр, икешәр-өчәр кирпеч зурлыгындагы китаплар, таш такталар, тагын әллә никадәр таныш түгел хәрефләр белән чуарланган, вакытлар үтүдән ящелләнә башлаган бакыр такталар...

Уртадагы аралыкта киң имән өстәл, аның янында тәбәнәк урындык. Өстәлдә өч башын өч якка сузган аждаһа сурәтендәге шәмдәл, очлап куелган каз каурыйлары...

Шәкерт аждаһа башындагы шәмнәргә ут элде, төргәкләрен өстәлгә таратып салды һәм уң як диварда, кеше буе биеклегендә уелган төнлекне ачып җибәрде. Хөҗрәгә елга исе, болын исе катыш салкынча һава ургылды.

* * *

Тышкы дөньядан калын таш диварлар белән аерылган җир асты хөҗрәсендә тынлык. Урам шау-шуы, атлыларның һай-һулап чаптырып үтүе дә, дистәләрчә кырыктартмачыларның малларын мактап кычкырышуы да, яшь җилкенчәкнең ваемсыз уен-көлкесе дә ишетелми. Шылт иткән тавыш та юк. Бары тик бакыр аждаһа башларындагы шәмнәр генә ара-тирә чертләп куя.

Кue тынлыкта Кол Шәриф борынгы бабаларыбызның рухлары белән сөйләшә, аларның күңеленә ачкыч эзли, киләчәкне бага. Авыр, ай-һай, авыр, мәшәкатьле, газаплы эш ул.

Кол Шәриф ашыгып, каударланып урыныннан күтәрелде һәм авыр сандыкларның берсен ачып, борынгы дисбе — аркылысы ике илле чамасы зурлыктагы бакыр түгәрәкне кулына алды. Яссы табага охшаш дисбенең уртасына канатларын җәйгән сәмруг кош сурәте, аның әйләнәсендәге кече түгәрәккә җиде пәйгамбәр, аннан соңындагы зур түгәрәккә исә янә уникe илаһи затның рәсеме төшерелгән иде. Бу — борынгы, бик• борынгы, затлы, кыйммәтле әйбер. Аның Казан китап йортына кайчан, ничек килеп эләккәнлеген, кыйммәтенең нәрсәдә икәнлеген, сурәт вә язуларның ниңәрсә аңлатканлыгын беркем дә белми. Әмма кайчандыр китап саклаучылардан калган гадәт буенча аны үтә кадерләргә кирәклеген беләләр, буыннан буынга васыять әйтеп, мирас итеп тапшыралар иде.

Үзе дә аңламаган теләккә буйсынып, Кол Шәриф мәгарә түрендә читләр күзеннән яшереп эшләнгән ишек янына килеп басты. Аның барлыгын белмәгән кеше монда һичнинди ярык-фәлән күрмәс, ишек бөтен дивар шикелле үк калын ташлардан ясалган һәм мәгарәнең бер ягын тәшкил итә иде. Ул дивардан чыгыбрак торган кечкенә ташка таянды да көч белән этә башлады. Эчтә нәрсәнеңдер гөрелдәгәне, шыгырдап шуышканы ишетелде һәм диварның бер өлеше артка чигенеп, кеше сыярлык ярык хасил булды. Шәмнән сирпелгән сүрән яктылыкта кое сыман караңгы бушлык, өскә күтәрелгән таш басмалар күренде. Кол Шәриф дисбене тотып ярыктан эчкә атлады, күптән кеше аягы басмаган ташлар буйлап манара эченнән күтәрелә башлады.

Төн уртасы. Күзгә төртсәң бәрни күренмәслек караңгы иде. Күк гөмбәзендә меңнәрчә йолдызлар җемелди. Казан йоклый. Ник бер эт өрсен дә адашкан җәяүленең тавышы ишетелсен. Каланың иң югары ноктасына күтәрелгән Кол Шәриф үле тынлыктан, күңелдә шом уятучы дәһшәтле матурлыктан калтыранып куйды. Әйтерсең, җир йөзендә барча җан иясе үлеп беткән, күк белән җир арасындагы бушлыкта бары тик бер тере җан — ул гына калган. Күзләрен күккә төбәп ул Тимер казык йолдызын эзләргә керешТе. Күк гөмбәзенең нәкъ уртасында, баш очында гына салкын нурлар чәчеп җемелдәгән йолдызны тапкач, җинел сулап куйды һәм дисбене итәге белән сөртеп, аны манара дивары өстенә куйды, кулындагы шәмне якынрак китереп, хәрефләрнең серен белергә теләгәндәй тагын аларга текәлде. Озак, бик озак карап торды Кол Шәриф. Һәм эчке бер сизенүгә буйсынып, дисбене акрын гына көнчыгышыннан көнбатышына таба әйләндерергә керешүен дә сизми калды. Шунда әллә нәрсә булды. Тимер казык йолдызыннан төшкән нурлар чагылдымы, әллә талгын исеп куйган җилдән шәм ялкыны тибрәлдеме,— дисбе өслеге әкрен генә яктырып куйды. Янәдән•дисбене шул хәленә кайтарды — яктыру кабатланды гына түгел, ә томан эчендәге шикелле генә күренгән сурәтләр ачыклана төште, алар җанлангандай күз алдында төрле төсләргә керә башладылар.

Кол Шәриф тирә-юньдәге бер нәрсәне күрмәс хәлгә килде, бөтен барлыгы, игътибары, акылы шушы сәер яктырышка юнәлде, миен томалаган томан таралып, күзе яңадан ачылгандай булды.

«Җир йөзендә барысы да кабатлана,— дип пышылдады ниндидер тавыш. Кол Шәриф сискәнеп китте.— Галәм чиксез бер түгәрәктер, әйләнгән саен яңа заман туадыр. Әмма аң бул, ул һәрчак яңа сыйфатта, яңа халәттә кабатлана».

— Кешелек тарихы гарасатлар, афәтләр, һәлакәтләрдән тора. Алар да шул фасылларга бәйлеме, бәйле булса — безне алда ни көтә? Котылыр чара бармы? Ни кылыйк? Гонаһларыбыз өчен җәза шулмы?!

— Гонаһны да, җәзаны да кеше үзе уйлап чыгарган. Табигатенә хас булмаганны кылмасаң, гонаһысы да юктыр. Тик моны аңлау өчен гаять күп, сезнең төшенчәләр белән әйтәм, гаять тә күп еллар агышы кирәк. Аныcы — киләчәгегез. Ә нәрсә көткәнен мин әйтә алмыйм, киләчәгегезне сез үзегез корасыз. Бүгенгегез, үткәнегез белән аңа нигез саласыз. Котылу юлын

да үзегез табарга тиеш. Мин ачкычын бирдем. Кисәтә генә алам: галәм фасылларының билгеле бер агышында адәм балаларына куркү иңә, затсызлык, кансызлык арта, алар табигатенә, хасиятенә тәңгәл булмаган эшләргә бата. Сез аны гөнаһ дисез. Шуннан сакланыгыз.

Кол Шәрифнең күз алдында берсеннән-берсе дәһшәтле, тәнеңдә кан агышын туктатырлык тетрәндергеч сурәтләр пәйда була башлады. Әйтерсең, бөтен кешелек тарихы канлы сугышлардан, җан кыюдан, үтерү-кочләүләрдән тора. Офыктан-офыкка утлы өермәләр котырып узды, авыллар, калалар өстендә дәһшәтле ялкын күтәрелде. Дисбенең һәр әйләнеше саен бу гарасатлар кимеми генә түгел, тагын да коточкычрак, канлырак була бара иде. Тарих һәм кан! Кан! Кан! Кан! Җир йөзендә бу газапларны, адәм баласының бер-берсен суешын туктатырлык, күзен ачарлык көч юк микәнни соң?!

Дисбе салмак кына әйләнә дә әйләнә. Менә һуннарның утлы ташкыннары юлындагы бар нәрсәне яндырып, изеп, сытып, канга батырып узды. Хәрабәләр өстендә бөек һун дәүләтенең әләмнәре җилфердәде. Телләрдә бер сүз — Аттила, Аттила!

Тагын бер әйләнеш. Галәм фасылы мизгелләрен санаучы өч йөз дә алтмыш ел. Һуннар дәүләтенең таланган, күмергә, көлгә әйләнгән гөлбакчаларында хазарлар каганлыгы хакимияте. Җир өчен, мал-мөлкәт өчен, байлык өчен, үзен алланың җирдәге вәкиле дип игълан иткән комсыз затларның мин-минлеген котырту, аның колагын ялагай тәгъбирләр белән иркәләү хокукы өчен үзара ызгыш-талаш, якыннарыңның аркасына кадалган хыянәтчел хәнҗәр...

Дисбе әйләнеше инде Кол Шәриф таныш заманнарга якынлаша. Офыкта гайрәтле Чыңгыз хан яулары, күз ачып йомганчы дистә чакрымнарны уктай очып узучы тыелгысыз атлылар ташкыны. Болгар, Биләр, Сувар — бөек бабаларыбыз корган кальгалар янында ут уйный, кеше язмышлары канлы өермәгә уралып тузан бөртегенә әйләнә, күккә каргыш, нәләт ургыла.

Кол Шәриф тетрәнеп дисбе әйләнешен күзәтә, аны туктатасы, бу дәһшәттән, җирәндергеч канлы суешлардан, колагында яңгыраган елаш-каргышлардан арынасы, ял итәсе килә. Әмма бу аның ихтыярында түгел, җанытәне тартышса да, тарихи дөреслекне, кешелек дөньясы үткән чынбарлыкны каплап та, бизәп тә, юкка чыгарып та, үзең теләгәнчә яңабаштан язып та булмый. Тешеңне кысып түз, йөрәгеңне учыңа кыс! Түз! Түз! Түз! Болар барысы да синең, синең бабаларың, бабаларыңның бабаларының бабалары үткән юл. Кеше гомере бер мизгел. Бу гарасатларда исә галәм әйләнеше фасылларының мизгелләре.

Сурәтләргә, ниһаять, серен ачкан тылсымлы язмаларга икеләнү, тетрәнү, аяныч үкенү һәм өмет, ышаныч белән текәлгән Кол Шәрифнең бүгенге көнгә, киләчәккә күз саласы килә. Киләчәк пәрдәсенең бер читен генә күтәреп алга караш ташлыйсы иде... Шул ук вакытта күңелен шом баса: кирәкме? Нигә җаныңны кыйнарга! Әгәр вакыйгалар көткәнчә, күз алдына китергәнчә, өметләнгәнчә булмаса?! Аһ, ни аяныч! Ул чакта яшәү мәгънәсе каламы соң?! Күрәсең, алдагы көнеңдә ни-нәрсә булачагыннан, үзеңне ни көтәчәгеннән хәбәрсезлек—яшәүнең асыл кануныдыр! Әгәренки белсәк, ул коточкыч афәтләрне көтеп тормас идек, ризалашмас идек. Күпме кеше муенына элмәк салыр, Иделнең караңгы чоңгылларында яшәү белән хушлашыр иде. Котылгысызлыктан чыгу, киләчәгеңнән, күрәчәгеңнән качу юлы бармы? Әгәр булса, ул котылгысыз дип аталыр идеме?!

Ил агасының миендә мең-мең сорау бәргәләнә. Ә дисбе туктамый. Менә-менә галәм әйләнешенең яңа фасылы башланачак. Ул безгә нинди канлы афәтләр белән яный? Әллә кан коюдан, үчлектән, хөсетлектән, хыянәттән туйган адәм балаларын тыныч, имин еллар көтәме?!

Кинәт Кол Шәрифнең йөзе агарып китте, сул кулы белән күкрәгенә ябышты. Томан эченнән шәйләнгән сурәтләрдә канлы байраклар айкала, сөңге очына котырган эт башларын чөйгән атлылар чабыша, таш урынына адәм башлары түшәлгән юлдан карчыгадай үткен карашлы, кыяфәтенә усал-

лык, шик, курку һәм бер үк вакытта нәфрәт белән кискен кыюлык сеңгән яңа хөкемдар кутәрелеп килә иде.

Белде, күзләрен кан-яшь томаласа да, Кол Шәриф афәтнең кайсы яктан янавын күрде. Сизенүе юкка түгел икән!.. Йөрәгендәге әрнүгә, авыртуга чыдый алмый ул аркасы белән манара диварына сөялде, авызын ачып еш-еш сулый башлады. Аңа һава җитми, төн кочагына сузылган биек манарада гына түгел, бөтен галәмдә кысанлык, тарлык... Күк гөмбәзе кечерәеп, тараеп кысылганнан кысыла, менә ул инде манара очына терәлде, берничә мизгел узар да колач җитмәс таш кирпечләрне сытып изәр, дәһшәтле авырлык астында сөякләр шыгырдар, таш уалып комга әйләнер, тимерләр сытылып коймак булыр.

Акылы, күңеле тынычлана төшеп, янадан күз салганда дисбе тагын да ерагграк киләчәккә төбәлгән әйләнешенә кереп килә иде инде. Имам-хатибның чәчләре үрә торды: киләчәк кешеләре бүгенгеләрдән мәрхәмәтсезрәк, явызлык, хөсетлек, усаллык һәм ерткычлыкта күз алдына да китереп булмаслык яңа ысуллар уйлап чыгарганнар, ахрысы. Томан эчендәге күренешләрдә ут, ялкын, үлем сибүче үзйөрешле тимер манаралар, очып үткән саен янартаулар актарылгандай җир өстен кара төтенгә күмеп тетрәтүче тимер кошлар... Агулы ачы җилләр сызгыра, чәнечкеле тимер чыбык белән чорнап алынган җәйрап ятучы карлы далалар, зәмһәрир суыгында ярым-ялангач ирләр, хатын-кызлар, балалар... Бер сынык икмәккә тилмереп аһ оручы, ләгънәт-каргыш яудыручы шыр сөяккә калган адәм уллары... Көтмәгәндә тигез җирдә атылган янартаулар... Тоташ-тоташ шәһәрләрнең парга әйләнеп күккә ыргылуы... Афәт! Гарасат!

Артыгын карарга көче, түземе җитмәде, Кол Шәриф дисбене тартып алды да күкрәге белән каплады. Иреннәре бертуктаусыз: «Юк, юк! Җитәр! Боларны белгәннән белмәгәнең мең артык».— дип пышылдады.

«Күзеңә генә күренгәндер. Ышанма! Гап-гади бакыр тәлинкә ни әйтсен. Болар хыялыңда туган сурәтләр генә иде».— дип пышылдады эчке бер тавыш. Шунда ук аңа икенчесе каршы төште: «Киләчәкне генә түгел, үткәнне дә болай ачык күзаллау өчен пәйгамбәр сизгерлеге, зиһен, кайчандыр җир йөзендә яшәгән йөзләрчә-йөзләрчә кавемнәрнең туплаган гыйлеме кирәк. Ә син аларны моңарчы колачлый ала идеңме? Ышан! Борынгылар гап-гади тәлинкәне күз карасыдай кадерләп сакларга васыять әйтмәс иде, бер-бер хасиятен тапмасалар, буыннан-буынга тапшырмаслар иде. Һичшиксез, дисбенең акылга сыймас ниндидер тылсымы бар. Пәйгәмбәрләрдән калган, моңарчы асылын аңларлык кеше табылмаганга гына сандык төбендә яткан хәзинә түгелме ул?!»

Йа алла! Сабырлык, түземлек бир! Белгәнеңне, сизенгәнеңне теш арасына кысып чыдарлык көч бир! Кара төннәргә уралып галәм фасыллары үтәр дә китәр, якты көннәр туар. Этләргә каласы Казан алардан арынып, бетмәс чорлар томаныннан яктырып, ялтырап яңадан күтәрелер, койрыклы йолдыз шикелле эзсез янып югалмас, галәм әйләнешенең яңа фасылында көлдән үсеп чыгар. Чөнки кальга астына эт салынса, мәчет астына тегермән ташы салынган. Этләр үләр дә бетәр, таш калыр. Амин!

Кол Шәриф догасын тәмамлап битен сыпырып куйды һәм ләякыл исерек кеше шикелле чайкала-чайкала ишеккә таба атлады. Үткәннәргә һәм киләчәккә күз салырга теләү, миенең һәр күзәнәген эшкә җигеп тәүлекләр буе үзе дә аңламаган ниндидер сәер халәттә үткән гомер эзсез калмаган, хәлсезлектән аның аяклары сыгыла, гәүдәсенә, әйтерсең, гасырлар авырлыгы иңгән иде. «Мәдрәсәдән чыгуга беренче очраган кеше урыс кавеменнән булса, юраганым юш килер».— дип уйлап куйды ул һәм аруын, ачыгуын, җеп өзәр хәле дә калмаганлыгын онытып, урамга атлады.

Бер-ике адым узарга да өлгермәде, каршысына ертылып беткән сәләмә киемле, озын чәчле яшь егет килеп чыкты. Бер сүз әйтеп тормастан, тез астына китереп суккандай бөгелеп төште, ике кулын аңа сузып ялварырга кереште:

— О Кол Шәриф хәзрәтләре, изге имам-хатиб! Читкә тибәрмә! Зинһар тыңла... Миңа бары тик син генә ярдәм итә аласың...

## Мөселманмы сән?

Вилаятьләрендә булган мөселманнарны тоттырып, аркаларыннан каеш чыгарып, минем динемә кер дип, сөкәнҗәләр итеп, каләме шәриф ва мәсҗед-мәдрәсәләрне ябып, мондай олуг гөнаһ иттегез.

Кырым ханы Сәламәттәрәйнең урыс патшасына җибәргән ярлыгыннан. 1554 – 1556 еллар.

Соң чиккәчә җитеп арыган, сеңерләре кылдай тартылган Кол Шәриф капкадан чыгуга ук кеше очратуына хәтта сөенеп тә куйды һәм кызыксынуын сиздермәскә тырышып сорау бирде.

— Син кем? Кем баласы? Мөселманмы сән?

— О изге имам-хатиб! Мин Углич сәүдәгәре Савелийның төпчек углы булырмын. Исемем Александр... Миңа синең ярдәмең кирәк. Зинһар үтенечемә колак сал, гозерләп сорыйм...

— Хуп, монысын ишеттек, углым. Ашыкма... Тәфсилләп, аңлатып сөйлә. Мин ни белән хәлеңә керә алам?

— Миңа мөселманлыкка чыгарга кирәк.

— Ай-һай,— дип, елмаеп баш чайкады Кол Шәриф.— Шулай тиз генәме? Мондаен да авыр йомыш белән килгәнсеңдер дип көтмәгән идем. Урамда аяк өсте генә сөйләшә торган сүз түгел. Әйдә, хөҗрәгә үтик. Тыңлап карыйк...

Кол Шәрифкә ияреп, Санька мөселманнарның изге йорты— мәсҗед-мәдрәсә вә китапханәне бер итеп, бер түбә астына туплаган олуг ташпулатның ишеген атлап керде. Ак мәрмәрдән түшәлгән чиста идәннәренә басканда гөмбәз түшәмнәр астында аяк тавышларының кайтаваз булып тоныкъ яңгыравына, бүлмәләрнең зурлыгына, биеклегенә игътибар итте, бөтен буыннарыннан әллә нинди, үзе дә аңламаган, сискәнүгә охшаш бер хис тибрәлеп узды. Шушы мизгелдә үзенең кире кайтарып булгысыз, гаять җаваплы һәм хәлиткеч адым ясаганын аңлаудан ул үзе дә бер йомарлам сеңергә әйләнгән иде.

— Йә, тыңлыйм, углым,— дип кабатлады Кол Шәриф арган тавыш белән.— Ни өчен сиңа мөселманлыкка күчәргә кирәк?

— Мин гашыйк булдым, имам-хатиб...

— Шул гынамы? Мөселманлыкның монда ни катнашы бар?

— Мәгъшукам мөселман затыннан... Казан кызы, имам-хатиб. Мөселманлыкка чыкмасам, мин аны, ике колагымны күрмәгәндәй, гомергә дә күрә алмаячакмын. Ата-аналары шулай диде.

Кол Шәриф егетнең үзенә ышанып, кискен һәм ашыгып сөйләвенә мыек астыннан гына елмаеп куйды: «Их яшьлек, яшьлек! Ул чакта барысы да ничек җиңел тоела!» Һәм мәхәббәт кыйссасын тыңларга әзерләнде. Бөтен нечкәлеген вә асыл сәбәпләрен белмичә хәл итә торган мәсьәлә түгел иде бу.

Гомер дигән көймәгә утырып тормыш диңгезенә сәяхәткә чыккан мәгъшук каһарманыбыз—күңеле керләнмәгән, олуг диңгезнең су асты агымнарын вә җаһәләтен әлегә белмәгән бүз углан Александр Кол Шәриф хәзрәткә үзенең башыннан кичкәннәрне, барча серләрен нәкъ Казанча түкми-чәчми сөйләде дә бирде.

— Әйе, үтә дә четерекле хәлдә икәнсең,— дип куйды Кол Шәриф Саньканы тыңлап бетергәч.— Әмма сөалем бар: Казан каласында укымышлы кешеләр, мәсҗедләр бихисап. Нилектән нәкъ менә минем янга киләсе иттең?

— Мин булдым инде, күпләр янында булдым... Тик берсе дә хәер-фатихасын бирмәде... Синең яныңа барырга киңәш иттеләр. Мәмләкәттә мондый эшкә тик Кол Шәриф хәзрәтләре генә рөхсәт бирә ала, диделәр.

— Бәлки, хак әйткәннәрдер... Ләкин син мөселманлыкның нәрсә икәнен ачык беләсеңме, күз алдына китерәсеңме соң?

— Хрәстиян дине кебектер инде,— дип куйды беркатлы гына итеп Санька.

— Ай-һай, җиңел уйлыйсың, углым... Җир йөзендәге бар кавемнәрне яраткан, юктан бар иткән Аллаһы тәгалә бер булса да, аңа табыну, инану, үзеңне рәхимле һәм мәрхәмәтле, шәфкать иясе Бөек Алланың җирдәге бәндәсе һәм илчесе итеп тою, шуңа ышанып яшәү бөтенләй башка нәрсә. Мөселманлык дөньялыкта тәнне җаннан аерып карамый. Тән белән җан берлеге — исламның беренче һәм иң төп кануннарыннан. Иманы саф кешенең тәне дә чиста, пакь булырга тиеш, углым. Көнгә биш намаз фарыз, һәр намаз алдыннан тәнеңне сафландыру фарыз. Гакылың, холкың-фигылең дә... тәнең дә, гаурәтең дә чиста булсын... Син боларны кабул кыласыңмы, гакылың колачлый аламы? Уйла...

— Кабул кылам, имам-хатиб... Аңлармын... Тик хәер-фатихагызны гына бирегез.

— Ашыккан ашка пешкән, диләр бездә. Сабыр ит, иң әүвәл тыңлап бетер. Өлкәннәр сүзен бүлдерми колак салырга өйрәнү дә ислам кануннарының берсеңдер.— Кол Шәриф үзе дә белми, нигәдер күңелендә бу егеткә ярдәм итәсе килү теләге уянды. Шул ук вакытта аның ашыгуына, нишләргә белми урсәләнүенә аз гына үртәлә дә кебек. Уй-хисләре капма-каршы ике якка бөреләнде. Егетнең каударланып, ашыгып, ашкынып сөйләнүе, мәхәббәте хакына бөтен нәрсәдән ваз кичәргә әзерлеге сокландыра һәм әллә нишләп бераз шикләндерә дә иде. Җете кызыл тиз уңа, диләр түгелме?— Мөселманлыкка күчү җиңел генә эшләнми,— дип дәвам итте ул.— Син инде тормышыңның бер өлешен яшәгән, балигъ булган, үзең өчен үзең җавап бирер кеше. Ә адәм баласы берьюлы өч халәттә яши: үткәнендә, бүгенгесендә, киләчәгендә. Үткәнеңне хәтерләү-белү, бүгенгесен намусыңа, вөҗдәнеңә, калебеңә хилафлык китермичә үтү фарыз. Киләчәгең шулардан укмашыр. Әмма шунысын да бел: телисеңме-теләмисеңме, үткәнең инде киләчәгеңә юл сабып куйган. Беркем дә узган гомерен, кылган гамәлен сызып ташлый алмый. Ә син, күрәм, бер селтәнү белән үткәнеңнән баш тартырга җыенасың. Тормышыңны яңа сыйфатта башлый алуыңа ышанычың бармы? Ныкмы? Үкенмәссеңме?

— Юк, имам-хатиб, үкенмәм... Мин бик озак уйландым, газаплы төннәр кичердем. Шунысын анык беләм: Гөлйөземнән башка миңа тормыш юк. Ул булмаса, яшәүнең мәгънәсе калмый. Үземә кул салыйммыни соң инде?! Башка чарам юк...

— Яхшы... Хуп... Мин сиңа мөселманлыкка күчәргә фатиха бирдем ди. Син шәкертләр янына утырып ислам догаларын өйрәнергә, аның кануннарының, шәригатьнең серләренә төшенергә, сабак укырга ризамы? Шунсыз мөселман була алмый.

— Риза, мең риза, изге Кол Шәриф!

Хәзрәтнең тавышына тимер чыңы керде, егетнең күзенә туп-туры карап, кырыс итеп сорады:

— Әй син урыс углы урыс, мөселманлыкка күчеп якыннарыңа, ата-анаңа, кавемеңә хыянәт кылганыңны беләсеңме?

Саньканың битеннән куе кызыллык, җете зәңгәр күзләреннән кара күләгә йөгереп узды. Ләкин бик азга гына. Кызыллык кәгазь аклыгы белән алышынды, күзләрендә тәвәккәллек очкыннары биеште.

— Беләм,— дип пышылдады ул.— Әмма, кабатлап әйтәм, Гөлйөзем хакына мин хәтта тормышымнан ваз кичәргә дә әзермен. Соңрак, ата-аналарым мине аңлар, кичерерләр дип беләм...

— Анысы шулай... Ата-ана бәлки гафу итәр дә,— дип үзалдына әйткәндәй пышылдап куйды Кол Шәриф.— Тагын бер сөалемә җавап бир. Синең бу адымыңны мәгъшукаң беләме? Аның ризалыгын алдыңмы? Ул ни ди? Соңыннан үкенмәссеңме?

— Юк, юк! Изге имам-хатиб, ул белә... Риза... Башка чарабыз юк. Бердәнбер өметебез шушы.— Һәм Санька, киселгән агачтай, Кол Шәриф каршына ауды; калтыранган кулларына таянып, аның итеген үбәргә шуыша башлады, бертуктаусыз сөйләнде дә сөйләнде, ачы яшьләре идәнгә тамды.

— Зинһар! И изге имам-хатиб! Зинһарлап сорыйм. Бәхетебезне кисмә... Мәңгегә бурычлы булырмын... Акчам күп минем!

— Мөселманлыкны сатып алмыйлар,— диде кырыс тавыш.— Тор! Егет кешегә — җирдә аунау түбәнлек. Горур затлар гына тиң күреп сөйләшергә лаек. Мотлак мондый гамәлеңне килештермим.

Санька үзенә чыгарыласы хөкемне көтеп таштай катып калды. Хәзер, менә шушы мизгелдә аның язмышы хәл ителә. Йә барысын да кисеп, өзеп, өметне тамыры белән йолкып аталар, йә җир фәрештәсенә тиң затка дәгъва кылырлык хокук бирәләр. Һәммәсе дә шушы олпат һәм изге кеше кулында.

Кол Шәриф кулындагы дисбе төймәләрен тарта-тарта тирән уйга чумды. Аның тагын зиһене чуалды, галәм агышының серләренә күз салган изге бер көндә вак мәшәкатьләр белән чуаласы, олуг фикерләреннән аерыласы килми иде. Икенче яктан күңелен шик корты кимерә: беренче очраган кеше урыс кавеменнән булса, юраганым юш килер, дигән иде. Ә хәзер үзе үк шул кешене мөселманга әйләндерергә фатиха бирергә җыена түгелме соң? Моның күрәзәлеккә бер-бер зыян-зәүраты булмасмы?

Санька үзен оныттылар дип уйлады, күрәсең, сак кына тамак кырып куйды. Кол Шәриф исә тирән сулап егеткә янә тагын бер сорау бирде:

— Мөселманлыкка чыккач, сөннәткә утыртылырга тиешлегеңне беләсеңме?

Санька тагын бурлаттай кызарынды, ләкин үзен бик тиз кулга алды һәм ашыгып җавап кайтарды:

— Беләм, изге имам-хатиб... Беләм һәм ризамын.

— Балигъ булганнарны, ягъни җиткән егетләрне сөннәткә утырту гаять авыр... Гомерлек хастага әйләнүең бар... Шуңа да ризамы?

— Риза, риза, имам-хатиб. Мин беркемне дә гаепләмәячәкмен. Тәңрем ни язган булса, шуңа күнәрмен...

Христиан динендәгеләрне мөселманлыкка күндерүдән тыелып яшәгән, моны дин әһелләренең барчасына канун итеп дүндергән Кол Шәриф бу егеткә ташлама ясарга карар бирде. Ике мәгъшук җанның Ләйлә илә Мәҗнүн мисалындагы газапларын ул йөрәгеннән үткәргән, аларга ничек тә изгелек кылырга тели иде. «Гозерләп килгән алла бәндәсенә күрсәткән бер изгелек, кайчан да булса уны белән үзеңә кайтыр»,— диләр акыл ияләре. Бәлкем бу егетнең кылган догалары да җирдә асылынып калмас, күккә барып ирешер... Барысы да бер Аллаһ кулында!» Һәм ул алдындагы намазлыкка ишарәләде.

Санька кечкенә келәмгә тезләнеп басты да муенындагы тәрене йолкып алды, аны бер читкә атмакчы иде, Кол Шәрифнең шелтәле карашын күреп, тиз генә кесәсенә тыкты һәм башын иеп хәрәкәтсез калды. Бу аның: «Мин синең ихтыярыңда, имам-хатиб!» — дигәнен аңлата, тулысынча аңа буйсынуын белгертә иде.

Кол Шәриф исә аның баш өстенә яшел сәхтиян тышлы коръән — каләме шәрифне куеп тантаналы тавыш белән акрын гына көйләп изге дога сүзләрен укырга кереште:

— Бисмил-ләһир-рахманир-рахим. Әл-хәмду лил-ләһи раббил галәмин. Әр-рахманир-рахим. Малики йәүмид-дин. Ийәкә нәгъбүдү вә ийәкә нәстәгыйн. Иһдинас-сиратал-мустәкыйм. Сиратәл-ләзинә әнгамтә галәйһим, гайрил мәгъдүби галәйһим-вәләддалина.

Мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһ исеме берлән... Моннан соң синең атың Сәет булыр... Сәет Сәлим углы. Аңладыңмы, хәтереңә сеңдердеңме, углым?!

— Әйе, имам-хатиб. Мин Сәет Сәлим углы, мөселман өммәтендәге затмын... Бөек Аллаһының җирдәге бәндәсе...

— Яхшы!. Инде бергәләп гыйбадәт кылыйк. Минем арттан кабатлап барырсың... И мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһ...

Сәет Кол Шәриф хәзрәт артыннан тылсымлы сүзләрне кабатларга кереште:

— Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, сиңа гына ярдәм сорап сыенабыз. Безне туры юлга күндер. Адашкан һәм ачуыңны казанганнар юлыннан түгел, изгелегеңә лаек кешеләрнең юлыннан атлат...

Гыйбадәтне тәмамлап, битләрен сыпырып куйдылар. Кол Шәриф егеткә торырга ишарәләде һәм, гаять авыр бер эш башкарган кешедәй җиңел сулап, үгет-нәсихәт, вәгазь сүзләрен тезәргә кереште:

— Мин кулымнан килгәнне эшләдем, Сәет Сәлим углы. Инде калганнары барысы да үз ихтыярыңда... Хак мөселман буласыңмы, әллә хрәстиян да, мөселман да булмыйча, урталыктагы бер имансыз затка әйләнәсеңме — барысы да, барысы да үзеңә тапшырыла. Әмма мин сиңа ышанам, углым. Шуңа тәвәккәлләдем дә... Аллаһы тәгалә мәгъшукаң белән кушылырга, бер-берегезне сөеп, кадерегезне белеп яшәргә ярдәм итсен. Мәхәббәтеңнең кайнарлыгын, йөрәгеңнең тугрылыгын, сафлыгын аңладым дип беләм. Җефетеңә гадел, тугры һәм хәләл ир бул, җәмәгатең исә сине аңлап, зурлап тормыш кичерүче хатын булсын! Амин! — Кол Шәриф догасын укып бетерде һәм алдындагы кәгазь кисәгенә нәрсәдер язарга тотынды. Каурый каләмен читкә куеп, язганына өстәлдәге кечкенә көмеш савыттан вак ком сипте, аны өреп төшереп, ягъни караны киптереп Сәеткә сузды. — Монда мин гыйльме табиб әһелләренә бер-ике кәлимә сүз юлладым. Теләгеңә каршы килмәсләр... Уйлаганыңны озакка сузмый гамәлгә ашыру фарыз. Йә, тәвәккәллә, углым!

Казан каласында мәхәллә саен аерым табиб булып, алар сырхауларны җәмәгать акчасына тотылучы хастаханәләрдә дә, өйләрендә дә карыйлар, кирәксә, хастаханәгә салып та дәвалыйлар икән. Аларның күбесе табиб кына түгел, фәннәрнең башка тармакларыннан да шактый мәгълүматлы, белемле адәмнәр икән. Боларны Сәетнең инде Угличта чакта ук ишеткәне бар, галим-голәмә арасында гына түгел, сәүдәгәрләр таифәсендә дә Казан акыл ияләренең абруе шактый югары куеп сөйләнелә иде.

Үзенә кирәкле хастаханәне Сәет бик тиз тапты. Гөлйөземне эзләп, аны бер күрергә зар-интизар булып, зарыгып Казан урамнарын айкап йөрү әрәм үтмәгән, ул үрмәкүч пәрәвезе җепселләре шикелле тармакланып, чәбәләнеп беткән күпсанлы тыкрык вә урамнарның кайсы кая илтүен, кайда ни-нәрсә барлыгын шактый ук яхшы абайлый башлаган икән.

Имче табиб бик кырыслардан иде булса кирәк. Ул Сәетнең гозерен тыңлап бетерер-бетермәс йөзен чытып куйды һәм кире кайтарып сорамаслык итеп кыска гына җавап та кайтарды:

— Юкка йөрисең, углым... Берни белән дә ярдәм итә алмыйм. Без балигъ адәмнәрне сөннәткә утыртмыйбыз. Нәкъ ун елга соңлагансың...

Сәет үзенең олуг ялгыш җибәрүен шунда гына аңлап алды. Кол Шәриф хәзрәтләре дә нәкъ шулай дигән иде ич. Һәм тизрәк хатасын төзәтергә ашыкты:

— Мин Кол Шәриф хәзрәтләренең мәктүбен алып килдем. Аның фатихасы белән...

Галим-голәмә арасында абруе чиксез олуг затның исемен ишетүгә, табибның йөзендәге кырыслыкны кул белән сыпырып аттылармыни, ул түбәнчелек белән баш иде, йөзенә елмаю, канәгатьлек һәм басынкы итагать билгесе кунды.

— Нигә башта ук әйтмәдең аны, — дип шелтәләп куйды ул. — Мәктүпне күрсәтүдән башларга кирәк иде...

Сәет кадерле язу кисәген табибка сузды да аның хөкемен көтеп тын калды. Хәзер менә тагын аның тормышында мөһим бер үзгәреш булачак, аны Углич белән, туганнары, ата-анасы һәм гомумән үз кавеме белән тоташтырып торучы тагын бер кыл өзеләчәк. Артка юл юк!

Аның бу уйларын сизгәндәй, табиб хатны укып бетерде дә Сәетнең күзләренә туп-туры текәлеп карады һәм барысын да хәл иткән кешеләрчә кистереп сорады:

— Соңыннан үкенмәссеңме?

— Юк, табиб әфәнде, үкенмәм... Никадәр тизрәк хәл итсәк, минем өчен шулкадәр яхшырак. Мин барысын да, барысын да уйладым инде.

— Хуп! Анысы үз ирекеңдә. Әмма хәлиткеч адым ясаганчы мин тагын бер кат уйлап карарга киңәш итәр идем. Безнең казанлылар: «Җиде кат үлчә, бер кат кис», — дип әйтергә ярата. Бу сиңа ефәк билбауның очын ки-

сеп ташлау гына түгел,— дип көлемсерәп куйды табиб.— Җан җире белән эш итәсе...— Аның әле һаман Сәетне уеннан кире кайтарасы килгәне сизелә, шуңадыр ахры, тәртмәлерәк итеп сөйләргә теле иде кебек.

— Юк, табиб әфәнде, уемнан кире кайтмыйм. Җиде генә түгел, мең кат үлчәдем инде. Синең катка да үз ихтыярым, үз теләгем белән килдем. Мин — мөселман затыннан, хак дингә үзем теләп күчүчеләрдән. Атым Сәет, атам — Сәлим булыр. Мин бар нәрсәмнең хак мөселманнарча булуын телим. Зинһар, сузмыйк... Әҗереннән тормам.

— Ай-һай, энем, борчакны тиз куырмакчысың... Яхшы! Мин сине сынап бактым. Инде сынауны үттем дип исәплә! Калганы — безнең карамакта. Мин әйткәндә ятарсың, мин әйткәндә торырсың... Ризамы?

— Берсүзсез ризамын! Ни әйтсәң, шул булыр, табиб әфәнде...

Табибның ни өчен алай әйткәнлеген, аның нәрсәне күздә тотканлыгын Сәет өч көннән соң гына төшенер. Әлегә ул үзенең тәнен вә җанын тулаем шушы имче табиб кулына бөтенләе белән тапшырганлыгын аңлап бетерми.

Имче табиб исә ашыкмый гына урыныннан күтәрелде дә Сәетне үз артыннан иярергә чакырды, кулы белән күрше бүлмә ишегенә күрсәтте:

— Хәерле сәгатьтә...

Тар тәрәзәләрдән төшкән сүрән яктылыкка күзләре ияләшкәч, Сәет диварның буеннан-буена сузылган өстәлләрдә, әллә ничәшәр катлы киштәләрдә эреле-ваклы төрле шешәләр, кувшиннар, йодрык хәтледән алып икешәр чиләк сыешлыга кадәр балчык чүлмәкләр күреп хәйран вә вәйран калды. Имән өрлекләрдәге кадакларга бәйләм-бәйләм төрле үләннәр, яфраклар, чәчәкләр, себерке итеп бәйләнгән юкә, имән вә каен ботаклары, тагын ул танып бетермәгән әллә нинди башка үсемлекләр, киптерелгән тамырлар асылган иде. Төрле зурлыктагы җамаякларда нәмәгълүм җимешләр, он хәленә китереп тарттырылган, төелгән үлән вагы, чәчәк бөреләре иде. Иң куркытканы — почмактагы адәм сөякләре булды. Ул, тәне-ите булмаса да, бөтен буена торып баскан һәм Сәеткә карап тешләрен ыржайта сыман тоелып китте. «Сихерче өненә эләктем, ахры»,— дип уйлап куярга өлгерде ул. Кайчандыр ишеткән куркыныч әкиятләрдәге мәкерле, усал сихерчеләр, тылсымчылар исенә төште, тәне чымырдап куйды. Ләкин чигенергә соң иде инде. Хәер, ул биредә үзенә начар гамәл кылынмасына чын күңелдән ышана. Кол Шәриф хәзрәтнең аңа карата игелегенә иманы камил иде. Андый затлар күрә торып кешене явыз сихерче кулына бирмәс. Бу акылга сыймас эш булыр иде. Аннан соң, йөзе җыерчыкланып бетсә дә, күзләреннән яшьләрчә нур бөркелгән бу имче карт аңа яманлык кылмас.

Имче табиб исә Сәеткә ишек катыннан урын күрсәтте дә, аны бөтенләй оныткандай, үз эшенә кереште. Өстәлдән нәни генә ак керәч савыт алды, аңа пыяла шешәчекләрдән онга охшаш берничә төрле матдә салды, аларны бармагы белән аралаштырап карады, кечкенә генә тукмак белән бик тырышып тагын бер кат изде дә савытны Сәеткә сузды:

— Менә шушыны аз-азлап кына тел астыңа сал. Гәүдәңне тоймый башлагач, тәнеңдә очып китәрдәй җиңеллек тойгач туктарсың,— диде ул серле тавыш белән.— Калганын үзебез башкарырбыз... Йә, тәвәккәлләә!..

Күрше бүлмәдән табиб ярдәмчесе чыкканын, үзен иплән кенә икенче хөҗрәгә күчергәннәрен, ятакка китереп салганнарын ул инде сизми иде. Барысы да аксыл томанга төренеп юкка чыкты. Сәет моңарчы бер дә татымаган тирән һәм татлы йокыга талды.

Ул, имеш, ниндидер сихерле бер дөньяда йөзә, су дисәң, су түгел, күк дисәң күк түгел. Идел өстендәге вак томандай сыек та, үтә күренмәле дә бер җисем. Тәнендәге җиңеллек аңа барча дөньядан өскә күтәрелергә, канат кагып очарга, әле күптән түгел генә булып үткән вакыйгаларны еракган торып, чит кеше күзләре белән күзәтергә мөмкинлек бирә, имеш. Күз алдында соңгы көннәрдә күреп танышкан, ярдәм кулы сузган яисә кабәхәтлек кылган затларның сурәтләре яңара башлады. Алар сөйлиләр дә сөйлиләр, сүзләре колакка кереп тә тормыйча баш миенең үзәгендә яңгырый, шунда язылып кала, имеш.

Яхшы хөллә, сәхтиян читек кигән мәһабәт бер зат пәйда булды. Бакты шаккатты. Бу — Казан сәүдәгәрләренең иң абруйлыларыннан Әҗем ага иде.

Әҗем ага

Карт балыкчы җибәргән кешене кире борыр хәлем юк. Мин дә синең шикелле үк аңа гомерем белән бурычлымын. Мәгъшукаң илә кавышуда үзеңне ирләрчә тота алсаң, сәүдә юлында, тормыш коруда ярдәмемнән ташламам. Бер игелек кешене мең бәладән йолыр, ди.

Шәһит

Әҗем картны кара мыеклы, зур елтыр күзле, гаскәриләр киемендәге чибәр егет сурәте алыштырды. Аның янында сары чәчле, чабаталы, сәләмә киемле икенче берсе пәйда булды.

Мыеклы чибәр егет әйтте: «Син кем? Каян киләсең? Кая юл тотасың?» «Мин карт балыкчы яныннан киләм. Казанга барышым. Үзем урыс сәүдәгәрләре кавеменнән, исемем Александр». Сәет күреп торды, Санька гаскәри киемледән бераз шикләнә, андый-мондый зыян салмагае дип шөбһәләнә иде. Гаскәри исә моны сизде, елмаеп җавап бирде: «Курыкма, Казан мәмләкәте сәүдәгәрләрне хуплый. Без сиңа зыян китермәбез, балыкчы карт юньсез адәмнәрне безгә юлламый. Инде минем дә кемлегемне бел: тоткавыл Шәһит булырмын. Кулдан килгән ярдәмне күрсәтербез».

Тагын икенче сурәт килеп чыкты. Бер төркем атлылар тыныч кына гәпләшеп урман юлыннан юырттыра. Алда, Шәһит янында бурлы айгыр өстендә Санька бара, имеш. Казан җирендә тапкан беренче дустына куанып, бәхет кошы тоткандый сөенеп бара. Мондый дус егетләр барында инде бер кем дә куркыныч түгел. Гөлйөземне кем урлаганын да, аңа ни-нәрсә булганын да тиз белеп булыр. Шәһит шаяртып сөйләшүчеләрдән түгел, тугры йөрәкле, үткен сүзле, пәһлеван егет. Әйтте бит, ярдәмемнән ташламам, диде. Озакламый Гөлйөземгә кул күтәргән җаһилләр алларында аунап гафу үтенер. Бары тик исән генә булсын! Табыйк кына...

Җиңелчә генә ат тыпырдый. Әңгәмә җебе сүтелә дә сүтелә. Санька башыннан кичкәннәрне бәйнә-бәйнә сөйли. Шәһит тыңлый. Игътибары вакыйга җебендә.

«Шул кызны минем кулымнан кара төндә йолкып алып киттеләр. Инде ни кылыйм. Йөрәгем парә-парә телгәләнә. Казанга ут йотып кайтып барам», — диде Санька. Шәһитнең кара мыеклы, кара кашлы чибәр йөзеннән тагын да каррак күләгә йөгереп узды. Борылып сорады: «Ул кызның аты нинди? Кайда аерылдыгыз? Кемнәр шулай рәнҗетте?» — диде. «Ул гүзәлнең исеме Гөлйөземдер. Ярминкә җыенында атлылар алып китте. Кем икәннәрен дә белмәдем», — диде Санька. Кинәт Шәһит атына камчы белән китереп орды, алга ыргылды да борылышта күздән югалды.

Бераздан Шәһит аларга килеп кушылды. Йөзе кырыс, караңгы, олы кара күзләре сәер елтырый иде. Санька янына килеп колагына әйтте: «Әле генә дуслар идек, инде көндәшләр икәнебез ачыкланды. Бел: Гөлйөземне урлап китүче ул мин». Санькaның ирексездән читкә тайпылуын күргәч, тагын әйтте: «Курыкма, асла сиңа заян китермәм. Гәрчә белеп торуың артык имәс, мин Казан мәмләкәтендәге дүрт куәтле ыруның да иң куәтлесеннән — җылкы ыруыннан, аксөяк морза баласымын. Хәзер үк сәне богаулап әсирлеккә сата алсам да, кулым күтәрелми. Гөлйөзем хакына тыелып калам. Күрик, белик, Гөлйөзем безнең кайсыбызны сайлар. Аның хөкеменә бирелик. Ул кемне сайласа, ничек хәл итсә, шулай булыр».

Казанга җиткәнче егетләр бүтән сүз алышмады. Атлылар төркеме Санькага үтергеч карашлар ташлады, әмма зарар салмады. Шәһит сүзе аларга канун иде.

Гөлйөзем

Тагын яңа күренеш.

Казан каласының һөнәрчән осталары, алтын куллы зәргәрләр яши торган мәхәлләсендәге биек ташпулат каршына бер төркем яшь атлылар килеп

туктады. Акрын гына капка шакыдылар. Аны хезмәтче хадим ачты. Аңа: «Гөлйөземне чакыр. Зинһар, чыксын! Шикләнмәсен, аңа бер-бер начарлык кылынмас!» — диделәр.

Капка уентыгында зәгъфыран сарылары иңгән чибәр йөз күренде. Бу — Санькаsuccessфы шашып елар дәрәҗәгә китереп җиткергән пәри кызы Гөлйөзем иде. Ул җайдакларның әле берсенә, әле икенчесенә бакты, сагышлы йөзенә үзгәреш чыкмады. Кинәт ул сәләмә киемле сары чәчле егеткә карады, авызын учы белән каплап бер аваз бирде: «Аһ!» Һәм аның гәүдәсе акрын гына җиргә чүгә башлады. Шәһитнең йөзен кара болыт каплады, әмма китмәде. Егетләренә ым какты. Тыңлаучан җайдаклар атларыннан сикереп төштеләр, ачуташлар иснәтеп кызны һушына китерделәр. Санька илә Шәһит каршына бастырдылар. Шәһит әйтте: «И җанымның бердәнбере, тыңла да хәл ит. Каршыңда ике көндәш торабыз. Кайсыбызны үзеңә тиң күреп кабул кыласың? Барысы да синең кулда. Хөкемеңә буйсынырбыз. Сайла!» — диде.

Гөлйөзем бер сүз дә әйтмәде, очынып Санька янына килде дә кулыннан алды. Гафу сорагандай Шәһиткә карады. Шәһит барысын да аңлады. Камчы белән кунычына сукты, атына сикереп атланды. Җайдаклар тавышсыз-тынсыз чаптырып китеп бардылар. Ерактан Шәһитнең тавышы ишетелде: «Дустым идең, көндәшем булдың. Инде бүтән арабызда берни калмады. Бүтән юлыма очрама. Үкенерсең. Аллам сабырлык бирсен, үземне тыя алмавым бар...»

Галиәкбәр абзый

Җирдәге гөнаһлы бәндәләрдән аерылып каядыр өскә, югарыга күтәрелгән Санькаҗның җаны аңлады: Гөлйөземнең әтисе аның каршына ватылмас чикләвектәй каты мәсьәлә куйды. Бер кулы белән рөхсәтне бирде, икенчесе белән кисте: «Бердәндер кызымның, багалмамның, җанга якын җимешемнең теләгенә каршы килә алмыйм. Инде җанының яртысы итеп сине сайлаган икән, каршы килмим. Шул ук вакытта колагыңа киртлә: минем кызым бары тик хак мөселманга гына тиң яр булачак. Башкасын белмим! Алга таба нишлисен үзең хәл ит!»

Сәет Сәлим углы гәүдәсендә җиңеллек, каты арып йоклаганнан соң була торган рәхәтлек тоеп ятагыннан күтәрелде. Гаҗәпләнеп як-ягына каранды. Ул таныш түгел хөҗрәдә, ярым караңгы бинада берүзе ята икән. Аның кыштырдаганын ишетеп булса кирәк, ишек ачылды, анда имче табибның йөзе пәйда булды.

— Мин озак йокладыммы? — дип сорады Сәет тәрәзәдән балкыган кояш нурларын тоеп. Чөнки ул кергәндә көн кичкә авышкан иде инде.

— Өч көн, өч төн йокладың, углым. Үзеңне аяп шундый дару биргән идек. Балигъ булганнарның гаурәте үтә сизгер нәрсә... Зыян китермик дидек...

Сәетнең йөзенә куе кызыллык йөгерде. Йоклаган арада үзе белән ни кылганнарын аңлап алган иде ул. Әмма оялу хисе тиз үтте, бөтен күңелен горурлык, шатлык, шушы изге күңелле затлар белән бер төрле булудан туган куаныч хисе биләп алды.

Ярминкә тәгәлләнер көннәрдә базар әһелләре Казанның иң бай һәм абруйлы сәүдәгәре Әҗемне сары чәчле, җете зәңгәр күзле, әле юньләп мыек та чыгып өлгермәгән яшь бер сәүдәгәр белән күрделәр. Сер сыйдырыр кеше буларак, ул җаен тапты, Казан малтабарларына, һөнәрчән ил агаларына:

— Ерактагы туганымның углының углы, зәргәр Галиәкбәрнең кияве... Сәүдә эшендә үзенә юл сапмакчы, — дип таныштырды.

— Миңа ышангандай ышана аласыз... Рибачы түгелмен, әмма Сәет угланны минем канат астында исәпләрсез.

Казан мәмләкәтенең базар әһелләре арасында яңа малтабар пәйда булды...

## Шомлы көннәр

Кирмәнгә кереп бикләнгән казанлылар,
Дошман яудан бер тамчы да курыкмады:
Барлык күрше дәүләтләрнең гаскәрләре:
Зур яу булып килсәләр дә бу каланы
Алу җаен таба алмый кайтыр иде!
Ә сугышка маһир, кыю казанлылар
Кирмәннән дә ныграк иде, каты иде.

XVI гасыр билгесез урыс язучысы.
«Казан патшалыгы турында риваять».

1552 елның җәе коры килде. Язгы ташулар үтеп, җир өсте куе яшеллеккә күмелгәннән соң ник бер яңгыр тамчысы төшсен дә, ник күк йөзендә бер болыт әсәре күренсен. Күтәрелеп килгән игеннәр сабагында саргая башлады, сусыл үләнле болынлыклар корыды, агачларның яфраклары бөреште. Әмма ул гына түгел, казанлылар күңеленә шом салырлык башка сәбәпләр дә бар иде. Көн белән төн тигезләшеп, җәй чилләсенә якынлашып килгәндә шәһәрдә имеш-мимешләр куерды. Алар, вакытлар үтү белән кимеми генә түгел, киресенчә, тагын да ишәеп, куркынычрак һәм дәһшәтлерәк яңа хәбәрләр белән тулыланып, өйләргә генә сыешмыйча, тыкрыктан тыкрыкка, урамнан урамга күчтеләр, кешеләр күңелендәге шомны тагын да куерта төштеләр.

Баштарак аларның чынмы-ялганмы икәненә диван әһелләреннән нә раслап, нә кире кагып бер-бер фикер ишетү мөмкин булмады. Чөнки хаким затлар үзләре дә төгәл белеп бетерми һәм кирәксез сүзләрнең зыян гына китерүеннән шикләнәләр иде, күрәсең.

Һәм, ниһаять, көннәрдән беркөнне чуан тишелде.

Атын ак күбеккә батырып куалаган Чапкын морзаның Казан капкасыннан атылып керүенә чагдавыллар гына түгел, шаһит булган дистәләрчә казанлылар да сәерсенеп, тел шартлатып карап калган иде. Мәскәү кенәзенә хезмәткә күчкән хыянәтче дип исәпләнелгән, әһле Казан тарафыннан ләгънәтләнгән морзаның каравыл башына нindидер кәгазь күрсәтеп, колагына пышылдап җай гына үтүе тагын әллә нинди имеш-мимешләр чыгуга сәбәп булды.

Чапкын морза тирләгән атын яндырудан да шикләнмичә, уңлы-суллы камчылап кала урамнарыннан туп-туры хан сараена юнәлде. Аны шыгавыллар[1] туктатмады. Нәрсәләр сөйләгәндер, нәрсәдән хәбәр җиткергәндер — анысы шәһәр халкына нәмәгълүм, әмма ул кайтканнан соң ярты көн дә узмады, шәһәр гөж килде:

— Мәскәүдә гаскәр туплыйлар!..
— Казан өстенә киләселәр, ди...
— Хыянәтче Шаһгали яшь Иванның саргаскәре, имеш!
— Казанлылардан канлы үч алачакмын, дигән.
— Иванга тугрылыкка ант эчкән зөбанидан ни көтәсең?!

Корылыклы елның ачлык белән янавыннан шөбһәләнеп яшәгән шәһәр халкы, якын-тирә авыллар өстендә икенче, тагын да куркынычрак, имәнечрәк афәтнең аяусыз күләгәсе пәйда булды.

Сәүдәнең, базарның рәте китте. Малтабарлар ашлыкка бәяне күтәрде, аның артыннан башка малларның да хакы күзгә күренеп үсте. Казан диварлары эчендә генә бикләнеп калмаган шомлы хәбәрләр саладан калага, каладан салага күчә-күчә мәмләкәтнең ерак чикләренә барып җитте, аларны үтеп чыкты. Артык сак һәм кирәксез тәвәккәллектән шикләнгән базарчылар Казанны әйләнебрәк узу җаен карый башлады.

Идел боздан арчылып, беренче көймә кәрваннары килүгә үк бураларындагы ашлыгын озатып өлгергән Сәет сәүдәгәр ярык тагарак янында утырды

[1] Шыгавыл — ишек сакчысы.

да калды. Иван белән агасы Василийның кисәтүен санга сукмавы сәбәп булдымы, еллар иминлегенә ышанычы артык зур идеме — әмма сәясәттән читтәрәк торырга тырышкан алыпсатарбыз быел алдатты, бар малын ашыгып сатып җибәрүе белән шактый зыян күрде. Хәер, ул аңа артык борчылмый, калган кадәресе гаиләсенә әле берничә ел кытлык күрми яшәргә җитәрлек, алла теләсә, башка төр мал-туар белән дә оста гына көн күрер җае бар. Аны башкасы борчый, башка уйлар җанын кимерә.

Сәет базарга чыкмас булды, үз эченә бикләнде. Шәһәр хәлләрен, дөнья хәбәрләрен хәзер улы — сәүдә тукталгач үз ирегендә калган Җәгъфәр алып кайта. Хәбәрләр исә берсеннән-берсе шомлырак, хәвефлерәк. Күңелдә бөреләнгән өмет учак кузысы күк пыскый башларга да өлгерми, яңа хәбәр аны пыран-заран китереп ташлый.

Юк! Казан өстенә моңарчы күрелмәгән олы яу килгәндә Кырым-йорт ярдәмсез калдырмас, солтан күз йомып тормас, диделәр. Сәет тә моңа ышана, элек еллардагыча, урыс Казанга килеп җиткәнче үк таркалып качар, дип өметләнә иде.

Җәгъфәр хәбәрләрне ташый да ташый. Егетнең йөзе суырылып калды, әллә ничек күз алдында олыгаеп китте. Күзләре генә ут яна. Гөлйөземнекенә охшаган зур кара күзләрендә ашкынып торган кыю дәрт тә, чаялык та, теләсә нинди хәтәр алымга тәвәккәллек тә тоемлана. Сәетне улындагы әнә шул дуамал тәвәккәллек борчый да инде. Әмма кистереп кенә берninди киңәш бирә алмый. Алай әйтсә дә, болай әйтсә дә, Казанны үлеп яраткан, аның һәр тыкрыгын, йортын, хөр күңелле кешеләрен, базарларын яшәешенең бер өлеше итеп кабул иткән, Кабанына, Болагына, мул сулы Иделенә гашыйк егетнең күңеленә яра ясар иде. Төзәлерлек кенә түгел, мәңгелек җөй, җәрәхәт салыр иде. Балага үз акылыңны биреп булмый.

«Без сугыш кешесе түгел, тыныч кына өйдә ят!» — дип аңа ничек әйтмәк кирәк!? Аңлармы ул аны, әллә әтисен куркаклыкта, хыянәттә гаепләрме? Нинди куркыныч янаганын белми, аңламый ич ул! Урыстан саклан дисә, анысын хәзер Җәгъфәр үзе дә белә булыр... Тагын ни әйтәсең?.. «Үзең урыс син, урыс булгансың!» димәсме? Сәетне иң куркытканы, йөрәген кысылып-кысылып авыртырга мәҗбүр иткәне шушы шиктер, ахрысы... Җитмәсә, Василийның өйгә килеп керүе нинди тәэсир калдыргандыр... Ни-нәрсә сөйләшкәнне улы белә. Үз вакытында аңа әйтүне кирәк тапмаган иде. Инде менә хәзер... Әйтсә, ышанырмы? Әйтсәң дә, әйтмәсәң дә, берсе дә Сәеткә аклану бирә алмый иде инде.

Ә хәбәрләр килә торды. Төрек гаскәре, тупчылары белән берләшеп, мең-мең атлы җайдакны әйдәп Мәскәүгә яу чапкан Кырым ханы Дәүләт Гәрәйнең Тула янында урыслардан җиңелүе турындагы шомлы хәбәр күңелдәге соңгы өметне дә сүндерде. Бетте! Барысы да челпәрәмә килде. Көч туплаган, хәтәрлеген, усаллыгын көннән-көн арттыра барган Мәскәү кенәзенә казанлыларга япа-ялгыз каршы торырга туры киләчәк иде. Башка яктан көтәр өмет, ышаныч калмады.

Гаиләсенә татулык, тынычлык, ил-көнгә иминлек, балаларына һәм газизе Гөлйөземгә бөтенлек бәрабәренә бар мөлкәте, байлыгы, соңгы алтыныннан ваз кичәргә әзер Сәет берни дә эшли алмады. Дәүләт Гәрәйнең җиңелүендә ул яман фал күрде, җанын газаплы көтү ачысы биләп алды.

— Дошман чирүе Иделне кичеп чыккан. Казанга киләләр!..

Бу хәбәрне җиткергән Җәгъфәрнең бите кызарып чыккан, еш-еш сулый, кая басарга, үзен кая куярга белмичә үрсәләнә иде. Аның бөтен шәһәр буйлап йөгереп кайтканы, әтисеннән — үзе өчен иң зур абруй булган кешесеннән — нииндидер хәлиткеч сүз көткәне әллә каян күренеп тора иде.

Сәет коелды да төште, авыз эченнән дога сүзләрен әвәләштермәкче булды, ләкин зиһене таркау — белгәне бер генә дә хәтеренә килми иде.

— Ни язган, шул булыр,— диде ул аптырагач.

Җәгъфәр әтисенә сәерсенеп карады да, һәр сүзен өзеп-өзеп, ашыгыпашыгып сөйләргә тотынды.

— Мин синең әйткәнеңә ышанмыйм... Ни язганны көтеп яту... ул... куркаклар эше...

Сәетнең йөрәгенә пычак кададылармыни! Бөтен багыре куырылып килсә дә, авыртуын тышка чыгармады. Кыяфәтен аклар өчен, табигатенә хас булмаганча, уенчаклыкка күчте. Үзе дә сәерсенде, теленнән углы ишетәсе килгән сүзләр чыкты:

— Ышанмый дөрес эшлисең, улым! Казан-йорт көчле, халкыбыз тәвәккәл. Кальга ныклы... Торырлар-торырлар да китәрләр. Кайда гына йөрмәдем, ниләр генә күрмәдем — мондый куәтле, ныклы ныгытмаларны очратмадым,— диде. Ул туктый алмый, сүзләре агыла да агыла иде.

Җәгъфәрнең күзләре елтырый башлады. Очынып, кабынып күргәннәрен тезәргә кереште:

— Урыслардан илчеләр килгән. «Ханыгызны, карачы, морзаларыгызны бәйләп безгә китерегез, сезгә берни дә булмас»,— дип әйткәннәр ди. Кальга өстеннән безнекеләр бер сүз белән авызларын каплаганнар: «Сез — дуңгыз ашаучылар,— дигәннәр. — Казанга баш булу кая, сез аны якыннан күрергә дә лаек түгел. Чөнки җаныгызда иман, денегездә нур юк,— дигәннәр.— Ә инде патшабызга килгәндә, без аны үзебез сайлап куябыз. Тәхетебездә тумыштан хөкемдар гали затлар утыра. Сезнең нәселсез кенәзләрегез ишене без якын да китермибез, китермәячәкбез дә,— дигәннәр... — Казан — хөр мәмләкәт, хөр булып калачак та».

— Улым, тукта, ашыкма! Илчеләр җибәрерлек булгач, алай ук начар ният белән килмәгәннәрдер...

Җәгъфәр бер тында әйтте дә ташлады:

— Урысның кайчан изге ният белән килгәне бар?! Ашаган табагына... төкереп...— Аның бите бер агарды, бер кызарды. Атасына ярамаганны ычкындырганны сизенеп булса кирәк, бер мәлгә тын калды, ни әйтергә белмичә, еш-еш сулап алды һәм басынкы тавыш белән әйтеп бетерде:— Яхшы ниятле кеше, ханыгызны бәйләп китерегез, дип киләме?

Дөрес сүзгә җавап юк иде. Сәет бер Гөлйөземгә, бер улына, бер кызы Галиягә карады да, җавап алмыйча кул селтәде. Соңгы чарасы итеп Гөлйөземгә текәлде:

— Сиңа әйтәм, нишлибез? Мин — чарасыз... Алар килеп җиткәнче авылдагы йортка — сәйфиягә[1] дә күченмәдек, ичмасам...

Сорау сәер, хәтта мондый көнне мәгънәсез дә иде кебек. Ләкин башка чарасы булмаган Сәет үзе дә белештермичә дилбегәне Гөлйөземгә тоттырды.

Гөлйөземгә — кайчандыр чибәрлеге белән генә түгел, чаялыгы, үткенлеге белән дә Казан егетләренең күзен яндырган Гөлйөземгә әллә нәрсә булды. Иренең сыгылып төшүе, югалып калуына үртәлде, эче пошты, аның белән икe арага күтәреп булгысыз авыр нәрсә ятты кебек. Ләкин, бер мизгелдә күңелендә кайнап алган хисләрне авызлыклап, ул үзен кулга алды һәм сабыр итеп, ләкин кистереп фикерен белдерде:

— Кеше ни эшләсә — шуны эшләрбез. Яу килгәндә кулына корал алмаган ир — башына бүрек кияргә оялыр... Нәселебездә куркаклар булмады.

Гаилә киңәше шулай тәмамланды.

Үз-үзен кая куярга белмәгән Сәет ашыгып урамга чыгып китте. Аңа фикерләрен тупларга, нинди дә булса бер карар кабул итәргә, ни кылырга кирәклеген ачыкларга кирәк иде. Кая басканын, ничек атлаганын тоймыйча урамнар буйлап йөрде дә йөрде. «Чыннан да, хәрәмзадәләрнең сүзе дөрескә чыктымыни соң?!» Ул — мәмләкәттә сыенып урын, әһле базар арасында гына түгел, гавамда абруй казанган Сәет сәүдәгәр ни эшли ала? Теленә йозак, күңеленә богау салып тагын ялгыштымы? Вакытында диван әһелләренә, инде алардан шикләнсә, үзенә хәерхак булган, иң өметсез чагында баласыдай күреп ярдәм кулы сузган Кол Шәриф хәзрәткә сиздерсә — үкенече дә бу кадәр авыр булмас иде.

Ул үзенең кайсы урамда, нинди төбәктә йөргәнен дә абайламый, чигәсен бораулап кергән соравыннан газапланып, дивана хәленә калган адәмдәй, бернинди максатсыз атлый да атлый иде.

---

[1] Сәйфия — дача.

Кинәт колак төбендә туптан аткандай яңгыраган дум-думбаклар гөрселдәвеннән сискәнеп китте, авырттырып кысылган йөрәгенә чыдый алмый күкрәгенә тотынды. Кайда килеп чыгуын шунда гына абайлап алды Сәет. Хан сарае алдындагы киң мәйданда, шаулашкан, гөжләшкән кешеләр арасында икән ләбаса. Алар нәрсәдер кычкыралар, ачулы кыяфәт белән йодрыкларын төйнәп урысларга хурлау, каргыш, ләгънәт сүзләре яудыралар иде. Думбак тавышлары аларның барысын да күмеп китте, бер мизгелгә мәйданда авыр тынлык урнашты. Шул чакта һәммәсе дә хан сараен мәйданнан аерып торган таш дивар капкасына борылды. Ялтырап торган тимер башлык, тимер көбә кигән, түгәрәк калкан, үткен айбалталар тоткан чагдавыллар үзләренә генә мәгълүм ниндидер әмергә буйсынып, тимер капканы каерып ачып җибәрделәр, мәйданга җайдаклар ыргылып чыкты. Аларның кулларындагы озын сорнай-көрнәйләрнең җизендә кояш нурлары чагылды, йөзләрендә кырыслык, кыяфәтләрендә кыюлык, шушы мизгелдә үк утка-суга ташланырга әзерлек чалымнары иде. Чая егетләр атларын уйнатып алдылар да, берничә төркемгә бүленеп, кала урамнарына чаптырып кереп киттеләр.

— Сөрәнчеләр! Сөрәнчеләр килә! — дип кычкырды кемдер.

— Тыңлагыз, оран салучылар чыкты...

— Олуг хан галиҗәнабларының ярлыгын, ил-көн өстенә канлы гарасат янаганда олуг хан сүзен, диван фикерен ирештерәчәкләр...

Сәетнең тирә-ягындагы кешеләр шулай сөйләште.

Мәйдан уртасында ялгызы калган сөрәнче атын тыеп, өзәңгеләрендә күтәрелде дә сорнай-көрнәен иренәнә тигереп, сузып-сузып оран салды:

— Газиз кардәшләр, куркусыз илдәшләр, кыю йөрәкле казанлылар, батыр җирдәшләр! Тыңлагыз! Тыңлагыз олуг хан — галиҗәнаб Ядегәр хан ярлыгын! Диван әһелләре, сәетләрнең сәете изге Кол Шәриф хәзрәт сүзләрен сезгә җиткерәбез...

Без Мәскәү кенәзеннән дә, аның саранча өере булып төшкән явыннан да шүрләмибез. Кыяларга бәрелеп шаулаучы диңгез кеби аның аяусыз, канлы гаскәре. Әмма безнең кальгабыз кыядай нык, диварлары биек, капкалары тимер. Нидән куркыйк?! Таш кыяга ташланып күбекләнүче дулкыннанмы?! Яугирләребез, кешеләребез җитез, кыю, пәһлевандай куркусыз. Базларыбызда ун елга җитәрлек азык-төлек. Арабызда денсез кяферләр юк. Динебез, илкөнебез, хөрлегебез, балаларыбыз, чал картларыбыз, аналарыбыз хакына җаныбызны аямабыз. Кулыбызда корал тотарлык көч барында безне моннан беркем дә әсир-кол итеп алып чыга алмас! Урыска кол булудан да түбән, җирәнгеч нәрсә юк.

И горур казанлылар!

Ыру тамырлары безнекеннән сай, диннәре вә деннәре безнекеннән түбән хрәстияннәргә кол булырбызмы?! Юк!!! Аллаһы тәгалә моңа юл куймас!

Мәйданда җыелган халыкның сөрәнчене хуплап бер тын белән кычкыруыннан Сәетнең тамырларында бозга әйләнә башлаган каны җылынды, җанына тынычлык, өмет һәм ышану иңде. Якты дөньяны томалаган шик пәрдәсе таралып, күз аллары яктырып китте. Ничек башыннан чыгарган соң ул, сугышта әсир булуга караганда үлемне артыграк күрүче казанлылар тәҗрибәсез, мәнсез Иванга баш иярме? Юк, әлбәттә...

Мәйданны меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылып чыккан ярсулы авазлар күмеп китте:

— Юк! Кол булмабыз! Булмабыз!

— Урыс астында калганчы, яу кырында үлүең мең артык!..

Морза балалары, яугирләр, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, шәкерт вә таләбәләрдән алып кол-чураларга кадәр барчасы кулларын йодрыклап өскә күтәрде, сүзнең һәр иҗеге саен йодрыклары белән күккә, фараз кылынган дошманга кизәнгәндәй селтәнделәр. Мондый берлек-бердәмлекне, меңнәрчә бугаздан берьюлы ургылган дәһшәтле авазларны ишеткәне булмаган Сәет, казанлыларның тәвәккәл батырлыгына, кискен җавабына хәйран калды, сок-

ланды, алар белән бергә тамагы карлыкканчы, күзеннән яшь чыкканчы илерә-илерә кычкырды:

— Казанны бирмәбез! Бирмәбез!

— Баскыннарга ләгънәт! Мең ләгънәт! Ләгънәт!

Гомум шаукымга бирелгән, үз-үзен белештермичә ярсып-ярсып кычкырган җиреннән ул кинәт туктап калды. Башына күсәк белән ордылармыни!.. Кылт итеп Иван сәүдәгәр, аңа биргән вәгъдәсе исенә төште. «Үзең булмасаң, улыңны беләбез, җиде кат җир астыннан эзләп табарбыз», дип зәһәр пышылдаганы миен көйдереп узды. «Ул бала кайда йөри икән?» Бүз углан булып үсеп килүче Җәгъфәрне аяп, ул аңа янаган куркынычны белдермәде, эченә йотты, азмы-күпме сакланып йөрергә кирәклеген дә искәртмәде иң. «Йа хода! Инде аңа карата бер-бер хаинлек, кабахәтлек кылынмаса ярар иде. Хәрамлык, хөсетлек утында янган, сугыш әләме күтәреп килгән Иваннан барысын да көтәргә була. Казанда шымчылары булмый калмас. Тәгаен бардыр. Аллам сакласын!»

Сәет пышылдап дога укыды һәм, аяклары тартмаса да, мәйданнан чыгып китәргә, кайтып тизрәк Җәгъфәрне күрергә, күңелен тынычландырырга ашыкты. Кабаланып, чаба-йөгерә диярлек сәүдә рәтләре ягына төшеп китте. Салмаклыгы, кеше белән аралашуда вәкарьлеге белән танылган Сәет сәүдәгәрнең болай пырдымсыз кылануын башка вакытта күпләр сәерсенеп карап калыр, бер-бер хәл булгандыр дип фараз итәр, ярдәмгә ашыгыр иде. Әмма бөтен Казан таяк тыгып болгаткан кырмыска оясыдай кайнаган бу мәлдә аңа игътибар итүче дә, әйләнеп караучы да табылмады.

Чат саен сөрәнчеләрнең авазлары, әйтерсең, аны эзәрлекли, дошман алып килгән дәһшәтнең ачылыгын исенә төшерә, күңелендә кайнаган каршылыклы уйларны тагын да болгата, зәһәррәк төсләр бирә-бирә артыннан ияреп килә иде.

— Тәнендә җаны булган азамат ирләр, чая егетләр, кавырсыны ныгыган бүз балалар ил өстенә афәт килгәндә куләгәдә калырмы?!

— Мөхтәрәм казанлылар! Дары базларында дары җитәрлек...

— Барыгыз да коралга! Күзе үткеннәргә — мылтык, ук-җәя, беләге нык-ларга — кылыч, бәдәне тазаларга — сөңге, айбалта, гөрзи!..

— Изге калабызны этләрдән талатмыйк, дуңгыз ашаучылардан нәҗесләтмик!

Ләкин ничек кенә бәргәләнмәсен, җанын кыйнамасын, үрсәләнеп иренен чәйни-чәйни бәддога укымасын — Сәет инде берни дә эшли алмый, бер генә нәрсә дә аңа бәйле түгел иде. Үзен сыендырган, байлык һәм муллык биргән, тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте бөреләнеп чәчәк аткан, каныннан яралган газиз балалары тәпи баскан шәһәрне, бөек Казан патшалыгын, җирдәге җәннәткә тиң изге мәмләкәтне саклап, яклап калу өчен ул хәзер инде берни дә эшли алмый иде. Кайчандыр булган мөмкинлекне кулдан ычкындырды, тар күңеллелек, курку колына әйләнде. Гомерендә бер мәртәбә кулына мылтык алып атмаган, кылыч белән кеше канын коймаган, җан кыймаган, базар әһеле булып тыныч кына яшәп яткан сәүдәгәр Сәет ике ут арасында торды да калды.

Җанын изгәне шул: һәр ике як та аңа бердәй якын, һәр ике як та аңа газиз, кадерле. Күкрәк сөте имезеп үстергән, телен ачкан анасына, уналты ел хәләл икмәген-тәгамен ашаткан атасына, бер ятакта аунаган карындаш агасына кул күтәрсенме, яисә җанының яртысы — хәләле Гөлйөземгә, җир йөзендә кеше иткән, үчне-хөсетлекне белмәгән, туганыннан якын күреп үз араларына алган Әҗем картка, кайчандыр сукбай егеткә фатихасын биргән Кол Шәрифкә, бәгыреннән өзелеп төшкән балаларына хыянәт итсенме?!

Пошамангa калырлык та бар. Ничек кенә сәер тоелмасын, Сәетнең моңа кадәр бу хакта тирәннән уйланганы, тән йокыларын калдырып, газапланып баш ватканы булмады. Ә гомер дигәнең көйрыклы юлдыз шикелле үткән дә киткән ләбаса! Яшьлектәге хаталар, комарланып дөнья куу, искә-өскә алмаган әллә ни кадәр вак-төяк ялгыш адымнар Сәетне чишә, сүтә, ерып чыга алмаслык катлаулы, гаять тә четерекле мәсьәлә алдында япа-ялгыз калдырды. Барып сыеныр кешесе дә юк бит ичмасам. Хәер, алай ук түгел. Алар

бар. Күп тә хәтта. Хәлбуки, дус-иш булсалар да, алар Сәетне аңламас, ул кичергәнне төшенмәс, газапларының серенә керә . алмас. Чапкын-күзәтчеләрнең әйтүләре хак булса, Казан капкасы төбендә йөз илле меңлек урыс явы корал шалтыратканда Сәетнең шик-шөбһәсе, икеләнүенең ни бәһа торачагын дивана кеше дә бер сүз белән әйтеп бирә алыр иде.

Аңа хәзер бер генә юл — эчендәгеи тышына чыгармау, авызга су кабып шым булу! Башка чара юк! Берьюлы ике куян койрыгын тотып булмаган шикелле үк, ул күңеленнән ике якны да якын күрә, әмма бер якка да авыша алмый. Бизмәнгә артык зур, кеше гакылы колачлый алмастай олы төшенчәләр — яшәү һәм үлем, намус һәм кабахәтлек, мәхәббәт һәм нәфрәт салынган. Мәхәббәтне сайласа, үлчәү тәлинкәсенең икенче ягындагы нәфрәт калкып чыга, яшәүне алыйм дисә, бизмәндәге үлем якыннарына, газизләренә яный башлый. Намусын саклыйм дисә, икенче бер тарафтан кабахәтлек баш күтәрә. Йа хода! Нинди гөнаһларым өчен җибәрдең миңа мондый җәзаларны?!

Җир йөзендәге дүрт кыйтганың сәүдә кыйбласы Казан-йорт бу афәттән исән-аман котылырмы? Хәзер барча мөэмин-мөселманның җанын шушы сорау кыйный. Сәет яхшы белә: Казан-кальга Кырым, Әстерхан мәмләкәтләренең, нугай урдасының, даладагы күчмә төркиләрнең калканы гына түгел, үсеп, көчәеп килүче Мәскәү кенәзлегенең ярсуын Ливония, Швеция, ләх короленнән читкә юнәлтеп торучы олы көч, бөек мәмләкәт тә ул. Әгәр, күзәтчеләр раслаганча, яшь Иван бар куәтен-көчен Казан-йортка ташлаган икән, димәк ки ливониялеләр, ләхләр, шведлар да тик ятмас, хуҗасыз калган йортка тәмгысын сузучылар табылыр. Шулай булгач, бәлки әле урыс гаскәренең Идел, Казан суы буйларында котырган эт өередәй айкалуы озакка бармас... Ләхләр яисә ливониялеләр кузгалуга, артын-алдын уйламаган Иван тупларын, азык-төлек төягән көймәләрен, арбаларын чәчә-чәчә Мәскәвенә чабар.

Ул гына да түгел... Кара диңгез ярларын дер селкетеп торучы солтан, кардәш Кырым-йорт, Әстерхан хакимнәре Казанның ялгызы канга батып урыс белән чапырылышуын тыныч кына карап ятарлармы? Юк, әлбәттә! Димәк, артык борчылырга, үзеңне ватарга ярамый. Афәтле кара көннәр үтәр дә китәр, янәдән Казан суы ярларына дөнья малтабарларының бихисап кәрваннары агылыр. Ничек тә күзгә-башка чалынмыйча сак кына, сабыр гына кара көннәрне үткәреп җибәрергә кирәк. Иншалла! Барысы да бетәр, үтәр... Урыс белән татарның беренче бәрелеше генә түгел. Азау ярган малтабарлар әйтмешли, Казанда «әлиф» дип әйтсәләр, мәскәүлеләр «би» диярга мәҗбүр, ә инде «әлиф-би»дән соң ливониялеләргә бер генә юл — «ти» диярга генә кала... Элек шулай иде, шулай булыр, шулай дәвам итәр. Амин! Шулай гына була күрсен!..

Миендә чәбәләнгән, чуалган йомгак хәлендәге уйларының эзлекле агымга керүе Сәетнең күңелен күтәреп җибәрде. Буыннарына хәл керде, күтәрә алмастай хәсрәттән сыгылган гәүдәсе турайды, сынын төз тотып, егетләрчә житезлек белән юлын дәвам иттермәкче иде... Олы урам чатыннан Аталык тыкрыгына борылуга, күкрәгенә гөрс иттереп нәрсәдер килеп бәрелде.

— Күзең чыкканмы әллә? Ат астына керәсең... Гомереңне урыс белән сугышырга сакла! — дип гөрелдәде калын күкрәк тавышы.

Әле яңа гына ак-караны аерып хәлгә килгән Сәет керфекләрен челт-челт йомды. Каршында түшенә каешлар белән табак зурлыгында тимер ат калканы беркетелгән озын торыклы чаптар басып тора иде. Маңгае белән калканга килеп төртелгән Сәет аны-моны аңламыйча, артка сикерде.

Тагын җайдакның калын тавышы ишетелде:

— Ә-ә... Синмени әле бу мөхтәрәм Сәет Сәлим углы... Кая шулкадәр ашыгасың?..

Шушындый көндә, иң кирәксез чакта, йөрәге алгысуга түзә алмыйча үзен кая куярга белмәгән мизгелләрдә нәкъ менә аны очратырмын дип башына да китермәгән Сәет телсез калды. Ат өстендә күптәнге танышы, кайчандыр көндәшләр булган би углы Шәһит утыра иде. Аның тавышында

мыскыллау чалымнары, астыртын көлү сиземләгән кебек булды Сәет. Бәлки алай да булмагандыр. Әмма күңеле тулы шик аңа шулай тоемларга куша иде. Дөресен әйтергә кирәк, моңарчы да юллары кисешмәде түгел. Ләкин ни Сәет сәүдәгәр, ни Шәһит морза бер-берсенә этлек эшләмәде, нәкъ кирәк микъдарда гына ташлама ясый белделәр, күзгә-башка бәрелмәслек иттереп кирәксез очрашулардан кача килделәр. Әйе, шулай иде. Гөнаһысына керәсе юк, Казан-йортта сүзе үтүчән абруйлы нәселдән булса да, Шәһит үчлек кылмады, хөсетле адәм түгел иде. Ә менә бүген... нигәдер аның гөбедән чыккандай тавышыннан йөрәге дертләп китте, анда, әйтерсең, төрттерү, яшерен киная бар иде. Сәет аны нәкъ шулай, үзенең үткәненә, дошманнар белән кардәшлегенә төрттерү дип кабул итте.

Миеннән яшен тизлеге белән шундый уйлар узды. Авызына су капкандай тору уңайсыз иде, аны бит башкача аңларга да мөмкиннәр, җавап бирергә ашыкты:

— Әйе, мин фәкыйрегезмен, Шәһит морза... Мондый көндә... ничек ашыкмыйсың...

— Җавабыңны хуплыйм, тәкъсир! Кулыңда соңге тотарлык җегәр тойсаң, йөрәгеңдә яугир утын алтын чыңы томаламаса, рәхим итеп, минем алаем[1] урын табылыр. Рәхим-шәфкатьсез дошманга ялгыз чыкмассың ич...

Шәһит сүзләрен әйтеп бетерде дә, җавап көтеп тә тормастан, үкчәсендәге типкеләрен түземсезләнеп ал тояклары белән җирне тырнап торган ярсу атының кабыргаларына батырды. Дөл-дөл кыяфәтле, ялыннан бәкәленәчә ап-ак төстәге чапкыр кешнәп арт аякларына басты һәм җайдагын Аталык капкасы ягына очыртып алып та китте.

Саргаскәрнең ялгыз юлаучы белән сүз алышканын сабыр гына көтеп торган пәһлеваннар тезгеннәрен бушатты һәм буәлеп торган ташкын ургылып Сәет яныннан агыла башлады. Аларның тимер көбәләрендә, очлы тимер башлыкларында, ат дирбиясенең шомартып ялтыратылган җиз өлешләрендә кояш нуры уйнады, киң урамны ташка бәрелгән меңнәрчә тояк тавышлары күмеп китте. Сафлар өстендә ефәк әләмнәр, соңге сабына күтәрелгән тулар[2] җилфердәде. Гаскәр ярсу иде, ачулы иде, көче-куәте ташып торган тоташ агым иде, сүзсез иде.

Аларны үткәреп җибәрү өчен янәшәдәге йортның капкасына сыенган Сәетнең әллә нәрсәдәш тәне калтыранып куйды, йөрәге касылды. Үз көнен үзе күргән һәм инде малтабарлыкта — сәүдәгәрлектә иң югары баскычка ирешеп тыныч кына яшәп яткан, гаскәрилектән бихәбәр кешенең Казан урамнарында мондый зур көчне, дәһшәтле ташкынны, таш манараларны селкетер куәтне күргәне юк иде әле.

Күңелендә урнашып өлгергән тынычлану хисен кул белән йолкып алдылармыни: тагын шикләр өермәсе кузгалды, күңелендә курку, бу тиелгысыз ташкын сытып-изеп үтәчәк кан-кардәшләрен кызгану дулкыны күтәрелде. Сугышның котылгысыз икәнен белгән хәлдә дә ул аны булдырмас өчен җанын-тәнен кызганмаска әзер иде. Әмма хисләрен авызлыклап тыя алмаган кебек, үзенең чарасыз икәнен, вакыйгалар колы икәнен дә яхшы аңлый. Янарына сыендырып кеше иткән, ил-көн арасында дәрәҗә, мал-мөлкәт биргән, нан һәм дан уртаклашкан казанлылар газиз һәм якын булган кебек, урыс кавеме дә аңа дошман түгел, якын һәм газиз иде. Һәр ике якка миһербан, шәфкать һәм мәрхәмәт, бер-берен аяуны теләп кемнәргә генә баш орырга!!!

Әгәренки шушы мизгелдә «Син — доньялыкта Сәет Сәлим углы, тумышың, чыгышың илә Александр Савельич Булгаков, җаныңнан ваз кичсәң, барысы да үз урынына кайтыр, урыс явы кубарылып кайтып китәр, казанлылар тынычланып элеккечә көн күрә башлар. Ризамы шушыңа?» — дисәләр, ул ике дә уйлап тормый, каланың иң биек манарасына менеп йөз, мең мәртәбә кычкырыр иде.

---

[1] Алай — полк.
[2] Ту — борынгы төрки халыкларда ат кылыннан ясалып, башына ай сыны урнаштырылган байрак.

— Риза, риза, мең кәррә риза! Тик хәләлем Гөлйөзем сау булсын, газизләрем Җәгъфәр илә Галия генә ачылып җитмәгән чәчәк көйгә харап булмасыннар... Кешеләр! Сез — адәми зат, аллаһы тәгаләнең сөекле коллары, табынуыгыз төрлечә булса да, бер кодрәт иясенең балалары, туктагыз, акылыгызга килегез, җир йөзендә урын җитмиме әллә,— дип сөрән салыр иде.

Аһ, ни аяныч! Бу аның кулыннан килми. Күзләрен кан баскан, җан һәм кан даулап, гөнаһлы дөньялыкта үзләренә җәннәт кора алган казанлылардан җир-су яуларга килгән явыз урыс Иванны айнытыр көч юктыр, күрәсең. Мондаен дәһшәт каршында казанлыларга бер генә юл — канга кан, үлемгә үлем белән җавап бирү, изге каланы яклап соңгы сулышкача дошманны кыру, юк итү, җир өстендә эзе калмаслык итеп себереп түгү.

Гаскәр үткән арада Сәет шуларны уйлап өлгерде. Соңгы атлы чаттан борылуга, юлын дәвам иттермәкче булып кузгалган гына иде, олы урамның аргы башында тагын бер төркем атлылар күренде. Алар дәртле тавышлар белән һай-һулап бөтен киңлекне тутырып чаптыралар иде.

— Нөгәрләр[1] алае, угланнар төркеме,— диде кемдер, шатланып хәбәр салды.— Һай, ничек матур киләләр!..

Сәет яңадан капка куышлыгына ешынырга мәҗбүр булды.

Ә угланнар төркеме, чыннан да, матур иде. Сөлектәй атларда зифа сынлы яшь егетләр... Гәүдәләре төз, кыяфәт көяз. Әле мыек та чыгып өлгермәгән иреннәре арасыннан ак тешләре күренә дә, йөзләрендә кырыс чаялык тоемлана.

Ерактан томырылып килгән яшьләр хан сарае мәйданына җитәрәк атларын тыя төшләр, бер-берсен дәртләндереп ярсып кычкырышулары, шаярышып әйтешкәннәре тагын да ачыграк ишетелә башлады.

— Канга — кан, үлемгә — үлем!..

— Казанга яу белән килгән яудан әҗәлен табар!..

— Әй, мөхтәрәм җирдәшләр, илдәшләр! Чын ир затлары барында Казан саклаучысыз, яклаучысыз калырмы?!

— Меник ярсу атларга, хөр Казанны сакларга!

Алгы сафларда иптәшләрен дәртләндереп, кычкырып барган егеткә арадан берсе шаярып төрттерде:

— Кулыңда сорнай түгел, сөңге! Әллә оныттыңмы, җыручы-чичән?

Җыручы-чичән дигәнгә кәефе килдеме, атын уйнатып барган киң күкрәкле егет бәрхеттәй йомшак, әмма көчле, калын тавыш белән, тирән сулыш алып җырлап та җибәрде:

Без капкадан чыккан чакта
Гөрселди урам ташы,
Гөрселдәсен урам ташы,
Калтырар дошман башы...
Һай!

Аны йөзләрчә угланнарның дәртле, яшь тавышлары күтәреп алды:

Һай!
Гөрселдәсен урам ташы,
Кыелыр дошман башы...

Җыенга баргандай чиста, ак-пакь киенгән, кулларына кылыч, сөңге тоткан, аркаларына ук-җәя аскан, коралчы кулыннан яңа гына төшкәндәй көмеш аклыгы белән ялтыраучы калканнар аскан нөгәрләрнең дәрте, ярсуы урамдагы узгынчыларга да тәэсир итми калмады. Берәүләр аларның чаялыгына, көязлегенә сокланып тел шартлатты, икенче берәүләр дога укып егетләргә җиңү, дан, кыюлык теләде, яшь кызлар ат тояклары астына тәңкә сиптеләр, чәчкәләр ыргыттылар.

Бер көн эчендә оешып, тупланып өлгергән гаскәрнең күплегендә, дошмани көчләрнең биниһая зур куәт белән кала капкасы төбендә генә ярсып

[1] Нөгәр, нүгәр — морза, би балаларының дус егетләре. Алар, гадәттә, бер алайда сугышкан.

азынуына да карамастан, көр күңеллелегенә Сәет хәйран вә вәйран иде. Кинәт аның йөрәге жу итеп китте, күргәненә ышанмыйча, күзләрен уып алды. Нөгәрләр сафында аның газизе, бердәнбер улы Җәгъфәрнең йөзе балкый иде.

Ата белән улның күзләре очрашты. Җәгъфәр өзәңгесендә күтәрелде һәм сөңгесен болгап әтисен сәламләде. Аның бөтен кыяфәте, гәүдә тотышы: «Әти, күр! Мин дә кала саклаучылар арасында. Йөзеңә кызыллык китермәм!» — дип сөйли, шуны белгертергә тели иде кебек.

Җәгъфәр җәйләүләргә чыгып, үзе тәрбияләп, карап үстергән алмачуар айгырны иярләгән, дирбияләрнең иң асылын, кыйммәтлесен сайлаган иде.

Үзе өчен иң кадерле затның — багалмасының дәһшәт эчендә югалып калмавы, киңәшми-нитми нөгәрләр алаена керүе Сәетне бер яктан сөендерсә, улының кыюлыгыннан горурландырса, икенче яктан ут йотарга, аның язмышы өчен борчылып кыйналырга мәҗбүр итә иде.

Атлылар үтеп китүгә бушанган урамда Сәет уйлары белән ялгызы гына басты да калды. Бу мизгелләрдә ул, чыннан да, ялгыз, бөтен Казан мәмләкәтендә япа-ялгыз иде, күрәсең. Әллә каян Җәгъфәрнең бала чагы — туп кебек йомры, ак шалкандай чиста, садә чагы, сөеп туймастай чагы исенә төште.

Уртак мәхәббәт җимеше, каннарын кушып яралган нәни йомарламнан да кадерле, аннан да тансык, газиз нәрсә юк иде ул чакларда Гөлйөзем белән Сәеткә. Ай бу гомер дигәнең! Бала бишектә чакта сөйдерә, аннан төшсә көйдерә, дигәннәр. Хактыр, шулайдыр!..

Җәгъфәр тугач, ике арадагы якынлык, мәхәббәт хисе кимемәде генә түгел, тагын да ныгыды, азмы-күпме аларның татулыгыннан көнләшеп йөргәннәрне дә сокландырырлык дәрәҗәгә җиткән иде. Дөньялыкта шулай бит ул: әллә каян гына килеп чыккан берәүне тиң күргәнче, үз араларына кабул иткәнче күпләр аны баштарак сөйми һәм, бу сөймәүне яшереп тә тормый, һаман-һаман читкә кагарга тырыша. Ә инде бернинди хөсетлеккә карамый үзенекен иткәнне, юлыннан тайпылмаганны күрсәләр, сокланып сөйли башлыйлар, үрнәк итеп куярга да күп алмыйлар. Чыннан да шулай. Мәхәббәттән нәфрәткә бер адым булган кебек, нәфрәттән мәхәббәткә дә бер генә адымдыр, күрәсең!

Ничек кайтып кергәнен дә сизмәде Сәет. Капканы ачып баш игән хезмәтчегә күтәрелеп тә карамыйча йортка үтте. Тизрәк, тизрәк Гөлйөзем янында тынычланасы, рухын, җанын изгән газаплы уйлардан арынасы килгән иде. Яшь чакларындагыча бар дөньяны онытып, хатынының назлы кочагында эрисе, яратып әйтелгән сүзләрдән изри-изри котылгысыз мәшәкатьләрдән ваз кичәргә иде бит!

Гөлйөзем дәшмәде. Куе керфекләре арасыннан күз сирпеп алды да читкә борылды. Ни эшләргә белмәгән Сәет: «Әй, сагынып та кайттым соң үзеңне»,— диясе урынга, бер сулыштан яңа хәбәрне әйтте дә салды:

— Җәгъфәр нөгәрләр алаена язылган. Угланнар арасында күрдем,— диде.

— Әйе, аңа мин рөхсәт бирдем,— диде Гөлйөзем басынкы тавыш белән. Күзләренә тутырып карагач, тагын өстәп куйды: — Ил өстенә гарасат килгәндә әнкәсе куенында ятмас!

Сәетнең йөрәгенә пычак кададылармыни!..

Гомерендә күтәрелеп иренә үпкә йә кинә белдермәгән Гөлйөземнең сүзләрендә киная ачык, артык дәрәҗәдә аңлаешлы иде.

Гаилә башы нә хуплау җәһәтеннән, нә каршы төшү җәһәтеннән өздереп бер сүз дә әйтә алмады.

— Ә-ә... Шулаймы?! Алай булса, ярар,— диде дә Гөлйөземнең күзенә туры карамас өчен, ашыгып түр бүлмәгә кереп китте.

«Утырып бер сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Болай ярамый ласа. Гаскәри түгелмен. Минем хәлне ул аңламаса, кем аңлар?! Эчемдә янган утны белми. Телем йозакта, кулым богауда... Нишлим?»

Сәетнең эчендәге ут кимемәде генә түгел, бөтен әгъзаларын яндырып, котырып ялкынланырга керешә. Гөлйөземнең аны куркак дип, яисә урыска

каршы барырга теләми дип бәяләячәген ул белми түгел, белә һәм хәзер моның нәкъ шулай икәнлеген дә төшенеп өлгергән иде инде. Хәер, бөтенесе дә, чыннан да, шулай да бит... Аңламыйлар, белмиләр... Кем өчен өзгәләнгәнен белмиләр. Әле дә ярый Җәгъфәр белән Галия сиздерми. Әгәр алар да шуны әйтсә, шикләнгәннәрен белдерсә?!

* * *

Казанның һәр тарафын кара чирү булып урыс гаскәре чорнап алды. Кальга өстеннән караганда баштарак мыжгып торучы тоташ бер көч шикелләрәк кенә күренгән яу хәзер тагын да якыная төште, иярләренә үлек эт башы аскан кызыл киемле, очлы башлы бүрек кигән сугышчыларның кырыс чырайларын, алай-алай булып урнашкан төркемнәр өстендә җилфердәгән кызыллы-зәңгәрле әләмнәрне дә абайларга мөмкин.

Дошман ләшкәренең[1] иге-чиге юк. Болак аръягындагы болынлыктан алып офыкта күгелҗемләнеп торган урманнарга хәтле ара кызыллы-каралы чуар атлылар, җәяүле укчылар белән тулы. Урыс озакка дип килгән. Утрау-утрау итеп калдырылган ачыклыкларда авыр, юан көпшәле туплар, мичкә-мичкә дары өемнәре. Алар янында атлы сакчылар таптана. Укчылар һаман агыла да агыла. Әйтерсең, Мәскәү кенәзе үз кул астындагы кенәзлекләрдә бер генә ир затын да калдырмыйча чирүенә куып керткән.

— Билләһи, шулай бу! — Алмачуарын дус егетенә калдырып кальга өстенә менеп баскан Җәгъфәр күңелендәген кычкырып әйткәнен сизми дә калды. — Их, Аталык манарасындагы авыр туптан дары мичкәләренә бер ядрә тондырырга иде!.. Күлләре күккә очсын иде.

Янындагы тупчылардан берәү яшь угланның кычкырып хыялланауын әллә хуплап, әллә яратып бетермичә кырыс кына әйтеп куйды:

— Урыслар да дивана түгел. Кала тупларының ни арага ата алуын исәпләгәннәр дә, нәкъ ядрә җитмәс җирдә чокыналар! Юкса, күрсәтер идек!

Ике арадагы дәһшәтле тынлык, һәр ике якның ашыга-ашыга сугышка, тәүге бәрелешкә әзерләнүе картрак, дөнья күргәнрәк гаскәриләрнең күңеленә шом салса да, аларның ни уйлавыннан, ни кичерүеннән бихәбәр Җәгъфәр тагын киңәш биргәндәй үзенекен сукалады:

— Дарыны күбрәк салсаң да җитмиме?

Тупчыларның әле генә сукранганы кызыксынып егеткә карап алды да җилкәсен җыерды. Иптәше җавап бирде:

— Туп үзенекен сорый ул. Артыгын салсаң, ядрә белән бергә үзең дә җәһәннәмгә олагырсың. Белдеңме?!

Уңайсыз, көлке хәлгә таруын аңлаган егеткә тупчылардан читкә кыеклаудан башка чара калмаган иде инде. Ул ачуын эчкә йотты, кыдрачлыгына уртәлә-уртәлә койма өстендәге ачыклыкка менеп басты да урыс гаскәрен күзәтергә кереште. Күзләре талчыкканчы, ачытып яшьләнгәнче карап торды. Кыяфәтләреннән, йөзләреннән, йә булмаса, үзләрен тотышларыннан ниндидер куркыныч сыйфат, дошманлыкны белгертүче нинди дә булса бер әшәке хасият табарга тели иде. Күпме тырышмасын, ул әлегә андый нәрсә абайлый алмады. «Ерткыч та бит тыныч чакта тыштан караганда бик сөйкемле, матур күренә. Болар да шулайдыр... дошманлыклары эчләрендәдер», — дип үзенчә нәтиҗә ясады. Һәрхәлдә, үз иркендә булса, казанлыларга афәт янамаса, сугыш хәле игълан ителмәсә, ул бу ят киемле кешеләр белән һич кенә дә сугышып тормас иде. Беткәнмени җир йөзендә башка кавемнәр?! «Әйдә, яши бирсеннәр!» — дияр иде.

Хәлбуки, бу фикере үзенә табигый тоелса да, атасының урыс кына түгел, дистәләрчә башка кавемнәр белән сәүдә итүен, мал алышуын белгән егет дөньяда бар нәрсәнең дә үзе уйлаганча гади түгеллеген дә яхшы аңлый иде, әлбәттә. Кешелек тарихының даими сугышлардан, кан коешлардан

[1]Ләшкәр — гаскәр.

торганлыгыннан да мәгълүматы бар, яшенә күрә шактый ук тәрбия алган, белем җыйган углан ич ул!

Уйларына йотылган Җәгъфәр койма өстендәге укчыларның тавыш-тынсыз гына имән бүрәнәләр ышыгына сыенып посуын да, тупчыларның тызбыз йөренә башлавын да сизми калган иде. Сәер тынлыктан айнып, Болак аръягына күз ташлауга, моның сәбәбен дә аңлап алды.

Әле күптән түгел генә ялга туктаган җыенчылар шикелле төркем-төркем утырган дошман гаскәре хәрәкәткә килгән, казанлылар күз алдында сафларга тезелеп, нәрсәдер эшләргә җыенып яталар иде. Менә каяндыр җигүле атлар килеп чыкты, арбалардан бүрәнәләрне араталап беркеткән кечкенә салларга охшаш җайланмалар төшерделәр. Бил тиңентен чишенгән әзмәвердәй ирләр аларны ярдан Болакка шудыртырга кереште. Урысларның көпә-көндез елга аша күпер салып маташуын күсәк углы күсәк булмаган теләсә-кем аңларга тиеш иде бит инде.

— Нишләп туплардан берне тондырмыйлар, нәрсә көтәләр,— дип үрсәләнде Җәгъфәр.— Нигә һич югы мылтыклардан күмәк атышка боерык бирмиләр? Кемне көтәләр?!

Ул гасабиланып, үртәлеп йодрыкларын кысты, ярсып-ярсып имән бүрәнәгә суккаларга тотынды:

— Нигә атмыйлар соң инде?!

Кызыксынып, бу сәер тынлыкның сәбәбен аңларга, имән диварлар артына посып һәрберсе сәгатькә тиң авыр мизгелләрне санаучы тупчыларның битараф тынычлыгын төшенергә тырышып карады. Әммә берни дә аңлый алмады. Тупчылар, әйтерсең, кунакка килгән таныш түгел мөсафирларны кабул итәргә әзерләнә, йөзләрендә салкынлык, ичмасам ник бер төкләре селкенсен!

Акрынлап алардагы салкын канлылык Җәгъфәргә дә күчте. Ныгытмадан ерак түгел калдырган Алмачуары белән дус егетен барлап күз салды да, тагын дошманның ни кыланачагын күзәтергә, өлкән укчылар, сабыр тупчылар шикелле түземлелек белән вакыйганың ни юнәлеш алачагын көтәргә булды. Тәҗрибәле гаскәриләр белми эшләмидер!

Болакта салчылар чупырдашты. Каланы саклаучыларның бер аваз белән, мылтыктан яисә туптан атып бу эшкә мөнәсәбәтләрен белдермәве аларның әрсезлеген тагын да арттырды. Казан ныгытмаларыннан ярты чакрымлап кына ераклыкта кычкырыша-кычкырыша, бер-берсен дәртләндереп, кайнашулары белделәр. Койма өстеннән аларның текә яр астында ни майтарулары күренми, әмма киң бүрәнә күпернең су уртасына ук узганын абайларга була иде инде.

Әйтерсең лә Җәгъфәр өчен вакыт акмый, үтми, бетми торган нидидер сәер халәткә әверелде. Аның мизгелләре минутка, минутлары сәгатькә әйләнде. Дошманның мәкерен, ут белән, кылыч белән өстеңә сикерергә әзерләнүен күреп, белеп, көтеп ятудан да газаплырак нәрсә юктыр җир йөзендә. Ни эшләргә, мөртәт дошманның юлына ничек киртә куярга белмәгән егет, үртәлеп, үрсәләнеп: «Ичмасам, тизрәк бу ярга чыксыннар иде инде», дип уйлап куярга да өлгерде.

Озак көтәргә туры килмәде. Күпернең әзер кисәкләрен, күрәсең, алдан ук бер-берсенә яраштырып, җайлаштырып килгәннәр. Җәгъфәргә кимендә алты-җиде сәгатьтәй тоелган ярты сәгать эчендә Болак суы ярларын шактый ук тотрыклы кичү тоташтырды.

Күпер коручы салчылар судан чыгып та өлгермәде, җәяүле урыс гаскәре кичүгә ургылды. Сөңге, гөрзи, озын туры кылыч, айбалта һәм укҗәя, мылтык белән коралланган сугышчылар бер-берсен дәртләндереп кычкыра-кычкыра текә ярдан үрмәләделәр, чыгып җиткәннәре исә, алдаучы хәрәкәт ясаулары идеме, каланы саклаучылар көткәнчә ныгытмаларга түгел, Арча кыры ягына агыла башлады.

Җәгъфәрнең артык карап торырга түземе җитмәде, теләләрен кысып, йөрәкләнеп, баскычтан иптәшләре — нөгәрләр янына йөгерде. Өч-дүрт басманы бер итеп төшеп җиткәндә, угланнар инде атларына менгән, кылычларын айкап, һай-һулап һөҗүмгә әзерләнәләр иде. Түземсезләнеп, ал аяклары

белән җирне казып бетергән Алмачуарның иярenә сикереп. Җәгъфәр дә аларга кушылды.

Менә-менә... хәзер... Капкалар ачылыр да атлылар ташкыны мәкерле дошман чирүен Болак суында тончыктырыр!..

Әмма угланнарны яуга чакыручы юк иде әле. Капка төбендә үзләре генә түгел, атларын да тимердән киендергән Шәһит морза алае. Сугышчыларның һәр хәрәкәте саен тимер чыңы яңгырый, йөзләрендә кырыслык, күзләрендә нәфрәт уты, хәрәкәтләрендә сабырлык. Алайның алдына баскан Шәһит морза кинәт шам кылычын кынысыннан тартып чыгарды һәм калын күкрәк тавышы белән кискен итеп кемгәдер әмер сүзләрен кычкырды:

— Беренче булып минем алай чыга! Ег-гет-ләр! Әз-зер-лән! Капка ачылуга — алга! Дошман өстенә!

Атлы гаскәр шым булды. Янәшәсендәге икенче бер төмәнбашка[1] иелә төшеп, Шәһит морза киңәш иткәндәй акрын гына әйтеп куйды. Алардан ерак түгел атын тыеп тезгенне күкрәгенә тарткан Җәгъфәр барысын да ишетте, шан-шәүкәтле саргаскәрнең сүзләре аңа да килеп ирешә.

— Угланнарны саклагыз! Бу бәрелештә карап торсалар да ярар.

— Шәһит морза! Баланы суга салмыйча йөзәргә өйрәтеп булмый. Җиңелчәрәк бәрелештә чирканчык алсыннармы соң әллә?! Һәрхәлдә зыяны булмас!..

Баштагы сүзләрдән әчендә кайный башлаган үпкәне, гарьлекне сүндерергә тырышып, Җәгъфәр саргаскәрнең ни җавап бирәчәген ут йоткандай түземсезләнеп көтәргә кереште. Анысы ашыкмады. Камчы сабы белән итек кунычына беркетелгән тимер тасмага суккалап торды да бер сулыштан хәл итте:

— Ышандырдың!.. Ләкин бездән соң... Урысны какшаткач, таркаткач... Иравыллардан соң[2].

— Хуп! Тыңлыйм, буйсынам.

Җәгъфәрнең эченә җылы йөгерде. Үзе дә аңламыйча, ни өчендер ул нәкъ менә шушы сугышта, бәрелештә катнашырга тели иде. Күз алдына Алмачуары белән дошман сафын ерып алга омтылуы килде, кылычы белән әле уңга, әле сулга селтәнде. Селтәнгән саен очлы бүрекле башлар аска тәгәрәде, аның янындагы дошман калтырап, артына да карамый Болак ярыннан ташланды. Ә Җәгъфәр: «Менә сезгә, менә сезгә Казан, менә сезгә Кабан, менә сезгә безнең хан»,— дип кабатлый-кабатлый алга омтылды.

Күрәсең, сугыш хәрәкәтләренә тагын да дәрәҗәлерәк, олырак саргаскәр җитәкчелек итә иде. Бәлки әле яшь хан — галиҗәнаб Ядегәр үзедер. Манара очында тимер тун өстеннән яшел хөббә кигән, тимер башлыклы мәһабәт сын күренде, кулы белән чагдавылларга ниндидер ишарә ясады. Шуны гына көтеп торгандай, калын тимер капкалар шыгырдап ачылды. Болак белән кальга арасындагы ачыклыкка казанлыларның тыелгысыз атлы гаскәре ябырылды, ул юлындагы бар нәрсәне изеп-сытып үтәр ташкындай алга ыргылды.

Урыслар Казанда бу кадәр көч барын көтмәгәннәр идеме, әллә көтеп тә күпердән чыгып өлгермәгәннәр идеме — кояш нурында ялык-йолык килүче тимергә чорналган дулкын алдында бер мәлгә каушап калдылар. Хәер, үзләрен бик тиз кулга алдылар. Дошман күпердән дә, йөзеп тә Болак аша сугыш кырына агылуын дәвам итте. Аларның иге-чиге юк сыман, кара болыт булып бөтен мәйданны тутырдылар. Кайсы мылтыктан, кайсы җәядән атарга кереште. Ике арада канлы бәрелеш башланды, атлар кешнәве, кешеләрнең ярсып кычкыруы, тәненә сөңге кадалган яугирнең үлем ачысы белән илереп үкерүе, корычның корычка бәрелеп чыңлавы... барысы да буталды, аралашып һич аңламаслык, кабатлап булмаслык дәһшәтле күренеш тудырды.

Әле бер як, әле икенче як өстенлек алгандай тоелды. Менә-менә инде урыс сафлары артка тәгәри башлады дисәң, алар тын Идел өстеннән

---

[1] Төмәнбаш — гаскәр башлыгы.

[2] Иравыл — алдагы отряд артыннан баручылар.

күтәрелгән калын дулкын шикелле тагын алга ташланалар, казанлыларны кысрыклыйлар. Тимер киемле атлылар Шәһит морзаның һәр әмереннән корыч йодрык булып тупланалар да, дошманның иң куе җиренә ярып керәләр. Аларны камарга теләгән дошман зәһәрләнеп чиный-чиный сафларын тыгызлый. Казанлыларга исә шул гына кирәк тә, иравыллар яңа көч белән алар өстенә ыргыла. Башлар җиргә оча, канлы гәүдәләр лапылдап җиргә барып төшә.

Озакламый өстенлек тулысынча казанлылар ягына күчте. Соң чигенә тарттырылган җәя бавыдай киеренкелек белән әмер көткән Җәгъфәрнең кылыч тоткан кулы, бармаклары тирләп чыкты, йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгар дәрәҗәгә җитте. Шушы мәлдә чакырмасалар, ялгызым утка ташланам дип торганда гына нөгәрләр сафы өстендә сугышчан оран яңгырады:

— Угланнар! Алга!!!

Түземсезләнеп авызлык чәйнәп ярсыган яшь чапкырлар, тезгеннәре бушаугa, үзләре кебек үк яшь җайдакларны бер ыргымда дошман сафлары арасына алып кереп тә киттеләр.

Җәгъфәр Алмачуарның муенына сыенды да атны ерактан ук шәйләп өлгергән дошман өеренә юнәлтте. Кызыл киемле бер төркем өч-дүрт атлыны чолгап алган, һәр егылган урынына дулкын булып тагын яңа сугышчылар калка иде. Уртада калган казанлылар арган, әмма бирешмичә, уңга-сулга кылычларын уйнатып, дошманны турыйлар. Тагын аз гына шулай дәвам итсә дә, урыс өеренең аларны изеп узачагы көн кебек ачык иде.

Чаптырып барган уңайга аның кылычы ялтырап очлы бүрекләр өстеннән узды, башы өзелгән муеннан ургылып кан чыкты. Җәгъфәрнең бер мәлгә бөтен буыннары көзән җыергандай тартышып килде, күзен кан басты, үзен-үзе белештермәс хәлдә селтәнде дә селтәнде. Кылыч тимере ниндидер йомшак нәрсәләрне кисеп, тишеп, кыеп узды, тимергә бәрелеп чыңлады... Ул инде бернәрсәне аермый, күз алдында тоташ бер кызыллык — кан, кан, кан, кызыл киемле дошман! Әгәр ул бер генә мизгелгә туктalса да, үзен шулай ук чоеп атачаклар, йөрәген очлы сөңге белән тишеп чыгарачаклар, ак, чиста гәүдәсен чаба-чаба тураклаячаклар, пычрак аяклары белән ул кисәкләрне таптап узачаклар иде.

Маңгаеннан туктаусыз тир ага, аны сөртеп алыр чама юк. Күзләре ачыта башлады. Селтәнгән җиреннән җиңе белән маңгаен сыйпап алганчы узган арада, аз гына, әһ дигәнче генә берни дә күрми торды. Күзләрен ачса — каршында үзеннән өч-дүрт яшькә генә өлкәнрәк урыс егете. Аның тиргә манчылган җитендәй озын чәчләре маңгаена сыланган, бүрегe бер якка кыйшаеп төшкән, зур, куе зәңгәр күзләрендә әҗәлен тойган болан баласыныкыдай томанлы элпә иде. Җәгъфәр шуларны абайлап өлгерде. Карашлары очраштьı. Шул ук мизгелдә урыс егетенең авызы ачулы кыйшайды, бугазыннан илереп зәһәр тавыш чыкты. Җәядән ычкындырылган уктай алар бер-берсенә ташландылар. Алмачуар өстендәге җайдагын күкрәге белән сакларга теләгәндәй алга сикерде, урыс егетенең җирән айгыры арт аякларына басты. Озак та үтми алар тирә-якта ни-нәрсә барлыгын белештермичә кылыч уйнаталар иде инде.

Җан көченә кизәнеп сугудан калканнары яньчелде, ямьшәйде, атлары ак күбеккә батты, әмма берсенең дә өстен чыгарлыгы сизелми иде әле. Шулчак Җәгъфәр күз ачып йомганчы хәйләкәр адым ясады: атын тезгенләп артка чүктерде дә, уң як үкчәсендәге типкене Алмачуарның кабыргасына батырды. Хуҗасыннан мондый усаллык көтмәгән айгыр соң көченә киерелеп, сул якка ыргылды, чүккән җайдакка ташланам дип ыргылган дошман сугышчысы исә кылычы белән бушлыкны айкап үтте дә тыела алмыйча алга томырылды.

Җәгъфәргә шул гына кирәк тә иде инде. Хуҗасының ни теләгәнен бер хәрәкәтеннән аңлый торган тыңлаучан Алмачуар яшен тизлегендә җирән айгыр артыннан сикерде. Урыс, атын борып турылаганчы, Җәгъфәр аны куып та җитте, сул ягына төшеп кысрыклап, кылычын селтәде.

Үзе өчен иң уңайсыз хәлдә калган мизгелдә дошман кинәт мәкерле итеп көлеп җибәрде, тешләре ыржайды, ул ярсыган атын борырга азапланган ара-

да шам кылычның үткен очы аның күкрәген кыеп узды. Җәгъфәр бер чапты, кизәнеп торып тагын чапты, көлүне күтәрә алмаган җаны тыела алмый, ул һаман кизәнә иде әле. Шулчак якында гына нәрсәдер лапылдап җиргә барып төште, тимер чыңлады.

— Айа, углан, булдырдың! Инде суына төш!

Таныш тавыш, калын күкрәк тавышы ишетелмәсә, Җәгъфәр инде ияреннән сыгылып төшкән гәүдә өстендә тагын күпме кизәнгән булыр иде. Шунда гына айнып китте, борылып карады. Шәһит морза җәпләренә кадәр батып кергән соңге очын яшел чирәм өстенә җәйрап төшкән корбаны гәүдәсеннән суырып алды да Җәгъфәргә елмайды, үз итеп дәште:

— Сугышта онытылма! Дошман бераү генә түгел! Юкса әнә кара!..

Үзенә нинди куркыныч янаган булганлыгын егет шунда гына аңлап алды. Урыс егете юкка елмаймаган икән.

— Рәхмәт... асылзадә!..

Тезгенен бушатып китәргә укталуга, аны Шәһит морзаның салмак, сугыш барышында кирәгеннән артык тоелган сабыр кул ишарәсе туктатты.

— Ашыкмасаң да буладыр... Әнә, качалар...

Җәгъфәр сугыш яланының бушап калуын шунда гына күрде. Казан гаскәре дошманны бөтен кыр буена кысрыклап, Болакның текә ярларына китереп кыскан, кызыл киемле яугирләр бер-бер артлы гаип булалар иде.

Нәкъ менә шул мизгелдә кала манараларыннан бер-бер артлы авыр гөрселдәү авазлары ишелеп төште. Болак өстендә болганчык су баганалары күтәрелде, инде тына төшкән иңрәү, үкерү, ат кешнәү авазлары яңгырады. Бераздан ядрәләр алга күчеп, инде елга аръягында, бер-берсен изеп-сытып качып баручы дошман өере өстендә шартлый башлады.

Аларга урыс туплары җавап бирде. Әмма алар казанлыларны зарарламый, ядрәләр калага җитә алмыйча ике арадагы бушлыкка төшә, зыян-зәүрат салмыйча куе чирәмлектә йотыла иде.

Җиңүчеләр яралыларны һәм кяфер кулыннан шәһит киткән изге батырларның гәүдәләрен җыеп, кире кальгага әйләнеп кайттылар.

Олуг мәмләкәт — дөнья сәүдәсенең үзәге, хөр Казан патшалыгыннан кан даулап, җир, мал, нан яуларга килгән урыс гаскәре, аларга сатылган хыянәтчел Шаһгали хан кавеменеһ беренче һөҗүме әнә шулай тәмамланды.

Казан халкы батырларны чәчәк, сусыннарын басарга ширбәт, тамакларын туйдырырга тәгам белән каршы алды. Уен-көлке, җыр-көй башланды. Җиңү исерткеч дәрәҗәдә саллы тоела, куанып җырларлык дәрәҗәдә татлы иде. Йөз илле меңлек чиру белән килдем дип мактанган явыз Иванның сүзе аяк астына салып тапталды, хакы булмаган килеш чар[1] дигән олуг исемне дәгъвалаган, тәмгысы, нәфесе чиксез яшь кенәзнең горурлыгы сындырылды.

Нечкә күңелле бүз углан Җәгъфәр генә бәйрәм сыенда катнаша алмады. Укшыды, күңеле болганды. Ризык күргә, күз алдына җитен чәчле урыс килде, яраларыннан ургылган канның укшыткыч исен тойган кебек булды.

## Урыс станында

Сөт урынына кан койдың,
Каныңны түгеп ни кылдың?
Казан, Кырым, Аждаркан,
Куныңны сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең!

«ИДЕГӘЙ».
Борынгы татар дастаны.

Кальгадагы туплар тынып калды. Хан гаскәренең соңгы атлылары капкадан кереп югалды.

Болакның текә ярыннан кысрыклап, төбе лайлы салкын суга чумдырылган сугышчылар дөньяда булган, үзләре белгән иң ачы каһәрләү, сүгенү,

[1] Чар — патша.

ләгънәтләү сүзләреннән буылып бер-берсен эзләргә, дусларын, белешләрен, якыннарын барларга керештеләр.

Бөек кенәз галиҗәнаблары карамагындагы сайланма полк бу бәрелештә катнашмады. Иван сәүдәгәр тәкъдиме, аның кодалавы белән шушы полкка азык-төлек, атларга солыдыр, печәндер юнәтүче итеп тәгаенләнгән Василий боларны читтән, Болакның сул ярындагы ачыклыктан — арбалар өстенә өелгән печәнлектән күзәтеп торды. Беренче тапкыр сугыш дәһшәтен үз күзләре белән күрде, казанлыларның ярсу гайрәтен, атлыларның уктай атылып гаскәр эченә керүен, аны урталай ярып тураклый, тарката белү сәләтен күрде. «Дөрес сөйлиләр, казанлылар кыю, батыр, сугышка маһир халык икән», — дип уйлап куярга өлгерде ул.

Шул мизгелдә Санька исенә төште, сафлар арасына текәлеп, күзе авыртканчы энесен эзләде. Сөлектәй чаптар өстендәге һәр пәһлеван аңа Санька булып тоела, анын һәр селтәнүеннән йөрәге кысыла, ачуы, нәфрәте күкрәгенә генә сыешмыйча, авызын ачса, күкләргә ургылыр сыман иде. Ләкин текәлебрәк караган саен күрде: боларның берсе дә Санька түгел! Болар — чын гаскәриләр, ат өстендә коеп куйгандай утыручы оста, маһир сугышчылар! Ул аларның кара мыеклары астында ялтыраган ак тешләрен дә, ачудан зур булып ачылган күзләрен дә абайларга өлгерде кебек.

Шунда тагын әллә нәрсә булды, аксыл чәчле татар сугышчысын күргә, чак кына «Санька!» дип кычкырып җибәрмәде, кан чыкканчы авырттырып иреннәрен тешләде. Кырыйдан якынлашып килүче сөңгеле урыс атлысын күрмичә, ул каршындагы пәһлеван белән алыша, кылычларыннан очкыннар чәчри, калканнарының бәрелүеннән күкләр дөберди кебек иде.

Үзенең гаскәри түгеллеген, монда бөтенләй башка максат белән килүен онытып, Василий исерткеч ярсуга, сугыш-һәлакәт шаукымына бирелүен сизми дә калды. Аксыл сары чәчле татар аста кала башлаcard, йөрәге кысылды, бөтен буыннарын яндыргыч курку өттереп алды. Аны Саньканың урыс кулыннан үтәчәге рәнҗетә, туганының казанлылар сафында булуы үрти, моны булырга тиеш түгел, гайре табигый эш саный иде. Ул Саньканы җәлли, үлемен дә теләми иде. Урысның кылычы күтәрелгән саен ул тешләрен шыкырдатты, үз ирегеннән башка бугазыннан кыргый авазлар чыкты:

— А-а-а-а!

Менә атлы урыс килгән шәпкә сөңгесен сары чәчленең күкрәгенә батырды, киерелгән гәүдә бер генә мизгелгә өскә омтылгандай тартышып куйды да башы каерылып аска салынып төште. Йөрәге бер учка сыярлык булып кысылган Василий Казан кешесенең кәгазьдәй ак йөзендә сызылган кара мыекны, куе кара кашларны күреп алды.

— Ю-у-ук! Бу Санька түгел, Александр түгел! Тү-ү-гел! — дип илереп кычкыруын сизми дә калды, тиле кешедәй чүмәлә өстендә сикергәләргә, үзен-үзе йодрыклары белән тукмакларга кереште.

— Ю-у-ук! Санька түгел! Буйга да кечерәк, җилкәләре дә ул кадәр киң түгел. Санька түгел бит!.. Минем җан кисәгем нигә үләргә тиеш ди әле?!

Кинәт ул тилереп сикергәләгән җиреннән таш кебек катты да калды. Әле күптәнме генә үзе өчен дошман санаган, улына үлем белән янаган, әлек газиз туганы булган, хәзер исә татарларга сатылган хыянәтче бер җан өчен иңәлүен, йөрәге шуңа бәргәләнүен аңлап-абайлап, куырылып килде, авыртканчы киерелеп ачылган авызындагы шатлыклы авазлар ыңгырашуга охшаш өн белән алышынды.

— Мин ниш-ли-им! Дошман өчен иңәләмме соң әллә?! Аһ, нинди хурлык — икебез ике якта!..

Башыннан ургылып, котырынып уйлар ташкыны узды.

Энесенә ачуыннан чак кына буылмады Василий. Бер карында яралган, тамырларында бер үк кан агучы туганының казанлыларга тугрылыгын, чыгырыннан чыгып пычакка-пычак килгәндә дә сүзен бирмәвен, салкын канлылык саклап, үз фәлсәфәсен Василийга, аңа үткәрергә тырышуын күтәрә алмады.

Ул аны аңларга тырышып карамады түгел, уйланды, бихисап йокысыз төннәр үткәрде, ләкин барыбер энесен аклар сәбәпләр тапмады. Тапкан хәтлесе исә ышандырырлык, туганыңнан баш тартырга мәҗбүр итәрлек дәрәҗәдә саллы түгел иде.

Бер ятакта тәгәрәп үскән, ерак илләр гизәргә, мал төяп күз күрмәгән, колак ишетмәгән мәмләкәтләргә сәяхәт кылырга хыялланган яшьлек дусты, туганы башка, бөтенләй башка кеше иде инде. Хикмәт аның сакал-мыегын татарча китәреп, Казанча киенүендә генә дә түгел. Кыяфәтендәге үзгәрештән бигрәк, Санькаңын үзен тотышындагы сәер басынкылык, Василий инанган, табынган нәрсәләрнең аңа чит-ят булуында, иң сәере — аңларга теләмәвендә иде.

Идел буендагы текә ярда тәгәри-тәгәри елап, үксүен чыгармас өчен иреннәрен тешли-тешли үч алырга, энесенең һәлакәте өчен казанлылардан канлы үч кайтарырга ант эчкән тугры җанлы Василий унҗиде ел аймыл булып яшәү дәверендә мондый очрашу булыр, булса-калса мондый да дәрәҗәдә салкын булыр дип күз алдына да китермәгән иде.

Инде менә... Күр, сөен, шатлан йә булмаса ачуыңа буыл, үзеңне кыйна!.. Санька бар да кебек, әмма шул ук вакытта инде ул юк та. Әллә булганыңнан булмаганы яхшырак идеме соң? Якты, кадерле истәлекләр белән яшәвең мең тапкыр артыграк түгел идеме? Һай, Идел чоңгылларында тончыккан булса, бу кадәр интегелмәс тә иде.

Болакны кичеп Арча кырына таба үтәсе полкларның хурлыклы чигенүе кызу канлы, сүзе аста калганны бер дә күтәрә алмаган Иоанн Васильевичны ярсытыр, күзенә ак-кара күренмәс хәлдә тагын-тагын яңа гаскәрләрне яуга ташлар дип көткәннәр иде. Әмма яшь кенәз бу юлы үзенә хас булмаганча салкын канлылык күрсәтте. Каладан ук һәм ядрә җитмәс ераклыкны чамалап, полклар кирәк-яракларын, җиһазларын урнаштырырга кереште, гаскәрнең бер өлеше атларга төялеп башка яклардан урау юллар эзләргә чыгып китте. Җиңелү ничек кенә ачы булмасын, Казанга килү һәм чыгу юлларының күпчелеге инде урыслар кулына төште. Һәр тарафтан камалышта калган казанлылар хәзер тышкы дөнья белән аралаша алмый, алар бары тик җыйган маялары, туплаган азык-төлекләре һәм кирәк-яраклары белән генә канәгатьләнергә мәҗбүр булачак. Камауның озакка сузыласы, яшь кенәзнең барысын да алдан уйлап, ныклы әзерлек белән килгәнлеге сугыш һөнәреннән хәбәре-мәгълүматы булмаганнарга да ачык аңлашылырлык иде инде.

Сугышчылар киндер чатырлар корырга кереште. Мәскәү хөкемдарының үз чатыры исә гаскәрнекеннән бер ук очышы ераклыкта, кечкенә генә калкулыкта урнаштырылды. Аның тирәсенә сайланма полктан — кенәз, воевода балаларыннан оешкан төркемнән сак куелды. Алар үзләре танымаган беркемне дә чатыр янына якын җибәрергә тиеш түгел иде.

Казанга каршы олы яу белән кузгалыр алдыннан митрополит Макарийның изге фатихасын алган һәм Мәскәү чиркәүләренда ике көн, ике төн дога кылудан башлаган яшь кенәз монда да алла сүзен алга куйды, гаскәр урнашкан болыннарда киндердән чиркәү чатырлары корылды, түбәләренә изге сулар сибеп, тәреләр беркетелде.

Арыган гаскәр, ашчылар, олаучылар, гаскәрне азык-төлек белән тәэмин итәргә ялланган сәүдәгәрләр арып-талып, соң гына йокыга талдылар. Аларны иң сөендергәне шул булды: күз алдында иге-чиге күренмәгән чирүнең тыныч кына чатыр корып ятуына казанлыларның әллә ни исе китмәде кебек. Алар үз көчләренә, кальганың алып булмаслыгына артык нык ышаналар идеме, әллә бер-бер яктан ярдәм, өстәмә көчләр килүен көтәләр идеме — моны беркем дә фараз итеп тормады. Арулары чиктән ашкан, иң беренче теләк — тизрәк башны ятакка терәү иде.

Җеп өзәрлек тә хәле калмаган Василий бик озак йокыга китә алмады. Гаскәриләр корган чатырда урын табылса да, ул Казан суы өстен Идел тамагынача тутырган көймәләрдә урнашуны артыграк күрде. Аның, бердән, сугышчылар белән бергә ятып, төнен казанлылар яу чапса, тормышын куркы-

ныч астына куясы килми, икенчедән, тәэтеп кылгән малга да күз-колак булырга кирәк. Сакка куелган гаскәргә ул тамчы да ышанмый, әгәр җае килсә, аларның бер төн эчендә ярты көймәне беренче очраган нәфесле шайтанга аткарачакларына иманы камил иде. Шуның өстенә, көймә төбендәге имән мичкәләрдә чымырдаган ачы бал, күз яшедәй саф аракы бик күпләрнең күңелен инде күптән кытыклый, ымсындыра. Монысын да истән чыгарырга ярамый. Дөрес, исерткечне гаскәр башлыгы рөхсәте белән генә саттыралар, әмма елгыр, үткенрәк саргаскәрләр үзләре дә, гади сугышчылар да мичкә тирәсенә сугылып узуны гаепкә санамый. Бер чәркә кемгә зыян китергән. Эченне тишмәс әле. Авызыннан аракы исе бөркелгән ул адәмнәргә башлыклар күз йома. Мөселманнардан яулап алыначак кала, андагы иксез-чиксез байлыкның озакламый кулга төшәчәгенә өметләнү — барысына да берникадәр дәрәҗәдә масаю, кәләйлек өстәгән, күбесе ни кыланганын белми иде. Чиркәү чатырларында урысларның өстенлеге, татарның басурманлыгы, түбәнлеге хакында поплар, руханилар җибәргән агулы сөрем һәммәсенең акылын томалаган, барысы да Казанның ансат кына җиңелүен, камалышка түзә алмыйча тезләнүен, ефәк мендәргә салып шәһәр капкасы ачкычын чыгарып бирерләр дип көтә иде.

«Татарлар аракы эчми. Диннәре кушмый,— дип уйлап алды Василий һәм көлемсерәп куйды.— Казанны алгач, бу мичкәләрнең һәрберсе алтын бәрабәренә китәчәк әле. Иван белеп әйтә. Шанлы урыс гаскәре шатлыгын аракыга батырып юачак»...

Никадәр генә уңайлырак урын сайламасын, ятагының җаен таба алмады. Йә аркасын нидер кырды, йә аягы ниндидер очлы әйбергә барып бәрелде... Чикмәнен башыннан ук бөркәнсә, тынына буылды, ачса колак төбендә безләгән, канга сусаган черки өере битенә, тәненең ачык өлешләренә ябырылды.

Урыс гаскәренең казанлыларга шул черки өере шикеллерәк котылгысыз җәфа икәнен күзалдына китереп янә елмайды һәм теш арасыннан сүгенеп, бөгәрләнеп ятагына сеңде. Саташулы, бимазалы төн йокысы барыбер үзенекен итте: бераздан күзләре йомылды. Идел ягыннан искән салкынча җилдән бөрешеп көймә төбенә сеңгән гәүдә өстендә черки болыты котырды. Очлы безләрен корбанның итләч муенына батырып, алар туй итәргә кереште. Әмма ике-өч көн рәттән юньләп йокы күрмәгән Василий инде моны сизми, ул, әйтерсең лә караңгы, төпсез упкынга чумды, якты дөнья белән бәйләп торучы бөтен нәрсә шартлап өзелдемени, гырлап йоклап та китте.

Менә Казанны алганнар, имеш... Биек таш манараларындагы туплар гөрселдәп бәйрәм уты ата, урамнар урыс гаскәре белән тулы. Шәһәрдә бер генә татар заты калмаган — челтәр тәрәзәле, олы, якты ташпулатлар, бодай белән, арыш белән тулы амбарлар, мал тулы лапаслар, кызыл мал, асылташ, алтын-көмеш чыңлаган бай кибетләр — барысы да урыс кулында. Гаскәр бәйрәм итә. Көймәләргә бәйләп кол тутырганнар: кәнизәк кызлар, һөнәрчән куллы хатыннар, яшүсмерләр, балалар... алардан читтәрәк аяк-куллары богаулы осталар, һөнәрчеләр... Ah, ни шатлык! Дөнья базары шау итәчәк, Мәскәү сәүдәгәрләре кесәсенә, урыс кенәзлеге хәзинәсенә әле тагын күпме алтын агылачак!..

Василий да үзенекен ычкындырмаган, имеш. Менә ул кальганың дошманнан тазартылып бетүен вәкарь белән генә көтеп алды, басмалардан яр өстенә аракы мичкәләрен тәгәрәтергә боерды. Бер тустаган эчемлеккә сусаган сугышчылар, хезмәтчеләр аның авызына гына карап торалар, имеш. Алар бер-берсенә утызар чиләк сыешлы авыр мичкәләрне ыһ иткәнче чыгарып та куйдылар. Китте сәүдә, китте алыш, китте биреш, китте бәйрәм... Бер чәркәсе бер алтын! Казан малын имеп баеган, көчле дошман белән алышып арыган гаскәр акчасын җәлләми. Әйдә, эч, бәйрәм ит, бие, җырла, уйна! Мәскәүгә кояшны каплап торгандай көнчыгыштагы сәүдә юлларына хуҗа булган Казан — безнеке! Үзебезнеке! Урысныкы!..

Җиңү шаукымыннан исергән Василий үзе дә чүмечләп аракы чөмерә, әмма күпме эчмәсен, башына китми, имеш. Авызын киң ачып кычкыра: «Күтәр мичкәсе белән! Агыз чишмә иттереп! Йөзсен халык колач салып»...



ӘЛУС ЛАТЫЙФИ ХИЯНӘТ

Шул чакта әллә нәрсә булды. үзле балчыкка түгелгән аракыдан аягы таеп китте дә басма буйлап аска, көймә төбенә тәгәрәде. Басмага беркетелгән тупсалар кабыргасын санап чыкты, лып итеп такта идәнгә килеп төште, сыны катты. Аягына басарга өлгермәде, өстенә бөкесе дә ачылмаган юан мичкә тәгәрәде, аны тибеп җибәрсә, икенчесе төште. Әйтерсең лә җан ияләре, мичкәләр төрле яктан аны кысрыклый, һөҗүмгә кучкән татар атлы гаскәре җитезлеге белән әле бер, әле икенче ягына төшәләр, авырттырып бәрәләр иде.

Авыртуга, кысрыклауга чыдый алмый, Василий бар көченә кычкырып җибәрде, бугазыннан ургылган куркулы ачы авазларга мичкәләр дөбердәве кушылды. Мөмкин булса, ул ике колагын кысып теләсә кая — урманга, болынга, тау араларына качып китәргә әзер иде инде. Бары тик тавыш кына булмасын! Әмма кыймылдый алмас хәлгә җиткән, мичкәләр аны ике яктан кысып, менә-менә уклау астындагы камырга әйләндерәчәкләр иде.

— Бу ни бу? Нәрсә булды?!

Аның кешедән бигрәк үзенә атап әйтелгән соравына, җан ачысы белән бәргәләнеп кычкыруына җавап бирүче булмады. Көймәдә мәхшәр... Бәйләреннән ычкынган мичкәләр тәгәри, җилкән колгалары җилдә уйнаклаган камыш сыман бөгелеп сызгыра, әллә ничә йөз батман сыйдырышлы көймә үзе упкынга эләккән йомычкадай уйный, янтайган саен кырыеннан ургылып болганчык су ташкыны керә иде. Күрәсең, тимер чапага — ыргакка тарттырылган арканнар өзелгән, эреле-ваклы көймәләр бер-берсенә бәреләләр, корбанына ташланган бүредәй һич көтмәгән яктан өскә сикерәләр, юлда очраган бар нәрсәне җимереп, ватып, изеп, сытып баралар иде.

Казан ягыннан котырып җил исә, ул авыз ачарга да бирми, тынга капла-на. Күк йөзен кара тузан болыты каплаган. Иртәнге кояш аның аша тутыккан кызгылт бакыр таба шикелле таплы-таплы булып күренә, җир йөзе кичке эңгердәгедәй караңгылыкка чумган, офыктан-офыкка җен туе — канлы өермәләр йөгерә. Алар инде ярым баткан көймәләрне өерләп Иделгә, таутау актарылган дулкыннар кочагына куалар иде.

Василийның йокысын кул белән йолкып аттылармыни... Мие котырып эшли башлады: «Бу афәттән, гарасаттан, бу мәхшәрдән ничек котылырга!?» Ләкин өстенә ишелгән мичкәләрне аралый-аралый күпме баш ватмасын, котылыр чара юк иде. Алда да, артта да, уңда да, сулда да — мәкерле Казан суы, шашкын дулкыннар, болганчык чоңгыллар. Үзе шикелле бәргәләнүче көймәчеләр, сәүдәгәрләр ярдәмгә килә алмый — аларның кайберләре инде сытылып мичкә астында калган, кайберәүләр кычкырып болганчык суга ташлана, әмма чыкканнары күренми. Хәер, аларны карарга ара юк, чак кына авызыңны ачтыңмы, шашынып чайкалучы көймәдәге мичкәләрнең берсе өстенә төшәчәк, сытып ташлаячак.

Шулчак дулкыннар өстендә чайкалып, иелгән саен су чумырып баручы көймә туктап калды, бер якка янтаеп авышты, аның өстеннән калын су ташкыны шаулап узды. Аракы мичкәләре камыш бөкеләрдәй су өстенә күтәрелде, аларның берсен иярләп өлгергән Василий да дулкын иркенә буйсынып агып китте.

Җыясы ризыгы бетмәгән икән әле, кучкыл төскә кергән таудай дулкын аны иң өстенә күтәреп селтәде дә Казан-су тамагының комлы-ташлы ярына китереп бәрде. Аяк астында каты җир тойган сәүдәгәр авызына тулган ләмле балчыктан, судан тончыга-тончыга алга үрмәләде, тешләре, тырнаклары белән үлән тамырларына, талларга ябышты. Икенче, тагын да көчлерәк, тагын да дәһшәтлерәк дулкын куып җитте һәм аның акрын кыймылдавына үртәлгәндәй, җилкәсенә күтәреп яр кырыеңа ук чыгарып ташлады. Артык хәле калмаган Василий берничә адым шуышты да ниндидер калкулыкка менүен абайлап, җиргә сузылды. Күз алдында утлы бөҗралар биеште, тәне, аяк-куллары үтереп сызлый иде. Котырып аккан су буенда бер йотым су эчәргә тилмереп, кипшергән телен авыз куышлыгында йөрткәләде. Әмма кушучлап шул суны эчәргә, тагын яр буена үрмәләргә аның көче дә, теләге дә калмаган иде инде. Башында бер уй бәргәләнде:

«Су куркыныч, судан читкәрәк!» Берничә мизгелдән ул үлектәй сузылып ятты, онытылды.

Һушын җуеп саташулы халәттә күпме яткандыр, белми, колак төбендә яңгыраган ачулы тавыштан айнып, уянып китте.

— Артына тибеп кара, бәлки исәндер...

Күзен ачса, янында Иван сәүдәгәр белән бер төркем коралллы укчылар тора.

— Аллага шөкер! Исән икәнсең әле,— диде Иван.— тора аласыңмы?..

Аңа җавап бирмичә генә Василий уфтанып ыңгыраша-ыңгыраша аягына басты, җанын, миен бораулап торган сорауны бирде:

— Ни булды? Көймәләр... ничек?

— Бат-ты-лар,— теш арасыннан бүлеп-бүлеп чыгарды Иван.

— Татарның сихерчеләре явыз, кабахәт җаннар... Сихерләп җил-давыл чакырдылар. Күрдеңме, өермәләр алар ягыннан килде...

— Барысы да баттымы?— дип илереп җибәрде Василий.— Минекеләр дәме?..

— Улама!— Иванның тавышына ачу, кыяфәтенә усаллык чыкты.— Бер син генә зыян күрмәгән. Җитәр! Тор да әнә ярдәм ит! Калган, таралган малны җыярга кирәк...

Василий шунда гына атлы олауларны, ярны буеннан-буена иңләп килүче коралллы кешеләрне абайлап алды. Алар дулкын чыгарып ташлаган мичкәләрне, капчыкларны, көймә калдыкларын, мәетләрне җыеп, арбаларга төйиләр иде. Әле кичә генә шау яфракта утырган урманлы-куаклы җир ачык яланлыкка әйләнгән, төбе-тамыры белән кубарылган агачлар, шәрәләнгән куаклар — барысы да коточкыч зилзилә үтүе турында сөйли иде. Бөтен кыр капланып ташланган йөкләр белән тулган. Арбаларда тау-тау өелеп торган печән кибәннәренең эзе дә калмаган, бөртегенә хәтле өермәгә уралып Идел аръягына очкан иде.

«Күрәсең, камау барып чыкмас! Иписез, печәнсез, ач-ялангач калган гаскәр белән әллә ни кыра алмассың,— дип уйлап куйды Василий. Йөрәген үкенеч, бар малыннан колак кагу ачысы кисеп утте.— Аһ, ни аяныч! Казан патшалыгының әкияти хәзинәләре кул сузымында гына юкса! Бер йодрык белән бәрергә иде дә, диварларын изеп, манараларын аударып, төнге ташкындай ыргылып керергә иде. Югалту ачысы да бу кадәр газаплы булмас иде!..»

Аның уйларын сизгәндәй, Иван сәүдәгәр тавыш бирде:

— Йә, таш сындай катып торма! Хәзер икенең бере — йә Казанны тончыктырып малны кайтарабыз, йә булганын җыеп эшкә җигәбез. Кыймылда!

Тәнендәге авырту, сызлануны җиңеп, Василий аларга иярде. Укчылар акрын гына үзара сүз алыштылар:

— Казанны алла кодрәте яклый инде әллә?

— Яклый пычагым, ишеттең бит инде, сихерчеләре кабих җаннар, җил-давыл чакыра беләләр...

— Ни булса да, ризыксыз монда озак тора алмабыз. Суган суы суырып кына сугыша алмассың...

— Анысы шулай, күрәсең, иртәгәдән дә калмый киредән өйгә — Мәскәү якларына кыяклarбыз. Хурлыгы ни тора!..

— Җитте сезгә, юкка лыгырдамагыз! Әмер бирсәләр, ач көе дә сугышырсыз,— дип кемдер ачулы кычкырып куйды.— Иң яхшысы, таралган-чәчелгән малны күбрәк җыегыз. Һич югы, бүген тамагыгыз тук булыр. Барысы да бөек кенәз Иоанн Васильевич галиҗәнаблары иркендә...

Һәм, чыннан да, барысы да Иоанн кулында иде, күрәсең. Азмы-күпме әйбер-кара җыелып, югалтуларны барлауга, азык-төлек юнәтүчеләргә гаскәр башлыгының фәрманын җиткерделәр:

— Кичекмәстән иң чыдам, түзем, житез атлар белән Мәскәүгә, Зөягә чабарга, бөтен шәһәрләрдән икмәк, жылы кием-салым төяп, янадан Казан тарафына сәфәр чыгарга!

Фәрман нигезендә һәр бояр кимендә бер полклык мал бирергә мәҗбүр ителә, патша казнасыннан кирәгенчә алтын-көмеш алырга рөхсәт ителә иде.

Василий моңа бик сөенгән иде. Иртәнге гарасаттан ул, дөресен әйтергә кирәк, шактый шүрләде. Казанны, чыннан да, сихерчеләр яклый, аны гади корал белән генә алып булмыйдыр, дип уена беркетеп куйды. Әмма моны кемгә дә әйтергә базмады, эченә бикләнде. «Менә, ниһаять, котылу юлы күренде. Мәскәүдән урап килгәнче ни генә булмас та, тагын нинди генә җил-давыл чыкмас. Һәрхәлдә, сугыш кырыннан читтәрәк булуың хәерле. Шуның өстенә, дәүләт казнасыннан агыласы алтын-көмеш тә бармакка йокмый калмас. Иван белеп сөйли»...

Ләкин иртәрәк шатланган булып чыкты. Уйларының очына җиткәнче, Иван касыгына төртте, күз кысып, башкалардан читкәрәк, кырдан җыелган мал өемнәренә таба китәргә ымлады. Тирә-ягына каранып, ашыгып пышылдарга кереште:

— Мин Мәскәүгә китүчеләргә башлык итеп тәгаенләндым...

Василийның авызы колагына җитә язды. Хуплап баш селкеде. Әмма Иван аны күрмәгән дә сыман үзенекен дәвам итте:

— Син... монда каласың. Аң бул, йоклап йөрмә! Менә бу исәбе алынмаган туздырылган байлык хәзер синең кулда,— диде ул мичкәләр, капчыклар, чыпталар өеменә күрсәтеп.— Дөнья хәлен белеп булмый, алай-болай без килгәнче Казан кулга төшсә, форсатны ычкындырмассың... Ә Мәскәү малыннан тамганы — минем кулда. Борыныңа киртлә: бары — бергә, югы — уртак.

Василий кара коелды.

— Нишләп мин? Беткәнме берәр...

Иван аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде, йодрыгын ияк астына терәде.

— Шым бул! Оныттыңмы? Күпме бурычың бары исеңнән чыктымы? Энеңнең казанлыларга сатылган хәсис икәнен белсәләр, Иоанн Васильевич беренче очраган ботакка астыра бит сине. Әйдә, сайла! Кайсысы күңеләңә якынрак?..

Василий телен тешләде. Күпме генә бәргәләнмәсен, пәрәвезгә эләккән чебендәй чапаланмасын, ул үзенең Иван сәүдәгәр ихтыярыннан чыга алмаячагын тагын бер кат аңлады. Күрәсең, чабатага тагылган киндерә шикелле мәңге аның артыннан сөйрәлергә туры килердер, ахрысы. Санька гаепле... Аның качып китүе, юк, качу түгел, пычрак хыянәте этисен шушы адәмгә гомерлек бурычлы итте, ул гүргә кергәч, бурыч Васяга күчте. Ләкин иң гаҗәбе шунда, еллар үткән саен ул кимеми генә түгел, артканнан арта бара иде. Әҗәтле буласы килми. Ялыктыргыч, алҗыткыч бәйлелектән котылу, Казан малына кинәнеп Иванның бугазына тыгу теләге китерде дә бит Васяны Казан сугышына! Юкса, болай йөрер идеме?!.

Иван, кирәген аңлатып бетергәч, яңадан күз кысып елмайды:

— Борыныңны төшермә! Беләсең килсә, Казанда нибары утыз мең гаскәр бар, диләр. Безнең көчкә каршы торырлыкмы? Атна-ун көннән ялынып үзләре чыгачак... Төшендеңме?...

Сөйләшү шуның белән тәмамланды.

Атна үтте, ун көн дә узып китте. Ә казанлылар бирелергә уйламый да. Урыс явы һай-һулап, әләмнәрен болгап, туп атып һөҗүмгә чыгуга кальга капкалары ачыла, ярсу атлылар ташкыны юлында очраган бар нәрсәне изеп, сытып, турап уза да яңадан калага кереп бикләнә. Аларның җитезлеге, елгырлыгы шәһәрдә беркемнең дә ачка интекмәвен күрсәтеп тора. Шуның өстенә, туплары тынгы бирми, бер-бер полк якынлашса, ядрә яудырырга тотыналар, мылтык аталар, яңгыр булып уклар коела.

Урыс гаскәрендә һәр кисәк икмәк санаулы. Мәскәүдән көймәләр, олаулар килеп җиткәнче бар нәрсә үлчәүдә. Зөядәге икмәк ачка үтермәслек кенә. Якын-тирә татар авылларында ашлык юк. Аны йә күмгәннәр, йә яндырганнар, суга агызганнар, юк иткәннәр. Явыз дошман кулына эләкмәс өчен барысы да качып беткән. Авыллар буш, авыллар үле. Ирләре яуда, хатын-кыз, бала-чага йә урманда, йә тагын да ераграк якларга күчеп киткән.

Василийның Санькага ачуы кабарганнан кабара, кайчагында буылыр хәлгә җитеп аны сүгә башлый, каргый, ләгънәтли. Зиннәтле йортында балда-майда йөзеп яшәүче энесе, казанлыларның үҗәтлеге җенен котырта.

Мең чакрым юл үтеп кил дә ачка койрык чәнчеп ят менә! Ә ул, хыянәтче, сатлык, хаин, басурман татарлар белән әҗе-гөҗе килеп, сыгылып торган табын янында урысларны каргыйдыр әле. Ничек каргамасын!? Чын татар булып беткән бит!

Дөрес, ризыкка, икмәккә хуҗа буларак, Василий тилмереп ятмый. Тамак тук, өс бөтен дигәндәй. Әмма казнаның ярлыкы, бар нәрсәне гаскәриләр тикшереп, үлчәп тору, барысына килеп тыкшынулары саруын кайната. Үз малыңа үзең хуҗа булмагач!.. Кая монда Иван әйткән керем? Кая табыш? Кая Казан байлыгы, алтын-көмеш, хәзинә?!.

Юкса, үз өендә, якыннары арасында, бай табын янында гына утырасы кеше дә бит.

Табын сүзе исенә төшүгә энесе йортындагы мул сыйлы өстәл күз алдына килде. Гөлйөземнең ниндидер таныш түгел ризыклар, тәгамнәр белән сыйлавын хәтерләп, төкереген йотып куйды. Һай бар иде ул андый чаклар, кайсын кабарга микән дип сайланып утырган көннәр.

... Сәер, бик сәер барып эләккән иде ул Саньканың гаиләсенә...

Кәрван-сарайдагы саташулы төшкә охшаган очрашудан соң аны гомеремдә күрмәм, рәнҗеттем, үпкәләттем, кайда яшәвен дә белми калдым, дип уфтанган иде.

Иртән аны Иван сәүдәгәр уятты. Махмыры чыга башлаган Василий икенче якка борылып ятмакчы иде, дусты өстенә салкын су койды.

— Нәрсә, шаштыңмы әллә? Нишлисең?..— дип тешләрен шыкырдатты Василий. Иван көлде генә.

— Тор, тор! Кая барырга кирәклеген әйтсәм, рәхмәт укырсың әле,— диде ул, һаман аны йолыккалап.

Василий күкрәгендәге йонны ышкый-ышкый торып утырды, күзләрен угалап сорады.

— Беркая да бармыйм. Кая, тап булмаса берәр чәркә...

— Өмет тә итмә! Чәркә булмый. Соңыннан...

Иванның сүзеннән кайта торган кеше түгеллеген белгәнгә, буйсынып сорарга мәҗбүр булды:

— Кая барыйм соң?

— Бар, юын, чистарын,— диде Иван аның сүзләрен ишетмәгәндәй.— Санька янына барырсың. Өен, балаларын күрерсең... Сез туганнар бит.

Василийның йокысын, махмырын кул белән юып алгандай булды. Шикләнеп кенә сорады:

— Кая... ничек? Йортын белмибез, үзе чакырмады...

Иван хәйләкәр елмайды да, гадәтенчә, күз кысты:

— Анысы синең эш түгел. Әзерләнүеңне бел!

Саньканың йортына Иван озатып куйды. Ике катлы ташпулат иде ул. Төсле пыялалары белән балкыган тәрәзәләре, ак, яшел һәм зәңгәр төсләрне аралаштырып буялган түбә кыеклары, аның астында ярымайга охшатып эшләнгән тәрәзәчек, өй алдындагы җимеш бакчасы — барысы да энесенең җитенкелекле мул тормышта яшәвен сөйли иде.

Иван үзе кермәде, әмма Василийны өйрәтеп, ни-нәрсә сөйләшергә кирәклеген аңлатып кертте.

— Кичәгедәй дуамалланма,— диде ул кинәт мыскыллы тавыш белән.— Син тузынсаң, ул да шулай җавап бирергә күп сорамас. Безгә аның ышануы, ярдәме кирәк. Алдан сөйләшкәнне онытма. Ничек тә ризалаштыр, алтын-көмеш вәгъдә ит. Мәскәүдә мул сәүдәгә юл ачылыр, дип котырт. Сәүдәгәр кеше кызыксынмый калмас.

Кинәт аның тавышына янау, усаллык галәмәте чыкты, сүзләрен теш арасыннан чыгарып, колагына иелеп пышылдады:

— Мин үзем генә түгел, без күбәү диген. Әгәр риза булмасаң, нәселең урамга чыгарга куркып яшәр, диген. Өркет! Малаең күрдек, беләбез. Кайда да булса пычакка килеп кадалмас дип кем әйтә ала.

Василийның аркасыннан салкын су койдыларммыни, бөтен тәне чиркаными тартышып куйды, әмма каршы әйтергә, Иванны туктатырга аның көче юк, ул тулысынча аның ихтыярында иде.

— Йә, бар! Миннән сәлам әйт,— диде Иван аның аркасыннан этәреп.— Туганнарча кочаклашып үбешергә дә онытмагыз.

Аның тавышына тагын мыскыл төсмере чыкты.

Үзен мәче тырнагына эләккән, аның канлы уенчыгына әйләнгән тычкан хәлендә сизгән Василийның әле махмыры чыгып җитмәгән, Иванның астыртын мәкере дә миенә барып ирешмәгән иде. Ул кыюланып, күптән көтелгән кунактай, дәрт белән ишек шакыды.

Аны Сәет ачты. Йөзенә башта кара күләгә йөгерде, ләкин бу хәле озакка бармады, ачылып елмайды.

— Син... Вася... Ничек табасы иттең?.. Кичә... аңлашып та бетермәгән идек,— дип сөйләнергә кереште.— Әйдә, үт, рәхим ит!..

Болары өтек-төтек кенә истә калган. Василийның күз алдында табын күренеше кат-кат яңара, ул андагы ризыкларның ят яңгырашлы исемнәрен исенә төшерергә азаплана иде.

— Монысы пылау,— дип елмайган иде Гөлйөзем, ниндидер саргылт төстәге җимешле, итле, дөгеле, таралып торган хуш исле ризыкка күрсәтеп.— Белмим, ошармы...

Ул чакта пылаудан бигрәк Гөлйөземгә таң калган иде Василий. Озын, куе керфекле серле кара күзләр, биленнән узган калын кара толым, ап-ак йөз... сыгылмалы зифа буй-сын... Ике бала табып үстерсә дә, инде утызның бу ягына чыкса да, энесенең хатыны яшь кызлар шикелле чибәр иде әле. Бер карауга ук аннан ниндидер җылы нур бөркелгәндәй була, шул талгын дулкын күңелне иркәли, тынычландыра сыман иде. Әйе, килен тиешле кеше матур, сөйкемле генә түгел, бик ягымлы, мәхәббәтле дә иде. Василий аңа карап телсез калуын, онытылып соклануын сизми дә калды.

— Йә, ризыктан авыз итик,— дип, сәер халәтеннән Санька чыгарды.— Ничә еллар күрешмәгән туганнарның очрашуы бәйрәм түгелмени!?

Василий исә күзен Гөлйөземнән ала алмый, энесенең шушы чибәр аркасында Казанда калуын, әти-әнисе, туганнарыннан ваз кичүен уйлый, олуг хыянәтенең сәбәпләрен аңларга тырыша. «Санька урынында булсам, мин нишләр идем икән?!»

Нечкә борынлы, өсте нәни мендәрчек белән капланган керәч савыт тотып кергән Гөлйөземнең бер елмаюы барысын да хәл итте: күңелендә көнләшүгә охшаш хис кыбырсый башлады. «Әллә мин Санькадан кимме?! Әллә мин бу чибәрне карата алмаган булыр идемме?.. Киреәксә, Казанда да кала алыр идем...» Уйларыннан үзенә үк кызык тоелып китте, ирен чите белән елмаеп куйды һәм кирәксез фикерләрне башыннан чыгарып ташларга теләгәндәй, сиздерми генә кул селтәп, Гөлйөземнең тылсымга охшаш салмак хәрәкәтләрен күзәтергә кереште.

Гөлйөзем исә чынаяк савытларны бер куйды, бер алды, күктән төшкәндәй назлы тавыш белән сөйләнде:

— Чәй эчкәндә күктәге илаһи затлар белән сөйләшкәндәгедәй рухи тынычлык кирәк. Бөтенебез бер булып, табигатькә кушылып, искән җилнең иркәләвен, аккан суның талгын пышылдавын, яфракларның шыбырдавын аңлар дәрәҗәдә үз-үзеңә йотылу сорала. Яныңда утырган якыннарыңның җанын үзең белән бер итеп тәярлык рухи тынычлык, җан сабырлыгы булганда гына эчемлекнең тәмен, канга сафлык бирүче ләззәтен тоярсың...

Василий боларны аңлый да, аңламый да кебек. Гади бер эчемлек эчкәндә шушындый бөек мәгънәле сүзләрнең табигый яңгыравы, Гөлйөзем йөзендәге тантаналы сабырлык аны сәерсендерә, әмма шул ук вакытта тылсымга бирелгәндәй аңа буйсынырга да мәҗбүр итә иде.

Гөлйөзем чынаякларны нечкә борынлы савыттан кайнар сыекча белән чайкап алды, аны өскә күтәрә төшеп яңадан тутырды да иң элек Санька алдына, аннан Василий алдына китереп куйды.

— Ягез, инде авыз итик, кадерлеләрем. Күңелегезгә хушлык иңсен, җаныгызга мәрхәмәт, каныгызга мәхәббәт керсен!

Санька үзенә сузылган савытны ике куллап алды да учларын җылыткандай бераз тотып торды, шуннан соң гына иреннәре янына китерде.

Беренче йотымны ясаганнан соң Василийга борылып пышылдады:

— Чәйнең беренче йотымы — беренче мәхәббәт кебек саф, беренче убү кебек үк нәфиссез булыр... Чәйнең җитмеш чиргә дәвасы бардыр...

Тантаналы, артык озакка сузылган йоланың мәгънәсен аңлап бетермәгән Василий аның үзе шикелле үк пышылдап сорады:

— Нинди эчемлек соң бу? Шулкадәр затлы нәрсәмени?!

Санька үзалдына елмаеп куйды. Ул ике арада урнашкан татулыктан рәхәт чигеп, изрәп мендәргә таянды, хатынына баш селкеп эндәште:

— Гөлйөзем, сиңа әйтәм, пешермәгәнен дә алып кер әле. Күрсәтик. Бәлки, ошап та китәр... Урыс халкы бал эчә, квас, хәмер эчә. Чәйне белми...

Василий аның бу сүзләренә кичәгечә үртәлеп куйды: «Үзе урыс түгелме әллә?!» Әмма үзен бик тиз кулга алды, ризалашып баш иде.

— Һәр халыкның үз эчемлеге... Әйе!..

Гөлйөзем ак керәч савытта ниндидер кара-көрән төстәге кипкән яфрак алып керде, аны нечкә ак бармаклары белән уып алды да өстәлгә таратып салды.

— Бик затлы эчемлек. Сихәтле әйбер,— дип сөйләп китте Санька.— Чин якларыннан кайтартабыз. Бәһасы алтын белән үлчәнә. Сирәк нәрсә... Хәер, нигә әле кунакны һаман сүз белән сыйлыйбыз? Әйдә, эчик, авыз итик... Үзең бәяләрсең...

Аны Гөлйөзем бүлдерде:

— Йә инде, артык мактанып ташладың түгелме?!

Иренә яратып, балага карагандай наз белән күз төшерде, озын керфекләре дерелдәп куйды, йөзенә алсулык йөгерде.

Боларны да Василий күреп, тоеп утырды, алар арасындагы татулыктан көнләшеп, кызыгып калганын да сизде.

Ә Гөлйөзем иренең агасына ярарга тырыша иде кебек, табындагы иң тәмле ризыкны аңа таба этеп куя, зур кара күзләренең ачык карашы Василийның бәгыренә үтеп керә, үрсәләндерә, уттан алып суга, судан алып утка салгандай эчтән куырылырга, үзе өчен тыюлы, энесенең хәләл җефетенә әйләнгән шушы затның ягымлы карашын күрергә, ягымлы тавышын ишетергә теләп тагын-тагын аңа борылырга мәҗбүр итә иде. Икенче бер нәрсә дә гаҗәпләндерә: кичә ире белән нәрсә булганны беләме бу, белмиме? Белсә, ничек шулай якты йөз күрсәтә ала? Фәрештә кыяфәтле татар хатынының эчендә бер-бер мәкер, хәйлә ятмыймы? Әмма Василий берничек тә соравын кычкырып әйтә алмый иде, әлбәттә.

— Мин Сәеткә күптәннән әйтеп килә идем инде,— дип куйды Гөлйөзем аның уйларын сизгәндәй.— Дөньялар имин, ил-көн тыныч чагында Угличка кайтып килик, танышыйк, дип. Кайчан да булса бер аңлашырга тиеш идек ич инде...

— Гөлйөз-е-е-ем,— дип сузды Санька.— Онытылган нәрсәләрне искә төшереп, җанны кыйнамыйк. Беләсең ич, мин кайта алмый идем... Мин алар өчен үлгән идем инде... Ә теге дөньядан кире кайтмыйлар. Юлы юк.

Сүзне дәвам иттерә алмадылар, бүлмәгә озын буйлы яшь егет килеп керде. Василий, авызына кабарга күтәргән ризыгын ярты юлда туктатып, егеткә карап катты да калды. Аның каршында Санька — моннан унҗиде ел элек югалган Санька басып тора иде. Шул ук буй-сын, бәдәненең төзлеген тагын да зифарак итеп күрсәтүче киң җилкәләр, мәрмәрдән уелгандай нык муен, ак йөз, ап-ак тешләр, куе кашлар. Хәтта аяк атлауларына кадәр таныш, Саньканыкыча иде. Ләкин бер үк вакытта Санька да, Санька түгел дә кебек. Үсмердә ниндидер икенче бер затлылык, ул чакта Санькага хас булмаган башка бер матурлык та бар иде, ахрысы. Ныклабрак карагач, тагын-тагын күздән кичергәч кенә Василий аңлап алды, гаҗәпләнүеннән, гадәттәгечә, чак кына маңгаена сугып куймады. Егеттә Санькага хас ирлек чалымнары Гөлйөземнең үтә нечкә, затлы, хатын-кызларча нәфислеге белән үрелгән. Ишек катында ир белән хатынның иң яхшы төсмерләрен берләштергән, аларның яхшыртылган нөсхәсе басып тора иде. Тагын шунысын да абайлап

алды: күзләре җете зәңгәр түгел, ә Гөлйөземнеке шикелле сер яшергән зур, кара күзләр иде.

«Шушы баланың җанын кыяргамы?! Мин шушы балага кул күтәрергә тиешмс?» Иван әйткәннәр исенә төшеп, Василий тетрәнеп куйды. Үзе өчен ике газиз җан — Санька белән Гөлйөземнең бәгырьләреннән өзелеп төшкән бу зат та аңа хәзер якын, бик якын, кадерле тоела башлаган иде.

«Чәйләре тәмле иде. Баштарак авызны бөрештергән кебек тоелса да, соңыннан тәнгә рәхәтлек бирә, җиңеллек китерә икән... Гаҗәеп әчемлек»,— дип уйлап куйды Василий. Аның фикере, уйлары бер эзгә төшә алмый, үткәннәр арасында бутала, күңелендә кайнаган ачуның зәһәре башка истәлек-хатирәләрне юып алып китә иде.

Чыннан да, гаҗәп бит. Чәй эчкәч, ишегалдына чыктылар. Шул чакта Василий гәүдәсендә рәхәт җиңеллек тойды, башы ачылып китте, әйтерсең, сиздерми, күзгә күренми генә басып, изеп торган билгесез чир-сырхаудан котылды.

Бакчада алмагачлар, кура җиләге, шомырт, карлыган куаклары. Уртадагы ачыклыкта ак мәрмәрдән шактый гына олы хавыз[1] ясалган. Аның бер як кырыендагы таш улактан челтерәп су агып тора, хавызда исә төрле сүсемнәр чайкала, төбендәге төрле төстәге чуерташлар вак дулкыннар аркылы биеп торучыниндидер җан иясләрен хәтерләтәләр. Шушы тын почмакка килеп утыргач, Василий әкрен генә Иван сәүдәгәр әйткәннәрне сүтәргә кереште, сакланып кына сорау бирде:

— Кичә сөйләшкәннәрне хәтерлисеңме?

Сәетнең битенә куе кызыллык йөгерде, зәңгәр күзләреннән кара шәүлә йөгереп узды.

— Мин ул хакта бүтән сөйләшергә теләмәс идем,— диде ул агасының күзләренә туп-туры карап.— Мин инде Казан кешесе, күреп торасың — динем бүтән...

— Анысы әһәмиятле түгел,— дип бүлдерде Василий.— Динең бүтән дә, җаның урыс ич. Без бит туганнар... Аңлыйсыңмы, туганнар!.. Кан тамырларында безнең кан, урыс каны ага. Динсез дәһри булсаң да, басурман булсаң да, тагын әллә нинди курчакларга табынсаң да, белергә тиешсең: урыс кайчан да урыс булып кала. Әгәренки син үз кавемеңә ярдәм итмисең икән, синең бу дөньяда яшәргә хакың юк. Урыс башкача яшәргә тиеш түгел. Аңлыйсыңмы син шуны? Беләсеңме?..

— Яхшы, бик яхшы аңлыйм, Василий. Әмма сез әйткәннәргә күнә алмыйм. Унҗиде ел татар арасында яшәп, алардан бер кәррә яманлык күрмәдем. Хәзер шуңа этлек белән җавап биримме?! Булмый! Онытма: хатыным татар, улым, кызым татар... Мин аларның бердәнбер яклаучысы, саклаучысы...

Сәет бераз уйланып торды һәм, үзе өчен авыр, гаять авыр нәрсәне хәл итеп бетергәндәй, маңгаен учлап авыр сулады да тагын дәвам итте:

— Мине теләсә ни эшләтә аласыз... Хатыныма, балаларыма гына тимәгез... Туган икәнсең, бер нәрсәдә килешик: иң яхшысы — бу сөйләшү булмады дип уйлыйк. Сез әйтмәдегез, мин ишетмәдем. Җаныбызга гөнаһ алмыйк. Мин сезгә зыян китермәм, ишеткәннәремне кемгә дә чыгармам. Шушының белән бетерик! Калганы барысы да алла кулында. Теләсә ярлыкар, кирәксә җәзасын бирер.

Василийның тагын ачуы кабарды, энесенең басынкы сабырлыгы, бөтен тәкъдимне читкә тибәреп, юкка чыгарып баруы аны үрти, үрсәләндерә иде. Йомышын үтәми кайтсаң, Иваннан игелек көтмә. Анысы да күңелендә авыр таш булып ята. «Үзенә яхшылыкка әйтәбез юкса. Казанга ни-нәрсә янаганын чынлап аңламыймы, аңламамышка салышамы?! Дивана түгел ләбаса!» Ачуын эчкә йотып, аның үзе шикелле салмаклык белән сөйләргә тырышты, иң каты, мәкерле соравын бирде:

— Ә Казан урыс кулына калса? Тагын урыслыкка чыгарсыңмы? Безнең дингә күчәрсеңме?

---

[1] Хавыз — бассейн.

Мондай сөальне көткән идеме, әллә инде күптән җавабын әзерләп куйган идеме, Санька бер тында әйтте де салды:

— Илгә ни булса, безгә шул булыр... Башкасын көтмим!

Озак сөйләштеләр, әмма аңлаша алмадылар. Санька тискәре, үз сүзендә каткан үҗәт адәмгә әйләнгән иде. Василийның соңгы фикере шундый булды. Хушлашканда Иван өйрәткәнне үзәгенә үткәрерлек итеп әйтергә тырышты:

— Кара аны, әгәр белгәнеңне хан сараена тишсәң, үзең түгел, улың җавап бирер... Аны үзеңнән артык яратканыңны сизәм... Аның җаны белән түләрсең. Калагызда бездән башка да кешеләр житәрлек. Ник туганыңа үкенерсең! Йә, инде хәзер ни дисең? Бәлки, кире уйларсың?.. Без ике сөйләмибез...

Саньканың йөзе кәфендәй агарды, иреннәре калтырап куйды, кулы билендәге хәнҗәргә үрелде.

— Чыгып кит! Хәзер үк чыгып кит!—дип пышылдады ул.—Эзең булмасын! Без туганнар түгел, ту-у-ге-е-л!

Василий исә аны үртәүдән, котыртудан тәм таба башлаган иде инде, юри аңламамышка салышты:

— Ә, әй-йе, китәм. Гөлйөзем белән, улың белән хушлашыйм да... Бәлки, аларга да әйтергә кирәктер... Киңәшләшик!.. Әле тагын кайчан күрешәбез...

— Беркайчан да,—дип кычкырып җибәрде Санька һәм кинәт мәче житезлеге белән Василийны җилкәсеннән эләктереп алды да җилтерәтеп таш капкадан чыгарып та ташлады.

Урамда Василий энесе ишетсен өчен башта кычкырып көлде, бераз киткәннән соң ачуына буылды, тешләрен шыгырдата-шыгырдата кире килеп, капкага тибәргә, йодрыклары белән төяргә керешге. Эчтән җавап булмады. Инде нишләргә дип кенә торганда урам чатыннан бер төркем атлылар—шәһәр сакчылары килеп чыкты. Алар, нәрсәдер дөбердәгәнне ишеткән, күрәсең, ачулы кыяфәт белән Василийга таба якынлаша башладылар. Василий баш киемен салып, буйсынучан кыяфәт белән аларга баш иде һәм, инде берни дә майтара алмаячагын чамалап, кәрван-сарайга атлады. Китүе яхшыга булды. Урамның икенче башыннан да атларын юыртып бер төркем чагдавыллар менеп килә иде.

«Аһ, шул чакта ялгыштым,—дип уйлап куйды Василий.—Иванга ирек куйсам, кызлар кебек чибәр әнчеген тотып бирәр җиргә япсак, Санька да хәзер тик ятмас иде. Казанлыларның дары базларын күккә очырса, без дә болай җәфа чигеп ятмас идек. Әле кайчан басурманнар җыйган байлыгын ашап бетерә?.. Казанлыларны ачка тилмертеп кенә шәһәрләрен алып булмый. Беләм мин!.. Казан бай, артык бай шәһәр. Бер Ташаяк ярминкәсе генә күпме мал бирә, керем бирә...»

Казанлылар, чыннан да, камалыштан артык борчылу сиздермиләр иде. Гадәттәгечә, морҗалардан төтен күтәрелә. Божра булып урнашкан урыс гаскәре өстенә җил искән саен пешкән икмәк, кыздырган суган, ит, балык исе килә. Тау башындагы каладан балык исе килүгә урыслар аптырый, бот чаба, коры җирдән балык табуларына шаккаталар. Телдән-телгә сүз йөри имеш татарларның сихерчеләре бар. Шулар таба, шулар ярдәм итә.

Бәлки шулайдыр да. Юкса, йөз илле меңлек чиру камаган кала халкы шулай тыныч, сабыр кала алыр идеме?! Яу кырында күзгә-күз очрашканда бер татарга биш урыс туры киләсен белгән казанлылар түземлек, сабырлык күрсәтәләр, нидер көтәләр, нәрсәгәдер өметләнәләр иде булса кирәк. Хәер, аларны аңлап була. Урыс үзе ачка тилмереп кайтып китмәгәе!.. Казанлылар—акыллы, алдан уйлап эш йөртә торган халык. Белмичә, алдан уйламыйча кыланмыйлардыр...

Инде ике көн сугыш кырында тынлык. Урыс һөҗүм итми, татар атмый. Сәер, шомлы, дәһшәтле тынлык.

Эч пошуга чыдый алмаган, түземе, тәкате беткән Василий азык-төлек чатырында ята. «Нигә доньясы кадалып китми шунда! Иваны да кайта белмәде, ичмасам!..»

Он тутырган капчыкка башын куеп черем итә башлауга тышта сугышчыларның, олаучыларның куркынган тавышлары ишетелде:

— Тагын сихерче чыкты...

— Сихерче... Сихерче!

Керфекләренә, күз кабагына кадаклы гердәй баса башлаган йокы шаукымын кул белән алып ташладылармыни, Василий сикереп торып тышка чыкты.

— Кайда? Кая? Кем ул?...

Олаучылардан берсе Казан өстендә сөңгедәй күккә үрелгән иң биек таш манарага төртеп күрсәтте.

— Әнә ич, әнә!

Күпме генә тырышмасын, Василий бернәрсә дә аера алмады. Очына алтын ярым ай куелган, җиде катлы манарага текәлде, аның катларын санарга кереште. Астагы өчесе дүрт кырлы, өстәге дүртесе сигезкырлы итеп кызыл кирпечтән эшләнгән таш энә җансыз, тавышсыз иде. Аны казанлыларның аеруча хөрмәт иткәннәрен, кадерләгәннәрен дә белә Василий. Ире Сафагәрәй ханның кабере өстенә төрбә-мәчет итеп аны татарның яраткан хөкемдары — Сөембикә патшабикә салдырган, имеш.

Манараның катларын, бизәкләрен, тәрәзәләрен санап маташкан җиреннән кинәт шым булды, эченә җирәнгеч бер курку керде, бала йоннары кабарды. Манараның иң очындагы тәрәзә уентыгында, чыннан да, кемдер бар, ап-ак киемле башын сузып, кулын кашларына куеп ул еракка — урыс гаскәре артында каралҗымланып торучы шомлы куе урманга текәлгән иде. Менә аның кулында берсе яшел, берсе кызыл ике әләм пәйда булды; аларны болгап сихер кылырга, шайтани көчләрне, тамуг җаһилләрен ярдәмгә чакырырга кереште. Әнә яшел әләм баш биеклегенә өскә күтәрелде, аннан көнчыгышка борылды, кызыл әләм исә кискен аска төшеп китте, тәрәзә астында болганды. Шушы хәрәкәтләрне сихерче өч тапкыр кабатлады һәм, әләмнәрне аркылы-торкылы китереп болгагач, уентык караңгылыгына кереп югалды.

— Бер-бер афәт килгәнне көт тә тор хәзер, — диде кемдер.

— Сихерләде, безне сихерләде, — диеште олаучылар.

Казан тылсымчысының кул хәрәкәтләрен өнсез күзәтеп торган төркем өстендә шом канат җәйде, күңелләрендә курку хисе борын төртте. Камый башлауның икенче көнендәге зилзилә, гарасатлы давыл исләренә төшкән саен һәркемнең йөрәге калтырап куя иде.

— Аллам сакласын! Спаси и сохрани! — Олаучылар, сугышчылар белгән догаларын укырга, тәре үбеп чукынырга керештеләр.

Сихерче тәрәзә уентыгына кереп югалуга ярты сәгать үттеме-юкмы, урман ягында күк күкрәгәндәй тавышлар ишетелде, меңнәрчә атларның такыр җиргә дөп-дөп басуыннан туган бу аваз каныңны бозга әйләндерерлек дәһшәтле, шомлы, куркыныч иде. Кобә, очлы тимер башлык кигән җайдаклар, аларның ялтырап торган калканнары һәм алга төбәлгән, җилдә сызгырып килүче сөңгеләре, тимер ташкын сыман алга ургылуы иң салкын канлы, гайрәтле сугышчыны да тетрәндерер иде. Сафлар өстендә яшел әләмнәр, ярым айлы сөңге сабына беркетелгән туплар җилферди, атлы гаскәр тыелгысыз дулкын булып урыс явы өстенә якынлашып килә иде.

— Ура! Кама!..

Бер ук атар ара калуга, меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылып чыккан көчле тавыш урыслар сафын таркатты, кайсы йоклап, кайсы ял итеп яткан гаскәриләр коралларын ташлап кача башлады, атлылар тупланып, каршы торырга әзерләнде. Әмма әзерлексез гаскәр тиз арада җыела алмады, татар ташкынын туктатыр көч юк иде инде.

Үлем белән, котылгысыз яу белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашкан Василий кинәт хәлсезләнде, тез буыннары йомшарды, куллары калтырый башлады.

— Нишләргә, нишләргә? Кая качып котылырга?! — Үзе дә белмичә ул бертуктаусыз шул сүзләрне кабатлый, бәргәләнеп котылыр әмәл эзли иде. Миен яшен тизлеге белән телгән уйдан шашынып сикерде дә чатырга чап-

ты, ашлыктан бушаган чыпта капчыкка кереп, авызын эчтән умырып тотты да тынды. «Татар капчыкны кисмәс, капчыкка кадамас. Җансыз әйбердә, капчыкта аның үче юк!»

Көтелмәгән яу ничек тиз килгән булса, шундый ук тизлек белән эреп юкка да чыкты, тояк тавышлары яңадан урман ягына китеп югалды.

Әле бик озак чыгарга базмый ятты Василий. Ниһаять, тәвәккәлләп чыптадан башын тыкты һәм тирә-яктагы тынлыкны күреп, җиңел сулап куйды. Эчендә шатлыклы хис котырды: «Мин исән! Исән! Тагын исән калдым... Алла ярдәменнән ташламады!..» Аның канлы гәүдәләр арасында бисе, сикерәсе, тамагы ертылганчы кычкырасы килде. Тыелгысыз бу хистән ул котыла алмый, аяклары чыпта эчендә үзеннән-үзе тыпырчына иде.

Шул ук мизгелдә икенче якта ат тояклары дөпелдәде. Соңга калган урыс гаскәрләре һай-һу кычкырып, бер-берсен дәртләндереп сызгыра-сызгыра урман ягына чаптырып китеп барды. Әмма куе агачлар арасындагы һәр сукмакны, киек җанвар эзләренә кадәр биш бармагыдай белгән татар белән урманда алышып кара! Бу — урысларның җавапсыз калмас өчен үзләрен дәртләндерергә маташулары гына иде, әлбәттә. Моны сугыш һөнәреннән бихәбәр Василий да яхшы аңлады. Тагын бер нәрсәне ачык төшенде Василий: шанлы Казанны канга тончыктырып үзләрен коллыкка төшерергә килгән урысларга карата татарлар аяусыз, мәрхәмәтсез булачак, канлы үч алырга тырышачак!

Соңгыдай манара очында сихерче көн саен күренә, ул кереп китүгә урыс гаскәренең әле бер, әле икенче ягында, бөтенләй көтелмәгән җирдә тотылмас атлылар пәйда була. Алар күз ачып йомганчы дошман баскан кырны өермәдәй иңләп үтәләр дә урман ешлыгына кереп югалалар.

Шул көннәрдә тагын бер аяныч хис кичерде Василий, үзен битәрләде:

— Их! Санька белән килешеп булмады. Үҗәт җан! Сатлык! — дип энесен дөньяда үзе белгән барлык әшәке сүзләр белән сүкте, каһәрләде.

Сәбәбе бик гади иде. Гаскәриләр әйтте, манарадан күренүче кеше сихерче түгел, күзәтүче икән. Урман артында посып калган татар гаскәренә кайдан һәм кайчан һөҗүм ясарга кирәклеген белгертә, урысның йомшак ягын күрсәтә. Утыз мең атлы белән Япанча морза урысның артында шуның өчен махсус калдырылган, имеш. Ул гына да түгел, күзәтүче дигәннәре әләмен болгап алар белән сөйләшә, кирәк хәбәрләрне дә тапшыра икән. Тагын сүзләр йөрде: имеш, бөек кенәз хәзрәтләре шул телнең — әләм теленең серен ачкан кешегә алтын, теләгәнчә мал, дәрәҗә вәгъдә иткән. Дөрестерме, юктырмы, әмма воеводалар гына түгел, гади сугышчылардан алып олаучы, аш-сучыларга кадәр барысы да манарада уйнаган әләмнәрнең серен аңларга тырышып баш ваталар, һәр хәрәкәтне үзләренчә аңлатырга җай эзлиләр, бәхәсләшәләр иде.

— Әгәренки Санька ризалашкан булса, бу телне дә белә алыр идем ич, — дип үрсәләнде Василий.

Ә сер чишелмәде. Япанча атлылары урыс гаскәренә бер генә көнгә дә тынгы бирми, бимазалый, үрти, даими киеренкелектә тота, яшь кенәзне гасабиланып тешләрен шыгырдатырга мәҗбүр итә иде.

## Хыянәт һәм үч

Һәм соңыннан мөһәндисләр хәйлә тапты,
Моңача урыс белмәгән эшне корды:
Кара төндә качып-посып юллар сапты —
Гаскәриләр кирмән астын казып керде.

«Казан патшалыгы турында риваять».

Иван сәүдәгәр җитәкчелегендә Мәскәүгә җибәрелгән олаучылар әйләнеп кайтты. Алар ашлык, ысланган ит, балык, җылы кием-салым, дары һәм байтак сугыш кирәк-яраклары төяп килгәннәр иде. Тагын берничә

көннән Иделдән йөк көймәләре килеп җитәсе. Мәскәүдә яңа полклар оешкан, алар юлга чыккан.

Болардан тыш та яңалыклар шактый иде. Йокчеләрне, сәүдәгәрләрне озата барган гаскәриләр үзләре белән бер төркем «телсез» мөһәндисләр[1] ияртеп килгәннәр. Алары исә кальга-кирмән алуның яңа, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән ысулларын беләләр. Казанның менеп булгысыз биек диварларын алуда, су тутырылган тирән урлрын кичүдә шулар ярдәменә таянасылар, имеш.

Чатыр корып инде ничәнче көн түшәмгә төкереп ятучы, эшсезлектән, ачлыктан һәм көчсезлектән, Япанча би атлыларының туктаусыз һөҗүменнән арыган, алҗыган һәм озакламый Мәскәү ягына кыяклау турында хыялланган гаскәрне алыштырып куйдылармыни — китте көлеш, китте уен, китте мәҗлес. Бөек кенәз бу тузынуга күз йомды, саргаскәрләр сугышчыларның дәррәү кузгалып бушануын күрмәмешкә салышты. Көчләрнең тигезләшүеннән күтәрелгән бу дәрт, яугирлык галәмәте аларга да йоккан иде булса кирәк.

Василий да гомум шаукымнан читтә калмады. Аның кулына күз ярми. Юан кәүсәле йөзьяшәр имән ябалдашы астына тәгәрәткән саллы мичкәләрдән чүмечләп ачы бал чүмыра, балчык кувшиннарга аракы бүлә.

— Әйдә, җырла, бие, урыс!.. Синең көнең килде. Тиздән Казан безнең кулда буласы. Ә инде анда болай гына туй итмәбез... Утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп... Шулаймы? Әйдә, ябырыл!

Үзен чорнап алган кешеләргә дәртләнеп кычкыра-кычкыра аның тамагы карлыгып бетте, көмеш, бакыр акча саный-саный бармаклары талды. Билендәге янчык авырайганнан-авырайды. Дөнья яңадан матурланды, яңадан киңәйде. Их! Яшәп күрсәтәбез әле бер!..

Шушы мизгелдә ул тагын Санькаsuccessfully, чибәр Гөлйөземне, аларның зифа сынлы яшь пәһлеван улларын исенә төшерде, кызганып куйды. «Бу кадәр чиргә хәзер каршы тора алырсызмы? Без дә күрсәтербез әле!» — дип масайды, аларның бу муллыкны, бу иркенлекне, көч-гайрәтне күра алмауларына үртәлде. «Күрсеннәр иде, тезләнеп каршына килсеннәр, ялынсыннар иде. Юк! Вася аларны куып чыгармас иде. Сыйлар иде. Янчык-янчык акчаларын чыңлатып күрсәтер иде. «Йә, татарга әйләнеп ни оттың? Инде хәзер ялгышканыңны белдеңме», — дип котыртыр, үртәр иде. Казанны алгач тагын ниләр бұлачагын уйлап, аның хыялы котырды, күз алдына тау-тау байлык, алтынкөмеш, затлы куннәр, чибәр кызлар, кәнизәк-җарияләр килде. Шуның өстенә Василийның хәтта Иван сәүдәгәр дә белмәгән яшерен хыялы, өмете бар. Әле сабый чагында ук әтисеннән ишеткән сүз ул. Дөрестерме, юктырмы — анысын тәгаен гына әйтә алмый, әмма әтисенең сүзенә ышанмаска да мөмкин түгел. Имеш, Казан сәүдәгәрләренең иң каттәләрендә ниндидер яшерен тамга була. Шул тамга аларга теләсә кайсы базарның, каланың ишеген ача, бернидән курыкмый, шикләнми сәүдә итәргә юл саба. Ул тамга иясе теләсә кайчан базар агасыннан теләгән хәтле акча алып тора ала, ярдәменә таяна. Шәрекъ базар агалары ул тылсымлы тамганы иң абруйлы, иң бай, иң гадел, акыллы сәүдәгәрләргә генә бирә, имеш. Аңа ия булсаң... дөньялыкта кайгың бетте диган сүз. Әтисе аны сурәтләп тә биргән иде. Сәмруг кош сурәте төшерелгән көмеш тәңкә, имеш. Чын сәүдәгәр аннан үлгәнче аерылмый, имеш. Үлсә үлә, әмма тамганы сатмый, алыштырмый, теләсә кемгә белгертми дә...

Василийның хыялы шул: Казанда әлеге тылсымлы тәңкәне — базар тамгасын кулга төшереп булмасмы?!. Кем белә... Эчемлек парыннан үрләгән, бәргәләнгән хыялның чиге юк, ул бу мизгелләрдә бөтен җиһанны колачлый.

Гаскәр ял итте. Шул ук вакытта һәр ике якның үзәгендә кайнар бәхәс бара иде.

Бөек кенәз чатырына боярлар, воеводалар, полк башлыклары кереп тулды. Яшь хөкемдарның алар фикерен, тәкъдимен ишетәсе килә. Ләкин белә — берсеннән бер юньле сүз чыкмаячак. Урыс белән татарның сугыш

[1] Мөһәндис — инженер.

сәнгате бер төрле. Таш кальга эчендә соң чиккәчә көрәшергә ант эчкән көчле һәм усал гаскәр. Шуның өстенә артта ни кыласын тәгаен белеп булмый торган җитез атлылар — Япанча морза алайлары.

Сугыш һөнәрен татардан ким белмәсәләр дә, воеводалар азмы-күпме өстенлек бирерлек нинди дә булса гайре табигый фикер, яңа алым тәкъдим итә алмаячаклар. Бар белгәннәре камауны дәвам иттерү. Анысын Иоанн үзе дә белә. Әмма камауның да бер чиге булырга тиеш ләбаса. Һәр куагы, һәр агачы урыска янаган рәхимсез татар җирендә күпме торып була. Алда пыскак көз, аннан зәмһәрир суыклары белән кыш килер. Җылы ташпулатларга кереп оялаган, үз җирендә, үз илендә һәр таш, һәр агач, һәр инеш ярдәм иткән басурман дошман белән якалашып кара!

Иванны иң гаҗәпләндергәне шул — тау башындагы кальга инде ничәнче көн камалышта. Очар кошлардан гайре анда беркемнең дә кергәне дә, чыканы да юк. Әмма казанлылар ачка интегү генә түгел, сусауларын да сиздермиләр. Юкса, Болак, Кабан, Казан-су — барысы да безнең кулда, якын-тирәдәге чишмәләргә кеше түгел, чыпчык та үтеп керә алмаслык сак куелган. Кара акыл белән исәпләгәндә дә, күп дигәндә бер атнадан сусаган, бер йотым суга тилмергән казанлылар яшь ханны бәреп төшереп, Иван алдына тезләнергә тиешләр иде. Икмәксез торып була, ә менә сусынны басу — башка мәсьәлә.

Иван йокысызлыктан кызарган ачулы күзләрен бер воеводадан икенчесенә күчерде, һәркайсының миендә ни кайнаганын белергә теләгәндәй, озак итеп, бәгыренә үтәрлек итеп карап торды. Авыр карашны күтәрә алмасалар да, күзләрен читкә төбәмәделәр. Иванның моны яратмаганын, күзгә туры карамаганны өнәмәгәнен алар яхшы беләләр иде инде.

«Йә, инде ни әйтерсез? — дип эчтән генә уйлап куйды яшь кенәз, әмма тынлыкны бозарга ашыкмады. — Инде азык-төлек җитәрлек, сугыш кирәк-ярагы, җылы кием-салым бар, дары һәм гаскәр хәттин ашкан... Алга таба ни эшлибез. Нигә авызыгызга су каптыгыз?! Барысын да мин генә хәл итимме? Тәкъдим әйтергә, фикерегезне белгертергә өркәсезме!?»

Шулчак чатыр тышында кемнәрнеңдер шаулашканы, сакчыларның айбалталарын бер-берсенә бәреп, ачулы әмер биргәне ишетелде.

— Галиҗәнаб бөек кенәз беркемне дә кертмәскә кушты. Артка! Артка чигенегез дим!...

— Мин мөһим хәбәр белән. Галиҗәнабка җиткерегез! Ашыгыч сүзем бар... Кабул итми калмас!

«Һа, кара син аны, үз-үзенә ничек ышана!» Иван үзалдына көлемсерәп куйды. Сакчыларга кычкыручы яшь тавыш иясенең кемлеген ул инде күптән танып алган һәм аның киңәшмәдә түгеллегенә күптән эче пошып утыра иде. Алексей Адашев — кенәзнең ышана, якын күрә торган бердәнбер киңәшчеләреннән иде. Моны сакчылар да белә булыр. Әмма боерыкны алар катгый үти. Шулай кушылган. Воеводалар сөйләшкәндә кем дә комачауларга тиеш түгел.

Иван, сизелер-сизелмәс кенә баш кагып, ишек төбендәге сарай хадимнәренең берсенә ишарә ясады:

— Кертсеннәр!

Хөкемдардан күзләрен дә алмый, аның һәр ымын, кул хәрәкәтен күзәтеп торган хадим «Аңладым!» дигәндәй бил бөкте дә ишектән чыгып югалды.

Күп тә үтмәде, чатырга еш-еш сулап, ярсыган Адашев килеп керде. Әдәп йөзеннән, сарай йоласы кушканча, иң элек бөек кенәзгә, дәрәҗәләренә карап аның тирәсенә төрле ераклыкта утырган боярларга башын иеп сәлам бирде һәм ашыгып сөйләргә кереште:

— Бөек хөкемдар! Казаннан якыннары белән Камай морза безнең якка күчте. Төнлә шәһәрне ташлап чыгу җаен тапканнар. Аның сез галиҗәнабка гына җиткерәсе сүзләре бар...

— Нинди сүз ул? Нигә сорашмадың? — Иванның йөз-кыяфәтенә шикләнү, ярсу һәм усаллык галәмәте чыкты, кашлары җыерылды, маңгаенда тирән сырлар барлыкка килде.

Алексей Адашев, барысы да сезнең ихтыярда дигәнне аңлатырга теләгәндәй, иңбашларын җыерып куйды да басынкы тавыш белән аңлатырга кереште:

— Камай морза Казанда хан сараена якын көчле шәхесләрнең берсе... Аңа карата вакытыннан элек, сезнең әмердән башка, усаллык, катылык күрсәтергә базмадым...

Кенәзнең йөзендә елмаюга охшаш нәрсә күренде, маңгаендагы җыерчыклар югалды, сөякчел бармаклары белән ияген угалап алды. Кинәт күзләре киң ачылды, теш арасыннан кысып, кискен өзеп сорау бирде:

— Тентедегезме?

— Әлегә юк, бөек хөкемдар! Боерыгыз!

Иванның канәгатьсезлеген сизгән Адашев ишеккә таба чигенде.

— Хәзер... Хәзер... барысын да эшлибез!..

Камай морзаның бите кәгазьдәй агарган, борын тишекләре киңәйгән, калтыранган бармаклары хөббәсенең көмеш төймәләрен әләктерә алмый азаплана иде. Сарай итагатенең бөтен шартын китереп иелеп сәлам биргәннән соң, ул утлы карашын Иванга төбәде.

— И урыс җиренең бөек хөкемдары Иоанн Васильевич! Мин синең янга чын күңелдән, намусым кушканга, изге теләк — ике арада кан коюны туктатырга ярдәм итү теләге белән килгән кеше. Беләсез: мин Бөек Казан мәмләкәтенең морзасы, тамырларымда аксөякләр каны ага... — Аның тавышы бер күтәрелә, бер төшә, фикерен югалтмас өчен барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыга иде кебек. — Мине... бөек асылзатлар белән мәҗлестәш морзаны... кара колдан, чурадан түбән куеп, чишендереп тентеннәр әле... Оят! Иоанн Васильевич, оятын кая куярсыз? Мин... Мин... ул кешеләреңне җәзага тартуны таләп итәм.

Морзаны анадан тума күз алдына китереп, Иван мыек астыннан гына елмаеп куйды, әмма аны бүлдерергә дә, хупларга да ашыкмады. Нинди максат белән килүе тәгаен ачыкланып җитмәгән казанлыга карата фикере урнашып өлгермәгән иде әле. Кинәт күңелен сөенеч хисе биләп алды: «Әгәр олуг морзалары безнең якка күчә башлаган икән, димәк, хәлләре мөшкел. Бусы — әйбәт фал!» Морзаны тынычландырырга теләп, сул кулын өскә күтәрде. Теленнән балдай татлы сүзләр агылды:

— Сине яхшы беләм, олуг морза! Дан-шөһрәтең Мәскәүдә дә билгеле. Тынычлан! Сиңа карата андый хөсетлек кылган холоп бүгеннән җәзасын табар — башы үләксәлектә черер!.. Без сине тыңларга әзер... Иң элек беләсем килә: безнең якка галиҗәнаб Казан ханы бөек Ядегәр ирке белән килдеңме? Хан ярлыгын китерүчеләрне без олуг кунак, иң зур хөрмәткә лаек затлардан саныйбыз...

Бераз тынычлана төшкән Камай морзаның битенә куе кызыллык йөгерде, бердән кечерәеп калгандай, гәүдә тотышындагы горурлык, турылык күзгә күренеп кимеде, акрын гына баш чайкады:

— Юк, бөек галиҗәнаб! Мин үз ихтыярым белән килдем!..

Иван чыраен сытып куйды. Мәҗлестә утыручы воеводалар сәерсенеп бер-берсенә карашып алдылар. Бернинди җиңелү, бирелү галәмәте сиздермәгән, кыю һәм горур казанлыларның хәле, алар уйлаганча, шактый нык, өметле иде ич әле. Һәм көтмәгәндә... беренче качкын! Гади сугышчылардан булса бер хәл. Ә монда... хан сараена, диванга якын даирә кешесе — морза басып тора. Аларның күз карашыннан шундый уйларны укып булыр иде.

Шуларны сизгәндәй, Камай морза ашыгып тезә башлады:

— О бөек хөкемдар! Урысларның җиңелү белмәс олуг патшасы! Мин артык каршы торуны мәгънәсезлек дип саныйм. Сезнең гаскәрнең күплеген, урыс коралының көчен беләм. Әгәр, мәрхәмәт күрсәтеп кабул кылсагыз, соң сулышымача сез галиҗәнабларга хезмәт итәргә әзермен!.. Аягың астында туфрак булыйм...

Камай артыннан кереп ишек катында басып калган Алексей Адашев җирәнгәндәй йөзен чытып куйды, морзага мәсхәрәле караш ташлады. Аның бу хәрәкәтен күреп калган Иван дусты, фикердәшенең йөз кыяфәтен кабат-

лый язды. Ләкин бик тиз үзен кулга алды. «Сәясәттә уй-тойгыларыңны тышка чыгармау фарыз. Юк кына сүзнең, мәгънәсез бер хәрәкәтнең, әһәмиятсез төбәлгән карашның эшкә зыян китерүе бар. Бәлки әле бу Камай морзаны файдаланып булыр... Кем белә... Сатлык җаннар үз халкына зыянзәүрат салмыйча гына дәрәҗәгә ирешә алмый. Ә бу, күрәм, дан-дәрәҗәгә, шан-шәүкәткә күнеккән адәм. Шул юлдан чыгасы килмәстер, шәт...» Тавышына ягымлылык төсмере салырга тырышып, сүзне дәвам иттерергә булды.

— Без сугыш кануннарына таянып эш йөртәбез. Корал көче кырда сынала, батыр яуда белен ә... Без казанлылар белән ачыктан-ачык сугышырга әзер. Чыксыннар ачык мәйданга: алышыйк, сынашыйк...

— Бу минем ихтыярымда түгел. Диван әһелләре соңгы сугышчы шәһит киткәнче каршы торырга җыена...

— Ядегәр ханның кыюлыгын хуплыйм. Әйе, хуплыйм,— диде Иван алтын шарлы таягына таянып.— Татар гаскәре көчле, йөрәкле, кыю... Моның белән без... Әмма урыска каршы торыр көч бармы хәзер?!

Камай аның сүзләрен раслагандай сыгылып баш иде.

— Әйе, бөек хөкемдар! Урыс олуг гаскәр белән килде. Көчләр тигез түгел...

Иван ачулы тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Белгәч, нигә каршы торасыз? Нигә кальга капкаларын ачмыйсыз?! Минем сабырлыгым, түземлегемне сыныйсызмы?

— Казанда берничә елга җитәрлек азык-төлек бар, бөек хөкемдар...

— Ә су... су безнең кулда... Бер генә кешене дә суга якын җибәрмәячәкбез. Белеп тор!

Камай морза үзе өчен нәрсәдер хәл итте, күрәсең. Иванга туп-туры карап, ашыгып пышылдарга кереште.

— О бөек хөкемдар, ялгышасың... Казанлыларның суы бар. Күз яшедәй чиста, саф сулы чишмәләре агып ята...

— Кайда ул, тау башыннан агып ятамы?— дип мыскыллы елмайды Иоанн Васильевич.

Аның мәсхәрәле тавышын ишетмәгән дә кебек, Камай һаман үзенекен тезде:

— Юк, юк, падишаһым! Ул тау куышында, Казан суы буенда. Халык җир асты юлыннан йөри. Сусауны белми дә... Нургали капкасы яныннан яшерен юл бар...

Ниһаять! Үзен борчыган сорауга җавап тапкан Иоанн Васильевич җиңел сулап куйды, ирен чите белән генә елмайды һәм алтын шарлы таягын тәхеткә сөяп, ике тапкыр кул чапты. Чатыр ишегендәге пәрдә чайкалып куйды, ачыклыкта баштанаяк коралланган ике сакчы күренде. Алар тавыш-тынсыз Камай морзаның ике ягына килеп бастылар һәм ишеккә таба ымладылар.

Камай кискән агачтай җиргә ауды, кулларын тәхет ягына сузып иңгырашты:

— Бөек хөкемдар! Ни өчен? Мин үз ихтыярым белән килдем...

— Ә син батыр йөрәклеләрдән түгел икән, морза! Курыкма! Без әле очрашырбыз,— диде Иван һәм сакчыларга ымлады. Алар исә ярым үле, ярым тере гәүдәне сөйрәп чатырдан чыгып та киттеләр.

Иван тагын бер мәртәбә кул чапты. Сарай хадимнәреннән икәү берьюлы ишеккә ташланды. Хөкемдарның һәр хәрәкәтен сүзсез аңларга өйрәтелгән бояр балалары берничә мизгелдән сәер киемле, җилкәләренә төшеп торган озын бөдрә чәчле бер төркем кешене ияртеп керделәр. Болар — мәгърип[1] илләреннән чакырылган телсез мөһәндисләр иде.

Воеводалар аларның тәннәренә сыланган тар чалбарларына, шунлыктан артык нечкә күренүче сыйракларына һәм кабартып тутырган мендәр сыман өс киемнәренә, барысыныкы бер төсле ак кодраләренә сәерсенеп карап алдылар, гаепләгәндәй баш чайкап куйдылар. Тукыманы җәлләмичә муллан

---

1 Мәгърип — көнбатыш.

тегелгән озын җиңле урыс киемнәре янында боларның өс-башы гайре табигый, ямьсез һәм шөкәтсез тоела иде.

Әмма мөһәндисләр үз дәрәҗәләрен яхшы беләләр иде булса кирәк. Алар уң аякларын барысы берьюлы алга чыгарып, кулларын як-якка җәеп, артык кабалану һәм ашыгу күрсәтмичә Иванга, боярларга баш иделәр, аңлашылмаган ят телдә берничә сүз әйтеп алдылар.

— Сез галиҗәнабләргә җиңү, байлык, сәламәтлек, дан һәм шөһрәт телиләр,— дип тәрҗемә итте баштанаяк кара киемгә төренгән озын буйлы тылмач.

— Теләкләрен кабул кылдык. Әйт: бер-беребезгә мактау һәм дан җырлап утырыр чак түгел. Кальганы күрделәр. Камауда ни майтарып күрсәтерләр икән?..

Тылмачны башларын кырын салып тыңлаган мөһәндисләр үзара тагын нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Арадан берсе, башкалардан өлкәнрәге — анысы башлыклары иде булса кирәк, иптәшләрен аралап алга чыгып басты һәм тылмачка әйләнеп тә карамыйча, туп-туры Иванга текәлеп сөйли башлады.

Тылмач ашыгып тәрҗемә итәргә кереште:

— Нәрсәдер башкару өчен без исәп-хисап ясарга, кирмәннең төзелешен белергә тиешбез, диләр. Мөһәндислек — төгәл хезмәт. Өйрәнмичә, белмичә нидер хәл итү безнең кагыйдәдә юк. Һәрхәлдә, мондый нык кальга-кирмәнне әлегәчә күргәннәре юклыкны әйтәләр.

Иван тәхетендә калкынып куйды, чит ил кешеләрен күрмәгән дә шикелле тылмачка ысылдады:

— Акыл өйрәтмәсен! Туктат! Монысын гына үзебез дә беләбез.— Аннан соң кенәз Серебряныйга борылып, бер мизгел эчендә үзгәргән ягымлы тавыш белән әйтте.— Кальганың төзелеше белән таныштыр! Чишмә турында да әйтергә онытма. Башларын ватсыннар. Йөзләрчә алтын түләп юкка чакырмадык...— һәм артык бер сүз дә әйтмичә тәхетеннән төшеп, чатырның калын зәңгәр постау белән бүленгән эчкәре ягына кереп тә китте.— Фикерләре өлгергәч чакырырсыз...

Василий Серебряный бөек кенәзнең мөһәндисләргә артык ышаныч җитмәвен, алар белән вакланасы килмәгәнлеген күптән аңлап алган иде инде. Эчендәгеен сиздермәскә тырышып, ул почмактагы тимер сандык өстендә яткан кәгазь төргәген алды һәм мөһәндисләргә кальганың эчке, тышкы төзелешен, ныгытмаларның үзенчәлеген, кайдан нинди юл барлыгын, казанлыларның гайрәтен, хәйләсен, түземлеген аңлатырга тотынды. Аның тиз-тиз сөйләгәненә тылмач чак өлгереп бара иде. Ниһаять, чират тау куышы, чишмә, җир асты юлына җитте.

Баштарак ялыктыргыч гадәти бер нәрсә тыңлагандай сызымнар өстенә битараф иелгән мөһәндисләр бер-берсенә карашып алдылар, күзләре ялтырый башлады, үзара нидер пышылдаштылар. Өлкән мөһәндис сөякчел бармагын сызымда күрсәтелгән манарага сузды. «Нурали, Нурали?» — дип куйды.

— Әйе, Нургали капкасы шул булыр,— дип җөпләде Серебряный. Аның ни әйтергә теләгәнен ул тәрҗемәсез дә аңлап өлгергән иде инде.

Мөһәндисләр бер-берсен бүлдерә-бүлдерә тагын нәрсә хакындадыр бәхәсләшеп алдылар. Эшсез калган боярлар, воеводалар авыз ачып кычкырып исни, урыннарында кырын ята төшеп, чит-ят кешеләрне сәерсенеп күзәтәләр иде.

Менә өлкән мөһәндис кулларын җәеп кәсептәшләрен туктатты һәм Серебряныйга карап, үзләренең әзер икәнлеген, бөек кенәзне күрергә теләгәнлеген белдерде.

Шуны гына көтеп торгандай, зәңгәр постау артыннан Иоанн Васильевичның озын какча гәүдәсе күренде. Аның йөзендә мәсхәрәле һәм бер үк вакытта канәгать елмаюны, сабыр, салмак хәрәкәтләрен күреп, воеводалар җиңел сулап куйды. Арадан берсе күршесенә төртте.

— Йөз алтынга бәхәсләшә алам, ул теге якта барысын да тыңлап, тәрҗемә иттереп торды...

Күршесе исә пышылдап җавап бирде:

— Күп сөйләшмә! Иванның колагы һәркайда...

Ул арада өлкән мөһәндис галиҗәнаб кенәз каршына килеп баскан иде инде. Ул тагын бер мәртәбә кергәндәге сәер хәрәкәтләрен кабатлады һәм һәр сүзен үлчәп алтын тәлинкәгә салгандай саллылык белән бәян итәргә тотынды:

— Без әмәлен таптык, бөек кенәз! Хәйләкәр татарлар үзләре үк юл күрсәтә. Алар казыган җир асты юлын без казый алмыйбызмы?! — Аның йөзенә тәкәбберлек, үзеннән разый-канәгать кешеләрдәгечә салкын елмаю чаткылары чыкты. — Сугыш сәнгатендә бу безнең өр-яңа сүзебез, олуг ачышыбыз булачак. О тарихи мизгел!

Иванның йөзе караңгыланганнан-караңгылана иде. Кинәт мөһәндис тотлыгып калды һәм хөкемдарның йөзенә карап тиз генә үзен төзәтергә ашыкты:

— Әйе, бөек кенәз! Бу урыс гаскәренең сугыш сәнгатендә әйткән яңа сүзе булачак... О бөек урыс гаскәре!.. — Һәм ул олпатлыгын онытып, ашыга-ашыга сөйли башлады.

Ярты сәгатьлек тәнәфестән соң чатырга Иоанн Васильевичның ышанычлылары җыелды. Аларга бөек кенәзнең яшерен фәрманы игълан ителде. Олуг хөкемдарга дан һәм мактау яудырылган чачаклы-чуклы сүзләрдән, аның ихтыярын шанлаудан соң фәрманның эчтәлеге кыска, мәгънәсе ачык иде: «Атлы һәм җәяүле гаскәр белән көн саен һөҗүм ясап, утка тотып татарны алҗыткан арада, Таһир мунчасы ягыннан җир асты юлы казып, чишмәне шартлатырга. Мөһәндисләргә үзләре сораганча җир казучы бирергә. Казуны үлем куркынычы астында һичкем белергә тиеш түгел. Серне ачучыга — әҗәл! Баз янына якын килгән һәр чит кешегә — ук! Сакчыларны агулы уклар белән коралландырырга. Җитәкчелек, сер саклауны тәэмин итү кенәз Василий Серебряный һәм Алексей Адашевка йөкләнә».

Киңәшмәдән соң, һөҗүм башланганнан бирле беренче тапкыр Иоанн Васильевич тыныч күңел белән чатырында бикләнде. Озакламый казанлыларның соңгы таянычтан мәхрүм калачагы җанына ял бирде, аяк-кулларын ятагына таратып тирән йокыга талды. Чатырда ятак сакчыларыннан — яшь бояр угланнарыннан гайре беркем дә калмады.

Ә воеводалар әмерне үтәргә ташланды. Гаскәрдән таза беләкле, нык бәдәнле сугышчыларны сайлап Таһир мунчасы янына кудылар. Тимер көрәкләр, тире капчыклар китерелде. Кич җитүгә, телсез мөһәндисләр әмеренә буйсынып, алар, өненә кереп качкан сукыр тычканнардай, җир тишегенә кереп югалдылар. Тирә-якка ук-җәяле сакчылар басты.

Бөек кенәзнең ихтыяры нигезендә, казу бары тик төннәрен генә алып барылачак, чыккан туфрак капчыкларда еракка, Казан-су ярына илтеп түгеләчәк иде.

— Тукта! Кем килә?

Каршында җир астыннан үсеп чыккандай пәйда булган пәһлеван гәүдәле сакчының тавышыннан Василий сискәнеп китте, кемлеген белдерергә ашыкты:

— Мин бу! Аш ташучы... сәүдәгәр Василий...

— Ананны... кабер тактасына... — Сакчы сүгенү сүзләрен ярсып, теш арасыннан кысып, пышылдап чыгарды: — Белмисеңмени... Сак янына килгәндә тамак кырып, кемлегеңне әйтеп киләсе... Йөрәгеңә ук аласың киләмени?..

— Гафу, гафу... Онытылып киткәнмен. Сезне болай якында ук дип белмәдем...

— Кара аны! Икенче килгәндә кемлегеңне сорап тормам.

Василий изүенә төкеренеп алды да сыртына аскан капчыгын рәтлирәтли каравыл яныннан тизрәк китәргә ашыкты. «Аллам сакласын! Патша полкы башкисәрләре күп сорап тормас!»

Чыклы үләндә тая-тая җир тишеге янына килеп җитте. Борынына юеш балчык, сөрем, атналар буе юынмаган ирләрнең авыр тир исе килеп бәрелде. Кеше биеклегендә казылып барган куышлыкта сумалалы күсәкләр дөрли.

еракта, чокыр түрендә кемнәрнеңдер сүгенгәне, тимер көрәкләрнең ташка бәрелеп чыңлаганы ишетелә иде. Василий капчыгын җайлаштырды, кулындагы мичкәне икенчесенә алыштырып тотты да белгәннәрен укып куышлыкка атлады.

Иван сәүдәгәргә җен ачулары кабарган иде аның. Инде тыныч кына Казанның бирелүен көтеп ятарга җай чыккач, тагын кабахәт җан аны мәхшәр уртасына китереп тыкты. «Көндез йокы симертәсең, төнлә нибары бер мәртәбә саф һава сулап кайтасың, имеш. Кайттың менә! Үзеңне китерәсе иде... Сулар идең саф һава,— дип эчтән генә Иванны каһәрләде, аның белән бәхәсләште.— Җаһиллеген кара! Кайда нишләп йөрүеңне эт тә белергә тиеш түгел, имеш... Алексей Адашев белән шаярырга ярамый. Бөек кенәзнең сөеклесе, тугры дусты, имеш. Адашев булмагае, шайтаным булсын. Нигә мин сәүдәгәр башым белән йомышчы малай сыйфатында йөрим ди...»

Эчтән сүгенсә дә, Адашев кына түгел, Иван сәүдәгәр белән дә шаярырга ярамаганлыгын бик яхшы белгән Василий карышып бер сүз дә әйтә алмаган иде. «Йөр менә хәзер... селкетеп»,— дип куйды ул һәм чертләтеп җиргә төкергәч, йомышын тизрәк йомышларга ашыгып адымнарын кызулатты. Чокыр түрендәге ут яктысында бил тиңентен чишенгән казучыларның тирле гәүдәләре, ялкын нурында җирдә уйнаучы шомлы шәүләләре күренә башлаган иде инде.

Бер мизгелдән аны битләре сөремгә, корымга буялган җир казучылар уратып алды. Аларның усал ялтыраган күзләрен, каклаган дуңгыз итенә батып керәчәк сары тешләрен күреп, Василий тетрәнеп куйды. «Болар белән шаярырга ярамый!»

— Озак йөрисең, сәүдәгәр! Йокың туймадымы әллә?

Алып гәүдәле казучының усал тавышы шөбһәсен тагын да көчәйтә төште. Әле генә Иван сәүдәгәр белән бәхәсләшүен онытып, киң күңеллерәк җавап бирергә ашыкты:

— Юл ерак, йөк авыр, туганнар! Килегез! Барысы да бар: каклаган ит, кабарып пешкән арыш ипие... Мичкәмдә ачы бал чымырдый.

Җир казучылар аны хуплап шаркылдаштылар. Көчле куллар аркасыннан капчыкны, бармакларыннан мичкәне ычкындырды. Карлыккан тавыш ишетелде:

— Йәгез, бөек кенәз Иоанн Васильевич хөрмәтенә...

* * *

Ярты көнен диярлек таш манараның күзәтү мәйданчыгында үткәргән Кол Шәриф хан сараенда булмаса да, анда ни барын, ни эшләнүен күреп, белеп торды. Иртәдән бирле сарай янында саргаскәрләр таптанды, каланың төрле ягыннан чапкыннар килде, берсе керде, икенчесе чыкты. Урыс гаскәренә көчле ярдәм киләсеннән инде күптән хәбәрдар Кол Шәриф моның шулай булырга тиешлеген дә белә, диван әһелләренә ни киңәш бирергә, изге Казанны саклап, яклап калу өчен ни кылырга кирәклеген уйлап баш вата иде.

Күрмәде түгел, күрде, урыс станында ни майтарып ятуларын да күзәтте. Алар да чарасыз иде, күрәсең. Ничә көн дәвам иткән камау урыска бер карыш та алга барырга мөмкинлек бирмәде. Ничек торган булсалар, һанүз шул көенчә тора бирәләр. Көчләр тигез. Көчләр нисбәте казанлыларның калын, ныклы диварлары, урысның сан ягыннан күпкә артык булуы белән тигезләшә, бер якка да өстен чыгарга ирек бирми. «Ниндидер гайре табигый, сугыш һөнәрендә моңарчы күрелмәгән бер-бер яңа алым, хәйлә кулланмасак, бу ялыктыргыч камау чиксез дәвам итәчәк. Диванда шуны әйтергә кирәк булыр»,— дип уйлап куйды Кол Шәриф һәм зурайткыч пыялалардан ясалган ерактан күрсәтүче көпшәсен урыс станына төбәде.

Кенәз чатыры янына көчле сак куелган. Воеводалар бер керә, бер чыга. Инде озак утыралар. Ниндидер сәер киемле кешеләрне алып кереп киттеләр. Дөньялыкта күп нәрсәне танып белгән Кол Шәриф бу адәмнәрнең мәгърип

ягыннан килгәнлеген дә, урысларга киңәшче сыйфатында чакырылуларын да тәгаенләми калмады, әлбәттә. «Болар безгә бер-бер хөсетлек, таныш түгел бер-бер хәйлә әзерли. Чит мәмләкәтләрдән үк укымышлы затларны юкка гына китермәсләр»,— дип уйлап куярга өлгерде. «Монысын белеп тору зыян итмәс. Дошманның мәкерен алдан сизенү хәйләләрен сүтәргә ярдәм итәрдер... Сарайдан кайткач, румнар һәм мәгърип илләренең сугыш тарихларына янә күз йөртеп чыгарга кирәк булырдыр. Нинди дә булса күзгә чалынмаган хәйлә-мәкерләре тасвирланмаганмы...»

Хан сараенда иртәдән бирле дәвам иткән ыгы-зыгы сүрелде, төшкә кадәр барлык гаскәрдән мәгълүмат тупланды, биек манарадагы хәбәрчеләр әләм болгап Япанча би күзәтчеләре белән сөйләшеп алдылар. Хәл кискенләште. Урыс яңа көч белән Казанга ташланачак. Хәер, моны саргаскәрләр һәм яшь хан Ядегәр генә түгел, кальгадагы бар кеше дә яхшы аңлый иде инде.

Ядегәр хан алтын тәхетендә җәйләп утырды һәм бизәкле күн мендәрләр салынган урындыкларга ике яклап тезелешкән саргаскәрләргә, диван әһелләренә сораулы караш ташлады. Аның тау халыкларыныкыча текә ак маңгае җыерылган, зур кара күзләре гаять тәшвишле хәбәр әйтергә җыенган кешеләрдәгечә борчулы елтырый, куллары гасабиланып тәхет читендәге култыксаларны сыйпый иде.

Кол Шәриф шунысына да игътибар итте: иң авыр, четерекле хәлләрдә дә тынычлыгын, сабырлыгын югалтмый, горур кыяфәтен саклый белгән яшь хан бүген үз-үзен тыя алмый, сүзен ничек башларга белми изалана иде кебек. Ниһаять, ул җанын кыйнаган уйларының очына чыкты булса кирәк, сынына элеккеге мәгърур турылыгы, төзлеге кайтты, игътибар таләп итеп, уч төбе белән тәхет култыксасына сугып алгач, калын, көр тавышы белән эндәште:

— Мөхтәрәм диван әһелләре, карачылар, саргаскәрләр...

Бөек һәм изге Казанның ышанычлылары! Язмышыбыз, киләчәгебез хәл ителгән, һәр сәгате, һәр дәкыйкасе[1] елга тиң шушы кара көннәрдә мәшәкатегездән аерып, барчагызны бергә киңәшкә чакыруымның аерым сере бар.— Кинәт аның тавышы калтырап китте, күзләреннән ачулы очкын чәчрәде.— Исемнәрен әйтмим, алдан ук сезнең нәфрәткә дучар итәсем килми... Үзара киңәшепме, әллә үзбаш кына уйлапмы — анысы миңа караңгы — хыянәтчел тәкъдим белән керделәр...

Диван әһелләре бер-берсенә карашып алды, тавышсыз гына пышылдаштылар:

— Нинди хыянәт?

— Кемнәр... Нәрсә бу?..

— Ашыкма, тыңлыйк! Ишетербез... Аттан ала да туа, кола да туа,— дип куйды арадан берсе пышылдашуны бүлеп. Чапкын морза исә сикереп торды:

— Олуг хан галиҗәнабләре! Әйдәгез, табышмаксыз гына сөйләшик. Хыянәткә җәза бирерлек көчебез, колак салырлык фикере булса, уртаклашырлык ихтыярыбыз бар дип беләм. Без изге Казанның бөек халкы алдында җавап тотабыз...

— Алайса тыңлагыз. Уртага салып сөйләшик. Ул тәкъдимдә күпме мәгънә, күпме акыл орлыгы бардыр, үзегез хәл итәрсез.— Ядегәр хан урыныннан торды һәм күн читек табаннарын шыгырдата-шыгырдата калын келәм өстендә йөренә башлады.— Беләсез булыр, кальгадан Кабан күле ярына чыгучы яшерен юл бар. Җир асты юлы... Япанча бинең хәбәр итүенә караганда, ул юл чыккан җирдә, Кабан буенда дошман чирүе юк. Алар кальга төбендә. Тәкъдим мондый: урыс яңа көч килүен бәйрәм итә. Сизгерлеге ташка үлчим. Тәнен бөтен гаскәр белән Казанны ташлап чыксак, алар иртәгәсен буш шәһәргә һөҗүм итәчәк... Ә без караңгылык пәрдәсенә төренеп еракка — Арча урманнарына кереп югалырга өлгерербез...

Гөмбәзләнеп менгән биек түшәм астында чебен очса да ишетелерлек авыр тынлык урнашты.

---

[1]Дәкыйка — минут (гарәпчә)

Беренче булып тагын Чапкын морза телгә килде:

— Гөнаһсыз сабыйларны, хәлсез карт-корыларны залим дошман туена калдырыпмы?! Аларның гомере бәрабәренә ирек алыйкмы?— Аның куе, калын тавышында тимер чыңы яңгырый башлады, биек гөмбәз астында кайтаваз булып кабатланды:— Сабыйлар бәрабәренәме?..

Әле генә шомлы тынлыкка чумган ындыр табагыдай олуг бүлмә умарта күчедәй гөжли башлады.

— Качып киткән ил булмас, куркак егет ир булмас...

— Ажгырган айгырны өердә сына, мин-мин дигән егетне өендә сына. Өебездә сынатырбызмы?..

— Аягы яман түрне болгар, авызы яман илне болгар.

— Үчен ирләрдән ала алмаган дошман Казанда бер җан иясен исән калдырырмы?.. Ипи тотып ант итәм, барысын кылычтан үткәрәчәк.

— Халыкны чыгара алмыйбыз. Ни генә кылсак та кулыбыздан килми...

— Тавыш! Туктагыз! Сабырлык!— дип кул чапты Ядегәр хан. — Бу тәкъдим белән керүчеләрнең гөнаһы үз намусларында калсын. Шулай да мин аны әйтеп бетерергә тиеш табам... Янәсе, мондый юл бар: кальганы ташлап чыккан гаскәр Япанча би атлыларына кушылып, бер йодрык белән урыска китереп бәрә...

— Һы! Кальгага кергән, кирмән ныгытмаларына поскан урыска бәреп кара аннан,— дип көлде кемдер.— Йөз илле мең дошманга без ике селтәнүгә дә житмибез...

— Җәннәттән чыгып тәмугка кермиләр,— дип сәерсенеп җилкәсен җыерды икенчесе.— Кальгада чагында без — көч! Яланга чыксак, берәмберәм тотып сыту чүпкә дә тормый. Монысы көн кебек ачык ич.

Саргаскәрләрнең аптырау катыш ачулы сүзләрен, тәкъдимнең ничек тәэсир итүен күреп канәгатьләнгән Ядегәр хан Кол Шәрифкә борылды.

— Изге Кол Шәриф хәзрәт! Диван әһелләренең синең фикерне дә ишетәсе килә булыр. Тыңлап багыйк!

Әле генә бер-берсен бүлдерә-бүлдерә шаулашкан морзалар, мәмләкәтнең акыл иясе исеме чыгуга, бердән тыелып калдылар, яңадан урыннарына утырышып, Кол Шәрифкә текәлделәр. Башына ак чалма чорнаган, килеш-килбәтеннән олпатлык, киң җилкәле таза гәүдәсеннән көч-куәт, куе калын кашлары астындагы күзләреннән акыл нуры бөркелгән бу кеше, әйтерсең, бөтен шик-шөбһәләрне бер үзе хәл итә ала иде.

— Игътибарыгызга тәшәккер әйтәм,— дип башлады Кол Шәриф ашыкмый гына.— Аңлавымча, диван дөрес юлда... Тәкъдим кертүчеләр уйлап әйткәнме, уйлап җиткермичәме — анысы миңа караңгы. Әмма бер нәрсәне ачык тоемлыйм, бу сүзләр астында яшерен хыянәт тоемлана, астыртын мәкер бар сыман... Яуга каршы торудагы иң зур өстенлегебез — таш ныгытмага ия булу. Аны дошманга калдырып китү — шәһәрне урыска бушлай бирү дигән сүз. Беләм, кайберәүләр солых төзергә дә каршы түгелдер. Әмма алар бер нәрсәне оныта — Иван бу юлы солых төзүгә бармас. Теләсә дә бармаячак. Яшь хөкемдарның артында митрополит Макарий, аның иярченнәре тора. Алар ничә ел инде Иванны Казанга каршы котыртты, фәтва бирде, дөньялыкта ук изге пәйгамбәргә тиң зат булырсың, дип күңеленә вәсвәсә салды. Шуның өстенә кенәзнең хөсетлеге, явызлыгы, мәкере җитәрлек, ул көч туплап килгән. Дөнья мәмләкәтләренең Казанга согынуы, сәүдә юлларының Казанга илтүе аны көнләштерә, күзен кыздыра, көнчелеге җанын яндыра. Шушы байлык тарта аны. Ач бүредән сарык мәрхәмәт көтә аламы?! Белегез! Урыс чирүе солых түгел, кан даулап килгән...

Кол Шәриф диван әһелләрен берәм-берәм күздән кичерде. Төпле, белемле затлар. Ни әйтергә теләвен ярты сүздән аңлаучылар. Аларга түгел, күбрәк Ядегәр ханга сөйләве хәзрәтнең. Шәҗәрәсе аксөяк хөкемдарлар нәселенә барып тоташкан, гыйлемле, дәүләт идарәсендә, сугыш эшендә мәгълүматлы булса да, Казан тәхетендә әлегә тәҗрибә, салкын канлылык җитеп бетмәгән яшь, кызу егет утыра. Дөрес, диван әһелләре, саргаскәрләр ашыгып-кабаланып карар-фәрман чыгарырга ирек бирмәс. Әмма да ләкин

олуг хан исеменнән халыкка әйтеләсе сүзгә хөкемдарның үзенең инануы, аны үз бәгырендә яралган татлы вә затлы кәлимә итеп кабул итүе кирәк. Шуңа тырыша Кол Шәриф.

— Бөтен мәмләкәт хакимнәренең күзе бездә — Казанда, — дип дәвам итте ул. — Сер бирмәскә, сәясәтләрендә сиздермәскә тырышып авызларына су капсалар да, ләх тә, Ливония вә Литва да, ерактагы швед та, мәгърибтәге башка дәүләтләр дә безнең җиңүне, урысның хурлыклы качуын тели. Безне сөймиләр. Диннәре башка. Әмма теләктәшлекләре безнең якта. Ни өченме? Сәбәбе, сере бик гади. Әгәренки нәфесе шашкан Иван Казанны буйсындыра калса, аның мин-минлеге котырачак. Бусы шиксез. Нәфесе Казан мәмләкәте белән генә чикләнмичә, канлы кулы алар ягына сузылачак. Урысның золымын үзенә тартып торган Казанның җимерелүе алар өчен һәлакәт үк булмаса да, афәткә тиң. Моны яхшы беләләр. Ярдәм итә алмыйлар, ә көтәләр. Алар әле бәлки Казан малын имеп симергән Мәскәү кенәзенә каршы торыр көч табарлар. Ә Казанга сыенып көн күргән, мәҗүсилектән чыгып та бетмәгән, курчакка табынучы ар, чирмеш, мукшы, башкорт, чуаш нишләр?! Бәгъзеләре сахраларга качар, бәгъзеләре урыстан мәрхәмәт сорап бил бөгәр, ярлыкагыл диеп хрәстиянгә баш орыр. Татарга үч итеп, Иван аларны сыендырыр, ташлама ясар, ясагын ким куяр. Әмма азга гына. Бераз ияләштерүгә, аларны да боргычлап сыга башлар.

Башка халыкны савып яшәргә күнеккән кавемнең рухы сына, табигате ялкаулана, мие сыеклана да үзен гали, бөек, асыл кавем дип исәңгери. Тирәяктагы чынбарлыкны аермас хәлгә килә, ялган бөеклегеннән исереп яши. Андый халык сихере чыкмаган бер мәхлук кеби, аны айныту, дөньяга аек карарга өйрәтү кыен, аһ-һай, кыендыр.

Инде янә шунысын да фараз итик, Казан кеби көчле, шанлы, тамыры нык мәмләкәтне тар-мар китергән көч ургылып Идел буйлап китәр, Хазар, Азак, Кара диңгез ярларына таралыр. Ары таба — көн чыгышына таба тамыры нык мәмләкәтләр юк. Җәйрәп ятучы сахралар, урман-күлләр, чәчәкле далалар бөеклектән исергән кавемнең бушлай табылган биләмәсенә әйләнер, типкелектән килгән мул ризыктан бу кавем котырып үрчер... Хәзергә без сан ягыннан бер чама. Тора-бара икеләтә, соңра өчләтә, янә дүртләтә кимербез. Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара уңлата... Шулай дәвам итәр. Иң яхшы угыл-кызларыбыз коллыктан котылу өчен хрәстиян кавеменә күчәр... Без шушыны телибезме?!

Кол Шәрифнең тавышы көчәйгәннән-көчәя, ул үзе инанган, танып-белгән, караңгы төннәрдә ялгызы калып газапланган уйларын, шикшөбһәләрен барысын да бәйнә-бәйнә сөйләргә тели иде. Җан ачысы белән бәргәләнеп уйлану, кычкырып фикер йөртү иде бу.

— Мин борынгы бабаларыбыз — болгар, сувар, кыпчакларның тарихын өйрәндем, галәм агышында дәһшәтле гарасатларның кабатланып торуын беләм. Без шундый чорга кердек. Йолдызлар шулай күрсәтә. Изге дисбе шуны раслый. Ялгышаммы, дөрес сизенәмме — белмим. Әмма шунысы хак: халкыбыз киләчәктә дә хөр, азат калсын өчен безгә түземлек, түземлек һәм тагын бер кәррә түземлек кирәк. Шунда гына җиңүгә ирешә алачакбыз. Бүген без урыстан көчсезрәк. Кырым, Әстерхан, Нугай берләшә алмады. Хакыйкатькә күз йоммыйк. Җиңсәк, бары тик түземлек, сабырлык, Казаныбызны бирмичә саклау бәрабәренә генә җиңүгә ирешә алачакбыз. — Ул бераз тын торды, нәрсәнедер әйтергәме-әйтмәскәме икеләнгәндәй талпынып алды да Ядегәр ханга карап тагын дәвам итте: — Инде боларын да әйтеп бетерим... Тар күңеллелек, куркаклык күрсәтеп дошманга бирелсәк, халыкка... бүгенгесенә генә түгел, киләчәгенә хыянәт иткән булырбыз. Йолдызлар белгертә: әгәр җиңелсәк, сугыш барган һәр көн ун ел коллык булып кире кайтачак. Бер көне — ун ел коллык! Аның ни китерәсен уйлыйк. Хөр күңелле, ирektә яшәргә өйрәнгән казанлыларның рухы чыдармы, киләчәктә сарык хәленә төшмәсме?..

Юлыбыз бер генә — соңгы сулышка, соңгы тамчы кангача көрәш! Көрәш! Коллыкта яшәгәнче хөр яугир булып үлүең мең артык!

— Мең артык! Мең артык!—дип кабатлады диван әһелләре. Алар тылсымга бирелгәндәй Кол Шәрифнең һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар, ул әйткән һәр гыйбарәне күңелләренә беркетеп баралар иде.

— Тагын шунысы да мәгълүм булсын,—дип дәвам итте Кол Шәриф,—Казанда хыянәтчеләр калмады. Бүген соңгысы дошман чатырында кенәз Иван каршында тезләнде...

Хәзрәт сүзләрен әйтеп тә бетермәде, дистәләрчә бугаздан берьюлы нәфрәтле сорау ургылды:

— Кем? Кем ул?!

— Хыянәтченең исемен атап телемне пычратасым килми... Арагызда кем юк? Карагыз!

Диван әһелләре сарай итагатен онытып, гаҗәпсенеп бер-берсенә караштылар.

— Камай морза!.. Әйттем исә кайттым, ул түгелдер ич,—дип шикләнеп кенә сорап куйды кемдер.

Кол Шәриф хәзрәт аның дөрес юлда икәнлеген раслап, керфек кагып куйды.

Сарайда бер көн эчендә инде ничәнче тапкыр авыр тынлык урнашты. Тәхет янында басып торган Ядегәр ханның кинәт йөзе агарды, ирен кырые тартышып куйды, Чапкынга борылды.

— Камай?! Камай!—дип кабатлап торды да кискен итеп сорады. —Җир асты юлын ул белә идеме?

Хыянәтнең бәһасын, кальгага янаган куркынычның дәһшәтен әле генә аңлап алган саргаскәрләр җавап көтеп, Чапкын морзага текәлделәр.

Ул исә, дистәләрчә карашның авырлыгын күтәрә алмагандай, башын аска иде, маңгаен тотып уйга чумды, авыз эченнән нәрсәдер сөйләнеп алды һәм кинәт күзен киң ачып Кол Шәрифкә, Ядегәр ханга карады.

— Юк! Ул Камайга мәгълүм түгел иде.

Барысы да җиңел сулап куйдылар.

— Әгәр сез әйтмәгән булсагыз, мин әйтмәдем,—дип өстәде Чапкын морза.

Диван әһелләре тагын бер-берсенә караштылар. Чебен очарлык тынлыкта тагын Чапкынның сүзләре яңгырады.

— Телем йозакта калды... Көтмәгәндә чыгып дошманны таркатыр идек, дип ялан-ялан сөйләнүендә әллә нинди ясалмалык, гайре табигыйлек сизеп килдем. Ялгышмаганмын... Йа тәңрем, телемне тешләргә сабырлык биргәнсең, мең шөкер сиңа! Әмма шунысын да әйтми булдыра алмыйм, ул нидер сизенә иде кебек. Тәгаен белми, әмма сизенә иде...

Диван мәҗлесе тәмамланып кешеләр таралыша башлагач, Ядегәр хан сиздермичә генә Кол Шәриф белән Чапкын морзага ым какты. Бу аның «Калып торыгыз»,—дигән аңлата иде.

Тәрәзә янына килеп бастылар. Кулларына Казан мәмләкәтенең язмышын хәл итү тапшырылган өч бөек шәхес бер-берсен сүзсез дә аңлыйлар, иңнәренә өелгән җаваплылыкның күтәреп булгысыз авырлыгын бик яхшы беләләр иде. Ядегәр ханның тавышы карлыгып чыкты:

— Хәзинә урнаштырылып беттеме?

Чапкын би җавап бирде:

— Кичә соңгы мичкәне төшердек. Казна буш!

Кол Шәриф исә сүзсез генә баш иде һәм бармаклары белән чигәсен уалап, арыган тавыш белән әйтеп куйды:

— Мәмләкәткә азатлык килмичә, Кабан серләрен беркемгә дә, беркайчан да ачмаячак! Хәзинә—Казанныкы! Аятелкөрси укып үзем юлга тәгаенләдем, фатиха бирдем. Фәрештәләр шаһит, күңелебездә, намусыбызда бер кәррә хөсетлек, нәфес вә комсызлык юк. Алла ярдәм итсен! Амин!

Өч хөкемдар изге сүзне кабатлап битләрен сыпырды.

Хушлашканда Ядегәр хан Чапкын морзага әмерен җиткерде:

— Хәзер инде ул юлның булмавы хәерлерәк. Ышанычлыларың белән чарасын күр! Казаннан чыксак, йә җиңүче булып, йә мәет булып кына чыгасы. Башка юл юк...

— Әмерең үтәлер, галиҗәнаб хан! Күңелең тыныч булсын!

Көзлеккә кереп баручы, язмышы кыл өстендәге шәһәр сугыш заманы кагыйдәләренә буйсынып яшәвен дәвам итте. Тагын бер көн узды. Сурәнләнә башлаган кояш Ослан тавы ягына тәгәрәп, кургашындай авыр болытларны кан төсенә манчуга шәһәр урамнарына, мәйданнарга сөрәнчеләр чыкты. Сорнай кычкырта-кычкырта, казанлылар күңелендә өмет уятып, шик-шөбһәләрне таратып оран салдылар:

— Газиз кардәшләр, илдәшләр! Явыз дошманга каршы хәлиткеч яуга күтәрелик! Һәр өй кальга-кирмәнгә, һәр ишегалды ныгытмага әйләнсен! Кулына корал тотардай ир заты мәмләкәткә куркыныч янаганда көтеп ятырмы?! Барыгыз да коралга! Яуга! Изге газаватка!

Шәһәр төн пәрдәсен ябынды. Әмма ул йокламый, ялны белми. Мәйданнарда, остаханәләрдә учаклар дөрли. Тимерчелек һөнәреннән азмы-күпме хәбәре булган һәр ир заты сөңге очы чүки, ук ясый, кылыч коя. Хуҗалыктагы һәр тимер кисәге исәптә, һәр бакыр йә җиз гөрзи-чукмарга әверелә.

Кальга тышында һәр дүрт тарафта шомлы ялкын уйный. Яңа көч алган, камау башланганнан бирле беренче кат лыкынганчы ашаган тук дошман гаскәре бәйрәм итә, кальганың биек диварларына ташланып үҗәт татарны изеп-сытар мизгелләрнең якынаюын көтеп исерткеч ләззәттә йөзә.

Сызылып таң атты. Тәрәзә капкачындагы челтәр бизәкләр аша кояш нурлары Сәетнең күзенә төште, аны уятырга теләгәндәй, керфекләрендә уйнаклады.

Башы чуенга әйләнгән, газаплы уйларыннан таң алдыннан гына черем итеп алган Сәетнең торасы килми, дәһшәтле чынбарлыкны куасы, яңадан тыныч көннәргә кайтасы иде бит... Юрганыңны ябын да онытыл иде. Дошман явы да, күңелне кыйнаган, үртәгән шик-шөбһәләр дә бетсен, таралсын иде. Их, ничекләр матур, мәгънәле яшиләр иде бит! Улы Җәгъфәрне бер чибәргә өйләндереп, Галиясен батыр угланга кияүгә биреп, ил агасы булып кына йөрер чакларда...

Галиясе искә төшүгә, ятагыннан сикереп торуын сизми дә калды. «Ул балага ничек ярдәм итәргә соң?! Нинди могҗизалар табарга?!»

Җилкәсенә тунын салып, аш бүлмәсенә чыкты. Гөлйөзем анда иде инде. Хатынының суырылып калган йөзенә, күз төпләрендәге шәмәхә күләгәләргә Сәет беренче тапкыр күргәндәгедәй сәерсенеп карап куйды. Сыек яшел төстәге яулык бөркәнгән Гөлйөзем бүген икенче төрле, башкача, яңача күренә, гадәттәге Гөлйөзем түгел кебек иде. Яулык аның муенын, маңгаен күренмәслек итеп каплаган, ияк астыннан тыгыз итеп бәйләп куйган. Моны күрсә дә Сәет аның сәбәбен сорамады, тел очына инде атна буе борчыган соаль килде:

— Ничек? Хәле җиңеләймиме?

Гөлйөзем авыр сулап баш селкеде.

— Ничекләр җиңеләйсен!?. Су урынына агу эчергәч...

Сәетнең җилкәләре бөрешеп, тараеп калды, гәүдәсе сыгылып төште сыман.

— Бигрәкләр дә нәзберек зат шул! Нишләр генә кылыйк?!.

Һөҗүм башланган көннән ир белән хатын арасына кара күләгә ятты. Дөрес, Гөлйөзем теле белән бернәрсә дә әйтми, элеккечә кайгыртучан, ягымлы ана, тугрылыклы хатын булып кала белде. Әмма күзләр!.. Күзләр башка... Алар хисләрне яшерә алмый. Озын керфекләр артына качкан җан көзгесе барын да әйтә, сөйли, җавап сорый. Сәеттән тәвәккәллек, ирлек таләп итә иде. Элек аның күзләренә багып, аларны сихри күлгә охшатып, газизенең җан җылысында коенырга яраткан Сәет, хәзер аңа туры карый алмый. Әрнүне, газапны, юк, юк, аларны гына түгел, әнә шул таләпне күрәсе килми аның.

Чишмә шартлатылып, өйдә тамак чылатырлык та чиста су калмагач, Гөлйөзем тагын үз эченә бикләнде. Аның ни өчен алай итүен яхшы, үтә яхшы аңлый иде Сәет. Әмма үзе белән берни дә эшли алмый. Идел төбеннән балыкчы карт тартып чыгаргач биргән анты исенә төшә: гомеремдә кулыма

корал алмам, кеше җанын кыймам дигән иде. Гомере буе антына тугрылыклы калды лабаса!

Хатынына күтәрелеп карамыйча Галия бүлмәсенә кереп китте. Кыз уттай яна. Иреннәре чабырып, ярганланып беткән. Юрган өстенә чыккан нәзек куллары тагын да нечкәреп калган, юка тиресе аша кан тамырлары зәңгәрләнеп күренә. Йөзенә, тәненә хаста сарылыгы иңгән. Сәет үзен белештермичә җан ачысы белән иңрәп эндәште:

— И кызым, кы-з-ы-ы-ым!..

Ата кеше бармаклары аша аңа көчен, сәламәтлеген бирергә теләгәндәй кулын кызның маңгаена куеп торды. Юк! Булмый! Кешегә андый көч, сәләт бирелмәгән.

Менә Галиянең күзләре ачылды, атасын танып, елмаерга итте. Әмма ул елмаю түгел, ә газаплы, интегүле бер ымга охшаган иде.

— Су, су-у...—диде кыз кипшергән иреннәрен ялап.

— Хәзер, хәзер, кызым. Әниең керә.—Ишеккә борылып эндәште:— Сиңа әйтәм, Галия уянды. Су сорый. Су керт!... — Әмма үзе өйдә бер йотым чиста су булмаганны бик яхшы белә иде. Яңгыры да яумый бит ичмасам!

Коточкыч ул көн искә төшкән саен бик күпләр дертләп, саташып уяна. Сәет тә шулай. Сугышның тынып, камау һөҗүменең туктабрак торган бер мәле иде ул. Кинәт аяз көнне күк күкрәде. Таһир мунчасы ягында берьюлы меңнәрчә яшен ташы атылды, күккә ут ургылды, диварның бер өлеше ялкынга уралып болытларга менеп китте. Таш, тузан өермәсе купты. Күз ачып йомганчы булган бу мәхшәрдән кешеләр телсез калды, шартлау дулкыны аларны аяктан бәреп екты. Тагын берничә мизгелдән күктән олы-олы ташлар, бүрәнәләр, балчык кантарлары ишелеп төште. Күпләр аның астында калып әҗәлен тапты.

Күп тә үтмәде, ишелгән коймa ягында дошман гаскәренең канны бозга әйләндерерлек дәһшәтле авазы яңгырады, кырны тутырып ачудан йөзләре кыйшайган меңнәрчә сугышчылар агыла иде. Әгәр дивар өстендәге татар гаскәре, каладагы барлык ир-ат тиз арада һушына килмәсә, моның ничек бетәсен әйтү кыен иде. Ләкин казанлылар тиз айныды. Убылып күккә очкан җимерек дивар аша беренче урыс сугышчылары күренүгә, мәхшәр онытылды, җирдә иң газиз нәрсәсен—хөрлеген, туган җирен яклаган пәһлеваннар ташкыны күкрәге белән ачыклыкны каплады. Урыс чигенде. Ашыгыч төстә диварны ямадылар, урыс уклары астында бүрәнәләрдән яңа ныгытма корылды, ике арага таш, балчык, ком тутырылды. Барысы да яңадан үз урынына кайтты. Бары тик камау газапларын авырлыксыз, сусауны белмичә күтәреп барырга ярдәм иткән бердәнбер чишмә генә күмелеп җир астында калды.

Галиянең хасталыгы шуннан. Ничә көн, ничә төн казып шәһәр кешеләре сасы сулы бер генә чыганак таба алдылар. Кальгада сусызлык башланды, яман су эчүдән чир таралды. Су түгел, эрен иде, үлек су иде ул.

«Юк! Алга таба болай яшәп булмый. Берни кылмыйча, ни килгәнен көтеп яту, күз алдында газиз кызың, җаныңнан өзелеп төшкән, тәнендә синең каның аккан баланы үлемгә дучар итү үзе үк антыңа хыянәт түгелме соң? — Сәет авыру янында үз-үзен белештермичә сөйләнде дә сөйләнде.— Балыкчы карт, син, игелек күрсәтеп миңа яңадан тормыш биргән изге карт, син нишләр идең? Яуда йөреп балаларыңнан, хәләлеңнән мәхрүм калган кеше, син, ни киңәш итәр идең?!

Яуда катнашу гөнаһ, беләм. Илеңә дошман килгәндә катнашмау—тагын гөнаһ. Әллә соң шул гөнаһлар өчен җавапны адәм баласыннан дөньялыкта ук алалармы? Әҗере авыр, ай-һай, авыр икән!..»

Кылт итеп исенә Кол Шәриф хәзрәтләре төште. Ул ни әйтер иде икән?! «Мөселманлык шәфкатьле һәм мәрхәмәтле, бөек һәм бердәнбер Аллага табыну ысулы гына түгел, ялгышма, ул яшәү рәвеше, ул тормышның үзе»,—дигән иде түгелме соң изге Кол Шәриф? Казанлылар пәйгамбәргә тиң күргән зат! Әйтче миңа, бу сугышта катнашу—антымны бозу буламы? Карындашым урыс белән кан коешу миңа лаземме? Лазем булса, аны ничек аклармын?.. Хак дин—ислам дине, дидең. Әмма хак тәгалә ялгышкан угыл-

лары урысларга да мәрхәмәт итә ич. Монысын ничек аңларга?! Бер яктан да катнашмый, ни язганын сабыр гына көтеп тору дөресрәк түгелмени соң, и изге Кол Шәриф. Җавабын син генә беләсең... Бәлки, болар миңа кылган гөнаһларым өчен җибәрелгән җәзадыр??»

Кинәт Сәетнең күз алдындагы томан таралды, әйтерсең, тәрәзә капкачларын берьюлы ачып җибәрделәр, бүлмәне нурга манчып күз камаштыргыч аклык пәйда булды. Түр башында сәетләрнең сәете Кол Шәриф хәзрәтнең яшел чапанга төренгән мәһабәт сыны басып тора иде.

— Ялгышасың, улым! Ялгышасың!—диде салмак, сабыр тавыш.

Сәетнең аяк бармакларына хәтле бөтен тәне чымырдап китте, кычкырып җибәрмәс өчен шытырдатып тешләрен кысты, кулларын кушырып тораташтай катты да калды. Күз алдында Кол Шәриф сыны балыкчы картныкына әйләнде, ул сөякчел бармакларын Сәеткә таба сузып, үпкәле, рәнҗүле тавыш белән эндәште:

— Куркак икәнеңне белгәнче, судан тартып чыгармаган булсамчы!..

— Куркак түгел! Курыкмыйм, вөҗданым кушмый,—дип илерде Сәет.— Туганнарыма кул күтәрә алмыйм. Аңла!..

— Туганнарың бәйләп көймәгә салмадымы?! Килеп янамадылармы?! Улыңның җанын кыймас иделәрме?—Балыкчы картның тавышы калтырый башлады, ак киндер күлмәкле озын сын тагын томанга төренеп югалып килә иде.

— Тукта! Тукта! Китмә! Аңлат, нишлим,—дип пышылдады Сәет балыкчыга омтылып. Ләкин гәүдәсе тыңламады, аяклары буйсынмады.—Әйт, зинһар, ни кылыйм? Әллә үземә кул салыйммы инде...

Томан эченнән зәгыйфьләнгәннән зәгыйфьләнә баручы өн килеп җитте:

— Күңелеңә кем якынрак, шулар ягына бас! Башкасын белмим. Нинарсә хакына Казанга килгәнеңне онытма. Оны-ы-ыт-ма-а!..

Икенче караштa балыкчы карт урынында яңадан Кол Шәриф иде инде. Ул иреннәрен кысып, сүзсез генә башын чайкады. Сәетнең уйларын хуплагандай елмайды да ашыкмый гына әйтте:

— Гаделлек ягында булсаң, беркайчан да ялгышмассың. Гаделлек кем ягында? Уйла! Миннән фатиха! Фатиха-а, улым!

Сәет күзләрен уды, авырта башлаганчы почмакка карап торды, әмма анда беркем дә, томан да, ак пәрдә дә юк иде инде. Кинәт җиңел сулап куйды, бөтен гәүдәсендә, аяк-кулларында сәер бер җиңеллек барлыкка килде, үзен уңҗиде яшьлек егетләрчә җитез, көчле, елгыр итеп тоя башлаган иде ул. Иреннәре бертуктаусыз «Изге Кол Шәрифтән, балыкчы карттан фатиха! Алар мине яуга өнди, гаделлек ягына басарга чакыра»,—дип пышылдый иде. Атналар буе йөзеннән китмәгән караңгылык, кайгы ни эшләсен белгән батыр ирләрдә генә була торган кискенлек белән алышынды, күзенә элеккеге нуры кайтты.

Шул мизгелдә урамда атлылар чабышканы ишетелде. Тояк тавышлары йөзләрчә думбакка бәргән ешлык белән тар урамнарда, тыкрыкларда бәргәләнде.

— Яу килә! Яу! Батыр ирләр, куркусыз егетләр! Яу килә. Барыгыз да коралга! Изге калабызга афәт яный...

Утыз дүрт яшендә хәлсез картка әйләнә башлаган һәм кинәт, күз алдында яңадан уңҗиде яшьлек халәтенә кайткан Сәет каударланып чолганга ташланды.

— Тизрәк, тизрәк! Моңарчы кул кушырып ятканның үчен бүген чыгарырга! Бүген ак күнем, пакь күнем. Фәрештәләр дөрес юл күрсәтә.

Биленә хәнҗәр, кылыч тагып чыкканда чак кына Гөлйөзем белән маңгайга-маңгай бәрелешмәделәр. Хәер, бу Гөлйөзем түгел, ә аңа бер тамчы судай охшаган чибәр яугир егет иде. «Чү! Күземә күренәме соң әллә?» Сәет гаҗәпләнүеннән чак кына кычкырып җибәрмәде.

— Син! Гөлйөзем! Нишлисең?

Гөлйөзем озын толымнарын кисеп ташлаган, өстенә Җәгъфәрнең киемнәрен кигән, биленә кыска хәнҗәр таккан иде. Ул еш-еш сулап Сәеткә текәлде һәм кинәт балаларча ачылып, иренең кочагына ташланды.

— Ак канатым!

Ул башка бер сүз дә әйтә алмады, Сәетнең күкрәгенә капланды да тынды. Җилкәләренең калтырап-калтырап куюыннан аның тыела алмыйча, җан ачысын чыгарып тавышсыз гына елаганын Сәет күптән аңлап алган иде инде. Үзенең дә күзләренә яшь тыгылды, аркасыннан назлап сөясе, битеннән, маңгаеннан, кайнар иреннәреннән шашып үбәсе килде. Әмма тыелып калды, кысып кочаклады да хатынны читкә этәрде.

— Гөлйөзем! Син йөрмә! Җәгъфәр белән без китик! Шулай яхшырак булыр...

Кинәт Гөлйөземнең йөзенә кискен кырыслык чыкты, кул аркасы белән яшьләрен сөртә-сөртә өздереп әйтте:

— Юк, Сәет! Мин өйдә ята алмыйм. Тупчыларга ярдәмчеләр җитми, ди. Икесенең берсе йә яралы, йә үле. Мин анда барам!

Сәетнең сулышы кысылды, ни әйтергә белми аптырады.

— Ә Галия?—дип куйды ул кара коелып.

— Мин күрше карчыгы белән сөйләштем. Ул кереп утырыр... Борчылма...

Сәет Гөлйөземнең үҗәт үсмер егетләрнекенә охшап калган йөзенә карап аптырау катыш соклану белән елмайды да, сүзеннән кире кайтмаячагын аңлап, кул селтәде.

— Аллага тапшырдык!..

Урамга чыгуга, аларны кораллы халык агымы бөтереп алып китте. Аяк астында җирне тоймый йөгергән Сәет сугышчылар арасында ирләрчә киенгән кызларны, яшь хатыннарны абайлап өлгерде. Ул күзләре белән Гөлйөземне эзләде, аның белән хушлашырга, дәртләндереп кул изәргә теләгән иде. Әмма таба алмады. Күрәсең, алар кала туплары куелган манараларга таба чапканнар иде инде. Бераздан аны атлылар төркеме куып җитте. Шактый сирәгәя төшкән нөгәрләр алаеның башында Алмачуарны иярләгән Җәгъфәр сызгырып узды. Сәетнең бугазына кайнар төер тыгылды, күзе яшьләнде. Ләкин ул моны тоймый, ат өстендә коеп куйгандай утыручы улына сокланып елмая, үз-үзен белештермичә ярсып кычкыра иде:

— Алга, туганнар, алга!

* * *

Василий ябыкты, яңаклары эчкә батты. Суырылып калган йөзендә ачулы ут булып зәңгәр күзләре яна. Иван сәүдәгәр сүзенә алданып, аның колына әверелеп ут эчендә калуына эче пошты, кат-кат үзен тиргәде, әшәке сүзләр белән сүкте.

Камау озакка сузылды. Эссе җәйдә юлга чыккан гаскәргә кием җитми. Көндезләрен әле түзәрлек, төннәрен исә кырау төшә, тиргә, суга манчылган киемнәре иртән торганда шыкранлап ката.

Учак өстендә күшеккән кулларын җылытып утырган җиреннән Василий тагын эчтән генә сүгенеп куйды:

— Алырсың бу Казанны! Тот капчыгыңны, әзерләп куйганнар ди. Чишмәләрен шартлаттык, убылган дивардан шәһәргә күпме гаскәр ургылды. Шунда да ныгып кала алмадылар. Татарлар барысын бергә кысрыклап, изеп чыгарды.

Уйга бирелеп, җиңенең көя башлавын да сизмәгән икән. Борынына ягылган постауның әчкелтем исе бәрелгәч кенә, кулларын ялкын өстеннән тартып алды, җиргә суккалап, утны сүндерергә керешле. Тагын бер кат эче итеп сүгенеп куйды. Аның үтереп йоклыйсы килә, Санька өендәге мамык түшәкләр җәелгән ятакны күз алдына китерә. Әгәр анда барып эләксә, бернигә карамыйча өч көн, өч төн рәттән йоклар иде, колак төбендә туптан атсалар да тормас иде...

Үзе дә сизми: энесенә булган ачу, нәфрәт акрынлап кызгану хисе белән алышына бара. Чибәр Гөлйөзем, зифа сынлы бүз углан Җәгъфәрне күз алдына китерә дә тыела алмыйча сыкрый башлый. Аларның да гомере ки-

селерме?! Чыннан да, Иоанн Васильевичның нәфрәте шул кадәр көчлеме, усаллыгы, җаһиллеге чиксезме?! Бөек кенәзнең өлкән воеводалардан соңгы олаучыга кадәр җиткерелгән фәрманының һәр сүзе миен көйдереп ала. «Казанда бер генә татар җаны да калмаячак. Бар йортлар, кибетләр — бар байлык сезнеке, алтын-көмеш, мал-туар сезнеке. Кемне кулга төшерсәгез — ул сезнеке. Барысы да өч көнгә сезнең ихтыярга бирелер. Яшь кызлар, киленнәр — җария, кәнизәк, угланнары кол булыр. Тездән югары һәр ир заты кылычтан үтәр... Татарның тамыры корысын! Әмерем шундый. Казан җире мәңгегә урыс җиренә әйләнер».

Онытылып утырган Василий урман ягыннан шаулап чаптырып килүче атлыларны күреп сискәнеп китте. Алар бер төркем татар сугышчысын куалап киләләр иде. Мәҗрухларның кулларын алга кушырып бәйләгәннәр, озын арканнар кылдай тартылган. Атка җитешә алмаган тоткыннар тузанлы юлга барып төшә дә капчык шикелле сөйрәлә. Егылмаганнары аларга ярдәм итә алмый, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, еш-еш сулап чаба бирәләр. Тирә-яктагы гаскәриләр аларны үртәп кычкыра, камчы белән мал куалагандай мәҗрухларның сыртларын каезлый.

«Араларында Санька юкмы? Җәгъфәр эләкмәгәнме?!» Василийның миен шундый уй яндырып узды. Йокысызлыктан шешенгән, кызарган күзләре тоткыннар арасыннан таныш чалымнар эзләде.

Кемдер кычкырып боерык бирде. Атлылар учак яныннан шаулашып уздылар да Мәскәү гаскәре ныгытмаларының алдына чыгып туктап калдылар. Каяндыр озын бүрәнәләр сөйрәтеп китерделәр. Аларны очлы башлары белән көзге яңгырдан йомшаган сыек җиргә кага башладылар. Менә бер-берсеннән өч-дүрт терсәк чамасы ара калдырып җитмешләп казык кактылар. Казыклар янына тоткыннарны алып килделәр дә йөзләре белән Казанга каратып, аларны бүрәнәләргә каерып бәйләргә тотындылар.

«Аңлашылды!— дип уйлап куйды Василий.— Урыс гаскәренә татарлардан тере калкан ясыйлар. Иоанн Васильевичның башы йомры...» Тагын шунысын да абайлап өлгерде, кирмән өстендәге татар сугышчылары да бу аңлаешсыз эштән хәйран калган иде булса кирәк. Аларның сүзсез-өнсез карашы, тавышсыз нәфрәте кемнең дә күңеленә шом салырлык куркыныч, дәһшәтле иде. Бер мизгел эчендә барысын да канлы измәгә әйләндерә алырлык дәһшәтле көч берни дә эшли алмый, газиз туганнарының хурлыклы түбәнлеккә дучар ителүен карап торырга мәҗбүр иде. Әсирләр тавышсыз гына каршылык күрсәтте. Әмма авызларыннан ник бер ләгънәт, бер үтенү, ялыну-ялвару чыксын! Алар горур иде. Карашларын яшермичә, үч һәм нәфрәт кайнаган күзләрен дошманнарына туп-туры төбәп тордылар. Казыкка каерып бәйләнгән кулларның сөякләре шыгырдады, яраларыннан тамган каннан җир өсте ал төскә манчылды.

Менә, ниһаять, соңгы мәҗрухны — егылып, арканда өстерәлгән яшь егетне сөйрәп алып килделәр. Аның хәле юк, аягында басып тора алмый иде. Өч-дүрт гаскәри казык янына бастырмакчы булып иелүгә, егет авыртуын җиңеп сикереп торды да эре адымнар белән казык янына килеп басты, кулларын артка сузды. Ул иреннәрен тешләгән, иягенә нечкә җеп булып кызыл кан ага иде. Кан тамчылары аның түшенә, күлмәк изүенә төште, күз алдында ак тукыма буй-буй бизәк белән капланды.

Үзе дә белми, нишләптер, Василий аны Җәгъфәргә охшатты. Шундый ук яшь, чибәр, тормышның чын тәмен дә татып өлгермәгән бүз углан иде ул. «Ә бит аның урынында Җәгъфәр булырга да мөмкин иде! Бәлки инде ул дөньяда юктыр. Дошман угыннан егылып җан биргәндер. Санька белән Гөлйөзем ут йотып аны көтәләрдер... Эзлиләрдер...» Василийның тәне тартышып куйды, үле Сәетне, яраланып ауган Җәгъфәрне, яшьләренә буылган Гөлйөземне күз алдына китерде. Аның күңелендә кайчандыр үзе ләгънәтләгән якыннарына бер кәррә дә дошманлык юк иде. Аның урынын кызгану, вөҗдан газабы биләп алды. Аларны ни көткәнен, Казан алына калса,ниләр буласын яхшы белгән Василий күңел тынычлыгын югалтты. Тешләрен шыгырдатып кенәз каршында җирдә ауната да, чәчләрен йолкып үрсәләнсә дә, ул аларга берничек тә ярдәм итә алмаячак. Монысы шиксез!

Шулчак күтелмәгән хәл булды. Егет күзләрен зур ачып карап торды да авызындагы канлы лайланы лач итеп каршындагы сугышчының йөзенә түкерде. Анысы бер адым артка чикте, җиңе белән битен сөртә-сөртә яралы ерткычтай үкереп кылычына ябышты.

— Ах син, хәшәрәт, татар калдыгы... Сытам!..

Ул кизәнеп сугарга өлгерми калды, янындагы воевода аны кискен җикереп туктатты:

— Артка!— һәм, сугышчының ярсуын басарга теләп булса кирәк, акрын гына өстәп куйды:— Әле вакыты җитмәгән... Ашыкма!..

Монда нинди сер, мәкер бар иде, ахрысы. Юкка гына мәҗрухларны ныгытма каршына чыгарып тезмәгәннәрдер!.. Василий шуларны уйлап куярга өлгерде.

Озак көтәргә туры килмәдә. Бер төркем воевода атларын уйнатып мәҗрухлар сафы алдыннан үтте дә чаптырып кала диварлары ягына китеп барды. Бераздан аларның кирмән өстендәге кешеләргә кычкырганы ишетелде:

— Казанлылар! Безнең сүзгә колак салыгыз! Иоанн Васильевич, әгәр аңа буйсынсагыз, шәһәр капкаларын ачсагыз, бу тоткыннарга тормыш вә ирек, ә сезгә шәфкать һәм мәрхәмәт вәгъдә итә. Дошманлыгыгызны ташлагыз! Бөек хөкемдар олы җанлы, ул барыгызны да гафу итәр...

Воеводаның калын тавышы тынып калган мәйдан өстендә кайтаваз булып яңгырады:

— Га-а-фу-у и-и-ит-тә-ә-әр...

Кинәт урыс ныгытмалары ягыннан ургылган көчле аваз воеводаның тавышын күмеп китте:

— А горур казанлылар! Алданмагыз! Нәҗес кяфер сезне тозакка төшермәкче. Явыз хрәстиян кулыннан үлгәнче, үзебезнең саф мөселман кулыннан шәһит китүебез мең артык! Урыныбыз җәннәттә буласы... А горур казанлылар! Соңгы мәрхәмәтегездән ташламагыз — атыгыз безгә ук! Үлик саф мөселман кулыннан! Урыс астында кара кол булганчы, үлүең мең артык. Алданмагыз! Алданмагыз!

Сугыш кырында үле тынлык урнашты. Кальга өстендәге гаскәриләр югалып калды, аларның бер-берсенә иелеп нидер сөйләшүе күренде. Казанлылар нәрсәдер киңәштеләр, аларның икеләнеп калганы ачык сизелә иде.

Баганаларга бәйләнгән тоткыннар тагын барысы беравыздан кабатлады:

— Алданмагыз! Безне барыбер газаплап үтерәселәр. Укларыгызны да, безне дә кызганмагыз. Атыгыз! Пычрак кавем корбаннары буласыбыз килми.

Воевода тагын үзенекен кабатламакчы булып авыз ачуга, әсирләр барысы берьюлы кычкырырга тотындылар:

— Алданмагыз! Алданмагыз!

Һәм, ниһаять, казанлылар нәрсәдер хәл итте булса кирәк, кирмәннең буеннан-буена ук-җәяле ирләр чыгып басты, алар күзгә күренмәгән кемнеңдер әмеренә буйсынып, барысы берьюлы укларын күтәрделәр. Бер ук мизгелдә җәя баулары зеңләде. Казыкларга бәйләнгән йөзләгән мәҗрух үз туганнары кулыннан үлем кабул итте. Канлы урыс кылычын, әсирлек түбәнлеген алар шулай кире какты.

Яу кырында үлем газабын, михнәтен татыган гаскәриләр бер мәлгә тын калды, бераздан меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылган оран күкләргә очты. Татар әсирләренең үлемне өстен күрүе, горур батырлыгы аларны таң калдырды.

Ә Василий сынын тота алмады, сыгылып төште. Дошманының битенә кан түкергән яшь егет күз алдында иде әле. «Юк! Мондый халыкны җиңеп булмый. Җиңелсә дә, ул баш бирмәячәк, тезләнмәячәк, кол булмаячак!» Миендә инде ничәнче кат шушы фикер бәргәләнде. Ашыгып чатырга атлады. Аңа ялгыз калырга, уйлаганын, ниһаять, эшкә ашырырга кирәк иде.

Ул калтыранган кулларына кәгазь алды, каурый каләмне үткен пычагы белән очлап карага манды, ашыгып язарга тотынды. Теләсә-кайсы мизгелдә сәүдәгәрләрдән йә сакчылардан кем дә булса килеп керүе бар... Йөрәге шашынып типте. Туган кавеменә хыянәт итүен дә аңлый иде ул, ләкин белә,

шушы адым һәр ике якка хөрлек китерәчәк. Василийның үзен дә, туганнарын да пычрак хурлыктан коткарачак.

Башы котырып эшли, уйлаганын хәзер үк башкармаса, икеләнәчәген, туктап каласын сизенә һәм... аның ничек тәмамланачагын күз алдына китерә алмый иде. Ашыгып чатырда эзләнергә керешә. Түр почмакта кемдер оныттып калдырган садак[1] белән җәя күргәч, күз аллары яктырып китте. Язмыш үзе үк аңа ни эшләргә кирәген күрсәтә түгелме?! Почмакка сикереп, кулына җәя алуын сизми дә калды. Ук сабына хатны урап, тарттырып бәйләде дә тышка атылды. Кеше-кара күргәнче кальгага якынрак килергә, хатны аткарырга! Аннан соң барысы да язмыш иркендә... Һәрхәлдә, кулымнан килгәнне эшләдем, дип җаным тынычланыр.

Ул тирә-ягына каранды. Бәхетенә, якында гына беркем дә юк иде. Укны җәягә куеп киерелеп тартты да атып җибәрде. Ялгыз ук һаваны ярып айлы манаралары балкыган, җимерелсә дә тезләнмәгән якты калага очты.

Өстеннән авыр йөк төшкәндәй җиңеллек килде. «Хәзер менә Санька каршында намусым чиста! Кулымнан килгәнне эшләдем. Ак йөз белән каршына чыга алам»,— дип уйлап куйды Василий һәм соңгы көннәрдә беренче тапкыр үзендә җиңеллек, рәхәтлек тоеп кире чатырга таба атлады. Әмма ерак китә алмады, каршына чабып килүче гаскәр агымы аны бөтереп алды. Ниндидер воевода кылычын болгап усал итеп кычкырды:

— Кая барасың?! Борыл!.. Алга диләр сиңа! Алга! Анаңны ач этләр талагыры...

Василийга башка чара юк. Каршы килсә, котырынган воевода кылыч белән чабып үтәргә дә күп сорамас. Ул кулын селтәде дә гомуми ташкынга кушылып алга йөгерде. Бар нәрсәне изеп, сытып килгән укчылар арасыннан аңа артка таба юл калмаган иде инде.

Казанның киереп ачылган капкаларыннан татар гаскәре ургыла. Тимер киемнәргә төренгән сугышчылар арасында гөрзи, сөңге тоткан шәһәр кешеләре, әле мыек та чыгып җитмәгән яшүсмерләр, иреккә чыгарылган коллар бар иде. Алар барысы беравыздан урыска аңлашылмый торган дәһшәтле сүзләр кычкыралар, ул исә сугыш авазы булып тоела иде:

— Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр, лә-илаһе иллалла!

Дәһшәтле авазлардан Василийның каны бозга әйләнде.

«Беттем!— дип уйлады ул.— Шушы бәрелештән исән чыксам, ныгытмалар янына якын да килмәс идем». Тагын берничә мизгелдән ике агым бергә кушылыр, бугазга-бугаз килер, очлы кылыч, үткен сөңгеләр кемнәрнеңдер җылы тәннәрен тишеп үтәр, кара җир өстенә кайнар кызыл кан елгасы агар. Үзенең хөрлеген, туган җирен, изге каласын, динен вә денен, балаларының киләчәген саклау, яклау өчен күтәрелгән татар гаскәрен туктатыр, артка алып ташлар көч юк иде инде.

Кол Шәриф ике кул яссуы чамасында калган тишеккә соңгы кирпечне урнаштырды, сыгылып чыккан измәне калагы белән кистереп алып ташлады да кулларын киндер алъяпкычына сөртә-сөртә бер читтәге тәбәнәк урындыкка барып утырды. Инде тынычлап ял итәргә дә була. Китап йортының иң асыл хәзинәсе тупланган мәгарәгә төшү юлы калын дивар артында калды. «Саклангыны саклармын дигән!» Ул үз эшенә тагын бер кат сокланып карап куйды. Кирпечләрнең әле яңа гына салынганы искеләреннән берни белән дә аерылмый, шундый ук төстә, шундый ук тәртиптә тезелгән иде. Моның серен Кол Шәриф үзе генә белә. Шәкерт-таләбәләрдән иске ташлар, кирпечләр ташытты, тизката торган үзле измәне исә агач ялгашларда иренмичә үзе болгатты. Казан мәмләкәтенең, укымышлы затларның гына түгел, Казан халкының иң зур байлыгы, борын-борыннан килгән хәзинәсе — рухи хәтере ышанычлы урынга яшерелде. Алдагы көннәрдә ни буласын тәгаен гына беркем дә белми. Моны хәтта Кол Шәриф үзенә әйтергә дә шикләнә. Әмма киләчәк көннәргә, галәм агышына күз салырга акыл куәте җиткән изге зат Казанга кара көннәр якынлашуын шактый ачык тоемлый иде.

---

[1] Садак — ук савыты.

Кирпечне өеп бетергәннән соң ул тузандай вак ком белән бөтен диварны тоташ эшкәртеп, бер кат каплатып чыкты. Иң тәҗрибәле оста ташчы да монда кайчандыр ишек булган дип әйтә алмас иде. Төргәк-төргәк калын кулъязмалар, чөй язулы таш такталар, җиз дисбеләр, көмеш каптырмалы тышлары асыл ташлар илә бизәлгән китаплар — барысы да якты көннәр килгәнчегә кадәр ышанычлы урында сакланыр. Дистәләрчә буыннарның күз нурын түгеп, берәмләп, бөртекләп җыйналган асыл хәзинәгә бер генә кәррә дә куркыныч янарга тиеш түгел.

Утырып хәл алгач, Кол Шәриф хәзрәт китап йортының ишегалдына чыкты. Анда беркем дә юк иде. Шәкертләр, хәлфә-мөгаллимнәр — барысы да гаскәр арасында. Гыйлем җыясы, киләчәктә мәмләкәтнең рухи байлыгын үстерәсе, аны яңадан яшь буыннарга тапшырасы яшьләрне ничек кенә саклarга теләмәсен, Кол Шәриф аларны Казанны якларга җибәрмичә булдыра алмады. Хәер, коточкыч һәлакәт янаган көннәрдә аларны халык арасына җибәрмәсә, ул аларның күзенә туры карый алмаячак иде. Монысын бик яхшы, үтә яхшы аңлый иде сәетләрнең сәете.

Кала өстендә туплар гөрселди. Һәр ике яктан сызгырып авыр ядрәләр оча. Казан җимерелде, ай-һай, нык җимерелде. Калын ташпулатлар әлегә түзә, ә агачтан җиңелчә итеп, бизәп, челтәрләп салынган нәфис йортлар бетте, пыран-заран килде, янды. Еракта казанлыларның тәкбир әйткәне ишетелде, урыс гаскәренең кыргый улауга охшаш ярсулы өне килеп җитте. Ныгытма кырыенда каты бәрелеш, канлы дау бара. Шәһәр урамнары буш. Олысы-кечесе, яше-карты, кулына корал тотардай хәле булган һәммә кеше кирмән өстендә. Казанның язмышы шунда хәл ителә. Берәүләр, көченнән килгәнчә, гаскәргә ярдәм итә, икенче берәүләр җимерелгән диварларны ямый, таш, ком, бүрәнә, балчык ташый, өченчеләр яралыларны куркынычсыз җиргә күчерешә.

«Йа тәңрем, гаделлек ягында булсаң, кулыбызга көч, җаныбызга дәрман бир. Сиңа гына согынган бәндәләреңне ярдәмеңнән ташлама!» — дип уйлап куйды Кол Шәриф һәм акрын гына капкага таба атлады. Ләкин бер-ике адым да атларга өлгермәде, шапылдап капка ачылды, аннан каты йөгерүдән тыны кысылган яшь кенә егет килеп керде. Хәтәр ашыгудан булса кирәк, аның йөзе кәгазьдәй агарган, күзләре зур булып ачылган иде. Егет бер сүз дә әйтеп тормыйча кулындагы кәгазь кисәген Кол Шәрифкә сузды. Ниһаять, тыны ачылды, телен көчкә әйләндергәндәй авырлык белән эндәште:

— Изге Кол Шәриф хәзрәт! Урыс ягыннан укка тагып мәктүп аттылар. Хан сараена чаба алмадым, сиңа китердем. Укып багасыңмы?!

Егетнең беләгендә терсәктән түбән күлмәк җиңе ертылган, ак чүпрәк аша саркып кан тама иде.

— Яралангансың түгелме, улым! Әйдә, башта җәрәхәтеңне бәйлик, — диде Кол Шәриф егетнең кулыннан кәгазьне алып.

— Зарар юк... Шушы ук сыдырып китте. Ярасы тирән түгел. Батыр ярасыз булмас...

Егетнең шаяртырга тырышып сөйләнүеннән үзалдына елмаеп, Кол Шәриф бөтерелгән кәгазь кисәген сүтеп җибәрде. Бер-ике юл укуга ук аның кыяфәтенә җитдилек, олуг җаваплылык тойган кешеләрдәгечә сабыр кызыксынучанлык чыкты. Кәгазьне тагын бер кат шомартып алды да, йотылды. Бераздан сөаль бирде:

— Укырга өлгердеңме?

— Юк, хәзрәт. Беренче юлларын күрдем дә туры монда йөгердем.

— Рәхмәт сиңа, егет! Әйбәт хәбәр китергәнсең.Тыңла, ни язалар: «Галиҗәнаб Казан патшасы! Сиңа түземлегеңне җигәргә генә калды. Озаклаmый Иоанн Васильевич Казан каласын хурлыклы ташлап китәр. Ашлык, азык-төлек төягән барлык көймәләрне Иделдә сезнең кешеләр батырып бетерде. Гаскәр ач. Тагын шуны да белеп тор: кирмән астында җир асты юлы казыла, кальганы шартлатырга. Саклана алсагыз — җиңү сезнең якта», — ди. Яхшы! Аллаһым үзе мәдәт бирсен! Инде тагын ниләр яза?.. «Хөкемдар вә урыс гаскәре шәһәрне ташлап киткәч, мин дә аларга иярер-

мен. Тик озакка түгел. Бераз юл үткәч, аерылып Казанга килермен һәм, бөек хан, тугрылыклы хезмәтчең-чураң булырмын. Бу хәбәрем өчен мине, тугры колыңны сакла, бөек падишаһ, сөй һәм юмарт бүләкләрсең дип тә өмет итәм.

Син хөкемдар каршында баш орып Углич сәүдәгәре Василий Булгаков дип белерсең». Йә, нәрсә диярсең, углым?! Бу хәбәрең өчен иң беренче нәүбәттә сине бүләкләргә кирәк түгелме икән әле?

Кәгазьдән аерылып башын күтәрүгә, Кол Шәриф шомланып кычкырып җибәрде. Яшь егет күз алдында сыгылып төште, гәүдәсе җансыз капчык шикелле лапылдап җиргә ауды, аяк-кулларын эченә җыеп бөгәрләнде дә тынды, иреннәре арасыннан канлы күбек бәреп чыкты.

Инде берничә тапкыр мондый сәер үлем белән очрашкан Кол Шәриф эшнең серен тиз төшенде, ирексездән пышылдады: «Агулы ук!.. Ни аяныч: яхшы хәбәр һәм агулы ук!..» Кулындагы кәгазен бөтәрләп кесәсенә тыкты һәм ашыгып егеткә иелде. Ләкин яшь, таза, чибәр сын җансыз иде инде. Хәзрәт укны алып әйләндергәләп карады, яшелләнә башлаган тимер очына күз салды, иснәп карады. Әйе, ялгышмаган! Аннан урыслар куллана торган көчле агуның баш әйләндергеч татлы да, бер үк вакытта сасы да тоелучы зәһәр исе килә иде.

Дога укырга дип кулларын бите янына китергән Кол Шәриф тәүге тапкыр егетнең йөз чалымнарына, киң маңгаена, газаплы авыртудан җыерылып калган иреннәренә игътибар итте. Чү! Нәкъ менә шушындый йөзне, нәкъ шушыңа охшаган егетне кайчандыр бер күргәне бар иде түгелме соң?! Ул егет тә ниндидер газаплы уйлары белән уртаклашырга, Кол Шәрифтән ярдәм сорарга килмәгән идеме? Кылт итеп кайчандыр, Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр җылынган елларда урыс егетенә мөселманлыкка күчәргә хәер-фатиха биргәне, канун дәрәҗәсендәге кагыйдәсеннән чигенеп, аңа ташлама ясаганы исенә төште. Йөрәгеннән әрнү, кызгану хисе яндырып алды. «Димәк, ул чагында ялгышмаганмын.»—дип уйлап алды ул эчке бер уфтану белән. Ләкин бу уй-тойгыларында шатлык та, сөенү дә юк иде инде. Нәкъ шул көнне борынгы дисбенең серенә төшенгәне, йолдызларның Казанга афәт белгерткәне исенә төште. Әйе, барысы да раслана, юраган юш килә. Хәтта шул көнне очраган урыс егете һәм аның нәселенә дә афәт яный, күрәсең. Ләкин котылу юлы бар әле! Бар! Ул—җаһилгә, күз күрмәс киңлекләрдә җәйрап яткан ил-дәүләтләргә золым китерәчәк явыз затка соң чиккәчә каршы тору, тешең-тырнагың белән ябышып каланы саклау. Хәтта язылганнар дәрес булса, котәргә күп калмаган. Түземлек, чыдамлык, тагын бер кат түземлек бир, ходаем!

Кол Шәриф мәетне торыпша белән ябып куйды һәм хан сараена, диван әһелләре, олуг саргаскәрләр янына ашыкты. Урыс ягыннан килгән хәбәрнең дөреслеген тикшерергә, бер-бер чара күрергә кирәк иде.

* * *

Ә бу вакытта үлем, кан һәм газап китерүче ике дулкын Арча кыры ягында бер-берсенә килеп капланган иде инде. Кылычлар үтмәсләнде, сөңге саплары шартлап сынды, үзара чапырылышып беткән урыс вә татар сугышчыларының йөзләрчә тамактан чыккан аһы, каргышы, ләгънәте, әйтерсең, күкләргә менеп җитте. Әмма күктән бер якка да ярдәм килмәде. Табигать җан ияләренең бер-берсенең бугазын чәйнәвенә битараф калды.

Ук-җәя белән генә коралланган, үзе дә сизмәстән иң алдагы сафларда татар арасына барып кергән Василий йодрык сугышында бер чарасыз торды да калды. Ни җәядән ата алмый, кулында хәнҗәре, сөңге, кылычы да юк, ичмасам. Ул гаҗизләнеп тирә-ягына каранды. Бер генә мизгелгә уяулыгыңны югалту да үлем бәрабәренә тиң мәхшәр иде бу. Менә алдында ниндидер сугышчының үле гәүдәсе күренде. Аның күкрәген аркылы тишеп чыккан сөңге тырпаеп калган иде. Бер селтәнүдә аны тартып

чыгарды, җәясен атып бәрде дә сөңгене күкрәгенә терәп алга ыргылды. Йә үзең үләсең, йә сине үтерәләр. Башка юл юк. Күзләрен кан баскан Василий берни дә аермый, башка сугышчылар белән бергә ярсып чаба да чаба. Каршында җир астыннан үсеп чыккандай ниндидер татар углы пәйда булды. Хәер, ул гаскәри түгел, яуга чыккан шәһәр кешесе иде булса кирәк. Якалары аерылып төшкән, Василий шикелле үк сөңге тотып аңа каршы йөгерә. Шулчак Василий аның ачык изүендә, муенында ялтыраган көмеш тамганы күреп алды. Башыннан яшен тизлеге белән әллә ничә фараз йөгереп узды: «Татарның иң олы сәүдәгәрләре йөртә торган серле тамга!.. Базар капкаларын ачучы тылсымлы көч! Тамга!» Күзе шул тәңкәдән гайре бернәрсәне дә күрмәс булды. Ничә еллар өметләнеп, саташыр дәрәҗәдә хыялланган серле тамга иясе үз аягы белән һәлакәтенә, аның сөңгесенә йөгерә түгелме соң!?

Ул кыргый авазлар чыгарып кычкырып җибәрде һәм сөңгене җан көче белән тамгалы адәмнең корсагына батырып айкады, шашынып кабатлады: «Тамга! Тамга!..» Шул ук мизгелдә күкрәгенә яндыргыч авырту килеп кадалды — тамгалы адәмнең пычактай нечкә очлы сөңгесе күкрәк сөякләрен шытырдатып йөрәге янына кереп тә китте. Гомеренең соңгы сулышында ул тагын бер мәртәбә: «Там-га-а», дип гырылдады. Канлы ярадан зәңгәрләнгән эчәгеләре тышка бүселгән дошманның: «Ва-а-а-ся-а-а! Васи-ли-ий!» — дип илереп ыңгырашуын ул инде ишетми иде.

Тирә-якта исә канлы бәрелеш һаман дәвам итте.

1989—1990.

# Сәйфи Кудаш

Башкортстанның халык шагыйре

## Бер саплам җеп

Тик бер саплам тегәр җептәй генә
Мин яшисе гомер торып калды...
Гомернең дә түгел язгы чагы,
Салкын көзнең тик бер эңгер алды.
Бу сапламны тик даһилар гына
Әверелдереп серле тылсымга,
Сихри нәгышь ясап чигеп киткән,
Әйләндереп үлмәс бер сынга.
Бу җеп белән мин дә күлне күккә
Аса торган аркан ишә алмам,
Әкияттәге бер паласны тукып,
Дәрьяларны җырлап кичә алмам.
Җитсә буе әгәр тегәрҗепнең,
Бәсәрмәсә егәрлекләре,—
Сүз толпарын тотып җигәр өчен
Энә күзләп чигәрлекләре,—
Аның белән, әгәр салалсам, тик
Бер ертыкка ямау салырмын,
Я өзелгән берәр төймәне
Балкытып урнына тагырмын.
Башка нәрсә кыла алырмын?!
Булмый икән, барыбер аның белән
Бәйләп китмәм өмет капкамны.
Һич булмаса калдырырмын саплап
Бер энәгә шушы сапламны:
Ак тегәрҗеп ятыр хәтерләтеп
Сызылып яткан язгы ал таңны!

## Каләмемне манып язам хәзер...

Сукыр күздән яшьләр чыкмый диеп
Әйтмәгәндер миндәй сукырлар.
Сукыр күз төбендә ята икән
Күз яше кайнаган чокырлар...

Язганнарым туңмасыннар диеп
Гасырларның салкыннарында,
Каләмемне манып язам хәзер
Йөрәгемнең ялкыннарына!..

---

Сәйфи КУДАШ (1894) — *Уфада яшәүче милләттәшебез, күренекле шагыйрь, аксакал әдип, татар, башкорт, урыс һ.б. телләрдә дөнья күргән күпсанлы шигырь китабы, Г. Тукай, М. Гафури һ.б. турында повестьлар, мемуарлар авторы.*

## Хатлар ята...

Хатлар ята өелеп минем өстәлемдә.
Утлар яна шуны күргәч эчләремдә.

Бу хатларга миннән җавап көтәләрдер,
Кайберләре мине йондай тетәләрдер...

Бер тилмереп карау белән үзләренә,
Мөлдерәшеп яшьләр килә күзләремә.

Ә мин ятам канатларым каерылып,
Өстәлемнән, эшләремнән аерылып.

Эшсезлектән боегып тора каләмнәрем.
Эшләмәгәч, һич үтәлми әмәлләрем...

Нишлимен мин, кайда минем сау көннәрем?
Эшләремне инде ничек тәмамлармын?!

## Калдырырмын...

Ул киткәндә чәчкә атып калды
Икебезнең исле гөлебез.
Гомер буе шуның хуш исеннән
Бәхет тапкан идек үзебез...

Ялгыз калгач, шушы изге гөлне
Үстерәм дә, иснәп исерәм.
Икәүләшеп үстергән чакларның
Сагыну сагышларын кичерәм.

Мәңге сүнми янган тылсымлы уттай
Сулмый торган чәчкә аттырып,
Калдырырмын бу мөкатдәс гөлне
Гамьхур гашыйкларга тапшырып.

Исле гөлнең ап-ак чәчкәседәй,
Илаһи саф сыннар баксыннар.
Без үстергән гөлдәй, картлык белми,
Мәңге аңкып чәчкә атсыннар!

# Кави Латыйп

## Шигъри газап

Шигырь язам, дип, үз өемдә
тоткын булып утырамын.
Күпме генә ялварсам да мин
каләмсм итми азат...
Дүрт фасыллы шигъри газап.

## Һәр мизгелен

Шат күңелем,
пакь йөзем.
Кешеләргә багышладым
гомеремнең һәр мизгелен.
Аларга мин һәрвакыт
кирәклегемне сиздем.
Кушып түгел,
игелеклелекне башкардым мин үзем.

Шат күңелем,
пакь йөзем.
Кешеләргә багышладым
гомеремнең һәр мизгелен...
Бирде хода түзем.

## Төсле

Син төсле төш күрдең,
син төсле кош күрдең.
Өзелсә дә төсле төшең,
яши һаман төсле кошың.

## Утлы көлен...

Кыз баланың
күз яше чыккан:
гөлен яшен суккан,
утлы көлен
учына тоткан...

---

Кави ЛАТЫЙП (1927) — *шагыйрь, прозаик, ике дистәгә якын китап авторы. Казанда яши.*

## Таң йөзендә

Гарьләнү,
әрнү,
һәр мизгелдә.
Йөрәгем ничек түзә,
таң калам үзем дә.

Минем янулар,
минем көюләр,
таң йөзендә.

## Баш куярлык

Кешенең бәхете таш яра башласа,
көнчелек башлана.
Аталар таш аңа.
Түзмәгәч,
дәрьяга ул ташлана.
Җирдә баш куярлык
юк таш аңа.

## Бөеклектән гафу үтенәм

Уйламастан,
ихласлыктан,
кул бирдем түбән бер бәндәгә
җенем сөймәс адәмгә.
Елмаймыймын,
көлмимен,
нишләргә дә белмимен?..
Урын таба алмыйча,
арлы-бирле йөримен...
Үкенәм!
Бөеклектән гафу үтенәм.

## Начарлык

Дошманнар җыя башладым,
начарлык тоя башладым.
Дөрес, аш атудан битәр,
таш аттылар миңа элек тә.

Киләчәктә мине нәрсә көтә,
дошманнар начарлыгы
ниләр белән бетәр?..

Ә хәзергә күңел аша
бер мизгелдә ун ук үтә.
Минем гомергә дә,
оныкларга да җитә
дошманнар кылган начарлык.
Сөенсеннәр:
урын юк качарлык!

## Җан биргәнче

Ишеккә-ишек яшәп тә,
шәһәрдә күршеләрнең
исемнәрен дә,
җисемнәрен дә белмисең.
Алардан сәламнар да алмыйсың,
үзең дә бирмисең.
Афәт килсә дә,
андый кешеләрнең,
андый күршеләрнең
төнге йокыларын бүлмисең.
Сиздерми генә үләсең...
Җан биргәнче,
күтәрәсе килә
авыл зираты капкасының келәсен.

## Кайтаваз

Гомер поезды үтә,
чигенә барып җитә.
Тукталышларым артта,
әллә кайда, еракта.

Каерылып карыймын
тылсымлы балачакка.
Сак белән Сок җыры
кайтаваз булып кайта.

# Бикә Рәхимова

## Кояшка күтәрик

Кояшка күтәрдем шигырьне,
Күрегез, манчылды нурларга.
Өйрәник без аны Тәңредәй
Олылап, хөрмәтләп зурларга.

Коткарган, рух биргән ул безгә
Илаһи, намуслы, шигъри сүз,
Гел укып, ишетеп торудан
Йөрәкләр ярсулы, яшьле — күз.

Коткарган ул элек Галине,
Коткарган Тукайны, Җәлилне.
Коткарган... тормышын кисеп, дип,
Гаепләр ташлама, я инде?.

Өмет бар, ышаныч халыкка,
Шигъри сүз күңелен кузгатса,
Кыйбласын билгелим дигәндә
Шигърият ягына күз атса.

## Чәчәк белән кылыч

Яшенләп давыл килде дә,
Йокламадым ул төнне.
Ялт та йолт яшен кисешә —
Туктатып тора тынны.

Яшен «чигүләрен чигә» —
Кылыч чигешләре күп.
Чәчәкләрдән, кылычлардан
Туп-тулы тулды бу күк.

И ходаем, чәчәк белән
Тагын янәшә кылыч.
Икесе бергә чигелә —
Ничек каласың тыныч?

* * *

Бәргәлисең мине, тормыш —
Мин шул синең эчеңдә,
Бәргәләнсәм дә, ис китми —
Мин бит әле көчемдә.

Көйләп җырламак буламын:
Генәедер, генәер...
Үзең чакыргач көрәшкә,
Кылычым үткенәер.

Үзем кылычлы булсам да,
Күбәләк кебек җаным.
Кылычым минем — шигырем,
Айыйм аның да җанын.

---

Бикә РӘХИМОВА — *шагыйрә, «Сәрвиназ», «Ачыл, күңел!» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Яралар яңарган

Утыр да яз, уйлап торасымы?
Аллы-гөлле, яшен-давыллы
Тормыш урап-чолгап алган минс...
Карам җитми?.. Кушыйм канымны!

Каным — җаным булсын, сулышым да
Һәр сүземә кереп таралсын!
Дөньяның якын, ерак чигенә дә
Минем күзем белән каралсын...

Фикеремдә йөргән уйларым
Сүзгә генә бетсен салынып,
Ут-хис диңгезләрендә йөзгәндә
Булсын минем көймә-салым нык...

Хисләрем кабат-кабат кабынып,
Йөзеп аккан салым янганда
Кычкырсам ачы, коткару сорап,
Таушым яңрар, бәлки, япанда...

Башлаган җиремә бер әйләнеп
Кайтыйм әле тагын яңадан:
Минем яралар шул, иске булса,
Дөньяныкы менә яңарган...

## Бүген ишетәсе

Уйларым кыршау булган да
Боргычлапмы боргычлый...
«Өйдән юлга кузгалганда
Бисмилла, — диң, — чыгышлый...»

Әбием йөзен эзлимен,
Уйлар ярдәм итешә.
Ничә ел элек әйткәнне
Колак бүген ишетә.

Ишетә дә, йөрәк әрни,
Йөрәкнең хәле — яман.
Саңгыраулыктан чыгам да,
Тоташ бер утта янам.

Инде хет бүген әйткәнне,
Бүген үк ишетәсе.
Юкса киләчәк буынның
Каты булыр шелтәсе.

* * *

Мөмкинлекләр чиксез түгел,
Мөмкинлекләр чикләнгән...
«Бетә ул, төзәлә», — дидем,
Бетми яра, чиләнгән.

«Бетә ул, төзәлә», — дидем,
Юату да кирәк бит,

Үз-үзеңне юатмасаң,
Юатучы сирәк бит.

Әллә яра, әллә күңел
Тынган инде, чигенгән.
...Җан талпына, узарга дип,
Мөмкинлекләр чигеннән.

## 1 Май. Ирек мәйданы. Казан, 1991.

Өмет белән язны күтеп алдык,
Өмет безне алга карата,
Гүя апрель-егет май кызына
Бер йомарлам калган кар ата...

Бөртек кенә булса да ул өмет,
Куып җитә хыял артыннан.
Карлар китсә, сулар кипсәләр дә,
Кемнәр әйтер: «Хыял,—дип,—тынган»?

Өмет белән — яшел байрак белән
Килеп кердек ирек алырга,
Мәйдан исме-җисме бирдер, диеп,
Күңелдәгeн әйтеп калырга.

Кечкенә лә йодрыгымны төйнәп,
Һава тиштем, даулап азатлык.
Ташкын булып минем халкым бара,
Ә халкымның хакы — тик хаклык...

Трибуналар — курку катыш ачу,
Йөзләре дә гүя газаплы...
Без бит кешенекен сорамыйбыз,
Без алырга тиеш азатлык!

## Безнең көннәр

Вандализм, кыргыйлык дип,
Тарихтан өйрәттеләр,
Ә үзләре кыргыйлыкның
Учагын көйрәттеләр...

Борынгы тарихмы соң бу?
Әллә безнең тарихмы?
Һәрбер көнгә билге куеп,
Тамга салып барыйкмы?

Салган тамга канлы булыр —
Адәм җаны кыела,
Ник соң гел явызга — ирек,
Ә яхшыга — тыела?..

Үз илеңдә тик үзеңчә
Яшәүгә диген, теләк
Нигә очрата юлында
Йодрык яки беләк?

Менә мин теләктәшче ич,
Яшәсен теләгәнчә!
Минем тавышны күмәргә
Кем генә теләсә дә:
Яклыймын ирек сөюне,
О, ул изге, бөек хис!
Тамырын кискән чәчәкләр
Әнә нинди боек ич.

Боегырсың, тамырыңа
Балта-пычак чапсалар,
Аннары шул катыйль җаннар:
«Карауыл!» — дип чапсалар.

Гөнаһ сылтау гаепсезгә —
Якасыннан тоткандай,
Көчләде дип, фәхеш хатын
Үзе күлмәк ерткандай.

... Канлы гәүдә җирдә ята,
Сызгырып пуля оча...
Гаделлек өчен көрәшнең
Хәерле бетсен очы...

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Рөстәм Кутуй**

# БЕР ДӘ БЕР КӨЗНЕ

ПОВЕСТЬ

### 1

Мин бу изге күңелле, авырлык белән генә йөри торган картны белмим диярлек. Шулай ук аның үткән гомере хакында да. Ул язгы ташкын бозлары тегермән ташы урынына ышкып бетергән, йомычкаларын чоңгылларга кертеп чумдырган бер бүрәнәне хәтерләтә. Тормыш яры буйлата көчкә-көчкә генә бара инде, әйтерсең лә аяк табанына кургашын коеп куйганнар, адымнары чит кешенеке шикелле тоела. Әмма житди кыяфәтле, нәфис ак йөзле туганнан туганы кызынамы, оныгынамы диим, көзнең сыек эңгер-меңгерләрендә үзенә гаҗәеп бер җиңеллек хисе иңүен сөйли дә сөйли. Мин аның әле сүрелеп, әле кабынып китә торган сөйләмен гел ишетеп торам. Ул бакчаны өреткән тын бушлыкны таратырга теләгән сыман, әйтәсен әйтеп калырга тырыша кебек иде.

— Син мине өйгә куып кертергә генә торма әле, яме? Өлгерермен. Мичне ягып җибәрүең бик яхшы анысы. Минем әле бераз яшәп каласым килә. Картлыкның ни икәнен беләсеңме соң син? Уеңа да килеп карамыйдыр. Авыр түгел миңа, түгел! Яхшы әле миңа, яхшы. Әйдә, бәрәңге әрчик. Инде әрчедең дәмени? Әйбәт кыз шул син. Уең ачык, шул тиклем сафлыкны каян җыеп бетергәнсеңдер. Эшеңнән күренеп тора. Ялгыз булуың гына кызганыч. Чыпчык шикелле поскансың. Бөтен хуҗалыкны синең җилкәңә өйдем шул. Суны да чиләкләреңне мөлдерәмә тутырып ташыйсың, утының да әзер. Кайчан өлгерәсеңдер. Ә мин хәлсез инде, ниндидер җиңеллек кенә калган. Кыбырсынма инде! Утыр әле минем катка. Аннары йөреп килербез. Көзне карап каласым килә. Менә чәчәкләрем генә әрәм кала. Син аларны ташлый күрмә тагын, карап тот. Берәр ярдәмчең булса икән ул. Ә мин бер аягым белән тегендә инде, күнегә торам...

Әллә ничек кенә кечерәеп бетеп, ул болдырдагы үрмәле урындыкка утырган. Аны үлемгә әзерләнгән, җыенып беткән дип әйтеп булмый әле. Тигез ут яктысы йөзенә җәелгән. Шома дип... чигәсе бераз кысылган, ә маңгае алгарак чыгып торганга күрә бит яңаклары калкыбрак калган. Күз төбе күләгәле түгел. Ә сулыш алулары авыррак бугай: вакыт-вакыт, тулы итеп тын алыр өчен, күкрәген киңәйтеп, урындык аркасына авыша да күз

---

Рөстәм КУТУЙ (1936) — *шагыйрь, прозаик. Мәскәүдә һәм республикабызда чыккан дистәләгән китаплар авторы. Казанда яши.*

кабакларын йомгалап тора. Үзе шундук күрәеп тә китә тагын, мизгел эчендә ниндидер бер җиңеллек, баш әйләнүе кичерә, күрәсең. Һавасы да сафлыгы белән җиңеллек бирә бит әле аның.

Әкрен генә өзелеп төшкәләгән яфраклар арасында ыгы-зыгыланмас, фани дөньяда җитәрлек яшәгән, мәңгегә тавыш ишетүдән мәхрүм калган шушы кешенең генә тын, нидер үгетләгәндәй тоелган тавышы гына яши кебек. Хәзер ул күзе белән ишетә инде.

Ә кыз аның яшәү рәхәтлеге турындагы сүзләренә әллә ни илтифат итми. Карт көзне мактавын гына белә: имеш, табигать ул вакытлыча гына йокыга тала — менә кар явар да җиргә саулык иңдерер.

Аларның өйләре үргә күтәрелебрәк тора. Яхшы, коры өй. Тәрәзә капкачлары ачык, пыялалары чиста, юк та кебек. Бу өйне җилләр шулай киптергән, ялтыравык канатлы энә караклары сыман итеп җиңеләйткән — һаваны кыштырдатып, менә-менә очып китәр диярсең. Кояш яктысында шулай тоела, ә эңгер-меңгердә ул үз тирәсенә барлык күләгәләрне дә җыеп ала шикелле.

Зәмһәрирдә өшеп корыган алмагачларын кисеп, төпләп аласылары бар, ләкин яңарып китмәсме, дип өмет итәләр, ахрысы. Алар язын ару гына яшәреп, күтәрелеп киткәннәр иде дә, тик аткан чәчәкләре озакламый саргаймыйча да диярлек коелышып төште. Аннары, кызгылт кәүсәләрне шәрә калдырып, кабыклары куба башлады. Ә бу җәйне тамырлары сут бирүдән бөтенләй туктады — шуннан кәүсәне каймалаган кызгылт төс җилгә очты да... алмагачлар кәфен бөркәнде. Шулай да алар үзләрендәге элеккеге көчне, тын гына газапланып, бакча тормышына бирүләрен дәвам итәләр шикелле иде. Бәлки аларны шуңа күрә кисеп ташларга ашыкмыйлардыр да. Кискән ботакларыннан, шәрәлекләреннән оялмыйча, төннәрен дә кайгы төсе биреп, алар шулай өченче җәйләрен үткәрәләр инде.

Урман читенә иркенәеп утырган йортлар тугызау иде. Агачлар арасыннан бер-берсенә моңаешып карап торалар. Соргылт тактасына «Мин монда булмадым. Женя Скоробогатов» дип язылган бер әңгәмә корып утыру куышы да бар иде әле.

Зәңгәрләнеп күренгән капканы чыккач, үрдәге каеннар төркеменә таба юл башлана. Ә шуның янәшәсендәге чокыр төбендә суы түгелмәс һәм кимемәс бер күл чынаягы ята. Аны беркем кайгыртмый, агач черегеннән чистартмый; анда вак-төяк ниндидер төссез, таңкәсез балыклар гына йөзгәли: сызылып таңнар атканда, бакалары сайраштыргалый, әмма аның суы таң нурлары булып та уйнаклап ала, чишмәсе салкынлыгы да тәүлек буена тота. Бу күлдән кичләрен дымсулык күтәрелеп менә дә тирә-юньне каплап китә, үзәннәргә, үрләргә җәелә.

Каравылчы Сәет боларның һәммәсен күрә, күңеле аша үткәрә иде. Ул тын гына пионер лагеренда эшләгән булып йөри. Бераз гына эчеп алса, әллә нинди моңсу, төсмерсез җыр сузарга тотына. Әллә офтана, әллә елый шунда — аңламассың. Ул хатынын җирләгән һәм һичкемне мәшәкатьләмичә яшәргә өйрәнгән иде инде. Тик электрны бик илтифат белән күзәтеп тора, торбалардан аккан суны тикшергәли.

Менә шулай посып кына чираттагы көз якынлашты.

Кыз әлеге картны бирегә сентябрь урталарында — йортлар бушап калгач алып килгән иде. Ихтимал, карт кеше җәен авыргандыр янсә эсселекне авыр кичергәндер.

Хәзер инде бирегә халык ял көннәрендә генә һәм анда да аз җыела иде. Югыйсә бөтен рәхәтлеге шәһәр тавышы килеп җитмәүдән, шул тарафтан искән җилнең чистарып өлгерүеннән, ыгы-зыгы булмаудан гына гыйбарәт бит. Тыңлый калсаң, шосседан килгән машина гөрелтесен һәм чокыр аръягындагы ниндидер хәрәкәтләрне тоярга була. Әйе, тавыштан котылырмын димә.

Бакчаларда астралар чәчәк атып утыра иде әле. Арыган-талчыккан табигать җәйге елмаюын саклап тота әле, агачлар арасыннан югарыга кошлар көтүен чөеп-чөеп җибәрә, әмма үлән сабакларына, рәшәткәләргә пәрәвез

җепләре ябыла, урала инде. Әкрен генә урман да шәрәләнә бара. Җиргә суык иңә. Иртәләрен тәрәзә өлгеләрен салкынча дымсулык өретеп ала. Кичкырын мичкә ягып җибәрәләр. Тәрәзәләрдә ялкын шәүләләре уйнарга тотына. Каравылчы Сәетнең монсу җырлавын басардай ялгызлык дөньяда гына түгел, бередә дә юк иде.

Гадәттә, мин үр кашына байый башлаган кояш нурлары белән бергә чыгып басам да, юл ягына карап, ак каенга сөялеп торам. Әллә кемнедер көтәм, әллә нидер телим шунда — белмәссең. Дөньяда һичнәрсә көтмәгән һәм теләмәгән җан иясе юк инде анысы. Шулай көтә белү шатлык, өмет бирә, хыялны алга әйди, чөнки адәм баласы дөньяга өмет белән килә һәм соңгы тынын алганга кадәр шул өмете соклану катыш газап белән ахыргы мизгеленә кадәр дәвам итә. Өмет — мәңгелек, аны һичнәрсә өзә, кисә алмый инде.

Минем каршыдагы юл чокыр буенча сузылган, язгы сулар агызып җәйгән комы алтынланып тора. Агач кәүсәләре аны бәләкәй кисәкләргә бүлгән кебек күренә. Тынлыкны һични бозмый.

Әйткәнемчә, көзен бередә халык әллә ни күп җыелмый. Иртәдән кичкә хәтле тыныч кына тукраннар тукылдый, кайчагында елгыр тиеннәр йөгереп үтә. Җил исмәгәндә барысы да ишетелеп тора.

Ком кыштырдатып, бер машина якынлая башлады. Йөрәк сулкылдап куйды: «Минем янга түгелдер ич?» — дип уйлап алдым.

Бензин исе килеп ягылды. Машина капка төбенә килеп туктады. Теге кыз, сак кына тотып, картны җиргә чыгарып бастырды. Шоферның:

— Бушлай гына дип исәплəгез,— дигәне ишетелде.

— Нигә алай, нигә алай? — дип тынычсызланды кыз.

— Ярар инде,— диде шофер.— Сездән түләтү гөнаһ булыр.

— Уйлап чыгармагыз инде!

— Әйберләрегезне онытып калдырмагыз. Яхшы, сау булыгыз.

Карт тураеп басты да капкага таба китте. Бер урында җайсыз гына сөрлегеп алды. Таяныр нәрсә капшагандай, кулын айкап куйды, ә кызның игътибары бүтәндә иде, ахры. Ләкин карт, югалып калса да, егылмады. Аның сирәк, чал чәче маңгаена ябышкан иде.

Машина тигез генә түбән төшеп китте. Кыз, сузган акчасын нишләтергә белмичә һәм кыйшайган яулыгын да төзәтергә онытып, бераз аптырап торды.

Ә карт, иркәләнгән сыман, кызны чакыра иде. Тавышы калтырап чыга, таләпчән:

— Нигә мине тотмыйсың инде? Төкер сәнә шул акчага!

Әллә ничек — адашудан курыккан шикелле тоела, тикмәгә түгелдер. Саңгырау ахры бу, дип уйладым мин. Аягы оегандыр. Әлеге кыз аның кеме икән? Картның кигән киеме дә әллә нәрсә түгел — сырган тән җылыткыч, чалбары да калын, ботинкасын йон оекбаш белән кигән. Үзе мамык шикелле ап-ак, диабетик, ахрысы.

Кызның әлеге картны кинәт исеп куйган җилдән каплап кочуыннан, һичкемгә мөрәҗәгать итмәгән кебек, гадәтләнгәненчәдер инде: «Килеп җиттек, килеп җиттек. Юл уң булды. Башлар әйләнеп бетте. Синеке дә әйләнә. Я инде, алла хакы өчен, чайкалма. Килеп җиттек дим! Монда яхшы. Ә букчалар торып торсын. Аннары алып керермен. Ашыгыр җир юк. Кабаланма, кабаланма»,— дип сөйләнүеннән мин картның тирән саңгырау һәм хәлсез икәнен, ә кызга үз тавышын ниндидер ымнар белән дә ул саңгыраулык бушлыгына үткәрүе авыр икәнен аңладым. Бу кыз, әлбәттә, аның туганы, шуңа күрә ул сабыр, ягымлы, авыруга иялəнеп беткән. Аларның бер мичәүдә икәне ап-ачык.

Мин булышырга кыймыйча, ирексездән өркетүдән шикләнеп, алар артыннан карап калдым. Гаҗәп инде: дулкынланулары мине дә биләп алды. Аларның якын бу арага ничек җыенуларын, бер-берсен аңларга, ахырынача төшенергә теләп, төрлечә фикер кылуларын күз алдыма китердем. Карт ничек тә үз дигәнен әйтергә җай тапкандыр, ә менә кызга аның саңгырау дөньясына үтеп керүләре гаять читен булгандыр. Ул үз дигәнен ымнар,

ишарәләр, ирен хәрәкәте белән генә аңлата ала ич инде. Ләкин карт күнеккәндер, күрәсең, төшенәдер. Ни әйтсәң дә, бөтен бер гомер кичергән, бер сугыш еллары гына да ни торғандыр... Ни генә кичермәгәндер ул, шуңа күрә акыл җыйган да. Саңгырау кеше үз-үзен бик яхшы ишетә ул.

Җил әле тузынды, әле басылгалады. Һава коры иде, әйтерсең лә корыган яфраклар үз җылысы белән һәрнәрсәне киптерергә өлгергән. Һәм бар нәрсәне баеп барган кояшның кыйгач нурлары яктырта. Урман, ялкынга куелган казан шикелле, җил, төрле авазлар, кыштырдаулар, төсләр белән кайнап тора сыман. Агач ябалдашлары арасыннан болытлар көтүе күренә.

Кыз букчаларын алмага чыкты, мине шәйләп, сискәнеп китте, бераз карап торгач кына әйберләренә иелде.

«Менә шундый күршеләр, көзге кунаклар»,— дип уйлап куйдым.

Мин гаять үзгә холыклы Әхмәт дачасында тора идем. Килделе-киттеле карашлары хакына ул әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәне кырдырырга әзер иде шикелле. Моңа латыш милләтеннән булган хатыны Айя сабырлык саклап түзеп килде. Кечкенә һәм кайнар «пәри туйлары» аларның йортында айга ким дигәндә ике-өч тапкыр кузгалып ала. Чәчәкләр һәм Әхмәтен өзелеп яраткан Айя моңа тын һәм ачусыз гына елау белән җавап бирә. Диңгезле, әйтеп бетергесез зәңгәр дулкынлы туган ягы моннан ерак — таяныч юк. Әхмәт аны ул яктан кырыс холкы, ярсулы баскын сөюе белән кубарып алып кайткан. Шуннан соң үз яныннан беркая җибәрмәгән. Шушы көзгә кадәр.

Кинәт кенә алар диңгез буена юлга чыкмакчы булдылар. Айя шатлыгыннан нишләргә белмәде. Чәчен дулкын-дулкын итеп җилкәсенә таратып салды. Ике тамчы гәрәбәсен колагына киеп куйган иде. Әхмәтнең кара көдрә чәче уйнаклап алды: «Ни булды сиңа?! Ант итеп әйтәм, мондый чибәрлек дөньяда бер генәдер! Ай-яй, Айка!»,— дип сокланды ул.

Минем Айяның мондый чагын күргәнем юк иде. Эчемнән генә аның аянуларын бала табудан мәхрүм булудан күрә идем. Иртәләрен аның күз кабаклары шешенгән була — күрәсең, төне буена елап чыга торгандыр инде, тумаган балалары төшләренә керәдер. Шуна күрә гел үз эченә бикләнеп йөри дә...

Самолетка таба ул әллә нинди бер тантаналы кыяфәттә атлап китте. Әхмәт ерактан аны миңа күтәреп күрсәтте. Шул чагында да Айя яктырып тора сыман иде.

Алар миңа мөмкин булганынча кадер-хөрмәт күрсәтергә тырышып яшәде. Ялгызак булганым өчен кызганганнардыр инде. Мине тилемсә йә кулыннан эш килмәүче дип уйлаганнардыр.

Дөресен әйткәндә, минем тормышым шактый ук шыксыз.

Хатын-кыз минем тормышыма нидер җимерер өчен генә килеп керә иде. Ә мин алардан җайлауларын өмет итә идем. Утыз яшемә җиткәнче шулай булды. Бер җылындым, бер туңдым. Мине кочсалар, мәгънә эзләп тормастан, үзем дә кочтым. Очраклы учакка, кайвакыт утлы күмергә дә елыштым. Ә алар мине дәрәҗәле, акыл иясе кыяфәтендә күрергә теләделәр, шуңа күрә һәр яхшылыкларын әҗәткә биргән иште генә кылдылар. Үз язмышыңа язмаган мине канәгатьләндермәде. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә охшашлыкка, кабатлануга тап булсам, мин ыгы-зыгылы очрашулардан качам, сай канәгатьлекне кире кагам. Битарафлык биләп алды, мин үз-үземә бикләндем, шул ук вакытта күңел тәрәзәмне дә ул-буга ачык калдырам. «Ул-бу» дигәннең берсе — күршебездәге Клава, ирсез хатын. Кайчагында яхшы тегелгән, әмма кат-кат юа торгач үтә күренмәлегә әйләнеп беткән халатын киеп кереп чыккалый. Ул миңа ярату хыялының һәрчак сусаулы булуы кызганычрак ышануының ихласлыгы бетмәс-төкәнмәс басынкылыгы белән ошый иде.

— Тыңлаучан мин,— дия иде ул.— Минем җаным таушалмаган-нитмәгән әле. Миңа караватка аркылы яткыры бер әрвах эләккән иде бит. Моңа мин гаеплемени? Иңбашымны тота да селкә, әйтерсең лә коелырга торган алтыным бар. Шундый җүләргә туры килүемне әйт...

Клава мине балага саный иде булса кирәк — әллә нинди аналарча ягымлылык белән килеп бәйләнде, назларын кызганмады.

Озак тормый китеп барды да шәһәр карурманында юкка чыкты. Мин аны сагындым, күңелем төште.

Кемдер «сәер бер доктор» белән таныштырырга теләгән иде дә, табигать җименә буйсынып, зур ышаныч белән баруыма карамастан, салкын кызыксыну, йодрыгы кысылган уйдырма дәрткә тап булуга, бөтенесен туктаттым. Мине һәртөрле кысудан шикләнүем, бәйдә тотылу ихтималы «саклап» калды. Шәхес азатлыгы минем өчен гаять кадерле нәрсә иде. Кайбер хатынкызның үз хаклыгын чит ирне буйсындыру бәрабәренә раславы миңа һич ошамый, мин моңа һич риза түгел. Шундый хәлгә калган күпме ир-атның миңа сыенып елаганы бар. Аерылышалар, мал бүлешәләр — миңа боларның берсе дә кирәк түгел иде. Салкын су белән сөртенү, теләсә нинди һава шартларында йөгерү, мускулларымны уйнаткалап көзгедән карану, кыскасы, үз сәламәтлегем күпкә кадерле.

Менә шундый бер вакытта мин Әхмәтнең дача ачкычын алып калдым да инде.

— Ял ит, — диде ул миңа. — Без сиңа диңгез буеннан бер кәләш алып кайтырбыз. Гәрәбә дә! Күз буена тор. Бөтенесеннән кач! Син качып яшәргә яратасың бит. Урманнан утын ташып як. Анда күп ул.

Аңа Айя да кушылып китте:

— Мичкә як. Сине чыршылар саклар. Җәй үтте, бөтенесе таралды. «Бася! Бася!» — дип чакырсаң, янына бер тиен килеп җитәр. Кая теләсәң, шунда ят: караватъ, тахта, диван — бар да синеке. Җырлый-җырлый ят шунда. Ашарыңа ни теләсәң, шул бар: консервы, ярма, ярты капчык бәрәңге, ике тавык. Оялып торма».

— Тазарасың бар, ябыккансың, — диде Әхмәт.

— Кадерле Ил, минем сине бәхетле итәсем килә бит, — диде Айя минем иңбашыма кагылып. — Дөньяда тагын бер бәхетсез Әхмәт булуы гына комачаулый.

— Онытып бетермә. — Без очабыз, син каласың, — дип көлде Әхмәт.

— Ә мин үзебезне онытып бетерә яздым инде, — дип кушылды Айя.

— Кире кагу гөнаһ булыр, — дип килештем мин. — Ялга чыгуны ничек тә җайлармын. Азрак Кахетия шәрабы да юнәтсәм, һәр нәрсә житеш булыр. Югыйсә, ялгызлык яман нәрсә ул.

— Шәраб дигәндә, база шыплап тулган. Бер төрләр генә чөмерсен димәгән аны. Анда бер алтын кеше булыр — башында ми түгел, ә бәлки кызыл уылдык. Шуңа күрә күпме кеше аның башын ашарга ашкынып йөри. Башына җитәрләр иде дә — кесәләре сайрак шул. Кушаматы бала чагыннан ук — Бишбалта. Әйдә, киттек.

— Хәзер үкме? — дип шаккатты Айя.

— Саваплы эшкә мук үсәргә тиеш түгел.

Болай итеп, мине алар гына якын күрә, язмышыма әллә нинди яхшы борылышлар уярга тели иде. Математик Әхмәт белән кибернетик Айя менә шулай гына яши белә — гади һәм аңлаешлы итеп. Ара-тирә өйләрендә кузгалгалаган «пәри туйлары»н ягымлы яңгыр басып китә, күңел киңлекләрендә сүрелдерә.

## 2

Мин Кахетия шәрабын чыгарып: «Менә тагын көзләр килеп җитте», — дип уйладым. Күренгәнчә, уем әллә ни тирән мәгънәле түгел иде.

Дача йорты тәрәзәләре караңгылыкка текәлгән. Мичтә тыныч кына ялкын дөрли. Нәкышле шәмдәлдә ике шәм яна. Алары Айяның бирнәседер инде. Мондый шәмдәлләр хәзер нәселдән нәселгә генә күчә. Миңа алар яшәүнең үзелмәс моңы, бетмәс мәгънәсе булып тоела.

Африка халыклары әкиятләренең чираттагы китабын ачып салдым да тагын:

Менә тагын көзләр килеп җитте,— дип кабатладым. Үз тавышыма колак салырга да онытмадым: ярыйсы гына көр чыкты. Төнлә, гомумән, үз тавышыңны яхшы ишетәсең. Тирән коега төшкәнсең кебек тоела.

Әллә кайчан гына мин эти белән әнине дәвалап терелтү өчен табиб булырга хыялланган идем. Җилкәләре тураюның ни икәнен белмәгәнгә, күзләрендәге сагыш бер дә бетеп тормаганга, алар миңа һәрвакыт авырыйлардыр сыман тоела иде.

Төнлә үз тавышың яхшы ишетелә. Монда, кара көз көнендә һәм читтә бигрәк тә. Төн уратып алганда аеруча.

Болдырга чыктым да баскычта агачларның диңгез шавын хәтерләткән шавын тыңлап утырдым. Һәрбер яфрак үз язмышын сөйли кебек иде. Кара чыршыларны, йортларны айның тигез нурлары яктырта. Авазлар, мәңгелектән үзе шикелле, каядыр ага да ага сыман. Күкне эре йолдызлар тутырган, тик аларның берсе-бер атылмый.

Әйтерсең лә янәшәмдә вафат булган анам да утыра, миңа аның кул хәрәкәтләре дә күренә сыман.

«Мин сине кичердем инде, улым, үз-үзеңне бетереп утырма. Йөрәк йокыңны истәлекләрең бимазаламасын. Очраклы ялгышларың өчен гомереңне битәрләмә. Минем сине ташлап китүемне, бикле ишеккә килеп терәлүеңне син белмәдең бит. Мин синең басынкы тавышыңны ишеткән идем, тик ишегемне ачарга кулымнан килмәде. Мин сине кичердем инде, кичердем. Арабызда караңгылык ятмасын. Бераз соңарып булса да, син барчасын да тиешенчә эшләдең. Мине тынычландырырга тырышуың кирәкмәс иде...»

Вакыт төннәр булып әйләнеп кайта, шуңа күрә тынгысызлый да. Артта этине дә тоям, күләгәсе бер куакка яткан диярсең. Арган-талчыккан, үз-үзен җиңәргә тырышкан кеше күләгәсе.

«Сиңа минем ярдәмем бик кирәк иде. Беләм, сиңа таяныч җитмәде. Гаеп ташларга ашыкма. Мин «ярату» дим һәм ни әйткәнемне яхшы беләм. Ярату — язмышның арыш ипие ул. Мин әниеңне, йолкыш эт сыман ташлап китмәдем, качмадым. Миңа бүтән нәрсә хаҗәт иде. Синең үзеңә дә шул язган. Сагыш безне үзе эзләп таба. Бәлки, син бәхетлерәк булырсың һәм сынган канатыңны очкан чакта ташламассың. Вакыт дәваламый ул, ә бәлки кызык хыяллары белән яңадан дөньяга китерә. Кулың күтәрелсә, миңа моның өчен таш белән бәрә аласың...»

Төн аша әллә кайларга карап утырдым да утырдым. Шаһит итеп кемнәрне чакырдым соң әле? Җанымны бастырып торган авыр таштан котылу хакына башка берәүгә ышанып тапшырырлык нәрсә фани дөньяда бар микән? Юк, билгеле. Мин чит тормышларны яралаудан, аларга сорау йә киңәш белән тыкшынудан курыктым.

Әмма бу тын көз төнендә мин үз башыма теләсә нинди чит кеше тезенә салырга, ачылып китеп сөйләшеп утырырга әзер идем. Тик ниндидер берәр хатын-кыз кулы астына гына керерлек булсын...

Яңадан өйгә кереп утырдым. Шәм ялкыны, йокларга ирек бирмичә, хәтеремне ялмап-ялмап ала. Түбәдә яфраклар тырмаша, кыштырдаша иде.

Иртән мин йөгереп диярлек бардым да, күземне йоммастан, кургаш суга ташландым. Су салкыны йөрәкләргә тиклем үтеп керде.

Ә өченче көнне кичкырын әлеге дә баягы кыз белән теге карт килеп төште. Һәм мин тын гына алар эзе буенча киттем.

Аларның өйләре безнекенә йөзгә-йөз карап тора. Араларында гөлҗимеш куагы да тар гына бушлык. Өч көн элек ул йорт минем күземә дә ташланмаган иде. Бактың исә, манараларны хәтерләтеп, күккә сыерчык оялы колгалар сузылган, чәчәкләре күп. Алмагач калдыклары агарышып тора. Тәрәзәләргә сирень куаклары елышкан. Болдырлары төбендә — кара кәүсәле карт каен. Болдырларының киң тәрәзәсенә чуар рәсемле пәрдә эленгән.

Су коенып, аларның йорты тирәли шыпырт кына әйләнеп чыкканда иртәнге биш иде. Тәрәзә пәрдәсе селкенеп, аз гына ачылып киткәндәй тоелды.

«Юк, алар сабыйлар йокысы белән йоклый әле,— дип тынычландырдым мин үз-үземне.— Авыл кешеләре түгел ич, дачада торырга килгәннәр. Карт йоклаганда тагын да көчлерәк сызланадыр. Ә кызның куллары таралып ятадыр. Аңа ничә яшьләр тирәсе икән? Егерме өчләрдән узмагандыр, шәт. Аның муены кичә ачык, төз, озын булып күренгән иде. Кыргый кошныкы шикелле.

Тиз генә үз өебезгә кереп киттем. Тән җылыткыч киеп, төймәләрен каптырдым. Салкын су туңдырып җибәргән иде. Башта: «Боларга коры каен утыны кертеп бирсәм, ничек булыр икән?»— дип басып тордым. Алар ярдәмгә бик мохтаҗдыр. Ничек алай тик тормастан чыгып китәргә уйладылар икән? Көзне тансыклаганнардыр, күрәсең. Әлбәттә, алар утын-фәлән хакында сөйләшеп куйганнардыр инде, аны-моны киңәшләшкәннәрдер, тик ахырынача, белеп түгелдер, нигә дигәндә, бу карт белән юлны аркылы да чыгып булмый ич. Аларга булышырга дип, кемнеңдер килеп чыгуы да бар, әлбәттә. Ташландык кешеләр түгелдер ләбаса. Әллә каравылчы Сәеткә ышаналар микән? Ә ул эчеп алса һәм очсыз-кырыйсыз җырын суза башласа? Күрәсең, «Ярдәмнәреннән калдырмаслардыр әле»,— дип уйлаганнардыр. Кеше заты аз калсә да, әллә нидә берәр күрше килеп чыгарына өмет баглаулары да ихтимал. Шуларның берсе мин ич инде. Ярдәмемне тәкъдим итсәм, ничек кире каксыннар икән? Шаккатсыннар соң...

Мин, татлы йокылы кешеләргә могҗиза эшләргә теләү уе белән, ике арадагы бушлыкны үтеп, аларга бер кочак коры, чиста каен утыны илтеп ташладым. Үзем дә сизмәстән, алар миңа ничектер якын булып тоелдылар. Бу дөньяда бер-береңә якынаю, бер-береңә якын булу фарыз. Ни әйтсәң дә, мин врач кеше бит, димәк, һәр авыру кешегә ярдәм итәргә әзер кеше. Бу хакта миңа кемдер киңәшен биргән иде инде, ә ул киңәш минем барлыгымны тәшкил итә ләбаса, моны мин үзем дә беләм.

Медицина дигәндә, миңа тылмач кирәкмәс. Иң әүвәл, үзем тиеш дип кабул иткәнчә, мин беркемнән дә җирәнмим. «Ак кул» дигән нәрсә минем косасыны ук китерә. Ә халатым белән башлыгымны мин кеше кулы җитмәс җирдә тотарга күнеккән. Авыруларның чиренә караганда миңа аларның җан саулыклары кадерлерәк, берәрсенең тәүбәсе минем өчен хезмәт хакыннан да югарырак бәядә йөри. Мине акрын кыймылдауда гаепләгәннәре бар, имеш мин авыруларны агымнары белән кабул итә белмим. Соң, ни хәл итәсең инде: тышкы яктан кемнеңдер биле сызлый, кемнеңдер башы чатный, кемнеңдер тәненә бетчә чыккан. Ә бу хәл авыру түгел ич әле ул. Һәр авыру һәм чир кешенең җанына яшеренгән. Күз курка, кул эшли дигәндәй, асылына төшү зарур, миңа кеше күзе төшмәстәй тирәнлекләргә төшә белү кирәк.

Кинәт кенә күз алдыма теге карт белән килгән кыз чирләп киткәндәй тоелды... Тик шундук, пәрәвезне аралагандай, мин бу күренешне кул селтәме белән читкә кудым. Ялгыш һәм ирексездән ни генә юрамавың ихтимал?

— Барыбер дәвалау чарасын табар идем,— дидем мин үз-үземә.

— Әлбәттә, дәвалар идем. Һичшиксез.

Мин бер генә нәрсә алдында көчсез икәнлегемне яхшы беләм— картлык алдында.

Шунда мин катгый бер фикергә килдем дә катып килә башлаган ысланган колбаса кисеп куйдым, ипи кыерчыгы сындырып алдым. Иректә бер ашап алыйм әле, ә чәйне аннары куярмын, кирәк була калса, самавыр дөрләтеп җибәрергә дә була.

Күз алдымда таң атты. Күл ягындагы вак агачлыклар ягыннан томан күтәрелә башлады. Инде бу дымны кул белән генә куып таратырлык түгел.

Беренче көнне үк, тирә-юньне караштыргалаганда, мин теге чокырның бер култыгын яратып үз итеп өлгергән идем. Шул чокырның үрләрен барлаганда ук мин шуннан корыган нарат ботаклары ташырмын дип уйладым. Аяктагы агачларга беркайчан кызыкмаганга күрә, мин тәрттең исә аварга торган агачларга исәп багладым. Бу нәрсә үзенә күрә дөнья рәхәте бит инде.

Элегрәк мин Әхмәтләр дачасына сирәк-мирәк кенә килгәли идем, күп булса, җәенә өч мәртәбәдер. Башкалар җаена карап яшәргә күнекмәгәнмен. Дуслар дип, кеше өстендә ничек тормак кирәк? Үз бәхетләре үзенә. Дачада тору Әхмәтләрнең үзләренә дә әллә ни тәтеми, һәрхәлдә, машиналары булса да, көн саен йөрмиләр. Иртәләрен эшкә ашыгалар. Ә кичне күрми дә каласың. Шимбә көннәрендә ярый әле. Шуңа күрә мин аларның ашына кара таракан булып төшүне өнәмим дә, теләмим дә.

Әнә шул сирәк-мирәк дигәнемдә дә алар белән бергә болдырда чәй эчүдән, куйганнан авыз итүдән, шахмат уйнаудан узганым юк. Төпле генә кеше булуыма карамастан, аулаграк җиргә «ычкынып», ялгыз агач төбендә уйланып утырырга вакыт тими. Җитмәсә, алар мине ялгыз итмичә, мөмкин булганынча кунак итәргә тырышалар иде. Әхмәт белән Айя тирәсендә әллә ничек гел дөньяга килмәгән балалары рухы сизелеп тора; телисеңме, юкмы, шул хакта сүз ялганып куйгалый. Мин, сак булырга тырышып, сүзгә кушылгалыйм, тынычландырам, сүзне бүтәнгә борырга теләп шаярткалыйм.

— Яшен ташының кайчан, каян килеп чыкканын беркем белми,— мәйтәм.

Әхмәт житдигә алып:

— Койрык болгама, яме,— ди.— Син шарлар куып йөрүче түгел,— медик. Син эзләп кенә чыкмый ич алар.

— Беләсеңме, дип куям мин тирәнгәрәк кереп,— яшен ташы кинәт пәйда була. Каян килеп чыкканын беркем белми. Моның өчен билгеле бер шарт кирәк. Гадәттән тыш шарт. Ниндидер хәтмәле борылыш. Эссе дә салкын. Җилләр юнәлеше...

— Аңламассың сине!

Мин маңгайларына терәп: «Балагыз булмауга сезнең җаныгыз-тәнегезнең тәңгәл түгеллеге сәбәпче. Кайнап алуыгыз кирәк, очыш! Син дигәнчә генә булмый ул. Гадәтилектән кача белегез»,— дип әйтә алмыйм ич инде. Менә шуңа күрә яшен ташы тирәсендә әйләндерәм дә. Миңа югыйсә: «Син Айяны Балтыйк буена җибәр. Артыннан үзең дә калма»,— дип саласы бит.

Айя күренү белән, телдән язам. Мин аны болдырда утыра дип торам тагын. Гадәттә, ул, Әхмәткә дигән яңа бәйләмен тотып, шунда төпләнә.

— Комачауламадыммы?— дип сорый ул.— Хәзер китәм, китәм. Җиләк утыртасым бар.

Бер заманны Әхмәт ике көн тирәсе юкка чыгып торды. Эзенә төшеп, махмырын чәй белән чыгардым. Хур булып йөрүенә гарьләнеп, бетә алмады.

— Без аерылышырбыз, ахрысы,— диде ул төшенке кыяфәттә. — Яшәүмени бу? Өйдән мәет чыккан шикелле. Җылылык юк, гел ләчтит сату. Торган саен кыргыйлана барам.

— Ә ул?

— Кайчандыр аның кемедер, ничектер булып алган, ахрысы. Әллә ниткән тәмле теллесе эләккән. Менә шундый-шундый хәл... Бармагы тирәли әйләндергән. Ә мин, үзең беләсең, кырыс кеше. Тупас. Хәзер Айя мине шул мужик калдырып киткән аршын белән үлчи. Тегесе ярамый, бусы батмый. Шуннан шул килеп чыга дим инде: мин каршы гына сыйпый алам, күрәмсең. Минем җанда атлар уйный. Төенне чишәргә вакыт...

— Синең ярсу чагың,— мәйтәм.

— Күптәннән инде бу хәл. Айяның бөтен дус хатыннары җыр һәм бию ансамбленә торырлык. Күралмыйм шуларны! Һәммәсе аерылган нәмәстәләр. Буш шешәләр шалтыраткалыйлар. Бер өер җыелалар. Ирләрне сүгәләр. Ә җаннары — буш ындыр табагы ише тап-такыр.

— Аңлыйм да бит... Башны эшләтергә кирәк.

Әхмәт кычкырып җибәрмәсенме:

— Балаларсыз тора алмыйм мин! Түзәр, җигелеп тартыр идем! Балалы йорт ал да гөл бит ул, ал да гөл...

Бугазга төер утыртып калдырган сүз шуның белән бетте. Арабызга кара мәче кергән ише булды. Әхмәтнең күзе кара күмер белән бер иде. Муен тамырлары бүртеп чыкты.

Шуннан соң тынлык урнашты. Әхмәт ык та итмәстәйгә әйләнде. Ә янында нинди ут дөрләгәнен мин яхшы беләм идем...

Айя җиләклектә кайнаша башлады.

— Ул яшен ташын кайдан казып чыгардың әле син?

— Бар инде шунда. Башка бәрде...

— Койрык болгама дим ич! Нинди гадәт ул синең, ә? Уйларың чытырман белән бер, ерып чыккысыз. Дәвам ит!—дип боерды Әхмәт.

Айя өйгә кереп китте дә тынды.

— Сөйләрмен, сөйләрмен,—дидем мин кабаланып.

Ишек ачык торганга, Айяга бөтенесе ишетелеп тора иде. Күз алдыма килә: сагайгандыр да, хәлсез кулын кая куярга белмичә, стенага сөялгәндер. Сагаеп тыңлаганда гел шулай итә ул. Утырмый да, ятмый да—басып кына тора, тын да алмый, чәнти бармагын да селкетми. Әллә кайлардагы диңгез турында уйланадыр, дулкыннарның кайнар комны кыштырдатуын ишетәдер, тамырлары калкып чыккан нарат күләгәсенә елышасы киләдер...

— Йә, сөйлә!—дип боерды Әхмәт тәмәке кабызгач.

— Ул авыл Көек дип атала, шунда бер мужик яши иде. Әйтик, Макар. Алны-ялны белми эшли торган чагым иде. Дәвалыйм, акыл җыям. Теге Макар дигәннең башы шаулый. Өзлексез яуган яңгыр кебек. Йоклаганда да тынмый. Ни нәрсә икәнен белми бу. «Күп уйлыйсыңдыр»,—мәйтәм. «Уйланам шул»,—дип килешә теге. «Тот та тукта»,—дим инде. «Ничек итеп?» «Син гел бер нәрсәне уйлыйсың ич». «Каян белдең?»—дип гаҗәпсенә. Мин аның ни уйлаганын сорашмадым, ничектер, кыймадым инде. Кирәк икән, үзе сөйләп бирсен. Дәшми бу, теге «яңгырын» тыңлап тора. «Менә нәрсә, Макар,—мәйтәм.—Хәтереңә сеңдер, бутавың бар. Урман уртасына кер дә күп итеп нарат ботаклары сындыр, шунда ят та йокла. Төштән соң кирәк. Ике сәгать йокласаң, яхшы; өч сәгатькә сузсаң, тагын да шәбрәк. Иренмә. Ун көн буена тоташлый, аңладыңмы? Ул миңа карап торды, торды да мыңгерәүләнгән ише китеп барды. Саубуллашмады да. Тәрәзәдән карап калдым—урам аша чыгып бара, фуражкасын киярга дә оныткан. Күзендә нинди сагыш ятканы аркасыннан да күренеп тора.

— Берәр дару язып бирә алмадыңмыни соң?—дип сорады Әхмәт.

— Тыңлавыңны бел. Нәкъ ун көннән соң Макар килеп чыкты. «Теге шау бетте бит, доктор!—ди бу миңа.—Хәзер нишләргә? Йокларга дигәндә мин аны хәзер кояш баеганчы йоклый алам». «Уеңнан да арындыңмы?»—дип сорыйм. «Арындым, арындым, арындым»,—дип алдыма кыздырылган тавык чыгарып куя бу. «Алмасаң үпкәлим!»—ди. Шуннан чыкты да чапты. Тәрәзәдә шәүләсе генә күренеп калды.

— Ялган капчыгы бит син!—диде Әхмәт урындык аркасына терәлеп.—Кахетия шәрабын эчеп куйганың ише генә алдагансың ич! Гонаһысын кая куярсың?

—Сөйләп бетермәдем ич әле. Нигә сабырсызланасың?

Әллә нинди тойгы белән Айяның якынрак килеп басканын сизеп алдым.

— Ә күз күне, онытылып беткәч, мине болдыр төбендә көтеп тора бу. «Тагын шаулый мәллә?»—мәйтәм. Ул елмаеп җибәрде. Шуннан соң карыйм: «Кем туар икән, ә?»—дип пышылдый. Күзе ялтыр-йолтыр килә моның, шул хәтле риясыз...

Әхмәт кикереп җибәргән иде дә, шундук учы белән авызын каплады.

— Макар Чудра син—менә кем!—дип, ул миңа төбәлә, йодрыгы аша гына сулый.—Әллә син күрәзәчеме?

Шуннан соң без самавыр куйдык. Миңа электричкага вакыт иде инде. Алар мине бер төенчек җиләк биреп озаттылар.

Саубуллашканда Әхмәт тагын төпченеп алды:

— Моңа яшен ташының ни катнашы бар соң?

— Кем белгән инде аны?—дидем мин аның кай төшенә кагылганымны аңлап.—Чыршы ботаклары, җил юнәлеше, карбыз исе. Калганын белмим.

— Син аның ни уйлаганын сизгән идең мәллә?

—Юк.

— Башын гына катыргансың булып чыгамыни?

— Зур сагыштан аның күзенә томан кунган иде. Мин кеше дәвалыйм бит. Дару — фәләннән нинди мәгънә ди? Әйтәм ич, калганын үзем дә белмим.

## 3

Мин көчемне кызганмыйча эшләдем дә эшләдем. Башым шауларга тотынды хәтта. Нарат ботаклары күп. Мин аларны балтасыз-нисез генә җыйдым. Борынны, нашатырь кебек, коры кабыкларның шәрабка тартым исе кытыклады. Аяк йомшак мүккә батып керә. Уч төпләрем кызышты. Мин рәхәтләнеп сумала исен иснәдем. Тирә-юньдә тонык кына булып ландыш яфраклары ялтыраша иде.

Шунда, беренче кар кебек агарып, башыма йөгерек уй килде: «Яз көне булса, мин аңа ландыш чәчәкләре җыеп биргән булыр идем. Ә көзен тагын да яхшырак...» Якында гына яңа күршебез — теге кызның йөз чалымнары төсмерләнде шикелле.

Шунда бөтен наратлыкны этләр өрүе күмеп китте. Таудан ишелгән таш йомарлары сыман бөтерелеп, каршыма да килеп чыктылар. Йортсыз-җирсез, ташландык этләр! Зур гына саллы бер ботакны чак кулыма эләктереп калдым. Йомгак-йомгак йон өере, күзләре ут яна, тешләре ыржайган. Тик алар, бәреп искән салкын җил булып, ары ыргылдылар, билгесез ирекләренә кереп югалдылар. Тагын эшемә керешкән идем, арка белән ят күз карашын сизеп алдым да борылып карадым: ауган усак агачы астыннан миңа шулардан аерылып калган бер эт текәлеп тора иде. Күзе әллә нинди бер тирән өмет чаткысы белән яна. Җыйган ботакларны җайлап, култык астына кыстырдым да, аны кызгануымны баса алмыйча:

— Әйдә соң, киттек. Теләсәң, миндә торырсың,— дип эндәштем.

Алга табан икәүләп киттек. Ул, мине аңлавын белдереп, бер алдыма, бер артыма төшә-төшә барды. Рәхәт булып китте. Әйтерсең лә нәкъ менә шушы этнең тирән ышанычы, шатлыгы гына җитмәгән. Мин үзем дә, шушы эт сыман, кешеләр арасына куе чытырманлыкларны аралый-аралый килеп чыкканмындыр, ахрысы. Ул да мине ошатты бугай. Тыныч тавышыма буйсынды, өрүен онытты. Миңа әллә ничә кеше җәберен кичергәннән соң тап булуына сөенде, күрәсең. Барган юлын хәтеренә сеңдереп калырга теләгән шикелле, әледән-әле юлны иснәштергәли — яңа тормышка юл сала.

Утынымны сарай турысында койма аша җиргә ташладым. Өч көн чамасына җитәрлек. Кәеф килсә, тагын алып кайтырмын, нарат исен иснәрмен, эт тә иярер. Күнегелер. Тик бер нәрсә юклыгы үзен гел сиздереп торырдыр: янда якын җан иясе булмау, эт өргәнгә чыдый алмыйча көлеп җибәргән берәр бала заты...

Әлеге эт миңа йөк булмаска охшый: ыгы-зыгыланмый, аяк астында буталмый.

Ә минем яңа күршеләрем уянмаган иде әле. Тирә-юньгә яктылык торган саен кыюрак җәелә инде. Күкне болыт каплаган, кояш чыкмастыр. Ничек тә ярый, монда пляж түгел ич.

Кичтән калган ашны калай тәлинкәгә салып, баскыч төбенә чыгарып куйдым. Эт шаккаткан сыман күтәрелеп карады да ашарга кереште. Газга чәйнек утырттым, колбаса, ипи кистем. Шул җитеп торыр. Медицина журналы укырга тотындым.

Минем көннәрем шулай башланып китә торган булды.

Мине кеше авыруының бер ягы кызыксындыра иде, аерым бер төрләре генә түгел. Әшәкелек тә — кешенең авыруы ул. Мин кеше тәнен аның яшәргә теләге нинди булуга карап өйрәнәм. Медицина минем өчен бар нәрсәгә караганда да кадерлерәк кебек.

— Тяпа! — дип эндәштем мин этне чакырып.

Эт шундук килеп җитте дә, көтелмәгән эндәшүгә нишләргә белмичә, башын кыңгыр салып текәлде.

— Кушаматың шушы булыр. Элеккегесен онытырга туры килер, чөнки мин аны белмим. Әүвәлге хуҗаңны да онытырга кирәк. Бер айдан йә алданрак мин сине шәһәргә алып кайтырмын. Килешербездер иң, ә? Кая, капшап карыйм әле. Шактый нык икәнсең син, аягың да көчле. Токымсыз түгел син, Тяпа. Нинди токымнан икәнеңне белүчесе дә табылыр. Болдырда йокларсың, берәр нәрсә җәеп куярмын әле. Айя шаккатыр инде...

Мин яхшылап Тяпага урын җәеп куйдым. Ул шундук сузылып та ятты. Аргандыр, күрәсең.

Үз болдырыннан миңа табан күрше кызы карап тора иде. Бөрешкән. Әчтән аны карт чакырып алды.

Мин дә чәй эчәргә кереп киттем.

Юлга кузгалыр алдыннан, бер атна элек, Әхмәттәге нииндидер үзгәрешне искәрүем искә төште. Әйтерсең дә аңлап булмастай дулкынлану чаткылары иркенә бирелеп калды. Адымнары елгырлашты. Карашына җиңүче кыяфәте керде. Кулын кесәсенә тыгып йөрүне бетерде. Кашлары турайды, йөзе яктырып китте. Теш казнасын кысмый иде инде. Пөхтә һәм кыйммәтле кием кия башлады, туфлиен гел чиста тотуы, хуш исле сигарет тартуы, ишеген ничектер бәреп кенә ябулары андагы үзгәрешнең тикмәгә булмавы һәм гадәти түгеллеге хакында ачык сөйли иде.

Клиникага килеп керде дә, эш ахырына кадәр ярты сәгать калуга карамастан, мине көчләп диярлек тышка алып чыкты. Минем бер авыру янына керәсем бар иде әле. Утыргычка утырып, ярты сәгать сигарет төтәтсә, йә авырулар арасында йөренсә ни була инде? Сагышлар һәм шәүләләрне күзәтеп, уйланып утырса ни була?

Мин мондый ирексезләнүләрне өнәмим. Аның да якасына ябышып, селкетергә әзер идем: «Миңа яшәргә комачаулама әле, яме?!» Ул таза-сәулар арасында, ә мин башка законнарга буйсынып яшим. Мин янартау кратерында, ә минем Әхмәт дустым шуның итәгендә генә йөрене бит. Моны аңлыймы соң ул? Һәрхәлдә, авыруның нинди фаҗига икәнлеге иманына иңгәнчегә кадәр.

Ләкин мине аның таләпчән көр күңеллеге биләп алды. Ул мине җиңде. Шулай да каршылык күрсәтә һәм ирексезләвенә буйсына алдым.

— Мине бер авыру кеше көтеп ята,— дидем мин.— Ул катлаулы операциядән соң яшәү омтылышын югалтты. Чөнки шуннан соңгы тормышы тереклек итүгә генә кайтып кала. Минем күз алдымда бер тормыш картаеп ята. Аңлыйсыңмы син шуны?

— Күпме дәвалыйсың инде аны?

— Бер атна.

— Иртәгә дәвам итәрсең. Ярты сәгать кенә нәрсә ул? Бар, саубуллаш та чык. Мә, ике лимон бир.

Минем ул унтугыз яшьлек авыруым сәгатьләп терелә башлаган иде инде. Умырткасына операция ясадык, тик өзлегер дип шикләндек. Егет үзе дә шиңеп төште. Мин аңа бөтен кешелек тарихын ачып бирдем, күбәләкнең уянуы, яңадан яши башлавы мисалы белән үлемнең бәләкәй нәрсә икәнлеген күрсәттем. Рухи үлем күпкә яманрак. Мин, донор сыман, яшь егеткә үз дәрт-дәрманымны иңдердем. Әгәр дә елга булсам, үз суымның кимүен, инде әнә елга төбендәге таш-түмгәкләр дә күренә башлавын күрер, сизәр идем.

Әлбәттә, ярты сәгать әллә ни хәл итми-итүен. Хәзер аеруча. Әхмәт машинасын гаражында калдырды. Без таксига утырдык та «Нарат» рестораныңа таба җилдердек. Җәһәннәм тишегенә. Әхмәткә иркенлек, очыш, хәмерле җилкәнсезлек, тантана кирәк иде, ахрысы.

Мин теге авыру егет тормышы өчен көрәштә җиңеп чыккан идем инде. Таушалдым, көчемне соңгы мыскылына кадәр сарыф итеп бетердем сыман. Минем биологик кырым — бөтен барлыгым, бар булганым — бал сыман, әлеге егетнең яшәү кәрәзенә агып бетте. Мин ул бер йодрыкка тупланган биологик кырның барлыгына һич шикләнмим. Ә Әхмәт исә, җиңүче кыяфәтендә, кичке гадәти җылылыкка, шома юлга соклана иде.

— Мине әрләмә инде,— диде ул. Тик син, шайтан алгыры, чыннан да күрәзәче икәнсең. Күзең очлы. Сине нык тыңларга кирәк.

— Ә нигә киресенчә кыланасың соң?
— Нигә дип... җиллатеп барырга яратам мин! Әйдә, бер сыйлыйм әле.
Керә-керешкә диярлек, без фужерны мылкытып салып, коньяк эчтек. Кан бенгал уты шикелле кайнап, чыжылдап яна башлаган кебек булды. Шул мизгелдә үк бар мәшәкать, кайгы таралып китте. Безне канәгать бер кәеф биләп алды.
— Мин зур бер бәхет иясе булуымны көтәм!— диде Әхмәт көр тавыш белән.
— Ниткән бәхет?
— Ул Кибернетикага кагылмый.
Ул әйткәнгә төшенеп җитә алмадым. Билгесезлек, чуалчыклык мине һәрчак югалтып калдыра. Соң, әгәр дә бер кеше гадәти чынбарлык пәрдәсен ертып чыккан да бераз кәефен күтәрергә уйлаган икән, моның зур бәхет белән нинди уртаклыгы бар әле? Җитмәсә, шуны бугазын киереп кычкыра. Ә тавык йомыркасы бик тиз ватылучан лабаса — моны оныту яхшыга илтми.
— Ниндидер бер коньяк хакына шәһәрнең җәһәннәм почмагына ыргылу кирәк идеме соң?
— Кирәк иде,— диде Әхмәт.— Ир кеше күктән иңгәнгә түзәргә тиеш ул.
— Айя өйдәме?
— Көтә. Диңгез буена җыена. Аңа бүтән берни кирәк түгел инде.
— Аны нигә монда ияртмәдең соң?
— Мин генә җитмиммени? Бәйләнмәле, яме?!
Без җырлап җибәрдек. Ни җырласак та, барыбер иде. Нинди җыр җырлаганымны оныттым инде — «Карурман», әллә «Утыр әле яннарыма». Ә кемнеңдер кырын караганы хәтердә. Мин ихтимал булган ул агрессорга ымлап:
— Кешегә җыр ошамыймыни? Кара, йөзе калмаган,— дидем.
— Ул күптәннән беткән инде. Төкер сәнә!— диде Әхмәт. Һәм, серле сандыкка тап булганын белгерткәндәй, тагын да кычкыра төшеп:— Мин тормышны яратам. Тугарылып яшәргә кирәк ул. Синең кара көеп утыруың кемгә хаҗәт? Машинамны сатам! Йә урманга илтеп ташлыйм.
— Андый җүләр тумаган әле,— дип көлдем мин.
Әйләнеп кайтканда да мин ни килеп чыкканына төшенмәгән идем әле. Каршыга утлар йөгерә, барган көйгә машина ишеген ачып, урманга кереп китәсе иде дә тирән йокыга таласы иде...

Карт сырмасын өстеннән төшермәде. Кәефе көр кебек күренә иде.
Сәгать уннар тирәсендә кыз аны йөртергә алып чыкты. Карт, каядыр ашыккан төсле, әле тыркылдабрак барды, әле тигезлеген югалтканын сизеп, капылт тукташтыргалады да, йөрәген тынычландырырга теләптер инде, авызын ачып һава сулады. Аннары акрын һәм сак кына итеп аягын җирдән аера да басасы урынын билгеләп куя, уңышлы адымы саен бала сыман куангандай була, горур кыяфәттә башын чөя — шулай итеп, яшәгәненә шатлана. Ә теге оныгымы, туганнан туганының кызымы, чак кына алга чыгып һәм аннан бер карышка да аерылмыйча, аны сабыр гына алга әйди, тик һич ашыктырмый иде. Сүз сөйләшмиләр, фикер уртаклашмыйлар — барчасын сәяхәт ахырына калдырып торганнар, хәзер исә бөтен игътибарларын болдыр белән капка арасын ничек тә сөрлекмичә, хәвеф-хәтәрсез үтүгә, кире кайтырга җитәрлек көч-әхвәлне саклауга биргәннәр булса кирәк.
Минем Тяпам, башын иңбашына борып, рәхәтләнеп йоклап ята. Бөтенләе белән җиңеләеп, таралып киткән, туктаусыз йөгерүдә үткән чагындагы ару-талчыгулары язылa. Ул тук, җылыда ята, аны беркем кумый, йокысы тирән, тыныч. Аның өчен моннан да зуррак уңышка ирешү буламы соң?
Ә мин карт белән кызның сүзсез сәяхәтен болдырдан күзәтеп утырам. Аларга күренмимдер. Гомумән, мин әллә бар, әллә юк — аларга барыбер ич.
Вакыт талчыгып кына ага да ага. Әйтерсең лә учындагы ком бөртекләрен санап утырган бер малай-шалай шунда. Кая ашыксын соң ул?...
Веранданы бикләдем дә койма тактасын аралап кына юлга чыктым. Таныш сукмак буенча чокыр төбенә, аның җылы кочагына төшеп киттем.

Шундук агачлар арасында күмелеп калдым. Монда һәр ботак качып кына күз йокысына кереп бара, әйтерсең наркоз тылсымына бирелә. Җилсез тынлык дымсу һавада эреп беткән. Кайдадыр тын гына су шаулап тора. Бөтен яктан тынлык белән уратылган хәлдә калсаң да, чокыр төбеннән тормыш җилләге ачыграк күренә кебек. Чөнки монда үз уйларың белән генә каласың, ә уйларга киртә куеп булмый ич.

Мин тагын, сагыз исенә сөенә-сөенә, текә ярда яткан нарат кәүсәләрен һәм ботакларын җыярга тотындым. Ә кинәт яңгыр ява башласа, дип уйладым. Шундук күршеләрем дә искә төште. «Алар янына беркем килми. Беркемне көтмиләр дә!»

Авыл кешесенә биргесез рәвештә, тапкан агачларымны сөйрәп киттем. Бабамның арба янында төшкән сурәте күз алдыма килде. Маңгае тулы җыерчык, карашында күтәралмаслык арганлык галәмәте, тирәсендә сарык көтүе. Без, исәнләшкән шикелле, беравык бер-беребезгә карашып торган сыман булдык.

Мине арттан:

— Әй, карале! Ашыкма әле!— дип туктаттылар.

Әйләнеп карасам — урманчы. Күзен кыса төшеп текәлгән.

— Син югартыннанмы?— дип сорады ул дачалар ягына ишарәләп.

— Шуннан шул,— дидем мин.

— Син урманга тимәскә дигәнне белмисең мәллә? Карыйм, карыйм — эзләнә дә эзләнә. Мин бөтен нәрсәне шәйлим, белдеңме?

— Урман түгел ич бу!— дип, утынымны җиргә ташладым.— Үзегезгә булсын соң алайса.

— Ә штраф чәпеп куйсам?

— Тик торгандамы? Әнә күпме агач череп ята.

— Анда синең эшең юк. Җир үстергән дә, җир алыр да. Бәлки монда берәр заповедник корырга ниятлиләрдер! Акылың үзеңдәдер ич?

— Монда нинди заповедник булсын ди?

— Бар, юлыңда бул. Бер юлга калдырам. Ә берәр учак ягып җибәрергә уйласаң? Монысына инде чәпим дә чәпим, аң бул... Кая, тартырга бир әле.

Күрәсең, сәбәпсез-нисез бәйләнүе үзен дә туйдыргандыр. Көйрәтеп җибәрдек. Урманчының йөзе кызгылт иде. Күреп торам — тыны кысыла моның.

— Беләсеңме, пионерлар аптыратып бетерде. Аларны инде элэктерәм димә, аягың калмас. Рәхмәт төшкере, әле дә ярый укулары башланды. Исәпләре-саны юк бит аларның, кырмыска инше. Бөтен урманны таптап бетерделәр. Ә агач, хатынынынан шүрләгән ир сыман, уттан курка бит ул.

— Хәзер монда кеше юк инде,— дидем.

— Ә штрафтан шикләндеңме соң?

— Яратмыйм— дид м мин.

— Нәрсәне?

— Менә шулай кукыраючыларны. Мондый хурлыкка эт тә чыдамый.

— Кыю кыланасың син. Ә минем куркытыр нәрсәм дә бар. Шүре җибәрергә дә күп сор массың.

Ул кискен хәрәкәт белән бил каешына кыстырган яңа, ялтырап торган балта чыгарып күрсәтте.

Әллә нишләп киттем. Каян килгән хуҗа!

— Сезнең күкрәгегездә бака бар икән,— дидем мин тыныч кына.— Күкрәк бакасы дигән авыру моннан зарарсызрак. Сезгә каты кычкырып сөйләшү бик зыянлы. Дәваланырга кирәк. Саф һава гына сезне алалмый. Үзегезне юкка бетерәсез.

— Врач мәллә син?

— Врач шул.

— Кара сана, ә?!— дип, урманчы сызгырып ук куйды.— Ә миңа ни эчәргә кушасың соң?

— Аракыны әзрәк эчәргә кирәк, ә күбрәк — кайнар сот. Су үсемлекләре чәйнәсәгез дә ярый, алар йодалы була. Чи килеш чәйнәсәгез, агуланмассыз. Бер очтан күл дә чистарыр.

— Тинтәк син, белдеңме? Микстураларым җитәрлек минем.

— Мин аны әйтмим ич әле,— дип елмайдым.— Сүз нервыларны саклау турында.

— Гәп корырга керермен әле. Күкрәгемне тыңлап карарсың. Алып куйганың юктыр ич?

— Кахетия шәрабым бар.

— Кая булышыйм әле үзеңә. Алайса мин сиңа моның ише ботак-сатакны йөге белән китереп ташлыйм. Әйт кенә. Күтәрдекме?

Бая ташлаган агачларымны күтәреп, урманчы белән янәшә атлап киттек. Әйтерсең лә гомеребез буена аерылгысыз дуслар, әле генә әрләшкән дошманнар түгел.

Усак яфраклары лепердәшә иде. Сазлык үләннәре тармак-тармак чәчәктә утыра. «Кешегә бер-берсен сак кына тыңлау да җитә бит, ә?»— дип уйладым мин.

— Мин Калистрат Ефимович булам,— диде урманчы.— Ә син?

— Ил,— дидем мин.— Илтазар.

— Мин дә синдәй баскынны татардыр дип уйлаган идем. Ярар соң, танышттык дип белик.

Бер авыздан дигәндәй урманны яңгыратып көлеп җибәрдек. Ерактан ук түбәндә яткан күлнең шадра йөзе күренә иде.

— Ул күлне бүрәнәләрдән чистартасы иде бит,— дидем мин.

— Бала-чага тагын тутыра аны. Гайрәтләрен кая куярга белмиләр.

— Тиздән суы сасып чыга инде. Җәл бит.

— Миңа калса, хәзер бөтен дөньясы җәлке. Бөтенесенә ничек кул җитсен?

Койма буена хәл алырга туктадык.

— Сараең минем кесә хәтле генә икән. Ярлы торасың.

Утынны сарай ишеге төбенә ташладык та учыбыздагы тузанны каккаладык. Аннары мин Калистратка ишекне ачып куйдым.

— Әйдә, кунагым булырсың.

— Их, анасын корт чаккыры!— дип куанды Калистрат.

Тяпа аңа муен йоннарын кабартып өреп алды.

— Ыржайма әле! Бу теге эт өереннән түгелме соң? Мин аларны картечь атып куркыткан идем инде. Бусы кайчан килеп чыкты тагын?

— Бүген.

— Сыендыргач яхшы инде.

Болдырга ике стакан белән башланган шешә чыгарып утырттым. Калистратка — тутырып, үземә гәпләшерлек кенә салдым. Бер күзен ачык калдырган килеш, Тяпа тагын йокларга ятты.

Көрнәп куйдык та шартлатып алма уртладык.

— Мин иртә таңнан бирле йөрим инде,— диде Калистрат.— Аяк калмады. Эчү эстәп йөри дип уйлама тагын. Нинди генә комсыз булсаң да, аны эчеп бетермәле түгел. Ул кешенең каберен дә күмәргә җитәрлек. Инде туры килгән икән кем әйтмешли, кыстатып торган юк инде.

— Мине дә йокы алмады,— дидем мин.

— Нинди кайгыга тарыдың?

— Болай гына... Башны ташка орырлык түгел.

— Очрашуыбыз файдалы булды әле. Адәм баласына очрашуларсыз ярамый шул,— диде Калистрат.— Мин яшь вакытта ничектер бер бүре белән йөзгә-йөз калган идем. Теге мәхлук юлга утырган да ач икәнен белгертеп тора. Биштәремне ачып күрсәтергә туры килде. «Менә, мәйтәм, ипи валчыгым да юк. Ә үземне ашарга мин сиңа ирек бирмим, дим. Бар, юлыңда бул». Аңлады бит. Качты. Кайвакытны адәм баласы гына аңламый ул... Ә хәзер дә шундагы курку йөрәк астын кымырҗытып тора. Бүре очратып, аның күзенә багу уен эше түгел ул. Ә ул ялгызы гына булмаса? Кулда берни юк, мылтыкны әйткән дә юк. Җитмәсә сөяккә кадәр туңган,— дигәч, ул бер мәл тынып торды, иелеп этнең башын сыйпады.— Токымлы эт бу, белеп тор. Шушындый этне ни йөзең белән ташлап китмәк кирәк? Ә моның белән

бергә үзләренең ярты йөрәкләрен дә ташлап киткәннәрен белмиләр, аңгыралар. Шулай ярыймы инде, йә?! Җаның юк икән, тотма инде.

Тагын берне салмакчы идем дә Калистрат стаканга учын каплады.

— Җитте, җитте. Сыйладың, рәхмәт. Иртән иртүк койма буена утын китереп аударырмын. Миңа юл уңай гына ул. Кирәк булсам, мине урман хуҗалыгында табаласың. Яхшы, хуш иттек,— дип, ул минем иңбашымны какты да кочаклап ук алды.

— Тикшеренәсең килсә, килеп чык,— дидем мин.

— Карармын тагын. Ә чынлап уйласаң, кирәге юк инде. Ходай чакырган вакытта теге җиргә генә ничек тә җителер. Язмышка язганнан качып кына котыла алмассың. Ул сиңа бүре түгел. Үзең исән-сау тор. Сиңа мохтаҗлар күп.

Калистрат, көтмәгән-нитмәгәндә очраган яхшы күңелле кеше, шулай дип китеп барды.

Кичкырын, мичкә ягып җибәрер алдыннан, мин Тяпаны су коенырга алып төшеп киттем. Сабын, мунчала эләктердем.

— Без бер эшне эшләргә онытканбыз ич әле,— дидем мин аңа. — Син байтак тулгангансың. Юынмый ярамас.

Капка төбендә нигәдер артка борылып карадым: күрше кызы, чиләкләрен шалтыраткалап, болдырлары баскычыннан төшеп килә иде. Үзем дә сизмәстән, аны кулымны болгап сәламләдем. Йөзенә елмаю чаткысы кунган иде дә... шундук юкка да чыкты. «Бу ниткән яңалык тагын?» — дип гаҗәпсенде бугай.

Ул яулык япкан иде. Тыгыз итеп төймәләнгән курткасы ипле генә итеп күкрәгенә яткан. Гомумән, ул бүген үзен бик ышанычлы кыяфәттә тота кебек.

Тяпа шатланып туймады. Койрыгын тырпайтып, алдан тыркылдый. Килгән шәпкә суга да кереп китте, яр буенча чабып йөрде. Дәшеп алдым да суга таяк ыргыттым. Тяпа йөзеп китте. Әйләнеп килгәч, минем аяк турысына шул таякны китереп салды.

Мин инде чишенгән һәм сабынымны әзерләп куйган идем. Тяпа үзен юганга тамчы да карышмады. Аңа хезмәт куюым, сыртларын шапылдаткалавым, сыйпавым, йонын бармакларым белән таравым гадәттән тыш тостә, күрелмәгәнчә ошый иде булса кирәк. Мин аны борыныннан койрык очына тиклем сабынлап юып чыктым. Тяпа күз алдында ябыгып киткән шикелле булды. Шуннан соң мин теге ботакны яңадан суга ыргыттым. Эт өреп җибәрде һәм бер йомгак сабын күбеге булып, елгага ташланды. Артыннан аксыл эз сузылып калды.

Аннары мин аны тагын тотып алдым да бик яхшылап ышкый-ышкый юдым. Ул гел ырылдап торды. Ниһаять, азат ителгәч, озаклап кагынды.

Шуннан соң үзем юынырга тотындым инде. Мунчала белән тәнем бурлаттай кызарганчы уындым. Башымны сабынлаганда эт ни өчендер өреп куйды.

Яр буенда һичкем юк иде. Су өсте шома, каралып тора. Сикереклап йөгереп килдем дә суга чумдым. Су астыннан байтак йөзеп бардым. Монда салкынча сафлык, колакны кытыкларлык тонык шау хөкем сөрә.

Җәһәт-җәһәт йомшак битъяулыгы белән сөртенгәч, тиз генә спорт киемемне, кроссовкамны кидем. Ә йөземне күтәрсәм, шаккаттым: бер агач төбенә җайлап утырган теге кыз гаҗәпсенеп миңа карап тора иде.

## 4

— Ә без сезнең белән күршеләр бит, дияргә ашыктым.— Сез кем атлы?

— Гүзәл,— диде кыз.— Бер дә тынмыйсызмыни?

— Чыдарлак.

— Утын өчен рәхмәт.

— Кирәк — ташырмын. Борчылмагыз.

— Бу эт каян килеп чыкты?

— Таптым инде. Юаш ул. Кушаматын Тяпа дип куштым. Ә үзем Ил атлы. Бабагыз черем итәме?

— Мин һава суларга гына чыктым. Кайчакны сагыш баса.

— Очрашкалап торыйк,—дидем мин.—Нигә читләшергә? Хәзер мичкә. ягып җибәрәм.

— Мин дә яктым.

Ул торды да күлмәк итәген төзәтеп куйды, хәрәкәтләнеп алды. Тик торырга күнекмәгән, күрәсең.

— Ул сезнең кемегез була?—дип сорадым мин карт турында.

— Соңрак әйтермен. Алай-болай гына түгел ул. Без монда күптән килергә уйлаган идек. Мәшәкать күп. Бу айны шушында уткәрергә исәплибез. Ничек тә сузарбыз әле. Аннары күз күрер. Иртәгә базарга барып киләм. Ә менә ялгызын калдырып торырга шикләнәм.

— Мин монда ич. Күз салгалармын. Аңа нindirәк ярдәм кирәк?

— Ул бик карт. Берни ишетми.

— Врач мин.

— Йа Ходай! Уңдык бит әле! Тик без үз-үзебезне карарга күнеккән инде. Аның бар чире шул картлык инде.

— Кирәгем чыкса, шәһәрдә дә рәхим итегез.

— Уйлап карармын.

— Тартынмагыз. Без күршеләр бит.

Сөйләшә-сөйләшә без сукмак буенча ауган бер каен турысына күтәрелдек. Ул бөтен киңлеге белән үзе үскән чокырны тутырып тора иде. Төп буеннан черегән җирән кырмыскалар тутырган иде.

Бу каенның үлеменә күптән түгел генә дулап киткән ачы җилләр сәбәпче инде. «Үлеме» дип, арттыру булгандыр инде, ләкин мин дөрестән дә шулай уйладым. Үз агачы черегәч, аумый нишләсен соң? Ә шикәр шикелле кайрысы ап-ак иде. Ябалдашы да тере... Мин аның җирне шаулатып, тирән бер ыңгырашу белән ауганын күз алдыма китердем.

— Кызганыч,—дидем мин.—Хәзер аның кемгә дә хаҗәте юк инде. Кисеп яксаң гына. Барыбер череп бетә.

— Әллә ничек бит. Кул күтәрерлек түгел.

— Череп әрәм булганын көтеп утырыргамыни?

Мин Гүзәл белән Тяпаны капкадан алга уздырдым. Дача җире буш, шуңа күрә моңсу иде. Кешесез калган дача уртасыннан, кулын сукырларча алга сузып, көзнең узып барганы күренә шикелле.

— Кешегә әллә ни кирәк түгел,—диде Гүзәл.—Бер көз дә җитә. Минем бабай шулай ди. Йоклаганда ул күзен йоммый да кебек. Кайчан якын килсәң дә, карап ята сыман. Аңа инде тормыш та йоклау сыман гына тоеладыр. Күп нәрсә башыннан кичергән кеше... Ярый, мин кереп китәм. Кич җитте.

Уйга баткан көйгә, бар дөньядан ваз кичкәндәй, мичкә ягып җибәрдем. Кара төтен чыгарып, каен тузы бик тиз кабынып китте, йөзгә ялкын кайнарлыгы китереп бәрде. Мин Гүзәл хакында уйландым. Сәер төстә кешегә ышануы, шул ук вакытта бер мизгел дә сагаюдан туктамавы белән ул кыр кәҗәсен хәтерләтә иде. Ул яклауга мохтаҗдыр, шул ягы белән үзенә тартып тора да. Ә мин үз-үземне нindidер хатын-кызга гына хас усаллыктан араларга тырышкан булам тагын!

Эт улап куйды. Чыгып карасам, гөлҗимеш куагы төбендә Гүзәл елап тора.

— Ни булды?

— Ул егылган, ә минем күтәрергә көчем җитми. Күтәрергә дә кушмый, карыша. Саташып ята. «Печәндә ятып торыйм әле, кузгатма»,—ди. Куркам мин.

Картны икәүләп караватка менгереп яткырдык. Ул мыскыллаган шикелле елмая иде. Күз карашы аныk. Киң учлары юрганда селкенмичә дә ята. Йөрәк тибеше тигез, көчле. Ә менә бу катып калгандай елмаюы, туп-туры карашы... Ни күреп ята икән? Саубуллашып калырга көчәнгән кебек.

Яңагына алсулык йөгергән, гүя тегеннән — өзелә башлаган гомер читеннән, югала барган хәтер көзгесеннән килеп ягылган төс.

Үткәннәреннән карт әкренләп кенә кайта башлады. Бүтән кайдан әйләнеп кайтсын ди инде ул? Анда бүтән ис-томнар, бүтән кояш хакимлек итә. Мин кинәт ни өчендер аның бар нәрсәсе әнә шул үткәннәрендә түккән көче белән бергә калган инде, дип уйладым. Тетрәнү-шатлыкларны кире кайтару мөмкин түгел. Ул шунда әйләнеп кайту хакына гына сулыш та ала инде. Менә бу сине кечерәйтеп күрсәтергә теләгән елмаюы да шуннан.

Аның маңгай сөяге калкып торган урыннарда агарыңып калды. Күзен йомгалап алганда күз кабакларының тиресе җәелеп бетмичә, бөгәрләнеп кала иде. Аның бөтен тәне яшәүдән һәм каршы торудан арыган иде инде.

— Кунак бар икән,— диде карт үз кызына.— Мине күтәрә төш әле.

Ул тагын да агарыныбрак китте, иренен кысып, нидер йота кебек иде. Ул нииндидер уенда тукталмакчы була, ләкин ихтыярын моңа туплаудан гаҗиз. Як-ягына карангалады. Үзенә сузган сулы чынаякка, таяныр нәрсәдәй, ике куллап ябышты да вак йотымнар белән эчә башлады. Ул күзгә күренеп тынычлана башлады.

Гүзәл аның арык иңбашын сыйпады. Ул яткан урыныннан эри башлаган боз кантарына охшап калкып тора иде.

— Ул сезне аңлый алмый, минем аша сөйләшегез,— диде аңа Гүзәл.

— Иптәшне дә сыйла. Безнең аңа бирердәй нәрсәбез бар әле? Кура җиләге суы белән сохари бир. Минем аны ишетмәвемне, шуңа күрә берни сорашмавымны аңлат. Саңгыраулар күп сорашмый. Берни дә сорашмауның үз яхшы яклары бар аның. Үз-үземне ишетүем житкән. Өстә тормагыз, яме? Үз әшегездә булыгыз. Минем монда булмавым да ихтимал иде. Ә сез — яшьләр, яшьләрчә кыланыгыз. Шулай тиеш. Әйе, үз әшегездә булыгыз.

Кулын тотып, йөрәк тибешен санадым. Ул гаҗәпсенеп калды, ләкин эндәшмәде.

— Казаны казан кебек кайный, — дидем мин Гүзәлгә.— Тибеше яхшы. Берәр чит нәрсә хакында уйлансын, җәлеп итегез. Ә мин аш куярга китәм.

Кара күзле Гүзәл моңсу гына елмаеп куйды. Мин дә елмаймый булдыра алмадым. Йөрәгемне аңа карата ягымлылык биләп алды. Мин гадәттәге ялгызлыгыма таба ашыктым. Күңелемне алар өчен борчылу һәм моңа кадәр кичермәгән бер хис биләп алды. Әни дә янәшәмә килеп баскандай булды, бөтен кыяфәте мәңгелек курку, шик һәм яктылык белән тулган, әнә чир пәрәвезе каплаган йөзе дә төсмерләнде шикелле: «Ә без синең белән очабыз да очабыз!» — дигәненә үзе дә куанып бетмәгән сеңлемнең яп-яшь килеш һәлак булуы да искә төште: һәм шушыңа охшаш, һичнинди сүз белән тасвирлап булмастай башка кичерешләр дә мине үз өермәсенә суырып алды. Әле килеп җитмәгән күк күкрәүне ерактан ишеткән сыман, Гүзәл белән нииндидер якынаю буласын сизеп алдым. Һәм моннан һич кенә дә өрекмәдем. Гүзәлнең дә карашын һич яшермичә, ыгы-зыгыланмыйча тыныч кала алуыннан аның үзенең дә әкрен генә ерактагы яңгыр шавына колак салуын, шуңа каршы барырга әзер икәнлеген сизеп алдым.

— Мин сезнең янга бераз соңрак керермен,— диде ул.— Керергә ярыйдыр ич, әйеме? Минем элегрәк шулай язган булса, нишләрмен дип котым оча иде. Утраудагы шикелле яшибез бит. Бактың исә гап-гади нәрсә икән.

— Көз шундый нәрсә инде ул,— дидем мин.— Көтәм.

Тынлык урнашты. Тәрәзәне агач ботагы тырный иде.

Чынлап та, җиргә тыныч һәм җиңел яңгыр җәелде. Әлбәттә, күк күкрәмәде. Офыктан офыккача соры дымсулык таралды.

Калистрат нәкъ вәгъдә иткәненчә эшләде.

Гүзәл шәһәргә кайтып китте. Автобус тукталышында мин аны төштән соң — сәгать дүрттә каршыларга тиеш. Ул шул вакытка өлгерергә тырышам, диде. Моңарчы аның бар кылганы агач көрәк белән ашлык ишкән сыман гына булды, гел вакыты юк, ә хәзер нидер килеп чыккан ахрысы. Ул ни икәнен үзе дә белми.

Шулай итеп, ул минем белән саубуллашты да кулын болгап китеп барды.

Вакытны тизрәк уткәрергә теләп, мин каравылчы Сәет янына барырга уйладым. Ерактан ук аның бакчада нидер караштырып йөргәнен күреп алдым.

— Хәлләр ничек, Сәет?

— Минем хәлләр дусларны сагына.

— Кунаклар көтәсең мәллә?

— Мин беркайчан да килмәүчеләрне көтәм. Әнә утыргыч — утыр.

Тәбәнәк буйлы булса да, утырган чагында ул ничектер көчле бер кеше сурәтендә иде. Күп сөйләшми, терсәкләре белән тезенә таянып, үзалдына утыра бирә.

— Бүген минем ял көне,— диде ул.— Озаттыңмы соң?

— Озаттым.

— Куян табып бирә алам. Ун тәңкә. Кирәкме?

— Кирәк,— дидем мин.

— Яхшы, яхшы. Әйдә, киттек. Ярты сәгатьтән куян синеке булыр. Алма ал. Күпме кирәк. Гел ал, яхшыларын сайлап ал. Сыйлан.

Мин акча алып килеп бирдем дә алма җыйдым. Ул китеп барды. Миңа куян кирәген каян белгән икән диген. Ә алмалары шәп, шәп...

Ул бик тиз әйләнеп кайтты. Нигә икәнен белмәдем, әмма авызы колагына җиткән кебек күренде.

— Менә ул!— диде ул төенчеген югары күтәреп.

— Рәхмәт,— дидем мин.

— Кирәк нәрсәңне сора, тартынма. Белмәсәң бел, күңелсез миңа. Ярый, мин киттем. Тернәгем бар микән,— тикшереп кайтыйм әле. Бәйрәм бүген!— диде ул һәм кинәнеп елмаеп җибәрде.

Мин, ахмакларча калуымны искәреп өлгергәнче:

— Нинди бәйрәм?— дип сорадым.

— Кан кайный әле, кайный. Күмер сорамый.

Тяпа миннән калмый ияреп йөри иде. Юындырганнан соң аның йоны күпереп, барган шәпкә уйнакларлык булып калган. Аңа чыдый алмаслык рәхәт иде булса кирәк.

Каршы йортта тып-тын иде.

Гүзәл әйткәнчә, карт бар дөньядан үз хикмәтләре хакына ваз кичкән, ахрысы. Мондый хәл аның өчен гадәти нәрсә икән. Тамагы тук, аягында кием итек. Гүзәл аны иртән яхшы ашатып китте. Куе сөт банкысы ачып калдырды. Карт ниндидер паек ала икән, бар тотнаклары шунда. Ул ризыгын чәйнәргә яратмый. Мине бимазаламагыз, дигән була, кичкә тикле ялгызын гына калдыруларын аңлап алды бугай. Бишкә кадәр кәнәфидә черем итә инде. Аның теләткечен сузып салып та була. Паралич суккан шәттә ничек тә өлгерерлек. Шундый сак кеше инде, бөтен яктан ышкылган, нинең ни икәнен яхшы белә. Нәүмизләнә белмәскә аны кырыс тормыш үзе өйрәткән. Дөньядагы бар нәрсә хакында аек фикер йөртә, үз дигәнен раслый ала. Ул фәкать тормышка һәм үз-үзенә генә таяна, ышана. Калганнарын сөйләүне ул аннарыга калдырган, аннарыга. Сикереклэп йөрүне күптән ташлаган инде...

Сәет биргән куянны мин алма, суган һәм бәрәңге көрнәп пешердем.

Ул арада идәнне юып чыгардым, аны-моны җыйнаштырдым. Көзгене дә калдырмадым.

Талдан үргән ике урындыкны янәшә китереп куйдым. Транзистордан тын көйләр агылыр, шәмдәлдә шәмнәр янар, тәрәзәләр көзге эңгер-меңгергә карап торыр...

Кешеләре булмаган бакчаларга кереп, бер кочак чәчәк җыеп кердем. Аларны төрле савытларга утыртып чыктым. Фәрештәләрне җыя алсам аларны да чакырып алыр идем дә бит... алар үз вакытлары белән үзләре генә килеп чыга шул. Үз-үземә сокланып туя алмадым: карасана бәхетле көтү дигәндә әлләниләр кыландырып була икән. Гомумән, үзеңә яраклаштырып файдаланыйм дигәндә вакыт дигән нәрсә дә сиңа баш ия икән бит, әй!

— Менә шундый-шундый хәлләр,— дидем мин Тяпага.— Әйттем исә кайттым, мәгәр ул мин куйган тырышлыкны зур илтифат белән күзәтте.— Дөньяны очраклылык тотмый ул, очраклылык зур алдашу, ул кирәк дигәннәрне барып чыкмаучыларны гына аклый.

Шундый купшы сүзләр кулланcам да, мин әллә электән үк, әллә хәзер генә вакыйгаларның барыбер ниндидер бер максатка корылганына, туры килүләрнең очраклы булмавына ышандым. Әнә, кесәмдә дача ачкычы, карт белән кыз, адашкан эт, миңа куян ите табып биргән Сәет, урман каравылчысы Калистрат, һәм, ниһаять, менә бу көз — һәммәсенең үз мәгънәсе, үз табигыйлеге, үз агымы бар. Кеше дигәнең: «Тормыш матур һәм гаҗәеп бер нәрсә ул!» — дип, нәкъ менә шушындый мизгелләрдә әйтәдер дә инде. Вә мондый чакта ул үз-үзен һич тә алдаламый инде!

Мин Калистрат китереп аударган һәм үзем җыеп кайткан утынны сәгать чамасы балта белән чапкаладым, юанракларын ышык урынга кертеп куйдым. Беркавым үземнең эш эшли алганыма да сокланып тордым әле: бабамның каны миндә җитәрлек дәрәҗәдә кайнап ага икән әле, дип уйладым. Бу нәрсә теләсә кем кулыннан килерлек түгелен мин бик яхшы белә идем.

Аннары без Тяпа белән тамак ялгадык. Куянны калдырып тордык әле.

Мин үземнең тулы бер азатлык хисен кичерүемә шаккатмадым, аптырамадым. Минем бердәнбер сыеныр урыным, сусавымны басар җирем булган клиниканы исемә дә китереп карамадым ичмаса.

Менә бит, көз җитте дә аулак бер урынга китереп чыгарды, шуннан соң китте дә китте. Моңа тиклем богаудагы шикелле яшәгәнмен икән лабаса: өй — клиника — тагын өй. Шуннан ары бер карыш та читкә атламагаңмын. Шуңа бар җаным-тәнем белән күнеккәнмен. Ял итүнең ни икәнен дә белмәгәнмен. Бөтен нәрсә кул астында — тагын ни кирәк инде? Хатын-кызлармы? Кем әйтмешли, матур җан ияләреме? Яшерен-батырын түгел, алар минем яныма килгәләмәделәр түгел анысы. Тик аларның берсе-бер минем өчен җаннарын атып тормады. Ләкин минем беркайчан да суын югарыга чөйгән фонтан суларын эчеп, сусавымны басканым булмады әле. Боз кыйпылчыкларының җылы бәреп торганын тойганым булмады. Мин моңарчы үземнең кемгәдер кирәк булганыма канәгатьлек кичерә алганым юк әле. Мин кеше, фәкать кеше генә булып калуны өстен күрдем — бөтен хикмәтем менә шунда инде. Ясалмалык, гайре табигыйлекне минем моңа кадәр җенем сөймәде... Күз яшьләре хакында йә «ямьсез», йә «матур» дигәннәре юк ич әле — менә шуның ише. Мин ике кешегә җитәрлек кайгы-хәсрәткә тансыклаган идем бугай. Караңгыдан котылыр өчен бер ут чаткысы кирәк. Үземнең дөньяга шушындый теләкләр, таләпләр белән яратылганым өчен мин гаепле түгел ич инде... Үз җанымдагы үтәкүренмәле бушлыкларны мин үзем дә тиз генә белә, аңлый алмадым лабаса. Әнинең ни дәрәҗә картаюын, сынып төшүен күреп калганмын икән, бу нәрсә үземнең балачагымның һәм яшьлегемнең бер балкышы гына булмаган түгелмени? Ялгыз фатирында вафат булган әнине бер мизгел эчендә югалтуым минем җанымны актарган да салган иде. Минем җанымның шуны күрүдән коты очты. Төшенеп җитмәстәй нәрсәләр дөньяда күп инде ул. Бергә туры китерсәң, ут белән боз да югалып калыр иде... Шуннан мин аңладым: кешеләр бер-берсен шатландырыр һәм коткарыр өчен дөньяга килә дә.

Сигаретымны алып һәм көлләвечне җайлап, диванга кырын яттым. Тик миңа һичнәрсә кирәк түгел инде — шундук йокыга талганмын.

Ә миңа тормышның дәвамы гаҗәеп бер балкышлы төш рәвешендә җанланды. Авызым сумала әчесе белән тулган килеш чокыр бугазы буенча автобус тукталышына таба ашыгам, имеш. Кояшта кара янганмын, уй-мәшәкатьсезмен. Әллә кайдагы көтеп тору, кемдер вәгъдә иткән очрашу минем күземне дәррәү ачтырган, холкымны кырыс иткән. Әгәренки өлгерергә тырышсам, мине зур бер бәхет көтеп тора, имеш... Тик мин әллә нинди тау артында калганмын, йөгерәм дисәң, җылы һәм коры ком ирек бирми, мин каядыр үрмәлим һәм кире шуып төшкән саен еларга тотынам. Кызганыч һәм ярдәмчесез калган сурәттә, мин шул комга егылып ауныйм, бәргәләнәм, һәм беркем дә мине йолып ала алмый...

Котым очып уяныгг киткәнмен — соңга калынган! Әмма сәгать дүртенче яртыны гына күрсәтә булып чыкты. Теге тауның мине җибәрергә теләмәве тикмәгә булмаган: төштә мин сабый идем, ә өнемдә өлкәнәйгән кеше бит. Әнә шул өлкәнәйгән кеше төштәге теге малайны тотып торган да инде, кабаланырга кушмаган. Төшнең төш кенә булып калуы да куаныч бит ул.

5

Мин торган дача йортына килеп кергәч, аның исләре-акыллары китте.

— Карасана! Нинди чәчәкләр, йа хода!— дип башлады ул керә-керешкә үк.— Көнне көчкә үткәреп җибәрдем. Чабам да чабам. Ул халыкның күплеге! Автобуста буылып үләм дип торам, билләһи газим. Җитмәсә күпме букчам бар, акылдан язарлык. Ташлап калдырасыларым килде. Адәм мәсхәрәсе инде бер. Көтеп торыр, тын алыр идең дә... синең ничек көткәнең ирек бирмәде...

— Ә мин урманнан бер куян тотып алдым.

— Кит әле!

— Үзе чаба, ә үзе кыздырылган.

— Чын дип әйтәм: мине кемдер көтеп тора дисәләр, һич ышанмас идем.

Ышанычлы тостә «син» дигәнгә күчеп һәм чынын әйтеп, мин:

— Каравылчы Сәет сиңа дип махсус атап бер куян китереп китте әле,— дидем.— Бүген аның ниндидер бәйрәме икән. Хәтта кырынып ук куйган, шайтан алгыры. «Бу дөньяда бар кешегә яхшы булырга тиеш»,— дигән була.

— Син дөрестән дә миңа дип тырыштыңмы?

— Соң. Минем күптәннән болай итеп беркемне дә көткәнем юк инде.

— Шулай укмыни?

— Бәйрәм безгә дә язык түгел ул... Өйдә ни хәлләр соң?

— Килеп керсәм, сәгать төзәтеп маташа. Бар арыганымны юып алган шикелле булды. Казаны казан кебек кайный, диден бит әле? Күңелләрем күтәрелеп китте. Сәгать төзәтергә тотынгач, яхшы инде.

Гүзәл туфлиен салып атты да, аягын бөкләп, кәнәфигә менеп утырды. Иңбашына чәчәкле-чачаклы шәлен салган. Карашын күләгә басты, яктылык ачык муенына гына төшеп тора. Канат шикелле очып китәрдәй, кочып алырга хәзерләнгәндәй кулына игътибар иттем. Бармакларында кайчангыдыр яра эзләре.

Суыткычның түрендә пешереп тозланган баллы гөмбәле банкы бар иде. Айя үпкәләмәс әле дип, шуны тәлинкәгә салып куйдым. Шәраб бүлдем. Шәмнәрне кабыздым да утны сүндердем. Гүзәл һәр хәрәкәтемне күзәтеп торды.

— Өйрәнеп беткәнсең син,— диде ул.

— Исең китмәсен. Мин ялгызак кеше бит, күнегелгән.

— Бер үзеңме?

— Үземне санамаганда. Әйдәле, шушы көз хөрмәтенә берне эчеп куйыйк әле,— дидем мин.

— Кеше ышанмаслык хәл... Шәраб, шәм... Кайчандыр кемдер бу шәмдәл янында утыргандыр инде. Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник чакта, ә? Бер хатын белән ир... Әй, үткәннәргә салават!

Юка пыяла савыт эчендәге шәраб янып тора шикелле иде. Гүзәл, тәмен дә татып тормастан, тыныч кына эчеп куйды. Гөмбәләрнең иң бәләкәен сайлап, чәнечте дә тәмләп чәйни башлады. Нинедер исенә төшерде булса кирәк.

— Ул вакытта яхшырак идеме әллә?— дип сорадым мин.

— Инде фараз да кыла башладыңмыни?... Нигә дип инде?

— Күз алдыма килеп китте.

— Эх, доктор, доктор! Яхшырагы хәзер икәнен белмисеңмени?... Син үпкәләмә инде, мин үзебезгә кереп чыгыйм әле. Әтине яткырам да керәм, яме? Көне буена аякка басканы юк.

— Эти дисеңме?

— Белмәдеңмени әле?... Әз генә торып тор. Тиз әйләнермен. Синең белән күңелле булып китте әле, Илтазар. Синең исемең әллә ничек — корыч шикелле чыкылдап тора. Бая теге ауган каенны кисәбез дигәнеңә исем китте әле.

— Нәрсәсе ярамаган?

— Әз генә торып тор дидем бит инде,— диде ул соравыма игътибар итмәстән. Һәм кабатлап:— Күңелле синең белән, күңелле,— дип кабатлады.

Һәм сиздерми диярлек чыгып та китте.

Мин тәрәзәне ачып куйдым да тарта калдым.

Менә сиңа мә: Гүзәл, мин уйлаганча, теге картның ни оныгы, ни туганнан туганының кызы да түгел. Баскан җиреңнән тораташтай катып калырлык. Аның атасына ничә яшь икән соң инде? Сиксәнне узган булырга кирәк. Дәрт-дәрманы калмаган бит инде, баткан чакта саламга гына ябышып булмый шул.

Күкрәгенә тиклем төшеп җиткән куе сакаллы бер картка гаҗәпләнгән бер мәл исемә төште. Шул ук Көек авылында. Ул больницада бакчачы булып эшли иде. Туры, үтәли тишәрдәй карашлы, астыртын бер кеше. Бар белгәнегез тыз да быз мәшәкать, авыру да дәвалану, ә мин менә җирдә казынганга күрә сау-сәламәт, дигән шикелле, каш астыннан сөзеп, саран гына елмаеп йөрер иде. Атыбызны тилемсәк хатын Зойка карый, вак-төяк төяп йөри, артыннан кемдер ташлап киткән бер малай калмый иярә. Ул малайны шул бакчачыныкы дигәнрәк шик йөри иде, ә тегенең исе дә китми, әлеге дә баягы астыртын көлемсерәвен белә. Халык сүзе хак булган, күрәмсең: бакчачы аны ара-тирә төрлечә сыйлый, янынннан кумый иде. Зойка күзгә кырын чәчен җилгәреп, вәсвәсәләнеп үр кашында шул бакчачы Савелийның бо-лынга килеп чыкканын көтеп йөренде. Мине картның җирдә һич кенә казынмагандай ап-ак, дин кешесенекедәй кара эшне белмәгән кулы сәерсендерде. Бәлкем бу тойгыны аның эшли торган чиркәүгә якын гына йортта торуы көчәйткәндер, белмим. Менә шул — Савелий үзенә урын тапмыйча дигәндәй тулганган тилемсәк Зойка янына канатланып ашыккалый иде...

Ниһаять, тирә-юньне җанландырып, куаклар кыштырдап алды. Киенепясанып, Гүзәл килеп керде. Үзенең нинди була алганын күрсәтергә теләгәндәй, бусага төбендә туктап калды. Югары өеп төйнәгән чәче дә, муенындагы нәзек көмеш чылбыры, борчак-борчак сурәтле кофтасы, каптырмалы түфлие дә аны күркәм, ыспай иткән. Чәчәкле-чачаклы шәлен җилкәсенә салмаган, караңгылык аша җиңелчә генә йөгереп узган. Өй җылы, җиңелчә генә итеп бакчалар артындагы агачлар шаулап тора, караңгылык җәелгәннән-җәелә бара, ара-тирә электричка кычкырткалап уза, чокыр-чакыр һәм агачлар тынлыкны сизгер саклый иде.

— Ул миңа беләсеңме ни диде әле? Оялып киттем. «Бар, ул сине көтеп тора,— ди.— Миңа бу хәлең барыбер түгел бит. Кара, адашып кала күрмә. «Исем-акылым китте. Анысы, карап торуын-торсам йә, аклануым дип белер. Буйсынып яшәве дә гарык, әмма ачу белдерергә дә ярамый. Аның саңгыраулыгы мине каршы дәшмәскә күнектереп бетерде. Мин ул кабул итәрдәйләрне генә сөйлим. Аның хөкеме сүзгә карамый. Ул ис-тәмнәргә сизгер, шәп күрә. Нәзберек тә соң! Берәр хушбуйга тотындым исә, әле бу җирем, әле теге җирем авырта, дип тотына. Көлке инде бер!

— Адәм баласы нәрсәгә генә күнекми дә, ниләргә генә өйрәнми,— дидем мин.

— Ул минем бернәрсәдән дә курыкмавымны яхшы белә. Без аның белән йөз кайгы-хәсрәттә шикелле инде. Һәр уемны белеп тора... Син сал, сал, күп такылдавыма карама. Әзрәк башымны әйләндерәсем килә. Арыдым, талчыктым, бераз. Сине Алла үзе җибәргән шикелле булды.

— Сине дә,— дидем мин.

— Чыннан дамы? Шаяртмыйсыңмы соң?

— Нигә инде.

— Сөйлә, сөйлә...

— Ә куянга кайчан тотынабыз соң?

— Аннары. Сөйләш, сөйләш,— дип кабатлады ул түземсезләнеп.

Буам ерылып киттемени. Йөземә кайнар кан китереп бәрде. Бераз сәеррәк күренгәнмендер. Соңгы көннәрне әллә ниткән наз көтеп үткәрдем шул. Шуннан котыласым да килми.

— Язмышка ышанам мин. Безнең туры килүебез тикмәгә түгел, ахрысы. Юлыбыз кисешсен өчен әллә нинди хәлләрнең нәкъ үзенчә генә агышы кирәк булгандыр. Мине ялгызлык туйдырып бетерде шул инде. Бикләнеп ятуның кемгә кирәге бар соң аның, әйеме? Кеше хәсрәтен җиңеләйтәм дип, үземнекен кайгырта да алганым юк. Әйтерсең лә көчем ташып тора! Үз кайгымны белгән дә юк. Чирле кешеләрнең зарыннан башка һични ишетмим, күрмим шикелле. Күпләр таза тән, йөгереп йөртерлек аяк, каптырып алырдай кул турында гына хыяллана. Ә мин кешеләрнең җан сафлыгын, күңел көрлеген кайгыртам имеш. Көлке! Каршылыкларны җимерәм дип, үземнең рухым сынып бетте... Менә үз-үземне барлап чыктым да — җәрәхәтләрдән генә торганымны аңлап алдым. Әчтерхан чикләвеге сымак, җыерчыкларга әйләнеп беткәнмен диярсең. Шулай аягүрә кибеп йөрим,— дип, бер тын белән сиптердем генә.

— Әй, Илтазар! Хәсрәтем минем!— дип, Гүзәлнең кулы миңа табан сузылды.— Бу шәфкатьсез дөньяда без икебез дә япа-ялгыз икәнбез. Бер без генә дә түгел әле. Җирдә ни кыланганнарын карасаң, котың очар, билләһи газим. Күпме кеше кан коя, күпме ил ут эчендә. Ни җитми инде, йә?

— Син минем янымда булырсың,— дидем мин.

— Ә мин кем янында соң әле?— дип гаҗәпсенде Гүзәл.— Аңламассың.

— Кай җирен аңламыйсың инде аның?— дип борчыла калдым. Болай итеп гомеремдә дә ташлап китәрләр дип өреккәнем, шикләнә калганым юк иде.— Нибарысы утыз яшьне тутырсам да, калган гомерне эт оясына бикләнеп үткәрергә җыенып бетергәнмен... Кешенең нибарысы бер уч хәтле йөрәге бар инде, әйеме? Ә ул шуның кушуынча да яши алмый. Кемгәдер таянырга вакыт. Кемгәдер таянырга.

— Кирәк шул менә. Ничек кенә кирәк әле!— дип килеште Гүзәл.

— Минем үз хакыма гына яшисем килми инде.

— Аңга килим әле,— дип, Гүзәл башын иде.— Син мине бик аз беләсең ич әле. Бөтенләй белмисең. Уйларга вакытың бар әле, бар.

— Булмый инде,— дидем мин.— Җитәр. Мин сине көткән идем.

— Тоела гынадыр.

— Юк инде, юк! Малай-шалай түгел ич.

— Үкенмәссеңме соң?

— Уйламыйм.

— Тор, ишекне бикләп. Берәрсе тыңлап тормасын тагын. Бикләп үк куй.

Карышмадым. Тяпаны уятып, чыгарып җибәрдем. Йозакны бикләдем.

— Кил әле монда,— диде Гүзәл.

Янәшәсенә килеп басуыма, ул шәмне өреп сүндерде.

Калганы тансыклаганынча булды инде. Караңгылыкны әллә ниткән ажаганнар уйнагандай балкыш күмеп китте. Мин Гүзәлне иренем, сулышым белән назладым да назладым.

— Кыюмы соң мин?— диде ул.— Минем күкрәгем бәләкәй. Миңнәрем күп булса да, бәхетем генә азрак.

— Тәнең шома икән,— дидем мин.

— Берни сорашасың килмиме?

— Юк.

— Менә яхшы. Язмаганны кылып ташладык бугай.

— Язганын искә алмыйк инде.

— Сабыр итеп торсак та булыр иде дер.

— Аның сәгате кайда соң?

— Ашык-пошык инде. Теләсә кайчан чакырып кычкыруы бар ич. Мәрхәмәт чишмәсендә күз яше күп ул.

— Әллә ничек сөйләнәсең шунда. Төшенерлек түгел,— дидем мин борчыла төшеп. Әйтерсең лә ул менә-менә атылып чыгып китәргә тора.— Ашыкма әле.

— Буталдым да калдым инде. Монда мин үзем түгелдер шикелле. Кем икәнен үзем дә белештермим. Бөтенесен җылытып бетереп булмый ич ул.

— Син нәрсә инде! Үзеңне битәрләмә.

— Шәмне кабыза аласың. Бераз эчеп куй.

— Хәзер, сиңа да китереп бирәм.

— Җәлт-җәлт кенә. Булгач булсын инде алайса. Үз насыйбың үзеңә диләр ич.

Шәм ялкыны бии башлады. Шәраб белән кабымлыкны бәләкәй өстәлгә тездем дә аның янына илтеп куйдым. Аннары, шәмдәлне баш очыма күтәреп, аңа бактым. Минем мондый ап-ачык, чиста шәрәлекне күргәнем юк иде әле. Онытылып киткән сыман, Гүзәл йөзен стенага табан борды. Шуннан кинәт җәймәне иягенәчә тартып бөркәнде. Һич тә оялган булып кыланмады, өн-тавыш чыгармады. Яктырып торган күзен зур ачып, эндәшми генә миңа карап торды. Мин аның сулыш алуына кадәр ишетәм иде сыман.

— Менә шулай яратасым, яратыласым килә,— диде ул.— Ничек ярата алганнарын белдерәсем килде. Тиктомалдан. Ишелеп төшкән күк итеп. Кемнекедер буласылар килә. Мине бу сүз куркытмый. Тик моннан да зуррак мәгънәлерәк нәрсәләр дә бар бит. Әйтеп кенә бирә алмыйм.

— Тагын башладыңмы?

— Басып торма. Йә ят, йә утыр.

Ул, ябырылып, мине кочып алды. Ягылмыйча да диярлек, бармакларын битем буенча йөрткәләде. Тынычланып калдым.

— Миннән башка ничек яшәдең соң син, Илтазар?— дип уфтанды ул.— Өч көн элгәре бер-беребезне тамчы да белми идек. Шулай мәңге белмәвебез дә бар иде. Ашык-пошык кына килеп чыкты. Болай тиз сәлам гына явып бетә. Комсызлыкка күрәдер инде. Әйтерсең лә ахырзаман житкән. Ашыкмыйсы калган. Үз-үзебезне ташлап качкан шикелле. Башта сынашырга идедер, күнегергә... Нихәл итәсең, күңелсез ич. Ә монда шәм, чәчәкләр. Үлсәң дә кызганыч түгел... Ул минем әти түгел шул, җаным. Нигә әти дидемме? Безне минем әни ташлап китте. Ул миңа карагандa күпкә яшьрәк иде. Әни алдап-йолдап йөртмәде, бүтән кешегә чыкты да китте. Минем иярәсем килмәде. Тавыш-гауга чыкмады, кычкырышмадылар, талашмадылар. Әти үтә сабыр кеше... Әни китеп бару белән ишетмәскә әйләнде. Әллегрәк ул яман яла ягу корбаны булган. Сигез еллап югалып торган, әллә диңгез, океаннар кичеп йөргән инде... Әйләнеп кайтканда дөньяда мин булганмын инде. Белүемчә, исе китмәгән бугай. «Шул кирәк миңа!» — дигән ул. Моны искә-оска алырга бер дә яратмый. «Телдән ычкынган фикер ялган нәрсә ул»,— дип аңлатып маташкан иде. Шуның белән бетте. «Кирәкми, кызым. Әйе, бәләкәчем, кирәкми...» Хәзер әнә сәгать төзәтә. Аның бөтен җире авырта да, авыртмый да. Кайчагында: «Ә үткән вакытны төзәтеп булмый. Шул кирәк миңа»,— дип елмаеп кына куйгалый. Шунда мин елап җибәргәлим. Аңа ватык сәгатьләр табып бирәм. Ул минем өчен әти генә — ата түгел. Әни кайтып кермәкче булып ясканган иде дә, мин, кырт кистем: «Үлсәң, кабереңә дә бардык юк»,— дидем. Әни иң кирәкле нәрсәне аңлап житкермәде — тормышның нигә нәкъ менә тормыш икәнен. Ул әтигә хыянәт кылганына караганда да күбрәк нәрсәсен сатты. Менә шулай яшәп ятмыш. Алай да башны ташка орырлык түгел әле. Теләгәндә, бәла-каза да туган йортның ише кабул ителә икән ул.

— Хәтәр сүзләр сөйлисең син,— дидем мин.

— Эшлим мин. Син хәтта икебез дә бер үк исне сулаганыбызны да белмисең. Мин аптекада эшлим. Карап туйгысыз чиста тотам. Менә, бөтен яшәлгән нәрсә учка сыярлык. Ә сөйләп бетерим дисәң... Шунысы хәтәр булыр иде дә. Йөрәгеңә боз катарлык.

Ул башын минем күкрәгемә куеп ята иде. Чәчен сыйпадым да сыйпадым.

— Китәләр дә әйләнеп кайталар,— дидем мин.— Нинди ахмаклык.

— Шуңа күрә газап чигү дип йөртелә дә инде. Ә явызлык кылып чистарынырмын, тәүбә итәрмен димә. Нигә икәнен Алла белсен... Әллә нишләп моңаеп калдың әле.

— Япа-ялгызым,— дидем мин.— Эти бар иде. Эни яшәп китте. Эти исәнлеккә исән әле, әмма кабердә кебек. Аның янына юлга чыгарлык түгел инде.

— Хәзер без икәү инде.

— Хәзер,— дип җөпләдем мин.— Тик хәзер генә бит ул.

— Озакка дип уйлыйсыңмы?— дип сорады ул күземә текәлеп.

— Талкыма инде.

— Мин эти белән генә булырга ант эчтем. Фәкать аның белән генә. Үз-үзенә бәхетне күрәп алырга теләүчеләрне язмыш тиз аера ул дип сөйлиләр ич әле. Әллә моны мин үзем китереп чыгардым микән? Бөтенесе буталып, чуалчыкланып бетте инде шунда.

— Минем сине аннан тартып алырга җыенганым юк ич әле,— дидем мин.— Кая барсаң да, синнән калмам инде,— бары тик шул гына.

— Кушмаган җиргәдәме?

— Йа хода! Нинди кеше син, ә!

— Әйдәле, очрашуыбызга куанышып кына ятыйк. Шәп уйлап чыгардың да соң, ә?! Куянны да онытып бетердек. Тиздән кузгаласы барын онытмыйк. Ә мин әлегә шушында әле, шушында! Төшеңә керим дисәң, минем нинди икәнемне отып кал. Төштә дә дәвам итәрлек булсын. Иртәгә айнырбыз да акылга килербез. Ә хәзергә, хәзергә...

Төн кочагын шәмәхә төс мылкытып тутырды. Бер-беребезне яратырга комачаулардай нәрсә бөтен дөньясында да юктыр кебек иде...

Мин аны болдыр баскычына тикле озатып куйдым. Ул миңа сарылып елышты да боз кантарын кочкандагы ише читкә тайпылды.

— Китәләр дә әйләнеп кайталар,— дип пышылдады ул.

## 6

Кәрҗин тулы гөмбә, урман тулы оеткыч салкынлык. Иртәләрен күлне томан сара, алтын тәңкә булып яфрак коела. Чыршы араларын зәңгәрсу дымык баскан. Бер урында ике юл кисешә дә тагын аерылып китә. Берсендә котырып үлән үсә: икенчесенең ерымына су тулган. Авыр тармаклы мүгезен игән бер бөкре поши күзгә чалынып китте. Бала чакта беренче карның туң җиргә ятуына шатлангандагы сыман, күңелдә әллә нинди куаныч төйнәлеп китә. Шундук пөхтә бүкәннәр итеп туралган теге каен. Һәм шундук — күзгә моңсулыкка балкыш биреп торган без икебез.

Шәм төбенәчә янып беткән иде инде.

Октябрь аеның беренче кар төсмерен күрсәткән көннәргә тикле җиткән Кахетия шәрабы бар әле. Мич җылы, суык әлегә бусага төбендә генә таптана.

Нигәдер моңаеп калган Тяпа арлы-бирле йөренә. Мичкә якканны ул озын гомер кичергән кеше сыман озаклап карап торырга ярата иде.

Көннәр шулай, җил таратып салган яфраклар сыман, берсен-берсе куа-куа үтә торды.

Бер заманны урманнан әйләнеп кайткач, картны үлгән җиреннән күреп алдык. Котырткан кебек хәйләле елмаюы йөзенә мәңгегә сарылып калган иде. Дөнья белән саубуллашыр алдыннан кемгә шулай елмайган икән ул?

Күкрәге белән өстәлгә капланып, кәнәфидә утырган көйгә җан биргән. Кулы сүтеп ташланган сәгать әйберләренә салынган. Янәгына, ни гаҗәп, сәгатьнең секунд санагыч угы ябышып калган иде.

— Сулыш алмый бит ул!— дип кычкырып җибәрде Гүзәл.

Аның саксыз хәрәкәтенә буйсынып, кәнәфинең тераткече авып китте. Әйтерсең лә монысын да карт уйлап калдырган.

Тагын дүрткә бөкләнгән бер кәгазь дә калган иде әле — карт кешенең соңгы васыяте. Ахыры якынайганын тоеп, анысын да алдан эшләп куйган. Яшермичә, пөхтә генә итеп сәгать кирәк-ярагы тутырган тартмага салган. Шундый язу барлыгын белсә дә, картны борчымаска теләп, Гүзәл аны шу-

шыңынчы укымаган булып чыкты. Алар бер-берсен алдалауның ни икәнен белмичә яшәгәннәр. Шуның өстенә карт та яшермичә:

— Миннән соң, миннән соң...— диган булган.

Ни язгандыр, мин сорашмадым-нитмәдем.

Җирләү чыгымнарын без бергәләп күтәрдек. Төне буена Тяпа янгырга кушылып улап чыкты.

Иртән иртүк каравылчы Сәет арбага салып табут китерде.

Картны соңгы юлга озатырга дачада гына җыйнадык.

— Ул-бу килеп чыкса, шушыннан гына алып китәрсез, дип кушкан иде,— диде Гүзәл.— Чәчәкләр куймагыз диде. Булышасыларын белгәндер инде.

Табут янында икәүдән-икәү генә утырып тордык. Сәет кенә баскыч төбендә иелеп-иелеп саубуллашты. Аннары сүз дә катмыйча китеп тә барды.

Калистрат машина юллап бирде.

Авыл зиратына җирләп кайткач, аларның йорты моңсуланып, шыксыз бушап калгандай булды.

— Үзем генә утырып торыйм әле,— дип сорады Гүзәл.— Шулай кирәк.

— Туңарсыңдыр ич.

— Өшемәм.

Ул сулыгып, карчык кешегә охшап калган иде.

Иртән торып, аларга үткәндә мин ишектәге йозакка һәм анда-санда сулган чәчәкләргә тап булдым.

Бу хәлгә ничек карарга белмәстән, мин үземә урын тапмас булдым. Әйтерсең лә ул узып барышлый гына:

— Мине шушында көтеп тор,— диган сыман булды.

Мин озын-озак өч көн буена көтеп яттым. Аннары гына аптекалар идарәсенә шылтыратып, өй адресын алырга мөмкинлегенә төшендем. Анда күз күрер әле тагын, белми калмаслар. Ул мине сүзсез генә көтеп алырга тиештер бит инде, куып чыгармас, дип уйладым. Тик мин аңа кем соң әле, Алла колы?

Картның үлем алды язуы белән Гүзәлнең кинәттән юкка чыгуында ниндидер бер бәйләнеш барлыгын күңелем кемдер әйтеп торгандай сизенгән иде инде. Алар картның үлеменнән соң кыз нишләргә тиешлеген дә уйлап куйган, ахрысы. Ул аңа үзләре генә белгән ниндидер бер йомыш тапшырган булырга охшый.

Әниләре мәллә? Шул, әниләре!

Аның атасы васыятенә каршы килмәслеген аңлап алгач, мин тетрәп киттем.

Моңа ышанырга, үземне ышандырырга тырышып, күпме генә карышсам да, нәкъ шулай булырын белгән идем инде.

Янымда берәрсе булса, болай ярдәмчесез азапланмас идемдер. Тиз көндә Әхмәт белән Айя кайтып төшәр. Тик аңынчы яшиселәр бар ич әле.

Көчсезлектән изаланып, минем улыйсыларым килеп китте.

— Чәнчелепләр китсен лә соң!

Ләкин шундук үз-үземә: «Кот — дип боердым.— Бирешмә!»

Бакчаны кырау алды сыман, яфраклар күгәреп килде диярсең, урман сирәкләнгән кебек. Җиргә корыган ботаклар коелышты. Төннәрен ургым-ургым җилләр исте.

Тиздән Гүзәлнең анасы тарафына китеп барганын белдем. Сизенүем ялгышмаган. Югалып калган һәм җиңелгән җанга ярдәмгә ашкынган ышанычның, тойгының шәфкатьсезе дә була икән! Караңгы күздә салават күперенең балкып чыгуы мөмкин хәлме соң?

Аннары мине, капшанып дигәндәй, бер хат эзләп тапты.

*«Дустым, моңсу дустым Илтизар!*

*Синең хакта авыру әни янында уйланып утырам, күз яшемне сөртеп бетерерлек түгел. Сине озаклап һәм күп тапкырлар үбеп калам. Дөньяларымның кадере китте. Кадерле доктор, син мине аңларсың дип беләм. Сайларга, сайланырга вакытым юк. Әти әйткәнчә, са-*

*гышлар кила да кита ул, яшәу нужасы гына торып кала. Янымда кайгы-хәсрәт барында нинди генә шатлыклар артыннан ташланыйм ди соң? Үз-үзенә бәхетне күрәп алырга теләүчеләрне язмыш тиз аера ул»,—дигән идем ич әле? Шулай килеп чыгасын кем белгән аның.*

*Болай моңсу язганымны кичерә күр инде. Шулай да ямьсез көннәрне дә мин синең үземне көтүеңне телим бит. Беренче карлар явар алдыннан сине кысып-кысып кочаклап калам. Беренче карлар җирне чистартыр һәм мәрхәмәт кылар өчен ява ул.*

*Бер көз бөтен гомергә дә җитә икән.*

*Гүзәл.»*

Хат юлларга адресы күрсәтелмәгән иде.

* * *

Тагын бер көз килеп җитте.

Әхмәт белән мине бала салган арбасын тирбәтә-тирбәтә Айя каршылый. Хәзер ул тып-тыныч инде.

Кемнедер эзләгән шикелле, мин чокырларны буйлыйм.

Әмма бу көз узганына һич кенә дә охшамаган иде.

Көтә-көтә көтек булдым инде. Һичнәрсә яңадан кабатланмый икән шул. Һәр көзнең дә үз йөзе, үз холык-фигыле бар икән.

Ә югыйсә былтыргы көз нинди ягымлы башланган иде. Искәрмәстән ишетелгән кыштырдау сыман булып, ул көз минем хәтеремдә ап-ачык, саф көенчә мәңгегә калыр ахрысы. Шулай булсын соң.

*Әхәт ГАФФАР тәрҗемәсе.*

# Әхмәт Гадел

## Хат

Мераба, азиз тувгъаным!— Мәрхәба!
Хат язамын сиңа ничә мәртәбә!
Ләкин озак хәбәрең юк еpактан...
Килсә килде — эссе чүл,— комлы яктан...
Йә, ни булды?
Син кайдасың?
Чүлләрдә?!
Ком илендә нинди сулыш гөлләргә?!
Сусыз чүлдә ни яшәеш балыкка —
диңгез буенда туган ул халыкка?!
Бәлки анда алып киткән зур ният?!
«Комсомол йөрәк үзе киткән теләп»?!
Үзбәк, төрекмән, казакъларга зур ярдәм
кылу уе биргән сиңа рух, адәм?
Әшраф, Шамил, Риза, Гомәр, Искәндәр!...
Коры җилләр баш очыннан исәләр...

Юк, кушмаган бу эшне Олы китап —
явыз тел, явыз йөрәк кылган этап.
Мераба — азиз тувгъаным!— Мәрхәба!
Күз яшемне агызам күп мәртәбә.
Юк йөрәккә яр буенда тынычлык...
Үксезләрнең баш очында кылыч күп!
Чит җирләрдә яшәешең сорамыйм.
Ләкин сине кайгыртам, юксынам мин.
Ятим калды туган илең — Кырымың...
Кайтарырга сине юктыр ырымым...
Тәмле катык, татлы йөзем, чибәрәк
юктыр анда, эзләсәң дә мукәләп!...
Нурлы йөзле татар кызы күренми!...
Йә бер раббем!
Күрештермисең һаман!
Мин моннан кычкырам сиңа, син — аннан!

## Чатырдагъ

Чатыр тауда ком да таш,
таштан ясала таулар.
Белсәң иде бу ташларны
ком итүче кай яулар?!

Карт күкрәккәе иңгән,
фәсе төшкән, яланбаш...
Нигә атмый Чатырдагъ —
ризасызлыгыннан — таш?!

---

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) — *шагыйрь, татар һәм кырым-татар, рус телләрендә дөнья күргән китаплар авторы. Казанда яши.*

Нигә чыкмый ялгызы
усал диңгезгә каршы?
Сабыр тора тау агай,
дусларын көтә ахыры!

Кырык батыр уяныр да
Дулкынларга күз салыр,—
Шулчак Чатыр кулына
янар йолдызлар алыр:

— «Чатыр, чатыр-чатырман.
Чатыр тауда — чытырман.
Чатырда чатыр корып,
Ил уллары ятырлар!»...

Көтмәгәндә яңгырар
Бу җыр тауны уятып.
Көчле булса да, диңгез
Куркудан калыр шашып!

* * *

Исерекләр йөри төнге илдә,
Йортсыз калган мескен байгышлар...
Йортсыз йөри, артларыннан
Өстерәлеп бара сагышлар...

Япа-ялгыз алар җир йөзендә...
Салкын чәчең сыйпый битемне...
Беткән адәм...
Ул да анасының
кадерлесе булган ич инде!..

Әнкәемнең изге догасына
Каршы тора күпме каргышлар.
Йөрәк җылың, чәчең назын тоеп,
Җан җылына, уйлыйм: «Ялгышмам!»

## Кичә — бүген

Кичә ул чит илләрдән тик кер эзләде,
Бүген башкача үлчи аның бизмәне:
Дуслар эзли,
контракт төзи,
коча байларны...
Кичә ул сүгә иде динне...
Бүген — үбә тәре вә айларны...

## Моң агачы

Язның матур чагы.
Әле генә
Яңгыр үтте юып җир йөзен.
Яшелләнде дөнья
Яшәрмичә
Калган моң агачы бер үзе.
Бер карасаң, агач шундый сәер,
яфраклары җансыз — шиңгәннәр...
Чәчәгендә кара хәсрәт яше...
Бәлки шуңа
Аны моң агачы дигәннәр?!

Моң агачы нигә болай моңлы?!
Нигә болай тирән кайгыда?!
Кая үстең?
Җуңлидәме[1] әллә
бакчадамы үстең җай гына?!
— Юк, и кеше, мине күчерделәр,
ерак илдән җылы көньяктан...
Чәчәкләрем анда көлеп торса,
сагыш булып монда елата.
Сут алалмыйм җан туган яктан!...

## Рух һәм тән

Елга сыман ага рухым...
Тар дөньяга сыймас
азат рухым!
Рух артыннан очмакчы да
авыр тәнем,
ләкин туктый — Җир тарта да...

Бик биектән бүген
тәнгә дәшә җаным!

* * *

Казаным өстендә болытлар.—
Сөембикә ак яулыгын япкан сыман.
Кабат тоткын булмасмы Сөембикә?!
Сискәнеп,
тетрәнеп китәм уемнан...

[1] Җуңли — Джунгли

# Нурмөхәммәт Хисамов

## ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

### Реквием

*Бөек Ватан сугышында һәлак булган*
*татар шагыйрьләрен*

Башланып та, тәмамланмый ничаклы җыр
Өзелеп калган Европаның кырларында...
Паганини скрипкасы кебек чыңла,
Поэзия, исән, таза кылларыңда!

### Көз каршылый Кышны

Көз күрсәтә Кышка мәртәбә,
Шартын үтәп затлы йоланың,—
Сары яфрак—алтын тәңкәгә
Кумеп аның килер юлларын.

### Син киләсең

Һич белмичә борчу, мәшәкать,
Яшәгәндә тыныч, төш күреп,
Син киләсең тагын, Мәхәббәт...
Шагыйрьлегем искә төшереп.

### Көнләшү

Тугрылыгың артык аккоштан,
Көйдермисең шик утларыңнан...
Көнлим сине ләкин вакыттан,—
Минсез узган минутларыңнан.

### Таулар артында

Мин тауларга карап шигырь язам,
Гүзәл исмең кушып һәр тынга.
Шул тауларга карап һуштан язам—
Сылу сының таулар артында...

---

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ (1937)—*галим, филология фәннәре кандидаты, Кол Гали ту-рында татар, рус телләрендә басылган китап авторы. Шигырьләре дә журналыбызда басы-ла килде.*

## Яктыртучым булып

Була кайчак бөтен тирә тын,
Караңгылык баса күңелне.
Калка шунда якты сурәтең,
Яктыртучым булып күгемне.

## Күрми димә

Син — артымда. «Күрми» димә — сизәм, беләм.
Карый алмыйм яман күзләр арасыннан.
Хәлем — газиз көен тик аркасы белән
Тыңлый алган чал Бетховен хәле сыман.

## Яшь Вертердәй

Әгәр белсәң яшь Вертер ни кичергәнен,
Аның исәп, таптан-кердән азат җанын,—
Син аңларсың нинди утка төшергәнен,
Бу өметсез януымның газапларын.

## Сандугачны тыңлаганда

Өзгәләнеп нигә, әй, сайрыйсың,
Урманнарга тулган моңнарың?
Хискә янып шулай сарымы син,
Лаекмы тик моңа сыңарың?..

## Сурәтеңне төреп

Каралтырга якты хисемне,
Кузгатсалар синең исемне,
Сурәтеңне төреп моңыма,
Мин юнәләм урман юлына.

## Яз кызына

Гөлләрнеңме сиңа назы күчкән,
Таңнарныңмы күчкән яктысы?
Кайсы йолдызлыктан килдең безгә,
Якты җанлы гүзәл Яз кызы?

## Син кагылгач

Кагылдың тик уйнап син бары
Бөтенләйгә тынган сазыма.
Кылларының тибрәп зыңлавы
Житте менә ничә языма.

## Гомер

Язлар үтә, кышлар җитә тора,
Чигәләргә бөркеп чал тынын.
Еллар бездән алып китә тора —
Көмеш биреп — яшьлек алтынын.

## Җан тынычлыгы

Җанга ял юк — даруларың
Бераү түгел, унау булсын:
Йокым тыныч булсын дисәң,
Вөҗдан һәрчак уяу булсын.

## Бер тәнкыйтьче

Буш шагыйрьне чөеп мактады,
Бушка түгел, бер-бер исәп — бу.
Чын шагыйрьне изеп таптады—
Халкым, сак бул: сиңа күсәк—бу!

## Философ...

Бәйнәлмиләл фәлсәфәсен сатты —
Безнең күзгә тузан чәчәргә.
Ә нияте юкса үтә гади:
Халкыннан да... калып яшәргә

## Кем баерак?

Бер бай дустым гел масая зиннәтенә:
«Диварларым тулы, — диеп, — затлы рәсем».
Бармы тиңдәш минем байлык кыйммәтенә —
Күңелемдә һәрчак синең пакь сурәтең!

# Илдар Әхсәнов

## Жирәбә

Мәңге туңнар, мәңге яшеллекләр
Безнең яктан читтәрәк.
Фасыл алыштырып яшәү, имеш,
Татар өчен бер гадәт.
Сынамышлар өмет-аянычны
Куя бирә чиратка:
Ачысы да, төчесе дә хәләл
Идел кичкән ир-атка!
Игелеккә явызлыклар кылган
Хәлләргә без чыныккан.
Ямандыр ла тарих коткылары
Башны кискән кылычтан.
Нахагын һәм хагын — икесен тиң
Татар җаны күтәргән;
Бу илаһи чыдамлыгы аның
Иңде микән күкләрдән?
Күзе алмашына, язы килә,
Кышы — җәйләр артыннан:
Татарлыгым корымаслык итеп
Чал табигать бар кылган.
Рухы ныкны җәберләмәс язмыш
Тик сан өчен яратып;
Август кичәсеннән бәйсезлеккә
Ыргыл әйдә, пар атым!
Урталыкта көн күрсәк тә, шөкер,
Уртакуллык читләгән…
Иманымнан яздырмыйча тота
Татар дигән жирәбәм.

* * *

Бирелсәк тә вакыт агымына,
Без вакыттан өстендер,
Килсен әле, килсен якты өмет,
Сүнмәс өчен килсен бер!

Бәхеткә бит җәннәттәге кебек
Әзер ишек куймаган;
Афәтләргә тарта язмыш җиле,
Язса халык кыйбладан.

Кабыз әле җирдә кояш итеп
Гаделлекнең өлгесен;
Житәр инанудан ваз кичәргә,
Абынмаган түгелсең.

Адаштырган затларының язмыш
Ташламасын берсен-бер.
Килсен әле, килсен якты өмет,
Китмәс өчен килсен бер!

* * *

Кагылулар мәрхәмәтлек нурын
Күзеңә сызарга да калдырмас;
Изге тамыр көчен тану бетсә,
Илнең газизенә кадер аз.

Бәреп чыга сулар калын бозны,
Дәгъва-дөньяң дәррәү кузгатып.
Шәфкать сорар актарылган хәтер,
Шәфкать кенә! —
Бүтән сүз — артык…

---

Илдар ӘХСӘНОВ — *берничә шигырь китабы авторы. Әлмәттә яши.*

* * *

Гыйбрәтеннән гайре нәрсә алыйм
Үткән тарихтан мираска?
Туры Тукай белән чая халкым —
Иманыма ихлас тотка.
Табынырлык — халкым тарихының
Калмаса да танырлыгы.
Кем хәтерен инанудан чикләр
Җәлилчеләр батырлыгы?
Татарга хас тыйнак күндәмлекне
Мирас итеп алам тагы.
Газиз миңа тибрәп кенә үскән
Кыр чәчәге — аландагы.
Ташламасын янә сынауларда
Атам-анам гаделлеге;
Бөгелмәслек итеп рухын бирсен
Кол Галиләр галилеге!
Горурлыгым арта — милләтем бай
Һич саекмас дастаннарга.
Егет күңелен сөйгән яры биләр,
Саф мәхәббәт — таҗ аңарга!
Таянычым булсын юлларымда
Туган телем белән денем;
Бәлки шунда олы ышанычны
Акларымны төшенермен...

## Көнлекчеләр

Яраланган кош хәлендә
Иртәгесе көнгә керәм:
Көн артыннан куып яшәү
Алып керде безне тирән.
Әхлагыннан язды бәндә,
Җимердек без уртак йортны:
Кыргыйлыкка ураланып,
Тудырдык без манкортлыкны.
Түбәнлеккә төштек тәмам,
Әйләндек тә көнлекчегә.
Нәрсә калды балачактан?
Көенечтән кыса чигә.

Язсаң тәүге сукмагыңнан,
Пакьлек биргән елга-судан,
Кайтмас һичбер югалтуың
Күңелеңне еглатудан.
Күкрәк төйдек ялган чәчеп;
Иҗатчылар килде, имеш!..
Нинди тылсым алыштырып
Куйды безне тере килеш?
Бакчабызны ботарлауда
Бармы бүген безгә тиңнәр?
Табигатьтә көнлекчегә
Калмагандыр инде имнәр...

## Юныс Әминов

# КУНАКТАН КАЙТКАНДА

хикәя

*Катлаулы тормыш юлы узды ул. Әгерҗе районының Салагыш авылыннан үсеп чыккан язучы Юныс Әминов Минзәлә педагогия институтын тәмамлап, балалар укытырга керешкәндә генә аны солдатка алалар. Анда хәрби мәктәптә уку, взвод командиры хезмәтен үтәү, Бөек Ватан сугышында катнашу, авыр яраланып фашистлар кулына эләгү, Совет Армиясе частьлары азат иткәнгә кадәр Румыниядәге хәрби әсирләр лагеренда тоткынлыкта яшәү, аннары тагын сугыш беткәнче — алгы сызыкта ...*

*Сугыштан кайтканнан соң Ю. Әминов озак еллар буе туган районында балалар укыта, эшеннән аерылмыйча укып, Алабуга Укытучылар институтын тәмамлый. 1959—1961 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. 1969 елда гаиләсе белән Әлмәт шәһәренә күчә һәм гомеренең соңгы көннәренәчә шунда яшәп иҗат итә.*

*Кыска гына итеп саналган шушы тормыш юлында әдип татар әдәбиятында якты эз калдырып китте. Аның «Гөлчәчәк», «Өти баллак», «Гөлҗәннәтнең җәннәте», «Минем җинаятем», гражданнар сугышы чорында авылдагы сыйнфый көрәшне күрсәткән «Умырзая чәчәкләре» һәм башка комедия вә драмалары Татарстанның һәм Башкортстанның төрле театр сәхнәләрендә зур уңыш белән барды.*

*Драматургның Әлмәт чорындагы әдәби иҗаты тематик яктан тагын да киңәйде. Әсәрләренә нефтьчеләр, завод эшчеләре образлары килеп керде. «Кан кардәшләр», «Сафура бураннары», «Сөймим дисәң дә ...», «Очрашырбыз, Гөлсылу!» кебек комедия һәм драмалары — әнә шуның мисалы. Юныс Әминов утыз еллык иҗат гомерендә ике дистәдән артык сәхнә әсәре иҗат итте.*

*Быелның 1 декабрендә драматург Юныс Әминовның тууына 70 ел тулды. Шул уңайдан аның әлегәчә дөньяга чыкмаган хикәясен укучыларга тәкъдим итәбез.*

Июль үзәге. Баш өстенә кунаклаган кояш Кама өстенә көмеш келәм сузган. Тымызык җил кузгаткан нәни дулкыннар йомшак куллары белән яр буендагы чуер ташларның битләрен юа, ә ташлар юеш битләрен ялтыратып дулкыннарга елмаялар.

Әле генә түбәнгә дә, югарыга да пароход узганга, бу кечкенә пристаньда халык аз: алты-җиде кеше генә. Әнә, бер почмакта, пристань картузыннан төшкән күләгә астында, дүрт кеше утыра. Берсе Әхәт бабай. Озын буйлы, татарча кыркылган түгәрәк сакаллы, кылыч борыны астында калын чал мыегы да бар. Элек колхозда ат карады ул. Хәзер инде пенсиядә, үзенчә әйтсәк, җәннәт түрендә: теләгәнен ашый, теләгәнен кия, теләсә эшли, теләмәсә ял

итә. Икенчесе — аның карчыгы Фәхрия әби. Бue Әхәт бабайның биленнән генә, әмма иңе һич зарланырлык түгел. Әле менә кияүләрендә кунакта чагында үлчәнеп караганнар иде, әбиең озын буйлы бабайдан пот ярымга саллырак булып чыкты. Өченчесе — күршеләре Фәйзелхак. Шофер. 30 яшьләрдә. Бәхәскә китсә, алты ярым метрга киселгән егермешәр сантиметр юанлыктагы бүрәнәләрне прицепка ялгызы төйи. Дүртенчесе — әлеге пәһлеванның хатыны Алмазия. Авыл кибетендә сатучы. Нәзек кашлы, юка иренле мөлаем гына хатын. Аларның да кунактан кайтышлары. Алларында термос, кружкаларында кайнар чәй, җәеп куелган газит өстендә Фәхрия әби кулы белән эре итеп туралган тавык ите, берничә кыяр, иртә өлгерә торган сары алмалар. Ризыкларын ашыкмыйча гына, тәмләп кенә чәйниләр. Нигә кабаланырга? «Метеор» үз вакытында киләчәк, билеты да булыр диделәр. Юллары да сәгать ярымлык кына.

Икенче читтә аркасын стенага терәп чемодан өстенә утырганы Салисә ханым. Изүен ычкындырып, күкрәгән кулларында яткан баласының авызына каптырган. Үзе дә черем итә, сабые да йоклый, тик унике яшьләрдәге кызы Гөлсинә генә әле яр буена төшә, әле пристаньга кереп чемоданнарны барлый. Әнә, хәзер дә ул үзенең кыйгач яулыгы белән әнисенең күкрәген каплап куйды. Каршыда гына ир-атлар, яхшы түгел, янәсе.

Пристань начальнигы, урта яшьләрдәге урыс, судан тоткан агачларны яр өстенә сөйрәткән, утын итеп тураган да, хәзер шуларны ярып маташа. Аның хатыны карар күзгә чандыр гәүдәле, әмма юан беләкле ханым, узып киткән ике пароходка билет сатканнан соң, тездән суга кереп, көндезге шулпага балык чистарта.

Тынлык! Җанга да рәхәт, тәнгә дә ял...

Тик бу тынлык озакка бармады, аны яр өстеннән ишетелгән карлыккан җыр челпәрәмә китерде:

Күпер башы күк тома-ан,
Күпсенмәгез, күп торма-ам...

Үзе күренмәсә дә, җырлаучының салмыш икәне бәхәссез иде. Әхәт бабай, авызындагы ризыкны чәйнәүдән туктап, яр башына карады, яхшырак ишетү өчен кулын колагына куйды.

Язлар торса-ам, көзләр торма-ам,
Сагынырсыз, мин булма-ам...

Җырчының күкле-яшелле тавышыннан бабай кеткелдәп көлде.

— Әйттерәме, әттәгенәсе!

Фәхрия әби ризасыз рәвештә кашларын җыерды:

— Таптың көләр нәрсә! Уттай эш өстендә көпә-көндез адәм көлдереп йөргәне өчен авызына чүпрәк тыгарга иде мәлгуньнең...

Озакламый җырчы үзе дә, аны култыклаган юлдашы да күренде. Җырлыйм дип ятим бозау тавышы белән мөгерәгәне Сафа исемле, култыклаганы Садыйк иде. Алар — баҗайлар.

Сафа Садыйкларга моннан ике көн элек килде. Ул, ишекне ачып керү белән, өй эченә бозылган балык, сөрсегән суган исе таралды.

— Кайгымны уртаклашырга килдем, — диде Сафа. — Фәүзиям мине ташлап Ижауга китте.

Юылмаган кулы белән күзләрен сөртеп алгач, Садыйкның хатынына текәлде:

— Зәйнәп, сеңлең Фәүзия сине тыңлый иде. Үгетләп хат язсаң, кире кайтмасмы икән?

Өй эче бер мәлгә тынып калды.

Садыйк белән Зәйнәп урынында башка берәү булса: «Фәүзияне шушы көнгә син китереп җиткердең, яшьлеген син таптадың, сәламәтлеген син урладың, җәзасын да ал!» — дип хөкем каршына бастырыр, закон буенча җавабын да бирдертер иде. Тик Зәйнәп тә, Садыйк та алай итмәделәр. Фәүзия

турында күңелсез хәбәрне ишеткәч, бигрәк тә Зәйнәпнең түбәсе күккә тиде: «Җәнҗаллы тормыштан, исерек ир йодрыгыннан котылгансың икән, сеңелкәем. Моннан соң ашыңны да күз яше өстәмичә ашарсың, йокың да тыныч булыр...» — дип уйлады ул.

Садыйкның исә үз уйлары: «Баҗай дигән булып кунакка килгән саен бер чиләк аракы чөмерә, бирмәсәң тавыш кубара иде. Фәүзия киткәч туганлык та бетте дигән сүз. Котылам кесә талкучыдан!..»

Шулай да әле элеккеге гадәт буенча ул торып, магазинга йөгерде. Әллә инде эчендәге шатлыгы йөзенә балкып чыкканчы дип ашыктымы, кунак килгәндә теләр-теләмәс кенә атлый торган Зәйнәбе ул кайтуга өстәлгә ашамлыклар тезеп куйган, хәтта кар базыннан тозлы кәбестә алып менәргә дә өлгергән иде.

Стаканнарга мөлдерәмә итеп салынды. Сафаны юатырга тотындылар:

— Юк өчен хәсрәтләнмә. Син кайтуга Фәүзияң өеңдә булыр,— диде Зәйнәп ханым.

Сафа борынын мышкылдатты:

— Холкын беләм! Кайтмас ул, кайтмас...

Әңгәмәгә Садыйк та кушылды:

— Кайтмаса, хатыннарга кытлык заманымени? Табылыр әле...

Беренче көнне Сафа тиз җебеде: өченче стаканын эчеп бетерә алмады, өстәл арасына әйләнеп төште:

— Иртәгә үк китәм, Фәүзиямне эзләп табам...

Күтәреп урынга салганда ул гырылдап йоклый иде инде.

«Иртәгә үк китәм»,— дигән Сафа икенче көнне таң тишегеннән уянды. Ыңгырашып алды, ухылдап куйды, булган җегәрен җыеп аягына басты, салкын су эчте, папирос кабызып җибәрде. Күрше бүлмәдән, аягына эләктергән башмакларын шапылдата-шапылдата, Садыйк килеп чыкты:

— Бераз йокларга иде әле, баҗай, пароходка иртәрәк бит...

Сафа чыраен сытты, папиросының да тәме юк, идәнгә төкерде:

— Баш чатный, йөрәк сикерә... Төзәтик инде, зинһар...

Садыйк бәхәсләшеп тормады. Яңа шешәне ачып стаканга салып бирде. «Ике сәгатьтән юлга чыгасы кеше, бераз күзе ачылсын инде, аннан соң үзен пристаньга озатып куярмын»,— дип уйлады ул.

Тормыш уйлаганча гына барамыни?

Сафа, стаканны бушатканнан соң өстәлдәге тәлинкәдән кәбестә суы йотты да, яңадан урынына ауды. Бик тырышсалар да иртәнге пароходка уята алмадылар.

Ул көндезге тугызлар тирәсендә генә урыныннан торды. Өстәл өсте җыештырылган: ялт итеп тора, анда бары тик язулы дәфтәр бите генә ята иде: «Без эшкә киттек. «Метеор» уникедә кузгала. Сау бул, баҗай». Сафа, кәгазьне укыгач, башында махмыр булса да, үзенә юлга җыйналырга кирәк икәнен ачык аңлады:

— Куалар! Фәүзия киткәч, кадерем бетте...

Сүгенеп куйды, бикләнмәгән буфеттан таныш шешәне тартып алды, стаканга тутырып салды...

Сафа күзен ачканда караңгы төшкән иде инде. Зәйнәп белән Садыйк та эштән кайтканнар, күрше бүлмәдә пышылдашып кына нидер сөйләшәләр...

Кичке аш алдыннан Садыйк шешә төбендә калганны Сафага сузды. Ачуланышкан кешеләр сыман, сөйләшми генә ашадылар.

Иртәнге табынны кабыклы бәрәңге белән тозлы балык кына бизи иде. Сафа өстәл янына килеп тормады. Күңеле болгана, башы әйләнә, йөрәге күкрәк читлеген ватардай булып бәргәләнә иде:

— Баҗай, аз гына булса да... Хәлем хәтәр...

Садыйк өчен Зәйнәп җавап кайтарды:

— Гаеп итмә инде, җизни, өйдәгесе бетте, магазиндагысын тагын ике сәгатьсез бирмиләр.

Сафаның күз алды томанланып китте, өй бер якка авышкандай булды, кунак урындыгыннан идәнгә тәгәрәде:

— Үләм!..

Хуҗаларның котлары ботларына төште. Махмырлаган кешенең башын вакытында төзәтмәсәң, аның үлүе дә ихтимал дип ишеткәннәре бар иде. Әгәр Сафа да җан тәслим кылса? Җитмәсә, алар өендә, кунакка килгәч! Зәйнәп Садыйкка, Садыйк Зәйнәпкә карап алды. Бер-берен сүзсез аңладылар. Садыйк идәндә яткан Сафа янына чүгәләде:

— Тор, бажай, пристаньга барышлый төзәтермен.

— Алдамассыңмы?

— Билләһи дип әйтәм... Үз туганымны алдарга... Ә хәзер әйдә, аша.

Сафа торып урындыкка утырды, ләкин балыкка да, бәрәңгегә дә борылып карамады.

— Пешергән ризыкларымны да яратмадың, җизни,— диде Зәйнәп ханым, үпкәләгән тавыш белән. Балыклы кулын гәзит кисәгенә сөртә-сөртә өстәл яныннан торгач, сүзен дәвам итте:

— Район үзәгендәге сеңелем авырган, хәзер аның янына китәм. Атна-ун көнсез кайта алмам инде. Хуш, җизни...

Сафа эндәшмәде. Папиросын яңаклары эчкә батарлык итеп суырды да, төтенен түшәмгә өргәннән соң, чертләтеп идәнгә төкерде. Садыйк та кулын юу белән киенә башлады:

— Мине командировкага җибәрәләр, бажай. Бер айга диләр. Синең белән утырулар бик күңелле булса да, аерылышырга туры килә инде.

Кичә адымнарын санап кына атлаган Зәйнәп юлга дигән сумкасын минут эчендә тутырып куйды, кулына өй ачкычларын алды:

— Автобусым китәргә ун гына минут калды, тизрәк бул, Садыйк. Син дә бүген «Метеор»ыңа кичегә күрмә инде, җизни...

Ишек алдына чыктылар. Зәйнәп ханым ат башыдай йозак белән өйне шарт-шорт бикләде дә, саубуллашырга да онытып, автобусына йөгерде.

Капканы шапылдатып япканнан соң Садыйк та иркенрәк сулап куйды: «Тәки ишек алдыннан алып чыктым бу дуңгызны. Аяк-куллары исән килеш «Метеор»га утыртып олактыра да алсам...

Сафа озак авырып урында яткан кешедәй хәлсез атлый, еш туктала, тукталган саен берүк сүзне кабатлый:

— Кайда төзәтәбез соң? Вәгъдә бирдең бит...

Ун минутлык юлны әллә кайлардан урый-урый кырык минут эчендә узгач, калдык-постык такталардан гына укмаштырылган ларек янына килеп чыктылар. Кара кашлы, сары чәчле, кызыл тырнаклы сатучы ханым Садыйк кулындагы сәмәнгә карап сәер генә елмайды:

— «Кечкенә»не дисезме?.. Бер сәгатьсез ярамый шул...

Садыйкның эченә җылы йөгерде. Бирмәсә бигрәк әйбәт була әле бу! Акча да кесәдә кала, әрле-бирле сугылып йөри торгач, Сафаның авыруы да узып китмәсме? Эчсә, пристань дип тормас, ятар да йоклар. Аннан утыр аны саклап...

Ларек янында бүтән кеше юк иде. Сафа да ялварырга тотынды:

— Сеңелкәшкәем, бөтен тәнем эткә салган сөяк кебек. Сүзебезне тыңламасаң, баскан җиремдә аяк сузуым мөмкин... Сатучы ханым Садыйк кулындагы акчага янә күз сирпеде:

— Сезгә кайтарып бирергә вак акчам да юк...

Сафа акчаны Садыйк кулыннан йолкып сатучыга тоттырды:

— Башка баш. Вак акчаң кирәкми.

Ханым «кечкенә»не одеколон тартмасына салды, Садыйкка сузды.

Шактый гына киткәч, бер иске барак каршында тукталдылар.

— Хет үтер, артык бара алмыйм,— диде Сафа, ул барак ишеге янындагы эскәмиягә барып утырды. Садыйк аны урыныннан куптару өчен хәйләгә кереште:

— Пристаньга ерак калмады бит. Монда стакан да юк...

Июль эссесендә башына кәшемир яулык бәйләгән, яулык өстеннән колакчынлы бүрек кигән бер әби шунда гына тавык чебешләре туйдырып йөри иде. Сафа елт кына урыныннан сикереп торды да карчык янына барды, исәнләште:

— Апа, бер генә минутка стакан биреп торчы...

Карчыкның стакан сораучылар белән беренче генә очрашуы түгел иде, ачуланырга кереште:
— Зәхмәт суы белән стакан пычраттырырга, аллам сакласын!..
Садыйк исә күңеленнән теләк теләде: «Бирмәсен иде, пристаньга барып җиткәнче генә җаны җәһәннәмгә китмәс әле... »
Сафа Садыйкка ишеттермичә генә алдашырга тотынды:
— Хатыным үлде. Кайгылы көннәрем. Шешәсен үзенә калдырырбыз.
Бүрекле әбигә әллә үлем хәбәре тәэсир итте инде, әллә буш шешә күңеле кылын чиертеп куйды:
— Зур гонаһ алам алуын да, кайгылы көнендә кеше хәсрәтен бүлешми булмый инде. Әйдә...
Сафа стакан алып чыкты. Садыйк, кирәкмәгән вакытта ярдәмчеләре дә табыла бит дигәндәй, шешә бөкесен ачу белән җиргә бәрде. Стаканга салыйм дигәндә генә кырыс тавыш ишетелде:
— Сез нишлисез, гражданнар?
Каршыларында милиционер формасы кигән яшь кенә егет басып тора иде. Садыйк күңелендә яңа өмет уянды: «Шешәне аракысы-ние белән ташка бәрсен иде...
Сафа аягына басты, мескен кыяфәт белән башын түбән иде:
— Безне бер юлга гафу ит инде, иптәш. Менә баҗайга кунакка килгән идем. Кайтып барышым. Гадәт буенча «юл аягы» дип кенә...
Егет үзеннән өлкәннәргә хөрмәт белән карый торган кеше идеме. Пышылдап кына киңәш бирде:
— Алайса әнә теге сарай артына ычкыныгыз. Монда күрсәләр: «Участогында көпә-көндез урам уртасында эчәләр», — дип мине тиргәүләре бар.
Кирәге беткәннән соң стакан белән буш шешәне әбигә кертеп тапшыргач, баҗайлар пристань урамына чыктылар. Сафаның теле тәмам чишелеп китте:
— Әкренрәк атлыйк әле, баҗай, сиңа әйтәсе сүзләр дә бар...
Садыйк сагайды: эчкәннән соң Сафа йә тәүлек буена йоклый (мондый вакытта уянган саен аңа бераз гына өстәп торырга кирәк), йә бик күп сөйләшә башлый, үпкәләргә тотына, аннан инде, сәбәпсез җирдән сәбәп табып, тавыш чыгара. Бу юлы да башта ул яшь чакларын, Фәүзиягә өйләнүен исенә төшерде, аннан инде «эчәсең» дип хатынының көн саен бәйләнүеннән зарланды, һәм сүзен һич көтмәгәндә Садыйкка рәнҗү белән тәмамлады:
— Үзең дә, хатының да мине яратмыйсыз. Ике кич кундым, мунча да якмадыгыз, бәлеш тә пешермәдегез. Ә «юл аягы» на бер «бәләкәй»... Тьфү!..
Садыйк акланмакчы булды:
— Вакыты тыгыз туры килде бит, баҗай.
— Нигә теге чибәр хатынлы ларектан яртыны алмадың соң, ә? Артыграк китсә, хаерчегә калырмын дип котың очтымы, карун?
— Ачуланышмыйк әле, — диде Садыйк. — пристань янындагы ларекта да кызылы өзелеп тормый иде.
Сафа үз шартын куйды:
— Кызылы булса — бер бөтен, агы булса — ярты! Шунсыз «Метеор»ыңа сыңар аягымны да атламыйм. Суга сикерәм. Минем үлем өчен хатыныгыз белән икәүләшеп җавап бирерсез!..
Аннан җырлап җибәрде:

Күпер башы күк тома-ан...

Пристаньдагылар аларны менә шушы вакытта ишеттеләр. Әхәт бабай, ниндидер кызык өмет итепме, газит өстенә кружкасын куйды, аягына басты:
— Кара әле, карчык, кунакны менә ничек озаталар! Минем кияү генә юл капчыгына «җылы су» тыгарга онытты...
— Ярар, ярар, — диде Фәхрия әби. — вакытында бер йөк утын алып чыгарга ат бирсәң дә яртышар литр чөмереп бардың...
Юлдан күп вакытта чама белән генә кызарып кайта торган шофер Фәйзелхакның да тамак төбе кычытып китте:

— Алма апа (шаяртып хатынына шулай дип эндәшә иде), әллә соң Әхәт абый белән бергәләп чемодандагы теге нине...

Алмазия ханым сөйләп бетерергә ирек куймады:

— «Ни»ең беркая да китмәс! Исерек күрдеңме, тормозың тотмый башлый. Бигрәк тагын...

Сафа белән Садыйк тукталдылар: эчемлекне ваклап сатканда тирә-ягы сүгенүче исерекләр белән мыжгып торган ларекның чыраена аркылы-торкылы итеп, тәре рәвешендә такта кадакланган иде. Сафа күзендә очкыннар җемелдәргә тотынды:

— Садыйк бажай, вакыт барында йөгер чибәр хатынга!..

— Аның кайда икәнен беләсең бит. «Метеор»га кичегәбез.

— Кичексәк җәяү кайтырмын.

— Сиксән километрнымы?

— Терелсәм, йөз сиксәнне дә кайта алам!..

Әхәт бабайлар төркеме пристань култыксасына тезелде. Фәхрия әби генә: «Монда керсәләр таптаулары бар»,— дип, ашыга-ашыга табынны җыйный иде. Соңыннан ул да карты белән янәшә басты. Пристань начальнигы да, сүнгән папиросын авызыннан салындырып, яңа килгәннәргә карап тора, тик Салисә белән сабые гына һаман йоклыйлар. Бажайларның башкаларда гамьнәре юк, алар ярдан пристаньга сузылган күпергә керделәр. Садыйк Сафадан ычкынмакчы булды:

— Белешим әле, билет бармы икән?

Сафа аны шытырдатып кочаклады:

— Биш билет алсаң да кайтмыйм дигәч кайтмыйм, әйттем — бетте!

Садыйк тәмам аптырашта калды. Таныш ларекка йөгерер иде — «Метеор» киң үгә әйләнеп өлгермәячәк. Йөгермәс иде — Сафа кайтып китмәячәк, пристаньда калачак, пристаньнан айныткычка да эләксә? Аннан соң: «Кунагыңны ни өчен дуңгыз хәленә китердең? Ни өчен пристаньда исерек кеше калдырып качтың?» — дип Садыйкның үзенә бәйләнә башласалар? Эш урынына шалтыратсалар? Айлык премиядән колак каксаң?..

Кинәт Сафа Садыйкны ычкындырды да төртеп җибәрде:

— Барасыңмы, юкмы?..

Аннан күкрәгән уа-уа күпернең тузанлы сайгагына утырды: дөнья белән бәхилләшер минутлары җитә, янәсе.

Әхәт бабай, колагы катырак булганга, аларны якынрак килеп тыңларга теләгән иде дә, карчыгы чабуына ябышты:

— Кая барасың инде тагын? Доктор ясаган тешләреңне койдырасың киләме әллә?!

Садыйк исә, култыгыннан эләктереп, Сафаны аягына бастырырга тырыша иде, тегесе күпер култыксасы тактасына ябышкан да һич урыныннан кузгалмый. Алмазия ханым Садыйкны үчекләп кычкырды:

— Алай гына кузгатырсың инде! Су сеңгән ит әле ул!..

Садыйк Алмазия ханымның сүзенә игътибар бирмәде, үзен тыныч тотарга тырышты:

— Бажай, «Метеор»да агы да була, кызылы да. Шунда үзең төзәтерсең. Менә, акча бирәм...

— Алдыйсың, кабәхәт! Анда хәзер пиво да юк! — диде Сафа ярсып һәм әле генә тотынып торган тактасына ачу белән китереп сукты. Карар күзгә калын гына күренгән такта бер сугуда сынып та чыкты. Яннарына начальник килде. Сафага кыҗраеп карады:

— Дурак, эчкәнсең!..

— Анысы безнең эш,— диде Сафа.

— Сезнең эш? Хәзер кереп шалтыратам да унбиш тәүлеккә олактырам.

— Анысы сезнең эш.

Әхәт бабайлар елмаешып куйдылар. Нигә елмаймаска? Кызык ич!

Начальник тактаны җентекләбрәк карады: ничек шулай җиңел генә сынып чыкты соң ул?.. Биш былтыр ук чатнаган икән ләбаса. Ялтыравыклы буяу гына чатнамны каплап торган. Юлчыларның бала-чагалары гел шушыңа атланып уйный иде. Әгәр такта шул вакытта сынып, берәр бала суга чумган

булса?.. Начальникның агарынган йөзе алсулана башлады. Бәхете бар икән: мәкерле тактадан хәвеф-хәтәрсез генә котылды. Бу минутта ул Сафаны оныткан иде инде. Искесен алыштырырга яңа такта эзләп, яр буендагы сарага кереп китте.

Сафа аягына басты:

— Табып килмәсәң кайта алмыйм, пристаньдә үләм...

Кызмача вакытында кордашлары Әхәт бабайны үрти торганнар иде, хәзер картның үзенең дә Сафаны ирештерәсе килде:

— Берәүнең дә үләсе килми, куркыта гына ул мошенник!

Сафа күкрәгенә сукты:

— Курка торган кеше дә түгел абзагыз, куркыта торган кеше дә түгел абзагыз!..

Фәйзелхак көлемсерәп кенә исереккә киңәш бирде:

— Чумып ал. Хәл кереп китәр...

Ире киңәшенә Алмазия ханым да кушылды:

— Бер уңайдан чуртан да эләктереп чык. Яр буенда уха пешерербез.

Әхәт бабайлар кеткелдәштеләр. Шулай булмыйча, исерекне ирештергән арада вакыт дигәне тизрәк уза бит аның. Сафа эндәшмәде. Ул көтелмәгән тизлек белән күпер култыксасына сикереп менде дә, башы белән түбәнгә — суга очты.

— Ай! — дип кычкырып җибәрде Алмазия ханым.

Аңа карлыккан тавыш белән Фәхрия әби кушылды:

— Батты бит, батты!..

«Батты» дигән сүзгә Салисә ханым коты алынып уянды. Ул, әле күзләрен дә ачарга өлгермичә, ачык күкрәген капларга да онытып, пристань буенча чабып китте:

— Кызым Гөлсинәкәем баттымыни?!

Гөлсинә әнисенең юлына каршы төште, аны биленнән кочып алды:

— Мин түгел, әни, бер исерек абый ул...

Биредәге маҗарага начальник хатынының гына сыңар чәче дә селкенмәде. Теге исерек үзе сикерде ич. Батса — үләр, батмаса — чыгар. Ә кулындагы корбан балыгы нинди симез! Шулпага салырга лавр яфрагы гына беткән бугай. Әмма начальникның шунда ук эше бүленде. Сафаның сикерүен күрү белән шомарта торган тактасы комга шуышып төште. Үзе хуҗа булган пристаньда нинди тәртипсезлек! Бу хәлне үзеннән югары начальник күрсә?! Ул тиз генә борынын яр өстенә төртеп йоклаган көймәсен суга этеп төшерде, ишкәккә таянып Сафаның судан калыкканын көтә башлады. Әүвәл чәч күренде, чәч артыннан баш күренде. Начальник, тавышын тамак төбеннәнрәк чыгарып, Сафага бармак янады:

— Ярга тәгәрә, югыйсә башыңа ишкәк белән тамызам!..

— Тамыз әйдә. Барыбер кадере булмады ул башның...

— Чәчеңнән сөйрәп алып чыгам!..

— Якын килсәң, чыкмаска чумам!

— Чыкма, чыкма, синең эше кабәхәтнең дөмеккәне хәерлерәк, — диде Салисә ханым, әле һаман да тынычланып җитмәгән баласын кулларында тирбәтә-тирбәтә.

Гөлсинә әнисенең колагына пышылдады:

— Ник алай дисең, әни? Безнең әти исерек кое чанасыннан төшеп калгач, фонарь белән эзләп үзең алып кайттың бит.

— Алып кайтса, ул бит синең әтиең.

Садыйк, яр буенда әрле-бирле йөгерә-йөгерә бәҗәсын битәрләде:

— Сикергәнче сәгатеңне салып куярлар. Харап иткәнсең икән...

— Үзем үлгәч, капкачын ачып кояшка куярсың. Чорт та булмый аңа.

Начальник, алар сөйләшкән арада мыштым гына ишә-ишә, Сафаның артыннан ук килеп җитте. Җитүе булды — аны пинҗәк якасыннан эләктереп тә алды. Сафа эшне соң сизенде, әмма югалып калмады. Ике кулы белән көймәнең бер читеннән тотты да зәһәрләнеп көймәне үзенә тартты. Бәләкәй көймә янтайды, бер ике чиләк су да чөмереп алды. Көймә уртасына аякларын киң итеп баскан начальник чак суга капланмады. Аның кулла-

рыннан ычкынган Сафа тирәнгәрәк йөзә башлады. Йөзе тәмам агарынган начальник, бер сәгатьтән кара көеп чыгарлык итеп, ишкәге белән Сафаның арт санына кундырып та алды.

Пристаньдагылар көлеп җибәрделәр...

Начальник, Сафаның суда үзен балык шикелле тотуын күргәч, аның батмаячагына тәгаен ышанды булса кирәк, исереккә татарлар да аңларлык итеп русча сүгенде дә көймәсен яр өстенә тартып куйды. «Бәладан баш-аяк. Кызып китеп башына бәрерсең йә. Коткарырга кергәнемне күреп тордылар ич. Су төбенә китә башласа, кычкырыр әле»,— дип тынычландырды ул үзен.

Сафа, начальникның ярга чыкканын күргәч, аякларын шапылдата-шапылдата, көчле агымнан котылу өчен ярга таба йөзеп китте, ишкәк ярыйсы гына эләккән булса кирәк: аның бер аягында ботинкасы юк иде инде. Ул исән калган ботинкасын аягыннан тартып алды да яр читенә томырды.

Фәйзелхакның кәефе күтәрелгәннән күтәрелә башлады, Сафаны чәнчебрәк чеметергә керешге:

— Пинҗәгеңне сала аласыңмы? Тик аны салганда суга кулларың белән кагылма, аякларың белән генә хәрәкәтлән.

Алмазия ханым ирен куәтләде:

— Су төбенә ятасы кешегә пинҗәк нәрсәгә? Калдырсын, баласы кияр.

Сафа пинҗәген дә ярга ыргытты. Әхәт бабай телләрен шартлатты:

— Кара син мошенникны! Өйрәтелгән маймылмыни?..

Фәхрия әбинең үз кайгысы:

— И аллам, пинҗәгенең тотарлыгын калдырмады...

Садыйк һаман Сафага ялвара:

— Чык инде, көзән җыерыр. Әниең җитмеш яшендә...

Сафа Садыйкка җавап бирмәде, аның белән сөйләшәсе килми иде, ахры. Бу кызыктан битләре алланган Алмазия ханым елмаеп кычкырды:

— Абый кеше, күлмәгеңне дә салсаң, йөзәргә җиңелрәк булыр...

— Анысын салмый,— диде Фәйзелхак, хатыны белән бәхәсләшкән булып кыланып...

— Салыр!..

— Салмас!..

Аларның бәхәсен ишетеп торган Сафа, әллә чибәр ханымның сүзен өскә чыгарырга итте инде, җилле көндә папироска ут элдерер вакыт үтмәгәндер, күлмәк тә лач итеп яр читенә килеп төште.

Уңга-сулга йөгереп йөри торгач, Садыйк тәмам әлсерәгән иде.

— Алла хакына чык инде, баҗай,— диде ул, яр буена чүгәләп.

— Син ларекка йөгермичә чыкмыйм.

Садыйк кулларын өметсез генә селтәде дә хәлсез адымнар белән яр өстенә күтәрелде, Сафа күрмәгәндә генә шундагы сарай артына посты. Үзе күздән югалгач теге юләр судан чыкмасмы, янәсе.

Билгеле, прицепны ялгызы да төйи алган Фәйзелхак йөгәннән ычкынган бу юньсезне ярга бик җиңел сөйрәп чыгара ала, тик теләми генә. Беренчедән, суга керү өчен үзеңә чишенергә кирәк, икенчедән, Сафа судан чыкса, карап торырга кызык бетәр сыман. Үз туганы яки якын танышы булса бер хәл иде, әллә кайдан килгән җиде ят өчен нигә мәшәкатьләнеп торырга!

Салисә ханымның су өстендә сары майка белән бигрәк тә шыксыз күренгән Сафага ачуы арта төште:

— Баҗаң да китте. Чыгасы булсаң чык, үләсе булсаң дөмек. Су өстендә сары шалкан кебек шакраеп торма!

Әхәт бабай мыек астыннан елмайды:

— Үлмәсен әле, үлмәсен. Чалбары әрәм китә ләбаса...

Сафа үзенә югарыдан чекерәйгән күзләргә мыскыллы елмайды, нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты, ләкин эндәшмәде, яңадан чумды. Бу юлы шактый озак калыкмады. «Бетүе шушы булдымы әллә?»— дип шүрләгән Әхәт бабай мыек чылгыйларын тарткалый да башлаган иде инде, Сафа су өстенә калкып чыкты, чумган арада салып өлгергән чалбарын селтәнеп күпергә ыргытты, чалбар култыкса өстенә килеп төште.

— Кибә торсын,— дип кыткылдады Фәйзелхак.

Фәхрия әби Сафа ягына төкерде дә пристаньга кереп китте. Башкалар да аның артыннан кузгалдылар. Чыннан да, алар өчен хәзер Сафаның кызыгы беткән иде: чишендерәсен чишендерделәр, әйтәсен әйттеләр, рәхәтләнеп көлделәр, вакытлары да сизелмичә күңелле үтте.

Ул арада үзләре яши торган бүлмәдән балык шулпасы асып җибәргән начальник хатыны килеп чыкты. Юеш кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә юлчыларга эндәште:

— «Метеор» килә. Билет алыгыз.

Бөтенесе дә кассага тезелделәр. Һәркайсы тизрәк кайтып җитү, кардәшыру, күрше-күлән белән күрешүне уйлый иде, тик Сафа гына берсенең дә күңеленә кереп чыкмады. Алар өчен бу дөньяда ул әллә бар, әллә юк!

«Метеор» килеп туктады. Юлчыларыбыз әчкә уздылар. Йомшак урындыкларга киерелеп утырдылар. Ник утырмаска! Дөнья тыныч, үзләре сәламәт, кайгы-хәсрәтләре юк. Алар, «Метеор»ның кузгалып китүен көтеп, тәрәзә аша пристаньга карап торалар. Шулвакыт юеш киемнәрен култык астына кыстырган, кулына сыңар ботинка тоткан Сафаның басма буенча «Метеор»га йөгереп узуын күрделәр, урыннарыннан кузгалдылар да, яңа мәзәк өмет итеп, әлеге басма янына килделәр. Билетларны тикшереп кертүче кыз ике кулы белән Сафаның беләгенә ябышкан.

— Билетың кайда? Билетың?—дип сорый ул.

Сафа кан баскан күзләрен челт-челт йома, калтыранган куллары белән юеш костюмын сүтәргә тырыша, үзе бер үк сүзне кабатлый:

— Пинҗәктә, пинҗәк кесәсендә...

Начальник исә Сафаны җилкәсеннән алга таба төрткәли, кызга ялына:

— Пожалысты моны ал инде, Тоня, алдагы пристаньда төшереп калдырырсың.

— Бу кыяфәтендә ничек алыйм мин аны?—ди Тоня.—Безнең идәндә кыйммәтле келәмнәр, урындыкларда ак япмалар. Барысын да пычратып бетерер бит ул...

Сафа әле күптән түгел генә күпер култыксасыннан үзенә карап торган «танышлар»ын шәйләп алды. Бәлки алар ярдәм итәр? Сафаның күзләре аларга текәлде, аларныкы Сафада иде. Бабай хәйләкәр елмая, карчык күзләрендә рәнҗеш, чибәр ханым күзләрендә салкын кызыксыну, иренендә—битарафлык. «Болардан мәрхәмәт булмаячак»,—дип өметен кисте Сафа. Җитмәсә, ут өстенә керосин сипкәндәй, бала күтәргән хатынның тавышы колагын ярды:

— Кертмәгез, кертмә, андыйлардан болай да җиң күргән!..

Шул вакытта тыны-коне кысылган Садыйк килеп өлгермәсә, бәхәс ничек бетәр иде, әйтүе читен. Сафага ул билет сузды:

— Бар инде, тизрәк бул, каласың бит!..

«Метеор» белән пристань арасындагы басманы шунда ук тартып алдылар. Сафа, беренче эш итеп, «Метеор»ның юыну бүлмәсенә узды.

Кузгалып киттеләр. Көймә күңелле генә гөлдердәп алга оча. Башларын күккә сузган, яр буендагы мәһабәт тирәкләр, яшел шәлләрен суда чайкаган купшы таллар артка таба йөгерәләр. Акчарлаклар һава кисеп оча. Түбәнгә узган пароходлар сәлам биреп китә...

Тәмам кәефе килгән Фәйзелхак елмаеп Алмазиягә карады. Алмазия ханымга бу караш күптән таныш: «Рөхсәт итсәнә»,—дип әйтүе инде бу. Дулкыннар өстендәге гаҗәеп тирбәлүдән Алмазия ханымның күңеле күтәренке вакыты иде: карлыгач канатыдай кашларын сизелер-сизелмәс кенә җилпеп куйды. Димәк, рөхсәт! Фәйзелхак җәһәт кенә чемоданнан тегe «ни»не тартып чыгарды, Әхәт бабайга ым какты. Бабай исә күзләрен мөлдерәтеп әбигә карады. Карчык юаш кына итеп ачуланырга тотынды:

— Бер аягың җирдә, икенчесе гүрдә, яшьләргә ияреп узынма...

Әхәт бабай мыек чылгыйларын бөтергәләде:

— Узынырга аллам сакласын, анасы! Тавык итләрең кайда соң? Мин капкалап алырга гына дигән идем.

Фәхрия әби Әхәт бабайның капкаудан соң «йотачагын» белсә дә, сүзне артык куертмады. Нәрсә әйтсәң дә, илле ел бергә гомер кичерделәр, яшәгән

кадәр яшиселәре калмагандыр инде. Кунактан кайтканда да нигә бер-берeңнeң кәефен бозарга?

Чемодан өстенә пристаньда ашаганнан соң калган ризыкларны тезеп куйдылар. Фәйзелхак ике стаканга да яртышар итеп салды. Фәхрия әби алар янында утыруны яхшысынмады булса кирәк: «Яр кырыйларын карап барам әле»,— дигән булып, иң читтәге урындыкка күчте. Алмазия ханым бушаган термосны күтәреп, кайнар су алырга китте. Ирләр стаканнарын күтәреп җибәрделәр дә йомшак күмәч белән тавык ите чәйни башладылар.

Юлчылар шушы эшләр белән мавыккан арада, Сафа өстенә киенеп юынгычтан чыкты. Әллә махмырдан, әллә суда озак торудан инде, иреннәре күгәргән, колагы гөжли иде. Ул, якын дусларымның берәрсен очратмаммы дип, күзләрен урындык рәтләре буенча йөртә башлады. Карашы Әхәт бабай белән Фәйзелхакта тукталды. Алларында стакан. Таныш ис борынын ярып керде. Бөтен гәүдәсе дерелдәргә тотынды: алларында ак бар! Их, аңа да өлеш чыгарсалар! Бер адым атлады, икене, өчне...

— Ризыклар тәмле булсын!..

Әхәт бабай белән Фәйзелхак икесе берьюлы күтәрелеп карадылар: каршыларында Сафа басып тора иде. Әштер-өштер генә сыгып кигән чалбарында һәм пинҗәгендә юеш ком. Бөтен гәүдәсеннән пар күтәрелә. Карар күзгә кызганыч та, җирәнгеч тә иде ул бу минутта. Әхәт бабай чыраен сытты. Сафа биргән сәламне алмады, башын тәрәзәгә борды. Фәйзелхак, ак күлмәгенә Сафа бәрелмәсен өчен, урындыкның теге читенәрәк шуышты. Икесе дә Сафа белән сөйләшүдән хурланалар, аның моннан тизрәк табан ялтыратуын телиләр иде. Ә Сафаның китәргә һич исәбе юк. Каккан казыкмыни, баскан урынында тик тора. Беренче булып Фәйзелхакның сабыр канаты сынды:

— Буш урын юклыгын күрмәскә күзең чыкканмыни?! Алдагы рәтләргә уз!

Мондый сүздән соң Сафаның тәне салкынаеп китсә дә өмете бөтенләйгә сүнмәгән иде әле. Гәпләшеп алсак, килешеп тә китмәбезме, дип сүз башлады:

— Миңа көйрәтергә генә...

Фәйзелхак аңа папирос тоттырды:

— Мә. Ләкин монда ярамый, әнә, теге ишектән чыгып...

Сафа Фәйзелхак күрсәткән ишектән чыгып китте. Әхәт бабай белән Фәйзелхак, җилкәләреннән тау төшкәндәй, җиңел сулап җибәрделәр. Алмазия ханым кайнар су алып килде.

Сафа папиросын теләмичә генә суыра, күз алдында әле генә күреп килгән шешә бии, авызыннан сулар килә, ашказаны укмашып бөтерелә. Ул, сүнгән папиросын кабызу өчен шырпы эзләп, кесәсенә кулын тыкты, кулына салкын түгәрәк металл бәрелде. Акча түгелме? Алып караса — бер сумлык көмеш! Менә күктән төшкән бәхет! Теге чакта Садыйк тыккан булырга тиеш. Ул шунда ук сүнгән папиросын чүп савытына ыргытты, кулына әлеге берлекне кысты, гәүдәсен байларча тотып эчкә үтте.

Танышлары хуш исле итеп пешерелгән кайнар чәйне бер-ике генә йотканнар иде әле. Алларында эчемлек салынган стаканнары да шул килеш тора. Сафа, бүтән кая барсын инде, тагын алар янына тукталды. Әрсез алабайны яннарында кабат күргәч, Фәйзелхакның иреннәре тартышып куйды:

— Тагын папирос кирәкме?— диде ул.

Җавап урынына Сафа кулындагы көмешне сузды:

— Мине дә өлешкә катнаштырыгыз әле, туганнар...

— Беренчедән, без сиңа туганнар түгел, икенчедән, безнең табында синең өлешең юк,— диде Фәйзелхак кырт кисеп.

Сафа үзенекен тукыды:

— Хәлем авыр минем, алла хакы өчен...

Фәйзелхакның түземе беткән иде, сикереп торды:

— Алла хакын алланың үз каршына баргач сорарсың. Типкәләп озатканны көтәсеңме?..

Фәйзелхакның ярсып әйткән сүзләре Сафа өчен аякка ябышкан балчык кадәрле дә түгел иде. Һаман үзенекен сукалады:

— Типсәң дә риза, суксаң да бәхил, ярты гына стакан...

Фәйзелхак аягына басты, Сафа каршына килде, тегенең күз төпләрендә берәр бөртек яшь, күгәргән йөзенә сары су бәргән, шешенгән иреннәре еларга әзерләнгән баланыкыдай мимылдап тора. «Типкәләп озатсаң да артыннан үрмәләп киләчәк. Бу афәттән котылу әмәле бер генә: сораганын бирергә»,— дип уйлады Фәйзелхак һәм үзенә дигән стаканны Сафага сузды. Тегесе аны күз ачып йомганчы эчеп тә җибәрде. Әхәт бабай аңа күмәч кыерчыгы сузды, үзе янында сәләмәләр буталуын сөймәгән Алмазия ханым, бармак очлары белән генә чеметеп, тавык муены тоттырды:

— Монда йөрмә инде син... Әнә теге почмакта буш урын бар. Аңладыңмы?

— Аңладым,— диде Сафа. Кулындагы көмешен алмалар тезелгән газет өстенә ташлады, ләкин өч адым да атламагандыр, аңа Әхәт бабай эндәште:

— Кил әле, чибәр егет...

Сафа күңелендә яңа өмет балкыды: бәлки, тагын аз гына... Кире алар янына килде. Бабайның йөзе бу юлы җитди дә, кырыс та иде:

— Мә, бездән сиңа сәдака!..

Сафа үз уч төбендә юеш көмешнең салкынын тойды. Табын тирәсендәгеләр, аның йөзен күрмәс өчен, башларын читкә бордылар. Моннан соң Сафа аларны борчымады. Бер читтә тавык муены кимерде. Бу минутта чүплектән тапкан сөякне ялаган эт шикелле иде ул.

Сәгать ярым вакыт тиз узды. Яр-Тамак пристанена килеп тә җиттеләр. Әхәт бабайлар урыннарыннан кузгалды. Пристаньнан «Метеор»га сузылган басманы узганда Фәхрия әби ят сулау ишетте. Борылып караса, сыңар ботинкасын күтәргән Сафа аның артыннан атлый иде.

— Бәй, кая барасың?— диде гаҗәпләнгән Фәхрия әби.— «Метеор»ыннан калырсың бит...

— Калсам ни, аның миңа кирәге дә юк.

Фәйзелхак Әхәт бабайга:

— Салган баштан саташа,— диде. Аннан Сафага борылды.— Үзең керәсеңме әллә озатып куйыйммы?

Барасы юлы әле шактый ерак калган Салисә ханым «Метеор»дан чәрелдәде:

— Кертмә, кертмә, андый дуңгызның абзары — үз фермасында.

Алмазия ханымның җене котырды:

— Әллә миңа бик хаҗәт дисеңме аны?..

Ирләр хатыннарның кычкырышуына игътибар итмәделәр. Әхәт бабай Сафаны өлкәннәрчә үгетләргә тотынды:

— Сиңа бу пристань түгел, ялгыш чыгасың, энем...

Сафа шик-шөбһә калдырмаслык итеп елмайды гына:

— Үзегезгә бу пристань түгел, мин шушы районда яшим!..

Алмазия ханымның күзләрендә яшен уйнады:

— Кибеттә сигезенче ел эшлим. Шофер булгач, бер сугылмасаң, бер сугылыр идең...

— Мин дә шофер,— диде Фәйзелхак.— Юлда ялгыш та очрашмадык бит. Алдашып торма, әйдә әле...

Берсенең дә Сафаны биредә калдырасы килми. Туган яклары гаҗәеп шул: тау башыннан сузылып киткән нарат урманы дисеңме, игене белән күпереп торган кырлар, печәне каерып ала алмаслык болыннары дисеңме?.. Юк, Сафа аларныкы түгел. Китсен моннан — Әхәт картлар туфрагыннан. Теләсә күккә очсын, теләсә җиргә сеңсен. Дүртесе дә Сафаның якташ булуына ышанмый, моны вөҗданнары кабул итә алмый иде. Әле соң түгел, тизрәк озатырга кирәк үзен. Әхәт бабай белән Фәйзелхак Сафаны ике култыгыннан эләктерделәр дә пристаньга таба сөйри башладылар. Сафа карышты, аякларын терәде:

— Саклау авылыныкы мин. Көрәшче Бәхти малае!..

Үзләреннән ерак булса да таныш авыл исемен ишеткәч, сагаеп калдылар. Бәхти карт үз заманында биш ел рәттән мәйдан тоткан кеше. Аны күрше районнарда да яхшы беләләр иде. Дүртесенең дә күзләрендә аптырау, гаҗәпләнү. Әхәт бабай сакалын кашыды:

— Бәхти кордаш малае булсаң, әйт әле: аның кул-аягында яра-мазар юкмы?

Сафа уйлап та тормый җавап кайтарды:

— Сугышта чакта йөзен снаряд кыйпылчыгы ярган. Шуның җөе бар.

Икеләнергә урын калмады. Дүртесенең дә муен тамырлары бүрткән, йөзләрендә нәфрәт! Теге пристаньда адәм мәсхәрәсе булган кеше тәки аларның якташы булып чыкты бит! Хәзер инде Сафадан берсе дә көлми, аны берсе дә җәлләми, киресенчә, аны яңадан суга ыргытасылары, дөмектерәселәре килә иде.

Сүзне Алмазия ханым башлады:

— Ит биргән булдым, якташ икәнеңне белмәдем шул, белмәдем...

Фәхрия әби Әхәт бабай белән Фәйзелхакны битәрләп ташлады:

— Яшь юләр белән карт юләр, шул мәлгуньне үзләренә дигән аракы белән сыйладылар җитмәсә!..

Әхәт бабай акланырга тырышты:

— Бәхти малае икәнен белсәм, район данын сатып йөргән өчен тегендә ук милициягә олактыра идем мин ул мошенникны!..

Фәйзелхак барысыннан да ныграк офтана булса кирәк, иреннәрен чәйни, вакыт-вакыт тешләрен шыгырдатып куя иде:

— Кемлегеңне башта ук белсәм, беренче эш итеп уңлы-суллы яңаклар идем, аннан аяк-кулларыңны бәйләп, айныганчы кеше күзе төшмәс җирдә йоклатыр идем. Niләр генә кыланмадың, хайван!..

Уңайсыз тынлык урнашты. Бер-бере каршында аклану өчен сәбәп, берберен гаепләү өчен нигезле дәлил таба алмаудан туган иде бу тынлык. Сүзне тагын Алмазия ханым башлады:

— Адәм гаре, юл буенча кешедән теләнеп эчеп кайта бит...

Сафа, чибәр ханымнан йөзен яшерү өчен, тубал башын түбән иде:

— Теләнә дип, сезнең якташ икәнегезне каян белим?!

Әхәт бабай кызып китте:

— Оста гына акланмакчы! Якташ икәнебезне белмәгән, янәсе. Якташ булсак та, булмасак та без кеше бит, кеше! Шул чаклы кадерсезләнергә... оятсыз! Теге бер сумын да кире бирәсе калмаган, җәяү кайтсын иде мошенник.

Сафаның моңа һич исе китмәде:

— Монда минем танышлар уйма.— Ул кулы белән яр өстендәге йортларга күрсәтте.— Буш чагың туры килгәндә машинаң белән утын, печәнебезне алып кайтырсың әле дип, урам саен унар кеше унар сумлык сузып тора! Алыгыз, сый-хөрмәтегез өчен!

Ул кесәсендәге көмешне ком өстенә ташлады, аннан: «Сезгә башка бурычым юк!»— дигәндәй, туры гына басып яр өстендәге өйләргә таба атлады. Фәйзелхак ачу белән Сафаның сукмактагы эзенә төкерде:

— Тьфу!..

Әмма моннан берсенең дә күңеле җиңеләймәде, тәкрекнең бер өлеше үз йөзләренә чәчрәде кебек. Юлларына борылдылар. Әнә алар ашыга-ашыга атлыйлар: үз төкрекләрен үз йөзләрендә күрүдән хурланалар, күрәсең.

Бу минутларда Садыйк белән Зәйнәп ханым, Сафадан бу юлы азрак чыгым белән котылуларына шатланып, тирли-тирли чәй эчәләр иде. «Метеор»дагы Салисә ханымның да кәефе күтәрелде. Аңа, теге исерек төшеп калгач, бөтен дөнья яктырып китте сыман. Ә ларектагы кызыл тырнаклы ханым белән милиционер формасы кигән яшь егет һәм бүрекле әби белән пристань начальнигы исә Сафаны бөтенләйгә онытырга өлгергәннәр иде. Шулай булмый ни, Сафаның маҗараларында аларның тузан бөртеге кадәр дә катнашлары юк ич...

# Роман Солнцев

## Төнге сорау

Төнге вокзал. Буфет. Бәхәсләштек.
Кырыслыгын тойдым мин аның.
Күзләрендә очкын кабындырып:
— Бармы,— диде,— синең иманың?

Сигез яшьтән бирле ак уйларым
Көн дә
Йөрәк аша уза яндырып!
Уйлап куйдым: шушы микән соң ул
Иман-мәсләк, шайтан алгыры?

Алар өчен утка керерменме,
Басармынмы ядрә каршына?
Әйе, дидем. Һәм шуңардан бирле
Кибә тамак, җаным ярсына...

* * *

Туган йортка кайтасы бар, саклап йөрәк утымны.
Чыңлатып ярсаң иде, дим, карлы-бозлы утынны!
Ишегалды уртасында
Чикерткәдәй атылышыр пүләннәр!
Ә болдырда сеңел: «Саграк кылан...»
Ә болдырда әнкәй: «Чү син, олан,
юкса тәрәзәне ватарсың...
Кышкы чиллә!
Бияләең салып ташла — кар өстендә алар
Эт авызыдай кайнарланып сулый!
Аннары чәй...
һәм дә дымлы газета битләре.
Арган караш белән юлларны капшыйсың үртәлеп.
Өлгермисең сүзләр тавыннан мәгънә эзләргә,
Инде йокы пәрдәсе төшкән була күзләргә...

Мин төш күрәм — ишегалды уртасында
Чикерткәдәй атылыша пүләннәр.

---

Роман Харис улы СОЛНЦЕВ (1939) — *безнен якташыбыз, шагыйрь, прозаик һәм драматург. Рус телендә чыккан дистәләгән китаплар авторы. Красноярскида яши.*

* * *

Учак өсләрендә ялкын бии —
Үрә баскан аттай ыргылып,
Иманнарне бәреп узар төсле
Әрәмәнең гамен туздырып!

Янәшәмдә моңсу утырасың,
Иңнәремә минем тотынып.
Җылытасың тәнне, уйларымны...
Шартлап яна учак утыны.

Без икебез ерак юлга чыктык.
Мин яшь егет. Ә син — кәләшем.
Качып киттек таныш-белешләрдән,
Ник тетрәүле бүген халәтем?

Ял-ял булып учак өсләрендә
Ялкын арты ялкын тирбәлә:
Алсу атлар — офыктагы атлар
Гүя безне куа киләләр...

## Көзгедәге чагылыш

Ярга ятып сулар эчә кызый,
Ак ташларда — зифа гәүдәсе.
Су төбеннән карап тора аңа
Кара йөзле карчык шәүләсе.

Иелеп-иелеп суга бакты әбкәй —
Ап-ак чәчле хода бәндәсе.
Су төбеннән карап тора кебек
Яшь бер кызның сылу чәһрәсе[1]

* * *

Очраштык та, язмыш-узмышымны
Кыл урталай ярып кына салдың...
Күперләрне сүтеп калдырдым,
Күперләрне тоташ яндырдым —
Миңа барыбер салкын!

*Рашат НИЗАМИЕВ тәрҗемәләре.*

---

[1] чәһрә — чырай, йөз.

# Юрась Свирка,

белорус шагыйре

* * *

«Яфракларны коеп йөри көзен»,—
Кемнең җилгә таккан яласы?
Ул кагыла гына агачларга,
Килә шулай назлап каласы.

«Май аенда җилләр инде көчсез,
Яфракларны өзми, күрәсез...»—
Юк сүз бу да...
Әгәр җене чыкса,
Йортлар кала хәтта түбәсез.

Яшәешне сөя җил малае—
Көзге яфрак сөенеп оча ла!
Ләкин тиздән— күпме тибрәнсә дә—
Туры килер җирне кочарга...

## Диңгез хыялы

Диңгезне мин күзәткәнем бар,
Күзләр арый чиксез киңлектән.
Киңен киң дә, җир өстенә ул
Һөҗүм итә икән нилектән?

Балачактан бирле юмарт мин.
Юатырга телим көйсезне:
Кошларга җим сипкән шикелле,
Вак таш белән сыйлыйм диңгезне.

Ә ул туя белми икән лә,
Риза түгел минем сыема,—
Элек хуҗа булган җирләрне
Кайтарырга ахры җыена.

Бер мизгел дә тынгы белми ул,
Нәни җиңү—һәрбер таш аңа...
Шуңа күрә — ярсу чиру кук
Дулкыннары ярга ташлана.

*Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәләре.*

## Туган авылда

Авылымда мин кунакта бүген,
Ишетелми шәһәр шавы монда.
Авылымда шигырь язмыймын мин,
Шигырь укымыйм мин авылымда.

Үз өемдә шигырь укысам гел—
Авылымның табигатен мактап,—
Үз-үземне мин күрәлмас идем,
Кулга каләм алмас идем хәтта!

Мин картларны беләм—изге картлар!
Сорар алар, күзгә карап әйтер:
—Соң син, улым, нигә киттең моннан,
Дан җырларлык булгач табигате?..

*Ләбиб ЛЕРОН тәрҗемәсе.*

## Михаил Сениэль,

чуваш шагыйре

### Төнге теләкләр

Төн инде туган җиремә,
Авылыма килде төн.
Йоклагыз, этләр, агачлар,
Шауламагыз — инде төн.

Йоклагыз, йолдыз, чишмәләр,
Йоклагыз — Кояш юкта.
Урман аръягына барып,
Көмеш Ай, син дә йокла.

Нәни кызым, йокла син дә,—
Мәңгелек яралгысы.
Куркытмасын дим үзеңне
Дөньяның караңгысы.

Йокла, кызым. Имин йокы
Телик һәммә кешегә.
Сине сөяр чая егет
Керсен димен төшеңә.

Сине сөяр чая егет
Җилеп килер ак атта.
Тик мин генә бабай булып
Күренермен ул чакта.

Төн килде туган җиремә,
Йоклагыз, агачларым.
Сөю йолдызын җуйсам да,
Барыбер адашмамын.

Аһ сез, алтын мизгелләр,
Хәерле йокы сезгә!..

### Бакча

Ай нурында коеналар
Каеннар.
Әйтче, бакчам, нинди сагыш,
Кайгың бар?

Хатирәләр күз яшьләрен
Кайната.
Әйтче, бакчам, безнең ярлар
Кай якта?

Сүзсез генә узган идек
Без моннан —
Тик үзебез тапкан Сөю
Юлыннан.

Кемнәр безнең сөюләргә
Ук атты?
Кемнәр анда таптый безнең
Сукмакны?

Эзләр безнең — ак чәчәкле
Майларда.
Ярлар гына калды — әллә
Кайларда.

Хатирәләр күз яшьләрен
Кайната...

* * *

Колаклы Ай йөзә күктә,
Бөдрә болытлар ага.
Беләмсең, Анна, син шуны —
Ни көтә безне алда?

Юлымнан тайпылдым ялгыш —
Менә шундый хәлләрем.
Мин хәзер китәргә тиеш,
Тик син әйтмә: «Хәләлем».

Тик син әйтмә «Яраттым» дип,
Тик син сорама: «Кая?»
Яшьлеккә илтер җырым син,
Шатлыкка илтер кайгы.

Беләмсең, Анна, син шуны —
Ни көтә безне алда?..
Колаклы Ай йөзә күктә,
Бөдрә болытлар ага.

*Газинур МОРАТ тәрҗемәләре.*

Вахит Юнысов

# ИБРАҺИМ ГАРӘП ЧӘЙХАНӘСЕ

Багдадны икегә бүлеп, шәһәрнең нәкъ уртасыннан Дуҗлә елгасы ага. Аның сул як ярындагы яртысы — Расафа, уң як ярындагысы Кәрх дип атала.

Моннан 1000, 1200, хәтта 1300 ел элек салынган атаклы мәчетләр, Хәлифә сарайлары, Гыйрак халкының горурлыгы булган тарихи һәйкәлләр — күбесенчә, Расафа ягында: монда атаклы һарун әл-Рәшид, Сәгъдүн һәм Җөмһүрия урамнары, Мустансирия мәдрәсәсе, Мәрҗән һәм Хәлифә мәчетләре, Газел манарасы һәм онытылмаслык Сук әл-Шәрҗи базары.

Борынгы Багдад биек һәм калын койма белән әйләндереп алынган, һәм аңа дүрт капка аша гына үтеп керә торган булганнар. Хәзер ул капкалар юк, ләкин аларның исемнәре сакланган: Баб әл-Шәрҗи һәм Баб әл-Моаддам («Шәрҗи капкасы» һәм «Моаддам капкасы») — Багдадта яшәүче һәр кешегә таныш җирләр.

Баб әл-Моаддам тирәсендә бихисап чәйханәләр урнашкан. Аларны кайбер гарәп «гәһвәханә» дип атый. Монысы да дөрес, чөнки һәрбер чәйханәдә чәй дә, кофе дә («гәһвә»), баллы ширбәтләр дә, әйрән дә эчәргә мөмкин.

Безнең илдә чәйханәгә гадәттә аз-маз капкалар өчен генә керсәләр, гарәп илләрендә чәйханәгә дус-ишләр белән очрашып эчләрен бушатыр өчен, яңалыклар ишетер өчен, рәхәтләнеп ял итәр өчен, буш вакытларын ләззәтләнеп уздыру өчен йөриләр.

Мәсәлән, дәүләт идарәсендә эшләгән гарәп көндез сәгать икедә янсә өчтә, эшен бетереп өенә кайта, ашый-эчә, бер-ике сәгать йоклап ала, аннан соң ашыкмыйча гына үзенең яраткан гәһвәханәсенә китә. Анда җыелган кешеләрнең барысы да диярлек аңарга таныш, чөнки алар — инде монда бергәләп бик күп кичләрне үткәргән кешеләр. Әгәр берничә кич танышларның кайбере күренмәсә, аның сәбәбен башка дус-ишләр аңлатып бирә:

— Хөсәен өйләнергә җыена икән, Басра кызына. Шул эш артыннан туганнары янына, Басрага киткән.

— Вәлид чирләп ята, ди.

— Абдурразакны алты айга Лондонга укырга җибәргәннәр...

Башка дус-иш, туган-тумача, таныш-белеш барысы да — монда. Алар ашыкмый, кич — аларныкы. Бөтен яңалыклар, — дөнья, ил, шәһәр, мәхәллә һәм гаилә масштабында, — монда бәян кылына, нәтиҗә ясала, бәя бирелә.

Ашаган кеше бик сирәк. Эчемлеккә килгәндә, кем нәрсәгә әвәс — шуны эчә. Иң яраткан эчемлек — кофе. Гадәттә аны «дәллә» дип аталган җиз кувшин сыман савытта кайнаталар. Гәһвәчи теләгән кешенең кечкенә фарфор чынаягына дәлләдән аз гына кофе салып чыга. Госман төрекләре заманыннан калган гадәт буенча монда кофе ясаучыга төрекчә «гәһвәчи», ә чәй ясаучыга «чәйчи» дип эндәшәләр. Гомумән, Багдадта төрекләрдән калган сүзләр аз түгел. Мәсәлән, гаилә башы үсмер малаен гарәпчә сүгә-сүгә дә, ахырда, гел безнеңчә итеп: «Әдәпсез!» — дип йомгаклап куя.

Чын гарәп кофены шикәрсез эчә. Кофе бик куе, әчкелтем, чөнки аңа кардамон һәм далада үсә торган ниндидер кыргый үлән орлыгы өстәлгән. Кофены бер-ике йотым гына эчеп куялар.

Унбиш-егерме минут саен гәһвәчи теләгән кешегә яңадан кайнаткан кофе өсти. Дәллә бер кичтә чәйханәне җиде-сигез мәртәбә урап чыга.

Чәйханәдә хатын-кыз юк, монда ир-ат кына җыела. Һәркем үзенең яраткан уены яки шөгыле белән мәшгуль: домино, нард уены уйный, кальян (монда — «наргиле») тарта, ә күбесе, сирәк кенә әңгәмәгә кушылып, әкрен генә дисбе (монда — «сөбхә») тарта-тарта башкаларны тыңлый.

Чәйханә хуҗасы, гадәттә, үзенең кунакларын яхшы белә, кунаклар да хуҗаны яхшы беләләр, алар арасындагы мөнәсәбәт тә дуслар арасындагы яисә гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтне хәтерләтә. Әгәр түләргә акча юк икән, киләсе килгәндә түләргә мөмкин, бу — гадәти хәл. Алдашу юк, аны башка да китерергә мөмкин түгел.

Кайбер кеше — өстәл янында, урындыкларда, тәлгәне аяк киемнәрен салып, келәм җәйгән сәке сыман урынга менеп, борынгыча, аякларын бөкләп утыра.

Һәркемнең үзе яраткан гаһвәханәсе, чәйханәсе бар. Кайсында — картайган офицерләр, башкасында — яшь шагыйрьләр, кайберендә ген студентлар гына җыйнала.

Алтмышынчы, җитмешенче һәм сиксәненче елларда Багдадның Баб әл-Моаддам мәхәлләсендәге Ибраһим Гарәп тоткан чәйханәнең дан-шөһрәте студент яшьләр арасында киң таралган иде. Кырык ел чамасы бер үк чәйханә-гаһвәханә хуҗасы булып калган кеше турында риваятьләр, имеш-мимешләр әле һаман да күп йөри, аның кайсы дөрес, кайсы уйдырма булуын беркем дә тәгаен әйтә алмый.

Сөйләүләре буенча, Ибраһим гарәп түгел, чыгышы буенча, төрек булган.

— Ибраһим, син чыннан да төрекме?— дип кызыксынып сораган кешеләргә тәэсирләнеп, хәтта ярсулы кыяфәт белән ул һәрвакыт:

— Юк, гарәп мин, гарәп, гарәп!— дип җавап кайтара икән. Шуннан соң аңар «Ибраһим Гарәп» дигән кушамат тагылган. Җиде дистәне тутырып сигезенче дистәне башлагач, ул кинәт кенә дөнья куйган. Ибраһим Гарәпне күмгән көнне Багдад университетында һәм колледжларында дәресләр булмаган, имеш, чөнки бөтен студентлар яраткан гаһвәханә хуҗасы белән саубуллашырга киткәннәр...

Багдад кешеләренең сөйләве буенча, Ибраһим Гарәп үз гаһвәханәсен, асылда, акча табу өчен түгел, җаны-тәне белән ул эшне яратканы өчен тоткан. Бу хакта минем дустым Хөсәен ышандырырлык мисаллар китереп сөйли. Аңар ышанырга мөмкин,— ул үзе Багдадта укыганда, күп кичләрен шул гаһвәханәдә уздырган, шунда шигырьләр яза башлаган, хәзер дә Анна Ахматова, Цветаева һәм Пастернак шигырьләре, аның тарафыннан инглиз теленнән гарәп теленә тәрҗемә ителеп, Гыйрак журналларында басылып чыга.

Инде дустымның сөйләгәннәренә күчик.

***

...Бер кечне гаһвәханәгә 30-35 яшьләр тирәсендәге бик затлы киенгән кеше килеп керә, Ибраһим Гарәпкә сәлам бирә һәм аның залдан үз бүлмәсенә керүен үтенә. Хуҗа аны бүлмәсенә чакыра, кофе китертә, хәл-әхвәлләрен, кем икәнен сораша.

— Мине танымыйсызмыни?— дип елмая кунак.— Мәхмүт бит мин! Хәтерегездәме, моннан ун ел чамасы элек монда бик еш килеп йөргән мыексыз ябык егет мин?

Кунак кесәсеннән студент чагындагы фоторәсемен чыгарып күрсәтә.

— Йа хода! Әй, гомерләр, гомерләр... Ә бит мин сине, Мәхмүт, танымадым, чит илдән килгән министр дип торам. Ай-һай бигрәк тә кәттә киенгәнсең, Мәхмүт, йөз-сыннарың да патшаларныкы кебек, күз тимәсен, сөбханалла-машалла! Йә, сөйлә, кайларда йөрдең, нәрсәләр күрдең, кем булып эшлисең?

— Лондоннан медицина буенча докторлык дәрәҗәсе алып кайттым мин, Ибраһим ага.

— Йәссәлам! Алла юмартлыгының чиге юк!

— Менә Багдадка кайтып, үземнең хосусый шифаханәмне ачып җибәрдем. Анда миннән башка унсигез табиб һәм хезмәткәр эшли. Менә дүртенче ел инде, эшләрем бик әйбәт бара.

— Мәбрүк, Мәхмүт улым! Алла гомереңне озайтсын! Безне онытмый килеп чыгуыңа рәхмәт!

— Килеп чыгуның сәбәбе бар бит, Ибраһим ага. Мин бит сезгә күптәнге бурычымны түләргә килдем.— Мәхмүт дипломатын ачып, өстәлгә бер төргәк акча куя.

— Менә монда мең динар, Ибраһим ага, бу — минем сезгә булган бурычым. Мин бит ул чагында дүрт ай чамасы сезгә акча түләмичә йөрдем. Һәр кич саен килеп кофе эчтем, шербәт эчтем, акыллы кешеләрнең сүзләрен тыңлап, дөнья гыйлеме җыйдым, түләргә акчам булмады.

— Әй, Мәхмүт энем, акча өчен тотаммыни мин бу чәйханәне!?

— Тик мин үз-үземә ирләрчә ант иттем: бу бурыч — изге бурыч, мин аны, кесәмдә акчам җыелу белән, ун өлеше белән кайтарып түләргә тиеш, дидем. Озак түләмәгәнгә гафу итегез, бу — сезнеке!

— Юк, энем, мин андый оятсыз кеше түгел! Бу бит зур акча, аңа бер-ике ел элек әр-яңа автомашина сатып алырга була иде, нинди намус белән алыйм инде мин аны?

— Бу — минем бурычым. Аңа озак еллар түләми торган өчен процентлар да, минем яшьлек хатирәләрем өчен рәхмәтләр дә өстәлгән.

— Юк, энем, ала алмыйм! Искә алып килүең дә миңа зур мәртәбә!

— Мин антымны үтәдем, бу — сезнең акча. Аны ничек тоту — сезнең эш. Телисез икән — чәйханәгә ремонт ясагыз, яңа җиһазлар алыгыз, ярлы студентларны бушлай сый-

лагыз! Йә, хушыгыз, фемалля, исән-сау күрешергә насыйп итсен! Әгәр дә чирләп-нитеп китсәгез, миңа килегез!

Мәхмүт, акча төргәге янына алтын хәрефләр белән басылган визиткасын куеп, ике кулын биреп саубуллашып чыгып китә...

* * *

Ибраһимның Багдад яшьләре арасындагы популярлыгын белеп, аңа Багдадның иң атышлы мәхәлләләрендә бергәләп яңа рестораннар ачарга да тәкъдим ясап карыйлар. Бер бай аңар атап тулысынча үз акчасына, әр-яңа гәһвәханә сала, бөтен җиһаз һәм кирәк-яракны сатып ала, тик гәһвәханә-чәйханәнең исеме «ИБРАҺИМ ГАРӘП» булсын, Ибраһим үзе анда баш администраторлык итсен. Керем урталай бүленәчәк.

— Юк, энем,— ди Ибраһим.— Мин монда инде утыз елдан артык эшләдем. Минем җаным да, тамырларым да — монда. Тамырларымны йолкыйммыни?

Ләкин чәйханә данының икенче сәбәбе дә бар һәм бу сәбәп беренчесенә караганда көчлерәк тә, тирәнрәк тә.

Ибраһим ага сөйләргә ярата. Сөйли башласа, ул дөньясын оныта, хыялга чума, фантазиясе аны әллә кайларга алып китә. Чәйханәгә җыелган бөтен кеше аның авызына карап тынып кала. Бара-тора ул мавыгып китә, бер генә капылка да сыймаслык, тузга язмаган, һич кеше ышанмаслык нәрсәләр сөйли башлый, тик ул шундый матур итеп, нәфис итеп, артистларча сөйли ки,— тыңлаган кешеләрнең күз алдына ул сөйләгән вакыйгалар аллы-гөлле чынбарлык булып килеп баса. Шуны да онытмаска кирәк: Багдад халкы балачактан ук күп әкиятләр тыңлап үсә, аның күзалдына китерү сәләте, фантазиясе бик көчле, шуңа күрәдер ул хыялларны һәм уйдырмаларны бик ярата.

* * *

Менә бер яшь егет сөйли: Кербала шәһәрендә яшәгән әтисе үзенең бакчасында хөрмә агачы янына ятып йоклаган; йоклаганда аның куенына елан кереп яткан; әтисе торып киенерлә башлагач, куеныннан башын чыгарып торган еланны күреп тартып чыгарган, ләкин елан аның кулын чагып өлгергән, шифаханәдә көчкә коткарып калганнар; уң кулы әле һаман да эшкә ярамый икән.

— Аның чагуы гына куркыныч түгел,— дип әңгәмәне күтәреп ала Ибраһим ага.— Иң куркынычы — еланның авызга кереп китүе.

Нард һәм домино уйнаучылар уеннарын туктата, кызып бәхәсләшү, әңгәмә сүнә, чәйханәдә сәҗдәгә киткәндәге кебек тынлык урнаша. Ибраһим Гарәп сөйли:

— Елан минем үз авызыма кергәне бар,— дип дәвам итә гәһвәханә хуҗасы. Хәзер инде уенчылар һәм әңгәмәчеләр генә түгел, хәтта хезмәтчеләр дә чәй һәм гәһвә кайнатуларын туктатып, хуҗаның авызына карап катапар.

— Шулай бер кичне бик арып кайткач, бакчада чыпта җәйдем дә, ятып йокладым. Күпме йоклаганмындыр, белмим, тик авызыма нәрсәдер кереп барганын сизеп уянып киттем. Ни күзем белән күрим — авызга елан кереп бара, койрык очы гына күренә...

Чәйханәдәгеләр: «Аһ!» — итә.

— Мин андый-мондый карарга килгәнче, елан койрыгы инде минем авызга кереп тә бетте. Нишләргә? Елан белән бергәләп яшәргәме? «Юк, минәйтәм, булмый болай, Ибраһим абзаңны алай гына тот башына утырта алмассың!»

— Йә, йә, нишләттең соң аны?— Төрле яктан сораулар ява.

— Нишләргә? «Еланымны куып чыгарыгыз!» дип солдатлар чакыртып булмый бит инде. «Нигә соң авызыңны ачып яттың?» — дип мыскыллый башласалар? Миндә шундый гадәт бар инде, гел авызны ачып йоклыйм. Гаеп үземдә, әлбәттә. «Аятел көрсине» укымаганмын, аны укып ятсаң, җен-пәри дә, елан да якын килми.

— Эчеңә кергәч чакмадымы соң?

— Нишләп чаксын ди? Синең эчеңдә булсын да, сине чаксын! Бөтенләй шыр дивана түгел инде ул, елан дигәч тә!

— Тагын ни булды, сөйлә инде, сөйлә!

— Гаеп үземдә, дим, һәм үзем мин аның белән алыш-бирешне бетерергә тиеш. Нишләргә? «Ярар, минәйтәм, хәйлә белән алдырабыз сине!» Чыктым да, кибеттән дүрт шешә хөрмә аракысы, бер дистә күгәрчен йомыркасы алып кайттым. Мин үзем гомер эчә торган кеше түгел, гомердә дә эчкәнем юк. Әмма ләкин елан белән көрәшкәндә нинди корал кулплансаң да, алла ярлыкаячак. «Аллаһыма әшфи, би шифан!» дидем дә, бер шешә аракыны эчеп куйдым. Эчкә дә җылылык керде, башка да китте, ашказанының иң тирән җирендә нәрсәдер селкенгәләп тә куйды. Башлаган эшне урта юлда калдырып булмый,— тоттым да икенче шешәне каппадым. Баш шаулый, эчтә нәрсәдер гөжли башлады, күрәсең, елан чайкала. Өченче шешәне ачып бераз эчтем дә, җырларга, биергә тотындым. Сизәм: минем такмакка эчтә елан да бии, аның башына да ярыйсы гына китте ахры. Башлаган шешәдән салып эчеп бетердем дә, елан белән сөйләшергә вакыт икәнен чамаладым. «Ну, елан дус, хәлләр ничек?» — «Ярыйсы, яшәргә

була»,— ди каһәр суккан.— «Ашыйсың килмиме?»— «Эчертер алдыннан сорамадың бит, эчерттең, рәхмәт. Ашатуын да ашат инде, сорап торма!»— ди оятсыз.— «Ә синең ни ашыйсың килә?»— «Ә синең нәрсәң бар?»— «Нәрсә дә табарга була»,— дим. «Җаны теләгән — елан ите ашаган»,— дияргә теләгән идем, вакытында тыелып калдым, ни әйтсәң дә, урынлы түгел, үзе елан бит, үпкәләве бар. «Менә, мәсәлән, өстәлдә бер дистә күгәрчен йомыркасы бар»,— дим. Күгәрчен йомыркасы еланның иң яраткан ашамлыгы, аның өчен, ул — оҗмах тәгамы.— «Әйдә, китер!»— ди җир бит. Беләм инде, аны ашау өчен ул җанын бирергә әзер. Мин дүртенче шешәне ачып бераз салып эчтем дә, тегеннән сорыйм: «Син миңа дусмы?»— «Дус, бипгеле, дус булмасак, эчертмәс идең».— «Дус булсаң, чык, минем белән өстәл янына утырып эч, күгәрчен йомыркасы аша!»— дим.— «Алдашмыйсыңмы?» — «Ышанмасаң, әнә үзең өстәлгә кара, анда савыт тулы күгәрчен йомыркасы!» Үзем авызымны ачык калдырам. Сизәм: тиз-тиз генә күтәрелә, ялт-йолт итеп бүлмәне карап апа, өстәлдәге йомыркаларны күрә дә, авыздан сикереп төшеп, берсе артыннан берсен йота башлый.— «Чын егет икәнсең, Ибраһим, мең яшә! Тагын юкмы?»— «Көтеп тор, хәзер алып кайтам!»— дим.

— Ай-һай, хәйләкәр дә кеше инде син, Ибраһим!

— Башыңа төшсә, башмакчы булырсың? Кибеткә барып, тагын бер савыт күгәрчен йомыркасы алып кайттым. Кергәндә кышкы калын чапанымны да элэктердем. Карасам, еланым өстәлдә гырлап йоклап ята. Анысы гаҗәп түгел, мин үзем дә аягымда чак кына басып торам, әле дә ничек түзгәнмендер,— икебезнең дә гомеребездә беренче мәртәбә хәмер эчүебез бит! Нишләргә? «Әллә соң сугып үтерергәме?»— дигән сорау да туды башымда. Юк, ярамый. Мин бит — мөселман өммәтеннән. Ничек инде үз өемдә бергә ашап-эчкән затны сугып үтерәсең?! Мин еланны әйбәтләп чапаныма төрдем дә, бер кулыма чапан, икенче кулыма йомырка тутырган савыт тотып, бакчага чыктым. Тулган ай яктысында чапанга төргән еланны һәм савытны агач кәүсәсе янына куйдым да, догалар укып әйгә кереп яттым.

Хатыным төштән соң мине уята алмый бик озак җәфаланган.

— Ә еланны карарга чыктыңмы соң, Ибраһим ага?

— Чыктым. Чапан эчендә елан юк, билгеле, савыт та буш, йомыркаларны ашап бетергән. Ә савытта кечкенә генә хат кисәге ята.

— Елан язганмы?!

— Шул инде, тагын кем булсын!! Ибраһим, рәхмәт, дигән. Ашаттың, эчерттең, кунак иттең, дигән. Мин дә мәгънәсез түгел, яхшылыкның кадерен беләм. Бәйрәм ашы, кара-каршы: мин сиңа үземнең мөгеземне бүләк итеп калдырам. Мөгез синдә булганда, эшләрең әйбәт барыр, кайгырма, дигән. Тик башка кешегә бирмә дә, күрсәтмә дә, дигән.

— Менә син, ә, яхшылыкны елан да яхшылык белән кайтара!

— И-и, Ибраһим, синнән дә күп күргән кеше юк бу дөньяда!

— Тагын килеп күренгәне булмадымы соң ул еланның?

— Менә кемдә икән ул елан мөгезе!

— Тагын берәр күргәнеңне сөйлә әле, Ибраһим ага, ә?

Юк, Ибраһим Гарәп кенәнә бер генә хикәя сөйли. Берне сөйли, берәгәйлене сөйли...

***

—...Заманында мин дә бит сәүдә иткән кеше. Хәзерге сәүдә — сәүдәмени ул, менә мин яшь чакта, бер йөк машина товарны Согуд Гарәбстанына барып сатсаң, кесәңдә миллион динар була торган иде.

— Синең анда да барганың булдымы?

— Ник булмаска?!

— Сөйлә әле, Ибраһим ага, сөйлә!

— Мин типсәм тимер өзәрлек егет чакта, безгә чәй эчәргә күршебез Рамазан сәүдәгәр килеп керде. Аның сөйләве буенча, Согуд Гарәбстанында биниһая биек таш пулатлар сала башлаганнар. Ләкин аларда йорт төзү өчен арматура корычы юк икән. Әгәр бер тонна шундый тимер илтсәң, чирек тонна алтын бирәләр икән.

— Сөбханалла, машалла!

— Минем яшь чак, дуамал чак, тәвәккәлләдем. Берәүдән йорт салудан калган дүрт тонна арматурасын арзан гына сатып алдым. Бер танышымның йөк машинасы белән бер генә юлга барып кайтырга сөйләштем. Арматураны төядем дә, юлга чыктым.

— Ә шофер кем?

— Үзем инде, кем булсын! Мин бит малай чакта ук машина йөрттем. Корольның да машинасы юк иде әле — безнең ишек алдында мине ялтырап машина көтеп тора иде!

Көн матур, сәхрәдә кошлар сайрый, минем машина да канатлы кош кебек оча, тыеп та булмый.

Бер ярты көн баргач, машинам кинәт ютәлли, төчкерә башлады. Төчкерде-төчкерде дә, шып туктады, тынды. Тегендә басып, монысын борып карыйм,— юк, исе дә китми, бер сүз әйтми, кыймылдамый, дерелдәми дә. Бакны ачып карасам, анда коп-коры,

бер тамчы бензин юк! Минем запас бензин юк, ә бензостанциягә чаклы ун чакрыммы, мең чакрыммы — шайтан да белми. Нишләргә? Әгәр башым кашысам, нинди очракта да берәр чара уйлап табам мин. Башны кашуым булды — кылт итеп искә төште: мин үзем белән ашарга-эчәргә җитәрлек алдым, шул исәптән биш шешә хөрмә аракысы да бар капчыкта, кирәк-яракка дип алдым.

Аракы салам машинага! Ул бит машинаны гына түгел, кешене дә чаптыра! Бакка биш шешә аракы салдым — мотор үкереп эшли башлады. Киттем. Минем куганны да көтми, элдертә генә машина. Ярсып чаба. Әле уңга, әле сулга кереп китәргә карый, тик мин дилбегәне нык тоттым, җибәрмим. Бара-тора гел типерде машинам, сикерә башлады, җырлагандай итә. Ну, минәйтәм, булуы җитте моның, исерде инде бу. Туктатырга кирәк, бәрелеп челпәрәмә килүе, мине дә имгәтүе бар. Аннан соң бит машинага бер миллион динарлык товар төялгән! Уен түгел бу!

Машинам ярсыган, туктарга исәбе дә юк. «Тукта, дим, туктамасаң, су эчермим, ашарга бирмим!» Көч-хәл белән туктаттым, Форат елгасына килеп җиткәч, өч чиләк су алып машинаны эчерттем, башын юдым, аннан соң икебез дә ачык һавада, борынгы изге Форат елгасы ярында күктә янган йолдызлар, тулган ай астында тәмләп йокладык.

Иртән машинаны уятам — торасы килми. «Баш авырта»,— ди. Су алып килеп эчердем, бик озак үгетләдем. Ярар, кузгалдык. Алда елга, күпер юк, ә су сай түгел. Нишләргә? Машина белән артка чигендек, чигендек тә, бөтен көчкә чаптырып, каршы як ярга сикердек. Ләкин теге як ярга чаклы җитә алмадык, елга уртасын аз гына үтеп су өстенә килеп төштек. Мин шәп йөзәм, машина гына йөзә белми, бата башлады. Машина җәл дә түгел, төялгән тимерләр кызганыч — миллион динар торалар бит! Алар су өстенә калкып чыгып, ага башладылар. Мин йөзә-йөзә бөтен булган дүрт тонна арматура тимерен теге як ярга чыгарып өйдем. Бер генә тимер дә югалмады!

Ә елга ярында дөя кәрваны юлга җыенып маташа. Кәрван башы белән сөйләшеп, бау алдым, елгага кереп машинага бәйләдем дә, дөяләр белән машинаны елгадан тартып чыгардык. Тавыш-тыны юк, су астында яткан бит, су астында кем исән калсын?!

Машинаны агач астына күләгәгә кертеп куйдык.

Кәрван Согуд Гарәбстанына бара икән, аның белән килешеп, минем тимерләрне дөяләргә төядек.

— Ибраһим җаен таба инде ул!— диештеләр чәй эчүчеләр.— Барып җитеп, сата алдыңмы соң?

— Бардым. Саттым. Җиңел генә итеп миллион динарны кесәгә салып куйдым. Бер җиңел машина яллап, кайтырга чыктым. «Әйдә, минем белән Багдадта кал, минем миллион динар акча бар, синең белән бергәләп зур ширкә ачып җибәрербез, Согуд Гарәбстанына һәркөн кәрван-кәрван арматура тимере җибәрербез!»— дим.— «Уйлап карарбыз»,— ди. Үзенең күзләре яна. Сизәм, риза булачак. Төнлә далада күчмә бәдәви кабиләсе чатырында кунарга туктадык. Шоферым миңа кофены үзе кайнатып китерде. «Менә мондый кофены башка беркем дә ясый алмый, эчеп карагыз»,—ди. Чатыр хуҗасына да салып бирде. Әчкелтем, куе, бик каты кофе. Башларыма бәрде. Ничек йоклап киткәнемне дә сизми калдым.

Иртән бик авырлык белән уяндым. Баш чатнап авырта. Кояш югары күтәрелгән. Чатыр хуҗасы һаман гырлап йоклап ята. Шофер юк. Көч-хәл белән тышка чыктым. «Шофер белән машинаны күрмәдегезме?»— дип сорыйм.— «Ул бит кичә кич үк бензин салырга дип машинасына утырып китте, башка күренмәде»,— дидpoints күрше чатырдагылар. Чатырга кердем, үземнең кечкенә юл сандыгын ачтым: бар нәрсә үз урынында, тик зур төргәк акча урынында кечкенә генә төргәк ята. Санадым — мең динар. Миллион урынына — мең! Димәк, шофер 999 өлешен үзенә алган, бер өлешен миңа калдырган. Анысына да рәхмәт!

Хуҗаны уяттым. Ул бернәрсә хәтерләми. «Гомеремдә дә мондый озак, мондый каты йоклаганым юк иде»,— ди. Хәлләрне сөйләп бирдем. «Йоклата торган дару эчерткән ул безгә,— ди.— Кайгырма, Ибраһим, мең ел үтсә дә табабыз без аны, мин аның сынын-йөзен бик яхшы хәтерләп калдым»,— ди.

— Тапканмы соң, Ибраһим ага?

— Кая тапсын, әле бит барысы 35-40 ел үтсә үткәндер. Ул бит «мең ел үтсә дә...!»— диде.

— Тагын ни булды соң?

— Мең динар белән Багдадка, өемә кайттым. Биш йөзен йөк машинасы хуҗасына бирдем, ул үзенә өр-яңа машина сатып алды. Ә калган биш йөзенә мин менә шушы гәһвәханәне ачып җибәрдем...

* * *

Бер кичне чәйханәдә утырган кеше сорый:

— Ибраһим ага, кайда манго җимеше табарга мөмкин икән?

— Нигә кирәк ул сиңа манго?

— Хатын бала көтә, манго ашыйсым килә ди.

— Гыйракта үсми ул манго агачы, син аны монда таба алмыйсың. Һиндстанда үсә, шуннан алып кайт!

— Нәрсә син, көләсеңме әллә миннән? Ничек инде җимеш өчен Һиндстанга барыйм!?

— Барырга кирәк, бармый ярамый. Син беләсеңме: әгәр йөкле хатын теләгән нәрсәсен ашый алмаса, шул нәрсәнең рәсеме туачак баланың тәнендә мәңгегә басылып кала икән. Син аны нинди сабын белән дә юып бетерә алмыйсың.

— Кит аннан, булмас!

— Әнә Габдел Сәлам малаеның бөтен тәнен шапкан рәсеме каплаган. Шапкан сезоны булмаган, базардан тапмаганнар. Минем үз гаиләмдә дә шундый хәл булганы бар. Хатыным Фәүзия беренче балам Габбаска узгач, беркөнне «балык ашыйсым килә» ди. Кәрхтә эзләдем, Расафада эзләдем, Сәгъдүндә, Зәвиядә, Кәррәдә, Шәркыйдә эзләдем, бөтен базарларда йөреп чыктым, бәхетсезлеккә каршы, балык юк.

Кайттым, Фәүзиягә әйтәм «бәлки сиңа кибеттән балык консервасы алып кайтыргадыр?»— дим. «Юк, ди, әле генә тоткан балыкны ашыйсым килә»,— ди.

— Ничек таптың соң?

— Атлантик Океанга барып алып кайттым...

Тыңлаучылар Ибраһимга әллә нинди юк-бар сораулар биреп тормыйлар, чөнки мондый сәфәрләр аның өчен гадәти хәл...

***

— Ибраһим ага, синең үзеңнең Һиндстанга барганың бармы соң?

— Бар. Анда миңа бик хикмәтле бер нәрсә бүләк иттеләр.

— Нинди әйбер?

— Багдадка кайтып китәр алдыннан индус иптәшем бүләк итеп карбыз төше бирде. Мин аны кесәгә салып куйдым. Өйгә кайттым, кич белән ятар алдыннан теге карбыз төшен кесәдән алып, ачык тәрәзәдән бакчага ыргыттым.

Иртән уянсам, бакчаны ямь-яшел тау каплаган. Ныклап карасам, тау чаклы зур карбыз үсеп чыккан. Стенадагы келәмнән әтинең кылычын алдым да, бакчага чыктым. Карбыз бөтен дөньяны, бөтен күкне каплаган. Бөтен көчемне җыеп кизәндем дә, кылыч белән карбызга чаптым.

Чапкан җирдән кып-кызыл баллы ширбәт саркып чыга башлады, мин аны туйганчы эчтем. Карасам, кылычым күренми. Ә әтинең кылычы бик борынгы, бик кыйммәтле,— аны минем бабайларның бабасының бабасына Һарун әл-Рәшид үзе бүләк итеп биргән, дип сөйлиләр. Чапкан җирне куллярым белән киңәйттем дә, эчкә кереп киттем. Барам, барам, карыйм, эзлим — кылыч юк та юк. Бер ярты көн эзләдем, арыдым да, бер агач төбенә ятып йокладым. Аннан соң нинди дер таныш тавышларга уянып киттем. Агач янында минем ике дус басып торалар.

— Йәссәләм, Ибраһим Гарәп бит бу!— ди берсе.

— Нишләп ятасың монда, Ибраһим?— дип сорый икенчесе.

Мин хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

— Көне буе эзлим, кылычны һаман таба алмыйм!— дим.

Егетләр мыскыл иткән сыман миннән кычкырып көлә башладылар. Берсе әйтә:

— Әй, тиле, кара син аны: бер көн буе эзли икән! Ә без менә монда югалган дөябезне инде бер ай эзлибез, әле таба алганыбыз юк,— ди...

Менә нинди хикмәтле карбызлар үсә Һиндстанда!

***

— Ибраһим ага, Һиндстанда фәкыйрьләр бик күп дип сөйлиләр. Имеш, анда халык бик ярлы яши икән. Дөресме?

— Дөрес, егетләр. Менә мин сезгә шул турыда үзем белән булган хәлне сөйлим әле...

Бервакыт бик каты авырып киттем. Хәлем шулкадәр авырайды ки, хатыным, балаларым, туган-тумачаларым төннәр буе мине саклый башладылар. Дәвалауның файдасы юк, көннән-көн начарлана барам. Шундый авыр көннәремдә шифаханәгә мәхәлләбезнең ахун хәзрәте килеп керде. Күрә инде: бер аягым җирдә, бер аягым гүрдә. «Син кем, Ибраһим туган, ди, менә болай эшлә. Әгәр терелсәм, мең фәкыйрьне җыеп, туйганчы ашатыр идем, дип вәгъдә бир: «Мең кеше түгел, миллионны ашатыр идем, аңа минем байлыгым җитәрлек!»— «Әстәгъфирулла, диген, Ибраһим, ничек миллион кешене ашатып була?» — «Терелүен генә терелим, үйлап тормыйм, җыям да ашатам!»

Менә шул көннән соң хәлләрем бөтенләй җиңеләеп китте бит, ходаның хикмәте. Бер атнадан инде аякка бастым, ун көннән тап-таза булып өйгә кайтып кердем.

Әйткән сүз — аткан ук, фәкыйрьләрне җыеп ашатырга кирәк. Бөтен күршекуланнәргә, таныш-белешләргә, кардәш-ыругларга әйттек, менә фәлән көнне фәлән җиргә фәкыйрь-фокырлар җыелсын, хәер-сәдака ашы булачак дидек. Тик, күрәсең,

берәүнең дә фәкыйрь буласы килми, барысы утыз-кырык кешә җыелды. Әллә инде Багдадта чыннан да фәкыйрь калмаганмы? Юк, болай булмый. Миллион кешене ашатыр өчен мең ай буена һәркөн кешә чакырып булмый бит инде. Нишләргә?

Шул чакта Һиндстанда фәкыйрьләрнең чамасыз булуы искә төште.

— Чакырттыңмы?

— Чакырттым. Фәлән көнне, Иран белән Гыйрак чигенең фәлән җирендә, Һиндстанның ашыйсы килгән миллион фәкыйренә тәмле шулпа, ит белән дөге өзерләнеп куелыр, дидем.

— Миллион кешегә савыт ничек җиткерергә кирәк?

— Анысы да уйланган. Кашыкларын үзләре белән алып килергә кушылды. Шулпа салыр өчен йөз чакрым озынлыгы канал казыттым, аның эчен бетон белән каплаттым да, шул каналга ит шулпасы кайнатып тутырдым. Ираннан Гыйракка килеп кергән чик буендагы бер зур тап-такыр кырга ит белән дөге пешереп өеп куйдым. Кыскасы, ит белән дөге тавы. Каф тавы кебек биек...

— Килделәрме соң?

— Нишләп килмәсеннәр! Көтеп көнә торганнар диярсең?!

Нәкъ бер миллион! Хәтта бер-ике кешегә артык та булгандыр. Апарын да кире борып кайтармадык. «Мәрхәбә, хуш килдесез!» — дип каршы алдык.

— Ашарга җиттеме соң?

— Көне буе ашадылар, иртәгесенә дә калды. Йөз чакрымлы каналның ике ягы тулы кешә булды. Ашап-туеп, симереп, Басра портында көймәләргә, баржаларга, корабларга төялеп кайтып киттеләр. Хатлар да язадылар соңрак: «Ибраһим әфәнде, син безгә күчеп кил, без сине президент итеп сайлап куярбыз»,— дип язганнар. Ничек инде мин шушындый матур чәйханәне ташлап китим?!

— Бөтенесе дә кайтып җиткәннәрме соң Һиндстанга?

— Әй, сөйләргә онытканмын икән, ул көнне бер көтмәгән, уйламаган хәл дә булды бит. Һиндстан кешеләре ит белән дөгедән ясалган тау каршына килеп чыккач, кашыклары белән «тауны» ашый башладылар. Бер төркеме бик мавыгып киткән, күрәсең, ашыйашый зур тау тишеге ясап, эчкә кереп киткән.

Берәү саксызланып дөгедән сарык боты тартып чыгарган икән,— өстәге бөтен тау шул тау тишегендәге кешеләр өстенә ишелеп төшкән. Шулай итеп җитмеш җиде кешә шәһит китте.

— Аның өчен сине җавапка тарттырмадыларм соң?

— Нишләп тарттырсыннар? Ачтан үлү яхшымы, ашап-туеп пылау эченә кереп үлүме?

— Бу кадәр күп кешене ашату бик кыйммәткә төшкәндер бит? Бөтен булган акчаларыңны тотып бетергәнсеңдер?

— Һәй, егетләр, баш юк сездә! Һич уйлый белмисез икән, валлаһи! Мин бит сезгә сөйләдем: йөз чакрым канал казыттым, аның эчен бетон белән каплаттым дидем. Фәкыйрьләрне ашаткан-эчерткәннән соң, икенче көнне үк минем янга хөкүмәтнең вәзире килеп керде: син, Ибраһим, ди, сат ул каналыңны безгә, ди. Хөкүмәт күптән инде анда канал казырга кыҗрап йөрде, ди. Баш кына җитмәде безнең, ди. Анда җир әйбәт, су гына җитми, ди. Әгәр синең каналга Дуҗлә елгасының суын кертсәң, ул җирләрне оҗмах бакчасына әйләндерергә була, ди. Сат, күпме сорасаң, шулчаклы түләрбез, казнада акча җитәрлек, ди.

— Саттыңмы соң?

— Шундук сатмадым әле. Бераз ялындырмыйча булмый. Ул вәзир бер ун тапкыр килеп ялынды. Аннан соң зур бүләкләр күтәреп, премьер-министр үзе килде...

— Ну хәйләкәр дә кешә инде син, Ибраһим ага! Аңа да сатмадыңмы?

— Аны мин бик тә хөрмәт белән каршы алдым, бик һәйбәтләп кунак иттем. «Килгәнең өчен бик рәхмәт, галиҗәнап,— дим баш вәзиргә.— Сатарга һич көнә дә исәбем юк иде, минем планнар башкарак иде. Тик мин сине бик ихтирам итәм, бик яратам, тик сатсам, синең хакка гына сатармын инде»,— дим. Куанычыннан түшәмгә сикерә язды кунагым.

— Күпмегә саттың соң?

— Әллә ни күпкә түгел. Шулай да бөтен тотылган акчаларны бер ун тапкыр артыгы белән кайтардым инде...

...Тыңлаучылар бик тә мәмнүн булып, иркен сулап куялар, чөнки апарның нзге теләге — Ибраһим ага ягында.

* * *

— Кичә төнлә соң гына өенә кайтып килгәндә сәүдәгәр Габделҗаббар Мәҗидне талаганнар...

— Авызыңны ачып йөрсәң, талапар шул. Минем үземне дә бер төнне талый яздылар...

Гәһвәханәдә кызып барган әңгәмә шып туктады, чәй һәм гәһвә эчүчеләр тынып калдылар, тик түшәмдә әйләнә торган җилләткеч кенә, ябалак канат каккандай, сизелер-сизелмәс тавыш чыгарып, пырылдавын дәвам итте.

— Бер кечкенә чәйханәне соң гына ябып, бераз чирләп киткән абыем Шәншәлнең хәлен белергә киттем. Шәншәл шәһәрнең ерак мәхәлләсе Зәвиядә тора, анда, үзегез беләсез, урамнар тар, караңгы кешеләр дә кояш баюга ук йокларга яталар. Мин сөйләшергә яратам, мавыгып киткәнмен, сәгатькә карасам, инде төн уртасы җиткән. Саубуллашып өйгә кайтып киттем. Такси-фәлән дә күренми, кеше-мазар да юк. Бара торгач, бер тыкрык чатында биш-алты кеше янына килеп чыктым. «Туктап кит, кордаш, ашыкма!» — ди берсе. «Юк, минәйтәм, хатын көтә, вакытым юк». Теге кеше тар тыкрыкта минем каршыга чыкты да: «Зарар юк, көтәр, безнең эш мөһимрәк!» — ди. Уң кулы — билендәге хәнҗәр сабында. Мин аның сул ягыннан урап китәргә карыйм, ул да сулга чыга, мин уңга — ул да шунда. Башкалары да әкрен генә миңа якынлаша башладылар. Нишләргә? Монда инде җебеп төшсәң, беттең дигән сүз. Мин заманында төшеп калганнардан түгел идем. Йодрыгыма бөтен илаһи көчемне җыйдым да, чигә төбенә тондырдым каршымда торган башкисәрнең. Эһ тә итмичә, тавышсыз гына ауды бу тыкрык уртасына. Ике-өч кенә кеше булса, курыкмыйча көчне сынап карарга булыр иде булуын, ә монда бит — биш-алты юлбасар; өстәвенә, сул яктагы тыкрыктан тагын бер зур төркемнең якынлашуы күренде. Кайсының кулында пычак, кайсының — наган, барысы да коралды. Юлбасарларның саны егермегә якын. «Юк, Ибраһим, дим үземә үзем, монда өтәчләнүнең файдасы юк, батырлык күрсәтәм дип Фәүзияне тол, балаларны ятим калдырып булмый». Заманында ярышларда мин йөгерешү буенча беренче урыннарны алган егет. Аяклар исән булса, коткарырлар. Мин йөгерешү буенча халыкара ярышта катнашкан чемпион кебек бөтен көчемне җыйдым да, алга ыргылдым.

Тегеләр, билгеле, пычак-хәнҗәрләрен һавада чайкый-чайкый минем арттан чабалар. Наганнан атарга куркалар, күрәсең, тавыш чыгарасылары килми. «Тукта, адәм актыгы, туктасаң, үзебез дә тимибез, башкалардан да тидертмибез!» — дип кычкыралар.

Сезнең вәгъдәгә ышанып туктадым ди, туктамый ни, тот капчыгыңны! Мин бөтен яшьлек көчләремне җыеп, тагын да тизрәк чаба башладым. Болан да болан, мин дә болан! Газель кебек, ярсыган гарәп аргамагы кебек чабам! Юлбасарлар да һаман туктап калмыйлар. Мин инде кая чапканымны да белмим, бу мәхәллә миңа гел таныш түгел, тик туктарга ярамый.

Алдымда — бик биек һәм калын дивар, анда зур калын капка пәйда булды. Йөгереп килеп капкага бәрелдем, капка ачылып китте, мин, Кадисия сугышында ярсыган ат дошман каласы эченә ыргылып кереп киткән кебек, «кала эченә» ташландым. Алдымда тау чаклы зур бак утыра, ә ул бакка биек тимер баскыч куелган. Мин йөгереп килеп, баскычтан үрмәләп менеп киттем! Аска карыйм: теге мур кыргыйы юлбасарлар да, капкадан бәреп керделәр дә, баскычка таба чабалар. Мин тиз-тиз баскычның иң югары очына мендем. Зур бакның тимер капкачы бар. Капкачны ачып карасам — туп-туры чиста су. Аңладым: бу бөтен Багдад шәһәрен су белән тәэмин итеп тора торган бак икән. Башкисәрләр баскычтан менеп җиткәндә генә, башка чарам юк,— тоттым да суга чумдым. Бак төбендә егерме кеше сыярлык зур торба, шул торбага бакның суы әкренләп агып тора. Торба эченә кереп китәр алдыннан өскә карыйм: теге юлбасарлар — төнчыгып үлгерләре!— берәм-берәм, чапт-чолт минем арттан сикерәләр...

— Юлбасарларның да бик тәвәккәлләренә юлыккансың икән, Ибраһим ага!— диде бер егет түзә алмыйча.

— Гел череп беткән усаллар инде! Алар бөтен дөньяны талап килгән юлбасарлар булып чыкты, аларны күптән инде халыкара полиция — Интерпол эзли икән.

Мин торба эченә кереп чумдым. Бераз баргач торба икегә аерылды: берсе «Расафа» дип язылган, икенчесе «Кәрх». Мин шәһәрнең «Расафа» дигән ягысында торам, шунда кереп киттем. Тагын бераз баргач, торба алты тармакка аерылды: «Адамия», «Вәзирия», «Сәгъдүн», «Мәсбаһ», «Кәррада Шәркыя», «Зәвия». Мин «Вәзирия» дигән җирдә торам, шунда юнәлдем. Бераздан торба урам тармакларына бүленде, һәм мин үземнең урам торбасын эзләп табып, шунда кереп чумдым.

— Сөбханалла!— диештеләр тыңлаучылар.

— Үзем артыма караштыргалап куям. Һаман туктап калмыйлар бит теге каһәр суккан адәм актыклары, һаман куалар! Мин соңгы көчләремне җыеп үземнең йорт торбасын эзләп таптым да, кереп чумдым. Һәм берничә секундтан — йа, ходаның бәрәкәте!— яп-якты дөньяга килеп чыктым. Бөтен үпкәләремне тутырырлык тирән сулыш алып җибәрдем, һәм күзләремне уып карасам — йа, алланың кодрәте!— хатыным Фәүзиянең кер юа торган тагарагында утырам икән...

Тыңлаучылар сүзсез генә бер-берсенә карашып, шаккатып, тирән сулыш алып куйдылар.

— Тик инде Фәүзияне күрү шатлыгыннан җебеп төшмәдем мин, билгеле. Бик тиз генә үрелдем дә, гөжләп су агып торган кранны бик каты итеп борып куйдым. Шул ук мизгелдә тимер кранга бер нәрсә килеп бәрелде дә, тыпырчына башлады. Колагымны куеп тыңласам, теге башкисәрләр, аяклары белән тибеп, кранны ачарга тырышалар, пычак-хәнҗәрләре белән кранга сугалар, сүгенәләр, мине каргыйлар, яныйлар.

«Ач, Ибраһим, диләр, ачмасаң, чыгып бөтен гаиләңне суеп бетерәбез!» — диләр. Ә минем алар белән алыш-бирешем юк: калын гына тимерчыбык алып килдем дә, кранны беркем дә ача алмаслык итеп бикләп куйдым. «Тотыгыз менә койрыгымны!» — дим тегеләргә кранга иелеп. Төн буе сүгенеп, җенләнеп чыктылар, тынычлап йокларга да

бирмәделәр. Иртән чәйханәгә китәр алдыннан мин Фәүзияне һәм бөтен бала-чаганы чакырдым да бөтен булган хәлне сөйләп бирдем. «Өч көн буена йортта да, бакчада да бер генә кранны да ачмагыз, эчәргә кирәк булса, ишетсен колагыгыз!» — дидем.

Икенче төнгә тегеләрнең тавыш-өннәре бетеп бара иде инде, ә өченче төндә кранда кабер тынлыгы урнашты. «Әһә, минәйтәм, нигә җәнҗал куптармыйсыз?

— Соң нишләгәннәр апар, кая киткәннәр?

— Ашыкма, энем, тыңла! Мин телефон аша Багдад полициясенә шалтыраттым. «Минем өйдә бик атаклы юлбасарлар булырга тиеш, дим. Гарәпләр генә түгел, әллә нинди чит ил каракпары да булырга тиеш алар арасында, Интерполга да хәбәр итегез, килеп карасыннар!» — дим.

Берәр сәгатьтән, мин сиңайтим, бөтен урамыбыз полиция машинасы белән тулды. Анда Франциядән дисеңме, Америкаданмы, Япониядәнме,— әллә кайлардан килгәннәр. Гарысын да чакырып керттем. Ашыкмыйча гына, Айга кеше утырган космик корабль җибәргән галим кебек, кранны ныгытып куйган тимерчыкны сүтә башладым. Полиция генераллары кайсы тагарак, кайсы мичкә, кайсы чиләк тотып көтеп тора. Тимерчыбыкны сүтеп алдым, кранны ачтым. Гөжләп су ага башлады, су белән бергә тагаракка шап итеп кулына наган кысып тоткан бер мәет килеп төште.

— У-у, безнең гангстер Джон!—ди Америкадан килгән генерал.—Аны без бик күптән, бөтен дөньяны бетереп эзлибез.—Аннан соң мичкәгә дөбердәп башына цилиндр эшләпә, өстенә фрак кигән, кулына бик кыйммәтле таяк тоткан кеше гәүдәсе төште.

— Бу бөтен Париж музейләрын басып йөргән, атаклы Гастон карак,— ди француз генералы.

Кайсы гына илдән юк монда үз эшендә шөһрәт һәм дан казанган кешеләр! Хәтта төньяктагы Казан ягыннан Шәкүр карак та бар алар арасында. Шәкүр каракны белмисезме? Ничек инде шундый кеше турында ишеткәнегез юк? Ул җайдакның астыннан иярле атын урлап китә икән, җайдак үзе сизми дә кала, ди!

Егерме каракны урамга чыгарып тротуарга тезеп салдылар. Чиксез күп халык җыелды. Багдад шәһәрендә мондый тамашаның һарун әр-Рәшид заманыннан бирле, мең елдан артык булганы юк икән!

Урамда митинг ясап алдылар. Безнең өйдән алып чыккан өстәлгә Интерпол начальнигы менеп басты.

— Хөрмәтле әфәнделәр! Мәшһүр Багдад шәһәре әһелләре!— дип башлады ул нотыгын.— Бөтендөнья каракларының, юлбасар, башкисәр, гангстер һәм аферистларының халыкара конгрессы шушы тирәдәге бер илдә үткәреләсен без белә идек. Тик аның Багдад шәһәрендә буласын гына ачыклый алмадык. Менә мөхтәрәм Ибраһим аларның барысын да безгә тотып бирде. Бу мескен юлбасарларның авыр туфрагы җиңел булсын!

— Урыннары тәмугта булсын!— дип нәтиҗә ясадылар Багдад кешеләре.

— Ибраһим кебек кеше белән Багдад шәһәре генә түгел, бөтен җир шары горурланырга тиеш! Ура, ура,ура!

— Ура,ура, ура!— дип күтәреп алды күршеләр.

— Иң зур орден алу өчен Ибраһим әфәндене Интерпол Парижга чакыра. Кайчан киләсең Парижга, Ибраһим әфәнде? Теләсәң, хәзер үк алып китәбез!

Юк, җәмәгать, анда барырга вакыт юк минем. Французча белмәгәнгә түгел, анысы минем өчен чүп нәрсә, бер кичтә өйрәнәм мин аны! Чәйханәне кемгә ташлап китәсең? Кемгә калдырасың аны? Мин киткәч, чәй эчәргә килгән кешеләргә кем хикәят сөйләр? Чакыруыгызга — рәхмәт, гафу итегез, барып булмый.

— Алайса орденыңны монда Багдадка җибәрербез, Ибраһим әфәнде!

Озак та үтмәде, Париждан орден килеп тә җитте.

— Ә кайда соң ул орденың хәзер, Ибраһим ага?— дип сорый бер тыңлаучы.

— Кайда булсын — Багдад музеенда! Калын пыяла астында ята зур алтын орден. Кыйммәтле ташлар белән бизәлгән. Бер патша рәсеме дә төшерелгән. Тик анда «Ибраһим ордены» дип язмаган инде. «Язмагыз»,— дидем музей директорына. Мин бит мактанырга яратмыйм! Җенем сөйми мактануны!

— Ибраһим ага, нәрсәләр булды соң шул хәлдән соң?

— Бөтен җир шарында бер ун ел чамасы кеше талау, урлау, кеше алдау, үтерүләр туктап торды...

Чәйханәгә стадионнан футбол матчын карап кайткан яшьләр төркеме килеп керә. Шау-шу, бәхәс, кемнедер күкләргә чөеп мактау, кемнедер эт итеп сүгү — футбол яраткан кешеләрнең гадәти хәле. Гыйрак командасы Пакыстан командасына оттырган, шуңа күрәдер, төркем һич тынычлана алмый.

— Хәзерге футбол — футболмыни ул? Стадионда карарлык нәрсә күрмисең, юньләп уйный белгән футболчы юк, уен ахырында йокың килә башлый...— дип сүзгә катнашып китә Ибраһим.— Менә мин яшь чакта футбол уенын бер карасаң, гомер буе онытылмаслык тамаша була торган иде! Мин бит үзем дә Гыйрак милли командасының иң атаклы футболчысы идем.

Бәхәс тынды. Димәк, «Мең дә бер кичә» маҗараларының яңасы башлана. Ибраһим ага сөйләгәндә аңа сораулар бирергә мөмкин, ә башка темага башка кешеләрнең кушылып сөйләүләре намазны бүлдереп сүгенә башлау кебек тоелыр иде.

— Шул елларда бер көнне тавык кыздырырга куйдым да газета укырга утырдым. Шул ук минутта телефон шалтырады. Тыңлаcontainsам, исем китте: премьер-министр Нури Сәид шалтырата. «Ибраһим, синең ярдәмең кирәк,— ди.— Стадионда Гыйрак футбол командасы белән Марадона командасы арасында уен бара. Безнең эшләр шәптән түгел, Марадона инде безнең капкага тугыз гол бәрде, ә без берне дә сылый алмадык, ди. Коткарсаң, син коткарасың, бөтен өмет синдә!— ди.— Давай, футболкаңны киеп урамга чык, мин инде үземнең машинамны сиңа җибердем, өч минутта өең каршында булыр»,— ди.

Тыңлаучылар берсенә-берсе карашып куйдылар. Гыйрак тарихын өйрәнгән һәм дөньядагы атаклы футболчыларның биографиясен белгән кеше аптыравы да мөмкин: Нури Сәид 1958 нче елның 14 июлендәге революция көнендә үтерелгән, ә футболчы Марадона аннан өч елдан соң гына туган бит, ходаның хикмәте...

— ...Футбол киемнәрен киенеп тышка чыксам, анда бөтен урамга ялтырап баш вәзиренең әр-яңа «Роллс-Ройс» машинасы көтеп тора, машина тирәсендә бер көтү кеше: тәртип саны 0000001 булган бу машинаны Багдад кешеләре генә түгел, шәһәрнең бөтен көчекләре дә белә. Полиция кешеләре бөтен хәрәкәтне туктатып, мин утырган «Роллс-Ройс»ны тоткарлыксыз үткәреп тора. Мин җил кебек очып, берничә минуттан стадионга килеп җиттем. Машинадан сикереп төштем дә, туктамыйча, туп-туры футбол кырына йөгереп кердем...

Тыңлаучылар кофеларны суынганын онытып, уйлары белән Ибраһим артыннан стадионга киттеләр.

— ...Ә шул минутта Марадона туп-туры безнең капкага унынчы голны бәрергә чамалап йөгерә. Мин, аның юлын кисеп, тупны җәһәт кенә чәлдереп алдым да, туп-туры тегеләрнең капкаларына алып киттем. Трибуналарда утырган меңләгән халык аягүрә басып миңа кул чаба, уңыш теләп кычкыра. Марадона һәм аның иптәшләре аңга килгәнче, мин инде беренче голны аларның капкаларына илтеп тә сыладым. Тамашачылар, миңа булган рәхмәтләрен белдереп, бөтенләй акылдан шаша.

Тыңлаучылар Ибраһим авызыннан очып чыккан һәр сүзне йота баралар.

— Марадона командасы аны-моны абайлап өлгергәнче, мин инде апар капкасына кырык голны чәпәп куйдым...

— Кырык гол! — дип выгыраштылар тыңлаучылар.

— Кырыгынчы голны кертеп җибәргәндә кылт итеп исемә төште: әй, черек баш, мин бит, өйдән чыгып киткәндә, плитәгә кыздырырга тавык куйган идем!

Минем яннан очып барган тупны сул аяк белән эләктереп алдым да, уң аяк белән, бөтен көчне салып, үземнең баш түбәсенә, һавага җибәрдем. Меңләгән тамашачы туп артыннан җиденче кат күккә карап катты.

Мин шундук стадионнан сикереп чыгып «Роллс-Ройс»ка менеп утырдым. «Давай, өйгә оч!» — дим шоферга. Өйгә кайтып керсәм, тавыгым тәмле исләрен чыгарып утыра, нәкъ өлгергән чагы! Газны сүндереп, тавыкны аш бүлмәсенә алып кереп ашадым, чәй эчтем, кулпарымны юдым да, мине көтеп торган 0000001 нче санлы машинага кереп утырдым. Тагын Багдад урамнарында хәрәкәт туктапды, тагын бөтен шәһәр полициясе турыга катып, миңа честь биреп калды. Стадионга керсәм, күрәм: тамашачылар һаман күккә карап каткан. Мин җибәргән туп, кечкенә нокта булып, түбән төшеп килә. Математик юл белән хисаплап, туп төшәсе ноктаны билгеләдем дә, шунда бастым. Туп әле җиргә төшеп җитмәде,— ә мин башым белән җәһәт кенә аны Марадона командасының капкасына кертеп тә җибәрдем. «Гол, гол, кырык беренче гол!» — дип шашып кычкыра диктор. Ә трибунапардагы тамашачылар бөтенләй котыра: «Ибраһим! Ибраһим!! Мең яшә Ибраһим!!!— дигән тавышлар җиденче күкләрне дер селкетә. Шулай итеп, Марадона командасын 41:9 исәбе белән җиңдем мин. Уен беткәч, Марадона үзе килеп мине кочаклады да: «Футболчы булырак, мин синең олтаныңа да ярамыйм, Ибраһим...» — ди.

Икенче көнне Багдад газеталары «Ибраһимга һәйкәл куелырга тиеш!» дигән мәкаләләр басып чыгардылар. Әллә кайсы чит илләрдән миңа чакырулар җибәргәннәр: «һәр футбол уены өчен бер миллион доллар түлибез сиңа, Ибраһим!» — дип язганнар... Ләкин ничек инде бу чәйханәне ташлап китәсең? Кемгә калдырасың аны? Футбол уйнау күңелле, билгеле, тик футбол уйнарга үзең белән чәйханәне алып барып булмый бит...

Багдад сәүдәгәрләре гадәттә үз гомерләрендә күп кенә кибетләр алмаштыралар, бер ширкә ябып, бөтенләй башка эш белән алыш-биреш итә торган яңа ширкә ачып җибәрәләр. Ләкин нигә соң Ибраһим гомер буена бер чәйханә — кәһвәханә тоткан?

Күрәсең, Ибраһим ага чәйханәсен түгел, ә чәй эчәргә җыелган кешеләрнең аны тыңлауларын яраткандыр. Шуңа күрәдер, ул чәйханәсен югалтасы килмәгән, чөнки аның иң бәхетле, иң рәхәт минутлары кешеләргә үзенең канатлы хыялпары турында сөйләү булгандыр. Бу инде нәкъ шигырь язмыйча яши алмаган шагыйрь яки скрипка уйнамыйча яшәүне күз алдына да китерә алмаган музыкант язмышы кебек...

Багдад-Насыйрия,
май 1990 ел.

## Александр Губарь

# «БЕЗ БЕР КҮКНЕҢ ЙОЛДЫЗЛАРЫ»

ЮНЕСКО дигән халыкара оешма карары белән 1991 елда украин шагыйре Павло Тычинаның 100 еллыгы дөнья күләмендә киң билгеләп үтелде. Бу исем, әлбәттә, татар укучыларына да бик яхшы таныш. Чөнки Павло Тычина үзе исән вакытта ук инде бөтен җир шарына билгеле шагыйрь иде. Аның турында бик күп илләрнең күренекле кешеләре, һәркайсы үзенчә фикер йөртеп һәм төрледән-төрле мисаллар китерә-китерә, Павло Тычинаның иҗади колачын, мәдәният күгендә һичкайчан онытылмаячак олы хезмәтен билгеләделәр.

Бу зур шагыйрь һәм актив җәмәгать эшлеклесе белән миңа да бик еш очрашырга, төрле темаларга кызыклы-кызыклы әңгәмәләр корырга туры килде. Әнә шундый сөйләшүләребезнең берсендә ул икенче бер украин шагыйре Иван Франко тарафыннан әйтелгән түбәндәге фикергә бигрәк тә басым ясый торган иде: әдәби тәрҗемәчеләр һәм бүтән милләт әдәбияты әсәрләрен популярлаштыручылар — алар, икенче төрле итеп әйткәндә, халыклар арасында дуслык күпере салучылар. Алар — рухи арадашчы ролен үтәүчеләр.

Әйткәнемчә, Павло Тычина менә шушы фикерне бик еш искә төшерә иде. Һәм бер дә юкка түгел. Аның үзенең иҗаты да әлеге принципиаль юнәлешне раслаган бик матур мисал булып тора.Халыклар арасында рухи күпер салу Павло Тычинаның иң мөһим эстетик кредоларыннан берсе иде.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан Киевта Павло Тычинаның 12 томлык әсәрләр җыелмасы басылып чыкты. Әнә шул унике томлыкның калын-калын 3 китабы тулысы белән тәрҗемәләргә бирелгән. Анда 37 халыктан 150 шагыйрь әсәре кергән. Шул исәптән татар шигырьләре дә.

Бүгенге көндә юлга-юл тәрҗемә итү ысулы барлыгын уйлап күпләр бәлки моңа бик үк гаҗәпләнмәсләр дә. Ләкин сез шунысына игътибар итегез: Павло Тычина үзе 15 телне белгән. Шул исәптән татар телен дә! Һәм башка төрки телләрне дә! Полиглот кебек мондый тәрҗемәчене безнең украин әдәбиятында бары тик әлеге дә баягы Иван Франко белен генә янәшә куеп була.

Унике томлык белән танышкан вакытта Тычинаның әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче буларак та гаять киң колачлы эш алып барганын күрәсең. Аның каләме дөньяның кайсы гына әдәбиятына кагылмаган да, бөекләрдән кем генә иҗатын тикшермәгән! Шекспир һәм Толстой, Уитмен һәм Тагор, Руставели Һәм Туманян, Го Мо Жо һәм Хәям... Алар янәшәсендә Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Муса Җәлил.

Украин шагыйре татар әдәбияты белән ничегрәк танышкан икән соң? Бу гүзәл илгә аны нинди юллар алып килгән?

Шагыйрьнең башка әдәбиятлар һәм телләр белән актив кызыксына башлавы егерменче еллар уртасына туры килә. Ә төрки телләргә кагылсак, эш болай тора. Башта Павло Тычина төрек телен өйрәнә. Ә төрек теленнән соң инде татар теленә бер дә ерак калмый! Бу телләр бик тә охшашлар.

Хәзер инде безгә Тычинаның татар телен кайчан өйрәнә башлавы да мәгълүм. 1925 елның август аенда шагыйрь үзенең кәләшенә — Лидия Петровна Папарукка болай дип яза: «Әле күптән түгел кибеттән татар шагыйрьләренең китапларын сатып алдым. Аңлавын әле бик нык аңламыйм, ләкин шулай булса да укыйм, барысына да төшенергә тырышам».

Нинди китаплар турында сүз бара микән соң, дип, мин байтак кына эзләнү үткәрдем. Ләкин мәсьәләнең һич тә очына чыга алмадым. Чөнки сугыш вакытында

гитлерчылар Киевны басып алгач, Тычина китапханәсеннән бик күп китаплар югала, китапханә талана. Әмма шунысы тәгәл билгеле: утызынчы елларда ук инде шагыйрь татар телен бик тә тырышып һәм эзлекелек белән өйрәнә. Әле чыккан унике томлыкта ул болай дип яза: «Татарстан республикасының газета-журналлары миңа тәртипле рәвештә килеп тора».

Үзе күреп белгән татар шагыйрьләренең әсәрләрен ул җыеп та бара. Бу хакта П. Тычинаның мондый сүзләре бар: «Җәлил шигырьләре басылган газета-журналларны һәм аннан килгән хатны бик озак саклаган идем. Ләкин, кызганыч, фашист башкисәрләре Киевны алгач, болар барысы да юкка чыкты. Бары тик 1930 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Сигнал» дигән китап кына исән калган. Дөресрәге, мин ул китапны бер дустыма биреп торганмын икән, соңыннан ул аны кире кайтарды. Ул китап, әлбәттә, татар телендә. Анда байтак кына татар шагыйрьләренең әсәрләре һәм шул исәптән Муса Җәлилнең «Ленин» дигән шигыре дә бар иде».

Утызынчы елларда Тычина бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗаты белән дә кызыксына. Украинаның әдәбият һәм сәнгатькә багышланган Дәүләт музеена экспонат итеп куелган бер хезмәт моны раслап тора. Павло Тычинаның 1938 елда «Коммунист» газетасында басылып чыккан «Халкым, мин синең тугры хезмәтчең!» дигән мәкаләсенең кулъязмасы ул. Биредә урыс, украин, әрмән әдәбияты классиклары белән янәшәдә беренче мәртәбә Габдулла Тукай исеме дә телгә алына. «Каһәр суккан царизм... Әнә шул авыр тормыш газабыннан тилмергән шагыйрьләрне уйласам, минем исемә урыс Глеб Успенский, әрмән Налбандян, татар Габдулла Тукай, украин Тарас Шевченко килеп төшә...» — дип яза Тычина намуслы шагыйрьләрнең урыс хакимияте шартларындагы авыр хәлен раслап.

Иҗат кешесенең чиксез кыен шартларга куелган булуы 1938 елның 18 июнендә «Әдәби газета» да басылган икенче бер мәкаләдә дә ассызыклап үтелә. Биредә татар шагыйре Габдулла Тукай исеме тагын бер мәртәбә җылы сүзләр белән искә алына.

Ә инде 1934 елда совет язучыларының Беренче съездына баргач, Павло Тычина Кави Нәҗминең татар совет әдәбияты турындагы докладын бик игътибар белән тыңлый. Ихтимал, шагыйрь бу съезд вакытында Казаннан килгән байтак кына каләмдәшләре белән танышкандыр да.

...1941 ел. Украинаны үлем, кан каплый. Ил җимерелә, халык кырыла. Бер төркем әдәбият-сәнгать эшлеклеләре белән бергә, Павло Тычина да ерактагы Уфа шәһәренә эвакуацияләнә. Биредә аларга җылы караш күрсәтәләр, хәлдән килгәнчә ярдәм итәләр. Бу чорда Уфада яшәүче татар шагыйрьләреннән бигрәк тә Сәйфи Кудаш белән дуслашып китә Тычина. Аларның бергә төшкән байтак кына фоторәсемнәре дә бар.

Уфада шагыйрь көн-төн эшли, иҗат итә. Биредә 1942 һәм 1943 елларда аның «Җиңәргә һәм яшәргә!», «Якты көн килер», «Халыкның иҗади көче» дигән җыентыклары басылып чыга. Тычина шулай ук мондагы иҗатчыларның әсәрләрен дә зур игътибар белән өйрәнә, алар турында әдәби тәнкыйть мәкаләләре бастыра. 1942 елда басылган «Мәҗит Гафури иҗатында патриотизм» дигән хезмәт әнә шуңа яхшы мисал була ала. Аңа түләнгән гонорарны автор оборона фондына күчерә.

Чор таләп иткән патриотлык темасын гына алса да, автор Мәҗит Гафури иҗатын шактый киң колачлый, аның халык язмышы белән һәрчак янәшә атлавын искәртә. Мәкаләдә Гафуриның мондый сүзләре дә өзек итеп бирелә:

*Һәр заман кайгы курәм татар өчен...*

Гафури турындагы хезмәттә Габдулла Тукай исеме дә кат-кат искә алына. Аларның Беренче революция елларында ни рәвешле халык мәнфәгатен чагылдырулары бәйнә-бәйнә язылa. Күпләгән әсәрләрдән өзекләр китерелә. Тукайның «Китмибез» е белән Гафуриның «1907 ел җавабы» аеруча игътибар үзәгендә тора.

Тагын шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Тычина үзенең хезмәтләрендә теге яки бу шагыйрь әсәрләрен популярлаштырып кына калмый, үзенең украин дусларын теге яисә бу әдипне тәрҗемә кылу эшенә дә тарта. Оештыру мәшәкатьләрен дә үз өстенә ала. Мисал өчен М. Гафури шигырьләрен украин шагыйрьләре М. Бажан, А. Малышко, Н. Терещенко һ. б. бик күпләр тәрҗемә итеп, Киевта украин телендә аерым китап чыгаралар. Ә Тычина үзе исә Гафуриның унсигез шигырен тәрҗемә итеп бирә.

Әгәр дә бүген Киевтагы Тычина музеена килеп керсәң, анда тупланган китапларның күплегенә исең китә. Шагыйрьнең шәхси китапханәсе әнә шулай бик зур, бик бай булган. Татар язучыларыннан да кемнәр генә юк анда! Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Г. Бәширов, Р. Бикмөхәмәтов, Р. Ишморат, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ф. Хөсни һ. б. Ә инде Г. Тукай һәм М. Гафури шикелле классикларны әйткән дә юк! Аларның күптомлыклары да, аерым китаплары да киштәләргә бик матур итеп тезеп куелган. Әле алай гына да түгел. Тычина Тукай турында чыккан китапларны да җыярга тырышкан. Ә. Фәйзинең «Тукай» романы әнә шуңа мисал.

Тычина киштәләрендә каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең китаплары да бик күп. Шулай ук аның турында чыккан хезмәтләрне дә санап бетереп булмый. Аларның

һәммәсе диярлек украин шагыйренең игътибарын җәлеп иткән, күңелендә урын алган.

Әйе, татар шагыйрьләренең тормышы да, иҗаты да Павло Тычинаны сокландырган. Тукайның трагик язмышы аны бигрәк тә тетрәндерә. Тугызынчы томга кергән «Автобиография» сендә мондый юллар язган: «Хәзерге вакытта татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатын өйрәнәм әле». Алга таба китеп автор үз хезмәтендә Тукай турында «көчле шәхес» дигән фикер үткәрә, соклану хисләрен белдерә. Татар халкы тудырган-бу рухи батырлык хезмәттә башка милләт уллары белән чагыштырып карала.

Хәзер безгә шундый бер факт та билгеле булды. Павло Тычина соңга таба татар халкының бөек улы Габдулла Тукайның иҗат портретын да тудырырга уйлый. Ләкин ул моны тулысы белән эшләп өлгерә алмый. Бары тик беренче өлеш — «Тукайның балачагы» дигән бүлек кенә тәмамланып кала. Ләкин, аның каравы, бу беренче өлеш — менә дигән лирик новелла! Укыганда бәгырьгә тия торган чын әдәби әсәр!

Ерак, ләкин йөрәккә якын Татарстан белән Павло Тычина гел кызыксынып тора. Ә инде Казанда бөек Тукайга һәйкәл салынгач, ул үзенең чиксез шатлыгын белдереп телеграмма җибәрә, күңеленнән ташып чыккан ихлас сүзләрен юллый.

Бирелә тагын шагыйрьнең тәрҗемә эшчәнлеге хакында сүз кузгатмый калу мөмкин түгел. Чөнки Тукай безнең әдибебезнең иң яраткан шагыйрьләреннән берсе була. Аның бу турыда язып калдырган сүзләре дә бар. «Тукайны бик теләп, яратып тәрҗемә иттем»,— дип яза ул хатында. Ни өчен дигәндә, Тычинаның үзендәге сыман, Тукай иҗатында да иң беренче урында халык, милләт кайгысы, аның мәнфәгатьләре. Халык тормышының драматик хәл-әхвәлләре, күренешләре. Әнә шулай халыкка якын торып һәм аның йөрәге ничек типкәнне тирәннән тоеп яшәгән шагыйрь өчен, чыннан да, бөек Тукай язганча:

*Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый!*

Әйе,Тычина утызынчы елларда татар әдәбияты белән чын-чыннан мавыга. Татар теле аша ул олы бер халыкның хис итү, фикерләү үзенчәлекләре белән якыннан таныша. Аның көченә, рухи җегәренә, үлемсезлегенә баш ия, соклана. Сез әле тагын шуңа да игътибар итегез: бу бит «халыклар атасы» Сталинның телләр кушылу турындагы ялган теориясе чәчәк аткан еллар!

Иҗат һәм яшәү чынбарлыгы әнә шулай ялган теорияләргә каршы килеп, украин теленең дә, татар теленең дә урыс теленнән ким түгел икәнлеген раслый. Һәр ике әдәбиятта иҗат иткән әдипләр моны үз әсәрләре белән ышандырырлык итеп күрсәтәләр. Тукайның атаклы «Туган тел»ен — татар халкы өчен гимн сыман яңгырый торган әсәрне — украин телендә яңгырату да нәкъ менә шундый зур фәлсәфи мәгънә ала. Бу шигырьнең украин телендә ничек яңгыравын белергә теләгән кешеләр булса, аларга Павло Тычина уникe томлыгының бишенче томына күз салырга киңәш итәм (дөресрәге: бишенче томның икенче китабына, 261 биткә).

Тукайның татар иле табигатен соклангыч дәрәҗәдә оста тасвирлаган әсәрләрен дә бүгенге украин укучылары яратып кабул итә. Ә инде шагыйрьнең нечкә лирикасын әйткән дә юк! Сизгер күңелле украин укучысы Тукай сазын бөтен рухы, җаны-тәне белән тоя, аңлый.

Ләкин Павло Тычина тәрҗемәсендә бирелгән «Шүрәле» белән «Су анасы»на махсус тукталу кирәктер. Бу әсәрләрдә Тукайның һәм Тычинаның олы талантлы тигез чәчәк ата диярго мөмкин. Оригиналдагы гаҗәеп гүзәллек, илаһилык, чиксез матур фантазия, хыял уены һәм психологик нечкәлек, сәнгати камиллек украин теленең тирән һәм сыгылмалы тукымасы аша гаять тә тулы бирелгән. Тукайдагыча чын һәм табигый, гармоник гәүдәләнеш тапкан ул.

Бу гаҗәп тә түгел. Чөнки Павло Тычина иң башта татар шагыйренең әлеге поэмаларын укып бөтен йөрәге белән рухланган, алардагы рухи җәүһәрләргә сокланган. Поэмалар хакында украин шагыйре язып калдырган менә мондый сүзләр дә билгеле: «Әгәр дә тагын бераз яшь алган булса, Тукай татар халкының дастаны шикелле олы бер әсәр дә тудырган булыр иде. «Шүрәле» не укыган вакытта күңелгә әнә шундый уйлар килә. Бу әсәрдә Тукайның дастаннар язарга да сәләтле булуы күренә». Мондый югары бәһа сүзләрен без уныичы томның 412 битендә укыйбыз. Горурлык һәм чиңга ашмый калган бөек әсәрләр өчен үкенеч тойгысы белән укыйбыз без бу юлларны.

Тычина һәм татар әдипләре... Олы шагыйрь белән әңгәмәләр вакытында без бу темага бик тә еш кагыла идек. Чөнки, югарыда әйтелгәнчә, Тычинаның Казанда танышлары күп. Ул аларның иҗатын даими диярлек күзәтеп бара. Уй-фикерләрен минем белән дә уртаклаша.

Әлегрәк булган шундый очрашуларның берсен һич онытасым юк. Без шагыйрьнең Киевтагы квартирасында, аның эш бүлмәсендәге түгәрәк өстәл янында сөйләшеп утырдык. Мин килеп кергән чагында ук инде Павло бик тә дулкынланган иде. Озак та тормый, ул дулкынлануының сәбәбен дә әйтеп бирде. Мәскәүдән, Муса Җәлилнең хатыны Әминәдән хат алган икән. Әминә Җәлил апа Мусаның тоткынлыгындагы

соңгы чоры турында язган. Тормәдә Павло Тычина исемен дә сагынып искә алуын әйткән.

Һич онытасым юк: Павло Тычина куллары белән яңагына таянган, кашлары җыерылган, ә кайгы һәм кызгану, тирән сагыш тулы күзләре миңа карый... Шагыйрь язмышын никадәр якын һәм тирәннән кичерүен тагын бер мәртәбә әнә шунда күрдем мин. Ә бу халәтнең сүзләргә әверелеп, кәгазьгә үк төшүе аларның дуслыгына бернинди дә шик калдырмый. Украинаның әдәбият-сәнгать музеенда 464 фонд 3404 берәмлек дип саклана торган документта Тычина куллары белән менә болай дип язылган:

«Минем күңелемнән һичкайчан чыкмаслык яңалык булды. Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгында җәзалап үтерелгәнен белдем. Соңгы көннәрендә ул дусларыннан Фадеев белән минә дә искә алган икән».

Әсәрләр җыентыгының 9 томында ул: «Без Җәлил белән ничек шулай якынаеп китә алдык соң? Моны нәрсә белән аңлатып була?» — дип үз-үзенә сорау да куя һәм Мусаның бу дуслык хисен тулаем украин халкына мәхәббәт билгесе итеп кабул итә, шулай аңлата. Алар ничек танышып киткәннәр соң?

Бу хакта Тычина мондый юллар яза: «1939 елда Киевта СССР Язучылар союзы тарафыннан Шевченко пленумы үткәрелгән иде. Аңа Муса Җәлил дә килде. Без әнә шунда таныштык. Шевченко һәм Пушкин турында да, Туманян һәм Габдулла Тукай турында да сөйләштек.» Әлбәттә, Тычина инде моңа кадәр үк Казаннан һәм Мәскәүдән килгән татар газета-журналлары аркылы Муса Җәлил шигырьләре белән танышкан булган. Аның исеменә игътибар итә килгән.

Дуслык хисләрен үз йөрәгендә тулы килеш саклаган Павло Тычина батыр татар шагыйренең тууына 60 еллык уңаеннан «Муса Җәлил Киевта, 1939 ел» дигән шигырен иҗат итә. Бу әсәрдә үткәндәге кояшлы матур көн дә, гүзәл олы бәйрәм үткәрергә украин башкаласына җыйналган дус-ишләр дә — кыскасы, һәммәсе дә тулы чагыла. Тантанага илнең иң зур әдипләре килә. Аны Алексей Толстой белән Павло Тычина ачып җибәрә. Шулай итеп, Шевченко юбилее төрле милләт улларын туганлаштыра, бер-берсенә якынайта, аларны рухи яктан баета.

Украин халкына һәм әдибиятына карата Муса Җәлил дә иң җылы хисләр саклаган икән. Бу хакта Тычинага соңыннан Әминә Җәлил әйтә. Унынчы томны ачып укыган кеше биредә Муса Җәлилнең Тарас Шевченко турындагы фикерләре белән очрашыр. Анда әдипләр өчен бердәнбер иҗат нигезе халык, милләт, аның үлемсез иҗаты булу әйтелә.

Муса Җәлил дә Татарстанда украин әдипләрен пропагандалау буенча байтак кына эшләр башкарган икән. Аның тырышлыгы белән 1939 елда Казанда «Кобзарь» басылып чыга. Шулай ук ул башка әсәрләрне дә тәрҗемә итә, «Шевченкодан өйрәнергә кирәк» дигән мәкалә яза.

Боларның барысы да, әлбәттә, ерак Украина язучыларына яхшы мәгълүм була. Дуслык җепләре ныгуны һәр ике як зур канәгатьлек, сөенеч белән күзәтә. Шуңа күрә Мусаның һәм башка татар әдипләренең сугыштагы, тоткынлыктагы каһарманлыгы украин әдипләрендә бары тик хуплау гына таба. Соклану хисе тудыра. Бу хакта Павло Тычина кабат-кабат яза. Ә бер урында ул Муса Җәлилне атаклы Прометейның энесе дип тә атый. Чыннан да, татар улының батырлыгы да шуңа тиң иде бит! Мусага — илебез әдипләреннән бердәнбер кешегә — бер үк вакытта Советлар Союзы Герое исеме дә һәм Ленин премиясе дә бирелгәч, Павло Тычина бу гадел бүләкләргә иң куанган кешеләрнең берсе була. Үзеннең уй-хисләрен дә шагыйрь кәгазьгә төшергән, халкы белән уртаклашкан. Боларны укучы уникенче томнан таба ала (454 бит).

1966 ел. Инде Павло Тычинаның безнең белән хушлашырына да бер генә ел калган. Әмма ул һаман халык арасында кайный, җәмәгать тормышында актив катнаша. Өенә төрле-төрле үтенечләр белән килгән кешеләрне дә кабул итә, аларга үз кулыннан килгәнчә ярдәм кылырга тырыша. Менә шушы елда Павло Тычина янында татар язучысы һәм тәрҗемәчесе Самат Шакир булып китә. Казаннан иң олы бүләк итеп Тычинаның дустына багышланган Муса Җәлил альбомын алып килә. Павло Тычина моңа чиксез шатлана. Альбомның һәр суретен, һәрбер битен зур игътибар белән карый. Һәммә сүзне йотлыгып укый.

Аннары инде Мусаның үзе турында сүз китә, бүтән татар әдипләренә күчәләр, татар һәм украин әдәбиятларының бүгенге яңалыклары белән уртаклашалар. Павло Тычинаның бик тә Казанга барасы килә, ул Җәлил һәйкәленә чәчәкләр бәйләме куярга, шулай итеп үзенең дустына хөрмәт күрсәтергә тели.

Язучылар сөйләшеп утырганда Тычинаның җәмәгате Лидия Петровна аларны табынга дәшә. Андагы сөйләшүләр турында үзенең Киевта басылып чыккан китабында Самат Шакир болай дип искә ала: «Павло Григорьевич бокалын күтәрде дә мондый тост әйтте. «Без барыбыз да бер күкнең йолдызлары. Күктә йолдызлар бик күп. Аларның һәммәсе үзенчә балкый. Әдипләр дә шулай. Халкы биргән иң яхшы сыйфатларны чагылдырып балкый алар. Безнең баш очыбыздагы күкнең чын матурлыгы да әнә шунда — төрле һәм яктыдан-якты йолдызлар күп, бик күп булуда!»

Бу мәҗлестә Павло Тычина Самат Шакир белән татарча сөйләшә. Ә аннары елмаеп сорап куя: «Сез минә украинча белмисездер әле...» Самат Шакир аңа уңайсызланып кына украинча белмәвен әйткәч, Тычина аны тынычландырырга ашыга: «Мәнә мин сезнең шигырьләрегезне украин теленә тәрҗемә итеп куярмын да, сез инде ул чагында үз әсәрләрегезне укыр өчен безнең телне дә өйрәнергә мәҗбүр булырсыз!»

Әнә шундый киң күңелле һәм бик тә тырыш кеше иде безнең Павло Тычинабыз. Казанга ул тәки бара алмады. Икенче елны рәхимсез үлем аны безнең арадан алып китте.

Украин һәм татар укучыларының яраткан шагыйре Павло Тычина турындагы бу истәлек-уйлануларны тәмамлаганда яңадан да аның яраткан сүзләре хәтергә төшә: «Без бер күкнең йолдызлары...» Әйе, Павло Тычина үзе дә әнә шундый йолдызларның берсе һәм бик тә яктысы иде. Ул тирә-юньгә җылыны һәм яктылыкны һич тә кызганмыйча, мул итеп сипте. Күп милләтләр арасына, аларның әдәбиятлары арасына дуслык күперләре салышты.

Шунысын сөенеп әйтергә була: Павло Тычиналар, Муса Җәлилләр салган дуслык күпере бүген дә нык. Үзара элемтәләр һич тә өзелми. Мисал өчен шагыйрь Зәки Нури тәрҗемәсендә басылып чыккан «Алтын хәзинә» һәм «Күңелле китап» исемле җыентыкларда (1973, 1979 еллар) украин әдипләренең әсәрләре күп урын алган. Шулай ук 1982 елда шагыйрь Роберт Миңнуллин тарафыннан төзелгән «Без яшибез совет илендә» дигән җыентыкта да украин шагыйрьләре М. Рыльский, М. Бажак, В. Коротич, А. Малышко, В. Сосюраның әсәрләре татарча бик матур яңгыраш тапканнар.

Боларның һәммәсе өчен украин халкы сезгә зур рәхмәт сүзләре әйтә.

*Симферополь.*

# ИХЛАСЛЫК

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА



Заманыбыз базарга кереп бара.

Базар базар инде ул, аның — үз законнары. Әйбергә бәяне кем ничек теләсә, шулай куя. Берәү алдый, икенчесе алдана, өченчесе елмаеп карап тора. Мөнәсәбәтләр, тәртипләр шундый — кемдер байый, кемдер бөлә.

Тормышта шулай. Ә безнең әһелләр арасында, әдәби хәрәкәттә — әдәп кануннары җитәкчелек итәргә тиешле җирдә ничегрәк?

Турысын әйтик, хәтта шушы өлкәгә дә базар тәртипләре, дөресрәге — тәртипсезлекләре урнашмакчы.

Төрле җыелышларда, утырышларда, редакцияләрдә, кулуарларда, мәҗлесләрдә әсәрләргә, авторларга яңа бәяләр билгеләнә. Мәнфәгать ачык — агайэнегә, дус-ишкә, бигрәк тә үзеңә бәянең югарырагын эләктереп калырга тырыш! Тыйнакланып әдәпне өстен куярга азапланганны яманла, шул кирәк аңа. Ә ышанучан укучы исә базардан затсыз товар алып, шуны мактасын. Анысы да шуңа лаек.

Әле күптән түгел генә: «Мин партиясез большевик» дип мактанган кешеләрне кайберәүләр фиркасыз булганнары өчен зурламакчылар, ә элек партиядә торганнарны «төп көчләр обоймасы»ннан төшереп калдырмакчылар.

Мәгълүм ки, мондый омтылышлар әхлаксызлык шартлары хакында борчылырга мәҗбүр итсәләр дә, аларның соңгы бәя түгеллеген хәтерләп, тынычлана төшәргә җай бар. Бу бит әле соңгы сүз түгел. Ә бит әле соңгы сүз бар — вакыт сүзе. Әгәр вакыт үз хөкемен чыгарса, моннан соң инде бернинди шикаятьләр кабул ителми...

Утызынчы елларда, әйтик, нинди генә күренекле язучылар юк иде. Беренче әсәрләреннән үк аларны мәктәпләрдә өйрәнә башладылар. Ул язучылар үзләренең классик икәнлекләренә ахыргы көнгәчә ышанып яшәделәр, әһәмиятле, кирәкле әһел булулары белән рухланып иҗат иттеләр. Ә нәтиҗә? Чынлыкта ул елларда язылган әсәрләрнең күбесе сәнгать түгел, сәясәт булган икән. Хәзер, тикшереп карагач, аһ итәсең: күренекле исемнәр бар, иҗатлар юк. Тегә заманнарда мәчетләрне көчләп аударсалар, хәзер исә әдәби манараләр үзлекләреннән авалар. Бөтен бер пирамидалар юкка чыга. Шуңа күрә, җитмеш еллык совет әдәбиятына бәя биргәндә, базар шуклыкларын инкарь иткән хәлдә, кыйммәтләрнең барыбер үзгәрергә дучар икәнлеген танырга кирәк була.

Юбилейлар килә тора. Иҗат кешеләрен ихтирам белән искә алырга тиешбез. Ләкин исәнме бу язучы, бармы ул? Йөрәк куркып тора.

Инде менә үз исәнендә күренекле җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы публицист, фикер иясе буларак танылган язучыларның берсе — Габдрахман Әпсәләмовны искә алабыз, әсәрләрен барлыйбыз. Һәм аңа да яңачарак карарга тиеш булабыз.

Язучының әдәбияттагы урынын билгеләр өчен аның иҗатын һәм шул ук вакытта әдәбият тарихының үзен дә бөтен хәлендә күз алдына китерергә кирәк. Тарихилык принцибы җирлегендә, әдәби фактлар тотрыклырак сакланалар.

Үткәннәргә карасак, йөзебез кызарырлык түгел — һәр гасыр, һәр дәвер диярлек үзенең рухи чагылышын таба килгән. Атап әйтсәк, беренче бөтендөнья сугышы һәм аннан соңгы дәверләр тарихи елъязмаларда гына түгел, әдәбиятта да шактый киң эшкәртелгән, үзләштерелгән. Бу чорны күз алдына китерү өчен Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ш. Камал, К. Нәҗми, Г. Бәширов, И. Гази әсәрләрен искә алу җитә дип уйлыйм. Илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү еллары тарихка кайбер әсәрләрдә үзләренең каршылыклар белән бергә беркетелгән. Бу чор әдәбиятында вакыт сынавын уза алмаган әсәрләр күплеген белгән хәлдә, әгәр барлык әсәрләрне бер себерке белән куарга тиеш түгеллегебезне онытмасак, хәерлерәк булыр иде. Бу чор белән шулай. Ә аннары?

Аннары — Бөек Ватан сугышы...

Хәтергә иң беренче булып шигъри әсәрләр килә. Ф. Кәрим, М. Җәлил... Аларга бүтән аерым мисаллар өстәргә мөмкин. Ә менә прозага кайтып, мин бу чорны Г. Әпсәләмовтан башка итеп күз алдына китерергә тырыштым. Болай фаразлаганда, тагын аерым мисаллар белән чикләнергә туры килә икән. Ә авыз тутырып әйтә алырлыклары сугышның тылдагы тормышына карый. Кызыклы, җитди әсәрләр. Әмма фронтның үзе түгел. Алар белән чикләнгән очракта, безнең әдәбият тарихында чор тормышы-

ның ярты гына ягы яктыртылган булыр иде. Сугышта халкың батырлыкның бөек үрнәкләрен күрсәтсен дә, шул ук вакытта ул әдәбиятта өнсез-тарихсыз калсын. Кичереп бетерә алмаслык гаделсезлек булыр иде бу. Әмма, бәхеткә хәлебез алай ук мөшкел түгел. Ватан сугышы вакыйгалары баштан азаккача әдәби елъязмабызда тасвирланып, тиешле бәясен алган. Чор өлешчә, И. Гази, Ә. Еники тарафыннан, ә бигрәк тә Г. Әпсәләмов иҗаты белән ныгытылып, шактый тулы һәм дөрес сурәтләрдә мәңгеләшкән.

Г. Әпсәләмовны тарихи киңлеккә чыгарган әсәрләрнең беренчесе «Ак төннәр» повесте булды. Монда әдипнең киләчәктә дәвам итәчәк барлык үзенчәлекләре, тематик юнәлешләре төсмерләнә. Фаҗигале вакыйгалар, документаль дәрәҗәдәге фактлар, шул ук вакытта романтик күтәренкелек, сюжет киеренкелеге — болар Әпсәләмов иҗатына гомумән хас сыйфатлар. Әсәрнең стиленә катнашкан маҗара алымы да югалып калмаячак, башка үлчәмнәрдә, башка дәрәҗәдә дәвам итәчәк. Ә характерлар ачылышы ягыннан исә бу повесть зур полотнолы романнарга да бирешмәячәк.

Әсәрдән — әсәргә, елдан-елга күчә-күчә, тулылана, көчәя барачак төп сыйфатлар — кешеләрнең ватандарлыгы, батырлыгы, төрле милләт вәкилләренең туганнарча эчкерсезлеге сугышның үз эчендә, аның да иң хәтәр төшендә — разведкада, кеше барлык үз асылында гына була ала торган шартларда күренә, распана һәм ышандыра.

Повестьнең яшьләргә адреслап язылганын искә алсак, аның бүгенге көндә дә файдалы эш башкаруын тою кыен түгел. Димәк, әсәр, тарихи факт буларак кына түгел, сәнгать ягыннан да вакыт сынавын уза алды дияргә мөмкин.

«Ак төннәр» повестенда ирешелгән максатлар «Алтын йолдыз» романында, жанр таләпләренә туры килгәнчә, тагын да күпъяклырак, төрлерәк рәвешләрдә, вакыт һәм пространство җәһәтеннән зуррак киңлекләргә чыгып, катлаулырак була бара.

Вакыт ягыннан бу әсәр икенче бөтендөнья сугышын артыгы белән үз эченә ала. Җир тарихында моннан да хәтәр, моннан да катлаулы, моннан да фаҗигале заманны табу мөмкин түгелдер. Кешеләр һәм илләр, иҗтимагый көчләр, капма-каршы басып, бер-берсен юк итәр өчен күтәрелгән. Бөтен кешелек язмышы сандалга куелган. Чорның һәм сәяси, һәм милли, һәм әхлакый эчтәлеге шуннан гыйбарәт иде. Г. Әпсәләмов «Алтын йолдыз» романында аны шул кискенлеге белән куйды да.

Әсәрне публицистик, хәтта сәяси роман дияргә була. Хәзерге заман күзләре белән карагаңда, табигыйлек җитмәгән урыннары юк түгелдер. Авторның үзенә хас булмаганча, геройлар тыйнаклыктан интекмиләр — алар батырлыкны эшләгәнче үк аны югары нотапарда игълан итәләр. Әмма бүтән очракларда гафу ителми торган бу манераны, сүзнең тәрбияви сәләтен искә алып, кешеләрнең позунглар белән бер-берсенең рухын күтәрергә тырышуын, шул рәвешле үзләренең иманнарын ныгыта торуын, максатны ант белән беркетүгә охшаш халәт кичерүләрен уйласак, «Алтын йолдыз» дагы риторикәны аңларга һәм кайбер искәрмәләр белән кабул итәргә тиеш булабыз.

Вакыт үзенчәлекләре мәгънәсендәге шундый картинаны күз алдына китерик. Геройларның берсенең өендә стеналар идәннән түшәмгәчә майлы буяу белән буялган, һәм бу төс квартираның матурлыгын, ә анда яшәүчеләрнең агылҗымлыгын (зыяпылыгын) шәрехләү максатында күрсәтелә. Стенадагы күзәнәкләрне томалап, һаваны кимете, сулышны кыса торган төти буяулар белән әдәбиятта да мавыккан чаклар бит бу. Әлбәттә, дәвер корган араннардан Әпсәләмов та сикереп кенә чыга алмады. Тормыш үзгәрә, көнкүреш культурасы үсә, эстетик тойгы камилләшә барган яңа чорда инде искергән күренешләр тарих атрибутлары булып кына кала. Мондый сурәтләрне хәзер шулай кабул итәргә кирәктер дә.

Бер үк вакытта һәр заманның үз өстенлекләре булуын истән чыгару дөрес булмас иде. Сүз барган дәвернең рухи галәмәте дигәндә, мин кешеләрдәге иман ныклыгын басым ясап әйтер идем. Экономик һәм социаль казанышлар белән распана килгән югары пафос, массовый күтәренкелек, якты киләчәк матурлыгына чиксез ышаныч, бөек киләчәк хакына көрәшкә, ә кирәк икән үлемгә әзер тору. Гасыр уртасында ачылачак фаҗигаләргә карамастан, авторитар система шундый бөтен бер буынны тәрбияли алган бит. Җир шарын чолгаган туры мәгънәсендәге яңгыннан совет илен шул алданган буын вәкилләре саклап калды. Алар үзләренең алдануларын, чынлыкта империя өчен кан койганнарын белмичә киттеләр. Иң изге идеаллар биләгән иде аларның саф җанын. Аларның ялгышуы ихлас ялгышу, гаепсез ялгышу иде.

Илдәге башка күп язучылар белән беррәттән, татар язучысы Г. Әпсәләмов та сугыш вакытында һәм аннан соң шул буынның тарихи миссиясен, характер сыйфатларын, дөньяга карашларын мәңгеләштерү бурычын үз өстенә алды.

«Алтын йолдыз» романында ватандарлык, интернационализм, батырлык сыйфатлары иҗтимагый чыганаклары белән бергә эзлекле рәвештә тасвир ителде. Ул сыйфатларны барлыкка китергән сәясәтнең икейөзлелеге, идеологиянең тормышка ашмый торган булып чыгачагы ул чакларда распанмаган гына түгел, хәтта шик астына да куелмаган бит әле.

Хезмәткә, белемгә, культурага, милли мөстәкыйльлеккә булган хокуклар, декларация булып калмыйча, чынлык дәрәҗәсенә ирешкән шартларда геройлар, тормышның чын хуҗалары булып, җиңүләрне туктаусыз дәвам итү, үстерү өчен җаннарын аямыйча көрәшәләр. Казан мәктәпләрендә үз телләрендә, татар телендә белем алалар. Аңлы

диган патриотизм шул җирлектә формалаша. Романның мәктәп тормышын чагылдырган бүлекләрендә атмосфера ышандырырлык детальләр аша гәүдәләндерелгән. Ул мәктәпләрнең бөек җиңүдән соң тиз араларда ябылачагын кешеләр (шул исәптән автор үзе дә) күз алдына китерә алмаган бит әле.

«Алтын йолдыз» — киң колачлы әсәр. Публицистика авторга чорны бөтен тулылыгы белән иңләргә мөмкинлек бирә. Төньяк диңгездән Кара диңгезгәчә булган фронт сызыгын үз эченә сыйдыра. Геройларның кайсы төбәккә китүләренә карап, барлык фронтлар диярлек сурәтләү офыгына эләгәләр. Чагыштырмача тәгаенрәк вакыйгаларда Калинин фронты, Сталинград сугышы тасвир ителә. Әмма романны әсәр буларак оештырып, беркетеп торган коллизияләр Карелия фронты вакыйгаларына нигезләнә. Бу вакыйгалар, башкалары белән чагыштырганда, тормышчанлык белән аерылып торалар.

Фикерне раслау өчен Свирь елгасын кичү күренешен искә төшерик. Көймәләр су астындагы чәнечкеле тимерчыбыкларга килеп бәрелгәч, Галим Урмановның солдатлар тукталып калмасын өчен шәхси үрнәк күрсәтү нияте белән суга сикерүе, су астында чәнечкеләргә эләгеп, көч-хәл белән генә ычкына алуы... Мондый тәгаен очракларны уйлап чыгару мөмкин түгелдер. Аларның чынлыгына сүзсез ышанасың. Тетрәндергеч хәлләрдә кешенең тәвәккәллелеген дә, тапкырлыгын, көтелмәгән авырлыкларга карамастан җиңүгә атлыгучы характер көчен дә үз күзең белән күргәндәй буласың. Сурәт һәм сюжет ныклыгын шулар хәл итә. Ирекле фикерләүләргә, уйлануларга җан кертә. Публицистика сәнгать дәрәҗәсенә ирешә.

Батырлык романтикасын тоя, күрә һәм күрсәтә алу, образны һәйкәл биеклегенә күтәрү, шул ук вакытта аны документаль дәрәҗәдәге фактлар белән ныгытырга тырышу «Газинур» романы һәм соңрак язылган «Мәңгелек кеше» романы өчен дә төп үзенчәлек булып кала. Һәр ике әсәрдә конкрет шәхесләр алына. А. Матросов батырлыгын кабатлаган Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин һәм сугышта каты яраланып әсирлеккә эләккән, ә анннары фашизмга каршы подполье көрәшенә җитәкчелек иткән подполковник Бакый Нәзиров язмышы һәм биографиясе әсәрләрнең төп эчтәлеген тәшкил итә. Шул ук вакытта «Мәңгелек кеше» дә язучының стиле һәм сурәтләү ысулында кайбер яңа төсмерләрне, вакытка бәйле үзгәрешләрне күрергә мөмкин. Кырыгынчы-илленче елларда язылган әсәрләрдән аермалы буларак, монда артык пафоска, матур бизәкләргә, риторикага бирелү инде сизелми диярлек. Боларны кырыс сурәтләр, динамик эпизодлар алмаштыра. Бу яңалык исә укучыга тәэсир итү көчен тагын да арттыра төшә. Сәяси яңгыраш сакланган хәлдә, фәлсәфи тирәнлек барлыкка килә. Әсәрдә, фашистларның ерткычлыклары ачылу белән бергә, расизм идеологиясенең реакцион асылы гәүдәләнә.

Сугыш кырларын аркылыга-буйга кичә-кичә тупланган тәҗрибә авторга башта дистәләрчә мәкалә, очерк, хикәя, ә соңыннан «Ак төннәр» кебек нык мускуллы повесть, аннары «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше» кебек киң панорамалы әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирде. Республикабызның, бөтен илнең гаять катлаулы һәм хәтәр бер чоры гәүдәләнгән бу әсәрләр, халкыбыз тарихында башка берни белән дә алмаштырып булмый торган зарур сәхифә буларак, үзләренең лаеклы урыннарын саклап калалар. Сугыш чоры вакыйгалары мәңгеләшкән рухи кыйтга Әпсәләмов иҗатының һәм шул ук вакытта татар әдәбиятының әһәмиятле бер өлеше булып тора.

Бу урында тагын шунысын басым ясап әйтергә кирәк: әле искә алынган әсәрләр Әпсәләмов иҗатының яртысын гына тәшкил итә. Аның иҗаты, янәшә ике юнәлештә башланып, азаккача шулай дәвам итте. Бу иҗатның тематикасын, гомумиләштереп әйткәндә, сугыш һәм тыныч хезмәт дип билгеләргә мөмкин.

Сугыш һәм тыныч хезмәт.

Язучы, шушы һәр ике юнәлештә тигез тырышлык куеп, әдәби кыйммәтләре ягыннан тигез дәрәҗәдәге әсәрләр калдырды.

Хәзерге чорда дәрәҗәсе кими төшкән тема — эшчеләр тормышы — әдипнең беренче әсәрләрендә үк үзәккә куелып, апарда сугышка чаклы булган чордагы эшчеләр тырышлыгы, бигрәк тә яшьләрнең якты уйлары һәм тойгылары тасвир ителә иде. Бу тема сугыш материалында язылган әсәрләрдә дә зур гына урын ала. «Алтын йолдыз» да, мәсәлән, сугышка кирәкле әйберләр җитештерү өчен «Урак-чүкеч» заводында көннетөнне белми эшлиләр. «Ил тәкерсә — күл булыр», — дип, Сталинград заказын үтиләр. Ленинградны саклаучылар чакыруына эш белән җавап бирәләр.

Язучы аннан соң да җитештерүчән хезмәт кешеләре турында күпсанлы очерклар, хикәяләр яза торды. Шуңа күрә, «Сүнмәс утлар» романы авторның үзе өчен дә, укучылар өчен дә көтелмәгән хәл булмады.

Производство романнары дип йөртелгән әсәрләргә мөнәсәбәт үзгәрүен аңларга мөмкин, әлбәттә. Чөнки аларның күпчелеге чынлап та, саф техника вакыйгаларына кайтып кала һәм кешеләрнең рухи тормышын чагылдыра алмый иде. Ләкин бу мәсьәләдә икенче чиккә ташлану белән, эш кешесе тормышыннан мәгънә, матурлык табып булмый, дип уйлаучылар белән мин беркайчан да килешә алмадым.

Билгеле, катлаулы өлкә буларак, материал каршылыгын җиңә алмау сәбәпле, бу жанрда, башка темалар белән чагыштырганда, уңышсызлыкка очрау мисаллары, бәлки чынлап та, күбрәктер. Ләкин моңа карап: барлык әсәрләрнең кеше турында булырга тиешлеген фетишка әйләндереп, эшче темасы, авыл темасы яки башка темалар эчтәлек-

сез терминнар гына, дип белдерүләр, ныклап уйласаң, теоретик яктан да, практика җәһәтеннән дә имтихан тота алмыйлар. Чөнки нинди генә профессия кешесе турында язсаң да, ул, барыбер, кеше турында язу дигән сүз бит. Тормышта гомуми кеше, абстракт шәхес була алмый. Кеше теге яки бу төгаен сферада, теге яки бу хезмәт шартларында яши. Чын дип кабул ителерлек характер бары тик конкрет җирлектә генә материальләшә ала. Аның яшәү шартлары, дөньяда тотып торган төп шөгыле күрсәтелми икән, ул теге яки бу әхлак тарафдары булып, абстракт персонаж булып кына кала. Кызганычка каршы, шул дәрәҗәдәге тормышсыз әсәрләр бездә әледән-әле күренә тора. Хәлбуки, субъектив мотивлардан азып урнашкан скепсисны инкарь итәрлек әсәрләр дә — әгәр игелекле ният белән карасак — бездә шулай ук аз түгел. Аларның бер мисалы — «Сүнмәс утлар» романы.

Әсәрдәге иң үзенчәлекле образлардан Урәзмәтовлар династиясенең өлкән вәкиле, карт эшче Сөләйман турында, мәсәлән, ике йөрәкле, ике башлы кеше, кыю, ә кайчакта дуамал кеше дибез икән, без моны барыннан бигрәк заводтагы гамәлләрен күздә тотып әйтәбез. Кайчандыр ул завод хуҗасы булган Яриковны ут хәлендә агызып торган металл кою мичена ыргыта язган. Хәзерге заводтагы тәртипсезлекәр өчен завод директоры Хәсән Мортазинны ул бала-чага мисалында тиргәп ташлый. Аның бу сыйфатын бары тик эш урынында гына күрсәтергә мөмкин. Гаилә рамкаларында мондый дуамаллык холыкның яманлыгы хакында сөйләр иде. Иҗтимагый, принципиаль эчтәлеген җуйган Сөләйман кечкенә кеше булып чыгар иде.

Әпсәләмов бу романда чын мәгънәсендә реалистик, төгаен образлар галереясе тудырырга ирешә. Сөләйман балалары — Иштуган, Илморза, Гөлчирә, Нурия, Илшат — үз буыннарының төрле сыйфат билгеләрен туплаган характерлар. Нурия белән Гөлчирә арада үзләренең күңел сафлыгы, ачык холыклы булулары белән аерылып торалар. Алар белән бергә, мишәр акцентлы вахтер Айнулла, тыныч-салмак табигатьле Матвей Яковлевич, флот жаргоны сибә торган Алеша Сидорин, мещан хатын Зонтик Шәмсия һәм башка кызыклы образлар белән танышкач, эшчеләр тормышының гаять күңелле, гаҗәеп мәгънәле булуына һәм сәнгатькә шул байлык шәм матурлыкларын саклаган хәлдә күчә алуына ышанасың. Димәк ки, әдәбият өчен яраксыз тормыш материалы юк, ә бары тик аны сурәтли белергә генә кирәк. Кызганыч, шушындый әлифба дәрәҗәсендәге төшенчәләр хакында да безгә чынлап торып бәхәсләшергә туры килә.

Тәнкыйть тарафыннан әсәрнең бәхәссез табышы дип бәяләнгән Хәсән Мортазин исә, административ-командалык ысуллары белән эшләгән җитәкче буларак, безнең көннәргә аваздаш һәм ул язучының тормышны алдан күрә алу сәләте хакында сөйли.

Икеләнүсез әйтергә мөмкин: «Сүнмәс утлар» романы язучының үз иҗатында да, гомумән татар прозасында да җитди һәм кирәкле әсәрләрнең берсе булып кала.

Завод кешеләре тормышына кагылмаса да, «Ак чәчәкләр» романын шушы ук юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр рәтенә кертсәк, шулай ук ялгышмабыз дип уйлыйм. Чөнки материал сайлау һәм аңа мөнәсәбәт нигездә бер үк төсле: әсәрдә медицина хезмәткәрләре гаилә эчендә генә түгел, ә башлыча эш урыннарында, үз һөнәрләренә бәйле рәвештә тасвирлана.

Шуның белән бергә, әдипнең иҗади алымнары, сурәтләү манерасы да «Сүнмәс утлар»дагыча кала. Ә үзгәреш дигәндә, вакыйгалар барышында психологик детальләргә, кичерешләргә күбрәк игътибар ителүен күрсәтергә була. Яңалык дип кабул ителгән хәлдә дә бу үзенчәлек элгәрге әдипнең элгәрге сөйләү һәм тасвирлау принципларына каршы килми. Бары тик аның кеше күңеленә тирәнрәк керә баруын, ягъни авторның табигый үсеш хасиятен генә дәлилли.

Г. Әпсәләмов әсәрләрен күздән кичергәч, кайбер нәтиҗәләр сорала. Язучы сугыш чоры вакыйгаларын гәүдәләндергән әсәрләре белән дә, җитештерүчән хезмәт кешеләренә багышланган әсәрләре белән дә әдәбият тарихында калырлык зарури эш башкарган икән...

Сугыш һәм тыныч хезмәт, бер карагандa, капма-каршы полюслар шикелле тоелса да, сугыш вакытында тыл һәм фронт бердәмлеге зарури булган кебек, бу юнәлешләр, Әпсәләмов иҗатының башыннан азагына кадәр тигез хокуклар белән файдаланып, бөтенлек хасил итәләр. Кешеләрнең ватандарлыгына һәм батырлыгына дан җырлау максаты язучының барлык әсәрләрен берләштерә. һәм әйтергә кирәк, бу бергәлек, бу үзенчәлек язучының үз тормышы белән аерылгысыз бәйләнгән.

Халыкның төрле катламнарында, шул исәптән язучыларның үз араларында әхлаксызлык, карьерачылык, әдәби бизнес кебек ямьсез күренешләр көннән-көн ныграк тарала барган бу чорда язучының шәхси сыйфатларын искә алу бик кирәк һәм урынлы булыр дип уйлыйм.

1911 елның азагында Мордва АССРның Иске Аллагол авылында туган крестьян баласының үз авылында өч класс бетергәч үк урта мәктәптә укырга Мәскәүгә китүендә һәм әдәби түгәрәккә йөри башлавында ук инде белемгә омтылучы, максатчан характер ярылгыларын чамаларга мөмкин. Малайның Муса Җәлил түгәрәгенә туры килүен, һөнәр мәктәбендә укуын, заводларда слесарь һәм токарь булып эшләвен, аннары М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлавын, 1941 елда сугышка китүен язмыш кушуы дип тә, ихтыяр чагылышы дип тә исәпләргә була. Аның биографиясендәге бу хәлләр бөтен иҗат юнәлешен билгеләгәнен әйтергә кирәк. Нәкъ әсәрләрендәгечә: сугышта ул

башта Карелия фронтының дивизия бригадасы составында миномет расчеты командиры, ә 1943 елдан 1945 елның маена кадәр — фронт газетасы хезмәткәре. Шәхес һәм язучы завод цехларында һәм сугыш кырларында формалаша, сынала, ныгый бара.

Әпсәләмов — тормышның шундый кырыс мәктәбен узган кеше. Экстремаль шартларда тәрбияләнгән холык сыйфатларының иҗатка күчүен фаразлау бер дә кыен түгел. Аның сугыш вакытында һәм аннан соң язылган хикәяләре, повесть-романнары эчтәлекләре белән дә, вакыйгалар кискенлеге белән дә, характерлар көче ягыннан да, шулай ук хәрәкәт тизлеге һәм күләм җәһәтеннән авторның үз батырлыгының да ачык чагылышы иде.

Без белгән, әдәбиятта күп кенә еллар бергә эшләгән Әпсәләмов, кеше буларак, беркайчан да үзенең дәрәҗәсен төшермәде — зур һәм затлы шәхес булып калды. Бу сүзне мин һич тә аның СССР Югары Советы депутаты, РСФСР һәм ТАССР язучылар идарәсе члены булганлыгын, фронтта һәм әдәбияттагы хезмәтләре өчен Ленин ордены, Октябрь революциясе, Хезмәт Кызыл байрагы, Кызыл йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән булуын искә алып әйтүем түгел. Ә бигрәк тә аның үз карашларыннан, үз иманыннан, яшәү һәм язу принципларыннан беркайчан да чигенми яши алуын күздә тотып әйтәм.

Тыйнаклыгы аркасында башкаларны өйрәтү белән бик мавыкмаса да, язу мәсьәләсендә ул безгә кайбер киңәшләрен бирә иде. Шул исәптән мин аның кайбер киңәшләрен истә калдырдым. Бервакыт минем әсәрләр хакында чираттагы гаугә башлангач, ул шундый киңәш бирде: «Сине төрле якка тарткалыйлар, бирешмә, үзең булып кал, үзеңчә яз»,— диде. һәм «үзеңчә яз» дигәнне ике мәртәбә кабатлады. Тәнкыйтькә бирешергә ниятем булмаса да, аның киңәше күңел ныклыгы өчен, әлбәттә вакытлы һәм файдалы булгандыр дип беләм. Әдипнең үз тәҗрибәсеннән чыгып әйткән ихлас сүзләр күп кенә иҗатчылар өчен хәзер дә әһәмиятен җуймагандыр әле. Мөгаен шулайдыр.

Әпсәләмов шәхес буларак беркайчан да вакланмады — төркемнәргә кушылып, әдәби хәрәкәттә җайлы позицияләр алу өчен көрәшмәде, терсәкләр ярдәмендә алга чыгарга тырышмады. Үзен күтәрү өчен башкаларга комачау итмәде. Үз шөһрәте өчен калтырап яшәгән кайберәүләрдән аермалы буларак: «Мин генә чын прозаик, мин генә әдәбиятның төп көче, мин генә шәп шагыйрь, ә син — прозаик» дигәндәйрәк ыбыр-чыбыр бәхәсләрдән ул өстен булды. Дан һәм бүләкләр бүлешү, берсеннән-берсе юха мәкаләләр оештыру кебек маҗаралар аның өчен ят иде. Аңа булган ихтирам, тәкъдир итүләр бары тик башкарган хезмәтләре бәрабәренә килгән намуслы дәрәҗә билгеләре иде.

Һәркайсыбызга мәгълүм булганча, алтмышынчы еллар башында Габдрахман Әпсәләмов каты чирләп китте. Йөрәк авыруы, инфаркт... Мондый хәлдә язу түгел, әсәр хакында уйлану да зарарлы. Ә ул исә, шул авыр хәлдә һәм больница шартларында да эшен туктатмады — яңа роман өчен материал туплады. Тиз арада «Ак чәчәкләр» кебек зур күләмле әсәр басылып чыкты. Тагын да авыррак хәлдә «Яшел яр», «Күк күкрәр», «Агыла болыт» романнары барлыкка килде.

Бу кадәр эшләрне бары тик чын мәгънәсендә батыр холыклы кеше генә эшли ала. һәм Г. Әпсәләмовның сугыш кырларында да, хезмәт мәйданнарында да халкыбызның һәм аерым кешеләрнең тарихи батырлыклар күрсәтүен барлык әсәрләрендә, тупаем иҗатында беренче планга куеп сурәтләргә омтылуы шушы контекстта бик яхшы аңлашыла дип уйлыйм.

Әсәрләрдә тасвирланган батырлык үрнәкләре язучының үз тормышы һәм яшәү принциплары белән ныгытыла.

Заманның иң әһәмиятле күренешләрен сурәтләгән, үз өстенә иң катлаулы, авыр бурычларны ала килгән язучы олы иҗаты белән, югары әхлакый үрнәкләре белән бүгенге проблемаларның хәл ителешенә катнаша, алдагы максат һәм бурычларыбызны хәтергә төшереп тора.

Әхсән БАЯНОВ

# АНЫҢ ҖЫЛЫ КАРАШЫ

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ



**Сибгат Хәким... Бу әдипнең татар халкы һәм әдәбияты өчен нинди олы, кабатланмас шәхес булуы һәммәбезгә дә мәгълүм. Ул хакта безнең матбугатта шактый языла килә һәм әле киләчәктә дә күп язылыр. Ә без, шагыйрьнең туууына 80 ел тулу уңае белән, журналда аның хатларын бирергә булдык. Хатлар Әлмәттә яшәүче күренекле шагыйрь Гамил Афзалга язылганнар. Аларның барлык күләме 100 бит. Биредә укучыга арадан берничәсе генә тәкъдим ителә. Төрле елларда язылган булсалар да, алар Сибгат Хәкимнең олы җанлы һәм тынгысыз шәхесен бик тә дөрес чагылдыра, аның ягымлы килеш-кыяфәтен, киң күңелен күз алдында җанландыра. Гүяки без әле һаман аның җылы карашын тоябыз...**

Гамил дус!

Мин инде син бер дә хатларга җавап язмагач, әллә берәр нәрсә өчен үпкәләде микән, дип тора идем. Белмәссең кеше дигәнең, катлаулы, четерекле нәрсә бит ул.

Мин Ленинградта булып кайттым. Иң элек Тукайның русча томын «Библиотека поэта»га тапшырдым, кульязма, кереш сүз, аңлатмалары, хәтта Тукайның рәсемнәре белән. Кабул итеп алдылар. Ә 1961 елның башына чыгарырга вәгъдә иттеләр. Ә 1961 елның апрелендә Тукайга — 75 яшь. Өстән тау төшкәндәй булды. Икенче инде (Тукайдан башка) беркемне дә төзәмәскә сүз бирдем, эше күп, әҗере юк, бары да алла хакы өчен. Бу әле Тукайның мондый зур нәшриятта беренче чыгуы. Аннан 1912 елда май аенда Тукай Ленинградта 13 көн яшәгән, Плеханов урамында 5 нче йортта торган. Ленинград шәһәр Советы каршында эш кузгаттым: шул урамда татарның бөек шагыйренә мемориаль такта куйсыннар. Ул дуслык дип сөйләшүләрнең нәтиҗәсе булыр.

Инде үзем Ленинградны карадым, минем (сиңа гына әйтәм) оятыма каршы, анда әлегә тикле булганым юк иде. Ленинград — бөек шагыйрьләр шәһәре: Жуковский, Пушкин, Некрасов, Блок h. б. Ленинград — Бөек Октябрьнең үзәге. Анда адым саен музей, истәлек, һәйкәл... Буш вакыт булган саен музейларга чыктым да йөгердем. Эрмитаж, Смольный, Пушкин йортында булдым. Пушкин йорты күңелдә искиткеч зур тәэсир калдыра. Бу — Мойкадагы йорт, ягъни үләренә 4 ай кала урнашкан соңгы йорты. Дүрт көн буе шагыйрьләр дискуссиясендә алган тәэсир, шунда килгәч, бары да минуты белән юкка чыкты. Барысы өстеннән үз заманындагы шикелле хәзер дә югары күтәрелде, ул гына яшәп калды. Җитмәсә әле дискуссиядәге һәртөрле ваклыкларга ачуым килә башлады. Ун дискуссия урынына ходай шундыйрак бер шагыйрь бирсә ни булган?

Мондый хис миндә 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында бер туган иде инде. Декада вакытында мин Толстойның Ясная Полянасына бардым. Хәзер менә Декада узып киткәч, миндә Декададан нәрсә калды соң, дип уйландым. Нигәдер күңелдә ачык берни дә күренми. Ә Ясная Поляна һаман йөрәктә! Аннан мин зураеп, тазарып кайттым, бөтен ваклыкларга нәфрәтләнеп кайттым, күңелдә бары олы хис кенә яшәп калды. Менә нинди була икән ул зур сәнгать! Шуларны уйлыйм да үзебезнең хәлгә карап сыкранам.

Дискуссиядә күбрәк күп кычкырып, язып түгел, бугаз белән алдырырга теләүчеләр җыелган (Прокофьев, Тихонов, Берггольц, Решитов, Кайсын Кулиев кебек шагыйрьләрне алмаганда). Твардовский, Асеев, Исаковский, Щипачевлар бөтенләй килмәгән. Үзләрен менә бу әле саналган шагыйрьләргә каршы куялар. Аларның зур тираж белән таралуына, үзләренең тарала алмауларына гаҗәпләнәләр. Мәсәлән, Мих. Дудинның (арада ул иң көчлесе) Ленинградта яңа чыккан калын китабының тиражы — 3000. Лев Ошанин да күп дәгъва итә, ләкин сатылмый. Китаплары таралмавын книготоргтан гына күрә. Ә менә Есенин, Блок, Щипачев, Твардовский кебек шагыйрьләрне халык үзе эзли! Юк, дискуссиянең тоны миңа ошамады. Мин үз чиратым-

да чыгыш ясадым. «Сов. Татария»ның 17 январь санында басылды. Шагыйрь булып халыкның үзе белән бергә тумасаң, дискуссияләр генә аллә ни ярдәм итмәс, дигән караштa торам мин. Дискуссия: иң әйбәте — язарга кирәк, дигән акыллы сүз белән бетте.

Синең китабың чыккан диләр. Минем күргәнем юк әле. Тагын яңа әйбәт китабың белән котлыйм (мин бит эчтәлеген алдан беләм). Яңа шигырьләреңне укырмын.

Үзем языштырып ятам. Малайлар укый, Мәршидә эшли. Башка яңалыклар юк. Бөтен гаиләгезгә күп сәлам. Сибгат Хәким.

24/I-60.

Гамил!

Барыгызга да бездән күп сәлам. Хатыңны алдым, рәхмәт.

Бу хатта бераз зәвыклар (вкуслар) хакында сүз алып барасы килә. Моннан алдагы хатларыңның берендә син минем «Ленин фәрманы белән» дигән әсәремнең сиңа ошавы турында язган идең. Күп шагыйрьләр (әгәр алар ялганламаган булсалар) әйбәт фикердә иделәр. Мәсәлән, Салих Баттал, Әхмәт Юныс, Нәби Дәүли, прозаиклардан Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, М. Әмир һ. б. Минем үземә дә ул формасы белән, интонациясе белән эзләнеп язылган бер әсәрем кебек. Ә менә Ибраһимнар аны журналда басуга бөтенләй каршы иде. Кашшаф Гази да борын эченнән генә үзенең яратмавын лыгырдап йөри. Син менә яратмаган Давыдов поэмасын И. Гази күккә күтәреп мактый. Мин дә ул поэманы бик урта кул әсәрдән саныйм.

Инде 11 нче санда басылган минем шигырьләргә килсәк, бу шигырьләрне күпчелек иптәшләр бертавыштан диярлек яхшы каршыладылар. Еллык йомгакта да шулай телгә алынды. Ә алар сиңа ошамаганнар. Менә бит ул ничек зәвык дигәнең. Мин үзем кайсыларын яратам? «Әтнә урамында» (хәрби әсирләр турында), «Давыл чәчәкләре», «Мин шагыйрьне алып кайтам», «Башка берни дә кирәкми», «Күңелдә, күңелдә». Болардан элегрәк «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле шигырем чыккан иде. Әгәр укучының 100% да яхшы дип торса, ул билгеле начар булмас иде. Мин синең тәнкыйтьне кире кагар өчен әйтмим, үз колагым белән ишеткәннәрне генә сиңа җиткерәм. Мин алай үзем белән мавыгып яшәргә уйламыйм. Мин үз-үземнән бүтәннәр уйлаганнан да ризасызрак! Тәнкыйть үз вакытында фикерен әйтми. Минем 1958—59 елда шактый әйберләрем басылды. Мин бу елларны иң күп эшләгән елларымнан исәплим. «Ибраһим Йосфи», «Сары капкалы йорт», «Ленин фәрманы белән», «Сов. әд»ның № 8, 9, 11 саннарында басылган шигырьләр, җырлар һ. б. матбугатта алар турында бер авыз сүз булмады, бары да авызына су капкан. Менә шуннан вкусны аңла! Мин тәнкыйть булмаганга карап үземнең кыйбламны югалта торган шагыйрь түгел, ләкин шушы чаклы ваемсызлыкка ачу килә. Шуңа күрә мин хәзер кем вкусына ышанырга да белмим. Күбрәк үз вкусыма таянам.

Нәкый Исәнбәт юбилеена Мостай Кәрим килгән иде. Минем бер җыентыкны Башкортстан чыгарырга уйлый икән. Әзерләп бирдем, 3—4 табак чамасы. Исеме: «Давыл чәчәкләре». Төрле еллардан сайлап төзедем. Мостай үзе редакцияләргә сүз бирде. Хәерле булсын, чыгарсалар — рәхмәт, чыкмаса да үпкәм юк.

Казандагы бер 2—3 табаклы китабымның производствога төшүенә инде 7 ай, әле сигналы килгәне юк. Үлеп терелергә мөмкин. Мәскәүдәгесе төште, Ленин көннәренә чыгарырга уйлыйлар. Анысы сиңа ошар. Сүз башы да үземнеке... Бизәлеше матур диләр. Сиңа салырмын.

Ярый, хуш, дус кеше. Яза бир. Бөтен зур җыелышлар: язарга кирәк, дигән сүзләр белән бетә!

Сәлам белән Сибгат Хәким.

7 февраль 1960.

Гамил дус!

Хатың белән шигырең кулга-кул тотынышып килеп керделәр. Синең хәлне аңлыйм мин. Язучыларның йорты салына башлагач та, мин бит сиңа киңәшләремне әйткән идем. Афзал абый куркак булмаса, ул аны гына эшли ала иде. Батыйга барып ул турыда сөйләп тору нигә аңа кирәк булган. Ә Батыйның карашы сиңа карата аллә кайчаннан билгеле. Кыскасы, минем башыма суктылар, берсе дә мине куәтләп авыз ачмады. Конкрет эшкә килгәндә безнең агайне шулай ул. Менә ул йортны бүлделәр, аның тирәсендә Курск дугасындагы шикелле каты бәрелешләр барды. Хәер, әле тынганы юк. Ишморат, Зәки Нури, Дәүли, Мин Шабай, Илдар Юзиев һ. б. күчтеләр. Барлыгы 9 квартира бирделәр. Хәзер язучыларның хәле яхшырды, мохтаҗ кешеләр бөтенләй аз. Моннан соң урнаштыру җиңелрәк булачак. Син, дус кеше, өметеңне өзмә, сине барыбер яңа йорттан бер квартирага кертәбез. Бу турыда язга табарак тагын бер кузгатырбыз. Син инде авылда шактый яттың, тәҗрибәң, аллага шөкер, җитәрлек. Бераз сиңа киңрәк дөнья кирәк, таптана башладың. Фикер алышу өчен кешеләр булу — зур нәрсә ул. Хәзер сиңа шул җитми.

Узган язда синең әйберләрне бергә укый алмауга мин үзем дә үкенәм. Вакыты бик уңайсыз туры килде. Минем яңа операциядән чыккан чак, көн аралаш врачка күренергә йөрдем, ванна алдым. Синең шигырьләрне укуйсы көнне каты яңгыр булып, Лебяжьега кайта алмадым. Иртән инде син киткәнсең. Ярый, үткән эшкә салават. Әле алда эшләр күп, төзәтербез.

Тукай турында шигыреңне «Сов. әдәбияты»на бирәм. Анысын әллә ни үзгәртә алмассың, чөнки ул риторик планда алынган, шул рухта язылган. Бик әйбет строфалары бар. Бераз озын, кирәк урында туктый белергә кирәк.

«...Бер укысаң...» дип башланган юлдан ахырына хәтле кирәкми. Бик гомуми һәм фикерләрең дә буталчык.

*Без, татарлар, юл буенда юлсыз идек,*
*Башын игән, куңеле көйгән, моңсыз идек.*

Бу юлларны укыгач М. Садриның татар халкы язмышы турында язылган бер шигыре искә төшә. Анда шундый юллар бар:

*...Мин бәхетсез татар идем,*
*Балыкларга азык булып ятар идем...*

Мәнә шушылай мескенләндерүне яратмыйм мин. Мескен түгел ул. Бу аны артык кимсетә, түбәнсетә. Үзенең кулыннан берни килми дигән шикелле. Тарихы зур, зур юл үткән, хезмәтчел, батыр һәм зур культуралы халыкны андый хәлгә куймыйк.

Тукайларда милли горурлык хисе көчле! «Моңсыз идек...» Ник моңсыз? Татар халкының моңы кая киткән? Кайда монда логика? Тукай ул үзе моңны татар халкыннан ала. «Халык әдәбияты» исемле лекциясен укы. Ярлы идек, хаксыз идек, телсез идек... Теле кая киткән? Син бәлки, дәшәргә хакы юк, дигән мәгънәдә әйтергә телисеңдер. Алай да дөрес түгел. Бик телле-тешле булган!

*Ял иткәндә ятып укыйм кичтән сине,*
*Тору белән тотып укыйм иртән сине.*
*Ак кәгазьдәй намусыма судья итеп,*
*Гомер буе йөрәгемдә,йөртәм сине.*

Мәнә бу инде шигырь, синең куңелең тапкан шигырь фикере дә зур: намуска судья! Ул сиңа гына судья түгел, безнең барыбызга да. Бу дүрт юлыннан яңа шигырь башланса, мәнә дигән нәрсә туар иде. Тегеләре инде язылган, кыскартып, үзе бер шигырь булып калыр. Әле вакыт бар. Февраль урталарына җибәрсәң ярый.

Үзем ике ай баш күтәрми, Тукай турында — шагыйрь һәм кеше турында мәкалә яздым. Русчасын «Октябрь»га җибәрдем, алар заказ биргән иде. Татарчасын «Сов. әд.»на бирәм. Сиңа укыйсы килә, син ерак. Мондагы иптәшләр бик яратты. Күптән язасы килә иде...

Мәнә, хәзергә шул. Сәлам барыгызга да.

Сибгат Хәким. 26/1-61.

Гамил дус!

Гадәт буенча быел мин тагын авырдым. Бу юлы — тамак. Бугаздан борчак кадәр шеш (киста) таптылар, бер ай буе аның белән азапланып йөрдем, аннан аны ярдылар. Кыскасы, тамакка тыгылды, начар шигырьләрем килеп тыгылды булса кирәк. Хәзер кәеф бераз рәтләнде инде. Сиңа хатны озак язмадым, бер сәбәбе шушы.

25—26 апрельдә Казанда Тукайның 75 еллыгы үткәрелде. Кунаклар чакырмадылар. 75 еллык закон буенча юбилей даталарына керми, (80 ел керә), шуңа хөкүмәт акча да бирми икән. Хәерле булсын. 80 еллыгына да күп калмады, 5 кенә ел. Монысы, әйдә репетициягә исәпләнсен.Әйбәт узды, опера театрында. Мин бер чыгыш та ясадым. Син Казанга май аенда килә идең, быел ният ничек?

Минем сиңа бер үтенеч бар. Мин берәр елдан үземнең мәкаләләр җыентыгымны бирергә уйлыйм, нәшрият үзе сорый. Иптәшләр дә әйткәлиләр. Моннан бер ел элек синең иҗатың турында мин мәкалә язган идем. Аның тулы оригиналы үземдә саклана. Мин инде азмы-күпме беләм, фикерләрем бар. Ул мәкаләне яңадан бер карап чыгарга исәп. Син миңа тулырак бер тәрҗемә итәлгән хәлеңне язып җибәр әле. Мәкаләдә кайбер детальләре кирәк була аның. Ясамыйча яз.

Инде «Кояш иле» балладасы турында. Сиңа нигәдер мондый характердагы әйберләр бик үк бирелмиләр. Сәбәбе: син конкрет деталь аша, үзең кичергән, уй хисләрдә-лирикада ачыласың. Синең анда шигырең уйный, яктыра, тыгыз ул, бер бөтен. Аерым интонацион моментларга бай. Шулар барысы шигырьне шигырь ясый. Ә бу легендада алар югалган: таркау абстракт, описаниега корылган (описание, гомумән, шигырьнең дошманы). Описаниега керсә, хәттә Тукай кадәр Тукай да батып калган. Мәсәлән, «Кечкенә генә көйле бер хикәя»дә Тукай кинәт авырая.

сүлпәнләнә... Ул басылмаслык әйбер түгел, бездә аннан күп йомшак әйберләр дә басыла. Синең шагыйрьлек көчең монда түгел. Үзең еллар буена тырышып, эзләп тапканны җуймаска кирәк. «Совет әдәбияты»на килгән соңгы шигырьләрдә дә описаниега бирелү бик нык сизелә. Описание ул шигырьнең ялкыны хисабына эшләнә. Мин аңа каршы. Андый чакта туктап тор, укы, эзлән, чыгып кит, йөр. Ләкин ансат юлга, шигырь юлларын ансат кына арттыру юлына басмаска кирәк.

Синең хәзер берничә китабың татарча чыкты. Берсе — русча. Халыкта исемең бар. Синең хәзер чыккалап йөрергә материаль мөмкинлегең дә бар. Сәламәтлегең дә элеккедән күп яхшы. Быел җәйне ничек файдалану (иҗат өчен) турында уйлан. Киңәш сиңа шул.

Тукайга багышланган шигырең «Сов. Татария»дә чыкты. Кузнецов тәрҗемә иткән.

Барыгызны да Беренче май белән котлыйбыз, сәламәтлек теләп калабыз. Сәлам белән Сибгат Хәким.

29 май, 1961.

Гамил!

Открытка да килде синнән, шигырь дә. Котлауларыгыз өчен рәхмәт. Вакытында җавап бирә алмадым, йөреп уза вакыт. Әле менә Мәскәүдә рус совет поэзиясе буенча сөйләшү булып узды. Рус поэзиясе секциясе киңәйтелгән утырышын оештырган, мин дә чыгыш ясадым, татар шагыйрьләре русның Твардовский кебек олы җанлы, зур хакыйкатьне халыкчан ачып сала торган талантлары белән горурлануы турында, гомумән Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Блок, Маяковский, Есенин, Твардовский, Исаковский кебек кешеләре турында үз фикерләрем белән чыгыш ясадым. Хәзер поэзияне чүп-чар басып китте. Мәскәүдә дә бик борчылалар. Тәрҗемә әдәбият буенча да кызык фикерләр әйттеләр. Мәсәлән, Расул үз телендә 20 тапкыр, рус телендә 70 тән артык китап чыгарган. Юван Шесталов үз телендә — 4, рус телендә — 20 һ. б. Э Леонид Мартынов үз телендә 20, Заболоцкий кебек талант — 4. Хәсән Туфан үз телендә — 4, русча — 2, Зәки Нури бер елда рус телендә — 4...

Кыскасы, Мәскәү китап кибетләрендә, урта кул оригинал шигырьләр җыентыклары белән бергә, милли телләрдән тәрҗемә ителгән җыентыклар да тулып ята, сатылмый. Пушкиннар, Блоклар поэзиясенең дәрәҗәсе бик нык төште. Эте-бете тәрҗемә иттерергә тырыша. Тәрҗемә итеп чыгару өчен әле шагыйрьнең еллар буе җыйган запасы, сыналган шигырьләре, шулардан курыкмый сайлап алырлык һәм зур дөньяга курыкмый чыгарырлык шигырьләре булырга тиеш. Күп сүз булды... Хатта сөйләп бетерерлек түгел. Синең «Икенче ватан» исемле шигыреңә Галиябану кул куйган бит, тагын нәрсә кирәк! Миңа аның 3 бүлеге ошады, шул ил-ватан турындагы шигырь үзе күп нәрсә турында сөйли, үзе аерым шигырь. Лирик шигырь. Тукайның «Туган җиремә» рухындагы шигырь. «Чаян» шигыре түгел. 3 бүлекнең беренче юлындагы «ялтыра» гына икенче мәгънә бирә, башка сүз сорый ул юл... Нигә ул бүлек дисәң, үзең яшәгән җир турында хисләр дә табигый чыга, нәрсәседер шуның ышандыра... Гомумән, билгеле бөтен килеш тә басып була, бернинди зарары юк, бар да дөрес. Тик кайсы шигырь дисәләр, мин 3 бүлеккә төртеп күрсәтер идем. Ярый, бу минем субъектив фикерем генә.

Әллә ни кырган юк. Минем яшьтә иң әйбәте — кешегә акыл өйрәтеп, хат язып яту.

Барыгызга да күп сәлам белән Сибгат Хәким.

9/I-74.

Гамил!

Хатың килде. Әхәт Гаффарга әйт, Сибгат абый язган язманы күрсәт, диген. Мин аларның минем исемнән сөйләп йөргәннәрен беләм, шуңа күрә хәзер фикеремне язып бирәм. Тукай турында алай җиңел генә яхшы әсәр язып булмый. Әсәрнең кимчелеге шунда: Тукайны Такташ, Җәлил, Туфаннар белән сөйләштерә. Тагын шундый якынайтып булмый торган аралар бар, ясый, ышану читен. Шуларны һәм башка кимчелекләрне әйттем язмада. Китабына кереш булыр дип уйлаган ул. Бу кимчелекләрне күрсәткәч, туктап калды. Менә шул. Тукай җитди булуны таләп итә.

Инде син аңлап бетермәгән Тукайның дүрт юлы турында.

*Аз шул бездә байлар, кайсысы кем*
*Фәрештәдән канат каермас;*
*Алсын гына шайтан иманыңны,*
*Җәһәннәмлек бу дип кайгырмас!*

Хикмәт бары әйтелеш формасында гына. Тукай халыктан ишетелгәнчә язарга ярата. Бөтенесен чәйнәп салмый. Мәсәлән:

*Җиктереп пар аттан,*
*Йорт салып нараттан.*

Без булсак әле ул мужикны башта урманга җибәрер идек, наратны кистерер идек, урманнан алып кайтыр идек, аннан гына йорт салырга керешер идек. Ә ул боларның барысын да төшереп калдыра да, йорт сала. Барыбер аңлашыла. Шигырь — кызык форма. Хәзерге рус шагыйрьләре Лермонтов шигырьләренең грамматик яктан бик үк дөрес түгеллегенә игътибар итәләр. Ә укыганда шулар сизелми, эчке ташкын оныттыра. Тукай да бу урында прозалаштырмый. Без хәзер, фәрештәнең канатын каеручы байлар азмыни, дияр идек. Аларның иманын шайтан алсын, алар җәһәннәмлек дип кайгырмас. Менә шигырь бетте. Тукай дүрт юлын эчке бер сизенү белән аңлый идем, хәзер үзем дә буталдым бугай, шигырь өчен «сизенү» сүзе әйбәт. Кайвакыт шул бер сүз җитә — «сизенү». Анализлый барырга гына мөмкин...

Оныкларың белән котлыйм. Үзең бер кара малай үстерә алмадың. Алмашка бер шагыйрь. Кызларыңа рәхмәт әйт.

Барыгызга да сәлам белән Сибгат Хәким.

2 май, 1986.

## ИГЪТИБАР!

Танылган татар язучысы МИРГАЗИЯН ЮНЫС:

*«Күрше ике милләт. Хәтта күрше генә дә түгел. Татарларның дүрттән өч өлеше — урыс арасында...»*

*«Милли гауганы җиңү чарасы: хакыйкать һәм шәфкать...»*

*«Милли азатлык көрәшенә чыккан туганнарыма мөрәҗәгать итеп, менә нәрсә үтенәм мин. Иң беренче, урыс халкына тел тидермәскә... Милли азатлыкның төп дошманнары — бюрократия, шовинистлар, карагруһлар. Алар арасында татарлар да җитәрлек...»*

Миргазиян Юнысның әнә шундый бәхәсле-каршылыклы фикерләр белән сугарылган «Шәфкать кыйбласы» исемле кызыклы мәкаләсен сез «Казан утлары»ның — 1992 елгы беренче саныннан укый аласыз.

Ашыгыгыз! Ашыгыгыз! Ашыгыгыз!

# ӨЛКӘН ДУС — ЯХШЫ КЕШЕ ТУРЫНДА

Шагыйрь Зәки Нуриға 70 яшь



Өлкән каләмдәш, сиңа чын киңәшче ага кеше булган шагыйрь, күпне күргән, кичергән, бу кырыс, дуамал гасырның житмеш елын исән-аман кичкән бәхетле ир-егет, олпат ил агасы турында безнең көннәрдә нәрсәдер язу жиңелме? Әйе, нәкъ менә бүген, доньяда, илдә — элек күз алдына да китереп, уйлап та булмас үзгәрешләр, еллар, айларда түгел, ә көннәр эчендә үк пәйда булып, сискәндереп, үзләрен кабул итәргә мәжбүр итеп, өйрәнергә кушып, сине дә бөтереп алганда?! Күп кыйммәтләр, бәяләр алмашынып, үзгәрешсез дип уйланган чынлыклар, идеаллар, шәхесләр күз алдында юкка чыгып, гүя мәңге булмагандай аннан ераклашканда?! Өлкән буыннар мирасыннан, алар инанган, табынган чынлыктан, ниһаять, алар варисы — бездән ни калыр?

Ә бит безнең күз алдыбызда гына күпме язмышлар, шәхесләр узды, доньядан ук кичте инде — бүгенге аяусыз, кырыс чынбарлык фильтры аша узганда тарихка алардан ни кала? Ә чын шагыйрьләр, шәхесләр заманга карап үзгәрәме? Кемнәр чорыбыз жинаятьләре өчен үзен бөтенләй үк «гаепсез» саный? Кайда алиби?

— Кемнең бөртек тә гонаһы юк, шул иң беренче булып таш атсын сез гонаһлы дип санаган бу хатынга! — дип әйткән Гайсә пәйгамбәр. Һәм усал кешеләр, үз-үзләреннән оялып, кулларыннан ташны жиргә ташлаганнар. Бу Инжил риваяте. Ә бүген? Үзен абсолют гонаһсыз дип санаучылар юктыр дисезме?

Ай-һай! Мондый ышаныч үзе үк бездәге иң зур икейөзлелек күренеше булыр иде.

Ә минем сүзем — Кеше турында, шагыйрь турында. Яхшы кеше дип барчабыз тарафыннан танылган, колоритлы, һичкем белән бутап булмый торган бай шәхес — Зәки ага Нури турында...

Казаннан читкә китеп, кем белән генә очрашсаң да, синең каян икәнеңне белгәч, әңгәмәдәшең — Уфаданмы ул, белорусмы, якутмы, калмыкмы — әлбәттә, Зәки ага турында сораша, сәлам әйтә башлый:

— Зәки партизан ни хәлдә анда?

— Зәки дустыбыз исән-иминме?Ниләр яза?

— Һаман шулай жор сүзле, шук-шаянмы Зәки Нури?

Сәлам әйтүчеләр, күбесенчә, аның чордашлары, кордашлары, үз буыны кешеләре — утны, суны кичкән, күпне күргән, белгән... белдем дигәч тә, ахыр бик күпне белмәвен дә аңлый барган буын. Каршылыклы хисләр эчендә калган буын. Яугирләр, фронтташлар, партизаннар, элекке укытучылар, озын гомерле шагыйрьләр... Алар һәр халыктан үз фикердәшләрен күрә белә, эзли, табыша, аралаша... Бергәләп бу каһәрле язмыш сорауларына жавап эзли, нык булырга тырыша... Әнә шуңа күрә дә калку, матур сыйфатлар тарта да аларны: шаянлык, жорлык, сер бирмәүче горурлык, олпатлылык — кыскасы, егетлек, ирлек сыйфатлары... Һәм безнең буын шагыйрьләре З. Нурины белеп, ышанып әйтә ала торган андагы асыл сыйфатларның берсе — кешелеклелек... Менә шуңа күрә шагыйрьгә багышланган мәкалә исемнәре дә үзенчәлекле яңгырый: «Зәки елмаюы», «Партизан пилоткасындагы шигърият», «Имәнлектән (димәк, ныклыктан! Р. Г.) башланган юл»... Болар барысы да шагыйрьнең кешечә матур сыйфатларына ишарәли!

Һәм без, илле яшьлекләр, инде моның шаһиты буларак та сөйли алабыз...

Мин житмеш яшьлек егет Кеше турында уйлыйм... Татарстанның Чүпрәле районы Татар Төкесе авылында туган ул. Жидееллык мәктәпне, аннан Лубян урман техникумын тәмамлагач, Ерак Көнчыгышта төзелештә, Чувашстанда урман хужалыгында эшләгән. Әйе, ул — урманчы... Шуңа да язмышы аны сугыш елларында да урман белән бәйли: чолганышка эләгеп, дошман тылында калгач, ул — Белоруссиядә, К. Заслонов житәкчелегендәге партизан отрядында... Разведка отряды командиры. Орша шәһәре советында башкарма комитет председателе булып эшли. Соңыннан ул — шул шәһәрнең почетлы гражданы... Ватан сугышы ордены, медальләр кавалеры... Сугыштан соң — янә урманчы, ул чактагы «Яшь сталинчы» газетасы редакторы урынбасары, Татарстан китап нәшриятының редакция мөдире, озак еллар (1957—1967) Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре, аннан — председателе (1971—1974 еллар), озак вакыт (1968—1971, 1974—1982 еллар) — «Казан утлары» журналының баш редакторы... Менә шундый кыскача тормыш юлы битләре... Кыскача... Тулысы, бәлки, ижаттадыр... Сугышка кадәр үк яза башлаган Зәки Нури 1945 елда беренче китабын чыгара. Аннары — лирика, публицистика, балалар өчен шигырьләр, юмор-сатира китаплары.

Татар телендә — кырыктан артык, русча — егермегә якын, башка телләрдә — алты, җәмгысе — алтмыштан артык китап авторы ул. Бу — бер зур тау кебек. Шуның иң калку булып торганы — «Күңел яктысы» исемле күләмле китап, «Шигырь китапханәсе» сериясендә дөнья күргән. «Үлгәннәр дә үч алды» кебек проза китабы да бар, очерк-публицистика китаплары да... Ә күпме тәрҗемәләр! Твардовскийдан, Щипачевтан, Я. Коластан... Тугандаш халыклар шигъриятеннән махсус серия рәвешендә үзе төзеп, тәрҗемә иткән китапчыклар.

...Дөнья һәм илебез халыкларының фольклор әсәрләрен (мәзәкләр, мәкаль-әйтемнәр) эченә алган «Күңелле китап» (1969, 1979), «Алтын хәзинә» (1973) кебекләр дә З. Нури иҗатының матур битләре. Аның үзе үстергән урманы...

Өч тапкыр шәһәр советы (1961, 1968, 1979), ике тапкыр (1967, 1971) Татарстан Югары советы депутаты булганын, 1971 елда «Почет билгесе», 1981 елда Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнгәнен дә искә алыйк. Бу фактлар да нәкъ менә З. Нури буынының пөхтәлекуңганлыгы, дансөярлеге, фидакарьлеге, хәтта ки эш аты дәрәҗәсендәге күндәмлеген раслый бит. Бүләкләр дә — шундый гомер, иҗат, хезмәт өчен бәя атрибутлары. Әйе, дәүләт, хөкүмәт бүләкләре... Әлбәттә, чын бәяне вакыт, халык үзе бирер. Әмма егет кешенең ялалары да, башка бизәкләре дә була. Карт гомер агачында да киртләр күп бит.

Ә гомер юлына ышаныч сүрелмәгән бу буында. Шагыйрь үзе дә болай дип белдерә:

*Йөрәк икән — яратмыйча тилмәс,*
*Көрәш икән — җиңми калмабыз.*
*Гомер икән — бушка янып үтмәс,*
*Ә ил кушса — куркып янмабыз.*

Әйе, ил кушса... фәрман көтү, үтәргә, яу-көрәшкә әзер булу сыйфаты хас бу буын өчен! Бирелгәнлек, антка тугрылык, солдат-яугир характеры тәрбияләгән аны...

Бу буын вәкилләре үзләренә әллә нинди дәгъвалар белән дә аерылмый шикелле... Яхшы хәлме бу? Белмим, әмма тыйнаклык, үз урыныңны, дәрәҗәңне белү дә әйбәт бит. Бу да егетлекнең бер ягы. Әнә шуңа күрә дә «түрә»лекнең югары басмаларында да Зәки ага кечелеклелек, кешелеклелек сыйфатларын югалтмады шикелле. Дуслары күп булды,— әле дә бар. Ил агасы була белү — үзе үк бәхетле язмыш. Моңа сирәк кешеләр генә ирешә. Зәки ага монда да үзе булып калды: үз манерасында, стилендә язмаган яки таланты зуррак булган каләмдәшләреннән дә көнләшү, үч-мәкер пәрәвезе кору, яки үз-үзен «ашау», хөсетлек — берсе дә аңарда юк. Шуңа да каләмдәшләре аның кешелеклелек сыйфатлары өчен аеруча ихтирам иттеләр, яраттылар шикелле.

Яхшылык җирдә ятмас, дигәннәр. Кешеләргә ярдәмле, мәрхәмәтле булу, олы мәхәббәт белән яшәү — үзе үк зур батырлык, сирәк талант. Шушы, нәкъ «урманчы» таланты өчен дә Зәки ага онытылмаска хаклыдыр... Хәер, кем белә бит: бәлки, әнә шушы талант — кешеләргә, халкыңа мәхәббәт — иң кирәклесе, аңлаешлысы һәм мәңгегә калачагыдыр? Бәлки, әнә шул кешелеклелек бигрәк тә кадерледер безгә Зәки агада? Һәм без, бүгенге илле яшьлекләр буыны, үз урманыбыз шушы кешелеклелек, үрнәк олпатлык, егетлек китергән шифа-бәрәкәт белән сугарылып, өлкән дустан көч, ярдәм алмаганбыз дип әйтә алабызмы? Һич юк.

Рәхмәт хисе дә бар бит ул шагыйрьләрдә!

Рәдиф ГАТАШ.

# АНГЛИЯ ЖУРНАЛЫ ТАТАРЛАР ТУРЫНДА

Англиянең Оксфорд шәһәрендә «Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте» эшли. Хәзер бу җәмгыять белән татарлар арасындагы милли хәрәкәтне һәм иҗтимагый фикерне өйрәнүгә багышланган күп санлы хезмәтләр авторы, күренекле галим А. Беннигсеннең (1913—1988) кызы Мари Броуксоп җитәкчелек итә. 1981 елдан бирле җәмгыять инглиз телендә «Үзәк Азияне күзәтү» исеме астында журнал чыгарып килә. Аны исеме телгә алынган Мари Броуксоп һәм Каролина Грай редакцияли. Журнал битләрендә Урта Азиядә, аңа чиктәш төбәкләрдә яшәүче халыкларның, беренче чиратта төрки халыкларның тарихына, мәдәниятенә, бүгенге көнкүрешенә, алар арасындагы иҗтимагый хәрәкәтләргә кагылышлы мәкаләләр басылып килә.

Журналның 1990 елны чыккан икенче саны тулысынча татарларга багышланган иде. Анда урнаштырылган мәкаләләрнең бер өлешендә халкыбызның тарихында һәм мәдәниятендә исламның роле яктыртыла. Журнал битләрендә шулай ук татар халкының үткәне һәм татарлар арасындагы милли хәрәкәтләр үзенең чагылышын тапкан. Шулай ук халкыбыз тарихында күренекле роль уйнаган шәхесләрнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктыртучы мәкаләләр дә журналда күренекле урын алып торалар. Журналның ахыр битләре исә хроникага һәм китап күзәтүгә бирелгән.

Идел болгарларының исламны кабул итүләренә багышланган тантаналар үткән көннәрдә журнал редакторларыннан берсе Мари Броуксоп Казанда булып киткән иде. Журналның беренче битләре шул тантаналарның аерым сәхифәләрен сурәтләүче фоторәсемнәр белән ачыла. Журналда урнаштырылган беренче мәкалә — философия фәннәре докторы, профессор Я. Г. Абдуллинның «Идел-Кама болгарлары һәм татарлар тарихында ислам» дигән язмасы да — шул вакыйгага багышланган. 922 елда Багдад илчелеген кабул итү көннәрендә ислам Идел-Кама Болгарстанының рәсми дине дип игълан ителә. Ә болгарлар арасына ул инде IX гасыр башларында ук үтеп керә башлый. Бу фикерне автор Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында китерелгән мәгълүматларга, археология истәлекләренә таянып дәлилли һәм болгарларның исламны берниндн көчләүсез, үз ирекләре белән кабул итүләрен күрсәтеп үтә.

Мәкалә, башлыча, исламның болгар-татар тарихында һәм мәдәниятендә тоткан урынын ачып салуга багышланган. Автор исламның тарихыбызда хәлиткеч ролен беренче чиратта Идел Болгарстанының дәүләт булып формалашуында һәм бердәм болгар халкы оешуында күрә. «Ислам,— дип яза ул,— оешып килүче Болгар дәүләтенең идеологик һәм хокукый нигезен тәшкил итте, Идел-Кама болгарларының һәм аларга кардәш башка төрки кабиләләрнең бердәм болгар халкы булып укмашуында идеологик алшарт булды».

Мәкаләдә исламның болгар-татар мәдәнияте формалашуында һәм аның үсешендәге ролен характерлауга да зур урын бирелгән. Исламны кабул итү болгарларга ул вакытта дөньякүләм алдынгы урынны алып торган гарәп мәдәниятенә якынаерга юл ачты. Шушы җирлектә Идел Болгарстанында язма мәдәният барлыкка килде, мәктәпләр ачылды, мәгърифәт чәчәк атты, фән үсте, фәлсәфи һәм әдәби әсәрләр языдды, галимнәр, әдипләр һәм шагыйрьләр иҗат иттеләр. Ислам мәдәнияте аерылгысыз рәвештә шәһәрләр тормышы белән бәйләнгән. Бу Идел Болгарстаны тарихында да үзен сиздерде. Моның шулай икәнен археологик эзләнүләр нәтиҗәсендә табылгын 150 дән артык болгар шәһәре калдыклары ачык күрсәтеп тора. Бу шәһәрләрдә һөнәрчелек һәм сәүдә үсте, мәһабәт биналар калкып чыкты. Нигезе Болгар чорында салынган әлеге мәдәният Казан ханлыгы чорында да үзенең үсешен дәвам иттерде. Бу бигрәк тә ислам традицияләре белән бәйләнгән мәктәп-мәдрәсәләр эшендә, китап таралуда, әдәбиятта, һөнәрчелектә һәм төзелеш сәнгатендә, кабер ташларында ачык чагылды. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң да татар халкы мәдәният өлкәсендә урнашкан шушы традицияләргә тугрылыклы булып калды.

Идел-Кама болгарлары һәм аларның варислары татарлар катлаулы тарихи юл үттеләр. Алар җиренә яулар ябырылды, аларның шәһәр һәм авылларын таптап илбасарлар узды. Шуңа карамастан, башта болгарлар һәм соңыннан аларның токымы татарлар халык буларак

үзләрен саклап кала алдылар һәм монда исламның роле хәлиткеч булды, дип басым ясап күрсәтә автор. Монгол яулары болгар җиренә зур һәлакәтләр китерде. Шулай да болгар халкы үзенең исламга нигезләнгән мәдәнияте үзенчәлекләрен саклап кала алды, илбасарлар тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән булса да, үзенең дәүләтен торгызды, яңа җирләр үзләштерде, шәһәрләр салды, һөнәрчелек, игенчелек һәм сәүдәне үстерде. Алтын Урда мәдәнияте формалашуда да, анда шәһәрләр барлыкка килүдә дә, һөнәрчелек таралуында да, ахыр чиктә аның халкының мөселманлашуында да болгарларның роле гаять зур булды.

Иван IV яулары болгарларның дәвамы булган татарларны яңа авыр сынаулар алдына куйды. Урта Идел буйларына үтеп кергән баскыннар Казан ханлыгын җимерделәр, андагы шәһәрләрне җир белән тигезләделәр, халкын канга батырдылар. Бу яулар үткән җирләрдә мәдәният учаклары сүнде, исән калганнар үз илендә качак тормышына дучар ителделәр. Һәртөрле чаралар ярдәмендә аларны көчләп чукындыру эше җәелдерелде. «Шушы социаль-экономик һәм милли кысрыклауларга, сәяси-хокукый эзәрлекләүләргә, ачыктан-ачык үткәрелгән урыслаштыру сәясәтенә карамастан,— дип күрсәтелә мәкаләдә,— татар халкы үзен саклап кала алды, үзенең милли үзенчәлекләреннән, мәдәниятеннән һәм традицияләреннән аерылмады. Бу очракта да инде милли аңның аерылгысыз өлешенә, милли үзенчәлекләрне саклауда идеологик таянычка әйләнгән ислам хәлиткеч роль уйнады».

Автор шулай ук исламның болгар-татарлар тарихында әхлакый кануннар формалашуында һәм үсешендә мөһим роль уйнавына да туктала. Бу тема философия фәннәре кандидаты Р. М. Әмирхановның «Ислам һәм татар социаль-этик фикеренең үсеше» дип исемләнгән мәкаләсендә алга таба үстерелә һәм һәр яктан тәфсилләп анализлана. Исламны кабул итү, дип яза Р. М. Әмирханов, халкыбызның язмышында яңа юллар сызды, дөньяны аңлауда аны яңача фикерләүгә китерде, аның рухи тормышын яңа идеологик агымнар белән бәйләде, гомумкешелек гуманистик принципларыннан булган гадәләт, мөсават, мәрхәмәт, шәфкать идеяләрен аның иҗтимагый аңының аерылгысыз өлешенә әйләндерде.

Мәкаләдә татарлар арасында исламга нигезләнгән социаль-этик фикер үсешенең хосусиятләре мәсьәләсе төп урынны алып тора. Бу үсештә башлыча ике юнәлеш игътибарга лаеклы, дип күрсәтә автор. Аларның беренчесендә дөньяви проблемалар өстенлек итә һәм ул рационалистик фикерләүгә нигезләнгән, ә икенчесе суфичылык һәм заһидлык белән бәйләнгән һәм аңа мистик тенденцияләр хас. Бу юнәлешләрнең икесе дә исламның этик тәгълиматына нигезләнгән булсалар да, фикерләүдә аларның беренчесе Әл-Фараби һәм Ибн Сина кебек хәкимнәрнең рационалистик философиясенә, ә икенчесе суфичылыкның әлгәрләреннән булган Бистами, Җүнәйдә һәм Хәллаҗлар тәгълиматына барып тоташа. Иҗтимагый фикеребез тарихында беренче юнәлешкә хас төсмерләрне без Кол Гали, Котби, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр иҗатында, ә икенче юнәлешкә хас төсмерләрне Мәхмүт Болгари, Хисам Кәтиб, Мәүлә Колый иҗатында күрәбез. Бу проблеманы һәрьяклап тикшергәннән соң, автор «Социаль-этик фикердә дөньяви юнәлеш җәмгыять, дәүләт иминлектә яшәгән чорларда һәм үсеш процессы кичергәндә яки аларга тышкы куркыныч янаганда, дәһшәтле вакыйгалар барганда ачыграк чагылыш. Чөнки мондый вакыйгалар иҗтимагый фикерне гомумхалык, дәүләт мәнфәгатьләре даирәсенә туплый, иҗтимагый көчләрнең һәм шәхеснең иҗади потенциалын активлаштыра. Җәмгыять кризис кичергәндә, аның тормышында таркалу күренешләре туганда, ил-халык үзенең бәйсезлеген югалткан вакытларда исә суфичылыкка хас әхлакый фикер өстенлек ала. Чөнки социаль тормышта туган кыенлыклар кешенең табигатендә яткан рухи һәм әхлакый сыйфатларга, изгелек, мәхәббәт һәм теләктәшлек хисләренә таянып яшәешне саклап калу ихтыяҗы тудыра»,— дип яза.

Шушы уңайдан автор суфичылык, заһидчылык идеяләренең татарлар арасында Казан ханлыгы урыслар тарафыннан яулап алынып, милли мөстәкыйльлек җуелгач, патша хөкүмәтенең мөселманнарга каршы көчләп христианлаштыру үткәрүе шартларында тирәнрәк тамыр җибәрүен күрсәтеп үтә. Ә XVIII гасырның азакларында, иҗтимагый тормышның җанлануы һәм милли яңарышка ышаныч арту шартларында исә этик фикердә дөньяви мотивлар өстенлек итә башлый, бөтен кискенлеге белән социаль үсеш мәсьәләләре алгы планга куела. Бу Т. Ялчыгол, Г. Утыз Имәни (әл-Болгари), Г. Курсави иҗатында үзенең ачык чагылышын тапты, ә Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри һәм Ш. Күлтәси әсәрләрендә исә бөтен кискенлеге белән куелды.

XX гасыр башларында, җәмгыять революцион тетрәнүләр кичергән чорда, этик фикердә революцион-демократик тенденцияләр һәм социализм идеяләре үзләренең тәэсирен сиздерә башлый. Шул ук вакыт, дип күрсәтә автор, социализм турында сүз алып барганда алдынгы фикер ияләре аның тормышка ашырылуын ислам нигезендә яткан гаделлек, тигезлек, теләктәшлек, шәфкатьлек идеяләре белән бәйлиләр. Бу исә сүз барган чордагы татар этик фикерендә милли традицияләрнең конбатышта туган революцион теорияләр белән үрелеп үсә башлавын, иҗтимагый фикергә этик социализм идеяләренең үтеп керүен күрсәтә.

Журналда урнаштырылган мәкаләләрнең икенче бер төркемендә татар халкының үткәне яктыртыла. Болар арасыннан Америка Кушма Штатларындагы Висконсин-мэдисон университеты профессоры ассистенты Юлай Шамил углының «Татарларда тарихи аңның үсеше: Шиһабетдин Мәрҗани һәм Алтын Урданың йөзе» дигән күләмле мәкаләсен күрсәтеп үтәргә кирәк. Мәкаләнең башында ук автор татарлар арасында тарихи аңның формалашу һәм үсүендә, шулай ук татар халкының фәнни тарихын тудыруда Шиһабетдин Мәрҗани уйнаган рольне күрсәтеп үтә. Мәкаләдә болгар, мөселман, татар, казан татары этнонимнарына тәнкыйди анализ ясала. Автор шулай ук, үзенең шәхси позицияләреннән чыгып, халкыбызның

үткәне турында сүз алып бара һәм шул уңайдан «Ислам урта гасырда яшәгән болгарлар белән хәзерге Казан татарларын тоташтыручы фактор булды» дигән фикер әйтеп үтә.

Майами университетыннан (Америка Кушма Штатлары) профессор ассистенты Жанет Мартын үзенең «Новгородта чукындырылган гаиләләр: 16 гасырда ассимиляция» дигән мәкаләсендә патша хөкүмәтенең төрле сәбәпләр аркасында Мәскәү жиренә килеп чыккан татарларга карата үткәрелгән сәясәтен яктырта. Мәскәү дәүләтендә, дип яза автор, беренче мөселманнар XV гасырда күренә башлый, ә XVI гасырда аларга кабиләдәшләренең икенче дулкыны кушыла. Мәкаләдән рус хөкемдарларының болар белән вакыт-вакыт камчы кулланып, ә вакыты белән прәннек ярдәмендә эш итүе күренә. Прәннек беренче чиратта христианлыкка күчүчеләргә карата кулланыла, аларга төшемле хезмәт урыннары, утарлар бирелә. 1533 елны, мәсәлән, Касыйм ханы Шаһгали Василий III-нең ачуын чыгара һәм үзенең 150 яраны белән кулга алына. Боларның күбесе ач үлемгә дучар ителә, ә кайберләре чукынып урыс хезмәтенә күчә. Шушы вакыйгадан соң бер ел үткәч, архиепископ Макарий көчләү юлы белән 170 татар хатынын һәм аларның балаларын чукындыра. Казанны алганнан соңгы елларда Новгород жирләрендә яңа алпавытлар төркеме барлыкка килә һәм алар барысы да «Казанский» дип теркәлгән булалар. 1577 елны рус армиясе составында йомышлы татарлар литвалыларга һәм кырымлыларга каршы сугышка әзерләнгән зур бер төркем хасил итәләр. Ә бер елдан соң немецларга каршы сугышта 6500 чукындырылган татар катнаша. Ахырда автор христианлыкка күчкән бер гаилә мисалында Новгород жирләрендә чукындырылган татарларның ассимиляцияләнү процессының ничек баруын күз алдыннан кичерә. Бу төркем озак еллар буена урыслар арасында яшәп тә, үзләренә хас традицияләрне саклап килделәр, ассимиляция процессы кыенлык белән барды, дип күрсәтеп үтә.

Венгрия галимнәре Георгий Ледерер һәм Иболья Такашларның «Польшада мөселманнар» дигән мәкаләсендә Польша һәм Литва жирләренә татарларның килеп утыруы һәм мөселман жәмгыятьләре формалашуы процессы яктыртыла. Авторлар күрсәтеп үтүенчә, бу төбәкләрдә беренче татарлар XIV йөзнең башында килеп утыралар. Һәм бөек Литва герцоглары аларны хәрби хезмәткә тарталар. Тора-бара аларга жир бүлеп бирелә. XVI гасыр урталарында Казан һәм Әстерхан ханлыклары урыслар тарафыннннан яулап алынгач, Польша һәм Литва жиренә качаклар агымы көчәя. Польша һәм Литва территориясендә татар катламы сугыш кырында әсирлеккә төшкән кырымлылар хисабына да арта бара. Төрле елларда төрле төбәкләрдән килеп урнашкан һәм этник чыгышлары төрлечә булган шушы кешеләр тора-бара Польша татарлары дип аталучы бердәм төркем булып формалашалар. Алар хәзер 2200 кеше исәпләнә һәм берничә мөселман жәмгыятенә берләшәләр. Бу жәмгыятьләр регуляр рәвештә мөселман бәйрәмнәре үткәрәләр, үзләренең «Әл-Ислам» исемле газеталарын чыгаралар, өч-дүрт елга бер мәртәбә «Ориент Сокольский» дигән милли фестиваль үткәрәләр.

Тарихка кагылышлы мәкаләләрнең берничәсендә милләт һәм милли хәрәкәт мәсьәләләре яктыртыла. Болар арасыннан беренче чиратта доктор Даниел Шаферның (Мичиган университеты) «НЭПның башлангыч чорларында милли тигезлек мәсьәләсе: 1920—24 елларда Татарстан жөмһүриятендә фракцияләр» дигән мәкаләсе игътибарга лаек. Беренче чиратта автор большевиклар вәгъдә иткән милли азатлык лозунгаларының урыс булмаган халыкларны революция ягына тартуда һәм гражданнар сугышында жиңүдә хәлиткеч роль уйнаганын күрсәтеп үтә. Шул ук вакытта партия өчен төп максат дөньякүләм революция ясау һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру булып калды. Милли проблеманы хәл итү исә шушы төп максатка буйсындырылды. Мондый каршылыклы сәясәтнс үткәрү төрле агымнар туууына китерде. Мәкаләдә шушы агымнар арасындагы мөнәсәбәтләргә анализ бирелә.

«Сул» агым тарафдарлары,— дип яза автор,— милли аерымлыкларга әһәмият бирмәделәр һәм пролетариат диктатурасы өчен көрәшне беренче планга куйдылар. Пролетариатның төп массасы руслардан торганлыктан, алар үзеннән-үзе революциядә русларның житәкчелек ролен яклау юлына бастылар. «Уңнар» исә татар пролетариатының азчылыкны тәшкил итүен һәм түбән квалификацияле булуын истә тотып фикер йөрттеләр. Шуннан чыгып, алар милли азатлык хәрәкәте татар буржуазиясе һәм игенчесе белән союзга керергә тиеш, дип хисапладылар. Шуңа күрә аларга буржуаз милләтчеләр тамгасы тагылды. Өченче бер агым да бар иде. Монысының тарафдарлары, «суллар»дан аермалы буларак, милли мәсьәләләрне инкарь итмәделәр һәм руслар белән рус булмаган халыкларның сәясәт, икътисад һәм мәдәният өлкәсендә тигез хокуклыгын алга сөрделәр һәм моны милли автономияләр кертү юлы белән тормышка ашырырга тырыштылар. Мәкаләнең ахырында автор шушы агымнарның бәрелешүе шартларында Татарстанда барган сәяси көрәшкә туктала.

Күренекле жәмәгать эшлеклесе Зәки Вәлиди Туганның журналга урнаштырылган ике мәкаләсендә дә милли азатлык мәсьәләләре яктыртыла. Мәкаләләрдән алда Зәки Вәлиди турында биографик белешмә бирелә һәм аның татар-башкортлар арасындагы милли хәрәкәттә тоткан урыны тасвирлана. Журнал редакторлары Зәки Вәлидине рус большевиклары белән хезмәттәшлек итүенең мөмкин булмаганлыгын аңлаган беренче мөселман лидерларыннан икәнлеген күрсәтәләр һәм шул ук вакытта аның 1919 елда советлар ягына күчүенең Колчакны тар-мар итүдә хәлиткеч роль уйналганлыгына да игътибар итәләр. Ә аның, Советлар белән араны өзеп, басмачылар белән элемтәгә керүе башка мөселман лидерларына, беренче чиратта, Солтангалиевкә карата Сталинда дошманлык уты кабынуына сәбәп булды, диелә.

Зәки Вәлидинең беренче мәкаләсе «Россия мөселманнарының бүгенге хәле» дип атала һәм анда большевикларның мөселман халыкларына карата үткәргән сәясәтенә бәя бирелә, аның шовинистик характерда булуы һәм бу халыкларны ассимиляциягә юнәлдерелгәнлеге

ачып салына. «Төркестандагы проблемалар» дигән мәкаләдә исә бу регионның тарихи үткәне яктыртыла һәм XX гасыр башындагы экономик үзгәрешләр аның киләчәгенә киң юл ача иде, дип күрсәтелә. Әмма рус хөкүмәте ул җирләргә русларны күчертеп утыртуны кулайрак таба һәм шуның белән милли капиталның үсеш юлын кисә, нәтиҗәдә җирле халык феодал хорафатлар коллыгында калуга дучар ителә. Большевиклар исә, сүздә колонизаторлык сәясәтенә каршы көрәш лозунглары күтәрсәләр дә, эштә царизм сәясәтен дәвам иттеләр. Төркестанның экономик, мәдәни һәм социаль коллыктан котылу юлы бары бер,— ди автор,— ул да булса, сәяси бәйсезлеккә ирешү.

Телгә алынган мәкаләләргә үзенең эчтәлеге белән Г. Ибраһимов исемендәге институтның фәнни хезмәткәре Рафаил Мөхәметдиновның «Социализммы яки феодализммы?» дигән язмасы да аваздаш. Бу язмада XIX гасырда патша Россиясендәге социаль структуралар белән XX гасырда СССРдагы иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә чагыштырмача анализ ясала һәм автор, соңгылары да феодаль характердалар, дигән нәтиҗәгә килә. Ахырда ул бу анализны милли мөнәсәбәтләр яссылыгына күчереп, аларның да феодаль характерда булганлыгын, бу система яшәгәндә милли тигезлекнең мөмкин түгеллеген күрсәтеп үтә. Кызганыч ки, дип яза автор, милли мәсьәләләрдә шушы система кысаларында фикер йөртү идарә даирәләренә генә түгел, күп кенә урыс интеллектуалларына да хас. Алар да илдәге кимсетелгән халыкларның хокуклары урыслар белән бер тигез булырга тиешлеген күз алдына да китерә алмыйлар.

Журналда урнаштырылган мәкаләләрнең бер төркеме татар халкының тарихында күренекле роль уйнаган шәхесләргә багышланган. Болар арасыннан беренче чиратта тарих фәннәре кандидатлары Ш. Мөхәммәдьяров һәм Б. Солтанбековларның «Мирсәет Солтангалиев: тормышы һәм язмышы» дигән мәкаләсен күрсәтеп үтәргә кирәк. Билгеле булганча, М. Солтангалиевнең эшчәнлегенә моңа кадәр илебездә чыккан матбугатта гел тискәре бәя бирелеп килende. Чит илләрдә чыккан хезмәтләрдә исә М. Солтангалиев эшчәнлегенә объектив бәя бирүгә, бу эшчәнлекне һәр яктан анализлауга омтылыш яшәде. Ш. Мөхәммәдьяров белән Б. Солтанбеков мәкаләсе — совет авторлары тарафыннан М. Солтангалиев турында объектив планда язылган һәм чит илдә дөнья күргән беренче хезмәт. Мәкалә авторлары бу күренекле җәмәгать эшлеклесен катлаулы тормыш юлы үткән каршылыклы шәхес буларак характерлыйлар һәм 20—30 елларда аның турында «Партия тарихының кыскача курсы» рухында язылган хезмәтләрдә аңа бирелгән бәяләмәләрнең урынсыз икәнлеген ачып салалар. Бу уңайдан мәкаләдә билгеле тарихчы һәм публицист А. Антонов-Овсеенконың: «Солтангалиев Сталин провокацияләренең корбаны булды»,— дигән сүзләре китерелә.

Мәкаләдә М. Солтангалиевнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге яхшы ук тулы яктыртылган һәм ул Татарстандагы революцион вакыйгаларда һәм милли хәрәкәттә актив катнашкан сәяси эшлекле буларак характерлана. Аның Татар-Башкорт җөмһүрияте төзүгә һәм гражданнар сугышы елларында акларга каршы көрәшне оештыруга керткән хезмәте аеруча басым ясап күрсәтелә. Мәкаләдән Солтангалиев милли хәрәкәтләрнең хәзерлекле җитәкчеләреннән берсе буларак күз алдына килеп баса.

С. Солтан (Уфалы) үзенең журналда басылган күләмле мәкаләсен «Гаяз Исхакый-Иделле (1878—1954): кыскача тәрҗемәи хәле» дип атаган. Мәкаләдә төп урынны күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм язучының олы тормыш юлына, иҗади эшчәнлегенә ясалган анализ алып тора. Мәкаләдә китерелгән мәгълүматлардан Г. Исхакый күз алдына халкыбызның тарихын, тормышын, ислам мәдәниятен тирәнтен белгән яхшы әзерлекле әдип, журналист һәм милли-азатлык хәрәкәте вәкиле буларак баса. Автор Г. Исхакыйның эшчәнлеген өч дәвергә бүлеп карый: 1) Милләтне агарту, халык арасында мәгърифәт тарату өлкәсендәге эшчәнлек; 2) Россиядә яшәүче төрки халыкларның тигезлеге өчен көрәш; 3) Идел буе төркиләренең милли бәйсезлеге өчен көрәш.

Мәкаләнең авторы Г. Исхакыйның сәяси эшчәнлегенә тукталып, аның беренче адымнарын соңыннан «Азатлык» исеме алган яшерен шәкертләр оешмасына нигез салуда һәм шушы оешманың легаль булмаган «Тәрәккый» исемле газетасын чыгара башлауда күрә. Бу эшчәнлек ахырда аны эсерлар партиясенә китерә һәм 1905—07 елгы революция вакытында ул шушы партиянең актив эшлеклесенә әйләнә. Ул чыгарган «Таң йолдызы» газетасы үзенең сугышчанлыгы белән аерылып тора. Г. Исхакый күп төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә; шулай да үзенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген туктатмый, яңа газеталар чыгаруны оештыра, милләт азатлыгы өчен армый-талмый көрәш алып бара. Февраль революциясеннән соң аның бу көрәше яңа төсмерләр ала, колачын киңәйтә. Ул мөселман съездларының эшендә актив катнаша, «Идел-Урал штаты» төзүнең инициаторларыннан була. Идел-Урал буенда барган көрәш большевикларның җиңүе белән тәмамлангач, Г. Исхакый чит илгә китә һәм анда татарларны берләштерү, аларның милли оешмаларын тергезү буенча актив эш алып бара, Берлинда «Милли юл», Манчжуриядә «Милли байрак» газеталарын оештыра. Шул ук вакытта ул әдәби-иҗади эшчәнлеген дә туктатмый. Безнең матбугатта Г. Исхакыйны немец фашистлары белән элемтәдә булуда, Гитлерга хезмәт итүдә гаепләүләр булды. Мәкаләдән бу гаепләүләрнең урынсыз икәнлеге күренә. «1939 елгы Мәскәү-немец килешүе һәм Польшаны бүлгәләү Гаяз Исхакыйның актив сәяси эшчәнлеге туктауга китерде. Ул җитәкләгән «Прометей» җәмгыяте әгъзалары Польшаны ташлап киттеләр. 1939 елның сентябрендә немец юлбашчыларының әмере белән «Милли юл» газетасы ябыла. Ә Гаяз Исхакый Төркиягә килеп урнашырга мәҗбүр була». Монда ул икенче бөтендөнья сугышыннан соң, милләттәшләрен берләштереп, «Милли мәркәз»гә нигез сала. «Үзенең эшчәнлеге белән,— дип тәмамлый автор мәкаләсен,— Гаяз Исхакый «Идел-Урал буйлары өчен азатлыкка, бәйсезлеккә бару юлларын яктыртты».

Журналда сүз барган олы шәхесләрнең тагын берсе — Галимҗан Баруди (1857—1921). Аның турындагы мәкаләне Истанбулдагы Мәрмәрә университетының тарих фәннәре буенча доценты Надыйр Дәүләт язган. Галимҗан Баруди да безнең матбугат битләрендә яхшы ук тапталган шәхес. Аңа реакционер, карагруһлар ияречене, азатлыкка омтылучы көчләрне эзәрлекләүче, дигән бәяләмәләр бирелеп килде. Мәкаләдә китерелгән мәгълүматлар аның эшчәнлегенә ачык күз белән карарга һәм объектив бәя бирергә мөмкинлек тудыра. Мәкаләнең башында ук автор Г. Барудиның татарлар арасыннан чыккан югары дәрәҗәле мөдәррис (остаз, укытучы) һәм яңа рухта язылган күпсанлы китаплар авторы булуын күрсәтеп үтә. Мәкаләдә шулай ук Г. Барудиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге тәфсилләп яктыртыла. Ул Казандагы җәдид мәдрәсәләренең беренчеләреннән булган «Мөхәммәдия»гә нигез сала һәм бу мәдрәсә тиздән татарлар арасында мәшһүр мәгърифәт учагына әйләнә. Анда шәкертләр, дини тәгълиматтан тыш, дөньяви фәннәр — мантыйк, тарих, тел, әдәбият, җәгърәфия, математика, физика, химия, биология һ. б. өйрәнәләр. 1905—07 елгы революция елларында шушы мәдрәсә азатлыкны максат итеп куйган «Ислах» хәрәкәтенең үзәгенә әйләнә. 1906—1917 елларда Г. Баруди җәдитчелек характерында булган «Эд-дин вә әл-әдәб» дигән журнал чыгара. Ул Россия мөселманнарының барлык съездларының эшендә актив катнаша. Үзенең шушы эшчәнлеге өчен патша властьлары тарафыннан эзәрлекләнә. 1917 елда Г. Баруди беренче мәртәбә альтернатив тәртиптә сайлау юлы белән Россия һәм Себер мөселманнары диния нәзарәте мөфтие итеп сайлана. Аның белән бергә, диния нәзарәтенең әгъзасы һәм казый итеп хатын-кызлардан беренче мәртәбә Мөхлисә Буби сайлана. Вафатына күп калмаган көннәрдә (1921 ел), Г. Баруди ачыгучыларга ярдәм оештыру буенча актив эш алып бара. Автор үзенең мәкаләсен «Баруди Россия мөселманнарының, бигрәк тә татарларның һәм башкортларның дини һәм мәдәни тормышларына үзенең зур өлешен кертте»,— дип тәмамлый.

Журналның хроника бүлегендә Татар иҗтимагый үзәгенең беренче корылтаена кагылышлы материаллар урнаштырылган. Башта корылтайның узуы турында хәбәрләр бирелгән, ә аннары корылтайда кабул ителгән карарлар китерелгән. Әйтергә кирәк, бу гыйбрәтле хәл. Татар иҗтимагый үзәге беренче корЫлтае карарларының мондый тулы тупланмасы әлегә кадәр татар матбугатында да, рус матбугатында да басылганы юк. Мондый мактаулы эш әлегә чит ил матбугат органы тарафыннан гына башкарылды.

Журналның ахырында Надыйр Дәүләтнең 1985 елда Анкарада «Россия төркиләренең милли азатлык өчен көрәше тарихы (1905—1917)» исеме белән төрек телендә чыккан китабына Тадеуш Святочковскийның рецензиясе урнаштырылган. Рецензиядән күренгәнчә, китапта 1905—07 елгы революциядән соң татарлар арасында җәелгән милли хәрәкәткә дә һәръяклап анализ ясала, милли яңарыш өчен көрәш тарихы яктыртыла, милли мәдәниятне үстерү, уку-укыту эшләрен заманча итеп кору өчен булган омтылышлар турында тулы мәгълүмат бирелә, иҗтимагый тормышта җәдитчелек уйнаган роль һәръяклап тикшерелә.

Күргәнебезчә, журнал битләрендә тарихыбызның һәм мәдәниятебезнең мөһим сәхифәләре яктыртылган. Журнал редакторлары көнбатыштагы укучыларга киң һәм күпкырлы мәгълүматлар җиткереп, халкыбыз өчен игелекле эш башкарганнар. Моның өчен рәхмәтләребез зурдыр.

Яхья АБДУЛЛИН,
Роза МӨХӘММӘТДИНЕВА.

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘ ЯҢАРЫШ

Яңарыш дигәндә без, әлбәттә, иң беренче чиратта Европаны күз алдына китерәбез. Бу — Европадагы XV гасырның ахыры — XVI гасырның башында булган мәгълүм яңарыш. Ләкин хәзерге фәндә бу төшенчәгә алай бер яклы гына карамыйлар.

Хәзер сүз Көнчыгыш, Мөселман, тагын да таррак алсак, Әзербайҗан һ. б. Яңарышлары турында бара. Гомумән, Көнчыгышта һәм һәр халыкның мәдәни тарихында Яңарыш булганмы, дигән сорау галимнәр арасында бәхәсләр дә тудыра.

Бу мәсьәләдә совет галимнәре әлегә бер фикердә генә түгел. Аларның бер төркеме, Яңарыш дигәндә, XV—XVI йөзләрдә Европада буржуаз мөнәсәбәтләрне барлыкка китергән һәм шуның аркасында культура үсешенә нык этәргеч биргән тарихи чорны гына күзаллый. Бу фикер, В. М. Рутенбург, О. В. Вайнштейн, А. Эйдлиннар тарафыннан яклана. Галимнәрнең икенче төркеме, Европа Яңарышы белән берлектә Көнчыгыш Яңарышы, ә аерым алганда, Мөселман Яңарышы да булган, дип саныйлар. Болар: Н. И. Конрад, Ш. Ш. Нуцубидзе, В. К. Чалоян, А. А. Һаҗиев һәм башкалар. Яңарыш Европада гына булган, дигән фикернең тарафдарлары, IX—XI гасырларда Мөселман Яңарышы хөкем сөрүен инкарь итәләр һәм, шул фикерне исбатлар өчен, Көнчыгышта феодаль формацияләрдән соң буржуаз формация барлыкка килмәгән, дигән фикерне төп дәлил итгереп китерәләр. Гарәп-мөселман Яңарышы тарафдарлары исә: зур, нык үскән шәһәрләрне барлыкка китергән, җитлеккән феодализмга да Яңарыш хас диләр. Һәм шул тезисны исбатлар өчен, алар Европа Яңарышын борынгырак, ягъни урта гасырларга күчерү юлы белән, Европа яңарышын җитлеккән феодализм чоры белән бәйләргә тырышалар. Мәсәлән, академик Н. И. Конрад, фәкать үз антик чорын кичергән һәм соңыннан бары тик феодаль формация аша узган халыкларда гына Яңарыш булуы мөмкин, дип саный.

Күп тикшеренүчеләр игътибар итүенчә, гарәп-мөселман Яңарышы булганын инкарь иткән галимнәрнең иң йомшак ягы — Көнчыгыш тарихын һәм культурасын начар белүе. Гарәп-мөселман Яңарышы тарафдарларының кимчелеге исә нык эшкәртелгән бердәм концепцияләре булмауда һәм өскормадагы күренешләрне яшәештәге күренешләр белән бәйли, бу элемтәләрне ачык иттереп күрсәтә алмауда.

Әгәр без Европа һәм Мөселман Яңарышына схематик рәвештә генә күз төшерсәк, алар икесе дә, антик культураны үз эченә алган мәдәният күтәрелешләренә генә кайтып калалар. Ләкин антик мәдәният үзе дә Борынгы Көнчыгыш белән эзлекле рәвештә бәйле булган һәм чәчәк атуга ирешкән бер культура гына түгелме, дигән сорау туарга мөмкин.

Әгәр без Яңарышны билгеле бер халыкның билгеле культурасы чәчәк атуы дип кенә түгел, ә закончалыклы бер тарихи өскорма күренеше кебек аңласак һәм бу күренеш һәр халыкның яшәешендәге билгеле бер компонентлары җитешә башлавы белән генә тәгаен барлыкка килергә тиеш, дип уйласак, мондый Яңарышның аңа гына хас булган гомуми типологик сыйфатлары да булырга тиештер, дигән фикер туа. Мондый типологик Яңарышка «тарихи яңарыш» атамасын кушсак, ул дөресрәк булыр иде. Нинди сыйфатлар белән билгеләнә соң бу тарихи яңарыш? Аңа минемчә, өч сыйфат хас:

1. Яңа иҗтимагый-экономик формациянең барлыкка килүе һәм аның җитлеккән дәрәҗәгә кадәр үсүе.

2. Берничә мәдәниятнең кушылуы һәм шуның аркасында яңа синтетик культура тууы. Элекке мәдәниятләргә тоташу.

3. Билгеле бер тип культура эшлеклеләренең барлыкка килүе. Энциклопедик белемле мондый эшлеклеләрнең бик азлыгы, җәмгыятьнең күпчелеге өчен алар таратка фикерләрнең әле ят булып тоелуы.

Әйтелгән принциплардан чыгып шундыйрак нәтиҗә ясарга мөмкин: күп кенә халыкларның тормышында тарихи яңарышның барлыкка килүе мөмкин, ләкин бу зарури түгел, чөнки һәр халык үз шартында яши.

Югарыда әйтеп үтелгән өч сыйфатны хәзер Борынгы Греция тарихында күрсәтергә тырышыйк.

1. Күп галимнәр фикеренчә, грек философиясе һәм бай культурасы миладигә кадәр VII—IV гасырлар арасында туа һәм иң югары уңышларга ирешә. Колбиләүчелек формациясе формалашу да чама белән шул ук арага, ягъни миладигә кадәр X—IV гасырларга туры килә. Колбиләүчелек үсешендә нәкъ менә иң югары ноктасына килеп җиткәннән соң гына, Греция рухи тормышында торгынлык күзәтелә башлый. Бу турыда антик культура белгече Ф. Х. Кессиди: «Хәзерге вакытта күп тарих

галимнәре, Греция тарихының классик дәверендә төп җитештерү тармакларында коллар хезмәте үзәк рольне уйнамаган, дигән бер фикергә килә... Ул вакытта коллар хезмәте ирекле греклар хезмәтен әле алыштырмаган булган — ирекледәр хезмәте әле ул вакытта зур роль уйнаган...»[1] — ди. Бу дәвер турында К. Маркс болай ди: «Классик грек җәмгыятенең иң чәчәк ата торган вакытында экономик нигезен вак крестьян хуҗалыгы һәм мөстәкыйль һөнәрчелек тәшкил иткән. Ул чакта элеккеге Көнчыгыш гомумилек инде юкка чыккан, ә колбиләүчелек исә әле тирән тамырлар җибәрә алмаган булган»[2].

2. Миладигә кадәр VIII—VI гасырлар арасы греклар өчен бөек географик ачышлар заманасы булган. Алар нәкъ шул вакытта Пиреней ярым утравыннан башлап Колхидага хәтле төрле территорияләрне үзләштереп өлгерәләр. Иониянең Милет дигән шәһәрендә атаклы бер фәлсәфи мәктәп барлыкка килә һәм шул мәктәпнең вәкилләре Вавилон, Мисыр рухи байлыкларын борынгы грекларга тапшыруда зур роль уйныйлар. «Грек философиясенә нигез салучы — Милет шәһәреннән Фалес дигән кеше, үзенең тумышы буенча финикияле (семит!) булган, — ди В. К. Чалоян. Ул төзегән фәлсәфи тәгълимат, Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасындагы күпер вазифасын үтәгән. Плутарх әйтүенчә, Фалес Мисырда булганда, андагы руханилар белән аралашып, фикер алышкан. Нәкъ менә шул руханилардан Фалес дөньяда иң беренчел матдә су булганын күрсәткән фәлсәфи төшенчәне үзләштереп ала һәм философиядәге беренчел материалистик принципларны Мисырдан Грециягә күчереп китерә. Шулар белән берлектә Фалес Мисырда астрономия һәм геометрия белемнәрен дә үзләштерә. Гомумән әйткәндә, җир, су, һава һәм ут кебек беренчел матдәләр турында тәгълимат нәкъ менә Көнчыгышта барлыкка килә һәм шуннан соң гына ул әле зур культурага ия булмаган грекларга күчә башлый. Пифагор, мәсәлән, Мисырның Гелиополис шәһәрендә булганда, Оннуфис исемле руханидан белем алган, ә Платон Сехнуфис дигән рухани белән сөйләшкән һәм аралашкан...»[3]

Нәтиҗәдә, VII—VIII гасырларда Урта диңгезнең Көнчыгыш буйларында греклар үзләреннән югарырак баскычта торган Мисыр, Финикия, Вавилон культураларын бик уңышлы рәвештә үзләштергәннәр, дигән фикер туа.

3. Грек галимнәре һәм философларының белемнәре бик тирән һәм күпкырлы булган. Бу бөтен укымышлы кешеләргә билгеле. Димәк, грек философлары үз сыйфатлары белән тарихи яңарышның өченче дәверенә туры киләләр.

Гарәп-мөселман хәлифәлегенең IX—XII гасырлардагы чәчәк ату чорына күз салсак, без монда да шул ук тарихи яңарышның өч дәверен күрә алабыз.

1. Бирердә феодализм V—XI гасырлар арасында формалаша. Күп белгечләрнең фикеренчә, нәкъ XI гасырның башында гына мөселман Көнчыгышында җитлеккән феодализм чоры башлана[4].

Европа белән чагыштырганда, феодаль изү Көнчыгышта дәүләт рәвешендә тамыр җибәрә. Җир, нигездә, дәүләт кулында була. Дәүләт башында хәлифә тора. Дәүләт байлыгының төп өлешен крестьяннардан җыелган «хәраҗ» дигән салым тәшкил иткән. Тәхетле башкалаларга менә шул салымнарның искиткеч зур күләмдә җыелуы зур шәһәрләрнең барлыкка килүенә бер этәргеч бирә.

Ислам культурасында, бер яктан, рациональ — фәлсәфи, икенче яктан, схоластик юнәлешне халыкның нинди социаль катламнары барлыкка китергән соң?

Мәгълүм ки, хәлифәлекнең беренче елларында дәүләт аппаратын, нигездә, ике төркем тәшкил иткән: төрле гарәп кабиләләре вәкилләреннән гыйбарәт гаскәр һәм чиновниклар. Алардан әкренләп ике яңа социаль төркем формалаша: крестьяннардан салымнарны җыйган, контроль эшләрен алып барган, аларны ачыктан-ачык изә торган хәлифә идарәчеләре төркеме. Икенчесе — гаскәриләрнең һәм чиновникларның бер өлеше баеп, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләргә әверелеп китә, бу яңа катлам киләчәктә туачак зур шәһәрләрнең төп нигезен тәшкил итә. Крестьяннар, җиргә кендекләре белән көчләп беркетелмәгәнлектән, еш кына шәһәрләргә күчеп килә алган.

Соңыннан, әлеге икенче төркем эчендә «гөләмә» дигән зыялы катлам да барлыкка килә, һәр төркемнең «голәмә»се үз ишләре мәнфәгатьләрен, идеалларын яклый, күтәрә башлый. Нәтиҗәдә, сәүдәгәр һәм һөнәрчеләрдән гыйбарәт булган социаль катлам әл-Кинди, әл-Фараби, Әбүгалисина кебек фикер ияләрен һәм гуманистик философияне барлыкка китерүчеләрне тудыра, чөнки бу катламның хосусияте, мәсәлән, сәүдә һәм һөнәр белән шөгыльләнүе рухи үсешкә, аң киңәюенә, аерым шәхеснең кыйммәтен аңлауга нык этәргеч бирә. Икенче яктан, әкренләп феодалларга әверелеп бара торган бюрократик чиновниклар катламы һәм аның голәмәсе ортодоксаль һәм схоластик рухтагы исламны барлыкка китерә, аның вәкилләре соңыннан иҗтимагый фикернең рациональ-фәлсәфи юнәлешенә сугыш игълан итә.

Ләкин XI гасыр урталарында җир биләүнең икенче — «икта» дигән формасы киң тарала башлый. Икта — хәлифә гаскәрендә хезмәт иткән өчен билгеле бер вакытка

---

[1] Ф. Х. Кессиди. От мифа к логосу. М., 1972. 7—8 б.
[2] Шунда ук, 10 б.
[3] В. К. Чалоян. Восток и Запад. М., 1968. 47—48 б.
[4] «Мусульманский мир» җыентыгы. М., 1981. 5 б.

гына бирелә торган җир биләмәсе. Гаскәри хезмәттән чыга икән, аның җире дә кире алына. Икта таралуына, нигездә, гарәп хәлифәлегенә килеп урнашкан төркиләрнең угыз кабиләләре сәбәпче була. Ә соңыннан сәлҗүкләр дәүләтендә җир биләүнең бу төре иң киң таралган форма булып кала. Икталар соңыннан әкренләп гаскәри феодалларның үз шәхси милегенә әверелү аркасында, дәүләттә таркаулык арта, шәһәр тормышында торгынлык канат җәя. Көнчыгышта җитлеккән феодализм чоры башлана һәм схоластик ислам феодалларның рәсми идеологиясенә әйләнә.

2. Инде VII гасырның башында ук Африка көнчыгышыннан Мадагаскар, Һиндстан, Цейлон, Кытай һәм Индонезиягә хәтле бөтен сәүдәне гарәпләр үз кулына ала. Диңгездә йөзү сәнгате гарәпләрдә бик югары дәрәҗәгә җитүен дөньяның күп телләренә гарәпчәдән кергән «адмирал» (әмир әл-бәхр), «баржа» (бәриҗә), «галера» (гураб), «фелюга» (харрака) кебек сүзләр бик ачык күрсәтә. Шул ук дәвердә гарәпләр Иран, Византия һәм соңрак тәрҗемәләр аркылы Борынгы Греция мәдәниятләрен дә актив рәвештә үзләштерәләр. Ул вакытта гарәп культурасының чуарлыгын Багдад шәһәренең төзелеш тарихында да күрергә мөмкин.

«Багдад, чыннан да, күп милләтле шәһәр булган. Хәлифә Мансурның утыз меңлек гаскәрендә Иран һәм Урта Азиянең бөтен өлкәләре вәкилләре хезмәт иткән. Шәһәр корылып беткәч Якын Көнчыгышның төрле илләреннән җыелган төзүчеләр дә шушында төпләнеп калган. Фарсы, арамей телләрендә сөйләшкән җирле халыклар Куфа, Басра һәм Васыт кебек гарәп шәһәрләреннән килүчеләр белән аралаша башлаган. Гарәп теле аралашу чарасына әйләнә, ләкин ул үзе дә башка телләр хисабына байый, мәсәлән, лексика, фонетика, синтаксис җәһәтеннән шомара, камилләшә. Нәтиҗәдә, монда гарәп, набатей, согыд, славян, төрки, грек, негр һәм әрмәннәрнең кушылуы аркасында барлыкка килгән яңа халык үзен фәкать дин һәм гарәп теле буенча гына бүтәннәрдән аера алган. IX—XIII гасырларда Багдадта яңа гарәп миллияте туа башлаган, дип әйтергә мөмкин»[1]

3. Мөселман Яңарышының әл-Кинди, әл-Фараби кебек зур эшлеклеләре күп кырлы белемгә ия. Җәмгыятьнең күпчелеге аларча фикерләүне әле тулысынча кабул итә алмаган. Моны Гомәр Хәйям шигырьләрен укыганда да тоярга мөмкин.

Югарыдагы әйтелгәннәргә таянып, минемчә, Мөселман Яңарышына да «тарихи яңарыш» атамасын бирергә мөмкин.

Европа Яңарышында тарихи яңарышның өч мизгелен күрәбез: Төньяк Италия һәм кайбер башка Европа илләрендә XV—XVI гасырларда буржуаз формациянең тууы һәм җитлегүе. Европадагы төрле халыкларның мәдәни аралашуына һәм кинәт үсүенә сәүдәнең киңәюе, бөек географик ачышлар ясалу. (Американы ачу һәм Магелланның җир шарын әйләнеп чыгуы), китап басыла башлануы зур этәргеч биргән. Бу аралашу процессын ачыграк күзаллау өчен, шул замандагы Лион шәһәре тормышын сурәтләү файдалы:

«Монда тормыш кайнап тора. Ел саен дүрт ярминкә уздырыла. Бөтен Европадан сәүдәгәрләр җыела. Тукыма, күн, келәм, төрле корал һәм Лион ефәге — бөтен бу товарларны акчага сатып алып була. Ярминкәләрдә барлык илләрнең акчалары гамәлдә йөри. Урамнарда голланд, немец, итальян, испан, инглиз телләрен ишетергә мөмкин. Монда төрле дингә ышанган кешеләр җыела, ләкин алар үз диннәре турында бәхәсләшмиләр, ә тыныч, тату гына сәүдә итәләр. Монда түземлелек һәм хөр рух хөкем сөрә һәм лионлылар бу ирекле бик нык саклыйлар. Лионга бөтен Европадан галимнәр дә килә. Аларның игътибарын монда бай басмаханәләр җәлеп итә.»[2]

Менә шундый атмосферада яшәгән, үз көченә, акылына ышанган шәхесләр арасында Яңарыш каһарманнары туа башлый һәм алар, ниһаять, үз гуманизмына аваздаш Борынгы Греция казанышларына мөрәҗәгать итә башлыйлар.

Европа Яңарышы титаннары, аларның киң кырлы белеме, гуманизмы турында фәнни һәм популяр әдәбиятта инде бик күп язылды. Аларның сыйфатлары тулысынча тарихи яңарышның өченче баскычына туры килә.

Югарыда өч тарихи яңарышның, ягъни колбиләүчелек, феодаль һәм буржуаз яңарышларның гомуми типологик якларын яктыртырга тырыштык.

Мәгълүм ки, татар халкы башка дөньядан аерылып яшәмәгән. Шуңа күрә, татар халкының мәдәни үткәнендә тарихи яңарыш булганмы, булса, кайчан, кайсы чорда йөз биргән, дип сорау кую урынлы. Минемчә, бу уңайдан татар культурасында ике дәвергә игътибар итәргә кирәк: монгол яуларына кадәрге Идел Болгарстанының чәчәк атуы билгеле. Ислам динен кабул иткәннән соң, Болгарстан гарәп-мөселман мәдәни тирәлегенә кереп китә. Хәлифәлекнең матди һәм рухи үсеш дәрәҗәсе Идел Болгарстанының шул ук күрсәткечләреннән ул чорда нык аерылмый. XII—XIII гасырларда Болгарстанда, бөтен хәлифәлектәге кебек, тарихи феодаль яңарыш процессын күзалларга мөмкин. Мәсәлән, мәйданы дүрт квадрат чакрымга җиткән Биләр шәһәрендә 70—100 меңләп кеше яши. Хакимият дәүләттә бик нык үзәкләштерелә. Җир дәүләтнеке була, дәүләт башында патша тора. Дәүләт байлыгының иң зур өлеше Биләр шәһәренә тупланa.

---

1 О. Г. Большаков. Очерки истории арабской культуры. М., 1982. 176 б.
2 А. А. Гаджиев. Ренессанс и поэзия Гянджеви. Баку, 1980. 25 б.

Әгәр без Биләрне хәлифәлектәге шундый ук зур шәһәрләр белән чагыштыра башласак, ул мәйданы һәм халык саны буенча Куфа һәм Басрага тиңләшә. XIV—XV гасырларда Европадагы 20—30 мең кеше яшәгән шәһәрләр бик зур дип саналуын да онытмыйк. XIV гасырда Парижда, мәсәлән, фәкать 70 мең кеше яшәгән. Ә Германиянең Нюрнберг һәм Страсбург кебек Яңарыш шәһәрләрендә халык саны фәкать 20 меңгә генә җиткән.

Ул чорда Болгарстанда да, хәлифәлектәге кебек, феодаль иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр тамыр җибәргән.

Европа һәм Азия чигендә урнашу, Идел белән Кама елгалары буенда яшәү һәм хәлифәлек канаты астына керү, әлбәттә, Болгарстанның мәдәни үсешенә нык тәэсир иткән. Ул чорда болгар, угыр-финнәр һәм гарәпләр мәдәнияте бергә үрелү нәтиҗәсендә, Идел-Болгар культурасы барлыкка килә. Болгарларның нык үскән гарәп-фарсы әдәбияты һәм фәне белән танышуы аркасында, антик хикмәтләр белән дә танышуы бик ихтимал. Бу нәрсәне «Кыйссаи Йосыф» әсәренең гуманистик рухы да ап-ачык күрсәтә. Поэмада Йосыф образы шәхес акылына мәдхия уку, Зөләйха образы ярдәмендә шәхеснең хиссият табигатенә игътибар итү, Зөләйха һәм Йосыфның ихтыярлы омтылышларына игътибар итү кебек күренешләр поэманың тирән гуманистик эчтәлеген күз алдына бастыра.

Болгарстан галимнәре, гадәттә, берничә тел белгәннәр (гарәп, фарсы, төрки ). Аларның кайберләре Иран һәм Гарәбстанда белем алган. Кол Гали, Якуб ибн Ногман, Идриси әл-Болгари кебек бөек шәхесләр, әлбәттә, хәлифәлекнең Багдад, Нишапур, Сәмәрканд кебек зур культура үзәкләре белән тыгыз элемтәдә торган. Кайбер болгар галимнәренәң әсәрләре хәлифәлектә дә киң таралган.

Кыскасы, Болгар культурасында да феодаль тарихи яңарышның өч төп сыйфаты барлыгы күренә һәм Болгар дәүләте IX—XII гасырларда феодаль яңарыш кичергән дигән фикерне расларга була.

Татар культурасы тарихында XIX гасыр аеруча мөһим бер чор булып тора. Без бу дәвердә буржуаз тарихи яңарышны сыйфатлый торган өч үзенчәлекне ачык рәвештә күрә алабыз. Г. Ибраһимовның «XIX гасырның икенче яртысында татарлар арасында реформация хәрәкәте, ягъни Яңарыш чоры башлана»[1],—диюе игътибарга лаек. «Әгәр татар тормышындагы, элекке схоластик дәверебезгә урта гасырларны искә төшерсә, хәзерге татар җәмгыятендә күзгә чагылган яңалык күренешләре исә, безгә Европада XVI гасырда булган Яңарышны һәм Реформацияне хәтерләтәләр»[2],—ди ул.

XVIII гасырның ахырында татарларның мануфактура җитештерүдә нык кына алга барулары күзәтелә, бу тармак матди тормышта үзәк урынны яулап ала. XIX гасырның урталарында Казан губернасының промышленносте кискен төстә механикалаштырыла бара[3].

Ләкин фәкать крепостной правоны юк иткәч һәм 1860—1880 елларда машиналаштырылган промышленность барлыкка килгәч кенә, капиталистик мөнәсәбәтләр Казан губернасының экономик тормышында зур урын ала башлый. XIX гасыр башыннан алып татар буржуазиясе гомум Русия экономик базарына бик актив рәвештә керә башлый.

Экономик үзгәрешләр нәтиҗәсендә, татар җәмгыятенең билгеле бер даирәләре урыс культурасын һәм аның аркылы Европа мәдәниятен дә үзләштерә башлый. Татар культурасы җитди яңарыш кичерә, ул хәзер ике өлешкә — мөселман һәм Европа мәдәнияте кушылмасына әйләнә. Идеология буларак, ортодоксаль, схоластик ислам барлыкка килә торган буржуаз җәмгыятьнең яңа рухи ихтыяҗларын, әлбәттә, инде канәгатьләндерә алмаган. Буржуаз җәмгыятьнең яңа кешеләренә киң караш, актив эшчәнлек, шәхес акылының куәтенә ышану, оптимизм кебек сыйфатлар хас булган. Алар инде үз эшчәнлегендә фәкать Алла ярдәменә генә ышанып тора алмаганнар. Шуңа күрә Курсави, Мәрҗани, Күлтәси кебек фикер ияләренең урта гасыр гарәп-мөселман гуманистик идеяләренә мөрәҗәгать итүләре, бу культурада алар яшәгән чорга туры килә торган сыйфатларны эзләүләре һич тә очраклы булмаган.

Шул чорның татар галимнәре, гадәттә, киң кырлы белемгә ия булганнар. Мәсәлән, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һ. б. Алар тараткан фикерләрне җәмгыятьнең күпчелеге әле кабул итә алмаган «Ш. Мәрҗанинең «Нәзурәт әл-хак...» исемле төп фәлсәфи әсәренең эчтәлеген һәр 20 мулладан, ичмаса, фәкать берсе генә дә аңлаган булса иде, бу да бик әйбәт булыр иде», — дигән Г. Ибраһимов.

Димәк татар мәдәнияте тарихында ике тарихи яңарыш булган: берсе — феодаль, икенчесе — буржуаз яңарыш. Аларның икесе дә татар тарихында гаять зур роль уйнаган, дип әйтергә мөмкин.

**Р. МӨХӘММӘТДИНЕВ,**
Г. Ибраһимов исемендәге
ТӘТИның фәнни хезмәткәре.

---

[1] Г. Ибрагимов. Татары в революции 1905 года. Казан, 1926. 4 б.
[2] Шунда ук. 28 б.
[3] Х. Х. Хасанов. Формирование татарской буржуазной нации. Казан, 1979. 61 б.

# НИЗАМИНЫҢ ҮЛЕМСЕЗ ИҖАТЫ

Әгәр дә әдип, шагыйрь, рәссам, нинди милләттән булуына карамастан, иҗатында кешелекнең мөкатдәс саналган теләкләрен, киләчәкне яхшы итеп күрергә омтылган хыялларын, гаделлек, тигезлек, дуслык, мәхәббәттә тугрылыклы булу турындагы уйларын җанлы сурәтләрдә бирә алган икән, андый әсәр һәр заман укучысының күңелен биләгән, аңа рухи азык биргән. Чөнки анда кешенең үз язмышын үзе хәл итә ала торган бөек зат икәнлеге сәнгатьчә сурәтләнгән була.

Әзербайҗан халкының бөек шагыйре, фикер иясе Низами Ганҗәвинең әсәрләре — әнә шундыйлардан. Алар инде сигез гасырдан артык вакыт кешеләргә зәвекъ, ләззәт биреп, аларны югары әхлак сафлыгына, намуслы хезмәткә чакырып киләләр. Шуңа да Низами — онытылмый, ул — халыклар күңелендә. Тууына 850 еллыгын дөнья күләмендә билгеләп үтү — шагыйрьгә булган ихтирамның иң олысы.

Низами — дөнья әдәбиятында үлемсезлек алган шагыйрьләрдән. «Мәхзәнел — әсрар», «Хөсрәү вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Һәфт пәйкәр» һәм «Искәндәрнамә» соңрак бишесе бергә «Хәмсә» гә — «Бишлек» кә тупләнгән.

Поэмаларның сюжеты борынгы Иран һәм гарәп дөньясының үткәндәге тарихы, бай авыз иҗаты һәм әдәбияты белән бәйләнгән. Моңа һинд мәдәнияте дә килеп кушылган. Низами үз чорының күпкырлы белеменә ирешкән. Күрәсең, ул вакытларда Ганҗә шәһәре мәдәни үзәкләрнең берсенә әверелеп, рухи иҗат эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыра алган.

Һәр поэманың үз йөкләмәсе бар. Тарихи вакыйгаларга багышланган булуларына карамастан, шагыйрь аларда заманының мөһим мәсьәләләрен кузгаткан һәм аларны үз карашынча хәл иткән.

«Мәхзәнел-әсрар» («Серләр хәзинәсе») нигезен нәсихәт тәшкил итә. Әмма бу — коры үгет, дидактика гына түгел, ә шагыйрьнең иҗат алымнарыннан берсе. Үзәктә — кеше. Ил башлыгының төп сыйфаты — гадел идарә итү, мул тормышның нигезе — намуслы хезмәт.

Низами әсәрләре фарсы телендәге сүзләренең күп мәгънәлелеге, нечкәлеге, образлыгыннан файдаланып, катлаулы, хәтта, аңлавы кыен һәм төрлечә фикерләргә мөмкин булган сурәтләр, шигъри алымнар белән бизәлгән. Төрки халыкларның укымышлы, талантлы вәкилләре Низаминың иҗат хәзинәсенә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, аннан файдаланганнар, үрнәк алганнар. Киң катлау укучыга житкерү өчен Низами әсәрләрен тәрҗемә дә иткәннәр, урыны белән кыскартканнар, яңа фикерләр дә өстәгәннәр. Бу иҗади тәрҗемә булган. Яисә Низами үрнәгендә яңа әсәрләр язганнар. XIV йөз ахырында хәрәземле төрки шагыйрь Хәйдәр Низаминың «Мәхзәнел-әсрар»ын әнә шул юнәлештә эшкәрткән. Гали Рәхим бу әсәргә игътибар итеп, «Татар әдәбияты тарихы»нда (1923) махсус мәкалә урнаштыра. Әсәр Казанда беренче мәртәбә 1858 елда нәшер ителә. Үзбәк әдәбиятчылары Хәйдәр поэмасының Британия музеенда саклана торган нөсхәсенең фотокүчермәсе белән эш итәләр. Соңгы елларда Татарстанда Хәйдәр «Мәхзәнел-әсрар»ының яңа бер кульъязмасы табылды. Болар өстенә, андагы аерым шигъри юллар Мөхәммәдъяр әсәрләренә дә килеп керә. Мондый күренешләрнең сәбәбен үткәндәге тарихи шартларда әдәбиятның һәм әдәби телнең билгеле бер дәрәҗәдә уртак булуыннан эзләргә кирәк. Ул вакытларда Хәрәзем Алтын Урда составында булып, Идел буе белән бергә бер дәүләтне тәшкил иткән. Урынчылык үзенчәлекләрен бер микъдарда саклаган хәлдә бу киң дәүләттә яшәгән төрки халыклар өчен уртак әдәби тел һәм әдәбият барлыкка килгән. Хәйдәрнең «Мәхзәнел-әсрар»ы шушы әдәби мохиттә барлыкка килгәнлектән, үзбәк әдәбияты ядкаре саналу белән бергә, аның татар әдәбияты тарихында да билгеле урыны бар. Димәк, Низами төрки-татар укучысы күңеленә төрле юллар белән килгән.

«Хөсрәү вә Ширин» поэмасы Фирдәүсидән башлап җырланган Иран шаһы Хөсрәү Пәрвиз белән гүзәл Ширин арасындагы фаҗигале мәхәббәт мажараларын сурәтләүне эченә ала. Низами вакыйгаларны үз чоры җирлегенә якынайтып, аларга заман рухы өрә. Ил башлыгының гадел эш йөртергә тиешлеге биредә тагын да ачыграк сизелә. Ә мәхәббәт исә Хөсрәү кебек һавалы, горур шаһның да күңелен йомшарта; ул, Ширинннең киңәшләрен тотып, гаделлек белән исәпләшергә тиеш була. Сөю Ширингә көч, куәт бирә, характерын чарлый, мөстәкыйльлек тойгысын арттыра, кешелеклелек дәрәҗәсен күтәрә. Гомумән, олы мәхәббәт тирәсендә һәрвакыт диярлек көнчелек зәһәре, мәкерлек ятьмәсе сакта торган кебек. Хөсрәү дә үзенең улы, Ширин мәхәббәтенә дәгъвачылык иткән Шируя тарафыннан үтертелә. Ширин ире кабере өстендә, аның җылы туфрагын күз яшьләре белән сугарып, үзен корбан итә.

«Хөсрәү вә Ширин» поэмасы — сүз сәнгатенең нәфислек алымнары белән бизәлгән үзе бер сихри дөнья. Ул Низаминың иң яхшы әсәрләреннән санала. Русның танылган шәрекъшөнасы — көнчыгышны өйрәнү белгече Е. Э. Бертельс: «Низаминың икенче поэмасы Әзербайҗанның гына түгел, бәлки дөнья әдәбиятының да иң бөек гүзәл әсәрләреннән — шедеврларыннан»[1] — дип бәяләде.

Низами иҗатының шушы гүзәл җимешен төрки укучыга — аның үз телендә җиткерүне Алтын Урда шагыйре Котб башкара. Дөнья әдәбиятының бөек казанышларыннан саналган «Хөсрәү вә Ширин» не башка телгә әйләндерү өчен тәрҗемәченең талантлы булуы белән

---

[1] Бертельс Е. Э. Низами. Творческий путь поэта. Изд-во АН СССР. М., 1956, 124 б.

бергә, аннан югары шагыйрьлек куәсе дә сорала. Һәм әдәби телнең билгеле дәрәҗәдә эшләнгәнлеге, әдәбиятның тотрыклы бай традицияләргә ия булуы да кирәк. XIV йөзнең урталарында Алтын Урда дәүләтендә төрки-татар әдәбияты һәм аның әдәби теле әле саналган зарури сыйфатларны үзендә туплаган була. Бу әдәбият Низами кебек тиңдәшсез осталарның әсәрләрен, алардагы бай образлылыкны, шигъри нечкәлекләренә кадәр саклап, үз төрки теле байлыгы нигезендә бирә алырлык талант ияләрен тәрбияли алган. Шулардан берсе — шагыйрь Котб.

Котб — Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын төрки укучыга аның үз телендә житкерүне беренче башлап жибәрүчеләрдән. Котбның киң колачлы бу тәржемә эшенә багышлап, Г. Таһиржанов һәм Х. Миңнегулов фәнни хезмәтләр яздылар. Бу ике тикшеренү — Котб иҗатын өйрәнүдә житди казанышлардан[1].

Мәрхүм профессор Габдрахман ага Таһиржанов зур эш калдырып китте. Ул Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының төрки-татар теленә иҗат тәржемәсенең Алтын Урдада Идел буе жирлегендә тарихи вакыйгалар, сарайда яшәп килгән йолалар, этнография әйберләре, тел үрнәкләре, мәкальләр, әсәрдә сурәтләнгән табигать күренешләре, археология табылдыклары, хәтта хайван, җәнлек, кошлар исемнәре белән бәйләп аңлатты һәм төрле яктан күп дәлилләр китерде. Әгәр дә Котб башка берәр өлкәдә: Урта Азиядәме, Әзербайжандамы яисә Анатолиядәме яшәп иҗат иткән булса, әле саналган Идел буе жирлегенә хас күренешләрне нечкәлекләренә кадәр белә дә алмас һәм әсәренә кертмәгән дә булыр иде. Бу фикерне икенче бер дәлил белән дә куәтләп була. Мәсәлән, Нәваи Низаминың шул ук «Хөсрәү вә Ширин»е нигезендә үзенең «Фәрһад вә Ширин» әсәрен иҗат итә. Ул аны Урта Азия жирлегенә бәйләнештә, үзбәк халкы тормышына мөнәсәбәттә эшли һәм шул якның үзенчәлекле күренешләре, арыклар төзү белән бәйли. Димәк, һәрбер сәнгать, нәфис әдәбият әсәренең төгәл тарихи жирлеге була, ул тик шул нигездә генә туа ала.

Котб иҗат иткән «Хөсрәү вә Ширин»нең төгәл ачык жирлеге хакында Е. Э. Бертельс болай яза: «Поэмада вакыйга исламга кадәрге Иранда баруга карамастан, шагыйрь аңлы рәвештә еш кына очракта төп нөсхәдән читкә тайпыла һәм Алтын Урда ханнарының гореф-гадәтләрен, көнкүреш детальләрен тасвирлауны кертә...»[2]

Заманының алдынгы фикер иясе Котб халык язмышы, илдәге тормышның авырлыгы турында борчыла һәм Низаминың шушы поэмасындагы гаделлек, тигезлек, хөрлек идеясен укучыга тагын да үтемлерәк итеп житкерергә тырыша, хөкемдарның гадел идарә итеп, илдә халыкның тигез, рәхәтлектә яшәвен тели.

Татар укучысы Низаминың «Хөсрәү вә Ширин»ен мәшһүр үзбәк шагыйре Галишер Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» дастаны буенча да белә, чөнки бу әсәр дә әзербайжан даһиеның «Хөсрәү вә Ширин»е сюжетына нигезләнеп язылган.

Нәваиның бу әсәре хакында югарыда әйтелгән берничә сүз белән чикләнеп, монда аның татарча тәржемәсе турында искәртеп үтәсе килә. Ул Әхмәт Исхак тәржемәсендә Казанда 1948 елда басылды. Үзе талантлы шагыйрь булган Ә. Исхак бу классик әсәрнең бик матур тәржемәсен бүләк итеп калдырды. Ул аңа илһам ялкынын бирде, Нәваидагы образлылыкны, бизәкләрне, шигъри аһәңне татар теленең әле без ачып житкерә алмаган сихри көче белән үз укучысына житкерә алды. Бу тәржемәдә Низаминың Ганжә бакчалары өстеннән очкан якты хыялы да, Котбның сандугачлы Идел тугайларында туган тылсымлы моңы да, Нәваиның хөрмә чәчәкләре хуш исен алган серле аһәңе дә бар кебек. Шулай итеп, Низаминың һәр әсәре татар укучысына төрлечә житә алган.

Низаминың «Ләйлә вә Мәжнүн» поэмасы да укучыны таң калдыра. Бу әсәрдә сурәтләнгән мәхәббәт тагын да көчлерәк. Аның ялкыны сүнүне белми, кызганнан-кыза, илһам өрә, күңел дөньясын күкләргә аштыра, шагыйрь итә. Кайсның Ләйләгә булган мәхәббәте әнә шулай. Сөю хисе белән шашканы өчен аңа Мәжнүн кушаматы бирәләр. Ике кабиләдәге затлы, ләкин төрле холыклы ике атаның каршылыклы мөнәсәбәтләре Мәжнүн белән Ләйләне кавышудан мәхрүм итә. Ләкин аларның мәхәббәте соңгы сулышларына кадәр сүнми. Гашыйк белән мәгъшуканың көенечле мәхәббәтләре турындагы легенда Низами каләме белән дөнья әдәбиятының иң күркәм әсәрләренә әверелә.

Низаминың «Ләйлә вә Мәжнүн»е алдында В. Шекспирның хәтта Көнбатышта бик шаулаган «Ромео һәм Жульетта»сы да тоныкланып кала. «Бу поэма, — дип язды Н. Тихонов, — Шекспир белән Гете әсәрен ерактан ук алдан каршылап алучы булып, тасвирлау көче белән алардан күп югары тора. «Ромео һәм Жульетта»ны алып карасак, бәдәвиләр риваятен, кайнар дәрттән башка, нәфис рәвештә яңадан сөйләп чыгу гына ул».[3]

Шунысы кызык һәм әһәмиятле: Ләйлә һәм Мәжнүн турындагы риваятьләр һәм алар сюжетына язылган әсәрләр, шулар эчендә Низаминың «Ләйлә вә Мәжнүн» поэмасы дөньяның бик күп өлкәләрендә киң таралган булса да, төрки халыкларда үз жирлекләрендә шуңа охшаш, төрдәш мәхәббәт легендалары барлыкка килгән. Татар, үзбәк, төрекмәннәрдә Таһир

---

[1] Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е турында кара:
Таһиржанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. Казан. 1979, 95—153 б., аныкы: Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре. — Татар әдәбияты тарихы. I т., 1984, 170—195 б.
Миңнегулов Х. Ю. Котб иҗаты. Казан, 1976.

[2] Бертельс Е. Э. Литература народов Средней Азии от древнейших времен до XV века н. э. — «Новый мир», 1939, № 9, 272 б.

[3] Тихонов Н. Низами һәм Нәваи. — «Совет әдәбияты». Казан, 1947, № 9, 117 б.

белән Зөһрә мәхәббәтләре турындагы халык авыз иҗаты дастаннары әнә шундыйлардан. Асылда Урта гасыр татар җирлеге белән бәйләнештәге бу риваять хәтта Һинд һәм Пакыстан халыкларына да барып кергән. Бу сюжетка язылган әсәрләр дә «Ромео һәм Җульетта»дан бер дә ким түгелләр.

Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн»е һәм андагы мәхәббәт каһарманнары татар шагыйрьләренә гасырлар буена канат биреп килгән. Кандалый, Дәрдемәнд һәм Тукайның Ләйлә һәм Мәҗнүн турындагы шигъри юллары сүз сәнгатенең иң күркәм үрнәкләрен тәшкил итәләр. Ф. Халиди XIX йөз ахырында Ләйлә белән Мәҗнүн риваятен нәсердә хикәя итеп бастырды. Поэма тулы килеш Казанда 1950 елда М. Максуд тәрҗемәсендә нәшер ителде. Бу шулай ук бик яхшы тәрҗемәләрдән.

Низаминың «Җиде гүзәл» («Һәфт пәйкәр») поэмасының да асылында дәүләт җитәкчесе ил турында кайгыртырга, халык мәнфәгате белән яшәргә тиеш дигән идея ята. Мәхәббәт бәйләнешләре бирелә дә булса, алар персонажларның кайсы яктандыр характерларын ачу чарасы буларак кына китерелә. Баш персонаж Бәһрам Гүрне халык, атасы кебек явыз булыр дип, шаһ тәхетенә утыртырга каршы төшә. Ул гадел идарә итү, золым күрсәтмәү, рәхим-шәфкатьле булырга тиешлеге турында сүз биргәч кенә, шаһ була. Бәһрам шулай идарә итә башлый. Ул халыкны рәнҗетүчеләргә, дәүләт байлыгын таратып, читләргә баш иеп яшәтергә тырышучыларга каршы көрәш алып бара. Һәм илнең иминлеген саклап калуга ирешә. Бу күренеш Казан ханлыгының соңгы чирегендәге хәлгә бик охшый. Шагыйрь Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында Сәхибгәрәй образына Бәһрам Гүр сыйфатлары бирүендә тирән мәгънә бар. Шагыйрь ил эчендә аны һәлакәт юлына этәрүчеләр турында искәртә, уяу булырга чакыра.

Низаминың «Искәндәрнамә» поэмасы шагыйрьнең иҗатына йомгак буларак күз алдына килә. Ул шигъриятнең биеклегенә озак үрмәләгән, ниһаять, аның башына менеп баскан. Аннан дөнья ачыграк күренә. Алда, кайдадыр офык артында, күңелләрне үзенә тарткан, кешеләре рәхәтлектә гомер кичергән ниндидер бер гаҗәеп ил күзаллана. Әсәрдәге төп фикер Искәндәр образы аша шул юнәлештә бирелә.

Искәндәр — күп илләрне яулап алучы да, акыл иясе дә, гадел идарәчелекнең камилләшкән юлларын табарга тырышып, кешеләргә яхшылык теләүче пәйгамбәр дә. Ул үзенең соңгы сәфәрендә төньякта таныш булмаган ят илгә барып чыга. Анда золым да, залим дә, бай да, ярлы да юк. Ялганның һәм гаделсезлекнең нәрсә икәнен белмиләр. Кешеләрне интектергән газаплы авырулар да юк. Бер-беренә ярдәмчел халык тату, дус яши.

Искәндәр менә шундый сокландыргыч, үрнәк җәмгыятьне күрергә ирешә. Бу — аның эзләгәне, ягъни Низами дөньяга карашының югары ноктасы, җирдә кешене бәхетле итү теләгенең хыялда сурәтләнгән үрнәк өлгесе. Кешелекнең киләчәк гадел җәмгыяте шәкелен бу рәвешчә тасвирлау Низамига кадәрге көнбатыш әдәбиятларында күренми. Әмма Көнчыгышта әл-Кинди, әл-Фараби әсәрләрендә идеаль җәмгыятьнең үрнәкләре күрсәтелә.

Мөхәммәдьяр үзенең поэмаларында Низаминың «Искәндәрнамә»сенә турыдан-туры иярә. Ул да Искәндәр төньякта күргәнгә охшаш идеаль җәмгыять картиналарын сурәтли һәм аларны үз илендә күрергә тели; чөнки, аныңча, җир — игелек, яхшылык урыны, кешеләр анда рәхәтлектә яшәргә тиеш.

Кыскасы, Низами иҗаты татар әдәбиятына гасырлар буена йогынты ясап килде, һәм бу йогынты болгар чоры ядкарьләреннән үк башлана, ул бүгенге көнгә кадәр дәвам итә.

Шакир АБИЛОВ

# БЕР МИРАСКА—ИКЕ КАРАШ

АКМУЛЛАНЫН ТУУЫНА 160 ЕЛ

Моннан нәкъ ун ел элек Татарстан китап нәшрияты «Акмулла» китабын бастырып чыгарган иде. Шул ук вакытта шундый ук китап башкорт теленә тәрҗемәдә Башкортстан китап нәшриятында да дөнья күрде. Ләкин бу ике телдә чыгарылган китапларның кереш мәкаләләре эчтәлегендә җир белән күк арасы кадәр аерма барлыгы абайлана. Сәер карашлар Әхәт Вилдановның (Уфа басмасы) «Мәгрифәт, яктылык йырсыһы» һәм китап ахырында урын алган «Аңлатмалар һәм искәрмәләр» дигән мәкаләләрендә аеруча күзгә ташлана. Ул, мәсәлән, 28 биттә олы галимебез Шиһап Мәрҗани турында язып килә-килә дә, Акмулланың Ш. Мәрҗанигә багышланган мәрсиясе турында көтмәгәндә шундый шаккатыргыч бер нәтиҗә китереп чыгара: «аңа дан җырлауга, аны мәдехләүгә, *идеаллаштыруга* (курсив безнеке.— Ә. С.) корылган». Кемне-кемне, ләкин Мәрҗани кадәр галиҗәнаб шәхесне «идеаллаштырасы» юк, әлбәттә! Аның классик гарәп телендә язып калдырган 30 томнан артык («Казан утлары» № 11, 1982, 165 бит) кульъязма хәлендәге әсәрләре хәзерге көндә Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә саклануы үзе дә безгә күп нәрсә турында сөйли.

Ә. Вилданов икенче урында (12 бит): «Төрмәдән чыккач, Акмулла Карагыз Бутачка барып, җәй буе хәл җыеп ята да көзгә табан Петербурга карап юлга чыга. Юл уңае Казанга сугылып, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек күренекле татар галимнәре белән күрешеп китә»,—ди. Ләкин шул ук мәкаләдә (29 бит) ул үз сүзенә үзе үк каршы чыга: «Мәрҗанинең вафаты мәгълүм булгач, шагыйрь әсәргә мәрсия стилендә берничә строфа өстәп яза:

*Качан ул зат китеп барды,*
*Казан күрке китеп калды,*
*Һәмма ах баб йәтим калды —*
*Жөда булдык, дәрига, аһ!*

—дип Мәрҗанинең үлүенә, *аны тере чагында барып күрә алмавына зур үкенеч белдерә»* (курсив безнеке.— Ә. С.), ди. Авыздан чыккан сүзен галимнең колагы да ишетергә тиештер ләбаса?!

Татар галиме М. Госманов «Мифтахетдин Акмулланың иҗаты һем мирасы» дигән җитди кереш мәкаләсендә Акмулланың, мәсәлән, Шиһап Мәрҗанигә багышланган шул ук «Мәрсия»сенең кереше ахырында: «Аһ, дәрига! Баралмадым кашына аның»,—дип үкенеч белдерсә, галим үлгәч өсталгән бүлегендә Казанда булмавын тагын да ачыграк яза» (23-24 бб.),—дип белдерә. Шулай ук Акмулланың үз сүзләре дә аның Ш. Мәрҗани белән күрешә алмавын аермачык дәлилли:

*Гыйнайәт кылса ни, йа рабб,*
*Үзем байгыш, атым арык:*
*Казан шәһренә бер барып*
*Күралмадым, дәрига, аһ!*

Ә. Вилдановны бу төгәлсезлекләр, әлбәттә, артык борчымыйдыр. Мәсәлән, шул ук «Мәгърифәт, яктылык йырсыһы» кереш мәкаләсендә ул: «М. Акмулла иҗаты үзе бер шигъри мәктәп иде... Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Давыт Юлтый, Шәйхзадә Бабич, Шәфикъ Әминев, Нурмөхәммәт Йомрани кебек бик күп шагыйрьләр тәүге сабакны шул мәктәптә алдылар» (38 бит),—дип яза. Башка башкорт әдипләрендә эшебез юк, әмма Тукай кадәр Тукайны бу урында мисал итеп китерү, минем уемча, бик үк урынлы түгел. Чөнки бу өстәмә дәлилләүне, тикшеренүне таләп итә. Без бу очракта М. Госманов мәкаләсендәге мисаллар белән дә бик килешеп бетә алмыйбыз. Ни өчен дигәндә, олуг Тукайга мең еллык мәдәнияте булган татар шигърияте дөньясында «сабак» алырдай андый «мәктәпләр» үз төбәгендә дә җитәрлек булгандыр. Ни дисәң дә, Идел буе ул дәверләрдә төрки дөньяга күп яктан өлге булырлык мәгърифәт нурларын таратучы үзәккә әверелгән. Шуңа күрә Акмулла, киресенчә, үзе Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов кебек күренекле татар мәгърифәтчеләренең турыдан-туры йогынтысы астында мәгърифәтче-шагыйрь булып җитешә алган. Аннары, М. Госманов үзе дә: «Мәрҗани-Фәезханов фикерләре, татар дөньясы кысаларыннан чыгып, бөтен Россия мөселманнарында мәгърифәтчелек хәрәкәте тернәкләнүгә, гөрләп үсеп китүгә зур өлеш кертте. Моның шулай икәнлеген хәзер Урта Азия һәм Казагстан тарихчыларының барлыгы диярлек таный,—дип белдерә. Бер урынлы сорау туа: ни өчен Ә. Вилданов шул юнәлештә тикшеренеп һәм анализлап, Акмулла иҗатына объектив бәя бирергә уйламады икән? Мөгаен, ул аның максатына туры килмидер. Стәрлебаш татар мәдрәсәсендә (Стәрлебаш бүген дә татар авылы) Акмулланың һәм аның атасының татар те-

лендә укып күзләре ачылганын, укытучысы шагыйрь Шәмсетдин Зәкидән шигърият маһирлыгына өйрәнгән булуын Вилданов сүз арасында әйтеп узса да, ул Шәмсетдин Зәкинең татар шагыйре икәнлеген кереш мәкаләсендә, ни өчендер, искәртергә «оныта!» Акмулла укыган Мәләвезтамак, Әнәч авыллары да саф татар (мишәр) авыллары ич әле! Шул авыллардагы татар мәдрәсәләрендә татарча сабак алып, соңыннан шагыйрь булу дәрәҗәсенә күтәрелгән ләбаса Акмуллабыз! Үз вакытында бөтен Урта Азия, Казагстан төбәкләрендә яшәүче жирле кавемнәргә мәгърифәт нурын сипкән («Казан утлары», 1982, № 11, 102—110 битләр) халыкның теленә һәм үзенә ничек инде хөрмәт белән карамаска мөмкин?! Безнең заман галименең фәнни фикерләү дәрәҗәсе шулай ук колачлы, гадел булырга, милли кысалар эченә кереп бикләнмәскә тиеш иде бит?

Акмулланың бу шигырь җыентыгына бәйле Вилданов «ачышлары», кызганыч ки, югарыда телгә алынганнар белән генә төгәлләнми әле. «Аңлатмалар һәм искәрмәләр» дә, мәсәлән, мондый юлларны очратабыз: «Әгәр дә ул, Мифтахетдин, беренче версиядә әйтелгәнчә, Мөхәммәдъяр казакъ белән Нигъмәтулла хәзрәтнең асравы Бибигөлсем никахыннан туган бала булса, туган авылы Стәрлебаш булыр һәм ул укыр өчен *әллә кайдагы* (курсив безнеке. Ә. С.) Мәләвезтамакка, Әнәч (бу авыл Стәрлебашка нибары 15-20 чакрым гына!— Ә. С.) мәдрәсәләренә барып йөрмәс иде. Ә ул Стәрлебашка нәкъ шул мәдрәсәләрдә байтак «шәкерт шулпасын» татып караганнан соң гына килеп чыга» (210 бит). Бу урында хаклы рәвештә өченче фаразны да китереп чыгарырга җирлек юк түгел! Мәсәлән, Акмулланың атасы буласы кеше казакъ Мөхәммәдъяр Сырдәръя якларыннан килеп, Стәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлагач, шунда өйләнеп, соңыннан Туксанбай дигән башкорт авылына хәлфә итеп тә җибәрелгән булуы бик ихтимал бит? Чөнки ул заманда Стәрлебаш әтрафында указлы хәлфә-муллаларга буш мәхәллә табу бик тә авыр була. Мәгълүм ки, Стәрлебашта яшәүче һәр дүрт кешенең берсе мәдрәсәдә укып белем алган. («Ленин юлы», 12. X. 1981. Стәрлебаш).

Акмулланың атасы Мөхәммәдъяр Бибигөлсем (дөресрәге, Бибиөммегөлсем) атлы асрау татар кызына өйләнгәч, аларның гаиләсендә Туксанбай авылында (Вилданов уйлаганча, Стәрлебашта түгел!) Мифтахетдин исемле баланың дөньяга килүе һәркемне ышандырырлык һәм иң реаль фараз! Шулай ук Акмулланың үз атасы саналган Мөхәммәдъярның да Стәрлебаштан Туксанбай дигән башкорт авылына килеп юлыгуын нәкъ әнә шушы өченче фаразга таянып кына дәлилләргә мөмкин. Юкса, Туксанбай Мөхәммәдъярның туган-үскән үз авылы түгел һәм анда кардәш-ыруы да, туган-тумачасы булуы да билгесез. Шуңа күрә профессор М. Госманов та: «Мифтахетдиннең чын атасы кем булуы мәсьәләсен аның кабере өстенә куелган таштагы язу хәл кыла»,— дип зур ышаныч белән яза. Кызганыч, әлбәттә, башкорт галимнәренең тырышлыгы белән Акмулланың элекке асыл кабер ташы урынына хәзер икенче бер «мифик таш» язып куелган! Мифтахетдиннең үз атасы Мөхәммәдъяр чыгышы буенча Сырдәръя ягыннан. Стәрлебаш мәдрәсәсенә ул белемгә сусаудан килеп юлыккан казакъ баласы! Ә. Вилданов Акмулланы чыгышы буенча фәкать башкорт милләтеннән дип кенә таный. Аның анасы ягыннан татар, атасы ягыннан казакъ икәнлеген дәлилсез генә кире кага. Бу шагыйрьнең чыгышы турында алай берьяклы килү үзен, билгеле, һич тә аклый алмый. Чөнки Акмулла, Вилданов моны телиме-юкмы, татар белән казакъ баласы. Аның күпмедер вакыт башкорт гаиләсендә тәрбияләнүен татар-казакъ галимнәре һич тә кире какмый. Шунысы да игътибарга лаек: киләчәктә туачак «даһи» галим Ә. Вилдановның ачуын чыгарыр өченме, шагыйрь бер әсәрендә үзе хакында:

*...агалар, хәүф итәмен:*
*Анасы нугай кызы димәсәгез,*

—ди.

«Нугай дип,— яза М. Госманов әлеге кереш мәкаләсендә,— киң мәгълүм булганча, казакълар татарларны атаганнар һәм хәзер дә шулай атыйлар». Фән докторы Г. Хөсәеновның безгә язган хатында (8. 04. 83 ел) мисал итеп китерелгән шикле «архив язмалары»на карагәнда, шагыйрьнең үз шигъре күпкә дәлиллерәк, әлбәттә! Шуңа күрә бу очракта, Г. Хөсәеновның үз сүзләре белән әйткәндә, безне «голословно»лыкта гаепләргә маташуы берничек тә үзен аклый алмый. Тик шулай да бернәрсә бәхәссез кала: бу дала бөркетенең канын коючылар, ачы хакыйкать лачынының җанын алучылар, йоклап яткан арбасында аны куй пычагы белән чалучылар «башкорт старшинасы Бурангөлдең кушуы буенча... Гафиәт һәм Дәүли дигән адәмнәр» була. («Башкортстан», 27. IX. 1924). Бу җирәнгеч җинаятьтә казакъ һәм татар халкыннан катнашкан кешеләр булуына берниндидә фараз юк. Без әнә шунысына да шөкерана!

Чөнки Акмулла мирасын «бүлешүчеләргә» бу күп нәрсә турында сөйләргә тиеш.

Ә. Вилданов Акмулла иҗатына бәя биргәндә әдәбиятчылык, фәлсәфә фәннәренең шундый тирән девон катламнарына үтеп керә ки, бу шагыйрьнең мәгърифәтчелек тамырларын хәтта Н. Новиков кебек атаклы шәхесләрнең әхлакый карашлары тәэсиренә китереп утырта. Моның, әлбәттә, ярамаган бер җире дә юктыр югын... Ләкин галим кешегә бу очракта «заман» һәм «чама» төшенчәләрен истән чыгару яхшы микән? Кыргый, ач далада арык аты белән кайгы чаңын кагып гомер иткән Акмулла, чигән хәлендә күченеп йөргән халык акыны Новиковның әхлакый фәлсәфәсен ул елларда кайдан белсен? Кайда моны раслаучы дәлил?! М. Госманов бу мәсьәләдә күпкә тотрыклырак һәм әдәплерәк карашны алга сөрә: «Акмулла, чыннан да, классик төрки-татар әдәби традицияләреннән тыш, казакъ халык шигърияте белән сугарылып, дала шигъри мәктәбендә дә тәрбияләнгән, шул ике башлангычны бергә кушкан

кабатланмас шагыйрь... «Казакъча яздым» дигән әсәрләренең зур өлеше татарча яңгыравын исәпкә алганда, Акмулланың тирән тамырлы татар шигърияте чишмәсеннән мул һәм даими су эчкәнлеге бәхәссез»,— дип яза ул югарыда телгә алып кителгән мәкаләсендә.

«Мәшһүр шагыйремез Акменланың Шиһабетдин әл-Мәржани мәрсиясе вә башка шигырьләре» Казанның «Шәрәф матбагасы»нда басылып чыгуы да М. Госмановның бу китаптагы «Библиографик белешмә»сендә телгә алына. Акмулла җыентыклары, әйтергә кирәк, барысы да борынгы татар телендә дөнья күргән китаплардан санала. Асыл нөсхәләр! Әмма ләкин «Большая Советская Энциклопедия»дә (том I, бит 339), ни өчендер, башкорт әдәбияты белгечләре Акмулла «шигырьләрен төрки (на языке тюрки), ә кайбер әсәрләрен казакъ телендә язды», дип ялганлап күрсәткәннәр. Димәк, башкорт «белгечләре»нчә фикер йөртсәк, Акмулланың татар укучылары өчен Казан басмаханәләрендә чыгарылган барлык китаплары да борынгы татар телендә түгел, ә башкорт һәм казакъ телләрендә язылган китаплар булып чыга! «Большая Советская Энциклопедия»дә урын алган Акмулла иҗаты турындагы материаллар шундый «шома» әзерләнгән ки, шагыйрьнең мирас тарихы белән якыннан таныш булмаган укучылар бу саташуларның ялтыравык юка конфет кәгазенә төрелеп бирелгән ялган икәненә шикләнмәячәк. Мәсәлән, андагы шундый бер җөмләгә игътибарны юнәлтәсем килә: «Аның шигырьләре 1904 елда аерым җыентык булып чыктылар». Бу урында, ирексездән: кайда дигән сорау туачак. Әгәр Уфада, Алма-Атада чыккан дип күрсәтсәң, автор «башкорт шагыйре» булудан мәхрүм кала! Шуңа да карамастан, Акмулланы энциклопедиядә «башкорт мәгърифәтче шагыйре» дип күрсәтергә җөрьәт итә алганнар! Башкорт галимнәре аның атасын да Мөхәммәдъяр дип түгел, ә үги атасы буенча «Камалетдин» итеп күрсәткәннәр. Акмулла китабының Казан матбагасы басмасында: «Мифтахетдиннең чын атасы» кем булуы мәсьәләсен аның кабер өстенә куелган таштагы язу хәл кыла»,— дип әйтелә. Һәм шундагы (Миас шәһәрендә) язудан түбәндәге юллар да дәлил итеп китерелә: «Шәһидләрчә үтерелгән, 1313 (һиҗри) елда сигезенче җомадиел үлядә, җомга көнс кичен (милади буенча, 1895 елның 26 октябрьдән 27 сенә каршы төнгә туры килә), Акмулла исеме белән билгеле Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдъяр хәлфә, тәрбия буенча атасы мелла Кәмалетдин. Тәмам, бетте». (13—14 бб).

Әйтеп киткәнебезчә, бу кабер ташы инде башкорт галимнәренең тырышлыгы белән Акмулланың җәсәде өстеннән алып атылган. Ләкин ул ташның фоторәсеме Казанда чыккан «Акмулла» китабында (12 бит) басылган, андагы язу бик ачык санала. Моның өчен күп миллионлы укучылар исеменнән профессор М. Госмановка ихлас рәхмәтебезне җиткерәсе килә!

Акмулланың атасын архивта сакланган 1816, 1834, 1850, 1859 еллардагы «ревизские сказки» мәгълүматларына таянып, «Туу турындагы таныклык» буенча язу һич тә хакыйкатькә хезмәт итми. Чөнки Мифтахетдинны (Акмулланы), ир бала булганлыктан, үги атасы Камалетдин фәкать имана җире алу өчен генә үзенә угыл ясавы» («усыновление») хәзер беркемгә дә «сер» түгел инде.

Акмулла иҗаты белән кызыксыну татар, шулай ук казакъ һәм башка халыклар матбагачылыгында да киң колач ала бара. Мәсәлән, Акмулланың әсәрләре «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «XIX йөз татар әдәбияты» (1957), «Татар мәгърифәтчелек әдәбияты» (1979) кебек югары уку йортлары өчен төзелгән дәреслек-хрестоматияләргә дә кертелде. Газета һәм журнал битләрендә дә аның иҗаты турында гыйльми хезмәтләр даими басылып тора. Мәгърифәтче шагыйрь мирасының татар әдәбиятында гына түгел, казакъ әдәбияты тарихында да урын алуына, бүтән милләт вәкилләре өчен дә рухи азык, әдәби чыганак булып хезмәт итүенә без, әлбәттә, чиксез шатбыз. Бу мәшһүр затны тудырган бәрәкәтле Урал туфрагына, шулай ук, рәхмәт әйтеп, сокланып баш иябез!

Әдхәт СИНУГЫЛ.

# «ӘЛ-ИСЛАХ» ГАЗЕТАСЫНДА ӘДӘБИ МӘСЬӘЛӘЛӘР

Әдәбият гыйлемендә, милли матбугатыбыз тарихында дәрәҗәле урын тоткан, абруйлы демократик юнәлешле «Әл-Ислах» («Реформа») газетасы Казанда 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр (барлыгы 68 сан) чыккан. Тиражы якынча 700—1000 данәлек бу газета журнал форматында, 16 битле (53 нче саныннан — 4 битле) булып, атнага бер тапкыр Кәримевләр басмаханәсендә басылган. Дөрес, чыгу вакыты тотрыклы түгел, кайчакларда төрле сәбәпләр аркасында атналар буе чыкмыйча да торган. Рәсми мөхәррире һәм нашире итеп Вафа Бәхтиярев саналган.

«Әл-Ислах» газетасы татар шәкертләре органы буларак дөньяга чыга һәм сәяси юнәлешен болай дип белдерә: «... гыйлем юлларыны һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган, сәяси вә икътисади сәбәпләрне үзләренә максуд иткән сәяси хизебләр (партияләр — Р. М.) безнең дусларымыздыр»[1].

Рәсми яктан мөхәррир саналмаса да, газетаның җитәкчесе, рухы, юнәлеш бирүчесе, Фатих Әмирхан булган. Газетаның тоткан юлы, мәсләге Ф. Әмирхан иҗаты һәм тормышының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Ул «Әл-Ислах»та эшләү дәверендә үткен публицист булып җитлегә һәм чыныга, шул чорда аның иҗтимагый-сәяси карашлары калыплаша. Публицист буларак Ф. Әмирхан зур тырышлык күрсәтә, бөтен көчен газетага бирә, җаны-тәне белән яратып, янып эшли. Дусты И. Аитовка язган бер хатында ул, «... минем бөтен удовольствием дә хәзер шул көн саен редакциягә чыгудан гыйбарәт бит: ял итү дә шул, гомер итү дә шул»,— дип яза[2].

Мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукай да Казанга килеп төшү белән «Әл-Ислах»ка тартыла. Ул, «... жалованье-фәлән алмыйча гына, «Әл-Ислах»ның даими сотрудникы кебек редакциягә көн саен диярлек килеп йөри башлый. Шигырьләрен, мәкаләләрен биреп бастыра, үзен редколлегия әгъзасы санап, газетаның бүтән эшләрендә дә катнаша, хәтта әдәбият бүлеген алып бара».[3] Аның да бер хатында: «... монда «Әл-Ислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән (чын күңелдән — Р. М.) сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем»,— дигән сүзләре бар[4].

Ике яшь әдип, шулай «Әл-Ислах»ка зур өметләр багълап, аны тормышлары, идея-максатлары белән бәйлиләр.

Газета тирәсендә шулай ук Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, Кәбир Бәкер, Миргазиз Укмасый, Ибраһим Бикколов, Солтан Рахманколый кебек алдынгы карашлы демократ әдипләр туплана. Аларны «Әл-Ислах» тирәсендә тормышка карашлары, максат, уй-фикерләренең уртаклыгы туплый, берләштерә. Төрле мәсьәләләрне күтәргән мәкаләләре белән Галиәсгар Гафуров-Чыгтай да «Әл-Ислах»та актив катнаша.

«Әл-Ислах» газетасының эшчәнлеген шул еллардагы көндәлек мәктәп-мәдрәсә, шәкертләр проблемалары белән генә бәйләп карау берьяклырак фикер булыр иде. Ислахчылар башлангычны, җирлекне турыдан-туры мәгърифәтчелек идеяләреннән алалар. Алар фикерендә XIX йөз татар мәгърифәтчеләре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйриларның идея-теоретик карашлары чагылыш таба. XX гасыр башындагы «шәкертләр хәрәкәте» исеме астында билгеле булган тарихи-иҗтимагый хәрәкәтнең асылына үтеп керү өчен XIX йөз мәгърифәтчеләре эшчәнлеген искәртеп үтү зарур. «Гадәти мәгънәдәге укыту һәм фәнни эшчәнлектән үзгә буларак, мәгърифәтчелек кешеләрдә барлык иҗтимагый мәсьәләләргә, шул исәптән уку-укыту мәсьәләләренә дә аек мөнәсәбәт тәрбияләүне, үткән тормышның бозыклыгын ачып бирүне һәм кеше аңын иске карашлардан коткаруны максат итеп куя... Мәгърифәтчеләрнең төп хезмәте шунда, феодализмга хас патриархаль мөнәсәбәтләрне фаш итеп, алар халыкның аңын уяталар һәм халыкны революцион идеяләрне кабул итәргә әзерлиләр»[5].

Мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган хәлдә, ул чордагы ислахчы татар яшьләре, уку-укыту мәсьәләләреннән тыш, бөтен татар тормышын үзгәртү тарафдарлары булып җитлегә язганнар иде. XIX йөз мәгърифәтчеләреннән аермалы буларак, алар шак-

---

[1] «Казан, 3 октябрь». «Әл-Ислах», 1907, 1 сан.
[2] Әмирхан Ф. Әсәрләр, 4 т.— Казан, 1986, 258—261 бб.
[3] Тукай Г. Әсәрләр, 5 т.— Казан, 1986, 87 б.
[4] Нуруллин И. «Фатих Әмирхан».— Казан, 1988, 91 б.
[5] Абдуллин Я. Г. «Мәгърифәт нуры ачар...» — Казан, 1987, 44—57 бб.

тый үсеш кичергән, милләт эчендәге капма-каршы сыйныфларны үзара аера төшеп, укыту, әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен дә халыкның социаль хәленә бәйләп, тирәнрәк рәвештә карау мөмкинлегенә якынайганнар. Ислахчылар XIX йөз мәгърифәтчеләреннән бер баскыч өскәрәк, революцион демократизм югарылыгына күтәрелгәннәр иде. Моны газетаның сәяси карашлары, Дәүләт Думасына, «Мөселман иттифакы»на мөнәсәбәтендә ачык билгеләп була.

Ислахчы шәкертләрнең социал-демократларга якын торулары, аралашулары да билгеле. «... Большевиклар, укучы яшьләрнең теләкләре самодержавиене юк иткән очракта гына тормышка ашачагын аңлатып, уртак дошманга каршы көрәшкә тартуга һәм большевиклар партиясе тирәсенә туплауга зур көч куялар»[6]. РСДРПның Казан комитеты тарафыннан «Шәкертләргә» листовкасы моның бер дәлиле булып тора. Социал-демократларның шәкертләргә йогынтысы эзсез югалмый, күпчелек шәкертләр революцион юлга басалар. Мәдрәсә шәкертләре арасыннан Х. Ямашев, М. Вахитов кебек ялкынлы революционерлар, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал кебек танылган демократ каләм ияләре, шагыйрь һәм язучылар, укытучы-педагоглар, сәнгать һәм җәмәгать эшлеклеләре үсеп чыга. Мәдрәсә еллары, шәкертләр хәрәкәте эчендә кайнау аларның иҗтимагый-сәяси карашлары калыплашуында билгеле бер роль уйнаган. «Әмма моннан чыгып, «Әл-Ислах» социал-демократик юнәлешле газета, ә аның фактик мөхәррире большевик булган икән, дигән нәтиҗә ясарга ярамый», әлбәттә[7].

«Әл-Ислах»ның киң пландагы үзгәрешләргә йөз тотуы анда басылган мәкаләләрнең күптөрлелеге белән аңлатыла. Уку-укыту өлкәсендә татар мәктәп-мәдрәсәләрен нигезеннән үзгәртеп, Европа һәм алдынгы урыс уку йортлары дәрәҗәсенә күтәрү, аларда дөньяви фәннәр, туган тел, әдәбият укыту, үзидарә урнаштыру, яхшы кадрлар белән тәэмин итү һәм башка шундый мәсьәләләр күтәрелә.

Газетада әдәбиятка киң урын бирелә; демократик урыс әдәбиятын һәм мәдәниятын пропагандалауга да игътибар ителә. Мәсәлән, «Әл-Ислах»та Л. Толстой, Н. Гоголь, И. Тургеневларның иҗат һәм тормыш юллары турында мәкаләләр басыла. Газета хатын-кыз азатлыгы һәм мәгарифе мәсьәләләрен дә күтәрә, кара реакция котырынган еллар булуга карамастан, ачыктан-ачык искелек, тар милләтчелек кебек тискәре күренешләргә каршы көрәш мәйданына әверелә.

Ислахчыларның дингә мөнәсәбәтләренә килгәндә исә, алар динне бөтенләй инкяр итмиләр, әлбәттә. Тормышның һәр катламына үтеп кергән ислам дине, шәригать, бигрәк тә аның иске караш рухы белән өретелгән өйрәтмәләре әле бу вакытта бик көчле, үз мәсләгендә нык тора. Шул сәбәпле ислахчыларны бу мохиттән аерым хәлдә күрергә тырышу ялгыш булыр иде. Аларның либераль буржуазия белән дә аралары өзеп бетермәүләре аңлашыла. Матди җәһәттән татар мәктәп-мәдрәсәләренең язмышы тулысынча байлар кулында, «Әл-Ислах» газетасы да андый ярдәмгә мохтаҗ иде. Ниһаять, бу дәвердә татар буржуазиясенең бер өлеше мәктәп-мәгариф мәсьәләсендә прогрессив карашта торуын инкяр итү дә берьяклылык һәм тарихи яктан дөрес булмас иде.

«Әл-Ислах»ның һәр санының яртысы диярлек тәнкыйть мәкаләләре һәм әдәби әсәрләрдән торуы редколлегиянең әдәбият мәсьәләләренә җитди әһәмият бирүен дәлилли. Әлбәттә, монда беренче чиратта Фатих Әмирханның әдәбиятка булган мөнәсәбәте чагыла. Ф. Әмирхан «Әл-Ислах»та башлыча «Дамелла», «Ташмөхәммәд» имзалары белән яза, имзасыз мәкаләләрнең дә күпчелеге аңа нисбәт ителә. «Әл-Ислах» газетасында Әмирхан имзалары белән әдәбият гыйлеменә кагылышлы, тәнкыйть-рецензия мәкаләләренең саны 40 тан арта. Аның мәкаләләрендә әдәбиятка карата зур таләпчәнлек, аның иҗтимагый ролен аңлауга омтылу сизелә; әдип тарафыннан халыкчанлык, әдәби осталык мәсьәләләре дә күтәрелә.

«Әл-Ислах»тагы әдәби тәнкыйть мәкаләләренең авторы, нигездә, Фатих Әмирхан булса да, анда шулай ук Кәбир Бәкер һәм башкалар да актив язышканнар. Алар әдәби әсәрләрнең иҗтимагый идеаллары ачык, дөньяви чынбарлыкны чагылдыру көче һәм тел-стиль ягыннан эшләнешләренең камил булулары өчен көрәштеләр. «Әл-Ислах» газетасы алдынгы каләм ияләреннән Г. Тукай, Г. Коләхметев, Г. Камалларның әсәрләрен югары бәяли, яклап чыга һәм пропагандалый. Монда Ф. Әмирханның, Тукай иҗатын чын һәм тулы мәгънәсендә яклаучы һәм саклаучысы буларак, бер мәкаләсен күрсәтеп үтү урынлы булыр. Мәкаләнең тарихы түбәндәгечә. 1908 елда, Казанда урыс телендә чыккан «Волжско-Камская речь» газетасында КТУШ (Казанская Татарская Учительская Школа) укытучысы, цензор А. П. Пинкевичның татар шагыйрьләренә кагылышлы мәкаләсе басыла. Ул Тукай иҗатында шагыйрьлек очкыннары күрә, Мәҗит Гафуриның шул чордагы шигырьләрендә милләтчелек белән мавыгып алу факторларын әйтә. Ә Касыйм Уралец дигән берәү, «Волжский листок» газетасында Пинкевич фикерләренә кискен каршы чыгып, Гафури иҗатын күкләргә чөеп мактый, Тукай шигырьләрен түбәнсетә, килешсез тәрҗемәләр дип атый. Ф. Әмирхан шушы мәкаләләргә нисбәтле рәвештә «Татар ша-

---

[6] «Большевистик сугышчан сүз».— Казан, 1987, 25 б.

[7] Нуруллин И. «Фатих Әмирхан».— Казан, 1988, 94 б.

гыйрьләре»[8] исеме астында Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатларын тикшереп объектив бәя биргән, үз фикерләрен нигезле дәлилләгән көчле мәкалә белән чыга. Бу мәкалә тәэсирендә Хәсән Туфанның Ф. Әмирхан хакында:

Тукайның бу, Фурмановлар кебек,
Комиссары булган, мөгаен!..,—

дип язган юллары искә төшә.

Ф. Әмирхан милләтчелек, реакцион динчелек кебек тискәре күренешләргә катгый каршы чыга, аларны рәхимсез тәнкыйтьли, кайбер күренешләрдән ачы итеп көлә. «Әдәбият базары» түбән дәрәҗәдәге әсәрләр белән чүпләнүе дә Әмирхан игътибарыннан читтә калмый. Мондый әсәрләрнең авторларын ул «матбугат паразиты» дип атый һәм «яңа чыккан әсәрләрне алып укый торгач, фикеремә: эшкә ярамаган күп мөхәррирләремез булганчы, гадәтләре (саннары — Р. М.) азрак булып, эшкә ярый торганрак булсаларчы, диган нәрсәләр килә башлады»,— дип яза. («Әл-Ислах», 1908, 3 апрель, № 25.)

Әдипнең «Әл-Ислах» газетасында «Гарәфә көн төшемдә», «Бәйрәмнәр», «Хакарәт саналган мәхәббәт», «Милләт тәрәккый иттеру», «Картайдым» кебек хикәяләре, «Авырулар галәмендә» шикелле көчле очерклары, күләмле әсәрләреннән «Фәтхулла хәзрәт» повестеның бер өлеше (газетада ул «42 елдан соң уянгач» исеме белән бирелә) басылган. Әмирханның әлеге хикәяләре әдәбиятыбыз тарихында яхшы билгеле, төрле яклап өйрәнелгән. Ә «Фәтхулла хәзрәт» повесте профессор И. Нуруллин тарафыннан Ф. Әмирхан иҗатында гына түгел, бәлки бөтен XX йөз башы татар прозасында иң яхшы сатирик әсәр сыйфатында бәяләнә.

Югарыда саналганнарга Әмирханның «Әл-Ислах»та басылган мәктәп-мәгариф, тел мәсьәләләренә караган хезмәтләрен, театр тәнкыйте, әдәби-музыкаль кичәләргә кагылышлы рәвештә чыккан күп санлы мәкаләләрен, фельетоннарын да өстәсәк, боларның барысы да 21—22 яшьлек бер авыру егет каләменнән чыгуына гаҗәпләнергә мөмкин. Болар Ф. Әмирханның сәяси, иҗтимагый мәсьәләләрдә иртә житлеккән, ачык фикерле, югары интеллектлы, искитәрлек энергияле зур әдип булуын раслыйлар. Әмирханның соңрак әйткән «бер кавемнең рухын аңлау фәкать аның әдәбияты аркылы гына мөмкиндер» диган фикере, аның әдәбиятка житди карашта булуын ача һәм әдипнең үз рухын аңларга ярдәм итә. Ф. Әмирханның «Әл-Ислах» газетасында әдәбиятка мөнәсәбәтле бик күп фикерләре белән килешмичә мөмкин түгел һәм алар әле бүген дә үз мәгънәләрен җуймаганнар.

Г. Тукайның «Әл-Ислах»тагы эшчәнлеге газетаның 3 санынннан «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» исемле мәгълүм мәкаләсе белән башлана. Шагыйрь, белгәнебезчә, бу мәкаләсендә әдәби тәнкыйтьнең максатын, [illegible]леген ачып бирә. Газетаның һәр санында диярлек Г. Тукай шигырьләре урын алган. Тукайның «Әл-Ислах»та катнашуы хакында Гыйльметдин Шәрәф «... «Ислах»ның һәр номерында үзенең бер шигърене булдырырга тырыша, берәр сәбәп белән шигыре булмаса, шуңа үзе пошына, «Ислах»ны үз газетасы итеп карый иде»,— дип искә ала. («Аң», 1914, 3 апрель, 7 сан.) Тукай газетада үз әсәрләрен «Шүрәле», «Мәҗнүн», «Г. Т.», «Феакут» (анограмма, кире яктан килеп шагыйрьнең фамилиясе укыла) имзалары белән чыгарган. «Әл-Ислах»тагы 99 шигъри әсәрнең 50 дән артыгы Тукайныкы булуы гына да күп нәрсә турында сөйли.

Сагыйть Рәмиевнең 12 шигыре, шулар арасында мәшһүр «Таң вакыты», «Авыл» әлеге газета битләрендә дөнья күргән. Шулай ук Миргазиз Укмасый, Зариф Башири, Фәхрелислам Агиев, Хәбиб Исхакый, Ягкуб Мамишев, Габдулла Мостакаев, Маһруй Мозаффария, Мәхмүдә Мозаффария һәм башкаларның шигъри әсәрләре дә биредә урын алганнар. Шагыйрәләрдән аеруча Мозаффария игътибарны җәлеп итә. Аның «Әл-Ислах»та «Уйганыйк, ханымнар!», «Остазбикә абыстайларга», «Ханымнар!» исемле мәгълүм өч шигыре басылган. «Остазбикә абыстайларга» шигырендә ул:

Ярый, ярый сез яшәгез искелектә,
Болакның да даны чыккан ислелектә...
Без, яшь кызлар, бер вакытта куәт табып
Җиһан тулыр безнең илә эшлелектә...»,—

дип яза. Заманы өчен ул, 14 яшьлек укучы кыз бала, шундый тәпле, шактый кыю фикерләр әйтә алган.

Газетада басылган шигъри әсәрләрнең тематикасы төрлечә. Габдулла Тукайның төрле рухтагы шигырьләре һәм Сагыйть Рәмиевнең гыйсъяный әсәрләре белән беррәттән, аларда мәгърифәтчелек идеяләре, ислах мәсьәләләре, шәкертләр хәрәкәте, социаль гаделсезлек, хатын-кыз азатлыгы, мәхәббәт һәм башка темалар да яктыртыла.

Югарыда «шигъри әсәр» диган гыйбарә кулланылды. Чөнки Тукай, Рәмиев кебек шигърият осталарының җәүһәрләре янында «Әл-Ислах»та басылган кайбер «пешеп» җитмәгән, бик сүлпән назым-бәет ише тезмә әсәрләрне шигырь дип атау бик үк дөрес булмас иде. Газета редколлегиясенең шигъриятка мөнәсәбәтен аңлау өчен «Идарәдән җаваплар» рубрикасындагы берничә җөмләне мисалга китерү урынлы булыр.

[8] «Әл-Ислах», 1908, № 34, 17 июнь, № 37, 13 июль.

«Әстерханда Х. Максудига — шигырегез моннан ун ел элек әүвәл язылырга тиеш;
З. Бәширигә — Сезнең шигырь дип язган нәрсәләрегез бик тупас нәзым гына».
(«Әл-Ислах», 1907, 17 октябрь, № 3.)

Ә соңгырак саннарның берсендә, язганнарын бастыруны үтенеп газетага мөрәҗәгать иткән Ә. Б.-гә түбәндәгечә җавап бирелә:

«Саташтым мин, саташтым, юлдан яздым,
Фикрем туздың, хыялланып хактан аздым.
Дүрт стена эчендә бер бинада
Утырам бугай ялгызым гүя букай»,—

дип язасыз. Һә! Букәй шикелле утырасыз икән. Харап икәнсез! Балаларны куркытмагыз тагы». («Әл-Ислах», 1909, 30 апрель, № 67.)

Шигъри, әдәби әсәрләргә булган үз таләпләре хакында Ф. Әмирхан да бер мәкаләсендә ачык итеп болай ди: «хиссияттән мәхрүм, тасвыйраттән мәхрүм сүз тезмәләрен һичвакытта, һичбер милләт әдәбияты үз шигырьләре арасында санаганы юк». («Әл-Ислах», 1909, 26 февраль, № 62.)

Г. Ибраһимов «Әл-Ислах»та «Гыйрфанзадә», «Мөхбиреңез», «Әл-Ислах мөхбире» имзалары астында мәкаләләре һәм хикәяләре белән катнаша. Аның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле күләмле хикәясе газетаның 2 нче санынннан башлап, эзлекле рәвештә 17 санда басыла. Ибраһимовның беренче әсәре булган әлеге хикәя мәгърифәтчелек идеяләренә нигезләнгән.

«Әл-Ислах» газетасының аеруча игътибарга лаек, кызыклы саннары да бар. Ике зур бәйрәм: Яңа (1908) ел һәм мөселман бәйрәме — Корбан гаетенә туры килгән 13 нче сан үзенең тулаем диярлек бәйрәмгә багышлануы белән үзенчәлекле. Бу санда В. Бәхтиярев һәм Ф. Әмирханның бәйрәм уңае белән тәбрик сүзләре, Тукайның «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты», «Фөръяд» шигырьләре, «Бәйрәм, без вә руслар» исемле мәкаләсе, Әмирханның «Бәйрәм вә бәйрәм» һ. б. мәкаләләре урнашкан.

Газетаның 62 саны да башлыча берничә автор катнашлыгында чыккан. Бу санда Ф. Әмирханның Тукай шигырьләренә тәнкыйть мәкаләсе, Кәбир Бәкернең «Үзгәреш» романының бер өлеше, Галимҗан Ибраһимовның Уфада, «Галия» мәдрәсәсендә булган тенту турындагы күләмле язмасы һ. б. бирелгән.

Тулаем алганда, кыска вакытлы чыгуына карамастан, «Әл-Ислах» газетасы матбугатыбыз һәм мәдәниятебез тарихында хаклы рәвештә абруйлы урын били. Татар иҗтимагый фикере тарихын, шәкертләр хәрәкәтен, мәктәп-мәдрәсә реформасы барышын, татар хатын-кызлары хәрәкәтен өйрәнер өчен дә ул, фән белгечләренә бай материал бирә ала. Шулай ук татар әдәбияты, әдәби тәнкыйте, мәдәният-сәнгать үсеше өчен «Әл-Ислах»ның зур өлеш кертүе әдәбият тарихын өйрәнү юлында материалларга бай чыганак булуы бәхәссез.

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев кебек авторларның анда актив катнашулары бу газетаның әдәби үсештә нинди урын биләвен тәгәлрәк аңларга ярдәм итә. Бөек әдипләребезнең исемнәре белән бәйле «Әл-Ислах» газетасы авыр реакция елларында да демократик әдәбиятка киң мәйдан биргән, милли мәдәният, әдәбият, сәнгать буенча мөһим мәсьәләләрне күтәреп чыккан һәм шушы юнәлештә үз йөзен ахыргача саклап кала алган.

Матди кыенлыклар, цензура кысулары нәтиҗәсендә «Әл-Ислах» газетасы, 1909 елның 22 июлендә соңгы саны чыгып, туктый. «Әл-Ислах»та эшләү дәверендә ныклы чыныгу алган, каләмнәре шомарган әдипләребез милли матбугатыбызның күпсанлы газета-журналларында публицистик һәм иҗади эшчәнлекләрен җәелдерәләр. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовларның халык тарафыннан зур хөрмәт казанган «Аң» журналын оештыруда зур өлеш кертүләре, анда актив катнашулары моңа ачык мисал булып тора.

**Раиф МӘРДАНОВ.**

## Китап күзәтү

# ХУШЛАШЫРГА АШЫКМА!

Шагыйрьләрне кемдер, кайчандыр елгалар белән чагыштырган. Әйе, тау елгалары сыман шаулап, шашкын хисләре шигъри калыпларга сыя алмый ташыган шагыйрьләр бар... Үзәнлектәге тын елгага охшаш сабыр, салмак агышлы иҗат ияләре дә бар... Бүген шуларның беренчесе өстенлек алды. Чөнки чорыбыз шундый. Заман бүген андыйларга күбрәк мохтаҗ. Халык язмышы, милли мөстәкыйльлек идеяләре йөрәкләргә, уй-хыялларга гына бикләнеп яшәүдән азат булып, ташып-ургылып митингларга чыкты, парламентларга үтеп керде. Шагыйрьләр сүзе халыкны мәйданнардан азатлыкка чакырды. Шигъриятгәге трибунлык, кайнарлык белән ачыргалану шуның нәтиҗәсе. Хәзер «заманча шигырь» дип күпләр чыгыш ясый. Сүз дә юк, бик борчулы мәсьәләләрне күтәрә алар. Ләкин бер нәрсәне онытмыйк әле. Шигырь, чын шигырь бер генә көнлеке була алмый. Заманның үткән формасы бар, бүгенгесе, киләчәк заман бар... Бәлки, гражданлык позициясен тоташы белән шигырьгә күчерергә кирәкмидер? Ярый да әйтер сүзең туар буыннар җанында да кайтаваз булып яңгырый алса? Әнә, Дәрдемәнднең «Кораб», Тукайның «Китмибез!» Рәмиевның «Таң вакыты...» хакында бәхәсләр бүген дә туктамый, бүген дә аларда без эзләгән күп сорауларга җавап табарга мөмкин. «Заманча» төшенчәсе, ай-һай, мәкерле, шома нәрсә бит ул.

Шигъриятнең гасырлар буе килә торган үз аһәңе, үз сурәт-тасвирлары бар ич әле: Мәхәббәт... Сагыну... Хыял... Моң... Табигать... Хәтер... Яшьлек... Сәясәт, иҗтимагый хәл көнләп түгел, сәгатьләп үзгәргән бер чорда без ул кануннарны да онытып бетермәсәк иде.

Фәннур Сафин — иҗат кыйбласын әнә шул мәңгелек темаларга юнәлткән шагыйрьләребездән. Аның «Чәчәк гомере» исемле китабы моны янә бер кат раслый. Юк, анда борчулы, гасаби дөнья мәшәкатьләреннән читтә торырга, хис ышыгына качарга чакыру түгел. Менә тыңлыйк әле:

*Ирекле кош, ярасы кош,*
*Канатларын кем кискән?*
*Бар дөньяга ал кан ява,*
*Кем кискән соң, кем икән?!*

Йәгез, нәрсә хакында бу, кем турында? Лирик геройның шәхси кичерешләреме? Бәлки ил, милләт язмышыдыр? Миңа шулай тоела. Сәяси телдә гаепләүләр көчәйгән бер вакытта халкым язмышы өчен борчылу тоям мин әлеге юллардан. Шигырь, әнә шул рәвешле, меңнәрнең мең төрле борчуларына җавап була алганда гына шигырь дип аталырга хаклы. Яки:

*Ярсып-уксеп уз ярларын*
*кыйный Чулман...*
*Безне курел Болгар шулай*
*елый сыман!..*

Тарихыбыз , кан-яшьтән аралансын, безгә өмет белән карый алсын өчен көрәшкә күтәрелгән бер дәвердә тынычланудан сак булырга чакырган шигъри оран итеп кабул итәм мин бу сүзләрне.

Ләкин... Дөньяның «ләкине» дә бар шул әле. Китапта бирелгән аннотациядә «гражданлык пафосы белән сугарылган җылы, ягымлы, хисси шигырьләр» вәгъдә итсә дә, кызганычка каршы, укучылар белән сөенеп-сокланып уртаклашырлык әсәрләргә еш тап булмадым мин. Әлбәттә, бу минем шәхси фикерем, шәхси позициям. Шулай да... Ә бәлки минә будыр? Бер уйласаң бу заманда еллар кыска, чорлар кыска,— ди автор «Таң» шигырендә һәм шундый нәтиҗә ясый:

*Шул тизлектә сиңа, кеше,*
*Үз-үзеңне тапмак кирәк.*
*Шуны сөйләп таң атканда,*
*Ничек йоклап ятмак кирәк?!*

Бәхәсләшмим, шагыйрьнең бер генә килгән гомердә гамьсез булмаска чакырган фикере игътибарга лаек. Ләкин С. Рәмиевның: «Таң вакыты... Татар йоклый... Мин, йокысыз, уянам. Уянам да, тиле кебек тик бер үзем уйланам»,— дигән мәгълүм шигыреннән соң инде минем тарафтан бүгенге көн авторының югарыдагы фикере гап-гади тәэсирсез сүзләр җыелмасы буларак кына кабул ителә. Уйны уйдырып сала алмау күпсүзлелеккә китерә, вак фәлсәфәләргә этәрә.

Хәер, бу фикергә нокта куеп, сүз сүрешен башка юнәлешкә күчерик әле. Фәннур Сафин поэзиядә башлыча лирик шагыйрь буларак танылган. «Совет Татар-

станы язучылары» (1986) дигән биобиблиографик белешмәдә дә шагыйрьнең «шигырьләре яшьлек романтикасы белән мул сугарылган булып, үз замандашларының күңел кичерешләре, туган җир, туган табигать турында лирик уйланулар рәвешендә кабул ителә»,— дипраслана.

Иң әүвәл Ф. Сафин — мәхәббәт җырчысы. Табигый ки, шигърияттә азмы-күпме каләм тибрәткән бер шагыйрь дә сөю хисе турында язмый кала алмады. Бер караганда бик җиңел юл кебек бу, чөнки — гаять отышлы. Әмма иң авыры, иң кыены да шушы. Әлеге мәңгелек темага никадәр әсәр багышланган, һәм шул хис ташкынында үз йөзеңне югалтмау өчен шагыйрьдән икеләтә, өчләтә шигъри талант сорала. Такташка ияреп әйткәндә: «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта». Ф. Сафин да бу җәһәттән үз сүзен ныклы, мәртәбәле итеп әйтүгә дәгъва кыла. «Таһир буласым килә минем, Таһир буласым килә!» — дип тәкрарлый автор бер шигырендә. Хуш, шулай да булсын, ди. Димәк лирик герой мәхәббәттә «пешка» гына булып калырга теләми, һәм шул җөмләдән бу хисне дә яшәешнең зур бер көче, төп тереге итеп таный:

*Мәхәббәт, нәфрәт һәм гуманлык...*
*Уйлап кара әле син яңа:*
*Шушы өчлочмак тирәсендә*
*Әйләнә дә дөнья әйләнә.*

Күрәсең, шагыйрьгә сөю, гашыйклык турында язу бик тә ошыйдыр, ул аны әллә нинди формаларда, чәчелә-сибелә яктыртырга тырыша. Шигырь исемнәренә генә игътибар итик: «Янып сөю», «Чын сөю», «Шаярту һәм мәхәббәт», «Мәхәббәт алмасы», «Мәхәббәтнең кадер кичендә» h. б. Мондый ташкыннан хәтта бер мәлгә югалып каласың. Китапта «хисләр яңа, чәчәк атып килгән мәхәббәт тә, дуслар, өр-яңа»,— дип шигърияттә инде мәгълүм кагыйдәне раслаудан алып, «мәхәббәтсез яшәп булды әле, сөю белән инде яшәрбез!»,— дигән сәер пародоксларга кадәр очратырга мөмкин. Ирексездән шундый тәэсир кала, автор бу отышлы темага чәтертән кебек ябышып, аны рәхимсез рәвештә эксплуатацияли торгач, үтә фәкыйрьләндерә, хисси көчен кимәтә. «Мәхәббәтнең белик кадерен, калдырмыйкчы аның хәтерен», яки «мәхәббәттән дә кадерлерәк җирдә ни бар тагын әйт, йөрәк?!» кебек тапталып-шомарып беткән гыйбарәләр арасыннан чак-чак кына шигъри энҗеләрне күреп өлгерәм:

*Мәхәббәттән узебез качканбыз*
*һәм без шуңа тиле төслер.*
*Кадер кичен кичтек Сөюнең,*
*Ә андыйлар изге кешедер.*
*Бәлки менә безнең ишедер!*
*Безнең ишедер...*

Автор кайчак шигъренең җегәре кимүен үзе дә сизә булса кирәк, ул илһам чыганагы, иҗат дәрте өмет итеп туган ягына, туган җиренә күз төби. «Сары айга карап сокланган» шагыйрь сагыну хисен тулы бер тезмәгә тарата: «Авылым», «Моң», «Туган якка», «Кайтчы, җырым!», «Кышкы авылга», «Туган җирем», «Туган якта»... Мин тагын аптырашта, автор һәрберебез өчен изге булган туган якны сагынуы турында сөйли, әмма ул мотив күп санлы шигъри юллар эчендә шулкадәр ваклана, шулкадәр бүлгәләнә ки, зиһен төп аһәңне эләктерә алмый изалана. «Моң» шигырендәге «Тынгы бирми, димәк, яши миндә һәм чакыра туган ягыма», яки «Еллар аша тарта җанны, тарта төнге утларың!» («Туган якка») дигән юллар берүк фикернең куәтсез тердәшләре булып күзалланалар. Шулай да авторның шактый ныклы даимилек белән бу темага мөрәҗәгать итүе иҗат дәрәҗәсеннән ризасызлыгына бәйле дип әйтергә нигез бар:

*Сукмак сабып кайтып киләм,—*
*Үзән аркылы юлым...*
*Үзен эзләгән улыңа*
*Фатиха бир, авылым!*

Шагыйрь эзләнә, борчыла, үз-үзеннән канәгатьсез калып, бер читтән икенчесенә ташлана. Сөенеп укый торган шигырьләре белән беррәттән тәэсирсез, күңелне кузгатырга сәләтсезләре дә булу шуның нәтиҗәсе. Автор моны үзе дә тоя: «Тау тау инде, ә без үзәннәр...» — дип аклана ул «Үзән» шигырендә. Монысы — аяныч, сискәндерә торган халәт бу. Газаплы эзләнүләр каршында аптырап, чарасыз калган күңел җиңелүен таный түгелме? Шагыйрь исә бөтенләй тынычланган ахыры: «Без атлаган юлдан да яктырак, кояшлырак юллар бар микән!» — дип үзен дә, укучыны да ышандырырга тырыша. Ә тынычлану — хәтәр, тынычланудан гамьсезлеккә бер генә адым. Туган җир, туган төбәк чынлап та җуя барган идеалны яңартырга, яисә яңасын табарга ярдәм итәрме? Автор үзе моңа уңай җавап бирә: «Җанга матурлык тула,— Туган җирем шул була!» Ләкин шәхсән мин үзем моңа шикләнеп карыйм, шагыйрьнең иҗади көч, илһам дәрте табуы турында тора кубып раславы эзләнүләрдән гаҗизлеген яшерергә теләве генә бугай. Бу исә котылгысыз ясалма пафоска, масаю белән өретелгән горурлануга китереп чыгара:

*Синең өчен мин дә чәчәк,*
*И киләчәк — куз алмам!..*

Ашыкма, шагыйрь! Үз-үзеңә бәя бирергә ашыкма. Әйтәсең бит: «Инде хәзер тынычландык, күңелләр генә елдам»,— дисең. Әнә шул күңел учагының сүнергә өлгермәгән күмерләрен урләтеп, гамьсезлек пәрәвезе белән урала башлаган тынычлыгыңны ялкыннарыңда көйдерү зарур.

Ә мин үзем Фәннур Сафинның шигъри бәйгедә дөрләячәгенә ышанам. Чөнки аның бу китабындагы иҗаты ниндидер эчке яшерен моң, ачынулы сагыш белән сугарылган. Вакыт-вакыт ул хис калкып та чыга, әмма тиз югала: әлегә ул зәгыйфь, көчсез. Китапның соңгы бүлеге нәкъ менә «Хушлашу түгел бугай бу...» дип атала. Мин монда зур мәгънә күрәм: шагыйрьнең җанында борчылу бар, ачыну сизелә. Биредә инде ясалма үзбәяләнүнең эзе дә юк. Автор бу җыентыгына шактый кайтыш әсәрләр урнашуын акланып та, бераз үпкәләп тә танырга мәҗбүр:

*Узганнарда яшим,—*
*Тоташ бер хәтер мин.*

Һәм ул тәэсирсез шигырьләре өчен гафу үтенгәндәй, элеккеге иҗатыннан бер үрнәк булган «Музей ачтым...» дигән, бер укуга ук җаныңны биләп алучы шигырен урнаштырган. Әйтерсең лә шагыйрь үзе дә тәнкыйть күзлегеннән ике чор иҗатын чагыштырып карарга алына. Бу очракта инде ул кырыс, гаять таләпчән укучы буларак чыгыш ясый. Кая ул тынычлану, кая ул үз-үзеннән канәгатьлелек!

*Зая гомер?!*
*Шуның өченме без килдек җиргә?*
*Уйласаң бер.*
*Ни алдык та әле,*
*Ни бирдек без илгә?*
*Канатлымы без күгебездә?*
*Хыянәт итмибезме үзебезгә?..*

Инде шагыйрь тынычлыгын җуйганда, мин — укучы сабырланам. Җанында ачыргалану ялкыны дөрләгәндә без Ф. Сафиннан әле күп шигъри җәүһәрләр көтәргә хаклыбыз. Бары аңа кушылып әйтәсе генә кала: «Сүз хәнҗәрен ал кыныннан — тутыкмасын!»

Фәннур Сафинның киләчәк иҗатына өмет белән карыйм, дидем. Эзләнгән, газаплы ачыргалану белән, үҗәтләнә-үҗәтләнә үз кыйбласын табарга тырышкан шагыйрьдән күпне көтәргә минем тулы хакым бар. Бары тик чарасызлыкка, өметсезлеккә юлыгып туктамасын да, вакытыннан элек иҗат-корәш мәйданыннан «үкчә күтәрергә» ашыкмасын иде.

Шигъри бәйге белән хушлашырга ашыкмыйк, Шагыйрь!

Фәрит БӘШИР.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1991 ЕЛДА ЧЫККАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ.

**Татарстан ССР Министрлар Советы. ТССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты карары. № 6**

**Татарстан республикасы Язучылар берлеге, Әдәби фонд уставлары һәм Кабул итү коллегиясе турында положение. № 7**

### ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахунов Г. **Гомер юлы.** *Роман.* № 1, 2
Батулла. **Сөембикә кыйссасы.** *Роман.* № 8, 9
Баянов Ә. **Җәй белән җәй арасы.** *Повесть.* № 6
Газизов Р. **Күккә ябышкан болыт.** *Хикәя.* № 4
Галиев Ә. **Һәр солдатның үз уе.** *Повесть.* № 5
Гыйльми Ф. **Зәйтүнәкәй, акчарлагым.** *Хикәя.* № 9
Горский С. **Явыз Иванның хатыннары.** № 7
Зәйнуллин З... **Сугыш алды малайлары.** *Повесть.* № 4
Кутуй Р. **Бер дә бер көзне.** *Повесть.* № 12
Кәримова Н. **Карурманнан чыккан юлчылар.** *Кыйсса.* № 10
Латыйфи Ф. **Хыянәт.** *Роман.* № 11, 12
Маннап Ш. **Ибрай абзый хикәятләре.** *№ 3*
Мәһдиев М. **Ачы тәҗрибә авазы.** *Истәлекләр.* № 1, 2
Низамиев Р. **Кар кеше.** *Повесть.* № 6
Садриев Ф. **Адәм әүлиясе.** *Юмористик повесть.* № 3
Садыйков З. **Ясалма чәчәкләр.** *Повесть.* № 4
Тавлин Г. **Буран.** *Хикәя.* № 4
Тавлин Г. **Афәт.** *Роман.* № 10, 11
Фазылҗанов Ә. **Сыерчык бураны.** *Хикәя.* № 1
Фәттах Н. **Кичү.** *Роман.* № 7, 8
Хуҗин М. **Чөй.** *Повесть.* № 5
Хәмидуллин Л. **Офыктагы рәшәләр.** *Эссе.* № 2
Хәсәнов Г. **Шәфәкъ чыпчыгы.** *Парча.* № 6
Әмирханов М. **Саба җиле.** *Хикәя.* № 6
Әминов Ю. **Кунактан кайтканда.** *Хикәя.* № 12

### ШИГЪРИЯТ

Аймәт Р. **«Сукыр тәкә»** *Шигырьләр.* № 6
Арсланов Н. **Төшмим.** *Шигырьләр.* № 4
Афзал Г. **Күңел кошы.** *Шигырьләр.* № 5
Булатова К. *Яңа шигырьләр.* № 3
Бужурова Л. **Зарыгу.** *Шигырьләр.* № 3
Бәширова Ф. **Кошчык.** *Шигырьләр.* № 3
Вәлиева Р. **Дөреслек.** *Шигырьләр.* № 3
Габдрәхим Ф. **И горур зат!** *Шигырьләр.* № 9
Гадел Ә. **Хат.** *Шигырьләр.* № 12
Газизов Р. **Каенлыкта үлән тамырлана.** *Шигырьләр.* № 11
Ганиева Т. **Истанбуллар искә сирәк төшә.** *Шигырьләр.* № 3
Гатауллин Р. **Үз чорыңны ничек танырга.** *Шигырьләр.* № 9
Гаташ Р. **Гомер-баг капкасын ачсам...** *Шигырьләр.* № 3
Гыйззәтуллина Ф. **Күкеле паровозлар.** *Шигырьләр.* № 9
Гыйләҗев И. **Кешелегем калды елап...** *Шигырьләр.* № 4
Гәрәй Р. **Күгебезне нурлап.** *Шигырьләр.* № 5
Зәйдулла Р. **Матәм.** *Поэма.* № 1
Измайлова Н. **Улларыма исем куштым.** *Шигырьләр.* № 4
Иксанова И. **Белми әле дөнья.** *Шигырьләр.* № 3
Ибраһимов Х. **Стефани.** *Шигырьләр.* № 6
Идиятуллин Р. **Ачлык баскан елда.** *Шигырьләр.* № 9
Кудаш С. **Бер саплам җеп.** *Шигырьләр.* № 12
Латыйп К. **Шигъри газап.** *Шигырьләр.* № 12
Мансуров З. **Хозыр галәйһес-сәләмне эзләү.** *Поэма.* № 2
Мингалим Р. **Югалган яшен.** *Шигырьләр.* № 10
Миңнуллин Р. **Авыл.** *Шигырьләр.* № 7
Моратов Г. **Аран.** *Шигырьләр.* № 11
Мостафин К. **Кем җаннары яши икән.** *Шигырьләр.* № 8
*Муллагалиев С.* **Милләтем.** *Шигырьләр.* № 10
Мусина В. **Әй.** *Шигырьләр.* № 9
Мөдәррисова Х. **Урман.** *Шигырьләр.* № 11
Мөслимова Ф. **Ике фәлсәфә.** *Шигырьләр.* № 3
Мөхәммәтшин Г. **Тәрәзәләр язга карый.** *Шигырьләр.* № 2
Нәзиров М. **Бу дөньяда бар шул әле...** *Шигырьләр.* № 9
Нәҗми Н. **Халкым арбасы.** *Шигырьләр.* № 1
Разов М. **Бөре кебек.** *Шигырьләр.* № 6
Рәхмәтулла С. **Очрашулар.** *Шигырьләр.* № 9
Рәхимова Б. **Кояшка күтәрик.** *Шигырьләр.* № 12
Садыйкова Л. **Сөлге чигәм.** *Шигырьләр.* № 3
Сафина Н. **Егет җыры.** *Шигырьләр.* № 6
Сибгат К. **Кемнәр дәшә безгә...** *Шигырьләр.* № 7
Синугыл Ә. **Кырымда гына.** *Шигырьләр.* № 5

Суфияров Ф. **Ир итте.** *Шигырь.* № 9
Султи Р. **Жырым минем.** *Шигырьләр.* №6
Таңчулпан. *Шигырьләр.* № 3
Фәйзуллин Р. **Казан алды.** *Шигырьләр.* № 10
Харис Р. **Тормыш алда гына.** *Шигырьләр.* № 5
Хисамов Н. **Дуртьюллыклар.** *Реквием.* № 12
Шагыйрьҗан Л. **Икенче микрофон.** *«Йөрәк авазы поэмасыннан»* № 7
Шәехов Ф. **Йолдыз булып.** *Шигырьләр.* № 6
Шәрифуллина Э. **Тәмуг кисәве.** *Поэма-мәрсия.* № 8
Шәфикова К. **Тел бозылды.** *Шигырьләр.* № 9
Әгъләмов М. **Кереш.** *Шигырьләр.* № 8
Әминова Н. **Дингездән түгел, йолдыздан.** *Шигырьләр.* № 9
Әхмәдиев Н. **Шәрык мизгелләре.** *Шигырьләр.* № 11
Әхмәтҗан Р. **Кулгә төшкән идем.** *Шигырьләр.* № 4
Әхсәнов И. **Җирәбә.** *Шигырьләр.* № 12
Җиһангирова Ш. **Бер адымга гына.** *Шигырьләр.* № 3
Яруллин Ф. **Коткарыгыз.** *Поэма-монолог.* № 9
Яхин Ф. **Тормыш, тормыш...** *Шигырьләр.* № 6
Юныс Р. **Качалар куселәр.** *Шигырьләр.* № 10

## ДРАМАТУРГИЯ

Хәмид Р. **Актамырлар иле.** *Трагедия-реквием.* № 10.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Солнцев Р. **Төнге сорау.** *Шигырьләр.* № 12.
Свирка Ю. **Яфракларны коеп йөри көзен.** *Шигырьләр.* № 12.
Сенизәль М. **Төнге теләкләр.** *Шигырьләр.* № 12.

## ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН

Камалов Х. *Ихласлык.* № 10.
Рәхимов Р. **Чишмә бурасы.** *Шигырьләр.* № 10.

## ЮМОР-САТИРА

Зарипов Р. **Мин кемнән ким?** № 4.
Шакирҗанов А. **«Су анасы» гаепле, иптәшләр!** № 4.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Әйди Т. **Исәнме, Гагаузстан!** № 5
**Гагауз шагыйрьләре бездә кунакта.** № 5

## ӘДӘБИ МИРАС

Агиев Ф. **Татар җыры.** *Шигырьләр.* № 1.
Габидов Х. *Шигырьләр.* № 1.
Зәйнуллин Җ. **Нәсыйхәтләр вә мәслихәтләр.** № 1.
Гайнетдинов М. **Тукайның «адашкан» шигыйрьләре.** № 4.
Патии К. *Шигырьләр.* № 11.
Киләчи Б. **Диңгез.** *Шигырь.* № 11.
Кәрибов К. **Ялындыра.** *Шигырьләр.* № 11.
Миннегулов Х. **Үткән гасырларның бүләге.** № 8
Мирзанов Б. **Гашыйк.** *Шигырьләр.* № 11
Сараи С. *«Гөлстан бит-төрки».* № 8
Рамазанов Г. **Минем фәһмем.** *Шигырьләр.* № 11
Рәмиев З. **Гасыр башы шигърияте̇ннән.** № 1
Сабиров С. *Авыр язмыш (С. Җәләлнең тууына 100 ел)* № 3.
Сагыйди Ә. **Бәхтемә.** *Шигырьләр.* № 11
Юмаев Җ. **Вөҗдан.** *Шигырьләр.* № 11.
Җәләл С. **Дим буенда.** № 3.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Бәширов Г. **Гыйбрәт.** № 1
Вәлиев Д. **Ничегрәк яшәргә соң?** *Уйланулар.* № 7
Вәлиев М. **«Идел» өчен көрәш.** № 7
Галиуллин Т. **Замана балалары.** № 11
Дәүләт Н. **Гәрчә анда тумасам да...** № 1
Еники Ә. **Кем җаваплы?** № 4
Зарипов М. **Бал нигә кыйммәт?** № 9
Мөслимов А. **Рәсми әләк.** № 7
Миңнебаев Т. **Татар халкының хәлләре: икътисади тамырлары, сәяси тормышта чагылышы.** № 10
Нуруллин И. **Әдип эзләреннән — Төркиядә.** № 3
Рәхим Г., Хәсәншин Б. **Сулар һаваң бармы?** № 6
**Татарстан: кичә, бүген, иртәгә. Түгәрәк өстәл янында галимнәр, язучылар, сәяси эшлеклеләр.** № 6
Хисмәтуллин Р. **Аһ, сызлый, сызлый җаным.** № 2
Хәсәнов А. **Бәрәңге.** № 10
Шабаев М. **Аджимушкай каһарманнары.** № 5
Юнысов В. **Ибраһим Гарәп чәйханәсе.** № 12
Ягъфәров Р. **Хәлләрең ничек, мәктәп?** № 4
Әхмәтова Ф. **Казанда таңнар ни төсле?** № 2

## ҮТКӘН МӘСЬӘЛӘ

Абдуллин Я. **Чишелмәгән төеннәр.** № 6
Маннапов С. **«Сәлам белән, Николай Иванович...» яки тапшырылмаган хатлар жанрында бер бәян.** № 1

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Бәширов Ф. **Егерме беренче ел авазы** № 1
Гайнетдинов М. **Такташ һәм такташлык турында.** № 1
Галиуллин Ф. **Күзгебездә ниләр чагыла?** № 3
Губарь А. **«Без бер күкнең йолдызлары».** № 12
Гыйләҗәв А. **Илче.** *(И. Салаховка 80 яшь.)* № 8
Ихсанова Л. **Аның сабаклары.** № 1
Ибраһимова Ф. **Ул галим дә иде.** *(А. Шамовның тууына 90 ел тулу уңаеннан).* № 3
Мостафин Р. **Тәнкыйтьченең акылы.** № 2
Мостафин Р. **Бер «зарарлы әсәр» тарихы.** № 5
Мортазин М. **Шигырьләрдә заман төсмере.** № 6
**Олы шагыйребез бар.** № 5
Сәхапов Ә. **Заманга җавап бирәбезме?** № 9
Садыйкова А. **Осталык тамырлары — халыкта.** № 3
**Тукайлар рухы** *(А. Хәлим белән әңгәмә)* № 4
Юныс М. **Исабәт.** № 2
Әгъзамов Ф. **Безгә нинди журналистика кирәк?** № 6
**Әйдә халыкка хезмәткә.** *Язучы М. Мәһдиев белән әңгәмә.* № 8
Әхмәтҗанов Р. **Үзебезнеке.** № 5

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Бәшир Ф. **Хушлашырга ашыкма!** № 12
Гайнетдинов М. **Бабич һәм аның яңа китабы.** № 11
Гомәрова З. **Иртәгә дә яшисе бар.** № 8
Кәшфиева Л. **Күрше тавыгы күлә.** № 10
Рамазанов Г. **Заманыбыз шундый булгач.** № 10
Сафин Ф. **Зөлфәтнең яңа китабы.** № 1
Хәлиуллина Р. **Каты бәгырьле кешеләр.** № 5
Шәрипов Р. **Хикәяне күңел сагынган.** № 4
Әмирхан Р. **Җилгә карап кыйбланы үзгәртмик.** № 9
Әхмәтҗанов М. **Хәбәрдарлык чорында язылган хезмәт.** № 3

## СӘНГАТЬ

Арсланов Г. **Халык улы.** № 7
Габделкаюмов Х. **Горький өлкәсе җырлары.** № 1
Ихсанова Л. **Язмышлар дәфтәре.** № 5
Монасыйпов Ш. **Бер канаты җыр иде.** № 7
Тимбикова К. **Сәхнәләрдә — йолдыз.** № 3
Фәхретдинов Р. **Хәтер** *(Ф. Вәлиевнең тууына 70 ел),* № 6

Яруллин Р. **Авылның җиденче чишмәсе.** № 9
Яһудин Ә. **Шигъри сүз куәте.** *(Истәлекләрдән өзек).* № 4
Хәмидуллин Л. **Мирхәйдәр Фәйзи эзләреннән.** № 11

## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Зарипова Р. **Ишан оныгы.** № 9
Муллагалиев С. **Күзләремне ачты.** № 9
Төхфи Х. **Язмышлар һәм ялгышлар.** № 9
Юныс М. **Сөенеп укыдым...** № 9
**Укучы сүзе.** № 3, 9
**Укучы фикере.** № 6

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я., Мөхәммәтдинева Р. **Англия журналы татарлар турында.** № 12
Абилов Ш. **Низаминың үлемсез иҗаты** № 12
**Гаяз Исхакыйның Ф. Әмирханга, хаты** № 2
Госманов М. **М. Гафури мирасыннан.** № 6
Заһидуллин И. **Жыеннар тарихыннан.** № 4
Зәкиев М. **Халкыбыз турында тулы белем.** № 10
Ибраһимов Ф. **Иж-Буби шәкерте.** № 9
Исхакый Г. **Мәгънәви васыятем кебек калсын.** № 5
Камал Т. **Татар рухы.** № 3
Миңнуллин Җ. **Латин әлифбасы.** № 2
Миңнегулов Х. **Гаяз Исхакый хаты.** № 5
Мәрданов Р. **«Әл-ислах» газетасында әдәби мәсьәләләр.** № 12
Мәһдиев М. **Өлкән әдип белән очрашулар.** № 10
Мөхәммәтдинев Р. **Татар мәдәниятендә яңарыш.** № 12
Нәфыйков Р., Вәлиев Ф. **Әйтикиннәр нәселе турында.** № 5
Синугыл Ә. **Бер мираска ике караш.** *(Акмулланың тууына 160 ел.)* № 12
Сәгадеев А. **Солтангалиев һәм Советлар Россиясенең милли сәясәте.** № 4
Хисамов Н. **Яңача фикерләү һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсьәләләре.** № 7

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Фәхретдинов. Р. **Татар углы татармын.** № 9

## ЮБИЛЕЙЛАР

**Аның җылы карашы.** *(Сибгат Хәкимнең тууына 80 ел).* № 12
Баянов Ә. **Ихласлык** *(Г. Әпсәләмовның тууына 80 ел тулуга карата).* № 12
Гаташ Р. **Өлкән дус — яхшы кеше турында** *(Шагыйрь Зәки Нурига 70 яшь)* № 12

ГАЛИШЕР НӘВАИНЫҢ ТУУЫНА 550 ЕЛ

Абилов Ш. Нәваиның шифалы йогынтысы. № 7
Нәваи Г. Бөекләрнең таң калулары. «Хәйрәтел-әбрар» дастаныннан. № 7

ЮНЫС ӘМРӘНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Зәйбәк Н. Миллионнар күңелендә. № 4
Әмрә Ю. Шигырьләр. № 4

И. ГАСПРИНСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Сафаров Р. Төрки халыкларның уртак каһарманы. № 3
Әмирхан Ф. Олуг милләтче турысында кечкенә бер хатирә. № 3

СОЛТАН ГАБӘШИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Салитова Ф. Югалмаска тиеш бу моңнар. № 5

Н. ЖИҺАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Ак рояль хуҗасы. № 1

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Сәрвәр Әдһәмованың туула 90 ел. № 4

КОТЛЫЙБЫЗ

Нил Юзиевка 60 яшь. № 1
Адлер Тимергалинга 60 яшь. № 1
Басыйр Рәфиковка 70 яшь. № 3
Рәдиф Гатауллинга 50 яшь. № 3
Фоат Садриевка 50 яшь. № 3
Нурислам Хәсәновка 50 яшь. № 3
Рәшит Әхмәтҗанга 50 яшь. № 4
Рәшит Гәрәйгә 60 яшь. № 5
Радик Фәизовка 60 яшь. № 5
Тәүфикъ Әйдигә 50 яшь. № 5
Роза Хәлиуллинага 60 яшь. № 6
Габделхәй Сабитовка 60 яшь. № 6
Гәрәй Рәхимгә 50 яшь. № 7
Флера Гыйззәтуллинага 60 яшь. № 9
Хәниф Хәйруллинга 60 яшь. № 9
Ризван Хәмидкә 50 яшь. № 10
Альберт Яхинга 60 яшь. № 11

КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — ССР ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Акъегет, Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон. № 4

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Исхаков Д. Пермь татарлары. № 8
Суыккан Т. Швеция татарлары. № 1

КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

Хәйри Ә. Корьән сүрәләре. № 8
Мулк сүрәсе. № 8
Фатиха, Нәбаә, Ән-Назигат, Габәсә, Тәквир, Инфитар, Мутаффин, Иншикакъ сүрәләре. № 9
Буруҗ, Әт-тарикъ, Әгъла, Әл-гашийә, Фәҗер, Бәләд, Әш-шәмсү, Ләйл, Духа, Иншираҡ сүрәләре. № 10
Галәкъ, Кадер, Бәййинәт, Гадийат, Тәкәсүр, Һүмәзәһ, Магун, Наср, Фәләкъ сүрәләре. № 11

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Миңнуллин Ж., Мәрдәнов Р. № 1, 3, 5

ТӨРЛЕСЕННӘН

Әхмәтҗанов Р. Борынгы мәхәббәт билгесе. № 6

ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева-Сөләйманова Г. Казан бүреге. № 5
Вәлиева-Сөләйманова Г. Корьән савыты. № 7
Вәлиева-Сөләйманова Г. Ука белән чигелгән. № 9
Вәлиева-Сөләйманова Г. Туй сөлгесе. № 10
Вәлиева-Сөләйманова Г. Чәмчәле башмак. № 12
Латыйфи Ф. Алтын кирпеч. № 8
Мөхәммәдиев Ә. Татар таңкаләре. № 1
Мөхәммәдиев Ә. Алкалы чүлмәк. № 2
Мөхәммәдиев Ә. Алтын шишәк. № 6
Татарстанның архитектура истәлекләреннән. № 3
Төрек әдәбияты классигы Юныс Әмрәнең юбилей җыентыгы. № 4
Халитов Н. Тимер бизәкләр. № 11

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан № 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12.

## КОНСТИТУЦИЯНЕ — ХАЛЫК ТИКШЕРҮЕНӘ

26 октябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев ТССР Конституция Комиссиясенең эшче группасы белән киңәшмә уздырды. Анда Яңа Конституция проектының аерым положениеләренә төгәллек кертелде. Проект өстендә эшләүне тәмамлап, аны тиз арада бөтенхалык тикшерүенә тәкъдим итү өчен матбугатта бастырып чыгарырга карар кылынды.

## ОЧРАШУЛАР ДӘВАМ ИТӘ

24—25 октябрьдә Мәскәүдә Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачевның РСФСРның дәүләт секретаре Г. Бурбулис белән очрашулары булды. Аларда Татарстан һәм Россия арасындагы мөнәсәбәтләр, үзара килешү төзүгә әзерлек проблемалары тикшерелде. Бу килешүнең конкрет мәсьәләләрен эшләү өчен хөкүмәтара төркемнәр оештыру турында килешенде. Алда очрашулар дәвам итәчәк.

## ХАЛЫК МӘГАРИФЕНӘ ЙӨЗ БЕЛӘН

Октябрь аенда Татарстан президенты М. Шәймиев һәм премьер-министр М. Сабиров халык мәгарифе вәкилләре белән очраштылар. Анда базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында халык мәгарифе өлкәсендә эшләүчеләрне социаль яклау мәсьәләләре тикшерелде.

Татарстан хөкүмәтенә бер ай эчендә халык мәгарифе хезмәткәрләренең эш хаклары һәм ставкаларын күтәрү, укытучыларның эш-көнкүреш шартларын яхшырту буенча чаралар комплексын булдыру бурычы йөкләтелде.

## ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

11 ноябрьдә Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин журналистлар белән очрашты. Ул матбугат вәкилләрен республика парламенты эшчәнлеге, анда якын арада каралачак мәсьәләләр һәм Татарстан белән РСФСР делегацияләре арасында бара торган сөйләшүләрнең кайбер нәтиҗәләре белән таныштырды.

* * *

Украин Милли Ассамблеясеннән шундый телеграмма алынды:

«Украин Милли Ассамблеясе татар халкының үзбилгеләнүе өчен гадел көрәшен яклый.

РСФСР халыкларының үзбилгеләнүе, үз дәүләтләрен булдыру, димәк, аларның РСФСР составыннан чыгуы — Россия империясен туздыруның бердәнбер юлы.

Империя юкка чыксын! Халыкларга ирек! Һәр кешегә — азатлык».

Телеграмма Украин Милли Ассамблеясе рәисе Юрий Цукевич, башкарма комитеты рәисе Виктор Мельник кул куйган.

## ТАТАРСТАН МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ— «КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ ОЕШТЫРУЧЫСЫ

ТССР Министрлар Кабинеты 5 ноябрьдә, «Казан утлары» һәм «Татарстан» журналлары редакцияләре хезмәт коллективлары үтенече буенча һәм Матбугат буенча СССР законы нигезендә, Министрлар Кабинетының «Казан утлары» һәм «Татарстан» журналларын оештыручы (соучредитель) булуы турында карар кабул итте. Журналыбыз «Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал» грифы астында чыгачак һәм оештыручыларны күрсәткәндә түбәндәге тәртиптә биреләчәк: Татарстан ССР Хөкүмәте, Татарстан Язучылар берлеге һәм хезмәт коллективы.

## МИТИНГ РЕЗОЛЮЦИЯ КАБУЛ ИТТЕ

Татарстанның «Суверенитет» комитеты 10 ноябрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда, митинг уздырды. Андагы төп мәсьәлә «Мөстәкыйль Татарстан: алда безне ни көтә» дип билгеләнде.

Митингта танылган язучылар, галимнәр, экономистлар, юристлар чыгыш ясады. Күп меңләгән халык катнашкан митинг исеменнән Татарстанның бәйсезлеген якларга чакырып, резолюция — Берләшкән милләтләр оешмасының Генераль секретарене һәм АКШ президенты Д. Буш әфәндегә мөрәҗәгать кабул ителде.

## ТАТАРСТАННЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

ТССР Министрлар кабинеты җөмһүриятебезнең В. И. Ленин исемендәге китапханәсенә Милли Китапханә статусын бирү турында карар кабул итте. Карарда әйтелгәнчә китапханәнең хокукларын, вазифаларын тагын да киңәйтү, эшчәнлеген камилләштерү, аны милли мәдәниятне,

миллэтара аралашуны үстерү үзэгенэ эверелдерү кузда тотыла. Анда шулай ук Татарстан ССР Мэдэният министрлыгына 1991—95 елларда Милли Китапханэне үстерү программасын эшлэү һэм тормышка ашыру бурычы йөклэнэ.

## БУЛЭКЛЭР ТАПШЫРУ

Татарстан ССРның бүелгы Г. Тукай исемендэге Дэүлэт премиялэренэ — татар китабы тарихын яктырткан мэгълүм хезмэтлэре өчен язучы һэм галим Эбрар Кэримуллин, «Илле җыр» исемле китабы өчен шагыйрэ Гөлшат Зэйнашева, симфония-поэмалары өчен композитор Алмаз Монасыйпов лаек булганнар иде. 4 октябрьдэ ТССР Министрлар Кабинетында аларга Почетлы диплом һэм билгелэр тапшыру тантанасы булды. Аларны ТССР Премьер-министрының беренче урынбасары, Г. Тукай исемендэге Дэүлэт премиялэре комитеты рэисе М. Хэсэнов тапшырды.

## МИРХЭЙДЭР ФЭЙЗИНЕҢ ОЛУГ ЮБИЛЕЕ

28 октябрь көнне Г. Камал исемендэге Татар дэүлэт академия театрында классик драматургыбыз Мирхэйдэр Фэйзинең тууына 100 ел тулуга багышланган зур кичэ уздырылды.

Аны кереш сүз белэн ТССР Премьер-министрының беренче урынбасары М. Хэсэнов ачты. Эдипнең тормыш һэм иҗат юлы турында доклад белэн ТССР Язучылар берлеге идарэсе рэисе Р. Мөхэммэдиев чыкты. Театрның баш режиссеры М. Сэлимҗанов М. Фэйзи иҗатының татар театры тарихында тоткан урыны турында сөйлэде. Кичэнең икенче өлешендэ театр артистлары тарафыннан эдипнең атаклы «Галиябану» драмасы буенча куелган спектакль күрсэтелде.

Кичэдэ ТССР вице-президенты В. Лихачев һэм ТССР Премьер-министры М. Сабиров катнашты.

## ЯҢА МИЛЛИ ОРКЕСТР

ТССР Телевидение һэм радиотапшырулар дэүлэт комитеты каршында ор-яңа милли оркестр оешу уңаеннан Г. Камал исемендэге Татар дэүлэт академия театры бинасында зур концерт-презентация булып узды.

Җөмһүриятебездэ мондый оркестр оешу — халкыбыз тормышында күптэн көтелгэн, «Шэрык» клубы эшлэгэн чордан бирле музыкантлар хыялында йөргэн зур вакыйга ул. Оркестрны оештыру эшендэ талантлы дирижер Рөстэм Үтэй эфэндемең хезмэте зур: сэлэтле музыкантларны сайлап алуга да зур көч куйган. Концертта Рөстэм эфэнде үзе, танылган диктор Лия Заһидуллина, ТССР Телевидение һэм радиотапшырулар дэүлэт комитеты рэисе И. Хэйруллин һэм радиокомитетның олкэн мөхэррире Р. Ильясов оркестрның туу тарихын халыкка җиткерсэлэр, сэнгатебез йолдызлары З. Сөнгатуллина, В. Гыйззэтуллина, З. Сэхэбиева, Х. Бегичев һ. б. җырчылар С. Сэйдэшев, Н. Җиһанов, Р. Яхин һэм башка композиторларыбыз эсэрлэрен зур осталык белэн башкардылар. Элбэттэ, җырларның тамашачы йөрэгенэ юлы бу кичэдэ элеге милли оркестр ярдэме белэн иде. Нэтиҗэдэ, гаҗэеп гүзэл бер кичэ халкыбыз тарихына кереп калачак. Хэерле юлга, яшь һэм яңа оркестр!

## ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

Татар театр сэнгатен тагын да үстерү, яшьлэр арасында иң яхшы драма эсэрлэрен пропагандалау максатыннан һэм Татарстан ССР Югары Советы карарын үтэү йөзеннэн, Татарстан ССР Министрлар Кабинеты ТССР Халык мэгарифе министрлыгы каршындагы татар театр студиясе базасында Казан яшь тамашачы татар дэүлэт театрын ачу турындагы тэкъдимне кабул итте.

## БӨЕК ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

ЮНЕСКО 1991 елны бөек төрек шагыйре Юныс Эмрэ елы дип игълан иткэн иде. Шагыйрь иҗаты яктырткан сэхифэ «Казан утлары» битлэрендэ дэ урын алды. Октябрь аенда, элеге олуг шэхеснең тууына 700 ел тулуга багышлап, Казанда да кичэ үткэрелде. Ленин мемориалы дип йөртелгэн бинада узган бу дуслык һэм шигърият кичэсендэ, күренекле эдиплэр белэн бергэ, башка җөмһүриятлэрдэн килгэн кунаклар да чыгыш ясады.

## ЖУРНАЛ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ЯНЫНДА

Самарада татар теленде чыга торган «Бердэмлек» газетасы үзенең бэйрэмен уздырды. «Металлург» комбинатының Мэдэният сараенда булган тантаналы кичэгэ Татарстаннан да кунаклар — эдиплэр, журналистлар чакырылган иде. «Казан утлары»ннан бу бэйрэмдэ язучы Мэгъсүм Хуҗин катнашты, журналыбызның килэчэккэ планнары, җөмһүриятебез хэллэре белэн таныштырды. Эдип шулай ук Самара телевидениясе аша татар телендэ турыдан-туры элемтэ тапшыруында да катнашты һэм Казан матбугаты, Татарстан турындагы сорауларга җавап бирде.

* * *

Шундый ук кичэлэр Ульяновск (Сембер) шэһэрендэ дэ узды. Телевидение аша җанлы эңгэмэдэ һэм журнал укучылар белэн эдэби очрашуларда журналыбыздан шагыйрь Шамил Маннап та катнашып, килэсе елда басылачак кызыклы эсэрлэр һэм үз иҗаты белэн таныштырды.

# ЧӘМЧӘЛЕ БАШМАК

Журнал тышлыгының беренче битендәге сурәткә игътибар иттегезме? Тагын да бер күз салыгыз әле! Сезнең алда татар халык сәнгатенең күнгә ясалган, башка бер генә халыкта да очрамый торган, дөнья күләм данлыклы, кабатланмас үрнәге. Бу — ир-егетләр өчен иҗат ителгән аяк киеме. Сәхтиян күннән чәмчәләп тегелгән һәм чигелгән бу башмаклар, ука белән чигелгәнлектән, аеруча затлы вә кыйммәтле санала. Сүз дә юк, мондый башмакны кигән ир-егет әллә каян игътибарны үзенә җәлеп иткәндер... Бер дә юкка гына бу аяк киемен Санкт-Петербургта 1901 елда ук ачылган этнография музеенда сакламыйлар инде. Анда ука белән чигелгән, асылташлар белән бизәлгән, безнең осталар иҗат иткән сәхтиян читекләр дә бар. Аны татар сәүдәгәрләре Александр III патшага бүләк иткән булган...

Шул вакыйгаларны күздә тотканда, әлеге сурәттәге башмаклар XIX йөзнең икенче яртысында эшләнгән, диярга мөмкин. Әмма мондагы үрнәкләрнең төзелешен, чәмчәләү үзенчәлекләрен ныклабрак өйрәнсәң, әсәрнең XVIII йөз азагы яки XIX йөз башына каравы ихтималын да күрергә була. Башмакларның кыяфәте, купшылыгы, ялтыравыклыгы аларның патша галиҗәнаблары даирәсе өчен әзерләнүен раслый. Башка аяк киемнәренә караганда болар үзләренең кабатланмас булулары белән аерылып тора. Шулай да бизәкләр һәм чәмчәләү ысулы аның бары тик татарныкы гына икәнлеген бик ачык күрсәтә.

Нәрсәдә соң моның аерымлыгы? Төп кулланма итеп алынган күнгә икенче төстәге күннән бизәк ябыштыру, ягъни аппликация ысулыннан аермалы буларак, татарлар бизәкне сурәт урыны киселгән ачык җиргә куялар һәм аны төп нигезгә, ябыштырып түгел, ә тоташтырып — чәмчәләп, чигеп беркетәләр. Чәмчәләп чигү өчен нык ефәк җеп, көмеш яки ука җеп алына. Күннең исә иң йомшагы, сәхтиян дип аталганы сайлана. Андый күнне: «Май кебек!» — дип, аеруча мактап йөрткәннәр.

Күнне бизәкләп кисүче осталар, пычакны туры тотып, аның сабын иякләренә терәп, гаҗәеп могҗиза тудырганнар. Алар тегеләчәк аяк киеменең нинди булачагын, чәмчәләүчеләрнең ничек эшләвен — барысын да күз алдында тотканнар. Сәнгать әсәренә тиң башмакларның нинди булачагын алдан күрү аларга дәрт өстәгән. Шунлыктан бу осталар һич тә авырсынмаганнар. Алар бит буыннан-буынга, ата-бабадан шул һөнәргә өйрәнеп үскән.

Казан татарлары сәнгатенең бу төренә караган кайбер якларны безнең чорга кадәр V—IV гасырларда яшәгән таулы-алтай кабиләләренең иҗат үрнәкләрендә дә очратырга мөмкин.

Инде журнал тышлыгындагы башмакларга кабат күз салыйк. Алар бары тик татар аяк киеменә генә хас өлге буенча тегелгән. Башка халыкларныкыннан, әйтик, урыс аяк киеменнән аермалы буларак, алар ике өлешкә: алгы һәм үкчә якларына бүленеп тора. Бизәкләү җәһәтеннән исә бу башмаклар аерым игътибарга лаек.

Башмакларның зәбәрҗәт төсендәге җирлегенә алтынсу сары һәм ачык кызыл бизәкләр чәмчәләнгән. Үрнәкләрнең чикләре ука белән чигелгән. Укалы җөйләр күннең иркен мәйданнарына да чыгып-чыгып китә. Монда төрледән-төрле үрнәкләр бар: җил уңаена бөгелгән яфраклар, каурыйлар, йөрәк сурәтләре... Үзәктә — кояшка ишарәләүче рәсем. Монысы табигатьнең төп көчен тасвирлый.

Үрнәкле чәмчәләүче үзәк җөйләр күзгә аеруча нык ташланып тора. Моның сере гади: күнне вак-вак сурәтләргә кискәләү авыр, әсәрнең гомуми мәгънәсен аңлату өчен эре бизәкләрдән файдалану отышлырак саналган.

Әлеге башмакны иҗат иткән кеше бу төр сәнгатьнең остасы булгандыр, мөгаен. Аның бу әсәренә тиң аяк киемнәре дөньяның төрле тарафларында популярлык казанган. Мондый ысул белән чәмчәләнгән башмаклар, читекләр урыс дворяннарының да иң кадерле киемнәреннән саналган. Төркестан, Себер, Урал халыкларында аларны бик кадерләп йөрткәннәр. Көнбатышта да аларга сокланып караганнар. Мондый аяк киемнәре Париж, Чикаго, Копенгагенда уздырылган халыкара күргәзмәләрдә дан тоткан. Татарның бу төр сәнгате хәзер дә югалып калмасын иде!

Гүзәл **ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**,
сәнгать белгече.

Тышлыкның дүртенче битендә: танылган шагыйрь Мәхмүт Хосәен.

Юрий **ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 1 сум 50 тиен.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог